
# КАЗАН УТЛАРЫ

10.1995



# ЯҢА ГАЗЕТА — ЯҢА ДУС




Татар матбугаты дөньясындагы зур бер вакыйганың шаһите булдык: шушы елның июль аеннан «Мәдәни җомга» исемле атналык газета чыга башлады. Һәр атнаның җомга көнендә 24 битле булып чыга торган бу басма республикабызның әдәбият һәм сәнгать тормышын даими яктыртуга, шулай ук тел, әхлак, тәрбия, дин, уку-укыту, сәясәт, фән, тарих, рухи мирас, милли мәсьәләләрне яктыртуга хезмәт итәчәк. Аның битләрендә проза һәм шигърият әсәрләре дә киң урын алачак.

Газетаның индексы — 54129.

Баш мөхәррире — Зиннур Мансуров.

Атналык басма үзенең күпсанлы укучыларын табар һәм әдәбият-сәнгать сөючеләрне яңа сәхифәләре белән куандырыр дип ышаныйк.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(876)**

**1995**

КАЗАН

*Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ф. ЯХИН. Август ае. *Роман.* ........ 3
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Кыялар моңы. *Поэма.* ........ 54
Ф. ӘМӘК. Вакытында әйтелгән сүз. *Шигырьләр.* ........ 111
Г. САТТАР-МУЛИЛЛЕ, Ф. МОРТАЗИН, Р. ЖАМАЛ, И. БИЕКТАУЛЫ, Ф. ГАТИНА, Ч. МУСИН, Р. МӘННАН шигырьләре. ........ 114
Б. КАМАЛ. Яшьлеккә хыянәт. *Хикәя.* ........ 125

ЖӘҮДӘТ ДӘРЗАМАНГА 50 ЯШЬ

Ж. ДӘРЗАМАН. Иң зур хикмәт. *Шигырьләр.* ........ 61

ДРАМАТУРГИЯ

Р. МИНГАЛИМ, Р. ХӘМИД. Идегәй. *Нәфис фильм өчен драма.* ........ 67

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ЮНЫС. Гасабилы уйлар. ........ 140

ӘДӘБИ МИРАС

М. ГОСМАНОВ. Гаяз Исхакый: «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм патша цензурасы *(Иҗатының яңа сәхифәләре ачылу).* ........ 152

МӘГЪСУМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Ак теләкне җилкән итеп. ........ 182

Безнең календарь. ........ 189
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,
бухгалтерия — 53-36-12.

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Ф. ЯХИНА «Месяц август», рассказ Б. Камалова «Измена юности»; поэма Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, стихи Ф. АМАК, Г. САТТАРОВА, Ф. МУРТАЗИНА, Р. ДЖАМАЛ, И. БИЕКТАУЛЫ, Ф. ГАТИНОЙ, Ч. МУСИНА, Р. МАННАНА.
«К 50-летию Дж. Дарзаманова»: стихи Дж. ДАРЗАМАНОВА.
«Драматургия»: драма Р. МИНГАЛИМА и Р. ХАМИД «Идегей».
«Публицистика»: статья М. ЮНЫСА. «Неспокойные мысли».
«Литературное наследие»: статья М. УСМАНОВА «Гаяз Исхаки: «Исчезновение через двести лет» и царская цензура.
«К 70-летию М. Насыбуллина»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА о творчестве М. Насыбуллина.
Наш календарь
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Шамаил Ф. Гирфанова; известный писатель М. Насыбуллин.

## In our issue

«Prose and poetry»: the beginning of Ph. Yakhins novel «August», B. Kamalov's story «Treason of youth», Ph. Gizzatullina's poem, the verses of Ph. Amak, G. Sattarov, Ph. Murtazin, R. Iamal, I. Biektauli, Ph. Gatina, Ch. Musin, R. Mannan.
«To the 50 th anniversary of I. Darzaman»: I. Darzaman's verses.
«The drama»: R. Mingalim's and R. Khamid's drama «Idegei»
«Publicism»: M. Yunis's article «Uneasy thoughts».
«Literary heritage»: M. Usmanov's article «Gayaz Iskhaki»: Disappearance in two hundred years» and tsar's censorship».
«To the 70th anniversary of M. Nasibullin»: Ph. Galimullin's article about the creative work of M. Nasibullin.
«Our calendar»
«The diary of the social and cultural life».
In our corvers: Shamail. The author is Ph. Girphanov, the well-known writer M. Nasibullin.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Марсель Гали, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 6.09.95 ел. Басарга кул куелды 13.10.95 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 7 984. Заказ Д-460.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

## Чәчмә әсәрләр



**Фәрит Яхин**

# АВГУСТ АЕ

РОМАН

1

Әллә ничек кенә үтә дә китә икән бу тормыш. Кичәгесе бүген онытыла, иртәгәгә әллә никадәр уй-хыяллар җыела, таң белән торып, эшкә тотынырга туры килсә дә, барып чыкмый. Коры хыяллар, мескен акыл аркасындадыр, гомерең буе озатып йөриләр-йөриләр дә, яшәешең арбасыннан төшеп калалар. Иркенәеп, үзалдыңа канәгатьлек табып, еллар белән бергә авышасың һәм, башыңны Кәгъбәтулла тарафына юнәлтеп, тынлык хөкеменә чумасың. Ә кайдадыр, еракта-еракта, галәм читендәме, йолдызлар белән йолдызлар сөйләшәләрдер, синең тавышыңны да ишетеп алалардыр? Ышанасы килә. Юк-юк, ышанычсыз һич тә ярамый. Җиһан ул очсыз-кырыйсыз.

— Ә син шикләнәсеңме?

— Ышанмаска, ди, ышанам. Шунлыктан һичбер шигем дә юк!

— Шикләнмичә мөмкин түгел бит.

— Бәлки мине дивана дип уйлыйсыңдыр. Әмма күңелемдә һичбер шигем юк. Шуңа сөенәм.

Ханбал аз гына булса да ялганлый иде бу җавапларында. Хәниф моны сизенмәде. Дөресрәге, аңламады. Сорауларын кабатларга да уйлаган иде. Мәгънәсе генә күренмәде. Әле кайчан гына үзен коммунист санап, Маркстан да, Лениннан да тезмәләр китерергә яраткан Ханбалның дингә кереп китүе сәер түгел идеме? Юк, шикләнәдер, ышанмаган җиреннән ничек кыйбла тапты соң ул?

Һәркемнең яшәеше терәк эзли. Ханбал да шушы хакыйкатьне төшенеп алган кеше. Әгәр дә бүгенге көндә мәктәп басмасыннан башланган, күңелгә салынып ныгытылган, хакыйкать дип табылган кануннар таркала һәм юкка чыга икән, аның монда ни гаебе бар? Үзгәрергә кирәк булгач, бер урында таптану бик үк килешеп бетмәс. Малайлык күрсәткәндәй киреләнеп торудан ни файда? Яшәсәң, үләргә ашыкма инде син. Җитешерсең. Көнең-көнгә охшаса, бетте инде ул, сүндең, дигән сүз.

Менә бу чаттан аерылыша алар. Ханбал үз юлы белән китеп барачак, Хәниф, уңга борылып, элекке Жданов урамы буйлап өенә юнәләчәк. Тиздән генә очраша да алмаслар. Ханбал иртәгәдән ялда. Һәр елны бер үк вакытны сайлый. Яме сүнеп барган табигатьнең август аен. Һавасы да саф, шәһәр халкының да, канәгатьлек табып, болын-кырлардан, су буйларыннан читләшкән чагы.

— Ярый, исән-имин генә ял итәргә насыйп булсын!

— Рәхмәт, дустым! Сиңа да исәнлек-иминлек телим!

— Әллә соң, берәрне, мин әйтәм, алып «бөклибезме»?

— Юк, эчмим. Аракыдан башка гына ял итәргә исәп.

— Алай күңелсез булмасмы соң?

— Бәлки... Юк! Аракы үзе тәннәрне оета-арыта бит ул. Аннан башка гына ял итәрмен инде, бигайбә! Ялыңны юмадык, дип уйлап ачуланма, бүтән вакытта, ярыймы!

— Юдык дип исәплә!

— Ярый, хуш! Күрешкәнгә кадәр!

Каты кысышып кул бирештеләр. Үз юллары белән китеп барганда Ханбалның башына шик төште: «Кул биреп саубуллашырга ярамый бит, бүтән тиз генә күрешмисең, диләр!»

Фалы дөрескә чыкты.

## 2

Ханбал ялының өченче көнендә, ялгыз фатирында китап укып ятудан тәмам туеп, телевизор-радионың тимер авызларыннан чыккан җансыз сүзләре-тавышларыннан арып, тере кешеләрне сагына башлады. Эшенә барып килергә уйлаган иде дә, бу фикереннән тиз кайтты. Аңа анда ни калган? Болай да ел әйләнәсендә туйдырып бетерәләр, шул Зәнфирәне генә күреп кайтса инде. Кирәкмәс, лаборанткалар белән нишләп чуалып йөрсен ул? Берәр чибәр кыз белән танышырга да тормышны җайларга кирәк.

Ханбал Вәлиев буйдак ир иде. Казандагы Дәүләт архивының фәнни хезмәткәре сыйфатында гомерен уздырып, кооператив фатир алуга ирешкән, хезмәттәшләренең фикеренчә, бик бәхетле иде. Хәниф аның буйдак булуыннан көнләште. Кичкә калып эшләргә яки бәйрәмгә җыелышырга туры килсә, һаман да бер сүзен кабатлап:

— Син бәхетле, соңарган өчен колак итеңне ашарга хатының юк! — дип куя иде.

Ялгызлыкта яшәүнең тагын да икенче рәхәтен татый Ханбал: хатын-кыз каршында сөекле ул! Йөз-биттә фәрештә сыйфатлары булмаса да, төшеп калганнардан да түгел шул. Холкы да күркәм. Сугышып-нитеп йөрми. Буйга да ару гына. Тик бераз диваналыгы гына бар. Ансы да зыянлы түгел. Бик яшьли гашыйк булып, шуннан калган истәлек кенә: шагыйранәлек, хатын-кызчалык кебегрәк.

Шулай итеп, Ханбал Вәлиев ел әйләнәсенә бер генә тапкыр бирелә торган ялга чыгып, аларның алдагы өч көнен йокы һәм китап уку белән уздырды. Казан елгасы буена төшеп, арка кыздырырга тиеш иде ул. Әмма көннәре, яман да усал вә бозык карт хатынның йөзе кебек, ямьсез иде. Төньяктан искән салкын җил яңгыр да, кар да алып килмәде, әмма күк йөзе салынып торган болытлар белән каракучкылланган, күзгә тартым. Кояшның әсәре дә күренми. Әллә табигать саташкан, әллә бәндәләрнең олуг гөнаһлары бар, белмәссең.

Радиодан иртәгә-берсекөнгә матур көннәр булачагын хәбәр итеп тынычландыралар. Бәлки? Ышанасы килә Ханбалның. Туган якларын да бер әйләнеп кайтасы килә. Җәлил каласын. Анда аның апасы, абыйсы яшәп яталар. Елга бер, шулай ялга чыккач, Ханбал күрешергә кайткалый торган иде. Быел нәрсәгәдер аягы тартмый. Юл хакы да кыйммәт.

Бозылып бетте замана. Тормыш авырлашканнан-авырлаша бара, кибеткә керсәң, әйбер сатып алырлык түгел, бәһаләрен күрсәң, күзең маңгайга йөгерә. Алып-сатарлар белән дөнья тулды. Завод-фабрикалар эштән тукталдылар. Инфляция. Дәүләтенә дә ышаныч калмады. Әле бер фирка мәйданга бәреп чыга, әле икенчесе. Һәммәсе халыкка олуг бәхетләр, рәхәт тормыш вәгъдә кыла. Әмма һичнәрсә үзгәрми, ватыла башлаганы тәмам җимерелеп бетә бара, оеша дигәннәре ярты юлда таркала. Халыкка вакытында хезмәт хакын да бирә алмыйлар. Җитте заманалар, ахырга килеп терәлде.

Кухня ягының диварына ярым авыш хәлдә эленеп торган радиосы телгә килеп, китап укып яткан Ханбалны сискәндереп җибәрде. Яңалыклар тапшыралардыр. Аларына да ышанып бетеп булмый. Матурлап сөйләгән генә булалар. Кая барсыннар инде? Анда эшләүчеләрнең балалары, тормышлары үзләренә, дигәндәй, хезмәт итәләр инде, өстәгеләрнең итәкләреннән чүп кагалар. Әмма каккан тузаннары авыр ташлар рәвешенә килеп, астагы мескен халык башына төшә. Аһ-ваһ, аһ-ваһ! Яшәү кыенлаша, имеш, социаль яклау кирәк, имеш. Кемнән? Чат саен утырган алып-сатарданмы? Әллә инде ясак өстенә ясак салучы дәүләттәнме? Әгәр дә менә шул ясаклардан коткармый, арындырмый икән, нинди социаль яклау хакында сүз була ала? Кызык инде, ә? Бер кулы белән мескен халыкка санап кына бирә дә, икенчесе белән учлап диярлек каерып ала. «Тамагың тукмы, өстең бөтенме?» — дип сорамый. Юк, гафу, сорый икән әле, бик сорый. Тикшереп караны ул аның, әле тагын нинди сынауларга түзә ала икән бу халык-сарык, дип уйлыйдыр.

Ханбал кичә кич подъезд төбенә чыгып утырган иде. Күршесе, бишенче катта яшәүче кечкенә буйлы карт — юантык урыс, аның янына килеп сыланды да сөйләштерә башлады. Гел юк-бар хакында инде. Бушка вакыт уздыру. Ханбал шулай да әңгәмәгә катышып китте. Шунда ул Федор дәдәй әйтеп салмасынмы:

— Йә, ничек, суверенитетыгыз барып чыктымы? Тормышлар яхшырдымы?

Урысның тел төбендә мәкер ята икән. Әле былтыр-өченче еллар гына бу тема шактый куертылгач, шушы Федор дәдәй аның белән бәхәсләшеп алган иде. Рәсәйдән башка беркая да китә алмыйсыз сез, дип теге хәтта кистереп тә куйган иде. Һаман шул җырын җырлый икән. Урыс урысныкын сөйләр инде, кемнекен тәкърарласын ди ул. Үз туны үз тәненә якын. «Үзем өчен куркасы юк, улым-кызым зур кешеләр, Рәсәйдә яшиләр», — дип сөенә иде бу картлач. Ни өчендер күчеп китмәде шул, китәргә теләмәде. Ул вакытта, бәхәсләшкән чакларында, Ханбал да үзенә әйтә килде:

— Федор абзый, үз илегезне яратасыз икән, мин каршы түгел, әмма миңа да үз ватаным кадерле. Мин аның азат булуын, суверен булуын телим...

— Ә безгә, монда яшәүче урысларга нишләргә? — дип хафага төшә иде ул. Үзен генә ярата белә торган халык кына мондый сүзләрне әйтә ала. Әмма Ханбал элегрәк аның бу соравына бик колак салмады. Картның артык хафага калуын күреп, аңа, соңгы әңгәмәләрендә, соравына сорау белән җавап бирә башлады:

— Әмрикәдә урыслар ничек яши соң?

Моңа, әлбәттә, Федор абзыйның артыгы белән ачуы килеп, без урысларны басалар, мыскыл итәләр, Татарстаннан куалар, дигән сүзләргә ябыша иде. Ханбал, теләмәсә дә, дошманның серен төшенim дигәндәй, «Вечерняя Казань» газетасын укыштыргалап торды. Үзе, дуслары арасында шаярткалап бу газетаны «Вечерняя казнь» дип атый, әмма теге яки бу мәсьәлә хакында язганнарын күңелдән сөйләп биргәли иде. Иптәшләре, хезмәттәшләре арасында берәүләр аны милләтчегә саныса, икенчеләре, киресенчә, артык ваемсызлыкта, милли хәрәкәтләрдә катнашмауда гаепләделәр. Әйе, Ханбал Вәлиевне алар көрәш мәйданының читендә

торып күзәтүче дип беләләр иде. Хәтта аның хакында шаяртып кына бер мәзәк тә сөйләштергәләп йөрделәр. «Имеш, халык, мәйданга агылып, шау-шөр килеп, митинглар уздыра, хөкүмәткә каршы зәһәр сүзләр ычкындыра. Ханбалга — кызык, урам почмагына басып тыңлый. Берәү килеп сорый моннан: «Болар нәрсә эшли?» Ханбал аркылысын-буйга үлчи дә, бу абзый берәр олы кешедер, хөкүмәттәндер, дип нәтиҗә чыгарырга өлгерә һәм җавап та бирә: «Безне ачуланалар!»...

Мәзәк дигәннән, ул, чыннан да, дөреслеккә туры килә, шаяртудан бигрәк, ачы тәнкыйть сүзе иде. Шулай да хезмәттәшләре арасында Ханбал милләтче буларак та, шовинист сыйфатында да танылмады. Ул, нәрсә булса — шул ярый, дип фикер йөртүчеләрдән иде. Аның өчен барыбер, арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит, дигәндәй, дәүләт башына менеп идарә итәсе юк, кая ашкынырга!

Федор абзыйның: «Йә, ничек, суверенитетыгыз барып чыктымы? Тормышлар яхшырдымы?» — дигән сорауларына каршы кичә кич әйтте дә салды:

— Саттылар безнең суверенитетны, саттылар. Урыслар үзләре дә Рәсәйләрен энәсеннән-җебенә кадәр саттылар. Хәзер татары-урысы барысы да бер хәлдә...

Ханбалның шушы сүзләрне әйтүе булды, Федор абзыйның йөзенә шатлык нуры иңде, сөенде карт, бик сөенде һәм тезеп китте:

— Әле кичә генә, юк, элгәре, минем Марфа китап кибетенә кергән. Үзең беләсең, туалет кәгазе кыйммәт. Марфам йөге белән китап алган, сиксән сумга бит бары. Марксын да Ленинын да. Тормышлары хакында, беләсеңме? Укыйм да боларны, кабат актарам. Бигрәкләр дә акыллы кешеләр булганнар инде. Фикерләре нинди!..

Федор абзый шактый озак сөйләнде дә сөйләнде. Социализм корган, ленинча яшәгән бу бабайның гомере ахырында гына Маркс белән Ленинга мөрәҗәгать итүе, бәрдәфкә кергәндә генә аларны һәм алар хакында укуы Ханбал өчен бик тә сәер иде. Бу да коммунизм төзибез дип авыз тутырып сөйләп йөргәндер инде. Балаларын да олы җирдә эшлиләр, ди бит. Булыр-булыр. Шулар таркатып вә таратып бетергәннәрдер дә инде. Белми генә торгандыр әле үзе. Минем белән ачуланышып утырганчы, балаларын тикшерсен иде дә аларны утлы табада тотып карасын иде. Ханбал шулай уйлады, әмма ихлас күңелдән сөйләнеп утырган картны сүзеннән бүлдерергә кыймады. Эһе-эһе, дигән кебек баш кына селкетүен белде. Әмма татарларның суверенлыгын югалтуы белән үзе татар буларак бер дә килешәсе килмәде, хакыйкатькә каршы күңеле тартышты.

Кичкә таба күк йөзе бераз ачылып, көн дә җылынып киткәндәй булганлыктан, Ханбал су буйларын, Казан елгасы ярларын бераз урап кайтырга ниятләде. Федор абзый подъезд төбендә утырмыймы, дип тәрәзәдән күз ташлады. Ул урыс белән бер дә тел әрәм итеп маташасы килми иде аның.

Урын-җирен тарткалап рәтләштергәләде дә, китабын үзе белән алыргамы-юкмы дип уйлап бераз торганнан соң, аны язу өстәлендә калдырып, җәһәт кенә ишеккә юнәлде. Нәкъ аны гына сагалаган диярсең, картлар кия торган калын күзлеген маңгай тиреннән саргая башлаган кулъяулыгына сөртә-сөртә, ярты гәүдәсе белән таягына таянган, кичәге зәңгәр эре шакмак күлмәгеннән баскычта Федор абзый басып тора иде. Лифт эшләмәгәнлектән, подъезд төбенә төшеп килүе икән. Ханбалны күрүгә, күрешергә дә онытып:

— Менә бит ничек безнең илләр...— дип сүз куертырга гына маташканда, коты очкан буйдак, нәрсә эшләргә дә белмичә, җәтмәгә эләккән кош төсле, артка-алга тартылды да:

— Федор абзый, вакыт тар...— дип, баскычтан аска ташланды, бераз ераклашкач кына, исәнләшергә дә оныткanлыгын исенә төшереп: «Дөрес эшләмәдем бугай?» — дип үкенеп тә куйды. Картлачның, чыннан да, гаебе юк иде. Кичә Ханбал тыңлап кына утырып дөрес эшләде, нигә

бәхәсләшергә. Сүз куертудан, фикер алышудан Федор абзый кебекләргә файда булса, дөньяда гел бәхетле кешеләр генә яшәр; авырулар да, борчулар да булмас иде.

— Кая ашыгам әле? — дип акрынаерга мәҗбүр булды Ханбал. Гүя, кыз янына очрашуга йөгергән егет диярсең үзен, башы-күзе әйләнгән, кем көтеп торсын ди аны, кемгә керәге бар?

## 3

Федор Зайцев, гомере буе заводта слесарь булып эшләгән, әмма хезмәте белән дә, акылы ягыннан да игътибарга лаеклы саналмаган Тау ягы урысы иде. Казанлылар Тау ягы дип Идел артындагы Югары Ослан районын атыйлар. Ләкин, Арча ягындагы Биектау аталган бер төбәк күпләрне Тау ягы дигән чагында саташырга мәҗбүр итә. Тик бу якны шул ук казанлылар икенче төрле атый һәм үзләренең ышаныч урыны санап, Казан арты дип йөриләр. Ераграк җирләрдән килеп монда төпләнгән килмешәкләр боларны белеп бетерми, хәтта урыслар да аңлашмыйча кала. Әмма татарлар, үзара сөйләшкән вакытларында һаман да шушы төшенчәләрне кулланып, бу мәгънәләрне сер урынына саклыйлар. Шунлыктан Федор Зайцев, чәчләренә ак төшкән, урта буйлы, гомергә үзен татар хәйләсеннән шикләнеп яшәргә мәҗбүр иткән кеше буларак, бу «серләрне» яхшы ук белә вә төшенә иде. Ул электән үзен җирле халык теленә күнектереп, сөйләшер дәрәҗәдә үк саналмаса да, аңлап калырлык рәвештә татарчаны белә диярлек иде. Дөньялар буталып киткәч, гел дә радио-телевизордан татар тапшыруларына колак салып:

— Менә нишлиләр бит, симерделәр! Сталин җитешми үзләренә, — дип, хатыны алдында усал-усал сүзләр белән җирле халыкны җиргә орып таптый, ачулана торды.

Хатыны Марфа исә гомере буена китапханәдә эшләп, мөдирлектән ахырга таба идән юучы дәрәҗәсенә төшерелсә дә, татарларга карата әллә ни усал сүзләрне кулланмый, иренә дә: «Алар да кеше инде!» — дип әйткәләп куйгалый иде. Аның ул гыйбәрәсе Федор абзыйны кузгата, ачуын кабарта. Шунлыктан үзен-үзе тыя алмас дәрәҗәгә җитеп:

— Акылың кыска булды синең! Исеңдә түгел мени? Мөдирлектән идән юучыга кем төшерде үзеңне? Шулар, шулар булмый ни, татар хатыны директор булып килде. Беренче итеп сиңа бәйләнде. Начар эшли идеңмени?

Марфа сер бирмәде. Гомумән, алар гомерләре буена фикерләрен ахыргача бүлешеп яшәмәделәр. Иренең коры һәм аю табанлы бер нәрсә булганлыгын яхшы белгәнлектән, күңелендәгең һич тә ачып салмый иде ул. Бер-бер нәрсәне төшенеп алса, җанын ашаганлыктан, нәрсә өчен сер бирсен, ди, әле? Матур иде, чибәр иде кайчандыр Марфа түтәй. Авылдан Казанга яшьлек юлләрлеге белән күченеп килмәгән булса, әллә кем итәрләр иде үзен. Һай, ничек йөрде аның артыннан Самуил, унбиш чакрымнан ук җәяүләп тә, атка атланып та килеп җитәр иде, мескенем. Карлыгач кашлы, кылыч борынлы, чандыр бу татар егете, гүяки, аның бәхете өчен генә күкләр тарафыннан яратылып, аларны махсус рәвештә район слетында очраштырган иде. Шундук бер-берсенә мөкиббән киттеләр. Әллә нишләде Марфаның йөрәге. Өзелепләр генә китте инде. Башы дингез суы кебек тора салып шаулап куйды. Егыл да үл генә инде. Самуилның маңгай чәчләренең бөдрәсен сыйпый-сыйпый иркәлисе килде. Сораштыра башлавына, бер сүзен җавапсыз калдырмады. Урыс телен аның вата-җимерә сөйләүләренә дә исе китмәде, сандугач тавышларын хәтерләткәндәй иде һәрбер әйткәне. Булган икән ул, булган гомеренең бәхетле чаклары. Килә иде бит, килә иде. Унбиш чакрымнарны исе дә китмәстән

җәяүләп килеп җитә иде. Ә бу Федор, белмим, кайдан очрагандыр газиз башына бәла иттереп? Белми шул барсын да. Исмаил бит әле? Самуил дип әйттертә иде үзен.

— Нигә алай? — дип сорагач:

— Урыс теле укытучыбыз, сезнеңчә менә шулай була исемең, дип өйрәткән иде, күңелемә кереп калган, матур яңгырый бит, — дия торган иде, аңлатып. Егет тә иде соң үзе.

Әгәр дә колхоз утарында янгын чыгып, өстенә нахак сүз әйтеп, авыл урамына да кермәс итмәсәләр, Марфа гомерлеккә аныкы буласы иде. Язмыштыр. Таң белән озаткан иде үзен, юлда милициягә очраган бит, икмәк каракларын сагалап йөриләр икән. Басуны ярып чыкмасынмы, мескенкәем. Кесәсенә бераз арыш башы да уып салган булган. Житмәсә аның артыннан ук авыл ягыннан ут ялкыны да күренгән. Тотып бәйләп китерделәр үзен.

— Шушымы? — диләр, халыкка күрсәтеп. — Ул гына чыкты сезнең авыл ягыннан, аның гына эше.

Аһ, ничек бәргәләнде Марфа, милициянең алларына тезләнердәй булып ашкынды. Әмма сакаллы авылдашлары:

— Татарыңны яклыйсы итмә, башыңа житәрбез, Христос дошманы! — дип кенә өркеттеләр. Башкача нәрсә кала? Буйсынды шул, буйсынды. Әллә ничек кенә жиңелде. Бирешмәскә иде. Бәхетен ятларга калдырмаска иде дә бит. Язмыштыр инде, язмыштыр.

— Ул түгел бит, ул түгел! — дипләр карады. Кемдер, арттан килеп, ике җилкә арасына каты гына сукты. Марфа үзенең тулып пешкән гәүдәсен тотып кала алмады, тузанлы җиргә ауды: «Ул түгел бит!» — дигән үтенечле өне генә күнитекле табаннар астында калды.

Самуилны Казанга алып киткәннәр. Марфаны урын-җиргә кайтарып салганнар. Төннәр буена әле калак сөякләре авыртудан, әле йөрәге әрнүдән сызланып, эче ката башлаудан тагын аңсызлык дәрәҗәсенә житкәләде. Боларның барысы да бергә төрле-төрле авырулар аркасында иде. Кичке караңгылык үткәч, бөтен буен кайнар ут алды. Нидән икәнен белештермәде. Эче катканлык сәбәпле, лапас артына чыгып тез чүкте. Бала төшерде. Әле яңа туган үрдәк бәбкәсе кадәр генә ит кисәге, яралгы хәлендә генә иде. Аны туфракка күмде. Мунчага барып юынды. Әллә ничек кенә үзен чиста татар хатыны кебек тоя башлады. Моңа кадәр сарафаны астыннан ыштан кигәне булмаса, моннан соң аны калдырмады. Гел дә чистарынып йөри торган гадәткә керде. Иптәш кызлары татар хатыннарының ыштаннар киеп йөрүләреннән көлсәләр, юынганда артлары белән кышын җиргә ябышып, кузгала алмый газапланалар, диярәк сөйләнгәләсәләр дә, Марфаның күңеле кайтмады. Озакламый әнисе дә аның гадәтләрен сизенә башлап, аптырады.

— Христос дошманына килен төшәрсең микәнни? — дип усал гына кырын күз ташлап ачулангалады. Әмма Марфаның исе дә китмәде.

— Мин — комсомолка! — дип кенә бәхәстән читләшә бирде.

Һай ул чаклары, һай ул көннәре! Бер яктан, яраткан кешесеннән малай тапкан бәхетле хатын кебек хис итсә, икенче яктан, нахак бәла белән ирен югалткан горур хатын кебек тотты буй-сынын. Баштарак авылының кара урыслары Марфага ачулы йөз күрсәтсәләр, озак та үтми чын гаепле бәндә кулга эләккәч, һәммәсе оятның нәрсә икәнлеген танып, моңа кадәр гайбәт сөйләүдән озынайган телләрен самогон суы белән өттеләр. Хәтта ни буй бирми торган ташмаңгай рәис Дмитрий Карпович та, Марфаның каршына төшеп:

— И кызым, гафу гына итә күр инде, минем гаебем юк бит! — дип теләнде. — Сорадылар: «Шушымы?» — диделәр. «Нәкъ үзе!» — дидем шул. Әмма артыңнан килеп, сиңа, кызым, кул күтәргән кешене белә алмадым. Шулай да белештерермен әле, ярыймы!

Дмитрий Карпович килештерә белеп сөйләшә торган кеше шул. Марфаның күңел төбенә җыелган барча үче-ачуы юылды да төште. Елмаеп

ук йөри башлады. Ул авырып, бала төшергән караңгы иртәдән соң, кулына аркан тотып, асылынырга инде әллә, дип уйлаган авыр минутларын да онытты, төне буе исәрләнеп йөрүләре дә исеннән чыкты. Ә юкса Казанга барып, Самуилын үзе алып кайтырга да ниятләгән иде бит. Барысын да сөйләп бирергә иде исәбе. Йөрәге җитмәде. Таң белән арып йоклады. Төш күрде, имеш, томанлы иртә икән. Самуилы, әнә, аркасына биштәр аскан да кара күзләре белән карап тора. «Кая минем малай? Нигә аны тәсем итеп сакламадың? Моннан соң син минем хатыным түгел, дип аерам үзеңне!» — ди, ә үзе: «Кара елан!» — дип кычкыра. Марфа аңлый алмый, ни хәл бу? Нигә алай, ди? Самуил күрсәткән җиргә карый. Араларында озын, юан кара елан. Йотам, дип килә. Самуил кул болгый. Томан арасында югала. Кара елан аның артыннан бармакчы. Марфа атлап чыгарга итә, булмый. Менә-менә Самуилның аркасы күренгәләп китә. Марфа кычкырыплар карый: «Безнең бит малаебыз бар!» Кулына биләүле баланы ала, күтәрә. Ачып җибәрә, ә анда һичнәрсә юк, бары кызыл миләш тәлгәше генә. Юк икән, кан. Кызыл җиреннән каралып китә. Марфа Самуилны дәшәргә маташа, башы сызлый, авыр...

Каядыр кайдандыр чишмә ага...

Уянып китеп күрсә, Марфаның башы мунча почмагына сөялгән, ә үзе туфракта ята икән. Лапас башында яны белән байлар кебек баскан, киндер чалбарын тезенә кадәр төшергән газиз әткәсе иртәнге кече йомышын озаклап үти икән. Ничек кызын күрмәгән.

Шунда Марфа, төшен онытып, һич көтелмәгәнчә уйлап куйды: «Һай шакшы да инде безнең халык!» Күз алдыннан бер якты нур үтеп киткәндәй тоелды, гүяки, дөнья бер генә мизгелгә балкып, барча әйләнә-тирәнең асылы-җаны ачылып куйгандай булды. Марфаны әтисе дә шәйләп, йомышыннан туктамыйча гына:

— Әй, эт җан, нишләп анда утырасың, атаңны куркыттың бит! — дип җир тибеп сүгенде, чалбарын эләктермәстән, бил турына күтәреп, берни булмагандай өенә чумды. Марфа, күтәрелеп, аның артыннан китте. Ишек катындагы тактадан ясалган урынына менеп ятты. Әтисе исә тагын аны шәйләмәде, әллә игътибар итүне кирәк санамады, мыгыр-мыгыр нидер бытыртап, кочагындагы хатынында каезланды. Марфаның әнисе йокы аралаш сүгенеп куйды:

— Кит әле, Христос дошманы!..

Тәнендә арганлык тоеп, төше исенә төшкәннән тиргә батар дәрәҗәдә куркып, Марфа йоклап китте. Кояш шактый күтәрелгәч кенә әрнеп уянды. Аягына басты. Су буена көянтә-чиләк тотып төште. Дәшминитми генә мунча якты. Көне буе авызына ризык капмады. Юындысөртенде. Тагын тәнендә кер бардыр кебек белеп, икенче кат мунча юынды. Һаман да Самуилын уйлады. Озаклап-озаклап сөртенгән чагында зәңгәр күзләре үз буен буйлады. Тәненә җылы йөгерде. Самуилы соклана торган иңбашлары, беләкләре, балтыр һәм калын ботлары — болар барысы да тик Марфада гына түгелме соң? Тагын кемдә бар? Һай, Самуил, ашадылар башыңны, тереләй ашадылар. Казан тиклем Казанга олактырылгач, кайтармаслар шул, кайтармаслар. Гаебеңне юк дип белмәсләр шул. Кемнәргә калдырдың ласа? Әллә соң тәмәке шырпыңны ташлап киткән идеңме? Тартмый идең бугай ич?

Самуилны гаепле дип уйлавыннан Марфаның үз-үзенә ачуы килде. Әмма күңелен тагын татлы уйлар биләп алып, аяк очларыннан биленә таба бармакларын шудырды. Нәкъ Самуилы кебек кыланды. Һай елгыр иде дә соң үзе! Акылларны адаштыра ала иде.

Марфаның куллары нечкә җиренә тиеп китте. Ыңгырашты. Күзләре йомылып, артка таба саклык белән генә ауды. Сузылып яткан хәлендә куллары белән акрын-акрын, үз алдына ләззәтле хисләр вә уйлар эчендә йөзеп, ак күмәч төсле кабарып пешкән күкрәкләрен сыйпады. «М-м-м... Самуил, кадерлем!..»

Кулын җәеп җибәрде. Рәхәт иде. Әмма ниндидер салкын әйбергә бармаклары тиеп китте. Акылы айнып, тиз ара күзләрен ачты. Нәрсә булыр? Йөрәгенә шом йөгерде. Тиеп киткән урында дәү вә куркыныч гөберле бака утыра иде. Күзләре дә сыерныкы кадәр. «Ай-й-й!»

Марфа анын өстенә чиләк каплады, тиз-тиз киенде дә өенә ашыкты. Ялгызы мунча керүдән гайрәте чигеп, моннан ары бары тик берәр иптәше белән генә юынырга йөри торган булды.

Аягына басканга өч көн үтте дигәндә Марфа Волковага атап чакыру кәгазе килде. Авыл советында мөһер иясе Митрофан карт тиз арада район үзәгенә барып җитәргә кирәклеген аңлатты, хәтта пожаркада арлы-бирле эшләр өчен генә тотыла торган, сабырлыгы өчен Куштан бия дип йөртелә килгән атны җиктереп, арба башына үз малае Алешаны утыртып, юлга кадәр чыгарды. Олы чатта башка юлаучылар очрап, аларга ияртеп, үзе кире җәяүләп кенә кайтып китте.

Көн кызу булды. Алдагы арбаларда кызыл комачлар эленгән, татар абзыйлары дәүләткә ашлык илтә иде. Марфаның хәтерендә еш ишетеп тә шулайдырмы-юкмы дип уйларга башына да килмәгән, әмма авылдашларыннан да сорашып белешмәгән, һәркемнең телендә йөргән бер сүз тугланды. Ул канатлы вә мәгънәле итеп әйтелеп, күңелләрдә дәрәҗә вә горурлык уята иде. Самуил белән йөрешә башлаганнан бирле онытылып беткән икән. «Татарлар эшләсен, урыс бай яшәр!»

Моның мәгънәсе болайрак итеп аңлатыла иде. Имеш, татарлар — буйсынган халык. Бу дөнья урыс белән татардан гына тора. Калган халыклар исә санга да керми, йә татардан, яки урыстан азганнар гына, хәтта французлар да! Урысны Христос ярата, ярлыкый, ә татарлар — басурманнар, денсезләр. Чиркәү төзеп, чаң кага белмиләр, манарага менеп кычкыра гына алалар. Шунлыктан алар кимсетелгәннәр, шайтан чакыручылар! Чаң каксаң, сатана кача икән. Манарадан татарлар кычкырып, аны үзләренә чакыралар... Татар — буйсынган халык, коллар кебек булырга, урыс өчен эшләргә бурычлы. Урыс бай яшәргә, көч түкми ашарга тиеш. Христос шулай теләгән!

Олаулардан күренгәнчә, татарлар, чыннан да, эшлиләр икән! Марфа аларның боек һәм күңелсез көйләрен тыңлап барды, Самуилын исенә төшерде. Аны кызганып куйды. Шулай да мәхәббәте әлегә күңел түрендә дөрләү сәбәпле аны кызгана, исән-имин генә төрмәдән азат ителсә, һичшиксез, урыс диненә күчертеп, үзе белән бергә яшәтергә иде исәбе.

Шулай итеп Марфа әлләниләр уйлап бетерде. Төрле планнар корды. Гүя, ул район үзәгенә Самуилын алып кайтыр өчен бара. Килеп тә керер, кочаклап та алыр, алып та чыгар. Дөньясы урыска буйсынганда, кем каршы килә алсын?..

— Сине дә шул янгын өчен чакырталармы? Татар белән йөрсәң, шул була ул. Әнә тегеләр төсле бил бөгәргәдер исәбең! — дип, мыскыллы елмаю белән Алеша үтереп кенә Марфадан көлеп куйды. Әмма кыз анын ярты сүзен дә ишетмәде. Үз уе үзе белән булганлыктан, кешенеке исенә дә кереп карамады.

— Сине дә чакырталармы? — дип Алеша тагын кабатлады. — Кичә Федор Зайцевны илтеп килдем. Аның белән озак сөйләшмәделәр. Теге татарының әнисеннән сорау алган булганнар. Тикшерүче көлә, ди, син буласыңмы инде ул Пидер, дип әйтә, ди. Имеш, теге татарның әнкәсенә: «Мин Пидер янына барам», — дип әйтә, ди. «Нигә болай аңа бик ешладың әле?» — дип сорагач: «Пидерем дрыгым!» — дип дия иде дип әйтә, ди. Көлә икән Федядан тикшерүче: «Давай, пидерем дрыгым!» — дип. Моңа Федя абый түзеп тора алмаган, тавыш куптарган. Шуннан үзебезнең урыс тикшерүчесе аны тынычландырган. «Монда анын да, синең кебек үк, бер гаебе дә юк. Сезнең авылда пожар чыгарган теге татарның әнисенең сүзләрен генә әйтеп күрсәтә ул, — дигән: — «Пидерем дрыгым» диюен генә кабатлый бит. Аңлыйсыңдыр, аңсыз малай түгел бит син. «Федор — мой друг» дигәне инде ул, ягъни шулай бит?»

Боларны ишетүгә, Федор абый тавыш куптарган тагын да. Юкка аларга Зайцев фамилиясе такканнар, дөресе сезнеке булыр иде. Ә менә сезгә Зайцев кушаматы бик бара.

Федор абый: «Ул татарны гомеремдә ике генә тапкыр күрдем, аның да беренчесе — слетта, Марфа артыннан киткәненә ачуым килеп калды, шулай да танышып, аны эчәргә кыстап маташкан идем, минем кыз артыннан бармасын, дип. Булып чыкмады. Үҗәт татар. Ә икенче тапкырында мин аны янгын көнне милиция кулында күрдем. Аның белән берниндн әшнәлегем юк!» — дигән. Сине яклаган инде. Тагын да сораштырып маташканнар. Кичә боларны бәйнә-бәйнә каравыл өе янында Федор абый сөйләп утырды. «Мин,— ди,— Марфаны беркемгә дә бирмим, мин аны яратам!» — ди. «Шулай дип тикшерүчегә әйткән идем, тагын сораулар бирделәр. «Син,— ди берсе,— бәлки ул татарның килгәнен-киткәнен сагалап та йөргәнсеңдер. Бәлки аларга үч итеп янгынны син чыгаргансыңдыр?» — дип аптыраттылар. Мин әйтәм, бетте баш. Нахактан башыма бәла салалар. Әле дә ярый исемә төште. Мине Лаеш районына бакчачыларның өч айлык курсына укырга җибәргәннәр иде бит. Мин монда булсам, Марфаны ул черек татарга бирер идемме? Юк бит, шулаймы? Шулай. Ә авылга таң белән кайтып төштем. Район үзәгендә үк бер юлаучы үзенә иптәшкә дип утыртты. Безнең авылга милицияне алып кайтырга килүен әйтте. Яхшы да кеше инде үзе. Татар булса да, алар арасында бер юньле дигәне очрады. Моны тиз чакыртып алдылар. Аның артыннан кергән тагын бер милиционер мине танып калды. «Теге ут төртүчене авылдан алып чыкканда каршыбызга очрады, арбада иде. Тәмәке дә бирде әле үзебезгә!» — ди бу. Ат тоткан татар да таныды. Сөйләп күрсәтте. Урысчасы да аңлашылырлык үзенең. Безнең боярда ат караучы хезмәтен үтәгәндә өйрәнеп калган. Менә шулай».

Аннан, ди Федор абый, болар тагын сораштыра башлады. Сөйләргә кушалар. «Әйт,— диләр,— очраштыгыз, таныдыгызмы бер-берегезне?» Таныдым, дим. Ул да таныды. Нидер әйтмәкче иде, милиционерлар каты тоттылар, ирке бирмәделәр, дидем, ди.

Шулай итеп, башка борчымаганнар үзен. Кайтарганнар Федорны. Кичә кич буе эчтеләр, бөтен авыл җыелды. Синең дә абзаң бар иде ич. Сөйләмәдемени? Федор абый белән кочакка-кочак җырлашып та утырдылар әле. Синең хакта да күп сүз йөрде.

— Нәрсә диделәр?

Тыңлап барган җиреннән Марфа да телгә килеп сораганын сизенмичәрәк калды. Һәрхәлдә, аның өчен ирләрнең ни-нәрсә хакында сөйләшенгәннәре кызык иде.

— Нәрсә, дисеннәр, ул татардан котылдык, үзебезнең урыска бирергә кирәк. Синең кебек чибәр кызны черек бер татарга тапшырырга ярамас, дип сүз куештылар.

— Шулайдыр инде!

Марфа боек кына җавап бирде. Әгәр дә Самуилы нахактан төрмәдә черсә, ул вакытта ни чара? Әнә бит, кемнәрне генә харап итмәделәр. Бер гаепсез учительләре Павел Зорин бар иде. Ни яхшы кеше иде, мескенем. Дүрт класс белемне барча балага тигез итеп бирде. Әллә ниткән гаепләр табып, район гәзитенә язган мәкаләләреннән дин исе килә, дигән булып алдылар да киттеләр. Баксаң, Чистай ягыннан поп улы икән үзе. Яшереп йөргән. Иллә дә яхшы кеше иде инде. Нәрсә булган, атасы поп икән, малаенда ни гаеп бар? Тере килеш ашадылар шул башкайларын. Нинди чибәр кешенең бит! Ул төс-бит, ул пөхтәлек, ул хатын-кызларга, олыларга карата хөрмәтләре дисеңме, ул итагатьлеккә өйрәтүләреме — барысы да сокландыргыч иде. Самуилны әллә ничек кенә шул учителенә охшаткан иде, менә нәрсә өчен икән! Язмышлары бер төрле килде дә чыкты. Аттылар бит Павел Петровичны, Зорин дигән фамилиясе дә калмады. Мондагы Медведевлар, Зайцев

ишеләр башы ғшагандыр инде. Хайваннар дөньясы! Менә хәзер Самуилның артына чокыр казыйлар, Марфаны бәхетсез итәләр. Үч итеп, баласын да яшәтә алмады ичмаса. Истәлеге сакланыр иде!

Куштан бия ихластан оеп, йоклап ук киткәләде. Алеша ара-тирә аның сыртын сәнәк сабыннан гына ясалган таяк белән изгәләде. Әмма барыбер файдасы күренмәде. Куштан бия сер бирмичә генә атлый торды.

— Бояр аты шушындый буламы инде, иблис,— дип сүгенде битенборынын ямьсез сипкел баскан Алеша.— Карт тәре, кара инде, татар җырына мәлҗерәп бара. Боярның ат караучысы татар булган, дигәннәр иде, дөрестер. Бу кадәр дә баш бөккән нәмәрсә б...мас иде! Ние! дим, ние!

Урыс малаеның гайрәтләнеп тавыш бирүенә татар абыйлар шыңшып баруларыннан туктап, атларын юлдан читкә алырга ашыктылар. Үзләре куркышып кына шушы сипкел баскан ямьсез Алешага карап-карап алдылар. Гүяки, менә хәзер бу маңка малай камчы белән аларның сыртларын каезлар да юлдан таярга әмер итеп сүгенер төсле иде.

Алеша исә, куштан бияне йөгертеп, олауның алдына чыкты һәм, масаеп кына:

— Менә шулай!—дип куйды.— Болар гомергә каеш дирбия күргән кешеләр түгел иде. Кара әле, совет нишләткән үзләрен!

Исәбе Марфаны сердәш итү иде дә, онытып җибәргән икән, сөйгәне татар иде бит!

Ул арада пристаньнән кузгалып баручы пароходның куе кара төтене күренде, аның артыннан ук якты вә саф Идел елгасы ялтырый башлады. Тузанлы юлдан акырын гына юырткан куштан бия, максатка ирешеп җитәчәген сизепме, әллә инде гадәти ялына тукталачагын белепме, башын күтәреп кенә фыркылдап алды.

— Син мине көтәрсең инде, Лешка, берүк, яме?—дип үтенде алдан ук Марфа.— Кичкә калмабыз дип беләм, әле төшлек туры гына бит, ярыймы?

— Анда карарбыз. Соңга калмасак!

## 4

Ханбал, адымнарын акырынайткач, Казан суы буена төшеп тормаска да булган иде, әмма ниндидер бер эчке сиземләү аны һаман җитәкләп бара бирде. Бер яктан, ул бәйләнчек урыстан котылды. Кара инде, ә, һаман аңламаса аңламый икән, дип уйлады ул. Татар халкы үзенең асыл егет-кызларын бирде бит шушы урыс милләте өчен. Барча кенәзләре татардан үзләренең, күпме язучылары, акыл ияләре, галимнәре. Кайсы халык шулкадәр урыс өчен хезмәт иткән? Татарлар! Ул сугыш батырлары, дисеңме, нахакка һәлак ителгәннәреме—меңнәр вә миллионнардыр. Бер дә үзләренең классик әдәбиятларын укымыйлармы соң алар? Татар мирзаларының исемнәре тулган бит ул әсәрләрдә. Юк, кадерен белмиләр, башкаларны санламыйлар, шунлыктан үзләренә дә көн тапмыйлар, бәхетләре юк. Әнә, бу хатын, эт ияртеп баручы, һаман-һаман урысча такылдый, ә бөтен килеш-килбәте—татарныкы, югыйсә! Ничек затлы киенгән! Боларына кадәр аларныкы булып беттеләр бит. Бер дә үрсәләнми мөмкин түгел. Ярый әле югары даирә татар зыялылары үз милләтен саклап кала алды, телен югалтмады.

Егет шушы рәвештә үзе белән бәхәсләшеп, ялкынлы милләтпәрвәр дәрәҗәсенә күтәрелерлек хәлдә иде. Картлач урыс белән гәпләшүдән котылган төсле тоелса да, асылда ул аның янәшәсендә киләдер кебек иде.

Ханбалның Казан су буена төшүендә тагын бер файда күренә иде: ул менә бүген булса да базда ятучы бәрәңге сабагы хәленнән чыгып, баерга якынлашучы кояшта иркәләнәчәк. Шушы салкынча болытлы күк йөзе әгәр дә кызыл шәфәкъка төренеп калса, иртәгә дөньялар бердәй жылы-

нып китәчәк. Иртә аязса, кич аязмас, кич аязса, һич аязмас! Анысы да бар бит әле аның. Нинди көзгә охшаш җәй бу? Үзе ямьсез, үзе гамьсез. Кояш телим мин, кояш! Йа Ходаем, шушы якты кояшыңны да бездән, без мескеннәрдән кызганасың...

Егетнең язмышында әһәмиятле урын тотачак өченче бер як та шушы Казансу буена төшүендә күреләчәк иде. Моны ул хәзергә белми һәм төшенергә дә мөмкин түгел, чөнки планнары башкачарак. Аның кем белән булса да танышырга һич ниятендә юк. Әмма күкләрнең йөреше аны үз җәтмәсенә тартып алганлыгын искәртми мөмкин түгел. Ялгызлык туйдырган аны. Бертөслелек акылын буалаган. Хисләр үзгәрешен таләп итә җаны.

Буйга җәелебрәк төшкән караңгы-кызыл плащ кигән татар марҗасы әледән-әле этенә дәшкәләп, аңа кая таба барырга әмерен бирә килде. Ханбалга бу күренеш кызык тоелды. Этенә караганда, бу ханым күркәмдер сыман тоелды һәм аның шулай булуын теләде егет. Әмма арттан килеп сүз башларга җөрьәт итмәде. Кара, эте ничек сизенеп тора барысын да! Яшь колын кебек житез-житез хәрәкәтләр белән яшел үлән өстеннән йөгеренсә дә, әле каш астыннан гына, әле буй басып, Ханбалга карап-карап куйгалый. Алла сакласын, биеклеге дә ярты метрдан югары булыр. Шома ак, дөресрәге, кар кебек ак тиресендәге сирәк-сирәк кара тимгелләре дә күзләр төсле.

Иясе тукталып калды. Ханбал аның яныннан үтеп китәм дигәндә тыелды. Эт, мускуллы аякларына ныклап терәлеп, аңа ташланырга әзерләнгәндәй, башын югары күтәрде.

— Айзик! Тынычлан! — дип тавыш бирде ханым. Эте тынычланган-дай итте, әмма үзенең вазыйфасын яхшы аңлаган хәлдә, күз-колагын сакка куйды. Авызы ерык бу адәм кисәген чәйнәп өзәргә әзер иде.

— Этегез, күренеп тора, матур да, акыллы да икән!

Ханбал теләмәгән жиреннән сүз башлады. Ханым җавап бирергә ашыкмады. Ул да бу ирне тиз арада өйрәнеп алырга омтылды. Дөресрәге, алар икесе дә күз ташлашып, бер-берсенең килеш-килбәтен, төс-кыяфәтен билгеләп алдылар. Айзик дигәне аларның ни эшләүләрен күзәтте. Хуҗасы елмаеп карагач, бераз тынычланып куйды, әллә ничек кенә, егетнең исен искәрергә ниятләп, яныннан узды. Таныш кебек тоела иде. Моннан соң тәмам тынычланып, яшь колын төсле алга элдерде. Хәрәкәтләре затлы һәм матур иде. Ул гына да түгел, хәтере яхшы буларак, Айзик бу адәмне танып алды: күрше йортларның берсендә яши, эчми-исерми, сасып йөрми, тавыш-гауга, таяк-таш күтәргәне юк! Ул өреп куйды, әмма хуҗасы игътибар бирмәде, елмайган килеш егетне тикшереп чыкты.

Күз карашына Ханбал нык кына гәүдәле, антик йөзгә тартым сыйфатлы, ябык бер кемсә иде. Әгәр дә артыгы белән үз-үзен яратуын, бәхәсләрдә өстен чыгарга омтылуларын, саранлыгын искә алмасак, яхшы кеше. Сәер сәерен, әмма зыянлы түгел!

«Бу минем кебек эт сугарып йөрүчегә охшамаган!» — дип нәтиҗә чыгарырга өлгерде ханым. Егеткә артыграк мөкиббән киткәнлеген исәреп, сүзенә җавап бирергә кирәк иде, дигән фикере башында кайнап чыгуга, хәтерен яңартып алды: «Ә, этнең нәселен сорады бугай. Әйтим инде, белеп торсын. Болай охшаш яклары да бар боларның. Йөз-кыяфәттәме, үз-үзләрен тотышларындамы?»

— Далматин нәселеннән ул, Әдрән диңгез далматины. Тычкы яктан гына шулай ягымлы кебек, ә асылда, белеп тору комачауламас, усал холыклы, яман хәтерле этләрдән санала! Бер мәртәбә кискән карашташласаң да, икенче тапкырында тешләргә әзер тора!

— Шулайдыр, — дип килеште Ханбал.

Ничектер бар да үз җае белән килеп чыкты. Ханым егет артыннан иярде, сөйли бирде. Теле ачылып киткәнлеген сизенми дә калды, тагын-тагын бу ирне тоткарлыйсы, этне ияртканe кебек янында йөртәсе килде, шулай булуын теләде.

— Бу нәселдәге этләр безнең илгә Әдрән буеннан кертелгәннәр, анда исә Греция һәм Югослав илләрендә киң таралганнар. Аларны затлы, тыңлаучан булганлыклары өчен аксөякләр бик ярата.

— Бөтен яхшы нәрсә аларда булыр инде, грекларда, диюем. Борынгы халык шул, акыллы милләт.

— Борынгы греклар далматин нәселле этләр барлыгын белгәннәрдерме-юкмы, әйтә алмыйм, әмма аларга аны Һиндстаннан китергәннәр. Төп йортлары — Һиндстан бу этләрнең. Рәссамнар белән сынчылар да далматиннарны читкә этәрмәгәннәр, һәр гасырның, һәр илнең диярлек рәсемнәрендә алар урын алган, бигрәк тә Шәрекъ миниатюраларында!

— Сокландыргыч! Һичшиксез, сокландыргыч нәсел!

«Көләме соң бу миннән? — дип уйлап алды ханым. — Әллә эттәнме? Кайсы җирләре охшаган соң боларның? Исеме дә Айваз ишедер әле!»

Ханымның тере кешене эт белән чагыштыруы начар нияттән яки тәрбиясезлектән килми, бәлки якын итүдән генә иде. Ул бит теләсә нинди эт белән түгел, үзенекенә тиңли, яраткан этенә. Аның хакында кычкырып әйтергә ярамас, әмма...

— Исемегез Айваз түгелме?

— Нигә алай дисез? Әллә берәр танышыгызга охшаганмынмы?

— Әйе, дисәм дә ялгыш булмас. Мин дөрес әйттемме?

— Сезнең кәефне бозасым килми, шулай да сез ялгыштыгыз! — Егет, борынын чөйгәндәй, тантана итеп алды.

— Ә нинди соң?

— Әйтми дә булмас. Ә үзегезнеке?

— Нигә, шикләнәсезме әллә? Минеке — Альбина! Тагын нәрсәләр кызыксындыра?

Егет каушабрак китте. «Тагын нәрсәләр кызыксындыра, ди бит! Ә кызыксындырмаса?» — ул үртәлеп куйды, әмма исемен белдерми торуыннан үз тупаслыгын танып, ханымның алай җавап бирүенең сәбәбен төшенде, хатасын төзәтергә ашыкты:

— Кызганыч, Айваз түгел, Ханбал исемле мин. Ханбал Вәлиев бар булганы белән сезнең каршыда!

Аның үз-үзен фамилияр тотуы бер дә файдага булмаса да, ханым көлеп үк җибәрде. Энҗе сыман ак тешләре белән тел очын тешләп куйгандай итеп тыела калды:

— Алай!

«Бу нинди дивана икән?» — дип уйлап куйды Альбина. Аңа ничектер кызык булып китте, шаярасы, көләсе килде. Әмма әле яңа гына таныша башлаган вакытта артык җәелеп затсызлану да мөмкин түгел иде. Ханбал да ашыкмады. Сораштырган булды, тегене-моны сөйләргә талпынып карады, теләгенә генә ирешә алмады. Сөйләшүләре танышу-белешүдән уза алмыйча, икесенең дә күңелен кайтарды. Буйдак үз уенда, ханым үз теләкләре эчендә тоткын иде.

Узгынчы гына танышу икәнлеген күңеленә беркетеп, Ханбал юлын ялгызы гына дәвам итәргә ниятләп алга тартылды, тик Альбина аның артыннан калмаска булды. Ялгызлыктан гаҗизләнгән чакларында аңа берәр иптәш кирәк иде. Буйдактан калышмады, адымнарын тизләтте һәм, егетне туктату максатыннан чыгып, сорау яудыру тиешлеген төшенеп алды.

— Сезне бу тирәдә бер дә күргәнем юк иде, кунакка килдегезме әллә?

Ханбалның көтелмәгәндә ачуы кабарган кебек булды. Бу ханым аңа бер дә кирәк түгел иде дә бит, сүз башлагач, ташлап китү ярамас. Аңа да күңелсездер. Бу кадәр күркәм вә дәү этне сәгатьләр буе гына түгел, иртәдән кичкә кадәр сахрада йөртергә кирәктер, дип уйлап, адымнарын киметте, акырын хәрәкәт белән генә кызның бозауныкына охшаш олы вә кара күзләренә текәлде.

— Күптән инде!

— Нәрсә күптән?

Ханым үзе биргән соравын да оныткан идеме, әллә башына төрле уйлар төшкәнме? Белмәссең. Шулай да Ханбалга кызык тоелды, Альбина хакында: «Сәер хатыннар да була инде бу тормышта. Матур гына нәмәрсә югыйсә»,— дип уйлады, әмма кабат ялганып киткән сүзләрне өзеп калдырасы килмичә, бу районда икенче ел гомер кичергәнлеге хакында белдерде.

Ханбал фатирны озак көтте, алдан ук кооперативка гариза язып, акчасын да түләп куйган иде. Кисәк кенә тормышлар үзгәреп, төзелеш өзелде, бер ел эчендә өлгерсә, шунда күчәрмен, дигән уйда йөргән Ханбал биш елга якын тулай торакта гомер черетте. Инде дә булмас, барып чыкмас, дип кенә уйлап, биргән акчасын кире юллап алу өчен кат-кат йөренә башлагач, аны әлеге ширкәт хезмәткәре тулы вә юан гәүдәле бикәч чакыртты да кулына ордер тоттырды. «Сезнең йорттан тиз генә булмас, ярдәмем тисен әле, гомерегез буена рәхмәт укырсыз!» — дип юмалый-юмалый сөйләнде. Ханбал бәхеткә төренде. Тулай торактан тулай торакка күченеп йөри-йөри аптырап беткән ялгыз башына һәрвакыт иптәш вазыйфасын үтәгән җыелма караватын һәм кыршылып беткән чемоданын сөйрәп, алдан барып та карамыйча, ордерын тоткан хәлдә, анда күрсәтелгән адрес буенча китте. Торак хуҗалыгын эзләп табып, фатирын ачып кертүләрен таләп итте. Әмма паспортистка хезмәтен үтәүче пыяла маңгайлы, бозау кебек үшән яшь хатын аны кире борды:

— Бар, элек торган жиреннән документлар китер,— дип санап китте.— Фәлән кирәк, төгән кәгазь булсын. Ничек болай тиз генә ордер бирәләрдер әңгерәләргә? Тәртип бетте,— дия-дия сүз юллап, Ханбалны озатып калды.

«Һай, шул вакытта, ишектән сөрелеп чыгарылгач, торак хуҗалыгы төбендә очраткан идем түгелме соң мин бу хатынны? — дип уйлады буйдак, башыннан узган вакыйгаларны исенә төшереп.— Әйе, әйе! Чү, ялгышмыйммы? Бәлки!» Шуны Альбинаның үзенә әйтеп китәргә кирәк тапты:

— Без сезнең белән танышлар. Мин монда күченеп килгәс көнне, хәтерегездә түгелме икән, ЖКУдан килеп чыктым, бер кулымда — җыелма карават иде, икенчесендә — кызыл төстәге чемодан. Ордер алган көнем иде. Кооператив фатир. Әмма ул вакытта сәгате-минутында урнаштырмый аптыраттылар. Башта элекке яшәгән урынымда документлар бирмичә йөрттеләр, анысы барып чыккач, ЖКУ башлыгы ялга китеп барды. Тәмам аптырап беттем, күзгә генә фатир ишегеннән ачкычны кулыма тоттырдылар. Яңа йорттан, дип уйлап йөргән идем, искедән бирделәр. Тавыш чыгарырга исәпләгән идем дә, монсыннан да коры калырмын, дип килештем инде. Тыныч урын булып чыкты. Мин бит китап укырга яратам. Малай-шалайлар да юк, карт-коры да, укучылар гына бугай безнең подъездда. Күпләрен белеп тә бетермим,— дип, Ханбал бәйнә-бәйнә барысын да Альбинага сөйләп биргәнен сизми дә калды.— Менә шул беренче килгән көнемдә, әйе-әйе, ачык хәтерлим, очраштык бугай без. Әмма сезнең дә кәефләр шәптән түгел идеме, бик боек күрендегез. Хәтеремдә калган, менә бу бит очындагы тары бөртеге кадәр миңегез ак йөзегездә карлыган кебек каралып тора иде. Әле сез миннән сәгать тә сорадыгыз булса кирәк...

«Алай ук түгелдер лә инде, ярар, әгәр дә күптән танышлар икән, бик яхшы!» — дип уйлап куйды ханым. Тагын да бераз сөйләшеп баргач, чыннан да, Ханбал элекке танышы төсле тоела башлады. Тукта, тагын да күптәнрәк белми микән ул аны?

— Ханбал, сез Алабугада укымадыгызмы, укытучылыкка?

— Юк, мин Казанныкын бетердем, тарих буенча, ягъни архив хезмәткәре белгечлеген алып чыктым. Ә менә дустым Хәниф исә шунда укып, хәзер монда эшли. Бәлки, беләсездер. Хәтерем ялгышмаса, сиксән бишенче еллардамы бетергән ул...

— Юк, белмим шул,— дип кырт кисте ханым һәм уйлап куйды: «Моның белән яшь арабыз ун еллар чамасыдыр. Әгәренки дусты сиксән бишләрдә тәмамлаган икән,— мин — җитмеш биштән үк анда укыдым!»

Араларында яшь аермасы шактый сизелеп тору сәбәпледер, егетнең сәерлеге Альбина өчен ачык күренеп, бала белән сөйләшкәндәй хис итте үзен.

— Ирегез күрсә, чит кеше белән йөргәнегез өчен битәрләр әле! — дип куйды Ханбал.

— Минем ирем юк, дөресрәге, өйдә юк, командировкада!

Альбинаның бу җавабыннан соң Ханбалның кәефе яхшырып китте, ханымны ничек тә иркәлисе килде. Ир назы җитми икән үзенә, менә нәрсә өчен боек күренә. Әллә соң, син буйдак, ул иреннән калган хатын, берәр эш майтарып булыр?

Башына килгән бозык уйлары Ханбалның күзенә кара кан йөгертте, хисләре куәтләнеп, күңел диңгезеннән менә-менә ташып чыгардай хәлдә кабарындылар. Шулай да сер бирмәскә тиеш иде ул. Акрын гына, иплəп-иплəп ханымга якынлашырга, өзми-тартмый гына хисләрен белештерергә, бәгырь түренә кереп оялarга һәм максат ташына су салырга! Ханбал шушындый нияткә килеп, тиз ара ничек-ничек эш йөртергә тиешлеген ачыклагандай планнар корып карады. Әмма бернәрсә дә барып чыкмасын да уена кертеп, вакытында тыелып калу җаен да күзләде. Шулай да наз төененә төйнәлеп, ләззәт бакчасында бәхетле минутлар кичерәсе килүдән читләшергә теләмәде.

— Һич югы балаларыгыз белән төшәргә кирәк иде, су буе бит, әллә кемнәр очрарга мөмкин. Әнә, ике исерекбаш килә, бәйләнүләре дә мөмкин!

— Минем балаларым булмады әлегә,— дип Альбина моңсу гына әйтеп куйгач, Ханбалның йөрәге жу итеп китте. Хатыннарда бала булмау олуг бәла инде ул.

— Гафу итегез, белмәдем бит. Аңлыйм, кыендыр инде сезгә.

— Киресенчә, тыныч һәм рәхәт. Мин дә элекләрне сезнең кебек уйлый идем, әмма ирем тынычландыра килде. «Нәрсәгә бала асырап баш катырырга, болай да рәхәт бит!» — дия иде. Буйга узган вакытларда да каршы чыкты, тиз генә врачка күренергә куша иде. Алар үз эшләрен оста башкара. Иремнең дә сүзе үтә...

— Кем ул шундый кансыз бәндә?

— Совет дәверендә комсомолда эшләде, өлкә комитетын җитәкләде. Төннәрен генә кайтып керә иде...

— Вәлишинме?

— Әйе, нәкъ үзе.

— Хәзер кайда соң ул, комсомолны бетерделәр бугай ич?

— Бетүен бетмәгән дә... Ул хәзер бизнеста, коммерсант. Акыллы кеше. Эшен ярата.

— Байлык артыннан куамыни?

— Хәзер дөньясы шундый аның, кем эшләми, шул ашамый!

— Бүрене аягы туйдыра, дисәгез, дөресрәк. Безнең кебекләргә андый зур эшләр башкару язмаган инде! — Ханбал мескенгә салынган кыяфәттә кыланды. Башына да уй төште: «Ире коммерсант булгач, йортында сакчылары да җитәрлектер әле. Бу ханым янында мәш килү бер дә файдага түгел!»

— Шырпы юкмы?!.

Теге ике исерек алар янына килеп җиткән иде инде. Ханбал аларның сорауларына җавап итеп җилкә сикертте. Әмма Альбина югалып калмады, плащ кесәсеннән алып, кулын сузганына зажигалка тоттырды. Тегеләр: «О, рәхмәт, ханым!» — дип кыландыра-кыландыра сөйләнеп, каты суыра-суыра «Идел» сигареты кабыздылар. Берсе артык якынрак килеп, кисәгрәк Альбинага зажигалкасын кире сузды. Ул да түгел, ярсып

килгән затлы далматин теге исереккә ургылып өрә башлады. Менә хәзер өстенә ташланачак, бугазыннан алачак иде, Альбина әмер биреп өлгерде:

— Айзик фу!..

Эт артка чигенде. Ачуы бугазына тыгылды, башын болгап, тешләрен ыржайтты. Ике исерек, алар белән бергә Ханбал катып калдылар. Елан кебек озын һәм тыгыз, ныклы койрыгын катырып, Айзик үз хуҗасыннан әмер көтте. Альбина канәгать кенә елмаеп, аңа таба якынлашты, башыннан сыйпап тынычландырды һәм муенчагыннан тотып алды.

— Барыгыз, китегез, хәзер тими инде ул! — диеп тә өлгермәде, ике исерек шапан-шопан сызу ягын карадылар. Әмма Ханбал урынында басып калды.

— Нигә, курыктыңмы әллә? — дип елмайды Альбина.— Диваналар, эт белән икәнлегемне күрмәделәр микәнни? Ярый әле тешләмәде үзләрен, юкса тавышыннан бәласе күбрәк буласы иде!

— Миңа тимәс микән?

— Тәртибеңә карап. Миңа артык якын килсәң, яратмас. Бик көнче ул, хәтта анда-санда кайтып күренгән иремнән дә көнли.

— Булмас ла.

— Менә күрерсең.

«Шулай укмыни әле!» — дип уйлап куйды егет. Ханымда өмет бар төсле. Ул онытылып аның киң күкрәкләрен сиздереп торган юка плащыннан карашларын шудыртып кына аягына таба төшерде. Бар җире дә матур, артыгы белән чибәр төсле тоелды. Аяклары да тулышып торалар. Иреннәре дә назлы күренә, чәчләре дә калын, хис томанына кертеп адаштырачак инде мондый ханым!

— Ярар!

Ханбал үз-үзенә ышанган кеше төсле сизмәстән әйтеп тә салды. Ханым тагын мул гына елмайды. Тешләрендә егетнең утлы күз карашлары чагылып киткән төсле тоелды.

— Күрербез... Айзик, гуляй!..

Бирелгән әмерне Әдрән далматины карышусыз үтәде. Тагын колын шикелле чабып, йөгергәләп йөрenә башлады. Әмма баягы вакыйгадан соң сабак алыпмы, еракка китмәде. Якында гына әле таяк башы, әле сукмак читенә ташлап калдырылган, корып беткән кыр чәчәкләре букетлары, яки такыяләр белән уйнаштыргалап маташты. Альбинаның «Күрербез!» дигән сүзеннән соң коелып төшкән Ханбал беразга телен йоткан иде.

— Ә синең хатының, балаларың кайда? Ялдалармы?

Ханым сүзләренә бернинди мәгънә салмыйча гына сорап куйды. Аның өчен егетнең, өйләнгәнме-түгелме, кемлеге бер дә кызыксынырлык әйбер күрелми иде булса кирәк. Тормышның ләззәтен генә җыярга сәләтле бу ханым, иң асыл затларны да алдында биетәчәк. Йөзенә чыккан.

— Мин әлеге буйдак,— дип белдерде Ханбал, Альбинаның ягымлы елмаюында бу хәбәрдән канәгатьлек күреп.— Баштарак тормыш көйләнеп җитмәгән иде, хәзер ошаган кызны табуы авыр...

— Сайланасыңмы?..

— Бу яшьтә сайландыра икән ул. Менә сезнең кебекне очратсам, уйлап та тормас идем...

— Ә нигә минем кебекне?

— Сез бит бик тә чибәр!

— Шаяртасыз! — Альбина үзенең кемлеген белгәнлектән юри шулай кыланып кына җавап бирде, әмма соравын кабатларга ашыкты: — Ә нигә нәкъ минем кебекне? Үзем ярамыйммыни?

Мондый сүздән Ханбал авып китәрдәй булды. Авызында теле кипте, күкрәгендә йөрәге бәреп чыгардай хәлдә сикерендә. Ханым аның акылын сыегайтты, диваналыгын арттырды, аңын алды. Бәгырь төбенә җыелган

тормышка үпкә-рәнҗү ташларын эретә-эретә мәхәббәт чәчәге нәзек сабагында тибрәлә-тибрәлә баш калкыта башлады. Ханбая бер авыз сүздән эреде дә төште.

## 5

Ханбалны мөкиббән иткән Альбина үзе Вәлишин Геннадийның икенче хатыны иде. Беренчесендә ике баласын калдырып, партия карьерасыннан колак кага язган ир, заманалар үзгәреп китү аркасында гына урыныннан очмады. Әмма өлкә комсомол конференциясе якынлашкан саен исенә әхлак мәсьәләсен төшерергә теләүчеләр табылды. Әле ул вакытларда яңа гына баш калкытып килгән кооперация вә бизнес хәрәкәте акыллы Геннадий өчен бердәнбер ышаныч иде. Озын буе, калку һәм калын җилкәләре, көрәшчеләргә хас сын-гәүдәсе, җитмәсә йөзгә-биткә дә чибәрлеге аның һәрбер башлаганын ахырына кадәр алып барачагы хакында белдертеп торганлыктан, өлкә комитеты исеме астында башлап җибәргән эшен алга этәрергә ярдәм иттеләр. Конференция көннәре якынлашкан саен Вәлишиннең бизнес вә коммерциясе чәчәккә бөреләнеп кенә калмыйча, мул җимеш тә бирәчәге ачык гәүдәләнелә иде. Ул монда да барысын оста хәл кылды. Бер яктан, дәүләт яклавына, икенче яктан, ышанычлы иптәшләренә таянып, ул шактый гына акчаларны әвеш-тәвеш китерде. Яңа хатыны Альбина белән икесенә тиз арада өч бүлмәле фатир алып, бу яктан да тормышы нигезенә терәк салды. Йокысын йокламаса йокламады, әмма үз дигәнендә торды. Әле теге шәһәргә барып чыкты, әле монысына. Комсомол комитетларының эшләрен тикшерү белән беррәттән, коммерция мәсьәләләрен дә хәл итәргә өлгерде. Сәгать заводыннан алынган зур партияне чит илгә озатып, реклама өчен дә табышның бераз өлешен бүлешү аркасында кооперативын баетып җибәрде. Долларлар агылды. Завод директоры да аның ярдәменнән канәгать калып, алга таба да хезмәттәшлекне югалтмаска чакырды. Вәлишин ахмак түгел иде. Сүз сүз белән, әмма хезмәттәшлек хезмәттәшлек белән. Моны кайбер иптәшләре аңлап та җиткермәде. Әмер генә үтәргә сәләтле булулары сәбәпле, акыл казаннарында фикер камырыннан коймак пешерергә иренәләр иде. Аларның сүзләренә колак салган төс чыгарып, Вәлишин үз юлы белән барды. Сәгать заводының җитәкчелегенә кыйммәтле бүләкләр, япон аппаратуралары китертте. Чит илләр белән бәйләнеше мул уңыш вәгъдәли иде. Ә моның өчен бу төпсез коены сыйфатлы товарлар белән туктаусыз тәэмин итеп торырга кирәк. Хезмәттәшлек һәм бүләкләр менә шуның өчен бик тә файдалы чаралардан булып чыкты. КамАЗлар белән дә тыгыз элемтәләрен урнаштырырга өлгереп, үзенә Казан заводыннан ташландык бер цехны алырга ниятләде. Ни уйласа, шул эше барып чыкты. Монда да технологияне тәртипкә салу өчен шактый гына акча түгеп, шәхси предприятиесен булдырды.

Заман Вәлишин файдасына чуарланды. Җәмгыятьтә партиянең дә, комсомолның да абруе төште. Өлкә комсомол конференциясенең кирәклеге-кирәксезлеге көн тәртибенә менде. Әмма Вәлишин өчен ул ут һәм су төсле зарур иде. Беренчедән, аның шәхси бизнесы бар, ә бу устав белән бер дә ярашмый, икенчедән, ул үзенең партия карьерасына үз куллары белән балта чапты. Аңа бер генә юл кала: комсомол йөгеннән иңнәрен азат итү.

Ниятләрен күпләр белми вә сизенми дә калды.

Конференция көннәре якынлашкан саен өлкә комитетында таркаулык һәм башбаштаклык көчәя барды. Ел саен бирелә торган яшьләр премиясен хәл иткән көннәрдә Вәлишин инде бар нәрсәгә дә кул селтәү дәрәҗәсенә җиткән иде. Таркаулык вә тарлык үз эшен эшләде. Ленинчыл сәясәт корбаннары булган вак җанлы хезмәттәшләре шушы заманда,

принциплар ватылган һәм җимерелгән чорда. Ленин темасын күтәргән һәрбер шагыйрь яки язучыга премия тапшырып калырга ашыктылар. Андый берәүне тиз ара эзләп табарга, аны күтәреп мактарга әзер тордылар. Аларның ихлас күңелдән йөрүләре көлке дә, кызганыч та иде. Күзләренә артык чалынмаска тырышып, Вәлишин фатирына вакытыннан күпкә иртәрәк кайтып керә һәм яшь хатынына мең рәхмәтләрен яудырырга тотына:

— Әгәр дә, сөеклем, синең белән кавышмаган булсак, шушы сазлыкта батып каласы идем бит! Шөкер, мең шөкерләр үзенә!

Альбина аның нәрсә хакында шулай шаулап куануларын аңлап та җиткерә алмый иде. Күңел түрендә башка хәсрәтләр йөртеп, һаман да буйга уза алмавына борчылды. Табибларга да күренгәләп карады, әмма күңелен юатырлык бер генә дә җылы сүз тапмады. Аллаһы тәгалә каһәре төшкән кеше кебек хис итте үзен. Ә юкса гаеп икесендә дә иде. Ул гөнаһлары беренче күрешеп кавышкан көннәреннән үк башланып китте.

Альбина студент кына иде әле. Чибәр, бөтен институтка бердәнбер сокландыргыч кыз. Укытучылар аның бер назлы күз карашы ташлавыннан зачеткасына «бишле» билгесе куярга әзер тордылар. Табигать тарафыннан мул итеп бирелгән чибәрлеге өстенә, ул әле зирәк тә иде. Бер кереп тыңлаган лекциясе озак хәтердә сакланып, аның хакында: «Укымыйча да белә ул!» — дигән билгеләмә таралуга сәбәпле булды. Мәктәптән үк күңеленә ныклап салынган белем нигезләре һәрвакыт диярлек Альбинаны коткарып килде. Чит телне бик җиңел үзләштерүен үзе дә яхшы сизгәнгә күрә, бер дә сер бирмәде, дәресләрне мөмкин кадәр калдырмыйча укыды. Дүртенче курста укытучылары белән ярышырлык дәрәҗәдә инглизчә сөйләшә башлады.

Шәһәр комсомол оешмасы конференциясенә аны да делегат итеп күрсәттеләр. Әзерлек ике-өч ай алдан ук башланып, Альбинага инглиз телендә чыгыш ясарга бурыч йөкләделәр. Баксаң, Казан университетыннан интернациональ дуслык клубының чит ил студентлары да өлкә комитеты секретарьлары белән бергә киләселәр икән. Алар каршында Алабуга шәһәренең һәм данлыклы институтының дәрәҗәсен күрсәтү зарур.

Альбина белән укытучылары көн-төн шөгыльләнделәр, аның болай да яхшы вә сокландырырлык белемнәрен тагын да камилләштерделәр. Кыз аларның һәр сүзенә күңел салды, дикъкать бирде. Бөтен лекцияләрдән дә үзен азат ясап, бары тик инглизчәгә генә йөрттеләр, ял итәргә тулы мөмкинлекләр ачтылар. Аның булганлыгына һәм тырышлыгына, хәтеренең камиллегенә тәмам ышанып җиткәч кенә укытучылары Альбинаны гаҗизләүдән туктадылар. Конференция башланырга да санаулы көннәр калган иде.

Җыелыш тантаналы төстә ачылды. Залның алды-арты, яны-кыры кызыл комачлар һәм партиянең олуг җитәкчеләренең портретлары белән тулы иде. Конференцияне өлкә комсомол комитеты җитәкчесе Вәлишин ачты. Моңа кадәр үз күңелен яулап алырлык кешене очратмаган Альбинаны биһуш итте. Ул тәмам телдән язды.

Кемнең нәрсә хакында сөйләгәнен төшенә алмады, акылы кабул итмәде. Үз чыгышының эчтәлеге нинди икәнлеген дә онытты.

Аның исемен атадылар. Сүз бирделәр. Ян-якта утырган иптәшләре аңа төрткәләп куйдылар. «Озаклама, ни булды, әйдә инде!» Шушы сүзләрне «бисмилла» урынына кабатлап, трибунага чыгып басты. Докладын, дөресрәге, чыгышын башта татарча, аннан русча, аннан инглизчә сәламләүләр белән башлап китте. Теле такылтады, күңеле киреләнде. Аның һәр хатасын эләктереп ала барган укытучылары хәйранга калдылар: «Нәрсә булган моңа? Әллә артыгын кыланып ташлаганбызмы?» — дип пышылдаштылар.

һәм ул сөйләп бетерде. Артыннан ук Казаннан килгән чит ил студентлары сикерешеп тордылар да: «Рот фронт!»[1] — дип йодрыкларын күккә чөйделәр. Соңыннан гына билгеле булды: Кубадан килгән бу Казан университеты студентлары инглиз телен белмиләр һәм ярым-йорты гына төшенәләр икән! Әмма өлкә комитеты таләп иткән эффект барып чыкты. Зал шау-гөр килде. Бигрәк тә Вәлишин утырган урынын да онытты, Альбинаны мәхәббәтле күзләренә элеп кенә алгандай зал буйлап карашлары белән озата барды. Һәр адымы, һәр тән селкенүе ягымлы да, якын да кебек тоелды. Конференция беткәнче Альбинаны күзәтеп утырды. Ахырда инде аңа карата мәхәббәт хисләре кабынган, үзенең ике бала атасы икәнлеген дә оныткан иде.

Алабуга комсомолларын бәхет күмде. Вәлишин мактады да мактады үзләрен. Әгәр дә шунда Альбина тирәсендә берәр егетнең кайнашканын күргән булса, бөтенләй дә башка төрле сүзләр сөйләгән булыр иде. Ярый әле мондагы кеше итагатьле икән!

Кичкә өлкә комитетыннан килгән кунаклар хөрмәтенә шәһәр комсомол оешмасы зур сыйлы банкет оештырды. Альбинаның исем-фамилиясе язылган кәгазьне Вәлишин, махсус чакыртып, райкомол җитәкчесенә тоттырды:

— Шушы чит телдә сөйләгән комсомолка банкетта катнашса, яхшы булыр!

— Һичшиксез!

Мескен җитәкче, алам-бәрәм кеше ерып, каядыр кереп югалды. Тиз арада Альбинаны табарга боерды. Әмма кыз конференция бетүгә үк чыгып киткән, тулай торагына да кайтмаган, институтка кермәгән булып чыкты. Махсус БКД отрядын кузгатып, ике милиция машинасын яллатып, Альбинаны урамнар буйлап та эзләп йөреп карадылар, табылмагач, «Танымыйбыз!» — дип акландылар. Тиз арада шәхси учет кенәгәсендәге фотосын зурайтып күбәйттерделәр. Энә түгел, табылырга тиеш иде...

Ә Альбина беркайда да түгел, Шишкин музей-заповеднигына кереп, экспонатлар белән ялгызы гына танышып йөрүдә иде. Һәр әйбергә озаклап күз ташлап, күңелен тынычландырды. Нилектән каушаганлыгын аңларга теләде. Вәлишин хакында ул инде оныткан, ышанычны аклавына гарьләнүдән генә изалана иде.

Музейдан ул сафланып, тынычланып чыкты. Уңга-сулга йөреп торган милиция машиналарына игътибар бирмичә, тулай торагына таба юнәлде. Ачуланырлар инде аны укытучылары, ачуланырлар. Әллә соң институтны ташлап китәргәме, дигән уйлар белән кайтып керде. Вахтада утырган әби шәрран ярып:

— Әнә ул! — дип кычкырып җибәрүдән сискәнеп, үзенә төбәлгән бармак очының авырлыгыннан агарынып китте. Гүяки, аңа мылтык көпшәсен терәп куйганнар иде.

Тиз ара ике милиционер ике ягына килеп бастылар, аңыннан киткән кызны култыклап кына машинага таба алып чыктылар.

Альбина һичнәрсәне аңларлык дәрәҗәдә түгел иде. Җитмәсә кырындагы сасы авызлы милиционер аның пальто төймәләрен чишкән булып, туйганчы күкрәкләрен капшады, итәк астына төшәргә маташты, куллары бер дә тик тормады. Ярый әле икенче ягында утырганы тыныч кына кала бирде. Күгәрченгә ташланган козгын исә һаман казынды да казынды. Әгәр дә янында икенче иптәше булмаса, максат ташының кызуын да басарга җаен табасы иде.

Ул арада ак «Волга» машинасы янына килеп тә туктадылар. Ялт кына чыгып, кызның табылуы хакында әлеге дә баягы сасы авызлы милици-

---

[1] «Кызыл фронт!»

онер хәбәр салды. Альбинаның хәлен белешеп, үзен бик тыныч һәм җитди тоткан бер яшь ир аны «Волга»га күчереп утырттырды. Милиционерларны азат итте.

— Кайда йөрдең, матурым?

— Шишкин музеенда!

— Һай, кретиннар! Бөтен шәһәрне кузгаттылар бит. Юньле кешенең кайда йөргәнлеген дә белмиләр. Өйрәнгәннәр...— дип, әлеге яшь ир нәтиҗә чыгарды да, шоферына:— Ресторанга!— дигән әмерен җиткерде.

Альбина нәрсә уйларга да белмәде. Әмма дә шушылай ягымлы сөйләшкән ирдән сорарга кирәк тапты, бер-ике тапкыр талпынып карады, барып чыкмады. Ахырда, батырлыгын җыеп, ярым пышылдаган хәлдә үтенде:

— Абый, абый, дип, берүк әйтсәгез иде, минем ни гаебем бар соң? Нигә мине милиция кулга алды?

Аптыраган ир Альбинага таба борылды. Ул алда утыра иде. Авырлыгыннан урындыгы да сыгылып куйды.

— Ничек, дисең, кулга алдылар, дисеңме?

— Әйе, абый...

— Әйтәм бит, кретиннар. Барысына белдерелде. Тавыш-гауга чыгармаска, табарга да үземә хәбәр итәргә, дип. Ахмаклар!

— Абый, минем гаебем юкмыни? Алай булгач кая алып барасыз?— Альбина үз язмышы өчен хафага төшкән иде.

— Тынычлан, сеңлем, тынычлан,— дип юатырга ашыкты яшь ир.— Кунакка чакырулы син. Менә, килеп тә җиттек.

Шәһәренә түгел, төбәгенә бердәнбер яхшы саналган ресторан төбенә килеп туктадылар. Бөтен булган утлар да бар көчләренә яктыртып, эчтән тантаналы марш һәм сөйләшү тавышлары ишетелеп тора иде. Бина каршына берничә милиционер бастырылып куелганны күргәч, Альбина артка чигенде.

— Абый, монда мине нигә алып килдегез?— дип качарга теләде. Әмма ул ир аны җай гына сөйләштереп култыклап алды һәм:

— Сеңлем, нигә алай курыктың әле. Кирәкми,— дип үгетләргә кереште, ә үзе күңеленнән милицияне битәрләде: «Шуларга эш кушалар димени, кретиннар, тора салып кыз баланың өнен алганнар. Ахмаклар! Җүләрләр иле!»— Сеңлем, синең чыгышың өлкә комитеты җитәкчесенә дә, чит ил кунакларына да бик ошаган, шунлыктан үзең белән якыннанрак танышу өчен банкетка чакырттылар. Бары шул гына. Бер дә борчылма,— дигәч кенә, Альбина аның әйдәкләвенә буйсынды. Үзенә карата ишек төбеннән үк күрсәтелгән кадер-хөрмәткә исләре-акыллары китеп, күгәрчен булып кереп килгән җиреннән аккошка әверелде. Аны һәммәсе диярлек күтәреп кенә алмадылар инде, барысы да сокланган күз карашларын аңа ташлап, кул чабарга керештеләр. Шушы алкышлар эченә керде дә эреде кыз. Әле яңа гына башыннан узган хәсрәтле минутлары онытылды, шик-шөбһәләре югалды һәм ул...

Һәм ул адашты. Вәлишин әле аның кулыннан тотты, әле танцыга чакырды, әле аерым бүлмәгә дәшеп, затлы эчемлекләр белән сыйлады, нәрсәләрдер киңәш итте, ниләрдер вәгъдәләде, үтенде, сорады. Әмма Альбина бер генә сүзен дә аңламады, кулына тагылып йөрде дә йөрде. Өлкә комитеты җитәкчесенең Альбинага күрсәткән хөрмәтләре мондагыларның берсенә дә татымады. Ул аларны бөтенләй үк онытты да булса кирәк. Кыз җиде кат күкләрнең рәхәтен татый бирде. Вәлишин аның саен үз янынарак елыштырды. Альбина мәҗлестән тәмам арган, ташлап чыгып качардай хәлгә җиткән иде. Әмма Вәлишин тозагыннан ычкына алмады.

— Мин сине яратам! Син — минеке, бары тик минеке генә!— дип пышылдады ул кызның колагына...

— Син — минеке, бары тик минеке генә!..

Альбина йокыдан айнып китте. Аның анадан тума шәрә тәне өстендә йонлач җилкәле авыр ир кеше ята иде. Туктаусыз нидер пышылдавыннан кыз берни дә аңлый алмады. Ара-тирә чия төсле кызылга буялган ястык-мендәрләр идәнгә кыйшаеп төшкән. Әллә төш, әллә өн иде бу.

### 6

Шәһәр өстенә күгелҗем-зәңгәр кич иңеп килә. Казансу иртәгәге көннең матур буласын вәгъдә иткәндәй назлы кыз бала кебек елмая, аннан-моннан исеп кузгалгалаган салкынча җил черкиләрне куак арасына сөрә. Тынлык.

Ханбал да, Альбина да яр кырыена утырган урыннарыннан кузгалырга җыенмый иделәр төсле. Ханымның сөекле Айзигы чабып йөрүдән тәмам туеп, аның алдына килеп башын салган хәлдә ят иргә үз итеп сак кына карап куйгалый.

Бу серле вакытларын бер-бер рәссам күреп алса, һичшиксез, үзенең күз нурларын тамыза-тамыза берәр картина ясап, музейларны бизәр иде. Әмма бу тирәдә һич кенә дә чит-ят адәм әсәре күренми шул. Ханбал белән Альбина егет һәм кыз шикелле онытылып утыралар да утыралар. Анда-санда колак артларында безелдәшкән черкиләргә дә игътибар итмиләр төсле. Ханбал хакында нәрсә сорарга мөмкин булса, Альбина барысын да белешеп бетерде. Хәтта беренче мәхәббәте хакында азмыкүпме мәгълүмат алды. Егеткә карата күңелендә изге хисләр уянып, ул аны әле бертуган энесе төсле якын итте, әле яшьлегендә югалткан сөекле яры кебек күзаллады.

— Үзегез хакында бернәрсә сорашмадым инде, сөйләдем дә сөйләдем,— диде Ханбал, үкенгәндәй итеп.

— Беренче тапкыр гына очрашуыбыз түгелдер әле, барысын да белергә өлгерерсез,— дип Альбина тагын серле генә елмайды. Әмма бу сүзләре Ханбалга очрашып-танышып киткәндәгечә тәэсир ясамады. Үз истәлекләреннән үзе үк боегып калган егет күңелендә хатирәләр чишмәсе саф суларын ташытып кайный иде.

— Бәлки, кайтырга вакыттыр?

— Азрак утырыйк инде,— дип киреләнде Альбина.

Ханымның бу сүзләренә буйдак буйсынмый булдыра алмады. Муен төбенә утырган черкине шап итеп сытты да:

— Иртәгә көн яхшы буласы,— дип куйды.— Болар да котырына башладылар, кичнең бар ямен җибәреп.

— Кузгалыйк алайса,— диде Альбина.

— Бу тынлыкта утыруы рәхәт бит әле! — дип киреләнде бу юлысы Ханбал.— Балыклар да уйный башладылар, күк йөзеннән йолдыз чүпләргә тырышулары, ахрысы.

Бу сүзләре сәер булса да, кызык кына килеп чыкты. Икесе дә шәмәхәләнеп калган төнге күк йөзенә төбәлделәр. Дөресрәге, өчесе дә. Аларга карап Айзик та югарыга текәлде. Альбина белән Ханбал йолдызларны күзләсәләр, ул аларның күзенә күренмәгән сихри хәрәкәтләргә игътибар итте. Ханымның вә егетнең күңеленнән чыккан җылы нурлар бер-берсенә таба тартыла, әмма якынаеп җитә алмый иделәр.

— Ә син йолдыз санарга яратасыңмы?

— Белмим,— дип җавап бирде Ханбал.— Шулай студент чакларымда колхозга көзге эшкә аткарганнар иде. Ул кадәр йолдызларны гомеремдә дә күргәнем булмагандыр. Бөтен күк йөзе энҗе сибелгән төсле ялыкйолык килеп тора иде, хәтеремдә шул калган.

— Берәр авыл кызын озата баргансыңдыр!

— Болай гына инде, озатып карагандай иттем. Аларның гадәтләрен белеп бетерергә мөмкинмени? Киләсең, капка төпләрендә утырасыңутырасың, кереп китә белми. Йокларга вакыт иде. Арган идем. Кайттым

да киттем. Икенче көнне бөтен авыллары белән үземнән көлеп йөрделәр, кызлар да озата белмим икән, имештер.

— Кызык иткәннәр икән үзеңне...

— Бик үк кызык булмады шул.

— Уҗым бозавы дигән исем дә такмадылармы соң?

— Кем белә инде аларныкын. Шулай да, китәр көннәр якынлашкач, тагын берсе артыннан барып карадым. Ул әйтә: «Капка төбендә калдырыр булмасаң гына озата кил!» — ди. «Ярар!» — мин әйтәм. Ә ул бөтенләй капка төпләренә кайтмады, таугa алып менеп китте. Менә шунда күрдем мин ул йолдызларны. Акыллы кыз икән. Барча йолдызларны исемнәре белән атап чыкты. Татарча инде билгеле. Шаклар каттым. Сорыйм моннан: «Йолдызларның да татарча атамалары бармыни?» — дим. Ә ул көлә. «Нәрсә, татарга йолдызлар яктырмый дип уйладыңмы әллә?» — ди. Миңа да кызык булып китте. «Әйдә, — мин әйтәм, — өйрәт әле, татарча исемнәрен белеп калыйм!» Ә ул: «Әйдә!» — ди. Төне буе аңа ияреп йөрдем. Йокы качты. Таң белән генә авылга кайтып төштек. «Хәзер адашмам, озатып йөрмә!» — диде дә китеп барды, кайда торганын да белми калдым. Икенче көнне клубларына да чыкмады. Нәрсә булгандыр? Ә очрашасы килде үзе белән, барып кына чыкмады.

— Кайсы якта булдыгыз соң?

— Апас районында, Бурсыкмы, Урсакмы, дигән авылда инде.

— Апас кызлары бераз хәйләкәр инде алар.

— Шулайдыр...

Ханбал чыннан да яшькә үтеп, акылга малайлар хәлендә калган иде. Альбина аның мондый беркатлы булуына эчтән генә куанып та куйды. Һай, ничәнче кат көлдерә инде үзеннән бу сакаллы сабый. Әмма аның белән сөйләшүләре рәхәт. Һичбер катлаулы материя мәсьәләләренә керми. Сабый да сабый, бу да сабый!

— Соңыннан очрашмадыгызмы соң?

Альбина тагын да кызыклы хәбәр ишетәчәгенә ният тотып сорап куйгач, егет сүзсез генә борынын тартты да:

— Юк шул! — дип әйтеп салды.

«Һай ул кыз мин булсам! — дип уйлап алды Альбина. — Ә нигә, үзем хакында әллә ниләр сөйләмәдем бит әле. Кайдан икәнлегемне дә белми, шаяртыйм әле үзен!..»

Ханым фикерен төенләде дә егеткә:

— Ә ул кыз мин булсам, нәрсә әйтерсең? — дип елмайды.

— Юк ла, — диде Ханбал, — шаяртасыз гына. Аны ут яктысында күргәнем бар иде минем. Ямьсез генә, сипкелле генә, кече борынлы бер кызчык сыманрак иде. Кая, ди, ул, юк. Сезне аның белән һич чагыштырырга мөмкин түгел, чынлап әйтәм!

Альбинага кыен булып китте. Ник шаяртканына үкенде. «Сабый, дип уйласаң да, хәтере яхшы икән, ялганнан чынны аера белә!» — диярлек фикерен төенләп куйды.

Алар кайту ягына кузгалдылар. Артларыннан Айзик иярде. Башын салып кына юыртты, әле егет ягына чыгып басты, әле хуҗасының аяк астында бөтерелде:

— Ашыйсы килә! — диде Альбина.

— Аннан йоклыйсы килә, — дип өстәде Ханбал.

Икесе дә көлешеп куйдылар.

Ханбал аларны йортлары каршысына кадәр үк озата барды. Әмма, ханымның үтенече буенча, алдан үзе кайтып китте. «Артларыннан күзәтеп килмәскә шулай таләп иткәндер инде!» — дип уйлады.

Үзләренә кайтып җиткәч, подъезд төбендәге утыргычка юнәлде. Федорларның да, ни хикмәт, тәрәзәләрендә ут сүнмәгән иде әле. «Бик иртә ята торганнар иде, бер-бер хәл булмагандыр бит?» — дип уйлап куйды ул. Күзләре аларның катыннан күтәрелә-күтәрелә, күккә текәлделәр.

Моннан да ачык кына күренә йолдызлар. Әмма башына бөтенләй бүтән уй килде егетнең: «Кара әле, теге исерекләргә Альбина ханым зажигалка чыгарып биргән иде, тарта микәнни? Бер дә сиздермәде! Кызык бит, ә?»

Ханбал утырган җиреннән кузгалып, подъездга чумды. Әмма нәрсәседер онытылып калган шикелле кире борылып карады. Ишектән төшкән яктылыктан кара тимгелле ак этнең йөгереп узганлыгы күзенә чалынгач, урамга чыкты. Әмма анда һичкем юк иде. «Күземә генә күренгән икән!» — дип уйлады да, фатирына күтәрелеп, газга чәй куйды.

## 7

Альбина чыннан да Ханбалның артыннан килгән иде. Максаты гади һәм гадәти булып, егетнең әйткән йортында яшәгәнме-юкмы икәнен белешү, карап калу һәм, шуннан чыгып, аның сүзләренә ышанырга мөмкинме икәнлеген төшенү иде. Ханбал утыргычтан күтәрелеп, подъездына кереп киткәндә, Айзик алга тартылып, чыннан да, аның артыннан менмәкче дә иде шикелле, әмма хуҗасын ташлап калдырганлыгын аңлап, кире борылды. Альбина ишек төбеннән узып, куаклар һәм агачлар белән капланган сукмактан атлады. Әгәр дә Ханбал шунда иренмичә тагын ике-өч адым алга киткән булса, алар, һичшиксез, күрешәчәкләр иде.

Аның баскычтан күтәрелгән аяк тавышларын Альбина санап барды. Беренче һәм икенче каттагы подъезд тәрәзәләре өлгеләре белән үк коелып төшкәнлектән, алардан Ханбалның сыртын күрү авыр түгел иде. Арганлыгы сәбәплеме, әллә күңеле сизенепме, егет теләр-теләмәс кенә күтәрелде. Мөмкин урыннардан урамга текәлеп караган кебек итте. Шулай берсендә Альбина белән күзләре очрашкан төсле дә булып китте. Ханымның күкрәгенә ут йөгерде: «Һай, хәерсез дә инде мин! Күреп алса, нәрсә уйлавы мөмкин? Артымнан килгән, дип әйтәчәк!»

Ул арада бишенче катта ут сүнде. Альбинаның нәкъ күз очларына гына яктыртып тора, чагылдыра иде. Яхшы булды әле.

Ханбал өченче катка менеп җитте, ачкычларын шалтыратып алды. «Айзик!» — дип ярым тавыш белән генә дәшеп, Альбина эте белән йортның икенче ягына чыгарга ашыкты. Бер бүлмәле фатирларның тәрәзәсе подъезд ягыннан булмый!

Ханбал кухня ягында ут элде. «Тәрәзәсенең дә челтәре юк икән!» — дип уйлап куйды Альбина. Буйдаклар тормышы шундый хәлдә инде ул. Бар эшне дә үзе карагач, бөтенесенә дә җитешә алмый.

Хуҗасыннан күрмешли, Айзик та Ханбалның тәрәзәсен күзәтте. Моннан ачык күк йөзе шикелле барысы да аермачык күренеп тора, баш кашып, терсәгенә таянып утыруларына кадәр.

Ханбалның суыткыч ишеген ачканын хәтерләп, Айзик шыңшып куйды. Аннан соң телләрен ялады. Әмма аның киштәләрендә бер дә күңел кызыктырырлык нәрсәләр күренмәде.

— Һай сөеклем, ашыйсың килдемени? — дип елмайды Альбина төкерек йоткан этенә. — Хәзер кайтабыз, туйганчы ашатырмын үзеңне. Тик ашыктырма гына, барысын белеп бетермәдек ич.

Ханбал, шушы гына сүзне көткән кеше төсле, урыныннан кузгалып, зал ягына атлады. Ул, әлбәттә, үзен күзәтеп торганнарын белми иде. Ут элде. Тезеп куелган, алар өстенә яткырып өелгән тузанлы китаплар авырлыгына чак түзеп торган киштәләр янына килеп, нәрсәдер эзләде. Калын гына бер төпләнмәне кузгатып куйды. Күңеле сизенепме, тәрәзәгә таба борылып, килә башлады. Әмма урамга күз салуны кирәк тапмады, яртылаш бер читкә кайтарылган челтәрен тартып куйды. Инде ул хәзер алай ук ачык күренми иде. «Залдагы челтәре Сирийский икән!» — дип уйлады тагын да Ханбалга бәя бирергә теләп Альбина. Бу әле бернәрсә хакында да сөйләми иде, чөнки андый затлы әйберләрне совет чорында

гына табуы авыр һәм танышлыклар аша гына булып, хәзер теләсә кайда, кибетендә дә, базарында да тулып ята, акчаң гына кирәк, акча гына!

Максатына ирешеп, Альбина кайту юлына юнәлде. Егетнең фатир номерын да карап төшмәкче иде дә: «Нәрсәгә кирәк, урынын белдем бит инде!» — дип ул фикереннән кире кайтты.

Төнге җил, адашыпмы, Альбина янынннан узып китте. Аның артыннан тук башаклы арыш басуы исе таралып калды. Шушы зур вә тынчу шәһәр урамында иген тәме булу бик тә сәер иде. Айзик шыңшып куйды.

Фатир ишеген ачып җибәргәндә ханым буылып шалтыраган, дөресрәге, сузылып сызгырган телефон тавышына бераз сәерсенеп аңлашмыйчарак торды да, кабаланып эчкә ташланды. Ире булса кирәк, чит шәһәрдән шалтыраталар. Әмма җитешә алмады. Телефон трубкасын күтәргән вакытта икенче башында аны борчылып эзләүче кеше куеп өлгергән иде. «Фу!» — дип Альбина үз алдына ачуланды, артыннан килеп җиткән Айзик та: «Аз гына иртәрәк кайтсак иде!» — дигән төсле шыңшып алды.

Фатир ишеген эчтән өч йозагына да бикләп, Альбина кухняга керде. Затлы күренештән туйган күңеле боегып калды. Айзигына ашарга консерва ачып, табагына ике өлеш артыграк бушатты:

— Аша-аша, акыллым! Синсез нишләр идем...

«Чәй куеп эчәргәме?» — дип уйлаган иде дә, нигәдер иренде, суыткычтан сайланып кына кап чыгарды, беразын фужерга бушатып, читкә этәрде. «Анис» сигареты алып кабызды һәм Айзикның ничек комсызланып ашавын карый-карый сут йоткалады. Бу вакытта аның күңелендә бернинди уй вә теләк юк, хисләре вә акылы аяк салындырып ял итә иде.

Эте ашап туйды, табагын ялап, теле белән ирен асларын, авыз кырыйларын чистартты һәм үз урынына, залга кереп, келәмгә сузылып ятты. Сигаретын сүндергән Альбина аның артыннан иярде. Һаман аяк астында булмасын дип Айзикны иркенрәк урынга, кечкенәдән үк залга ияләндергәннәр иде.

Өч бүлмәле фатирларының берсе Альбинаның үзенә, икенчесе иренә аталып, хәтта йоклаулары да шулай аерым-аерым иде. Геннадий, яшьли Маркска гашыйк кеше буларак, бар гадәтләрен дә шушы шәхес үрнәгендә нигытты. «Ул хатынынннан аерым йоклаган, кирәгендә генә янына килгәләгән!» — дип, Альбинага да алдан ук өйрәтеп куйды. Моның серен ханым баштарак төшенмәде, әмма бергә яшәүләрендә тормыш моның да мәгънәсен ачыклап бирде: иреннән көнләшү хисен аерым йоклау аркасында тәмам югалтты.

Ә башта, язылышып тора башлагач, бигрәк тә, Геннадий соңга калып кайтты исә, җен ачулары котырып, үзен-үзе белештермәү дәрәҗәсенә кадәр җитә иде бит! Ничек түзгән дә, кайлардан гына шулкадәр сабырлык алган? Чит-ят хушбуй исләре белән аңкып, хәлен белештермәү дәрәҗәсенә кадәр исереп кайткалый иде бит ул. Андый вакытларында күзе һичкемне күрмәде, дөньяларны әйләндереп ташлардай кылана иде. Нишләп йөргәнен, кайларда типтерүләрен аңламый иде Альбина. Акыл бирүчесе дә булмады. «Мин җүләргә шул кирәк!» — дип үз-үзен генә битәрли иде дә, еларга җөрьәт итмичә, эчтән генә сыктый-сыктый чишендерә иде исерекне.

Балалары булмаячагы беленгәч, ире бөтенләй чыгырыннан чыкты. Үзен гаепле дип уйлап та карамады. Юк, анда гаеп бармы соң, элекке хатыны, әнә, ике бала белән аерылып калды, өч ай да үтмәде Геннадий Альбина белән яшәгәнгә, кияүгә дә чыкты. Асыл кошлар җылы оясыз кала димени?

Ә Альбинаның мәңгегә бала назыннан мәхрүм калуына чынында Геннадий гаепле иде дә бит, йөзенә бәреп әйтә белмәде, исенә төшерүне кирәк тапмады. Әгәр дә төнге мажараларыннан вакытында тукталмаган булса, Альбина аны ташлап китәсе иде. Дөрес, китәргә талпынып карады ул. Студент чагында ук, дөнья читенә, җәһәннәм авызына, әмма Геннадийның кулы озын иде шул. Артыннан килеп тапты. Яратачагын

белдереп вәгъдәләшкәнлектән: «Сүзендә тора булыр!» — дип уйлады шунда ханым. Ә яратуы, чыннан да, хак иде.

Алабуга комсомол конференциясенең банкетыннан соң ничек оятлы хәлдә калдырса да, ташламады ул Альбинаны, үзенә басып йөрде, әле Казанга чакырттырды, әле үзе килеп чыкты. Таләбе бер генә нәрсә булды: хисләргә күмелгән татлы кочак!

Шушындый төнге марафоннардан соң Альбина кияүдә тормаган килеш ике тапкыр балага узды. Беренче мәртәбәсендә сөяркәсенә әйткәч, хәзер үзенең аңа өйләнәчәген белдерәчәк инде, дип көтте. Әмма ялгышты. Геннадий үрсәләнде, борчылды, әмма чыгып та китмәде. Казаннан ук Альбинасын күрү өчен йөгереп килеп җиткән иде бит. Хыялында гына йөрткән асыл кошның назын ташлау мөмкинме соң?

— Матурым, чибәрем минем, бер дә борчылма, барысын да хәл итәрбез! Безнең киләчәк тормышларыбыз алда әле. Хәзергә бала кирәкмәс, аны калдырып торыйк, бәхетебезгә аяк чалмыйк, җитешербез, бик җитешербез! — дип сөйләнде.

Альбина каршы чыкмады. Ул әле Геннадийның саф күңеле булуына чын күңеленнән ышана, хәтта аның өйләнгәнме-юкмы икәнлеген дә ачык кына белми иде. Бер тапкырында: «Синең хатының бармы, Гена абый?» — дигәч, сөяркәсе тыныч кына: «Ансы нигә әле аның?» — дип, сүзне читкә борып киткәннән соң ул теманы бер генә тапкыр да кабат кузгатмаган иде. Ә менә хәзер, көтелмәгән хәбәрне белдергәч, ул үзе үк ачылды да куйды:

— Минем бит тормыш иптәшем бар! Моңа кадәр әйтмәгән идем, хәзер яшерә алмыйм, шунлыктан тиз генә бергә гаилә корып җибәрә алмабыз дип беләм. Сабыр итик. Бик яхшы таныш врачларым бар. Бернинди хәвефсез ярдәм итәрләр...

Альбина, ни хикмәт, Геннадий Вәлишинны үлеп ярата иде. Ни әйтсә, шул дөрес һәм шулай булырга тиеш дип кабул кылып буйсынды. Бу төндә дә мәхәббәт назында бар теләкләре дә канәгатьләндерелгәч, таң белән ир китеп тә барды. Артыннан, һичшиксез, машина җибәртәчәген белдерде. Сүзендә торды. Ике көннән «Волга»сы әйләнеп тә килде, Альбинаны алып та китте. Тик кияүгә түгел, Казан шифаханәсенә.

Шул килүдән ул бала төшереп кайтты. Кире үзе озата килә алмаса да, Геннадий сөяркәсен ташламады, тагын «Волга»сы белән китереп куйдылар. Җитмәсә шоферы ике пакет татлы ризыклар тулы күчтәнәчләр дә калдырып китте. Альбина хәвефнең җиңел кулдан үтеп китүенә сөенде. Ул инде институтны уңышлы гына тәмамлап, аспирантураның беренче курсында укый, бер бүлмәле, яхшы җиһазландырылган кеше фатирында гомер кичерә. Ашау — байдан, үлем — Ходайдан, дигәндәй, бер дә борчылырлык җире юк иде. Айга бер килеп күренгән хуҗа хатын аның хәлен белешеп китә, түләр акчасы юк икән, сорамый, булса, баш тартмыйча ала. Аның каршында Альбина үзе җай гына торырга тиеш, югыйсә, әмма гел елмаеп сөйләшкән бу әби, киресенчә, үзен кимсетебрәк тота: «Булыр әле, бәбкәм, булыр, акчаң килгәч бирерсең!»

— Бусы әле башы гына, мин сине җәннәтнең үзендә яшәтәчәкмен! — дип мең вәгъдәләр бирә иде Геннадий да. Альбина аңа ышанды, шунлыктан тупсасыннан бүтән бер генә чит ир заты да атлап кермәде. Ярата иде ул, бик ярата иде шушы кара чәчле, киң маңгайлы, ак йөзле өлкә комсомол комитеты җитәкчесе Вәлишинне. Берәр гәзит яки журналда исемен генә очратса да, сурәте күренсә дә, хәзер кулына кайчы алып, пөхтә генә кисә дә, үз альбомына конфет кәгазе җыйган сабый кызчык төсле ябыштырып куя иде. Һәм ул аларны карарга керешә икән, дөньяларын оныта инде. Йөзендәге һәр сызыгын өйрәнә, күз карашларына соклана, җил кузгаткан булса, чәчләрен сыйпап куярдай булып үрелә. Сурәт түгел, үзе итеп, тере, дип күрә, сөйләшә, диванага сабыша.

Геннадий кебекләр, сөяркәләре буйга узса, аларны тизрәк ташлап качарга, баланың үзенеке түгеллеген тәкърарларга тотынсалар да, Аль-

бинаны секретарь әрәм итәсе килмәде. Артыгы белән чибәр бит, чукынчык, төшләреңә кереп саташтырырлык. Кем аның белән тиңләшә ала? Юк бүтән андый зат дөнья йөзендә! Әгәр дә калдырса, Геннадий кебекләрне генә Альбина йөзне, хәтта мине табаячак, аларны бәхетле кылачак! Ә син карьера өчен өйләнгән ямьсез хатының белән торып калачаксың, гаилә назыннан, бәхетле тормыштан мәңге читтә йөриячәксең! Менә шулар хакында кат-кат уйлап, Вәлишин тиздән сөяркәсен хатын итәргә ниятләгән дә иде, көн артыннан көн үтеп, максатына ирешү теләген тышаулап, сабырлыкны таянычы ясады. Әмма сагынмый кала алмыйча, кайбер айларга өчәр-дүртәр тапкыр да Алабугага машина кудырды. Ярый әле Казан уку йортларының берсендә аспирантурага алдырмады, юкса бөтенләй башы бетәсе иде, мәхәббәт хәлләре барлык халык каршысында, күз алдында булыр иде. Алабугада торуы яхшы әле, аңлашмыйча да калалар!

Альбинадан галим чыгарлык түгел иде. Моны Геннадий үзе белмәде, гомерендә дә төптән фән нигезләрен актару белән шөгыльләнгәне булмагач, ул эшнең никадәр авыр вә кыен икәнлеген төшенерлек дәрәҗәдә түгел иде. Дөрес, ул университеттан соң партия юлламасы белән Югары курсларда укып кайтты. Аңа анда тема биреп эшләттеләр. Берничә китап нигезендә реферат шикелле нәрсә язды да тапшырды, шуның белән хәтта кандидатлык дәрәҗәсен дә алды. «Фән шулай җиңел әйбер икән!» — дигән фикер белән коралланган хәлдә, ул барлык көчен оештыру эшенә юнәлтте һәм ялгышмады, бу өлкәдә шулкадәр өлгерлекләр күрсәтеп, тиз арада югарыга үрмәли бирде. Партия өлкә комитетында җаваплы бүлекләрнең берсе саналган һәм үз кешеләр арасында гына шаяртып «Цензор» кушаматы белән аталып йөртелгән, калын кысасыз күзлек киеп йөрүче хәбәрләндерү комитеты җитәкчесе Сабир Габделбәрович Вафинның тынкыш борынлы кызына ярәштерелгәч, Вәлишинның дәрәҗәсе бермә-бер күтәрелеп китте. Карьера мәсьәләсендә үтә дә сак һәм беренчелекне кулдан ычкындырырга бер дә исәпләре күренмәгән аның кебек акыллы баш яшьләрнең Геннадий ясаган шушы адымнан соң кикрикләре шиңде. Өлкә комитетында һәм Үзәктә комсомолларга Татарстанда нинди җитәкче булырга тиешле, дигән сүз кузгатылгач, Вәлишиннан да яхшырак кандидатура табылмады. Мәскәү исә өлкә комитетының фикеренә каршы чыгарга теләмәде. Алда зур эшләр торганлыктан, таркаулык бер дә файдага түгел иде.

Бар нәрсәләрне алдан белеп һәм белешеп торган атасы, ягъни бабасы,— Геннадий аны Казан гадәте буенча әти дип йөртә иде,— Сабир Габделбәрович киявенә кайда ничек сөйләшергә, кем янында үзен ничек тотарга, кайчан артка басарга, кай вакытта үзенең барлыгын белдереп алга кукыраеп чыгарга тиешлекләрне өйрәткәләп, аңа юл күрсәткәләүне дә кирәк тапты. Әмма Вәлишин үзе дә төшеп калган кешеләрдән түгел иде. Атлаган саен ата киңәше белән генә йөреп булмый шул! Берничә тапкыр командировка алып, КамАЗга барып, анда үз бүлеге буенча комсомолларның эшен тикшереп, җыелышлар үткәреп кайтты. Өченче генә булса да, комсомол өлкә комитеты өчен өченче бит ул, аның эше — идеология, яшьләрне героик хезмәткә тарту, аларга рухи җитәкчелек күрсәтү, димәк, ул иң кирәкле кеше, иң кирәклесе,— ул үзен беренче кебек тотты. Җыелышларда, идеологларның киңәшмәләрен үткәргән вакытта:

— Безнең максат — халыкны данлыклы хезмәткә рухландыру, аларга үзләрен эш белән күрсәтү өчен мөмкинлекләр ачу, юл күрсәтү! — дип тезеп-тезеп кенә ялкынлы гыйбарәләрдән сүзен башлап китә иде дә, алга таба да шул юнәлештә тимерне кызу тота иде: — Әгәр дә һәр кече ячейкада идеологлар, агитаторлар булмаса, алар үз иптәшләренә рухи көч бирә алмасалар, ул вакытта комсомол йөрәгендә дәрт бетәр, алга омтылыш та юкка чыгар иде. Моннан да мыскыллы түбәнлек юк. Идеология эше, агитация — безнең йөрәгебез. Әгәр дә ул туктала икән,

димәк, йөрәге туктаган кеше төсле, без дә бетәбез, без дә үләбез. Шунлыктан комсомол, бигрәк тә сез, яшь эшчеләр, хезмәткә булган дәртне сүндермәс өчен партиябез тарафыннан даими үстерелештә, алга омтылышта алып барылган марксистик-ленинчыл идеологиягә тартылырга, ялкынын һәрбер кешегә күчерергә бурычлы. Безнең юл бер генә, ул — коммунизм! Ул — сез һәм сез төзегән шушы заводның тизрәк автомобильләр чыгарырлык дәрәҗәгә җитүе, ә ул машиналар, сез һәм без төзегән заводның илгә бик кирәкле машиналары, әлбәттә, халкыбызны коммунизм юлыннан тизрәк алга алып китәр вә китереп җиткерер. Мин моңа ышанам, Маркска һәм Ленинга ышанган төсле ышанам, данлыклы партиябезнең һәр сүзенә чын күңелемнән ышанган төсле ышанам!..

Мондый сүзләреннән соң кемнәрнең күзләреннән кайнар яшь бөртекләре күренә башлый, кайсылары «ур-ра!» кычкырырга керешә, зал шашынып кул чаба. Вәлишин тантана итә. Сурәте гәзитләрдә дә сирәкмирәк күренгәли. Сабир Габделбәрович та кияве кайтып җиткәнче үк болардан хәбәрдар. Җилкәсеннән сөеп, мактап каршы ала, кабинетына чакырып, эчке бүлмәгә дәшә дә:

— Син, кияү, үз улым төсле бит, миңа бик якын. Яраттым үзенне,— дия-дия сөйләнгәләп, күңелендәгесен чыгарып салгандай мәтәштерә дә,— ашыкма, кабаланма, отчет язып бирергә житештерсең әле, менә, эчеп, хәл җый,— дип киңәш бирә-бирә сыйлый үзен.— Беренчегә чыгышларың бик ошаган, әмма үзегезнекенең кәефе кырылды. Бер дә урыныннан кузгаласы килми бит. Өлкә комитетына инструктор итеп чакыртырга уйлаганнар иде дә, тыелып калдылар: алдыларммы, аның урындыгына Икенчегез менә дә утыра. Син, төннәрен йокламыйча, аларның эшен эшләп йөрисең, җылынып кына яталар!

Сабир Габделбәрович серле генә елмаеп куя.

— Сиңа, кияү, бер сюрприз бар бит әле минем! Әйтмәм, дигән идем дә, картайдыммы шунда, булдыра алмыйм. Белеп тор әле: синең хакта Үзәктә бик яхшы гына фикерләр туплансын өчен дә ярдәме тияр, артыннан бер журналистны җибәреп, очерк сыманрак нәрсә әзерләттек әле! Бер нөсхәсе белән танышып та чыга аласың. Безнең Беренче дә бик хуплады, «Комсомольская правда»га юллаттырды. Шәп язган. Җыелышларында да катнашкан. Өченче көнне үк кайтып җиткән иде, кичә мәкаләсен монда кертеп чыкты. Бүген иртәннән бездә гел шуның хакында гына сүз. Ничә кеше шалтыратты инде. Ул да! Мин кичә фатирыгызга да кереп чыккан идем, өеңдә булмадың. Хатынның ялгызы гына иде. Тоткарланган чаклар булгалый инде ул, булгалый...

Сабир Габделбәрович текә генә сынап карагач, Вәлишиннең арка тамырлары чымырдап китте. Чаллыдан кайтышлый, берничә сәгатькә генә Менделеевскидагы әти-әнисенең хәлен белешеп чыгарга әллә ничек кенә теләге кузгалган иде шул. Керәшеннең дә үз гадәтләре бар. Берничә сәгать дигәне өч көнгә сузылды. Мәктәптә укыган чагында гыйшкы төшеп, тормыш юлларына кергәч, читтә онытылып калган мәхәббәте Галина иреннән аерылып кайткан икән. Геннадийларга да кереп чыккан, сәламнәр юллаган. Менә шул адаштырган иде, ни пычагыма кирәк булгандыр үзен барып күрү?

Вәлишиннең ике колагы да утка пешкән кебек кызарды. Ул да түгел: «Барысын да белеп торалар икән!» — дигән уе башыннан узуга, бөтен битен ялкын каплады. Әмма боларның берсен дә белмәгән һәм бу очракта белергә дә теләмәгән Сабир Габделбәрович киявенең болай коелып төшүен үзенчә кабул итте, ояла, кимсенә, дип нәтиҗә чыгарачыгара сүзен сөйләүдә булды:

— Төнге уннарда Чаллыга, күрсәтмәләр бирү өчен, беләсеңдер, Горбатовка шалтыраттым. Синең хакта да сүз кузгаттым. Чаллыда түгел идең...

Ул тагын Вәлишингә: «Сак бул, малай актыгы!» — дигән төсле карап куйды.

— Синең бер яхшы сыйфатың бар! Бер чыккач, тегендә-монда кагылып үтәсең. Элеккесендә дә Чистайларны урап кайттың. Мондый эш стиле бәрәкәтле ул, кияү!

— Киңәшегезне тотып инде, киңәшегезне!

Вәлишиннең теленнән әле дә ярый кирәкле сүз вакытында чыгып өлгерде, бердән кызыл йөзе дә төсенә кайтты, авызы да ерылып китте. Сабир Габделбәрович, аннан боларны ишетеп, канәгать өстенә канәгать иде, мин сиңа әйтәм! Менә шулай берсенең ныклы ягы, икенчесенең йомшак сыйфаты ачылды да китте. Геннадий сер бирмәс рәвешен ала башлады, иргә әверелде дә китте.

Бабасы алдамады. Бер атнадан аның хакында татлы гына очерк «Комсомольская правда» газетасында басылып чыкты. Шушы куанычтан канатлары үсеп, үз-үзен белештермичәрәк йөрүенең өченче көнендә Мәскәүгә чакырттылар, партиянең өлкә комитеты беренче секретаре аңа, кулын кысып, хәерле юл теләде. Казаннан комсомол өлкә комитетының өченче секретаре хәлендә чыгып киткән җиреннән ул Беренче булып кайтып керде. Тиз ара конференция җыелып, аны җитәкчелеккә тәкъдим итәргә Мәскәүдән ВЛКСМның генеральные үзе килде. КамАЗ тарта иде аны. Комсомолъяшьләр төзелеше саналсын да, ничек әле ул читтә калырга тиеш? Конференциянең башыннан ахырына кадәр дилбегә аның кулында калды. Янында җитди кыяфәт белән Вәлишин утырды. Шуннан бирле ул өлкә комсомол комитетын җитәкләп, тайпылышсыз принципларыннан ахырда тәмам читләшеп, вакытлар җитү белән, менә хәзер бер байгурага әверелде...

Эте артыннан кереп, Альбина ут яндырды, ятканмы-юкмы икәнлеген тикшерде. Аннан соң кухняда утны сүндереп, ишек бикләренә кабаттан күз салды. Үз бүлмәсенә узгач, видеомагнитофон кабызмакчы булып, кассеталарына карап торды. Әмма аның шкафындагылары кат-кат күрелгәнлек сәбәпле, икенче ягына чыкты, андагы кассеталарның исемнәрен укыды. Бер дә юньлесе юк иде, кайсы — бизнес мәсьәләләре буенча өйрәтмәләр, кайсы — кызыксыз язмалар.

Альбина, күңелсезлек тоеп, кулына китап алмаякчы иде, киштәнең аркылысына өелгән кәгазьләр ишелеп төште. Арада бер калын папка булып, ханым кызыксынып, аның титул битен ачты. Кире япты, кабат ачты. Анда эре басма хәрефләр белән «Мөхәммәд пәйгамбәр һәм сөеклесе Хәдичәнең мәхәббәте, яки Олуг гыйшык серләре» дип язылган иде. Аскарак «кыйсса» дип җәя эченә куелган. Шуларны укыгач, Альбинага кызыклы кебек тоелды, чәчелгән дәфтәр һәм кәгазьләрне дә җыярга онытып, үз ягына чыкты, урынына җәелеп, баш астына мендәр кыстырды да укый башлады. Кыйсса аны мажаралары эченә алып кереп китте.

## 8

Марфаны тонык күзлекле, сары йөзле хәрби киемдәге кеше каршысына китертеп утырттылар. Барлык сыйфатларыннан күренгәнчә, ул татар иде. Шунлыктан аңа ышанасы, Самуилны яклап чыгар, дип бөтенесен дә бәйнә-бәйнә сөйләп бирәсе килде. Әмма сорау алу башлангач, дорфалыгы белән Марфаның һәммә уйларын аяк астына салып таптаячагы ачыклана барды. Кешегә кеше охшамый шул!

Каршысына килеп утыргач та җирән адәм икәнлеген аермачык хәтерләп калмаган Марфа җавап тота-тота, аның барлык мимикаларына кадәр игътибар итә башлады.

— Самуил дисең инде,— дип мыскыллы елмайды ул.— Ә без аны Исмәгыйль Вәлиев дип беләбез. Комсомолка башыгыз белән ничек итеп шундый халык дошманы белән дуслашып киттегез, барысын да бәйнәбәйнә сөйләп бирергә туры килер. Ялганлау аның белән бер юлда йөргәнсез дигән сүз, җаваплылыкны аңлыйсызмы?

— Нинди халык дошманы ди ул? Бер дә алай түгел!

Марфа уйламыйча җавап бирде. Ә югыйсә бер генә сүз җитә иде. Әгәр дә: «Аңлыйм!» — дигән булса, тикшерүче бу кадәр җикереп кычкырмас иде:

— Молчать!

Кырыенда утырган икенче милиционер да сискәнеп китте. Марфаның акылы буылды, күзләреннән яшь бөртекләре бәреп чыкты.

— Кем сораган әле аның кемлеге хакында сездән? Белербез! Һәм беләбез дә! Әгәр дә үз башыбыздан чыгарып әйтәбез икән, монда утырмас идек, мондый эшне тапшырмас та иделәр. Тагын кабатлап әйтәм: сорауларга гына җавап бирергә! Тикшерү эшен бутарга маташсагыз, ахыры начар бетәр, белеп торыгыз, гражданка Волкова! Кабатлап әйтәм: сорауларга туры һәм төгәл җавап бирегез! Үзегез өчен дә, безгә дә яхшы булыр. Сөяркәгез хакында әйтмим дә инде! Сорау. Кайчан һәм нинди шартларда таныштыгыз! Ни өчен ул сезнең авылга килеп йөри башлады?

Марфа сәерсенеп китте. Нигә кирәк инде болар моның өчен? Ни әһәмияте бар? Аңлый алмады. Икенчедән, Самуил белән булган мәхәббәтләренең серләрен ул хәтта газиз әнкәсенә дә сөйләмәде, иптәшләренә дә белдерергә теләмәде бит. Гүяки, көнләшерләр дә, араларын ераклаштырып, гайбәт таратырлар төсле тоелды. Күңеле алдан ук сизенгән булган икән!

—Ниләр хакында сораштыра, нәрсәләр турында сөйли иде? Барысын да бәйнә-бәйнә исегезгә төшерегез. Әле вакыт җитәрлек! Әгәр дә бүген бетәрлек түгел икән, иртәгә дә килерсез, берсекөнгә дә. Һәр детальне, төшереп калдырмыйча, бәян итүегез таләп ителә. Болар барысы да эшнең уңышлы барышы өчен кирәк!

Марфа, район үзәгенә слетка килгәч, Самуил белән ничек танышып киткәннәрен исенә төшерде. Чалт аяз көн иде. Ыспай гына киенгән, маңгай бөдрәләрен бер якка кайтарып куйган, нәзек күркәм мыеклы шушы егетне Марфа үзе беренче булып күреп алды, әллә ничек кенә аны күңеле якын итте. Ачык йөзе, елмайган иреннәре аның өчен сихри вә татлы кебек тоелды. Башы әйләнеп китте. Үзенә игътибар иттерү өчен яныннан ничәмә-ничә тапкырлар үтеп карады, ялгызы да, иптәш кызлары белән дә. Әмма егет күтәрелеп тә карамады, шаяртып сүз дә катмады, аңа атап әйтелеп үткән шаяртуларны да игътибарсыз уздырды. Аның каравы авылдашы Федя исә Марфаның алдына вә артына төште, бер дә бирмәде, хәтта кыздырылган көнбагыш белән дә сыйлап карады, биегән, җырлаган, шаулап күңел ачкан халыктан читкәрәк алып китәргә дә маташты. Уе барып чыкмасын җитәрлек кадәр аңлагач кына, иптәш егетләре белән җыелышып, кибеттән туктаусыз аракы ташып, тәмам исергәнче чүмерделәр. Ахырда исерешеп, кайсы канау буенда, кайсы тирәк астында мәлҗерәп йокладылар. Урыс егетләренең гадәтләре шушы иде. Ә татарлар итагать белеп кенә читтәрәк тордылар, кыенсынып кына биеделәр, җырлашып алдылар. Аның каравы Марфалар үзәктә булды, туйганчы гөрләштеләр. Тәмам исереп җиткән Федя әллә ниләр кыландырып йөрде-йөрде дә юкка чыкты. Марфа моңа куанды. Теге татар егете янына килеп сүз башларга, үзе сөйләштерергә ниятләде. Бәйрәм буе бер генә урында басып торганлыгын белгәнлектән, шул якны күзәтте, әмма ул да халык арасында юк иде инде. «Һай, барып чыкмады бу!» — дип кызның кәефе канат белән сыпырып ташлаган төсле бетте дә китте. Хәзер үк авылларына кайтып китәсе килә башлады. Инде җыенып та бетә язган иде, Исмәгыйльнең атлар янында ялгызы гына басып торганын күреп, шунда ашыкты. Килә килешкә:

— Безнекеләр күренмәдеме? — дип сүз башлады.

Егет елмайган хәлендә җилкә сикертте.

— Нәрсә, телегезне югалттыгызмы әллә? — дип шаяртырга кереште.

Егетнең русчасы болай ярыйсы гына иде. Сүз артыннан сүз ияреп, алар танышып киттеләр. Самуил инде кайтып китәргә җыена икән, ялгызы гына калган. Атының аркалыкларын күтәреп, хәзер юлга чыгасын белдергәч, Марфа, нинди җене котырыптыр, аның арбасына утырырга теләде:

— Мин дә җыенган идем. Әмма безнекеләр әле ашыкмый, үзегез белән алмассызмы икән?

Самуил аның кайсы авылдан икәнлеген сорады да кире дә какмыйча, әйдәкләмичә дә әйтеп куйды:

— Безнең авылдан сезнекенә кимендә сигез-ун чакрымнар бардыр! Бәлки үзегезнекеләрне көтәрсез?

— Куып җитәрләр әле! — дип Марфа киреләнгәч, утыртты. Һай, сөенгән иде ул шунда, һай куанган иде. Кыланып-кыланып иптәш кызларына кулын болгады:

— Мин үземә таптым! Куып тотарсыз... Безнең якка кайта.

Олы юлга чыккач, Марфа арбаның башына, Самуил янына күчеп утырды. Җайлап-җайлап кына бер-берсен сораштырырга тотындылар. Егет инде дөнья күрергә дә өлгергән, Фин сугышында катнашып, яше дә егерме өчтән узып киткән икән. Ә Марфага ул вакытта бары тик унсигез яшь кенә тулган көннәр иде. Әмма чибәрлеге вә чаялыгы белән ул Самуилдан өлгеррәк булып чыкты. Үзенең аның янәшәсендә утырып кайтуын кияүгә чыгып, аларга килен төшеп килүе кебек хис итеп, җаны-күңеле саташты.

Исмәгыйльнең авылларында сөйгән кызы юк иде. Моны белеп алгач, Марфа баштарак ышанырга теләмәде. «Ничек инде шушындый егетнең сөйгән яры булмасын, ди, бардыр, өрмәгән урындыкка та утыртмыйлардыр, йорт саен берәр чибәр татар кызы аңа серле мәхәббәтен багышлап, кич очрашуларга өмет тотадыр!»

Әмма ул болай уйлап ялгышты. Чыннан да, Исмәгыйльнең ярәшеп йөргән кешесе юк иде. Дөресрәге, бар иде ул, бар иде. Чибәр кыз, Гөлсара. Хәтта аның хакында җырлана торган «Комсомолка Гөлсара» дигән җыр да бар иде. Һәрхәлдә, аны Гөлсарага багышлап махсус чыгарылган җыр дип белә иде Исмәгыйльнең авылдашлары. Әмма алар бергә була, кавыша алмадылар. Исмәгыйль армиягә алынгач, ни сәбәптәндер, Гөлсара аңа бер генә дә җавап хаты язмады. Ә егет, бер-бер хәбәр юкмы, дип аның хакында әнкәсенә дә язып карады. Ни өчендер ул да җавап биргәндә Гөлсара хакында бер генә дә җөмлә яки киная аша нәрсәләр булып ятканын бердерергә кирәк тапмады.

Быел кыш кайткач кына белде серләрне Исмәгыйль: Гөлсарасы район үзәгендә җитәкчелектә эшләгән җаваплы партия адәменә алданган иде. Сораштыра торгач, әнисе аңлатып бирде.

Колхозларга еш барып һаман-һаман тикшереп йөргән район вәкиле, шулай чираттагы бер ревизиясеннән кайтып килешли, яңгырлы көн булып, арбасына Гөлсараны утырткан. Кыз ул вакытта авылда комсомол оешмасын җитәкләгән икән. Бераз танышлыклары булган. Вәкил аны үз янына алган, яңгырдан ышыкланыр өчен Гөрсара да каршы килмәгән. Юл уңае сүз кузгата бит, сөйләшеп киткәннәр. Вәкил, бик тә мут адәм, бераз төшереп тә алганлык сәбәпле, үзен бик җиңел тоткан. «Мондый көнне юлга чыгалар, димени, имеш. Бигрәкләр дә шәбәреп беткәнсең бит. Тәнеңә үтә су йөгергән, җылытыйм бераз, син миннән шикләнмә», — дия-дия, хәлгә кергән кебек кыланып, кызны кочагына да алган. Ул арада, әллә каушаудан, әллә чыннан да артык чылануыннан, Гөлсараны бизгәк тота башлаган. Вәкил тагын да хафага төшкәнрәк рәвеш чыгарып: «И-и, бала, хараплар гына булсаң, нишләрмен, менә генә гаепләрләр, менә тот моны, бер дә куркып торма!» — дип кесәсеннән шешә чыгарган, салып биргән. Мондый сүзләрдән соң кызның тагын да ныграк коты очкан. «Юк-юк, абый, мин урыс суын эчмим!» — дип баш тарткан. Әмма вәкил һаман үз сүзен сүз итеп: «Менә шунда, арбамда

суык тиюдән үлеп китсәң, ничекләр җавап бирермен! Эчә күр, балам, эчә күр! Синең хәлдәге кешегә урыс суы түгел, дару бит ул, дару!» — дип кыставын дәвам иткәч, Гөлсара чыдамаган, стакандагы аракыны эчеп тә җибәргән, бизгәге дә тукталган.

«Менә шулай, менә шулай,— дип вәкил куанып куйган.— Сүземне тыңласаң, сеңлем, бәхеткә кинәнерсең!» Шулай итеп, ул «бала»дан «кызым» дип сөйләшүгә, аннан «сеңел»гә күчкән. Хәмер томаныннан кызның арыган тәнс мәлҗерәп төшкән, аның саен теге кара җан аны ныграк үзенә кыскан.

Гөлсара ул көнне дә, икенчесендә һәм өченчесендә дә әйләнеп кайтмагач, авылдашлары хәвефкә төшеп, тагын бераз сабыр итәргә булганнар. Алай да беленмәгәч, район үзәгенә хәбәр алырга әтисе килсә, кызы шифаханәдә икәнлеген белешкән. Бер танырлык җире дә калмаган, тәмам шешенеп беткән икән, мескен. Әмма аңында, ди. Күзләренә борчылу, курку һәм оят, рәнҗү тулган. Әтисен танымаган кебек кыланган.

Бөтен авыл белән бу хәбәрдән борчуга калганнар. Инде сәламәтләнеп җитте, бер-ике көннән чыгар да, дип көткәндә, Гөлсара шифаханәдән качып, Казанга китеп барган. Әмма монда сырхаулап ятучы күрше авыл хатыны Сабира түтигә башыннан узган хәлләрне әтиләренә сөйләсен өчен белдереп калдырган. Әманәт итеп тапшырырга кушкан. «Мине эзләп йөрмәсеннәр, бәхетемне югалттым, һичбер генә дә гөнаһым юк, ачуланмасыннар,— дигән.— Артымнан бик өзелепләр йөргән егетем бар иде. Хәзер армия хезмәтенә алынды гына, берүк аны-моны хәбәр итмәсеннәр. Кайткач кына әйтерләр: «Мин аны яратмадым, болай гына йөрдем, күлеп кенә!» — дисеннәр»,— дип хушлашып, шул сәгате-минутында югалган да. Баштарак аны, батып үлгәндер, дип фараз кылып, яр буендагы балыкчыларга хәбәр салганнар. Әмма гәүдәсе бер генә җәтмәгә дә эләкмәгән. Аннан халык, аны жуликлар белән күргәннәр, вәкилнең башына җитмичә, тынычлык табасым юк, дип әйтә икән, дигән сүз чыгарган. Әмма бу фараз да гайбәт кенә булып калган. Инде аның хакында тәмам онытып бетергәч, әти-әнисенең күзләре ачылып килгән вакытта «Правда» гәзитендә яхшы хезмәт хакында мәкалә басылып, анда Гөлсара Хәмзина турында да матур гына хәбәрләрне укыганнар, фотосы да урнаштырылган булып, бер төркем иптәш кызлары уртасында елмаем торганын күреп сөенгәннәр. Озакламый Сабира түтинең вәкил хакындагы хакыйкый сүзләрен ялганга чыгарып, Гөлсарадан герой ясап бетергәннәр. Әтисе исә, Казандагы адресын белешеп, кызына исәнлек-саулык теләп хат җибәргән, иске хәлләрне бер генә исенә төшереп торуны кирәк тапмаган. Шундый мөләем хатына Гөлсара да ягымлы җавап язып, әти-әнисен үз янына күчеп килергә чакырган, бер яхшы кешенең үзен хатынлыкка соравын. Октябрь бәйрәменә бәлки туй да итәчәкләрен, әгәр дә әтисе-әнисе киләсе итсәләр, кичектерергә дә мөмкин икәнлеген — һәммәсен тезеп чыккан имештер. Ахырда вак хәрефләр белән тагын да шундый юллар өстәп куйган: «Мин яшьлек юләрлегем аркасында чыгып киткән идем. Әмма яхшы кешеләр юлдашым булдылар, максатыма ирештем. Исмәгыйль армиядән кайтса, сәламемне җиткерегез, гафу итсен, язмышыбыздыр, вәгъдәмдә тора алмадым, бәхеткә ирешсен!»

— Менә шулай, сеңлем,— дип әллә ничек кенә йомшарып, чит-ят караңгы бер урыс кызына боларны сөйләп чыккач, Исмәгыйль авыр гына көрсенеп куйды.— Кешеләрне бәла йөртә, диләр, юк икән, бәхете дә җитәкли икән! Солдаттан кайткач, боларны ишеттем дә, ятып үләрдәй булдым. Нигә шунда Карелия сазлыкларында ятып калмадым икән, дип үкендем. Синең бу көнгә кадәр исәнлегеең өчен үкенгән кешене очратканың бар идеме? Андый адәм мин булам!

Шушы вакыйгаларны җиңел генә сөйләп биргәч, Марфа аны тагын да үзенә якынрак хис итә башлады. Була шундый чак, эчкә җыелган уйхәсрәтләрне кемгәдер белдереп, бушатасы килгән халәт. Исмәгыйльнең дә, гүяки, күңеле тынычланып калды. Әмма, аның каравы, кызныкы

авырайды. Ул бу кадәр үк яңалыклар ишетермен дип көтмәгән иде. Егет тә аңа сөйләгәндә: «Сенлем, курыкма миннән, андый яман кешеләрдән башыңны сакла!» — дигән киңәш бирә-бирә, кемлеген белдерәдер төсле иде.

Олы юл кечкенә инеш аша узганда, Исмәгыйль атын туктатып сугарды, озын-озын итеп сызгыргалап торды:

— Эч, малкаем, эч!..

Аты, гүя, аның холкын яхшы белгән шәхси малы төсле барча әмерләренә буйсынды. Инеш аркылы чыккач, егет аркалыгын күтәрергә дип тартылган иде дә, ат яңа чыккан яшел бәбкә үләнен чемчи башлагач, ашыкмаска уйлады.

— Бераз ял итеп алыйк алайса, шулай бит, Марфа?

— Мин каршы түгел.

Исмәгыйль, атын иреккә куеп, сөзәк яр читенә барып утырды. Кулындагы алты үрмә чыбыркысының очын суга манчыды. Уйга бирелеп, күзләрен баеп баручы кояшка таба юнәлтте. Бәбәкләре тәмам кысылып, арган тәне йокыга чумган төсле иде.

Марфа исә, арбадан төшеп, арыш уҗымы аша, якындагы каенсарга карап юл алды. Моны хәтерләп калган егет:

— Озак йөрмәгез, ул-бу була күрмәсен, — дип сүз белән озата калды. Әмма кыз: «Акыл өйрәткәнче, артымнан килсәң ни була?» — дип үртәлде. Тик Исмәгыйль урыныннан да кузгалмады. Сагышлы гына сызгыргалап, һаман да еракка, офыклар артына карашларын ташлаган хәлдә уйланды да уйланды.

— Һай-һай-һайлар...

Марфа каенсарның эченә килеп керде. Басу-кырда сизелмәсә дә, монда талгын җил яшь яфраклар белән уйный, сыпыргаланып йөри иде. Кыз читтәге бер каенга килеп сөялде. Югарыга таба үрмәләгән кырмыскаларны күреп, аларның берсенең юлына бармагын куйды. Теге мескен, каршында көтелмәгән тоткарлык күреп, тиз ара өскә-аска карап куйды да, әйләнеп үтәргә мөмкинлеген искәрмичә бармак өстенә килеп менде. Марфа аны шунда ул җәһәт кенә каеннан алды, карашына якынрак китерде. Көлке иде. Болай ук булыр дип уйламаган бөҗәк аркылыга-буйга чапкынлый башлады. Кызның эссе тыныннан шикләнде, пар мыегын уңлы-суллы йөртте:

— Электеңме кармакка! — дип көлде Марфа. — Моннан соң алдыңны-артыңны карап йөрисе...

Кыз сискәнеп китте. Аның янәшәсенә Исмәгыйль килеп баскан. Көтмәгән иде.

— Нәрсә булды?

Егетнең борчулы йөзен күреп, Марфа тагын да каушый төште.

— Менә, — диде, — кырмыска тоттым.

Егет аңа якынлашты, әмма күтәрелгән бармагында бер нәрсә дә күрмәгәч, елмайды да:

— Кая, юк бит? — дип куйды.

— Ничек? — дип Марфа да аптырап китте. — Әле яңа гына шунда иде бит. Куркыткансыз инде алайса.

— Ә-ә-ә!..

Аларның күзләре очраштылар. Икесенә дә дөньялар тигезләшеп китте, тыннарына тыннары уралды, акыллары буталды, йөрәкләре урыннарыннан кузгалып, ирennәре иреннәренә сузылды. Кем уйлаган шушы каенсарда урыс кызы белән татар егете берберсенең каен суыдай татлы вә шифалы бәхет һәм сәгадәт бүләк итәргә әзер мәхәббәт хисләрен чүпрә төсле кайнатып җибәрәчәк ирен очларының түмен татырлар дип?

— Гафу итәсез, — диде егет, башын аска төшереп. — Әллә ничек килеп чыкты әле бу!

Шулвакыт юлның күтәрелеп алган җиреннән атлар белән килүче кешеләрнең өзек-өзек кенә җыр авазлары ишетелеп китте. Көенә

караганда, урыслар иде. Слеттан кайтучылар. Арбаларында ничә кеше барлыгы аңлашылмаса да, барсы бергә биш ат иделәр.

— Безнекеләр кайтып килә...

Алар каенсардан төштеләр. Инде уҗымга үрелергә маташкан атның аркалыгын күтәреп, Исмәгыйль:

— Куып тотарлар, атлары яхшы, без юлны дәвам итә торыйк,— дип Марфаны арбага чакырды. Кыз тагын артка карап утырды.

Көтелмәгән аңлашудан соң, дөресрәге егет һәм кыз икесе дә яшертеп генә теләгән беренче үбешүләреннән соң, бер-берсеннән оялып, сүз куз-гатып җибәрергә кыймый бардылар. Әле ерак төсле тоелган теге юла-учыларның җырлаганнары тагын да ишетелә барды. Әмма Исмәгыйль атын куаламады. Арбадагы алты капчык белән кызыксынган төсле, теләмәсә дә, сүз башлансын өчен алар хакында Марфа юри сорап куйды:

— Болар нәрсә?

Егет каерылып борылды.

— Нәрсәне әйтәсез?

— Капчыкларны!

— Ә, алармы? Йон! Безнең рәис шундый кеше инде. Бер эш белән җибәргәндә, юл уңаена дип, тагын бер-ике йомыш куша. Районга китер-гән идем, контора ачык булмады. Биш әйләндем. Кешесе юк. Калдырып булмады. Тагын шулар аркасында ат куарга туры киләчәк. Рәис орышыр инде. Башкаларга җиңелгә туры килде: алар кыш чыккан бәрәңге китер-деләр, шуларны пристаньгә тапшырырга калдылар. Анда да тәртип булмады бүген, көне буе чират тордылар. Кичкә генә җитештеләр, әнә.

— Нигә аларга җиңелгә килде, дисез? Киресенчә, сезгә җиңелгә кил-гән әле монда. Алты капчык йон атыгыз өчен дә авыр түгел.

Кызның болай сөйләнүенә егет тагын көлеп куйды.

— Нигә алай дисез? Мин дә арбага бәрәңге төяп килдем. Әмма районга барып җиткәч, аларны иптәшләремнең атларына күчердек. Ми-ңа ике йомыш кушылган иде бит!

— Алай икән...

Сүз тагын өзелеп каласы иде. Әмма Марфа ялгап китәргә ашыкты:

— Сез татарларның гомергә шулай инде, бер эш белән киләсез, биш йомышыгызны хәл итеп китәсез. Эшләгәндә — эшләргә, ял иткәндә — ял итәргә кирәк!

— Сез башка төрлерәк шул.

— Юк, сез ул башка төрле, татарлар! Эштән һич тә башыгыз арына белми. Кем эшли, шуны эш ярата, гел чыгып кына тора һәм бетми дә тиз генә. Ә кем ял итә-итә маташа, аныкы гел бетеп бара. Шулай түгелме?

— Шулайдыр да...

— Безнең авылга килеп, өйрәнеп китегез, шулайдыр да, дип әйтмәс-сез. Килерсезме?

— Болай чакыргач, һичшиксез! — дип елмайды егет, тагын каерылып, Марфаны күзләре белән иркәләде.— Иртәгә үк. Сезне кайдан табып була соң?

— Иске чиркәүдән сулга бишенче йорт. Йә өйдә булам, йә капка төбендә, әгәр дә кичен килсәгез. Көндез, белмим кайда, нинди эш куша-лар бит.

— Юк, көндез булмый. Мин дә эштә. Көтүләр кайткач авылдан чыксам да, караңгыда гына килеп җитешәм. Егетләрегез кыйнап кит-мәсәләр...

— Юк, алар әйбәтләр безнең.

Ул арада атларын шабыр тиргә батырып куалаган Марфаның авыл-дашлары аларны куып та тоттылар. Көлешә, җырлаша, шаярыша иде-ләр. Егетләренең кайсы йоклап ята, айный башлаганнары арбадан арбага күченеп, әле бер кызга, әле икенчесенә бәйләнгәндәй итә, үбә-коча иде.

Беренче арба туктамады. Исмәгыйль белән Марфага авыз тутырып көлделәр дә:

— Кияү белән кәләш! — дип шәрран ярып кычкыра-кычкыра шаяртып уздылар.

Башкалар да аларга кушылды. Дүртенче арба үтеп киткәч, Марфа Исмәгыйльнең колагыннан үбеп алгандай пышылдады:

— Мин сезне көтәрмен, Самуил!

Һәм сикереп төште дә, арттагы арбага, бишенчесенә таба йөгерде. Андагылар куанып, аны үз кочакларына алдылар. Исмәгыйльне узганда, юри шаяртып:

— Әй кенәз, кәләшеңне урладык бит, оттырдың!.. — дип көлештеләр.

Үр төшеп үр менгәнче артларыннан калышмый килде дә үз авылларына илтүче юлдан борылып китте. Марфа аңа кул болгады. Аның белән бергә башкалар да селкеделәр:

— Саламалейкум, кенәз!

Башкаларга ияреп юырткан аты, ялгызы калгач, ашыкмаска булды, ахры, адымнарын акрынайтты. Әмма Исмәгыйль аңа сыдырып җибәрде: «Әйдә сәнә!»

Урыслар — сулга, Исмәгыйль — уңга. Икесе дә берьюлы диярлек ике якка китеп күмелделәр.«Аларның атлары да яхшы шул, күмәкләшеп бәйрәм дә итә беләләр. Без татарның эш тә эш инде!» — дип уйлап уфтангандай итте. Әмма татлы хыялларының пәрдә чите күтәрелеп, Марфаны исенә төшерә-төшерә, күңеленә уелып калган чибәрлегенә сокланып, ничектер җиңеләеп киткәндәй булды. Ул җиңеллек аның кәефен күтәрде. Җай гына шуып барган төсле тузанлы юлдан тәгәрәгән арбасының тибрәнүе дә аның әллә арылудан, әллә кызның бүтәннәр кочагында китеп баруыннан бозылып калган күңелен ачарга ярдәм итте, сузып-сузып җырлыйсы килде. Әмма авыллары инде якын иде. Салган дип уйлаулары бар. Кемгә — ошый, кемгә — юк.

## 9

«Боларның барысын да сөйләргәме икән инде?» — дип уйлады Марфа, курыккан күзләре белән тикшерүчегә күтәрелеп карап. Ул аннан җавап көтә иде.

— Озак телсез утырыргамы исәбегез?

Юк, мыскыл итеп көлүче бу кеше тикшерүче түгел, тикшерүче болай ук дорфа кыланмас иде. Бар нәрсәне дә берьюлы искә төшереп бетерү мөмкинмени? Кайсын сөйләргә, кайсын сөйләмәскә белмәссең. Иң яхшысы, Исмәгыйльне коткара торган нәрсәләр хакында гына әйтергә, вакларын телгә алып тормаска кирәк. Һәм Марфа шулай эшләде дә:

— Таныштык инде шунда. Дөресрәге, мин үзем аның мине ярата башлавын теләдем. Моның бит бер дә гөнаһысы юк. Киресенчә, хәзер урыслар белән татарларның катнаш никахларын мактап язалар. Сез дә каршы түгелдер бит?

Тикшерүченең тәмам ачуы кузгалды:

— Мин монда ЗАГС бүлеге түгел, мин — тикшерүче һәм бары тик бирелгән сорауларга туры, дөрес җавап бирүегезне генә таләп итәм. Юкса үзегез дә аның артыннан олагырсыз! Белеп торыгыз!

Марфаның йөзенә аптырау билгеләре бәреп чыкты. Икенче бер тикшерүче, кыяфәтенә караганда, урыс милләтеннән булырга кирәк, иптәшенең болай җикеренүләрен бик өнәп бетермичә, үзенчә сүз башларга, сорау алу барышын үзгәртеп җибәрергә исәпләп баш күтәргән иде, тәмәке кабызып, бүлмә буйлап йөренгән татар: «Ярамый! Мин үзем!» — дигән төсле кулы белән кырт кисте.

— Исегезгә төшерергә вакыт бирдек, кирәк булса, тагын бирербез. Алда көннәр бар, әмма чиксез түгел!

Күзе тәрәзәгә карап, ул туктап калды. Аның бу сәер халәтеннән соң иптәше дә шунда текәлде. Боларның дәшмәвенә аптырап башын

күтәргән Марфа да ирексездән шул якка карады. Анда берсе артыннан икенче кеше, кайсы — чиләк, кайсы — көрәк, сәнәк кебек әйберләр тотып, кулларын селти-селти кычкырышып йөгерешкәннәре күренә иде. Урыс тикшерүчесе тәрәзәне ачып җибәрде. Хәзер аларның нәрсә кычкырышканнарын аермачык ишетеп була иде.

— Пожар, пожар... Янгын, элеватор яна...

Команда бирелгән төсле, болар җәһәт кенә кабураларына үрелделәр, коралларының шунда булуына инанып:

— Хәзергә монда калыгыз! Хәзер! — дигән кисәтү ташлап, берсе артыннан икенчесе ишеккә ташландылар. Марфа баштарак нишләргә белмичә утырды, аннан соң тәрәзә янына килде. Йөгерешкән халык төркеменнән өркеп калган атының башын тоткан малайны күреп, күңеле тынычланды: «Китмәгән икән әле, рәхмәт яугыры!» Шулай да көтми калуы да бар.

— Алешка, әй, Алешка! Хәзер чыгам, китә күрмә!..

Малай Марфаның тавышын ишетеп, каян килә икән, дип прокуратура һәм милиция идарәсе урнашкан бер катлы буйга озын агач йортның тәрәзәләренә эзләнеп карады. Кыз теләген яңадан кабатлады. Алешка ишеттеме-юкмы, кыз ул хакта онытып, болай таба якынлашып килгән, йодрыклар селкеп кычкырынган халык төркеменә бар игътибарын юнәлтте. Уртада карт елгачы икенче берәүне беләгеннән җилтерәтеп алып бара иде. Аның тоткыны сакал-мыеклы башын аска салындырган, әмма усал күзләре белән вакыт-вакыт уңга-сулга сөзеп куйгалый иде. Халык ачы сүгенә: «Мерзавец!» — йодрык төеп кычкырына, хәтта тегенең башына да менеп төшкәли, чәченә дә үрелә иде. Ул да түгел, артларыннан йөгереп килеп, моннан чыгып чапкан теге татар тикшерүчесе белән иптәше һәм тагын берничә милиционер карт дингезче кулыннан мескенне тартып диярлек алып, халыкка артык кызарга ирек бирмәделәр. Төркем исә, моның белән ризалашып, адымнарын акырынайтты. Тоткынны милиционерлар өстерәп диярлек алып кереп киттеләр, башкалар шунда калды. Озак та үтми, теге тикшерүчеләр һәм халык тотып китергән кеше Марфа утырган бүлмәнең ишегендә күренде. Тонык пыяла күзлекле татар кырә-керешкә әмерен җиткерде:

— Иртәгә килсен, Василий, моңа повестка язып бир!.. Ә син, гражданка Волкова, ягъни, иптәш Волкова, барысын да исеңә төшереп, иртәнге җидедә иртәгә монда бул! Аңладыңмы?

— Әйе...

Ул арада язып тутырырга өлгергән повестканы икенче тикшерүче аның кулына тоттырды. Татары әмер тонында куып ук диярлек чыгары і җибәрде:

— Бар-бар, иртәгә төгәл килеп җитәсе бул!

Марфа саубуллашмыйча да урамга чыкты. Әле яңа гына монда ат башы тотып басып торган Алешканы эзләде. Әмма ул ахмак малай, көтеп тормастан, китеп тә барган иде. Марфа бу хәлдән егылып китәрдәй булды: «Һай, шапшак малай актыгы!»

Хәзер аңа авылларына кадәр җәяү кайтырга кала. Нишлисең бит, бу кадәр шаулашкан халыктан куркып та качарга мөмкин. Күпме көткәч, азагына кадәр аз гына сабыр итмәгән.

Баскычтан акырын гына төшеп, Марфа олы юлга таба атлады. Икмәк кибете ягыннан яңа пешкән калач исләре килә иде. Анда кереп, күчтәнәчкә бирәр ризык алырга уйлап, кыз тыкрыктан шул якка таба борылды. Тәбәнәк һәм кысынкы тәрәзәле өйләрне узгач, кибет каршысындагы таш җәелгән мәйданчыкка килеп чыкты. Сөенеп куйды. Ул утырып килгән ат шушында иде. Койма буена бәйләнеп, тәмам усалланган чебен-черкиләргә баш вә коерыгын селки, уңга-сулга тартылгалый, монда торуына бер дә риза түгел иде.

Ул арада кулына калач тоткан Алешка да йөгереп чыкты. Алар йөзгә-йөз очраштылар. Малай көлеп җибәрде һәм акланырга кереште:

— Тиз генә әйләнеп килермен, дигән идем. Чыгардылар дамыни? Кибеттән берәр нәрсә аласыгыз юкмы соң? Көтеп торам...

— Кереп чыгыйм...

Эчтә кеше бөтенләй дә юк иде. Олы корсаклы сатучы татар адәме, майлы күзләре һәм тирләгән йөзе белән җәелеп елмайган хәлендә уфылдап, бер капчык он өстендә утыра иде. Марфаны күргәч, йөрисез шунда, дигән төсле канәгатьсез генә:

— Нәрсә кирәк иде? — дип ашыктырды.

Кыз, сайланырга исәбе бар кеше төсле, киштәләргә күз ташлады. Кибет әллә ни бай түгел икән. Перәннек, сахари, яшел чәй һәм кирпеч-кирпеч икмәктән гайре нәрсә юк. Марфа татлы перәннек белән икмәк сорады. Тегесе ялт кына үлчәп маташканда сөйләнә-сөйләнә өч хатын килеп керделәр. Ирексездән аларның сүзләре кызның колагына үтте.

— Менә нишлиләр бит, ә? — дип, тыр-тыр чәтни иде озын буйлы ябык хатын.— Халык дошманнары белән ил тулды. Элеватор кадәр элеваторга көпә-көндез бит! Халыкның эштән тукталган чагын көткән ул! Ут төрткән бит! И-и, кабәхәт...

— Шулай-шулай, малайгынам, шулай-шулай,— дия-дия ике ягында ике юантык һәм буйга тәбәнәгрәк ике хатын сүзләрен җөпләп бардылар, әңгәмәләренә караганда, әле яңа гына очрашып, бер-берсенә нәрсә белгәннәрен уртаклашырга тотынганнар иде булса кирәк.

Кибетче ир Марфаны бөтенләй онытты. Аларга таба тартылды һәм сораштырырга тотынды:

— Ишетеп кенә калдым. Бара да алмадым! Кем яндырган, элəктергəннәрме әллә?

— Шунда ук тоттылар, шунда ук! Яндырып җибәргән дә, малай мин сиңа әйтим, торып йөгергән. Әллә ярый Митрофан күреп калган.

— Кайсы Митрофанны әйтәсең соң син? Теге тиленеме?

— Нишләп ул булсын. Ансының йортына ут салсалар да кузгаласы юк. Маякчыны әйтәм, маякчыны. Әле дә ярый шунда гына маташкан вакыты икән. Ярый әле эләктергән. Юкса үзенә сылтарлар иде. Куып та тоткан, теге китереп тә суккан. Ә бу, хап, аягына егылып каптырган. «Тукта,— дип әйтә ди.— Үтерәм, хайван!» Тавышына елгачы Митри күтәрелгән. Ә теге, ә теге, мин сиңа әйтим, култык астыннан гына корал чыгарган да, Митрофанга аткан. Митри килеп җитешмәгән булса, качасы икән. Митрофан да батыр кеше икән, аягыннан эләктергән килеш җибәрмәгән. Тавышка халык җыелган, халык. Маторда эшләүче Габделмән сөйләде, малай, Габделмән үзе шунда булган. Митрофанны арбага салып, тиз ара духтырга озатканнар, хәле начар, ди. Теге дошманны милициягә илткәннәр.

— Кем иде икән, танымаганнармы?

Сул ягындагы хатынның соравына игътибар да бирмәстән, бу һаман туктый белми сүзен дәвам итте.

— Ярый әле патроны бер генә булган, соңгысы, диме. Юкса Митрине дә харап итәсе икән. «Миңа төбәде, Ходай рәхмәте, мылтыгы атмады!» — дип сөйли икән Митри.

— Коты алынгандыр үзенең дә,— дип куәтләде теге сорау биргән хатын.— Иллә дә батыр кеше икән үзе!..

— Ник батыр булмасын, ди. Иделдә йөреп, җанга-тәнгә ныгып беткән инде ул. Тегене дә җилтерәтеп кенә илтеп биргән. Урыс авылындагы, теге, боярдагы колхозны әйтәм, андагы пожарны ул иптәшләре белән оештырган, ди, бит. Берәү генә түгелләр, ди. Биш-алтау, ди. «Барыгызны да комарскийга биетәбез!» — дип әйтәләр, ди. Раиф урманнарында качып яталар икән. Берсен тотканнар инде. Монысы да эләккән.

Тәмам түземлеге калмаган иптәш хатыны тагын соравын кабатлады. Әмма сөйләүче әллә ишетмәде, әллә ишетергә теләмәде. Сүзен бүлдереп, кибетче сорагач кына:

— Бер дә әйтә алмыйлар. Бу якларныкы түгелдер, бер дә үзебезнекеләргә охшамаган, диләр. Какча йөзле, сакал-мыеклы, бик тә гонарлы адәм, ди. «Болар бар да минеке булырга тиеш. Минем хәләл малларым, минем хәләл икмәкләрем!» — дип халыкка җикергән.

— Бәй, ахирәткәем, әллә соң боярның малайларыннан берсе микән? — дип сорау биргән хатын тагын сүзгә тагылып китәргә маташты. — Башка кеше андый каты итеп әйтмәс. Йортлары да урыс колхозына калды түгелме соң? Сарай кадәр иде бит. Ул кадәр маллары-мөлкәтләре сагындырадыр шул. Эченә чыдый алмагандыр. Аларның байлыклары белән рәхәтләнделәр дә соң урыслар. Бүлмә җиһазларына кадәр бүлешеп ташыганнар, идән сайгакларын да куптарырга керешкәннәр дә икән, мәктәп буласы дип туктатканнар. Хәзер балалар йорты, детдом ачалар, ди, инде.

— Тегесе кем иде икән? Ансын бит татар, диләр. Фин сугышында да катнашкан икән. Бергә иделәр микәнни?

Ахирәтләрнең өченчесе биргән бу сораудан соң алар телләренә салынудан туктап калдылар. Кибетче, Марфадан акча санап алгач, бу хатыннарга карап, янгынны ничек сүндерергә өлгергәннәрен сораштыра башлады. Марфа, ишеткән кадәресенә канәгатьләнеп, шул ук вакытта Самуилын хурлауларына көенеп, Алеша янына чыкты. Йөзе борчулы һәм агарган иде. Малай исә моңа игътибар да итеп тормады. Арбага җәелеп утырган җиреннән кузгалмыйча гына Марфаның менгәнен көтте. Чебенчеркидән үзен талатуга тәмам аптыраган ат, дилбегә башы бушауга, юыртып ук алып китте:

— Кайту ягына таба булгач, бу да йөгерә, — дип көлде Алешка, әмма Марфа аның сүзләрен ишетми иде. Башында бер генә сорау тугыланды: «Самуилның башкайларын гына ашарлар микәнни? Әллә соң гаепләре хактан да бармы? Юк, ышанырга ярыймы соң кеше сүзенә!»

## 10

Әле берничә көн генә элек, бу вакыйгаларга кадәр, унсигез яшьлек шаян һәм бәхетле кыз иде Марфа. Теләсә, авылларындагы барлык егетләрне колы итә ала иде. Шушы хәсрәтләр бер-бер артлы өстенә килеп өелгәч, тәмам уйчанланып, олыгаеп китте. Шулай бик кыска булды микәнни аның яшьлеге? Күбәләк гомере кадәр генә?

Самуил белән каенсарда ирен очларыннан гына сер алышкан көнне ул нинди бәхетле иде бит! Күчеп утыргач та егеттән күңел күзен ала алмыйкайтты. Дус кызлары шаяртканга да, арбадагы Федорның исереккә салышып күкрәкләрен кыскалауларга да әһәмият бирмәде. Чаттан аерылып киткәч, йөрәге өзелеп калгандай сикерде, кошлар кебек Исмәгыйль артыннан очыплар җитәсе килде. Юл буе теләк теләде, киләләр генә күрсен инде, диде.

Рәхмәт яугыры, егет килде. Аның юл буйлап эңгер-меңгердә үз авылларына күтәрелеп атлаганны бакча башыннан ук күреп торды Марфа һәм каршысына йөгерде. Бер дә итагатьсезлек дип тормады, чөнки аны башкаларга күрсәтеп, рәнҗеттерәсе килмәде.

Алар урам юлга бер генә дә аяк басмадылар. Һаман да ындыр артларыннан гына йөрделәр, арыш басуында шаярыштылар. Дөресрәге, Марфа үзе тәвәккәл булды. Әгәр дә егетнең башын әйләндермәсә, акылын адаштырмаса, күңеленә кереп оялый алмам, мәхәббәте сүрелер, дип уйлады. Самуилның намуслы икәнлеген тиз төшенде, шунлыктан җанытәне белән бирелде. Аның башларыннан, киң җилкәләреннән йомшак учлары белән иркәли башлап, куенына керә иде дә, иреннәреннән өзелеп кенә колакларыннан тешли, ашап йотардай хәлгә җитә иде. Самуил баштарак үзен ныгытма кала төсле нык тотса да, бу кадәр иркәләүләргә сабыры бетеп, саташулы сүзләр белән хисләрен белдерә һәм мәхәббәт

иркенә бирелә иде. Мондый уеннары көн дә кабатлана барып, кочышып-үбешеп кенә туя алмас хәлгә төшкәч, Марфа тагын үз теләге белән тәвәккәлләде, егетнең иненә богау салды, җаннарын гына түгел, тәннәрен дә кавыштырды. Мондый бәхет вә рәхәтлекне гомерендә беренче тапкыр татуы иде, аның кабат-кабат булуын теләде. Аңа башка кеше, бүтән ир кирәк түгел, бары Самуилы гына янында күренсен, тәкате югалып, тизрәк шул арыш басуына ашыктыра. Хәтта бу рәхәтлекләрнең ахыры яманлык белән тәмамланыр дип уена да кертеп карамый иде. Менә хәзер бар да бетте. Аларны язмыш аерды, бәхет агачына балта чаптылар. Яңа гына башакланып килүче сөтле арыш басуында алар сернең төбенә төшенгәннәр иде, июнь урталары үтеп, августка керүләре булды, табигать ничек көзгә авышса, Марфа һәм Исмәгыйльнең дә мәхәббәт чәчкәләре өстенә кырау төшеп, бәхетләрен харап итте. Нигә кечкенә генә кеше гомере олы сөенечләрне күтәрә алмый икән? Артык бәхетле булырга да ярамый шул, дошманнар көнләшмәсә, күкләр нигъмәттән аера...

Алешка бер генә тапкыр да чыбыркысын күтәреп карамады, килгәндә ялындырып кына атлаган куштан бия юыртудан туктый белмәде, хәтта олы юлда очраган Марфа беренче тапкыр егетен үпкән инеш вә каенсар яныннан да үтеп киткәне сизелмичә калды, үргә дә чабып кына менә бирде. Аның артында — чат. Юлның берсе Исмәгыйльләр авылына төшеп китә, икенчесе, бара-бара да, тигез кырларны узгач, калкулык сыртына урнашкан Марфаларның авылына илтә. Аның уртасында ак таҗ төсле балкып элеккеге бояр Вороновский яшәгән затлы сарай, тирәсендә — бакчалар, бераз арырак — әйләнә-тирәдәге барлык каргаларны үзенә җыя торган чиркәү, биш капкадан соң — аларның, Марфаларның нараттан салынган, такта түбәле, алма бакчалы йортлары, егыла башлаган мунча һәм лапаслары — болар барсы да сөрелгән звонарьнең[1] хуҗалыгы, Волков Тимофейның бәхетенә советтан тигән өлеш.

Звонарьне авылдан утыз бишенче елда алып киткәннәр. Егерме беренче елда Кызыл армиядән бурлак малае Тимофей Карпович кайткач, аның бәхетле күзе шул звонарь кызы күркәм Василисага төшкән. Өйләнешергә уйлаганнар, бу уңайны файдаланып, звонарь яхшы гына туй уздыргач, кияүләре совет яклы кеше саналып, егерме дүртенче елда сөрелүдән котылып калган. Әмма колхозга бер дә күңеле тартмаган. Кулга алынуы шуның аркасында гына булган.

Марфа — менә шул йортта егерме икенче елда май ахырында дөньяга килгән, бабасы чукындырган, әти-әнисе сөендергән бердәнбер бала. Шунлыктан иркә дә, шаян да, үзсүзле дә булып үскән иде.

Туган авылларында башта дүртьеллык, аннан җидееллык мәктәпләрне тәмамлап, унбиш яшеннән колхоз эшенә тартылган Марфаны иптәшләреннән соңарып кына комсомолга алдылар. Моның сәбәбе — бабасына яхшы мөнәсәбәт аркасында иде. Әмма әтисенең данлыклы кызылармеец икәнлеген исәптән югалтырга һичкемнең батырчылыгыннан килмәде. Арада кызның уңган һәм тырыш булуы да файда бирде. Комсомолга кергәнгә кадәр үзенә карата яхшы хөрмәт күрмәгән Марфа тиз арада бер башка күтәрелеп китте. Йөзгә-биткә матурлыгы көннән-көн артты. Һәм менә аны быел, мин дә тугыз йөз дә кырыгынчы елда, слетка да алып бардылар. Бу шатлык-куанычлар барысы бергә җыелып килгән бәхет иде. Ахыры яхшыга илтеп, сәгадәткә тиендерергә тиеш исә дә, янгын чыккан төннән соң бөтен ышанычлары җимерелә башлады. Унсигез яшьлек кыз бала һич тә болай булыр дип көтмәгән иде.

Куштан бия үртүбән кушаяклап чаба башлагач, Алеша дилбегәләрен ике куллап катырак тартып җибәрдеме, әллә инде берәр нәрсәдән өркепме, тукталды да калды. Юл чаты иде.

— Нәрсә булды?

---

[1] Чиркәү чаңны сугучы.

— Бармый, өректеме?—диде Алешка.—Сулга тарта, татар атыдыр бу!
Марфа арбадан төште. Ат тезгененә баскан, шунлыктан дилбегә башындагы малайның нәрсә теләгәнлеген аңламый газаплана иде.
— Хәзер...—диде Марфа.—Ашыкмый тор, тезгенен алыйм. Баскан бит, күр инде...
Күтәреп бәйләде. Ат тагын йөгерергә әзерләнде, арбасы да түбән таба этә иде.
— Әйтә җәһәтрәк!..
— Юк, Алешка, мин җәяү кайтам... Өйдәгеләргә әйт, хәзер кайтып җитәм, борчылмасыннар. Көтеп торганың өчен рәхмәт!
— Әллә тилерденме, унбиш чакырымнар бар бит әле!
— Юк, моннан сигез генә! Туры сукмактан бөтенләй дә юк! Булса, биштер...
— Иблис...
— Ярар, бар, ачуландырма. Болай да күңелем кителгән вакыт, син дә монда теләсә нәрсә такылдыйсың, малай актыгы...
Алешаның ачуы килеп, сипкелле бите кып-кызыл булды. Хәзер кыз өстенә берәр оятсыз сүз ташлый инде бу.
Әмма батырчылыгы җитмәде. Куштан бия алга тартылып куйды.
— Ярар, әйтермен,—диде дә Алешка дилбегәсен качып куйды.—«Неу!» диләр сиңа.
Шушыны гына көткән төсле ат юыртып китте. Төенчеген кулына тоткан Марфа юллар чатында басып калды. Сул тарафта, калкулыклар арасына кысылып яткан татар авылы аның киләсен көтми иде. Әмма ул шунда таба атлады. Көзгелектәгечә яктырткан кояш исә, озын һәм җиңел нурлары белән, гүяки, кулын сузган кебек: «Бар-бар!»—дип артыннан этә, фатиха юллый иде.
Анда килеп кергәндә, инде кызыл шәфәкъ сүнеп, кич иңә башларга җыена, урамнар буш калганлыктан, Исмәгыйльләрнең өе кайдалыгын сорарга кеше күренмәде. Мондый вакытта, урыс авылы булса, капка төпләре саен исермеш ирләр вә хатыннар җыелышып, гайбәт сагызын чәйнәр иделәр, ә болар, сукыр тавыклар төсле, өйләренә кереп посканнар.
Марфа акырын гына атлый бирде. Бу татар авылының, шактый гына фәкыйрь хәлдә торса да, төзеклеге һәм тәртиптә икәнлеге күзгә ташланырлык иде. Кыз үзенең туган авылын искә төшерде: бу юл башында—тирес, анда-монда яңгыр сулары җыелып, җәйләр буе сасып-сөрсеп бетә, ихаталар бүсек-җимерек, чүп-чар, исерек адәмнәр төсле уңга-сулга сузылып яткан, кирәк-кирәкмәстән мыркылдаучы чучкалар, болар өстенә—ишелеп китәрдәй байлык, бәрәкәт...
Көтүдән аерылып калган карт сыерын куып килүче берәү күренгәч, Марфаның йөзе балкып, аның каршысына ашыкты. Чандыр гына, буйга озын, өсте-башы мең ямаулы, кыска җиңле күлмәк, үзенә кысан чалбарлы малай иде ул. Кулындагы чыбыгы белән сөяккә генә калган сыерның сыртына сукты:
— Ашык, диләр сиңа, савылмаган да бит әле син!
Болай әйтүе бик тә сәер иде. Бу кадәр тире вә сөяккә калган сыерны да саварга мөмкин микәнни?
— Берүк әйтсәгез иде. Исмәгыйль абыйларың кайда яши?
Сорауны ишетүгә туктап калган малай ялт кына тар ыштанын өскә тартып куйды. Сүзләреннән бигрәк, Марфаның үзеннән шикләнеп: «Бу марҗа монда нишләп йөри икән?»—дигәндәй сәерсенеп калды. Кыз тагын да татарчалаштырырга тырышып, русчасын җимерә-җимерә соравын кабатлады:
— Исмаил абы йорты кайда? Исмаил абы...
Малай, әллә сәерсенеп, әллә шикләнеп, әллә инде бөтенләй аңламыйчамы, җилкәсен сикертте, чыбык тоткан кул аркасы белән борынын изеп

куйды. Куучының тукталуыннан файдаланып, сыеры койрыгын күтәрде, тизәк салды.

— Исмаил абы...— дип Марфа соравын икенче тапкыр кабатларга җыенган иде, малай җәһәт кенә бүлдерде:

— Аңладым инде, аңладым... Менә бит, каршыда гына!

Борынын изүдән бушаган чыбыклы кулы белән ул сул яктагы миләш куагы артындагы тәбәнәк өйгә төртеп күрсәтте. Күтәрелгән кулындагы чыбыкны күргәч, сыеры урыныннан кузгалып китте, артык сүз әйтмичә, малай да аңа иярде. Самуиллар йортына күз ташлап өлгергән Марфа:

— Рәхмәт! — дип әйтергә ашыкты. Капка төпләренә якынрак килде. Ишекләренә күз салды. Киң итеп эшләнгән баскычларының иркен башында бер ялгызы гына басып торган җиз комган: «Без монда мөселманнар гына яшибез!» — дигән кебек сак тора иде. Ишек алларында эт-фәрман күренмәде. Арырак, лапас астына кертеп сөялгән уфалла арбасы, киселмәгән утын һәм чабылмаган чыбык-чабыктан башка, аргы читән казыгына табаны белән өскә каратып эленгән күнитекләргә күзләре төшкәч, Марфа Самуилның үзен күргән кебек рәхәтләнеп китте. Җил капкага тартылды, ачарга дип ябышты. Әмма юкә бау белән ныклап бәйләнгәнен күргәч, эчкә үтәргә кыймады. Чыннан да ятканнар булса кирәк! Нигә кеше борчып йөрергә?

Марфа уңына һәм сулына карады. Кеше күренми иде. Җәһәт кенә озын толымыннан берничә чәч бөртеген йолкып алды да читән казыгының кояштан вә яңгырдан яргаланып беткән очына кыстырып куйды һәм теләү теләде:

— Башымны шушы нигезгә китер... Миннән бүтәнне монда кертәсе булма...

Эшен башкаргач, беренче тыкрыктан ук борылып, бакча артларына күтәрелеп, үз авыллары тарафына илтә торган юлга таба ашыкты. «Бәхетле булачакбыз әле без синең белән, Самуил! Бик бәхетле булачакбыз! Көтәрмен мин сине! Нахак бәладән котылырсың, һичшиксез, котылырсың! Иртәгә барам да барысын сөйләп бирәм! Чыгарырлар, нишләп чыгармасыннар! Гаепсез кешене төрмәдә ябып тоталар, димени!»

Шактый ара җир үткәч, сукмак читенә чагып, төенчегеннән прәннек алды, тамак ялгарга булды. Кич тыныч кына иңеп, ярымай җай-җай күтәрелә иде. Бераз читтәрәк ялтыраган җыентык суда бакалар гөрләшә, әрем араларында гамьсез чикерткәләр сайраштыргалый. Һава салкынча, рәхәт. Һичкемнең һичберсендә хәсрәте юк. Һәммәсе аерым, үз тормышлары белән яшиләр, тынычлыкка киңәнәләр.

Марфаның соңарып йөргәненә күнеккән әти-әни бу юлысы ятмаганнар, алгы өйгә ут алып, аны көтәләр иде. Кызлары кайтып керүгә, икесе дә сораулы күз карашларын аңа текәп, ачуланырга ниятләнгән җирләреннән йомшарып киттеләр.

— И бала,— диде әнисе.— Ниләр генә булды синең белән? Кайларда гына таныштың шул татарың белән? Бабаң хәсрәте генә җитмәгән идемени безгә? — дип бер-бер артлы сорауларын яудырырга тотынды. Менә хәзер кызып китеп, орышуга да күчәргә мөмкин иде. Әмма газиз әткәсенең хәлләре исенә төшеп, күзләреннән яшь бөртекләре бәреп чыкты. Әгәр дә шул хәсрәтләре башларына төшмәсә, Марфаны кулдан ычкындырасы түгелләр иде. Күңел күрмәгәнне күз дә игътибардан читтә калдыра шул. Алар әле кызларының саф икәнлегенә ышана, барысын да белеп бетерми иде.

Марфа да үз хәлен сөйләргә җыенмады. Әнисе әйткәннән бабасы исенә төште. Нинди укымышлы зат иде бит! Совет кергәч, моңа кадәр еш ишетеп тә, укырга туры килмәгән Маркс һәм Ленин китапларын кайлардандыр юллап табып, шуларга ябышты ул, хәтта урыны-урыны белән шактый сүзләрен укучылар дәфтәренә күчергәләп, читләренә сораулар куйгалап, килешмәгән фикерләрен теркәштергәләп тә барды. Бигрәк тә икс китапка ихласы төшеп, үз ишләре һәм кызлармеец кияве белән бәхәскә кергәндә, шуларны болгый-болгый күрсәтә һәм:

— Укыгыз, боларда ничек яхшы итеп аңлатканнар, күзләрегез ачылыр иде. Сез социализм төзергә җыенмыйсыз! Маркс та, Ленин да аллабыз Иисус Христос кебек өйрәтәләр, яманлыкның кайдан һәм ничек килгәнен бик оста аңлаталар,— дип кызып китә иде.

Аның сөекле китапларының берсе Бахның «Ачлык патша»сы — Маркс «Капиталы»на аңлатма булса, икенчесе Ленинның «Дәүләт һәм инкыйлап» брошюрасы иде. Ул әсәрләр аны тәмам коммунизм юлына кертсә, шул ук вакытта башына да җиттеләр.

Бара-бара карт звонарь шундый дәрәҗәгә җитте ки, дәүләт булмаска тиеш, ул иң зур явызлык, дигән сүзләрне ешрак кабатлый башлады. Гәзитләрдә халык дошманнары хакында хәбәр ешая төшкәч, моның белән дә килешмичә: «Алар берсе дә дошман түгел! Халыкка һичкем дошманлык кыла алмый, халыкка халык кына дошман була! Кеше — кешегә! Төп дошман — дәүләт һәм акча, бәндәләрне шулар аздыра, шулар явызлыкка китерә, чөнки алар үзләре төп явызлык, адаштыручы!» — дип сөйләгәннәре органнарга билгеле булып, кара төндә иске йортыннан алып киттеләр. Авылда идарәне үз кулларына тоткан рәисне дә районга чакыртып:

— Нигә моңа кадәр кулак калдыгын, халыкның канын имеп ятучы динчене аткармадыгыз, нигә яшереп калдырдыгыз! — дигән сүзләр белән ачуланып, җаны коелыр дәрәҗәгә җиткерделәр. Озакламый рәислегеннән да алып ыргыттылар. Моңа кадәр якшәмбе көннәрдә качып-посып кына чиркәүгә җыелучы әби-бабайларга да юл бикләнде. Гыйбадәтханәнең тимер ишекләрен каерып ташлап, эчендәге бар әйберне туздырдылар. Алтын буяуларын кыргычлар белән кыргалап йөрүчеләр дә булды. Әмма башка авыллардагы төсле чиркәүләрендә ат абзары ясатмадылар, мәктәп тә ачмадылар. Чөнки бояр Вороновскийдан калган мал-мөлкәт мәктәбенә дә, абзарлар өчен дә, башкасына да бише белән җитә иде.

Халык теле — хаклык теле шул. Карт-коры шушы бәлаләрнең һәммәсендә Маркс-Ленинны укып җенләнә башлаган звонарьне гаепләде. «Ул гына авылыбыз өстенә иблисне чакырды! Звонарь булып, поп белән бер табыннан ашап ятты-ятты да ахырда үзе мөртәт хәленә калды!» — диделәр. Бүтән төрлерәк сүз сөйләсәләр, Марфаның әнисе болай ук борчылмас иде. Әмма әтисен денсезлектә һәм иблис ялчылыгында гаепләп, Христос дошманы дип бәддогалар укыгач, башы авыртуга, күңеле болгануга чыдарлыгы калмыйча, авыруга әверелде. Анысы-монысы килеп өстәлде, кызының егете белән булган вакыйгалар. «Кеше баласы әле, ул татарга ни булсын! Кыз бөтенесен дә белеп бетерми, шөкер, котылдык әле!» — дип җиңел кулдан гына үтеп китәренә ышанган иде, бик алай килеп чыкмады. Менә бит, повестка белән милициягә чакыртып алдылар. «Бергә йөргәнсез, бергә эшләгәнсез!» — дип ябып та куйсалар, нишләрсең?

## 11

Вакытыннан алда килеп җиткән Марфаны, повесткасын күрсәткәч, милиционер хатын канәгатьсез генә озатып, кичә тикшерү барышында катнашкан теге урыс Василий утырган бүлмәгә кертте.

— Повестка буенча чакыртылган Волкованы китердем! — дип белдергәч, кызның ачуы кабарып алды. Ничек китерсен, ди, ул? Марфа үзе килде бит.

Тикшерүче өстәлгә куйган повесткадан озаклап-озаклап сәгате-минутны карады, стенага сөяп куелган олы зур көзгегә күз ташлады. Сәерсенеп китте. Урыныннан кузгалып, акырын адымнар белән атлады.

— Утырыгыз, басып тормагыз! — дип Марфага узып барышлый гына тәкъдим ясады.

Сөйләшү озынга булачагын күз алдына китергән кыз күрсәтелгән урынга якынлашты.

— Төенчегегезне монда бирегез!

Марфаның кулыннан алып, читтәрәк торган өстәл өстенә куйды. Аннан соң дивар биеклеге сәгатьнең олы ишеген ачып, чылбырын тартты, тукмакларын күтәрде, ишекне ачып:

— Дежурный, сәгать ничә? — дип кычкырды.

Коридорның аргы башыннан теге милиционер хатынның чырылдык тавышы ишетелде:

— Иптәш лейтенант, сигезенче биш минут!

— Кычкырма шулкадәр... — дип, рәхмәт урынына усал эндәшеп, вакытны дөресләде. Сәгать алтынчы яртыга килеп җиткәндә туктап калган иде.

Телен кузгатып җибәргәч, тонык кына саный-саный, үз җае белән йөрергә тотынды. Байлардан калган бу мирас ватылуны белми һәм яңа хуҗаларына тагын йөз ел хезмәт итәргә әзер иде.

Тикшерүче арган кыяфәт белән сәгать ишеген япты, өстәл янына килеп, кәгазьләрне, өстендә яткан папиросын алды. Тәрәзә янына җиткәч кабызды. Озак һәм суырып-суырып тартты да тартты. Марфага бер генә сүз дә әйтмәде, сорау да бирмәде. Бөтен кыяфәте төнс буе кораб бушатып арыган бурлакны хәтерләтә иде.

«Теге татарның килеп җиткәнен көтә, ахрысы! — дип уйлады Марфа, утырган җиреннән чак кына да кузгалырга куркып.— Бүген кичәге төсле авызыма су кабып утырмыйм, сөйлим дә бирәм! Бәйнә-бәйнә барысын да! Нәрсәгә оялырга тиеш ди әле ул? Кешенекенә тимәгән бит, үзенеке!»

Әмма кичәге күзлекле татар һаман да күренмәде. Тәмәкесен тартып бетергәч, бармак очын төкереклэп, тикшерүче аның күлөнә басты. Кинәт йөткерә башлады. Буылып-буылып киткәндә яртылаш бөгелеп төште. Марфа графинга үрелмәкче, су тоттырмакчы иде дә, ярыймы-юкмы, кем белсен, тыелып калды. Ул да түгел, тикшерүче сузылып шунда үрелде, графинны айкый-чайкый стаканга бушатты, тиз генә алып эчте. Ютәле басылды. Урынына килеп, башын артка җибәрде, ял алгач, әйтеп куйды:

— Аклардан калган күкрәк ярасы бар, кайвакыт шулай буып, тамактан тота.

Шулайдыр инде. Марфа куркынып утыра бирде. Менә хәзер җикерер, сорау ала башлар, башын катырыр, дип көтте. Барысын да сөйләр ул, бер яшерен сере дә юк бит тикшерүчедән.

— Синең дә әтиең кызылармеец бит әле?

Бу көтелмәгән сораудан кыз аптырап китте, кичәге ялгышын кабатламыйча, тизрәк җавап бирергә ашыкты:

— Әйе... Волков Дмитрий Алексеевич.

— Беләм-беләм, шәп егет синең әтиең, Мишка Волк. Аның белән бергә Казаннан башлап Уралга кадәр бергә булдык. Ул яраланды, без — алга. Мине соңрак эзләп тапты аклар пулясы. Әтиеңә миннән сәлам әйт. Васька Дурнойдан, диген. Ул белә кем икәнемне, борчылма, Дурной дигәннәре — кушамат кына. Шул сүзне бер дә телемнән төшерми идем. Дога урынына да, сүгенгәндә дә әйтелә иде инде, аңлыйсыңдыр.

— Әйе...

Кыз һаман да ачылып китә алмыйча, аскы иреннәрен тешләгән хәлдә башын иеп утыра бирде.

— Павел Зоринда укыдыңмы?

«Моның эшкә ни катнашы бар икән?» — дип тагын да күңеле бозылудан Марфа елар дәрәҗәгә якынлашып килә иде. Әмма җавап бирми калдыра алмады. Барысын да сөйләргә ниятләп килгән иде бит. Ә бу бөтенләй әллә нәрсәләрне сорап утыра, чыннан да Дурной, белеп кушамат такканнар икән, үзенә.

— Шулай бит?

Сорау кабатлангач, Марфа онытылып китканлеген аңлап, болай кыланса, үзенә начаррак буласын төшенеп, җавап тотарга ашыкты:

— Әйе...

— Аттылар аны. Халык дошманы, дип. Соңыннан акладылар. Гаебе булмаган. Ялгышлар безнең эштә дә очрый, кайдан барысын да белеп бетерәсең. Мәскәүдә бик яхшы китабы чыккан булган, атеизм буенча иптәш Сталинның үзенә барып җиткән. Казанга шалтыратып сораган. Кайдан белгәндер безнең якныкы икәнлеген. Әйе, алар барысын да күреп, бөтенесен күзәтеп тора. Ялгыш атып өлгергәннәр шул. Хәзер гаиләсенә пенсия түлиләр...

Марфа: «Нәрсә әйтергә икән моңа?» — дип аптырап утырды. Әле генә елап җибәрергә әзер булган кыз инде тынычланып калды. Тикшерүче сөйләде дә сөйләде, үзе әледән-әле сәгатенә карап куйды. Теге татар күренмәде.

— Иң кирәге — үзтәнкыйть булырга тиеш, дөрес аңлагыз. Партия безне шуңа өйрәтә. Мондый эштә ялгышмый мөмкин түгел. Иң кирәге, тирәнгә киткәнче, вакытында күреп, туктату хәерле.

Сөйләшүгә башкача әзерләнеп килгән кызның күңеле бу сүзләрдән соң акрын-акрын гына булса да ачыла башлады. «Самуилны азат итәләр микәнни?» — дип уйлады ул. Кечә әнкәсенең еларга җитешеп сөйләгән сүзләрен исенә төшерде, ярыймы-юкмы икәнен дә аңларга өлгермәстән сорап куйды:

— Бабам Звонарев?..

Әмма ярты сүзе авызы эчендә тоткарланып калды.

Дурной ниндидер кәгазьләр актарды. Арадан берсен сайлап алды, текәлеп кенә Марфага карап куйды, языльганнарга күз йөртеп чыкты, тагын башын күтәрде.

— Әтиеңне чакыртып, үзенә тапшырырмын, дигән идем. Болай да борчулары күптер. Шулай да мин белдерергә тиеш. Кайтарып бирерсез.

Кызга ярым бастырылган, ярым кулдан тутырылган кәгазь кисәген тоттырды. Икенчесен, олырагын, папкасына кире салып куйды. Марфа укырга теләде, әмма хәрефләрдә күзе иялөшеп җиткәнче, тикшерүче үз теле белән әйтеп бирде:

— Бабагыз Митрофан Васильевич Звонарев гаепләрендә акланмады. Казанда, төрмә шифаханәсендә, апрель аеның, анда ундүрте диелгәнме? — Папкасын ачып карады.— Әйе, ундүртендә кара тифтән вафат.

Кызның күңеле тагын ватылып китте. Әмма күз керфекләре коры, әрнүе юк иде.

— Менә шулай!..

— Исмәгыйль Вәлиевне, ничек дисез әле, Самуилны яратасыңмы соң?

Бар сораганнарына да җавап бирергә ниятләнеп килгән Марфа берьюлы ишеткән авыр хәбәрләрдән соң хәтерен чак-чак кына җыярга өлгерде.

— Әйе, яратам!

— Бик яхшы!

Кыз, кызарып, башын аска салындырды. Ничек сөйгәне, дөньяларын онытып яратканлыгы хакында сөйләргә теләде. Әмма теле әйләнмәде. Бу мәхәббәте еракта, бик еракта калган төсле тоелды. Гүя, хәзер бик теләсә дә, кайтарып ала алмас сыман.

— Аны да чыгарырлар. Кечә бик куркыныч халык дошманын тоттык, бояр малае, сезнең авылныкы, Вороновский... Күптән эзли идек инде. Аның эше икәнлеге ачыкланды, дисәк тә була. Язмышын суд хәл итәр. Ә Вәлиевне чыгарырлар. Вороновскийны иртәнге пароход белән Казанга алып кителәр, Самуилны алып кайтырлар.

Сикереп очынасы урынга, бу сүзләрдән соң Марфаның сөенечтән тыны кысылды, күзләренә яшь тулды. Моңа кадәр түзеп утырса, хәзер елап җибәрде.

— Йә-йә, ярамый алай, безгә рәхмәт әйтегез! Сездән сорау алуның кирәге калмады.— Тиз-тиз язып, кызның кулына кәгаз тоттырды.— Монысын дежурныйга бирерсез. Юкса чыгармас. Бар, сеңлем! Барсы өчен гафу үтенәм. Чыннан да гаепле дип уйлаган идек бит. Үз кулым белән тоткан идем бит. Янгын чыккан яктан килеп төшмәгән булса, бу бәлагә тарымас та иде.

Марфаны, җиңеннән тотып, ишеккә китерде.

— Хушыгыз!

Кыз башын гына селкеде һәм акырын адымнары белән озын коридор буенча атлады. Тикшерүче Васька Дурной аның артыннан күзе белән озата барды. Кыз, акрын хәрәкәт белән кулын сузды, каршысына чыгып баскан дежурный милиционер хатынга кәгазь тоттырды һәм төенчеген кочаклаган килеш атлады да атлады. Беркая борылмады һәм туктамады. Юл уртасыннан барды да барды.

Йөзен хуш исле җил сыпырып үтте, басуларда өлгергән иген тәме, икмәк җылысы иде бу. Шунда гына Марфа айныгандай булды, уңынсулын карады һәм үксеп елый-елый йөгерә башлады. Тыны кысылып, тамагына тузан утырды. Әмма кыз туктамады, күзләреннән яшь акты, җаны тетрәп үкседе, кемнәндер куркып качкан төсле чапты да чапты. Хәтта юлга аркылы аккан инешне дә ерып кына чыкты һәм каенсарга кереп, каеннар арасына капланды.

...Тыныч, рәхәт. Әйләнә тирәдә яшел чирәм. Алга таба үр менә. Ә Самуил белән Марфа янәшә баралар да баралар. Рәхәт. Егете түгел, инде ире икән, имеш. Күтәрелеп-күтәрелеп бер-берсенә карыйлар. «Самуил! — ди Марфа.— Синең күзләрең караңгы күрән түгел идемени? Нигә ачык зәңгәр төскә кергәннәр?» Ә ул — елмая: «Мин хәзер шундый инде!» — ди. Карый. Аралары ераклаша бара. Яшел чирәм үзалдына саргаеп, баскан җирләре сазлыкка әверелә. Араларында әллә ниткән тирән чокыр, упкын. Буйга сузылган. Һаман киңәя. «Самуил!» — дип кычкыра Марфа. Ә ул — дәшми. «Нигә дәшмисең, чакырсаң, хәзер яныңа барып җитәр идем!» — ди Марфа. Ә ул һаман зәңгәр күзләрен төтырып карап тик тора, ерагая. Нидер дәшә, ишетелми. Аңлашылмый бит...

— Ни булды, кызым? Нишләдең?

Марфа башын күтәрде. Каршысында иелеп, ак сакаллы түгәрәк кенә бер татар карты дәшә икән. Кыз сикереп торды. Итәкләрен какты.

— Нәрсә, кызым? Ни булды?

— Менә, арганмын да йоклаганмын.

— Ә мин бер-бер хәл булганмы дип торам.

— Юк-юк!.. Рәхмәт, бабай, уятканыгыз өчен дим.

Ул-бу булмадымы дип борчылып килгән бабай елмаеп җибәрде.

— Зыян юк, алайса, кызым, зыян юк... Үзең кайдан соң?

Марфа туган авылының исемен әйтте. Бабай һаман елмаеп тора бирде. Аның нур кебек балкыган йөзе Марфаның күңеленә ягымлылык салды. Уйлары да, күргән төше дә берьюлы онытылды. Югарыга менеп җитеп, инде авышырга да әзерләнгән кояш дөнья йөзенә шатлык бүләк итә иде. Кыз үзенең монда ничә сәгатьләп ятканлыгын чамаларга маташты. Бабайдан сорарга яхшысынмады. Төенчеген кулына алып, үз юлы белән атламакчы иде, чыбык сындырып маташкан бу татар карты аны туктатты:

— Утыр, кызым, утыр. Шул якка барам...— Кулы белән ишарәләп, юлы уңаена күрсәтте.— Бу минем ат инде, яхшы бия, яхшы! Авылыбыз да шул якта. Нигә кадәр утырып бар. Ни соң әле... Менә, хәтер диген. Ярар, анда әйтермен!

— Рәхмәт, бабай!

— Имин бул, кызым, имин бул!

Арбасында бабай ялгызы гына түгел иде. Башын бөркәтеп утырган хатыны, Марфаны әйдәкләп китерүен күргәч, яратмады булса кирәк,

башын читкә борды. Бу кыланышын күреп алган кыз кыенсынып куйды. Әмма бабай һаман кыстый иде:

— Утыр, кызым, утыр!

Үзе хатыны янына менеп, алга карап утырды, дилбегәне кулына алды. Әмма Марфа һаман тәвәккәлли алмыйча тора иде. Бабай моны күргәч, ашыктырып карады, ә кыз мыштырдый бирде. Ул да түгел, битен ярым каплап, әбисе борылып карады, башын селкеп:

— Утыр-утыр...— дип үтенде.

Марфага шул сүз генә җитмәгән икән, җәһәт кенә арбага менде, артка карап утырды. Аска калын итеп түшәлгән печән җылысы озакламый тәненә күчте. Авыр гына кузгалып киткән ат рәхәтләндереп юырта бирде.

Бераз юл үткәч, бабай елмаеп кына Марфага борылды да, сорап куйды:

— Безнең Исмәгыйль сездә янгын ясаган, диләр, белмисеңме?

— Беләм, бабай, беләм,— диярга ашыкты Марфа.— Тик, бабай, аны ул чыгармады. Дөрес гаепләмәгәннәр! Янгын чыгарган кешене таптылар. Тиздән Исмәгыйльне азат итәрләр.

Кызның бу белдекле сөйләүләреннән бабай үзе генә түгел, әбисе дә аптырап китте. Алар Марфага дүрт күз белән текәлделәр. Яңадан да яңа хәбәрләрне ишетәселәре килде. Горур итеп башын күтәргән, әмма кабат бер сүз дә эндәшмәгән кызга бабай тагын да сорау бирергә уйлады. Атының дилбегәсен тәмам кулыннан төшереп, борылып диярлек утырды. Үзе кебек хәйләкәр сыйфатлы биясе исә, хуҗасының юлдан күңеле читләшкәнен сизенеп, акрыная-акрыная туктады һәм рәхәтләнеп иген басуыннан ашлык башакларын гына сайлап чәйнәргә кереште.

— Кайда ишеттең, кызым, кемнән белдең?

Марфа рәхәтләнеп елмайды.

— Белдем, бабай, яхшылап белдем. Мин бит аның кәләше! Әле иртән генә милициядә булдым! Шунда әйттеләр. Үз колакларым белән ишеттем!

— Кем әйтте?

— Тегe кем әле? Васька Дурной!

— Ә-ә, Дурнуй, дисеңме? Алай булса, дөрес инде!

— Хак-хак, бабай, алдамыйм. Исмәгыйльне азат иткәннәрдер дә инде, ни сөенеч!

— Һе... Ни сөенеч шул әле бу!

Алга таба борылып, арбадан төшеп барган дилбегәсенең очын эләктереп алды да биясенә дәште:

— На-а, малкай, яхшы хәбәрләр алып кайтабыз икән, әлхәмделиллаһ! Йөгерсәң дә була, чапсаң да ярый.

Моңа кадәр дәшмәгән хатыны, чабып барган атка бабай сындырып биргән чыбык белән сугып, үзенчә олы мәгънә күргәндәй сорап куйды:

— «Кәләш» дип әйтәме? Шушы микәнни инде ул кыз?

— Шушы-шушы, нәкъ үзе! — дип бабай рәхәтләндереп елмайган хәлендә әбиенә җавап тә бирде, күзләре Марфада иде.

— И карт җүләр,— диде хатыны, аңа терсәге белән төртеп.— Кыз күрсәң, котыра башлыйсың. Бик чибәр нәрсәкәй бит бу!

— Хараша нивиста, хараша![1]

Марфага бик тә, бик тә рәхәт, күңелле булып китте. «Рәхмәт, бабай!» Җаны шулай дия-дия сөенә иде.

Атын бабай юл читенә җиңел генә китереп туктатты.

— Йә кызым. Сиңа — монда, безгә — тегендә!

Марфа аптырап китте. «Кара әле, безнең Исмәгыйль, дигәннәр иде түгелме соң, авылдашлары булып чыктылар бит. Барыбер барырга ниятләгән идем инде, яхшы икән әле!» — дип алар белән бергә юлын дәвам итәргә уйлады һәм:

---

[1] Күркәм кәләш, күркәм!

— Бабай, ә мин сезнең белән бергә! Исмәгыйльләргә керәм!

— Кара-кара, нәрсә ди ул? Исмәгыйльләргә барам, диме? Булмаганны, оят кирәк азрак!

Бабайның әбисе Марфаны авылга алып кайтасы килмәде, терсәге белән картына төртеп-төртеп куйды. Алар ни сөйләшкәннәрен Марфа ачык ишетмәгәнлектән, бер нәрсә дә аңламады.

— Халык ни әйтер? Без алып килгән булып чыгабыз! Юк-юк, әниләре дә эзли торгандыр бу баланы, кайтсын авылына. Гомер булмаган эш. Өйләнергә исәбе бар икән, Исмәгыйль үзе дә бик оста алып кайтыр, төшсен!

Әби тормышны белеп сукалый иде. Бабай кыенрак хәлдә калды. Шулай да Марфага аңлатып карарга булды.

— Кызым, эш шулайрак бит әле. Минем карчык әйтә, йола кушмый, ди. Ярамый сиңа безнең авылга, бөтенләй дә ярамый керергә. Аңла, кызым, яхшылык белән әйтәм. Йоласы кушмый. Йоласы шулай. Менә эш нәрсәдә, сынамышы бар. Кайсы килен тәүге тапкыр кияү йортына ялгыз башына килеп керә, яхшы булмый. Кияве үзе алып кайтса, шул киленнән уңа. Ярамый бит, һич ярамый! Яхшылык теләп әйтәм, бабаң начар киңәш бирмәс. Карчыгым дөрес әйтә, ул да яхшылык теләп кенә бит!

Әмма кыз аны тыңларга теләмәде. Исмәгыйлен бик тә сагынганлыгы сәбәпле, йортларын гына булса да кырын күзе белән күреп китәсе, күңелен тынычландырасы килде. Бәлки кайтып та җиткәндер? Юк-юк, арбадан төшеп калса да, җәяү барачак ул.

— Бабай, өйләренә үк кермәм. Болай, күз генә салып үтәрмен. Шикләнмәгез, һич ни яманлык булмас!

Марфаның үтенеч катыш сүзләрен ишеткәч, бабай уйга калды. Әмма әбисе тагын тынгылык бирмәде. Терсәге белән кабыргасына төртеп-төртеп алды:

— Нәрсә ди ул бала? Барам, дип әйтә түгелме соң? Әллә аңлата белмәдеңме? Җебеп торма инде!

«Татарда ирләр хатыннары өстеннән идарә итә дип сөйләгән булалар, бер дә белеп әйтмиләр икән! — Марфа шушы фикереннән елмаеп куйды. — Кара ничек изә бабайны!»

Картлач тагын арбадагы кызга борылып, җай гына аңлатырга керешсе, бу юлысы тавышы ачулырак иде:

— Бар, кызым, бар. Кирәксә, әнисенә үзем әйтермен, чыгарганнар дип сөендерермен. Кәләшегез әйтте, диярмен. Ярамый сиңа анда барырга. Исмәгыйль кайтса, үзе артыңнан килеп алыр. Шулай дөрес булыр!..

Сүзен бабай татарчалап бетергәч, әбисе дә Марфага таба борылып, кызны үгетләргә кереште:

— Бар, балам, бар! Әти-әниең дә көтә торгандыр. Кайтып сөендер үзләрен. Ә без үзебез әйтербез. Сине күрдек, диярбез, Исмәгыйльне ялгышып зинданга салган булганнар, гаепле кешене тотканнар, диярбез. Бар, балам, бар!

Бабай әйткәч, Марфа әле киреләнергә, аңа барыбер анда барырга кирәк икәнлеген аңлатмакчы да иде, әмма хатынының болай үгетләвен ишеткәч, уеннан кире кайтты. Чыннан да, бәлки аларда шундый гадәт бардыр, ырым.

Марфа арбадан төште. Төенчеген ике куллап күкрәгенә кысты. Моңа бабайның күңеле булып елмайды да:

— Хараша нивиста, үчен хараша! Бәхетле бул! — дип дилбегәсен тартып куйды. Инде авылларының кыек очлары күренгәнен ат та белә иде. Сукмыйча да юыртып китте.

Кыз, кулын күтәреп болгый-болгый:

— Рәхмәт, бабай, рәхмәт, әби, хәерле юл! — дип калды. Әмма алар артларына борылып карамадылар. Аркаларына төшкән кояш нуры ул

әби белән бабайның гәүдәләрен бергә кушып, очып кына барган төсле итеп күрсәтә иде.

Марфа үз авылларына таба борылды. Юлда һичкем юк иде. Тик киң кырлар вә үзәнлекләр буйлап зең-зең иткән тонык тимер тавышы һәм саранчалар-чикерткәләр кетертәгәне генә ишетелгәләп куя. Тимерчеләр урак теши бугай? Ни кадәр вакытлар үткән. Әле кичә генә чәчелгән төсле иде, үсеп тә җиткәннәр. Уракка төшәр вакытлар да якынлаша.

Кояш, Марфаның күзләренә кырын-кырын карап, юри шаяртадыр төсле иде. Кыз әле кытыкланып, әле теге бабай белән әбинең нинди яхшы кешеләр булуларын исенә төшереп, әле Исмәгыйльнең менә тиздән азат ителәсенә чын күңелдән ышанып, елмая-елмая кайта бирде. Әмма Исмәгыйль мәсьәләсендә әлегә ашыгып уйлый иде.

## 12

Сузып-сузып кына телефон сызгырды. Айзикның сак колагы кузгалып-кузгалып алды. Әмма хуҗабикә йокысыннан уянырга теләми иде бугай. Телефон тавыш бирде. Ул тагын кабатланачак. Айзик хуҗабикәнең бүлмәсенә үтте, битен ялады. Альбина, иренеп кенә:

— Кирәкми, кирәкми инде! — дип ыңгырашты.

Ул, гадәте буенча урынына шәрә тән белән чумып, изелеп-йончып йокларга ярата иде.

Телефон тагын сузып-сузып кына сызгырды.

Бу юлысы хуҗабикә күзләрен ачты, трубканы кулына алды. Йокы аралаш эндәште:

— Әйе-әйе, мин тыңлыйм!

Шалтыраткан кеше ире иде. Инде ничә көннәр Мәскәүдә бизнес эшләре белән мәшгуль булып, көннең теләсә кайсы вакытында хатынына шалтырата, хәлен белешә, бүген-иртәгә кайтып җитәм, дип әйтә, мәхәббәте хакында сөйли.

— Тыңлыйм-тыңлыйм, Геннадий!

Альбина торып утырды. Затлы йомшак юрганын алып, читкә кайтарды. Шәрә калган тәненнән оялыпмы, әллә инде итагать белепме, Айзик шыңшый-шыңшый үз бүлмәсенә чыкты.

Геннадийның тавышы бик борчулы иде.

— Мин кичә кич сиңа шалтыраттым, нигә телефонда юк идең? Нәрсә булды?

Кыз уйларга өлгермәде, әмма гадәтләнгән җавабын бирде:

— Һичнәрсә булмады, Айзикны йөрттем.

— Шулай соңга калганчымы? Мин бит унберда шалтыраттым!

— Айзик теләгәч, мин нишли алам. Нигәдер кәефе китеп тора.

— Дару бир!

— Бирдем, файдасы булмады. Әллә кайда түгел идем бит, подъезд төбендә генә!

Альбина, әлбәттә, алдый һәм ялганы тотылачагын белми иде. Ире, чыгырыннан чыга язып диярлек, тагын үкерде:

— Мин Вариска да шалтыраттым. Ул сине карап килде. Звонок та биргән, подъезд тирәләрендә йөргән. Борчылып беттем. Сине тапмаган!

Әмма хатынының исе дә китмәде, шунда ук башы эшләп алды:

— Тынычлан, иркәм, тынычлан. Айзик мине һичкемнән кимсеттерми, янымда саклап кына йөри. Читкәрәк киткән булганбыздыр. Көннәр буе өйдә генә утыру күңелсез бит. Кайт инде тизрәк, көтәбез. Икебез дә көтәбез. Айзик бара да гел синең кием шкафыңны исни, ул да сагынды.

Бу сүзләрен ишеткәч, ире эреп китте булса кирәк, тавышы тынычланды, сүзләре дә ягымлы булып ишетелә башлады:

— И җан кисәгем, синең өчен генә борчылып әйтәм бит. Ул-бу хәтәрләрдән Алла сакласын. Төшемә дә янгын, гел пожар керә. Кот-

ларым оча инде. Менә бүген бер килешүне тәгәлли алсам, кичке рейс белән Казанга очармын дип торам...

— И-и-и җүләрем! Төш тә юрый белмәгәч, нигә дип күрәсең аларны? Янгын — яхшы фал, никадәр көчлерәк, шулкадәр әйбәтрәк. Байыйсың, дигән сүз, череп байыйсың!

Альбинадан бу сүзләрне ишеткәч, Геннадий үкереп җибәрде. Бизнеска кереп киткәнче үзенең хисләрен болай кыргый рәвештә әкәмәт итеп белдерми иде, хәзер үзгәреп бетте. Начарга да үкерә, яхшыга да. Имеш, йоласы шундый. Кемнең ничек үкерүенә карап акчасы арта, эше уңышлырак бара. Әйтик горилла кебек бии-бии үкерсәң, синең эшләр уңышлы, башка суга-суга һыылдасаң, оттырдың, авызны дүрт бармак белән ябаяба һо-һо килсәң, бу товар, һичшиксез, синеке, аһ-уһ килсәң, кайгың бар, яки банкротлык якый, гү-гү дию — мәхәббәт һәм бәхет... Морзе системасы төсле, барысын да сөйләп бетерергә мөмкин түгел. Коммерция һәм бизнеста шушыны белмичә эшкә тотынган кешеләр беренче көннәреннән үк уңышсызлыкка очрыйлар.

— Нәрсә алып кайтыйм үзеңә, җан кисәгем?

— Бернинди әйбер дә кирәкми. Үзең кайт тизрәк!

— Мин монда сиңа атап тун алган идем, матур, яратырсың дип беләм!

— Нәрсәгә алар шулкадәр?

Альбинаның исенә яңа танышкан дусты Ханбал килде. Кухня тәрәзәсендә челтәре юк иде бит. Алып кайтсын әле Геннадий!

— Иркәм, тюль алып кайт! Кухня тәрәзәсенә. Бик әллә ни затлысы кирәк түгел.

— Безнеке бар бит әле...

— Бар, дип, искерделәр инде, алмаштырырга вакыт!

— Тагын нәрсә?

— Кочаклыйм, үбәм, сагынып көтәм!

— Мин дә! Айзикка сәлам!

Сөйләшүләре шушының белән тәмамланды. Альбина, урыныннан кузгалырга теләмичә сузылып-тартылды, кабат йомшак түшәккә чумды.

— Кадалып китсеннәр әле, йоклыйм!..

Бераз ятты, әмма йокысы ачылган иде инде. Торырга булды.

Күзгә алдына килде. Исенә күптән укыган бер хикәя килеп, үзалдына көлеп куйды. Ничек иде әле анда? Бер бай кызы, ишеген бикләп, анадан тума шәрә кала да, үзен алдан-арттан карый. Чибәрлегенә гашыйк була һәм үзеннән башка һичкемне яратмас дәрәҗәгә җитә. Хезмәттәге асравының күреп калганын сизенә дә, дөньяның һәм андагы бәндәләрнең нинди шакшы икәнлегенә үз-үзен ышандырып, ахыр чиктә һәркемнән чирканып, хәнҗәргә кадала, үлә. Ахмак! Була бит шундыйлар.

Күзгедә Айзикның ишек артыннан карап торганын күргәч, Альбина тыела алмыйча көлеп җибәрде.

— Һай, чукынчык, кит моннан!

Шыңшый-шыңшый эт яңадан үз бүлмәсенә кереп китте. Ханым, кулына тарак алып, чәчләрен тарамакчы иде, бу ниятеннән кире кайтты, өстенә халат салып, душ бүлмәсенә таба юнәлде, сөлге башын гына чылатып, битен-кулын сөртте. Ашыкмыйча гына кием шкафы янында күлмәген яңартты һәм залга таба башын тыгып:

— Айзик, йөреп керәбез! — дип дәште.

Инде күптән шуны көткән эт ачык ишектән подъездга ташланды. Әмма чыгып йөгермәде. Хуҗабикәнең йозакларны бикләгәнен көтте. Ханым лифт чакырырга уйлады, әмма ул эшләми иде.

— Чукыйдылар инде!..

Урамда күзгә тартым алтын кояш үз биләмәләренә карап соклана-көлә иде.

Айзик озак йөрмәде, исәнәнде, йөгерде, йомышын үтәде дә, Альбинага карый-карый, артыннан ияртте. Подъезд төбендә ике татар әбисе,

һәрвакыттагыча кулларына сумкаларын тоткан килеш, нәрсәләрдер хакында ваклап-ваклап озын итеп сөйләшәләр иде. Утырган эскәмияләре әллә кайчан буялган зәңгәр төсен югалтып яшелләнә-яшелләнә кырышылган, тик чит-читләре генә элеккеге сыйфатын саклап калдырган иде.— Альбина аларны яхшы белә, берсе — сигезенче каттан, бабасы белән бергә тыныч кына шөкерана кылып, ахирәт тормышына күңел баглап яши; икенчесе — беренче катта шаулы тормыш белән гомер кичерүче гаиләдә тора, оныкларын тәрбияли.

— Исәнмесез, әбекәйләр!

Алар Альбинаның үтеп-сүтеп йөргән саен исәнлек-саулык сораштыруына күнегеп беткән гадәт белән ялт кына эндәшә калдылар:

— Исән әле, кызым, исән әле, Аллага шөкер!

— Саумы, кызым, иминме!

Дини бәйрәм көннәре булганда, Альбина, бер дә кызганмыйча, бу әбиләргә хәер-садакалар чыгарып бирә, хәтта кайвакыт шушы гадәтен белгән абыстайлар бишәү-алтау җыелалар, рәхмәт укып, дога кылып калалар. Бу хөрмәтләрен күрсәтсә дә, артыгына бармый ханым. Өенә кертеп, Коръән дә укытканы юк. Шулай да һәр ел саен, ире белән язылышып тора башлаган көнне, ахирәт әбисенә алдан ук күчтәнәчләр һәм хәер акчасы кертеп бирә һәм үзенең теләген кабатлый:

— Безнең исемебезгә, имин тормышлар өчен Аллаһы тәгалә шушыларны кабул итсә иде, Коръән укысаң иде атап!

— Ярар, балам, ярар, укырмын! Аллаһы тәгаләнең рәхмәтләре яусын, бик матур төш тә күргән идем әле,— дип кабул итеп ала, төшен сөйләми, әмма хәтерен яхшырту өчендер инде, исемнәрен сораштырып куя.

Альбина оялып китә. Тапканнар бит үзен ничек атарга. Мөселман исеме юк иде микәнни? Альбина? Бала чагында җиңел бу, үскәч, авырлаша, йөк кебек күтәреп йөрисең төсле. Картайгач ничек булыр икән? Альбина әби! Бигрәк көлке инде.

Иренең дә, үзенең дә исемен әби юри бозып, гарәпчә әйтә:

— Генасы Гали булыр, синеке, кызым, Әминә! Калган бар җирегез дә килеп тора! Укырмын, кызым, укырмын! Бар шартын да туры китереп укырмын, Аллаһы тәгалә кабул итеп алсын!..

Айзик тагын шыңшып куйды. Баскычтан акырын гына күтәрелеп килгән Альбинаны ялагайланып каршы алды. Ашыйсы килгәнлеген белдереп, телләрен ялагандай итте. Ханым үзалдына көлеп куйды: «Бигрәкләр дә бала сыман инде син, матурым!» Әмма бу шаян уе икенчесен, сагышлысын кузгатты, бәгырь түренә тузан утырган кебек булып китте. Балалары юклыгын уйлап чәчләре агарыр дәрәҗәгә җитеп кайгыга калган чаклары бар иде бит аның, ә хәзер бары тик күңеле генә әрни, ышанасы килә, үстерәсе килә үзе кебек чибәр бер кызны. Малай да ярар иде әле! Юк, малай кирәкми! Берәрсенең кызын кимсетсә, атасы кебек булса? И татар баласы, и татлы хыяллар тулы мескен хатын! Бәхетеңне бер югалткач, алтын акчаларга да сатып алу мөмкин түгел икән ул...

Ә Альбинаның, чыннан да, кызы туарга тиеш иде. Беренче тапкыр бала төшергәндә, алданган кичәдән соң, ул әле күп нәрсәне аңламый иде. Аңа врач әйтте бит:

— Сеңлем уйлап кара, ялгышлар төзәлә ул, әмма бу, бала төшерүегез... Белмим, икенче тапкыр кыз балага мондый очрак кабатланмый! Син әле яшь, уйлап кара, матурым! Ятим булмас, аласың килмәсә, больницада калдырырсың! Гомерлек бәхетсезлек алма үзеңә,— диде бит, кат-кат әйтте, үтенепләр карады. Әгәр дә ул карт врач абыйны бүген очратса, ул вакыттагы кайгыртулары өчен үбеп-үбеп кочар иде, рәхмәтләрен белдереп, бүләкләр бирер иде. Ә ул чакта, искә алулары да күңелсез, Альбина аның шушылай сөйләүләренә ачуланды, хәтта тупас итеп әйтте дә әле:

— Сезгә эшегезне эшләгән өчен акча түлиләр бит. Шулай булгач... Мин әзер!

Карт татар аптырады да калды. «Ярар, Аллага тапшырдым, белеп-күреп тора, бер гөнаһым да юк!» — диде дә юри шулай кыланган кебек газаплады. Болай ук авыр булыр дип башына да китермәгән иде Альбина, газап икән, үлем газабы...

Икенче тапкыр балага узмасын белгәч, Альбинаның моңа бер дә исе китмәде, нинди таш йөрәк иде икән ул вакытта? Андый түгел иде бит. Иптәшләреннән дә ераклашты, хәер-фатиха биреп торган укытучыларыннан да, җитмәсә, туганнарыннан да бит әле. Баулы шәһәрчегендә яшәп ятучы кадерле әти-әнисе янына кайта торган иде. Вәлишин белән йөреп киткәч, дөресрәге, Вәлишин сөйрәлчегенә әверелгәч, аларны да онытты. Җәйләрен Кырымга озата иде аны Геннадий, кайда гына яллар иттермәде. Берәүләр комсомол путевкасы белән зур төзелешләргә китәләр, Альбина исә, шундый юлланмалар тотып, Кырымга яки Кавказга юл ала. Берәүләр Ленин һәм партия исеменә атап батырлыклар кыла, тау-ташларны яра, гомерен һәм яшьлеген зур сынаулар астында калдыра, хәтта үлемгә бара, ә Альбина, үзе кебекләр белән бергә, татлыдан татлы ризык ашап, рәхәттән рәхәткә чума. Күрмәгәннәрен күрсәтте инде Геннадий, бу бәхетеннән баш чөерергә, җүләр түгел иде шул ул!

Кайда гына ялга җибәрсә дә, озакламый Вәлишин үзе дә ике көнгә, өч көнгә килеп-китеп йөри башлый иде. Альбина бу галәмәтләргә шундый күнегеп бетте, бик тиз үтеп киткән җәйне сагыныплар ала башлады. Ә хәзер, менә, кышны ярата, ак, саф, салкын кышны ярата!

Беренче мәртәбә бала төшергәннән соң бүтән булмас дип әйткән теге карт врач икенче тапкыр үзенең каршысына килеп утырган Альбинаны шунда ук танып алды. Хәтере яхшы икән. Дәшмәде-нитмәде, янындагы ак халатлы ассистентын ишек артына гына чакырып алды да өстәлендәге телефонын боргалый башлады. Йөзе усал һәм кайнар иде.

— Вәлишинмы? Чукынып китсен, табыгыз! Миңа Вәлишин кирәк! Чакырыгыз! Кичекмәстән, диегез!..

Трубканы карт, үчекләнеп, кулы белән кысты, колагына куеп-куеп тыңлады, тынычлана төште һәм, Альбинага карап, йомшак тавыш белән сөйләнә бирде:

— Алар белән менә шулай каты телле булырга кирәк, кызым, янгын чыккан, дип белсеннәр! Юкса, кемлекләрен онытып җибәрәләр, акылларын да, йөрәкләрен дә мүк баса башлый...

— Әлү-ү, әй, әлү, Вәлишин, дим! Тыңлыйсыз? Ә-ә, тыңлыйсызмы! Шулаймы! Сез нәрсә миңа бу баланы икенче тапкыр җибәрәсез! Нәрсә, аны гомерлек бәхетсез итәргә телисезме! Ничек бала кирәкмәсен! Бик кирәк!.. Үзе әйтә?!. Нигә алай дисен әле ул?!. Нигә сорамаска, сорадым, сорамыйча да белеп торам! Аның ни гаебе булсын! Ничек кирәк түгел! Аллага рәхмәт әйт, икенче тапкыр бит, каһәре төшәр, дип тә курка белмисез!.. Ничек ышанмыйсыз! Нинди коммунист, ди, инде сез, бала бит әле ул, бала! Үзеннән сора...

Усалланган карт врач шып тукталып калды. Дәшми утырды. Геннадий нидер аңлата иде бугай. Берничә тапкыр каты-каты әйткән сүзләре Альбинага да ишетелеп киткәндәй булды. «Хәзер мине сөреп чыгара инде бу!» — дип көткән иде дә, юкка борчылган икән. «Ярар!» — дип врач телефон трубкасын куйгач, аңа ягымлы эндәште:

— Шулайрак икән, сеңлем, алай-й! Нигә бала кирәк түгел соң? Бәлки, уйлап карарсыз? Сезнең кебек яшь, чибәр кызга, баласы бар, дип тормаслар, тагын да егетләр табылыр, солдат кебек шәпләре табылыр, Аллаһы боерса!

— Миңа башка кеше кирәкми!

Альбина башын аска иеп, елар дәрәҗәдә шулай дигәч, картның күңеле тагын да бозылып китте. Юмаларга кереште:

— Елама, сеңлем, елама! Бик яратасынмыни?

— Бик тә, бик тә... Үлеп яра...

Усал әйткәнне күкрәк киереп кабул итәргә әзер торган карт врач каршысындагы чибәр һәм яшь кызның күз яшьләреннән җебеп китте, шулай да үзен кулга алырга тырышты.

— Уйлап кара, сеңлем, әле соң түгел! Башка бервакытта да балагыз булмаячак! Теге юлы ук булмас дип әйткән идем, әмма Аллаһы тәгалә сиңа икенче тапкыр уйларга юл бирә, кабат сыный, әгәр дә монысында да сынатсагыз, гафу итмәс! — Ул борчыла иде. Шул сәбәпле әле «син», әле «сез» дип сөйләде.— Бик сирәк очрак, икенче тапкыр. Вакыты узган бит! Хәзер төшерергә ярамый! Җан кергән!

— Каян беләсез? Сез бит әле мине карамадыгыз да!

Альбина алдарга җыена иде, әмма тәҗрибәле врач белми каламы соң? Алдарсың, бар!

— Буеңнан, күзләреңнән күреп торам!

— Ярар инде, абый, миңа бала кирәк түгел! Больницада да калдырасым килми, гомер буе мине каргар дип куркам!

— Нәрсә? Ә болай, инде җан иңдерелгәч, каргамас, дип беләсеңме! Уйла, сеңлем, уйла, вакыт бирәм!

— Мин уйладым инде...

Альбина усалланып киткән карт врачның күзләренә туры карап, сөйрәлчек хатыннар төсле оятсыз рәвештә әйтергә тырышты. Нигә әле ул күз яшьләрен агызып утыра? Нигә ди әле аңа бала? Гомер буе аның белән интегергәме? Кирәкми, и бетте шуның белән.

Карт врач моны ук көтмәгән иде. Мизгел эчендә карарга килде һәм:

— Мин үземнекен әйттем, гафу...— дип урыныннан купты, ишекне ачып, каты гына кычкырды: — Агафия Павловна, кайда йөрисең анда! Кил бире!

Озак та үтми атылып-бәрелеп ассистенты килеп тә керде.

— Мин монда гына идем, Зөфәр Зарипович! Үзегез әйткән идегез бит...

— Ярар, менә бу кызны өстәлдә әзерләгез, карарга кирәк!

Минут эчендә Агафия Павловна янәшәдәге бүлмәгә алып та керде, чишендереп, Альбинаны чатлы-ботлы урындыкка да яткырды. Аякларын галәмәт рәвештә як-якка күтәртте. Кызның билдән түбән бар җире дә шәрә хәлдә иде.

Кулларын сабынлап юып, озак-озак корыткannan соң, Зөфәр Зарипович сафландырылган резин перчаткалар киде, дәшми-тынмый гына карады һәм әмер бирде:

— Операциягә әзерләгез. Бер сәгатьтән!

Карт врач Зөфәр Зарипович бер сәгатьтән әйләнеп керде. Бераз гына салмыш икәнлеге теленнән сизелде, һаман сөйләнде дә сөйләнде.

— Иманым камил, тагын бер буын, и бетте, моңа кадәр үзенең чибәр кызлары белән дан тоткан Казан шәһәре ямьсезләр, котсызлар, шөкәтсезләр каласына әверелеп калачак. Бер генә дә алай буласын теләмәсәләр дә. Һай-й, дөньялар, вай, дөньялар! Бер генә дә, бер генә дә... Килмиләр бит, күренми ямьсез кызлар, ә, Агафия Павловна, безнең өстәлдә. Бар да гүзәл кызлар гына. Алар гына килә. Монысы кебек ут кебек чибәрләре дә килә. Аз түгел, күп киләләр. Юк, дөрес түгел! Китерәләр! Во-о, китерәләр. Да-да... Әйтәм бит, тагын бер буыннан Казан каласында чибәр балалар туудан туктаячак, шәһәребезнең нуры сүнәчәк, Агафия Павловна! Шулвакыт безне исләренә төшерәчәкләр журналистлар, язучылар, галимнәр, тарих язучылар. Аптырап калачаклар! Казан шәһәрен гүзәлләрдән мәхрүм иткән кешеләр — без, ике явыз! Яшереп кала алмаячакбыз, таптап китәчәкләр. Ә теге дөньяда, җан кыяларенә Газраил булганым өчен, Аллаһы тәгаләнең теләгенә каршы төшкәнем

өчен мине дә, сине дә, әйе-әйе, сине дә һәм,— Альбинага ишарә ясады,— аны да утка салачаклар. Менә күңелле булачак, шулай бит! Там-тарам, там-там...

Авыз эченнән генә көй көйләштереп, карт врач кулларын тагын бер кат юды, әзерләнеп яткан Альбина янына килде, елмаеп җибәрде:

— Менә монысы яхшы булган, бик яхшы! Хәзер без аны, хәзер... Агафия Павловна, анда Сергей Николаич белән Антонина Михайловна әзерләнеп торабыз дигәннәр иде, китерсеннәр!

— Хәзер!..

Ассистенты ялт кына чыгып китте. Карт врач әйтеп куйды:

— И-и, кызым, шушы кадәр чибәрлегең белән син әле җәннәткә дә керерсең!..

Өч көннән Альбинаны Геннадийның машинасы килеп алды һәм тагын Алабугага озатып куйды. Төшергән бала яралчыгын пробиркага салып, фәнни белешмәләр өчен алып киткәннәрен һәм ясалма рәвештә үстереп карарга җыенганнарын белми иде ул. Әмма икенче нәрсәне күңеленә ачык итеп уеп куйды:

— Башка минем бервакытта да балам булмаячак... Мин мәңгегә бала хәсрәтеннән азат! Мин — ирекле кыз, мин — ирекле хатын!

Шушы фикерләре аны сөендергәннән сөендерде һәм бәхет кебек тоелды. Әмма ул ялгыша иде. Аспирантурасы бетеп, педагогия институтында чит телләрне укыта башлагач, аның күңелендә акрынлап-акрынлап изге хис уяна барды, ул да булса — бала кадерен аңлау, аның шатлыгы белән шатлану, аның хәсрәте белән көенү иде. Әгәр дә язмышы дөрес эздән генә барса, ул бүгенге көндә ике бала анасы дәрәҗәсендә яшәр иде, әмма бәхете, куанычы, кадерлесе Геннадийның назларыннан, мәхәббәтеннән коры калыр иде шул!

Айзик аш табагы янына килеп басты. Бер — аска, бер — өскә, Альбинага карады, ашарга бир, янәсе. Ханым гадәтенчә консерва ачты һәм этенә бушатты. Үзенә чәй куйды, өстәл хәстәрләде.

Телевизорын кабызып карады, әмма бер дә юньле тапшыру юк иде. Аны сүндереп, радионы ялгады. Ул арада чәе дә кайнап чыкты һәм ул арган кеше кебек килеп утырды. Исәреп калды. Радиодан моңлы гына көй сузылып-сузылып чыга һәм җанын бөтереп алып, каядыр еракка-еракка алып китә иде. Ә анда, еракта, аның сизелмичә узган яшьлеге, бәхет һәм шатлык, тигез тормыш вәгъдә иткән самими чаклары адашып калганнар да, килеп алганын көтеп торалар, чакыралар төсле тоелды. Ә, юк икән, онытылып калган яшьлеге түгел, очар кошлар кебек тезелешеп килгән сабый чаклары, әтисенә ияреп йөргән яланаяклы кызчык вакытлары икән! Чакырмыйлар, чакырмыйлар бит! Ерагая баралар, мәңге кабатланмаячаклар бит! Һәм ул шулай булачак та...

*Ахыры киләсе санда.*

## ШИГЪРИЯТ



**Флера Гыйззәтуллина**

# КЫЯЛАР МОҢЫ

ПОЭМА

### Яну

Кемнәр бүген кыяларга менгән?
Төштә кемнәр күргән Акбүз ат?
Матур төшнең өндә юш килүен
Көтеп алулары, һай, озак!
Һай, аяныч замананың хәле:
Тыпырчына канда, мәкердә.
Мөэмин-мөселманның җан сурәте
Кыя булып калка хәтергә.
Гарасатлы сугыш кырларыннан
Ябырылып килеп өсләргә,
Пар аккошлар, Акбүз атлар түгел,
Кара кошлар керә төшләргә.
Тарасаң да шундук чуалта җил
Ил атының чая ялларын...
Уттан-утка салганнарыдыр — без,
Каргалганыдыр без — алланың!
Алла хакы безнең бер гомердә
Әллә ничә төргә үзгәргән.
Хәерхаклык көзләп җаннар чыга
Җиргә төшми калган эзләрдән.
«Бөек империя» көченгәндә
Илдән-илгә канлы кер ташып,
Уздык ич без алга, «туры юл»дан
Йөз басасы җиргә бер басып.
Төштә түгел, өндә ничә гасыр
Карурманнар гизеп берочтан,
Кайгыларга уралганбыз ич без,
Туралганбыз ич без кылычтан.
Бүген дә мин безнең кан дошманның
Кылычлары кында димәм, һич!

Һәр үтәр юл, каны сөртелмәгән
Кылыч йөзе төсле имәнгеч!
Һәр тоткан эш таләп итә бездән
Илгә тоташырдай җан көче.
Өметебез дә туа-тумыштардан
Йөрәкләргә сауган кан төсле!
Шушы төснең ачыклыгын саклау
Безгә мәҗбүриләп йөкләнгән...
Мин тарихның мәкер күзен ачтым
Бөркет күзләгәндә күкләрдән.
Бәхет эзләп читтә йөргән чакта,
Ачтым аксакаллар фикерен:
«Соңгы чиктә гүрле булу өчен
Төзи халык илдә үз түрен...»
Китә калса — урап кайтачагын
Ак юл итеп чорнап уена,
Саубуллашкан мизгелләре белән
Серләшә ул гомере буена.
Тәннәреннән җан җылысы китсә,
Ярга учак ягып җылына...
Баккан саен килеп төртелә күз,
Ятименә, илнең толына.
Күңел күге күрәзәлек көтә
Ак коштан да, кара коштан да...
Куены тулы алтын таулар тоткан
Шушы изге Татарстанга
Гомерсезлек, тимерсезлек янап
Безнең котны алган чакларда,
Шул кошларгаияреп киттем дә мин,
Кайталмадым туган якларга.
Әмма бүген кара козгын туе
Бәреп кергәч үзәк йортларга,
Яндым кайтып... дөрли-дөрли яндым
Илкәемә капкан утларда.

## Милләтемнең башка тарихы юк

Халык әйтә: «Илдә тилмермисең,
Янсаң бер-береннән алып ут...»
Юк, мин башка төрдә яна алмыйм,
Минем өчен башка яну юк!
Милләтемнең башка тарихы юк,
Шушы тарих ташка басылган.
Мин тезләнеп җиргә укыйм шуны
Әткәемнең кабер ташыннан.
Мәңгелеген түзә ут өстендә
Тезләнүне белмәс тезләрем!..
Кара дингез аша карый илгә
Мөлдерәмә яшьле күзләрем.
Үзен өзелеп көткән күзләремә
Кайгы салып дингез кадәрле:
«Кырым азатлыгы өчен!» — диеп,
Килде аның соңгы хәбәре.
Бөтен Рәсәй халкы җиңү даның
Мактап күккә чөйгән айларда
Без «туганнар каберлеге»н эзләп
Юл тотмадык каян-кайларга?!

«Пик»-тауларны, «Каф» тауларын үттек,
Артыбыздан калды җыр ташып...
Кызынырга — бераз ялга талдык
Кырым ярларына урнашып.
Безне анда сәяхәттә йөртте,
Кырымлылар түгел, бүтәннәр!
Юл өстендә сибелеп-сибелеп калды
Каберлекләр, гөлле түтәлләр...
Сугыш корбаннары каберенә
Гөлләр салдык без дә елашып...
Кая юнәлсәм дә алдан миңа
Әткәм рухы йөрде юл ачып.
Әмма татар икәнемне белгәч,
«Бүтәннәрнең» йөзе каралды.
Сиздең: бу каралык, милли өнне
Һәлакәткә илткән яралгы!
Бу каралык борын-борынгыдан
Буа бөтен өнен-өммәтен
Зурлыклары яла хурлыгында
Сөрген киткән горур милләтнең.
Кырым ярларына кырлай ятсаң,
Күңел тагын шуны төшенә:
Монда кызыну — гөнаһ, үз йөзендә
Иман нуры йөрткән кешегә.
Алган сулыш саен, адым саен
Курку кирәк монда алладан!
...Сөрелгәндүк инде халыгының
Чиреге дә исән калмаган!
Кырымлылар илсез генә түгел,
Якты кәнсез, гүрсез, кабирсез!
Үзгә үрдән баккан гамьсез күзгә
Ае, кояшлары кадерсез.
...Яшәү белән үлем тартышканда
Иңләп Җир белән күк арасын:
Сөйкемлеме күмелмәгән сөяк?! —
Хәтереңә сөяп кара син?!
Һәр кыя таш, һәр сөякле тияк
Һәр тамчы су монда кансырый.
Кабердәге әткәем дә минем
Палачыннан үзенең җан сорый.
Кара чаршау коралмаган палач
Хәтер атлы текә кыяга.
Үчкә каршы үч давылы купкан
Татар нәсел типкән оядa.
Килмешәкне көйли алмагачтын
Алма-хөрмә, җимеш ашатып,
Мең әҗәлен җиңгән кырым халкы
Гомер кыясыннан таш атып,—
Мәңге кадер белмәс бирән затка
Капкан ачы нәфрәт давылы.
Авыр булган кыя бөркетләрен
Кыялардан аерып алуы.

## Гыйбрәт булсын!

Мин ышанмыйм!
Юк! Юк! Хак түгелдер:

«Хәтер» диләр — бәллүр пыяла!
Бар хәтере, җаны-сыны белән
Охшаш безнең язмыш кыяга.
Мәңге-бакый тояк тавышын тоеп
Туй төшергән Акбүз атларның,
Таулар, таш кыялар бәйләп торган
Һәр тармагын моңлы татарның.
Һәм хәзер дә җиңү шарты белән
Юллар аерылса икегә,
Бар дөньядан гүр газабы ялмап
Бөркет-татар утка сикерә.
Диңгез аръягына аваз салсаң:
— Ни яңый! — дип анда татарга? —
Диңгез үксеп, таулар ыңгырашып,
Кыя шыңшып җавап кайтара.
Әнә шул кайтаваз, тарих өчен
Гыйбрәт булсын бүген бездән дә!
Сугыш кайгысының сагышына
Сарылып йөздек диңгез гизгәндә.
Кызганычка каршы, йөзеп чыктык
Бер ташландык шәһәр катына.
Җан тетрәүгә, кыя белән бергә
Хәрабәләр анда атыла.
Бүгенгәчә һичкем күченмәгән
Кыядагы үле шәһәргә.
Югарыда Бөркет кенә оча
Күрәчәкне тотып шәһәрдә.
Шуңа күрә хәтәр бу күренеш
Уйга сала адәм башларын!
Аста затлы чиркәү салган чакта,
Мәчетләрнең изге ташларын
— Ташыгыз! — дип, катгый әмер биргән
Таш бәгырьле сөрген түрәсе...—
Каһәрләнгән сатлык илбасарга
Куркынычтыр кыя түбәсе!
Баскынчыны анда баштанаяк
Чорнагандыр гөнаһ шомлыгы!
Гөнаһлылар дәшми. Аларның шул
Эчләрендә кабер тынлыгы.
Аларның шул үзләреннән алда
Өрәкләре йөри юл ачып.
Ә бит йөрәк зирәклеге кирәк
Яшәү өчен дөрес урнашып.
Төп-тамырдан уйлый белү кирәк.
Кем туфрагын таптап йөрисең?
Нәселеңә нинди сулыш өрдең
Киләчәктә яулар үр өчен?
Җиккән атың синең туй атымы?
Акылкаең алтын акылмы?
Газиз Ватан өчен баш очында
Сакладыңмы изге атыңны?
Барладыңмы бөтен шәҗәрәңне
Бәйләп үзең туган гасырга?
Гасырларның мәкерен без ачтык,
Әрнешләрне ничек басырга?!

## Дагалы ат кирәк заманага

...Туган яклар өчен, атлар өчен
Кыйммәт торгангадыр кирәге...—
Агам чүкеп куйган дагаларның
Шундый шома иде җөйләре.
Бигрәкләр дә газиз иде җанга
Тимер тулы балчык алачык.
Заман икътисады алтын даулап,
Хәзер йөри шунда адашып,
Илләр-көннәр әверелгәнгә күрә
Ачы язмыш көянәгенә:
— Мин — бөркет! — дип, канат кага өстә
Хәтта көя күбәләге дә.
Көя кебек үрчегәндә җирдә
Үч-гайбәтнең вагы-төяге
Ничә тапкыр без күлкәгә калдык
Бутап бөркет белән көяне.
— Юк! — диюдән куркып, Акбүз атның
Кара эшкә җиктек соңгысын.
Кешнәүләре аның төшкә кереп
Боза хәзер йөрәк тынгысын.
Йөгерә күңел тимер тиендәге
Җанга якын урак-чүкечкә,—
«Бәхетемә» — дип аны балачактан
Алып торган идем үтечкә.
Шушы тимер тиен очын-очка
Ялгап торды бөтен гомернең.
Сугыш елларында ут алырга
Мин гел алачыкка йөгердем.
Сандалларда көн-төн тимер чүкеп
Абыйларым шунда кышлады.
Җырларыма кергән шул алачык
Булды миңа җәннәт почмагы.
Авыр чүкеч тавышы иңрәвендә
Алдым шунда хезмәт дәресен.
Тимер чыдамлыгы белән тиңли
Авыл халкы кылган һәр эшен.
Шәп тимерче гади тимерне дә
Тиңләштерә ала алтынга.
Тимеренә кызуында сукса
Уйлап алтын дага хакында.
Шуңа «Тимер!» — диеп исем кушам
Чордан нинди җыру отсам да:
...Заманага кирәк дагалы ат
Тимерчеләр кирәк күп санда!
Дөрес итеп төш юраучы кирәк:
Төшләр, өннәр безнең бер чама.
Тояк тавышларын еллар йота,
Торган саен илгә моң сара.
Тәкъдир безне мишень итеп тота
Әйтерсең лә кыя очында.
Татар сула! Сына, юкка чыга
Татарстанымда, шушында!
«Очта» кылыч-хәнҗәр чыңлап торса,
Төпкә корыч капкын корыла.
Атсыз, саксыз шуннан узып кара,

Юл күрсәтеп һәрчак турыга!
...Илдә кан исенә исеңгерәп
Туры юлны күпләр онытткан.
Милләтемнең киләчәген мактап
Ялган белән буын ныгытмам.
Үзлегемнән бер дәлилсез илгә
Вәгъдә итмәм корыч ихтыяр...
Минем алда ике сынык канат,
Тирән томан баскан ике яр!
Тоткан юлың кая юнәлсә дә,
Кара-каршы ярлар кавышмый.
Мин бары тик узганнарны аулыйм
Томаннардан — кояш баешлый.
Балачакның балчык алачыгын
Хозурласын өчен яңа таң,
Мин бары тик күрәзәлек итеп
Ил хәтерен генә яңартам.
Сизгер тимерчеләр колагына
Ипләп кенә шуны беркетәм:
— Йөзең кара! Көш-ш-ш! — димәгез аңа:
Чал каурыйлар коела бөркеттән!
Гасыр буе безнең иңгә дә бит
Ак шәл булган бөркет канаты...
Юк! Шәл түгел, горур Татарның бу
Саубуллашу экспонаты!
Кайгы кочып очу рәвешләрен
Милләт язмышына охшатып,
Бу бөркеткә төбәп корылгандыр
Ничә мылтык бүген, ничә туп?!
Бу коточкыч фаҗиганы бәлки
Күпләр игътибарга алмыйдыр?...
Тимерченең күмер күрүкләре
Тын-сулышын көчкә ялгыйдыр.
Күндәм күңел... җитмеш үлем аша
Тиенәдер, тимер, түземгә...
Акбүз атын, үзенең яшәү шартын
Тотып канлы кылыч йөзендә.

## Кайту кыйбласы

...Кан дошманың сиңа һәр офыктан
Кылыч-хәнҗәр янап торганда,
Тыныч кына ничек утырсын җан
Богауланып корыч «кыннар»да?
Сулыш алган саен чит мөхиттә:
— Ай, йөрәкне хәнҗәр чәнчә, — дип,
Без болай да якты дөнья белән
Көн дә саубуллашып яшәдек.
Тормыш йөген дөнья тарталмагач
Ачу итеп атка-йөгәнгә
Бер-ике юл җыр җырлаган өчен
Дилбегәне бирдек чегәнгә.
Ярыш-бәйгесендә үз атыбыз
Чегән аты булып саналды.
Тимерчелек, һөнәрчелек түгел,
Чегәнчелек илдә дан алды.

Ил буйлата, «ачык авыз»лыкта
Тота-тота нәсел-затыңны
Болай булса, соңгы тиенне дә
Алдап алыр чегән хатыны —
Каргар, сүгәр:
— Аз бирдең ич! — дияр,—
Тулмый калды алтын чүлмәгем!
Чегән сиңа тотып карарга да
Рөхсәт итмәс ефәк күлмәген...
Юк, онытмас, атта качкан чакта
Үзе белән алыр кәртен дә...
— Хах-ха-ха! — дип көлгән тавыш кына
Ишетелер еллар артында.
Сугар шулчак милли хис гарьлегең,
Антың сугар газиз башыңа...
Илгә, ышанычка якынаю
Вәгъдә-антлар аша ачыла.
Антым, Акбүз атым саклаганда
Мин дә көч-куәтем аямам.
«Кайту» кыйбласында милләтемнең
Тапкыр җайдагына таянам.
Туфрагыңны таптап йөргән өчен
Бәхиллегең бир! — дип, син безгә,
Исемемне, адресымны язып
Көмеш йөзек салдым диңгезгә
Илгә кайтсын өчен кыйбла ачам
Кошның карасына, күгенә.
Кошлар гына очар биеклектән
Уйларымның төшәм төбенә.
Аң-зиһенем тирәнәйгән саен
Үз алдыма шуны төшенәм:
Чал каурыйлы изге кош хәтерен
Көтә язмыш һәрбер кешедән.
Гасыр бездән хәер-дога көтә
Ярдәм, яклау көтә Кырым да! —
Әче җан газабын кысрыклап
Кыяларның маңгай сырында.
Чорга маңгай терәп сорау бирсәң:
Эшләр бара, диеп, кай таба?...
Диңгез — үксеп, таулар — ыңгырашып,
Кыя шыңшып җавап кайтара.



# ШИГЪРИЯТ



## ҖӘҮДӘТ ДӘРЗАМАНГА 50 ЯШЬ

**Җәүдәт Харис улы Дәрзаман 1945 елның 13 октябрендә Татарстанның Лениногорск районы Сугышлы авылында туа. 1964 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Шул ук елны Совет Армиясе сафларына алына. Хезмәтен төгәлләп кайтканнан соң, ул университетта укуын дәвам иттерә һәм аны 1972 елда тәмамлап чыга. Озак еллар Татарстан радиосында эшли һәм «Ялкын» журналында баш редактор вазифасын башкара. Җәүдәт Дәрзаман — нигездә балалар шагыйре: ул алар өчен «Ирбатыр», «Солдат булдым», «Төнге мажара», «Гөлназ мәктәпкә бара», «Безнең әлифба», «Җир авазы», «Айбулат», «Бизмән йолдызлыгы» кебек әкият, шигырь китаплары, повестьлар бастырып чыгарды. Шулай ук аның «Ник кирәсез төшләремә» һ. б. проза әсәрләре дә укучыларыбызга яхшы таныш. Юбилее белән котлап, бу санда шагыйрьнең балалар өчен төрле елларда иҗат иткән шигырьләреннән бер бәйләм тәкъдим итәбез.**

## Җәүдәт Дәрзаман

### Иң зур хикмәт

Әйтерсең лә кайнар мичтән
Яңа чыккан икмәк,
Җылы бөркеп тора Кояш,—
Ичмасам бу — хикмәт!

Аның нуры төшкән җирдә
Гөлләр чәчәк ата,

Ужымнары шытып чыккан
Кырлар җәйрәп ята.

Көн тудымы, көнбагышлар
Аңа багып тора.
Елгалар да сөенешеп,
Дулкын кагып тора.

Һәркөн иртән баш иеп мин
Сәлам бирәм аңа.
Иң зур хикмәте дөньяның —
Күктә Кояш яна!

## Аҗаган

Бик еракта, күк читендә
Аҗаган уйнап китә.
Алсулыгы болытлардан
Офыклар буйлап китә.

Әйтерсең лә карт тимерче
Өйрәнчеген өйрәтә,
Ә тегесе, күрек тартып,
Мичтә күмер көйрәтә.

## Булачак юрга

Дөнья кемгә рәхәт дисез,—
Рәхәт безнең тайга.
Канат кына чыкмый калган,
Очар иде айга!

Ник очмасын, бик оча ул,
Оча болын буйлап,
Сабантуйда узышасы
Чабыш юлын уйлап.

Оча гына — тояклары
Тими кала җиргә,
Әй чаба ул, әй ашкына
Төшеп шабыр тиргә.

«Сабантуйлар юргасына
Җитми болын гына!»
Әнә ниләр уйлап чаба,
Үзе — колын гына...

## Умырзая

Тауда умырзая таптым,
Таптым да кире чаптым.
Чәчәкне тоткан көйгә,

Йөгереп кердем өйгә,
Йөгереп түргә уздым,
Әбигә кулым суздым:

— Мә, ал,— дип,— умырзая!
Ул, юкса, никтер боек,
Утыра озак оеп.
Ачсын әле күзләрен бер,
Сөендерим үзен бер!
Сөенмәде, нишлисең...
Әйтте тартып дисбесен:

— И балам, гомер зая...

## Ялгыз сандугач

Бер сандугач һәр таң саен
Җыр суза өзеп-өзеп,
Бер моңлана, бер зарлана
Сүзләрен тезеп-тезеп.

Моңын аңлыйм, сүзләрен — юк.
Аңлый алмыйм зарын да.
Чү, әнием белми микән,
Аңлый бит ул барын да.

Соравымнан моңсуланды
Әниемнең күзләре.
Миңа туры карасa да,
Мөлдерәмә үзләре.

— Сөеклесен югалткан ул,
Шуңа моңлана, балам.
Менә мин дә синең белән
Ялгыз ни эшли алам...

...Ә сандугач инде елый,
Сүзләрен тезеп-тезеп.
Моңсу сүзләр тезеп-тезеп,
Минем үзәкне өзеп...

## Бабам сүзе

Җиде Чишмә дип кушканнар
Безнең авылга исем.
«Җиде Чишмә» булганга да
Китә шул акыл-исем.

Нибарысы бер чишмә бар,
Суы — тик сызык кына.
Чиләгеңне тутырасың
Тик тартып-сузып кына.

Калган алты чишмә кайда,
Кая киткән шулары?
Кая киткән көмеш кебек
Чыңлап аккан сулары?

Әгәр соңгы чишмә кипсә,
Күчеп китәрме авыл?
Авыл кадәр авыл бетсә?!
Алай начар була ул...

Калган алты чишмәнең мин
Берсен булса да табам.
«Чишмә башы — гомер башы»,—
Дип белми әйтмәс бабам!

## Уйлану

Шәһәр асфальтларын бизәп,
Утыра өрәңгеләр.
Өрәңгеләр асфальтта да
Үсәргә өйрәнделәр...

Үссәләр дә... Мин аларны
Кызганам шул, кызганам.
Ничә еллар һаман ташка
Төшәләр дип сызланам:
Салкыннарда чыныккачтын,
Яңгырларда коенгач,
«Көч тупладым. Инде хәзер
Яшәргә!» — дип җыенгач,
Җилфер-җилфер коелгач...

Таш юлларда таптап узу
Безгә генә уендыр.
Орлыклары шыталмаган
Өрәңгегә кыендыр.

Өрәңгегә кыендыр...

## Бәрәңге бакчасында

Әти белән әни казый,
Ә мин күз салып барам.
Әни әйтә: «Өскә карат
Күзәнәкләрне, Кәрам!»

Моңарчы гел дөрес салдым,
Ялгыш салдым бары... бер.
Туфрак белән каплап куйгач,
Күрми лә ул барыбер!

## «Чабата»

Әтиемнең иң яраткан
Бию көе — «Чабата».
— «Чабата»га тимәгез, — ди, —
«Чабата» безгә бата!

Биеп китә, мин сиңайгим,
Вак атлап, тыпырдатып,
Аю кадәр гәүдә белән
Идәннәр шыгырдатып.

Үзе көлеп такмак әйтә:
— «Чабата» безгә бата...
Вәт әкәмәт, читек киеп,
«Чабата» биеп ята!

## Беренче яңгыр

Күрше кызы Ләйсән кергән,
Кергән сулышы кабып.
Шул, урамга дәшүедер
Тагын бер сәбәп табып.

Дөрестән дә!
— Тизрәк! — ди бу. —
Ләйсән күрми каласың!
Бүтән сәбәп табалмаган,
Ну бу адәм баласын...

— Үзең йөгереп кергәнсең ич,
Ничек күрми калыйм? — дим, —
Кил, алайса, битеңдәге
Сипкелләрне саныйм! — дим.

Ләйсән көлә:
— И тиле, — ди —
Сипкелне кем санасын?
Минем белән тел озайтып,
Яңгыр күрми каласың!

Рәхмәт, Ләйсән, рәхмәт сиңа!
Ярый син бар күршедә —
Синең кебек матур итеп
Дәшми миңа берсе дә!

## Күзле кычыткан

Кычытканмы?
Кычытканның
Беләм мин ике төрен.
Берсен озак сөйләп тормыйм,
Яхшы беләсез серен.

Анысының тылсымы бар —
Яфрагы сырлы-сырлы.
Кире булсаң, үҗәт булсаң,
Сикертә үрле-кырлы!

Ыштаныңны төшерә дә
Йомшак җирне «пешерә»:
«Моннан соң сүз тыңлар идем!»—
Дияр көнгә төшерә.

Икенчесен әйтмим дә мин,
Анысын мин санламыйм.
Санламавын да санламыйм,
Тик шунысын аңламыйм:

Ник әйттеләр икән аңа
Сукыр кычыткан диеп?
Әллә «өтмәгәнгә» микән,
Китсә дә тәнгә тиеп?

Ул, ичмасам, кагылсаң да
Сыйпап иркәли генә...
Ә тегесе бакчаларга
Юлны киртәли менә!

Җиләк, кыяр күптән беткән,
Белмим, нәрсә карыйдыр?
Күзле булгач, күрәләтә
Чакмаса да ярыйдыр!

## Төнбикә

Зәңгәр күлмәк киеп,
Кара шәлен ябып,
Колагына сыңар
Ай-алкасын тагып.

Энҗе-мәрҗән тулы
Тырыс алып кулга,
Менә Төнбикә дә
Чыкты ерак юлга.

Аны күргәч, Кояш
Янып, тирләп, пешеп,
Китте шыпырт кына
Тау артына төшеп.

Ә Төнбикә туктап,
Кара шәлен салды.
Шомырт-кара чәче
Бөдрәләнеп калды.

Аннан шәле белән
Томалады күкне.
Абынды да шунда,
Энҗеләрен түкте.

Энҗе-мәрҗәннәре
Чәчелделәр чыңлап.
Һәм ул күзен йомды
Алар чыңын тыңлап.

Йоклап утырмый шул,
Таң кошы да наян! —
Энҗе-мәрҗәннәрне
Күрде әллә каян.

Салмак кына сөйрәп
Кара шәлнең читен,
Кабат каплап куйды
Төнбикәнең битен.

Аннан чүпләп төште
Мәрҗәннәрне күктән,—
Ә Төнбикә күрми —
Йоклый инде күптән!

**Рөстәм Мингалим**

**Ризван Хәмид**

# ИДЕГӘЙ

(НӘФИС ФИЛЬМ ӨЧЕН ДРАМА)

## Өченче фильм

### I бүлек

**Ак Бүре ыруы авылы. Тишелеп килгән иртә таң.**

**Биш-алты зур йорттан һәм берничә каралты-курадан торган авыл. Барлык йорткуралар бергә биек казык коймa белән уратылган, авыл капкасы тирәсе буралы һыгытмалы һәм бикле. Җәй урталары. Кояш чыкмаган әле.**

**Авыл капкасы янына тимер туркалы җайдак чабып килеп туктый.**

Җайдак *(түземсезләнеп капка кага)*. Әй! Йоклыйсызмы әллә! Карлуклар явы килә!

**Капка ачыла һәм йокылы-уяулы кыл киемле сакчы күренә.**

Җайдак. Яу килә — ә син күзеңне ерта алмыйсың, гамьсез! Ыру башы Хәйбулла абызны уят тизрәк!

Хәйбулла *(киенә-киенә ашыгып килә)*. Сәлим углым, синме бу? Ник даулашасыз? Нишләп постырмаңны ташлап кайттың?!

Сәлим. Бәдри калды анда, Хәйбулла абыз. Әзерләнегез — карлуклар ерымнан Дүртмаңгай тавына күтәрелеп җитеп киләләр инде!

Хәйбулла. Канча җан?

Сәлим. Өч йөзләп чамасы булыр, Хәйбулла абыз! Барысы да баштан-аяк коралланган. Буш арбалы атлары да күп: безне искәрмәстән талап китәчәкләренә әз генә дә шикләнмиләр, димәк! Дәргаһтан сөрелгән Идегәйгә ышанмагыз, зинһар! Үз йортына яу китерткән нәмәрсә ул, дип күпме әйттем мин сезгә, Хәйбулла абыз! Ә без аның үзенә өй башыннан икешәр яугир биреп җибәрдек! Син үзең дә хәлал задәңне кызганмадың. Аксак Тимер бөтен чирүе белән Идел буенда дүрт атнадан артык Туктамыштан талап җыйган гыйнимәт исәбенә типтереп яткан, имеш. Яшь кыз-кыркыннарны гына да гаскәренә кырык меңләпне өләшкән, ди! Идегәй кая булган шул вакыт?! Ник безне Аксак Тимердән калган килмешәкләрдән көпә-көндез кычкыртып талата?! Карлуклар — шуларга ияреп килгән этләр ич! Юньсез хуҗа үз өенә үзе яу китерә!

Сакчы. Идегәйнең безгә хуҗа булганы юк ич әле, нәрсә юкны лыгырдыйсың, калтак?

Сәлим. Булмаса — булыр, өшегән авыз! Аның бар максаты шул!

Хәйбулла. Тынып торыгыз. Карлуклар — өч йөзләп дисең? Без — малай-шалайларны да санап — ике йөзгә дә тулмыйбыз... Беркөнге яулары барып чыкмаганның үчен алырга килүләре инде бу... Менә нәрсә, оланнар: син *(сакчыга)* барлык хатын-кызларны, бала-чагаларны, кулына корал тота алмаган карт-корыларны җый да, Куянкул урманына озат, ә син *(Җайдакка)* — яугир ирләрне уят. Менге атта булсыннар. Кирмәндә беркем дә калмый.

Сәлим. Ничек?! Шул битләрен юа белмәгән күсә карлуклардан качабызмы?! Болай да Аксак Тимергә ияреп килгән җыен килмешәктән дер калтырап торабыз! Йортҗиребезне бер карусыз сасы карлукларга ташлап качканыбызны ишетсәләр, бөтен

---

[1] Ахыры. Башы 7 һәм 8 нче саннарда.

тирә-як кирмән тавыклары кычкырып көләчәк ич бездән!

Хәйбулла *(тыныч)*. Кем сиңа ташлап качабыз, диде? Авыл тирәли посабыз да... җаен туры китереп, барысын берьюлы укка алабыз. Халыкка әйтегез: әзер бузаларын мичкәләр белән капканың бу ягына чыгарып куйсыннар. Карлукларның кылыгын яхшы беләбез — иң башлап буза чөмерергә тотыначаклар алар! Кушканны үтәгез!

Сәлим. Ул чагында... берничә егет белән мин авылда посып калам!

**2. Шул ук җир. Иртә.**

**Авыл тирәсендә тынлык: капка шар ачык. Бары тик утар эчендә адашып калган бер эт йөри һәм берничә кош-кортның тибенгәне күренә. Ыру башлыгы кушканча, капка янына берничә мичкә белән буза чыгарып куелган.**

**Капка янына, авылны ике яктан урап, карлук җайдаклары килә: алар бик сак кыланалар, хәтта атларының тоякларына чүпрәк урагаled. Өсләрендә җиңсез кыска тун, башларында күрпә бәрән тиредән тегелгән биек бүрек. Коралләры Ак Бүреләрнекеннән артык аерылмый, атлары гына бераз тәбәнәгрәк. Аларны авыл каршындагы кечкенә калкулык артыннан Хәйбулла абызның яугирләре күзәтеп ята. Карлуклар, капканың шар ачык икәнен күргәч, аптырашып туктап калалар. Берничәсе утар эченә үтә һәм шундук кире борылып чыга.**

Берсе. Бер җан әсәре дә юк анда! Кирмәннәрен ташлап, табан ялтыратканнар, ахрысы, болар.

Икенчесе *(атыннан төшеп, мичкәләрне тикшерә, учы белән алып, буза кабып карый)*. Дөрес! Хәтта бузаларын түяргә дә өлгермәгәннәр! Менә сезгә гаярьлеге дөньяга таралган Ак Бүре ыруы! *(Көлә.)* Егетләр! Җәһәтрәк килегез: бик шәп буза әзерләп куйганнар безгә! Яхшы буза калганчы, яман корсак ярылсын!

**Яугирләрнең кайберләре аның янына ташлана.**

Яубашы *(ачулы)*. Ашыкмагыз, ахмаклар! Ачы кушкан булсалар?

Берсе. Хәзер раслыйбыз аны! *(Якын тирәдә чуалган этне тотып ала һәм, чината-чината, башы белән мичкәгә тыгып эт, карышса да, бузаны эчәргә мәҗбүр була. Җибәрә.)* Инде карап карыйк: нишләр икән бу?

**Мескен эт чәчи-чәчи өргәндәй итә, бераз чайкалып тора да, кинәт каты өреп, кыерсытучысына ташлана. Аны күзәтеп торучылар кычкырып көлешә башлыйлар.**

Берсе. Күрдегезме, ничек гайрәтләнеп китте, ә?! *(Этне типкәли-типкәли читкә куа.)* Ташландык, егетләр! Беткән баш бе-ткән.

Яубашы. Ашыкма! Чапмас борын агач та аумый. Иң элек бөтен йортларны җентекләп тикшереп чыгыгыз! *(Бармаклары белән төртеп.)* Син. Син. Син. Һәрберегез унбашы буласыз. Егетләрне үзегез сайлап алыгыз. Карагыз аны — әйле-шәйле генә кыланмагыз! *(Тагын бер-ике егетенә.)* Ә сез тирә-якны күзләп чыгыгыз: посып ятмыйлармы икән?

**Егетләр: «Бузаны безгә дә калдырыгыз, гужланмагыз!» — дип аның әмерен үтәргә ташланалар. Ике егет каршыдагы калкулыкка таба, Хәйбулла абыз белән авылдашлары поскан җиргә юнәлә.**

**3. Калкулык арты. Шул ук вакыт.**

**Калкулык артына поскан егетләр тиз генә куаклар арасына кереп яшеренәләр. Менә карлуклар алар янына килеп җитә. Авыл егетләре аларны үзләре яныннан үткәреп җибәрәләр һәм, артларыннан сикереп чыгып, икесенә дә ханҗәр белән кадыйлар. Карлуклар, әһ дияргә дә өлгерми, җиргә тәгәриләр. Постырмада торучы егетләр тиз генә аларның гәүдәләрен куаклар арасына яшерәләр һәм атларын урман арасына кертеп бәйлиләр, ә үзләре кабат авылны күзәтүне дәвам итәләр. Капка кырында мәш килгән карлуклар мондагы хәлне сизми дә кала.**

**4. Капка төбе. Шул ук вакыт.**

**Ул арада йортларны тикшерергә утарга кереп киткән яугирләр капка янына урап чыгалар: кайсы төрле-төрле ашам[illegible]лар күтәргән, кайсы култык асларын[illegible]лы кием-салым, алтын-көмеш әйберләр[illegible]тырган.**

Егетләр *(шат)*. Һу! Андагы байлык! Әҗеренә рәхәтләнәбез икән, агай-эне! Өйләрдә калган бузаның да иге-чиге юк! Бөтен урдабыз белән күченеп килеп, шушында утрак тормыш корабызмы әллә? Нигә? Бөтен кирәк нәрсә әзер! *(Көлә.)* Җәй бар, кыш бар, китәргә ашыгып ни эш бар?

**Кәеф-сафа кору башлана.**

Яубашы *(ул һаман атыннан төшмәгән)*. Бик хәвефле хәл бу! Артык онытылып китмәгез әле сез, егетләр: көтмәгәндә өстебезгә ташланмасыннар.

Берсе *(аңа алтын савыт белән буза бирә)*. Әҗәл житми үлмәбез, борчылма юкка, яубашы! Өркәк атлар түгел. Мә — эченә җылы керсен... Куян йөрәк «бүреләрне» ничек тә эзләп табарбыз!

Яубашы *(эчә)*. Егетләребез никтер озакладылар... Болай итик: табылган ганимәтләрне арбаларга төягез дә, кирмәнгә ут төртергә әзерләнегез. Ә мин урман авызы тирәләрен караштырып кайтам. *(Берничә егетенә.)* Син... син... син... Минем арттан!

**Яубашы белән берничә илбасар яугир урман ягына таба чаптырып китә.**

**5. Калкулык арты. Шул ук вакыт.**

**Кирмән башлыгы Хәйбулла абыз тирәсенә авылдашлары җыелган.**

Хәйбулла. Ут төртергә ирек бирмәскә... Хәзер үк һәрберегез, укка алыр өчен,

берәр-икешәр илбасарны үзара бүлешеп куегыз. Кая?! Әйткәнне тыңлап бетер!

**Тарала башлаган ирләр кабат аның кырына кайталар.**

Исерә төшсеннәр бераз!

**Авыл ягыннан җыр тавышы яңгырый.**

Ирләр *(көлешәләр)*. Синең сүзне генә көткәннәр икән, Хәйбулла абыз! Исерештек инде — эшегезгә керешегез, диләр алар безгә! Җиде бабаларын танытыйк әле, чыбыктан чыбыркы булган нәмәрсәләрне!
Хәйбулла *(күзәтчеләргә)*. Ничек анда?
Берсе. Һаман әйбер ташыйлар... Күбесе исереп килә бугай инде... Яубашлыклары урап кайтмады әле.
Хәйбулла. Капка тирәсендә күпмеләр?
Икенчесе. Барысы да шунда чуала. Тагын ике мичкә буза тәгәрәтеп алып чыктылар! Чыр-чу күтәрделәр: чыдап кына тор!
Ирләр. Болай барса, безгә тамчысын да калдырмаячаклар болар! Башлыклары югында шым гына эшләрен бетереп куйыйк булмаса, Хәйбулла абыз!
Хәйбулла *(уйланып)*. Аллага тапшырдык, оланнар! Шау-шу арасында сиздерми генә калкулыкны иңләп тезелегез: берсе дә качып китәрлек булмасын! *(Атына атлана.)*

**Авылдашлары, тирә-якка сибелеп, атларына сикерешеп менәләр.**

**6. Капка төбе. Сызылып таң ата.**

**Илбасар карлукларның күбесе шактый кәефләнеп алган: тик берничә комсызы гына утардан капка төбенә әйбер ташый. Уилабы, таякларга сүс урап, кирмәнгә ут төртергә әзерләнә. Менә алар сүсләрен, үзләре белән алып килгән чуендагы утлы күмердә кабызалар һәм утар эченә кереп китәләр.**

**7. Утар эче. Шул ук вакыт.**

**Факеллар тоткан карлуклар төрле якларга тарала һәм каралтылар янына якынлаша. Сәлим белән кирмәндә посып калган егетләр аларны чардак тишекләреннән күзәтәләр. Карлукларның берсе Сәлим качып торган йортка якын килә һәм барган шәпкә утлы таягын түбәгә суза. Сәлим аны тиз генә ук белән атып ега. Иптәшләре шулай ук бүтән карлукларны дә берәм-берәм укка алалар.**

**8. Капка төбе. Шул ук вакыт.**

Илбасар *(шактый олкән булса да исерек)*. Нишләп һаман төтен күренми анда? Бар әле, егетем... Исем шәрифләренне онытгым... Йә әле, яме?.. Буза эчеп, исерешеп ятмасыннар!

**Берничә карлук утар эченә кереп китә.**

**9. Утар эче. Шул ук вакыт.**

**Иптәшләрен эзләп кергән карлуклар җирдә аунап яткан бер якташларын күреп, өнсез торалар: аның гәүдәсен озын саплы ук аркылы тишеп чыккан, ә сүсле таягы пыскып сүнеп маташа.**
Берсе *(чәпчеп кычкырып җибәрә)*. Икенчесе әнә тегендә ята! Ни булыр бу?! Постырма калдырылган монда, егетләр! *(Капка янына йөгермәкче була, әмма Сәлим аны да тез астына суккандай атып ега. Аңга килгәләгәнче бүтәннәрен дә укка ала.)*

**Бер карлук исенә килеп, капка ягына таба йөгерә: Сәлим дә, иптәшләре дә аңа ук тидерә алмыйлар.**

**10. Капка төбе. Шул ук вакыт.**

Карлук *(иптәшләре янына йөгереп чыга.)* Эшләр хөрти! Бузаны ташлагыз! Кирмәндә постырма калдырганнар! Безнекеләр анда барысы да укка... *(Калкулык ягына карап, авызын ачып, тасраеп ката: бөтен калкулыкны Ак Бүре ыруы яугирләре сырып алган.)*

**Капка янындагылар ул караган якка таба борылалар һәм сикерешеп торалар. Калкулык уртасындарак туктаган Хәйбулла абыз югары күтәргән кулын кинәт түбән төшерә; ике йөзләгән ук шул ук секундта илбасар карлукларга кадала. Аяк өсте каткан карлуклар ачы кычкырып җиргә ава, утырып торганнары — урыннарында сеңеп тынып кала. Исән калганнары коралларына тотыналар, әмма исерекләр берни эшләргә өлгерми: беренче залп артыннан тагын йөзләгән ук исән калган карлукларны бәреп ега. Берничә җиңел яралы һәм укка эләкмәгән карлук утар эченә ташлана: аларны постырмалардан чыккан Сәлим иптәшләре белән бергә укка ала. Шулай итеп, бер-ике минут эчендә илбасарларның бөтенесе үтерелеп бетә.**
**Шул арада кирмән янына егетләре белән бергә Яубашы кайтып төшә һәм күзалдындагы мәхшәрне күреп, шашардай булып ката.**

Хәйбулла *(калкулык башыннан)*. Монда таба борыл, илбасар яубашы! *(Егетләренә ишарә ясый: яубашының иярченнәрен шундук укка алалар — алар иярләреннән җиргә мәтәләләр.)* Инде хәзер ялгызың калдың, яубашы! Нинди ният белән килдең безгә — әйт!

**Яубашы өтәләнеп бер Хәйбулла ягына карый, бер җирдә аунап яткан иптәшләренең мәетләренә текәлә һәм, хәнҗәрен суырып алып, үз күкрәгенә кадамакчы була, ләкин өлгерми — аның кулына Сәлимнең угы килеп кадала һәм коралы төшеп китә.**

Хәйбулла. Хуп, Сәлим! *(Әкрен генә яубашы янына килә.)*

**Берничә җайдак илбасар яубашын уратып ала. Егетләренең берсе аның җилкәсеннән җәясен ала.**

Хәйбулла. Җавабыңны көтәм, илбасар.
Яубашы *(карлыккан тавыш белән ялварып)*. Башымны ора чаптыр, кирмәнбашы! Синең йортыңа мин илбасар булып ки-

лдем! Юлдашларымны кыруыңа үпкәләр урын юк.

Хәйбулла. Башыңны чапсак, ырудашларыңның язмышы хакында ачы хәбәрне илегез агаларына кем җиткерер?

Яубашы *(түбәнлек белән)*. Зинһар, азат ит мине ул авыр вазифадан, кирмәнбашы! Җәйләвемдә ил агаларыннан берәү генә калды! Ләкин ул да корал тотарлык хәлдә түгел инде... Минем башны ора чаба алмаячак! Мине ул монда әҗәлләрен тапкан ирләрнең хатыннары кулына тотып бирәчәк.

Хәйбулла. Ә бүтән яугирләрең кая?

Яубашы. Бүтән яугирләрем?.. Булганнарның бөтенесе дә шушында — синең алдыңда яталар... Тиле кулса, зур куба.

Хәйбулла. Ә корал тотардай яшүсмерләрең кайда?

Яубашы *(пышылдап)*. Алары да — монда... Ә җәйләүдә калганнарның буе тез тиңентен дә юк әле...

Хәйбулла. Ничек алай килеп чыкты соң, яубашы? Буын чылбырыгыз ник кинәт өзелде?

Яубашы. Чөнки... Шаһ Тимер нәселебезнең чылбырын өзмичә дәвам иттерерлек барлык ир-атларыбызны моннан унбиш җәй элек чирүе астына салып таптаткан иде!

Хәйбулла. Хәзер, димәк... Нәсел чылбырыгыз тагын шулай бик озакка өзелеп торачак, яубашы? Җәйләвеңдә калган сабыйларыгыз үсеп, бәлигъ булганчы?

Яубашы. Сүзең хак, кирмәнбашы! Мондый ачы хәбәрне ил агаме алып кайтырга көчем җитми минем... Шәфкать сорыйм: зинһар, шушында башымны чаптыр! Тибешкәндә дә тиңең булсын икән...

Хәйбулла *(кырыс)*. Тамашага чакырып китермәдем мин сине монда, илбасар. Язмышыңны кавемеңнең хатыннары хәл кылсын! Боларны илтешербез: үзең ил агагыз кулына кайтарып тапшырырсың. *(Мәетләргә күрсәтә.)* Ганимәт төяргә алып килгән олавыгыз ындыр артындамы?

**11. Карлуклар җәйләве. Көн.**

**Урманлы далада киң болын. Болын уртасында карлукларның эреле-ваклы чатырлары тезелеп киткән. Арадагы иң яхшы чатыр янына зур олау килеп туктаган. Ак Бүре ыруы илбасарларының мәетләрен китергән. Хатын-кызлар арасында елаш-кычкырыш: һәркем үзенең ирен, улын яисә якын туганын танып, атка салып алып китә. Йөзгә якын кораллы кеше бер читтә күләгәдә утыра: Ак Бүре кавеме яугирләре алар.**

**Бер читтә егермеләп хатын-кыз ике каенны, очларыннан бау белән тартып, сыгып маташа: илбасар яубашының гәүдәсен, ике аягын ике агачка бәйләп, икегә аерырга әзерләнәләр. Яубашы шулардан ерак түгел бер агач кәүсәсен кочаклап, җиргә чүгәләгән: үзенең күзләреннән бертуктаусыз яшь ага. Хатын-кызларның берсе дә аңа игътибар итми: ритуал башкаргандай, талгын гына хәрәкәт итәләр, йөзләре җитди, ирennәре тыгыз кысылган. Тик арада бер хатын гына тавышсыз елый: ул — яубашының хатыны.**

Бер хатын. Шыңшыма! Сиңа тимибез ич — мөртәт ирең үзе җавап тота! Чынлап уйлаганда, икегезне дә бергә аерып ташлыйсы иде — иреңне яуга иң нык котыртучы син, юньсез, булдың!

**12. Ил агасы чатыры. Шул ук вакыт.**

**Ап-ак сакаллы ил агасы аякларын бөкләп келәмгә утырган һәм Хәйбулла абызны чәй белән сыйлый. Ул дулкынлануын «кунагы»на сиздермәскә тырыша, әмма барыбер тавышы калтыранып чыга, кулы белән сирәк-сирәк күз яшьләрен сөртә.**

Аксакал. Сүзләрем сиңа урынсыз тоелыр, Хәйбулла абыз... Йөз суларым түгәм... Вәләкин... Сез дә төркиләр, без дә — төркиләр...

Хәйбулла *(олпатлык белән)*. Кичер, Аксакал, өлкән сүзеңне бүлдерәм: сез дә төрки, без дә төрки — монсы хак. Әмма без сезгә яу чапмадык, сезнекеләр безгә яу чаптылар — бусы да хак!

Аксакал. Туры сүзгә җавап юк. Килешергә мәҗбүрмен, кунак... Кызганыч, минем киңәшне җиргә салып таптадылар. Ат азгыны тайга ияргә. Яубашы үз җәзасын алды... Тик сүзем бу түгел, Хәйбулла абыз. Зур үтенечем бар сиңа...

Хәйбулла. Үтенечеңне әйт, Аксакал.

Аксакал. Яугирләрең таза, бары да гаярьләр... Яугирләреңне бер төн бездә кунарга күндер, зинһар?

Хәйбулла *(аңлап бетми)*. Мин — синең акылың алдында яшүсмер генә әле, Аксакал. Шуңа күрә, кайбер зирәк сүзләреңне төшенеп тә бетмимдер. Ниятеңне ачыграк итеп әйтеп бирмәссеңме?

Аксакал. Нәсел буыныбыз бүген ахмаклык һәм комсызлык аркасында тагын озакка өзелде. Киләчәгебезне күзаллау кыен... Сезнең белән кан аралаштырсак, дошманлыгыбыз тату кардәшлеккә әйләнмәсме? Сиңа йөзләп батырың ияреп килгән... Бер елдан кавемебез, ходай кушып, йөз бишек асар иде!

Хәйбулла *(ниһаять, ул картның ни әйтергә теләвен аңлый)*. Гозерең бик сәер... Шулай да, мин сине аңлыйм... Тик... үти алмабыз, Аксакал! Бер елдан бишектә елап ятачак сабыйлар, үсеп яугир булгач, үз аталары өстенә бүгенге өчен үч кайтарырга яу чапмас, дип кем кистереп әйтә алыр?! Юк, Аксакал, булмастайны сорап, олпат йөзеңне ертма! Бүген ирләрен югалткан хатыннар, улларын җуйган аналар, абыйлары белән энеләрен җирләгән кыз-кыркыннар безнең канны беркайчан да бөтенләе белән мәңге үз итә алмаячаклар! Бүген аларның бәгырьләре таш булып катты. Шуңа күрә, үстереләчәк оланнар аларга ертылаш кына кадерле булачак. Үч коралы итеп үстерәчәкләр алар газиз улларын! Юк, Аксакал, үтенечеңне кабул итә алмабыз! *(Чәй эчеп туйганын белдереп, чинаягын каплый һәм кузгала.)* Сыең өчен рәхмәт, Аксакал, бигайбә!

**Шулвакыт үлем ачысы белән кычкырган тавыш яңгырый. Чатырга салмак адымнар белән аксакалның карчыгы керә һәм ишек чыбылдыгы янында башын иеп туктый.**

Аксакал *(кырыс)*. Мин сине чакыртмадым, хатын.

Карчык *(башын күтәрмичә)*. Мин синең белән алтмыш җәй җәйләдем, хәлал ирем! Шул алтмыш елда бер генә тапкыр да үз белдегем илә сиңа сүз катканым булмады. Бүген беренче мәртәбә үз ихтыярым белән монда керүем. Ләкин сүзем сиңа түгел, ачуланма! *(Хәйбулла абызга карап баш ия.)* Хәлал иремнән узып, сиңа дәшүемне әдәпсезлек дисәң, Хәйбулла абыз, кичер. Мин — кавемебезнең хатыннарының уртак авызы. Сиңа аларның сүзе бар.

Хәйбулла *(тора: ул шактый гаҗәпләнгән)*. Тыңлыйм сине, ил анасы!

**Аксакал да гаҗәпләнүеннән ни әйтергә дә белми.**

Карчык. Алар сиңа гозерләрен тапшырырга куштылар.

Аксакал *(ирексездән)*. Без монда үзара аңлаштык инде, хатын. Калдыр безне!

Карчык *(тыныч)*. Сабыр ит, аксакал. Хатыннарның уртак гозере шул, Хәйбулла абыз: алар сездән безнең кавемне үз җирегезгә сыйдыруны үтенә.

Аксакал. Ниләр таптыгыз?! Олы аналык чоры күптән үткән! Ирең барын онытма, шәйтан карчыгы!

Карчык *(картның сүзенә колак салмый)*. Хатыннарга нинди җавап бирим, Хәйбулла абыз?

**Тынлык. Сөмсере коелган Аксакалның күзләрендә яшь.**

Хәйбулла *(авыр сулап, картка таба борыла, ләкин аның елап утыруын күреп, тизрәк күрмәмешкә салыша)*. Ыру киңәше ни әйтер бит, ил анасы... *(Карчыкның күзләрендә дә яшь күреп, башын ия.)* Күндерү җиңел булмас... Әмма... сезгә әлегә шуны гына әйтә алам: мин үзем моңа каршы түгел! Сүзләребез берегер шәт. Бер атнадан җавап алырсыз! Йортыгызга иминлек телим. *(Карт белән карчыкка баш иеп, чатырдан чыгып китә.)*

**Хуҗалар бер сүз дә дәшмиләр: чөнки алар сөйләшерлек хәлдә түгел. Кунак чыгып киткәч, карчык иренең алдына барып тезләнә һәм, башымны чап дигәндәй, иелә. Карт сөякчел кулы белән карчыгының башын сыйпый.**

**13. Урман юлы чаты. Кичке як.**

**Карлуклар җәйләве арттта калган. Юл урман авызында икегә аерыла. Җайдакларның күбесе урман эчләп үгә торган юлга кереп киткән иде, соңгылардан булып, тирән уйга чумган Хәйбулла абыз, Сәлим белән Бәдри ияләр пышылдашып киләләр.**

Сәлим *(атын юл чатында туктата)*. Сүзебез бар сиңа, Хәйбулла абыз.

**Егет белән Хәйбулла абыз да туктыйлар.**

Хәйбулла *(уйларыннан бүлдергәнгә бераз ачуы килгәндәй)*. Сузма, төн каплап килә, ә юл шактый. Якты күздә кайтып җитик.

Сәлим *(егеткә ымлый)*. Сүзебез кыска безнең. Бәдри дустым белән икебезгә, сул юлдан китәргә рөхсәт итеп, изге сәфәргә фатиханы бирче, Хәйбулла абыз.

Хәйбулла *(икесенә дә таләпчән карый)*. Сәфәр?.. Нинди сәфәр?

Сәлим. Изге сәфәр. Син — этием урынына калып, мине үз улың кебек кадерләп үстергән абызым... Синең һәр сүз — миңа гел атам сүзе булды. Әмма — бишек ташларга вакыт. Без бер хыянәтчедән үч алырга карар кылдык!

Хәйбулла. Кемнән? Нишләп мин андый кешене белмим?

Сәлим. Беләсең син аны, Хәйбулла абыз. Күргәнең дә бар. Аны бездә һәркем әйбәт белә... үз иленә дошман явы чакырып китергән тамгалы агач ул!

Хәйбулла *(исе китеп)*. Идегәйме?!

Сәлим. Әйе! Китергән казаларыннан соң, җирдә яшәргә хакы юк ул иблиснең!

Хәйбулла. Акылыгызны сыер яладымы әллә?! Томшыкларыгызның сарысы чыгып бетмәгән — түрәләр эшенә тыгыласыз!

Сәлим *(ул аннан шундыйрак җавап көткән)*. Фатиханы бирмисең, димәк, Хәйбулла абыз?

Хәйбулла *(атын урман юлына төшерә)*. Миннән калмагыз!

Сәлим. Хуш, Хәйбулла абыз! Исәнимин күрешә алмасак — бәхил бул! *(Атын сул юлдан чаптырып китә.)*

**Дусты Бәдри дә аңа ияра.**

Хәйбулла *(атын алар ягына бора)*. Кире борылыгыз, юньсезләр! Юкса, хәзер үк артыгыздан егетләрне бастыра җибәрәм, бүре балалары!

Сәлим *(чапкан уңайга аңа таба борылып кычкыра)*: Маташма, Хәйбулла абыз! Барыбер таба алмыйсыз безне!

**Хәйбулла, нинди карарга килергә белмичә, сөлек кебек сузылып, томырылып чапкан атларга карап тора.**

**14. Күк Урданың пайтәхете Сарайчык. Иртән.**

**Хансарай. Алтын Таштан бик нык кайтышрак, әмма шулай да бай һәм зиннәтле эшләнгән. Тәхет залында Идегәй белән Норадын. Алар аяк өсте килеш сөйләшәләр.**

Норадын *(елмая)*. Күк Урда тәхетен күрсәтергә алып кергән булсаң — юкка мәшәкатьләнәсең, әти. Аның буш торганын күптән беләм. Ул — сине көтә, әткәм Идегәй баһадир! Утырып карале — таманмы икән?

Идегәй *(җитди)*. Әйләнгән саен кабатлама, Норадын улым! Минеке түгел ул.

Норадын *(чынлап гаҗәпләнеп)*. Ничек инде?! Орышка син килеп җитмәгән булсаң, Аксак Тимер Туктамыштан тау кәҗәсе урынына куркып качасы иде! Ә Күк Урда һаман Туктамыш хан кулында каласы иде. Ә хәзер бу тәхет — тулысынча безнең кулда! Күк Урда — синең дәүләтең хәзер, әти! Форсатны ычкындырма... *(Сынап.)* Биегрәк тәхет кызыксындырамы әллә? *(Көлә.)* Туктамышның тәхете? Моны Алтын Таш белән чагыштырып булмый, әлбәттә! Ул чагында... *(Туктап кала.)*

Идегәй *(йомшак)*. Нәрсә — ул чагында, Норадын углым?

Норадын. Бу тәхеткә үз улыңны утырт! *(Тәхеткә менеп утыра.)* Фу, тузан... *(Култыксаларына өргәли.)* Йә, нишлисең, әти?

Идегәй *(гади генә)*. Төш, углым. Юкка ымсындырма күңелеңне. Ярап беткән эш булса, ике дә уйлап тормас идем.

Норадын *(ухҗәтләнә башлап)*. Таныммыйм мин сине, әти! Үзең дә утырырга теләмисең, мине дә утыртмыйсың... *(Тәхеттән теләр-теләмәс төшә.)*

Идегәй. Ике колагыңны дүрт итеп тыңла, углым. Безнең юлда буш тәхетләр күп булыр әле. Әмма аларга утырырга атаңның да, синең дә хакыбыз юк.

Норадын. Әй, әти! Тәхет — меңгәннеке! Аксак Тимер тәхеттә утыра ич!

Идегәй. Бүлдермә, углым. Шаһ Тимер тәхеттә утырмый, хакимлек итә. Сәмаркандта бер ел яшәдең, ә шуны да аңламагансың. Бу — сине бизәми. Солтан Мәхмүт хан утыра Сәмарканд тәхетендә.

Норадын. Аның ханлыгы! Аксак Тимернең күз буявы гына ич ул!

Идегәй. Менә бу сүзең хак, углым. *(Елмая.)* Бөтенләй үк өметсез түгел икәнсең. Ярты юлда атыңнан төшәргә ашыкма. Аллаһы боерса, Солтан Мәхмүт кебекләрне үк тәхетләргә утырта башларсың әле, углым!

Норадын *(бала-чага кебек үпкәләп)*. Һай, үзем утырырга ярамагач, аларны утыртудан миңа ни файда?! Һаман башыма барып җитми, әти: нишләп синең белән мина тәхеткә менәргә ярамый? Нидән куркасың?! Хәлал көчең белән яулап алган урын ич бу!

Идегәй. Күп нәрсәләрне белмисең әле син, Норадын углым. Бездә ерак бабаларыбыздан килгән катгый канун бар: тәхеткә бары тик Чыңгыз нәселеннән чыккан кеше генә утырырга тиеш.

Норадын. Чыңгыз үзе, хан нәселеннән булмаса да, утырган бит!

Идегәй. Дөрес, утырган. Тик ул үзе төзегән дәүләт тәхетенә менеп утырган. Ә без синең белән — аның нәселләре корган илдә яшибез.

Норадын. Яшәсәк ни? Сарайчык тәхетенә утырсаң, сиңа каршы кем сүз әйтә ала? Авыз ачып карасыннар!

Идегәй. Нишләрсең?

Норадын. Бугазларын чәйнәп өзәчәкмен!

Идегәй *(елмая)*. Һәм — икенче көнне үк, бөтен әмирләр берләшеп, үзеңне ботарлап, эткә ташлаячаклар. Чөнки... Идегәй әмиргә яраган, безгә дә ник ярамасын, диячәкләр алар. Юк, углым. Безгә акыллырак эш итәргә кирәк. Аксак Тимердән өйрәнергә. Аның кебек үк ерле-ваклы бөтен ханнарны уч төбебездә биетергә! Ә кем безнең кубызга биергә теләми — тәхетеннән тибеп төшерергә! Шуңа күрә, гомерең булса, буш тәхетләрне бик күп күрерсең әле, дип әйтәм мин сиңа.

Норадын. Ә аннан без ни отабыз?

Идегәй. Файдасы шул: дәүләтебезгә тулысынча без хуҗа булачакбыз. Баштарак мин, аннан соң — син, Норадын углым. Әтиең мәктәбен үтик башта. Мин шуны телим! Бу тәхеткә мин Тимер Мәлик углы Тимер Котлыйны утыртам. Ә хәзер — бар, углым, ялгызымны калдыр: монда Тимер Котлый үзе керергә тиеш.

**Норадын башын иеп чыгып китә. Идегәй тәхетне, йомшаклыгын тикшерергә теләгәндәй, кулы белән сыйпап карый. Тузанланган кулларын сыпыра. Тәхет залына Тимер Котлый хан керә: ул бераз олыгая төшкән. Төсенә гаярьлек чалымнары калыккан.**

Тимер Котлый *(шат)*. Исәнлек-аманлыкмы, Идегәй агам? *(Килеп күрешә: алар, йола кушканча, уң аякларын бөкләп күтәреп, уң кулларын кысышалар һәм янбаш янбашка җиңелчә кагылалар — яшергән кораллар шатырамыймы, янәсе.)*

Идегәй *(ачык йөз белән)*. Аллага шөкер, Тимер Котлый хан. Тарханлыгыңа сәфәр ничек, уңдымы? Күпме яугир җыйдың?

Тимер Котлый. Көткән кадәр үк булмаса да, мин канәгать, агам. Зур олыс бит: әйләнәсен ат чабып узгысыз.

**Урындыкларга утыралар.**

Идегәй. Энебез Күнче солтаннан хәбәр бармы?

Тимер Котлый. Очраштык без аның белән. Аның хәлләре дә ярыйсы. Шаһ Тимер ярлыгында күрсәтелгәнчә, үз тарханлыгын кулында бик нык тота ул! *(Елмая.)* Ядәчен киереп кенә сөйләшә. Шәп тархан үсеп килә. Бик яшь бит әле син, авыр түгелме, дип ычкындырган идем, яшьне ат базарында гына сорыйлар, дип авызымны томалады!

Идегәй *(ул да елмая)*. Ачыграк әйткәндә?

Тимер Котлый. Шаһ Тимер аңа ел саен ике мең җайдак әзерләп бирергә боерган иде бит. Ул — өч меңне җыйган!

Идегәй. Ә синең үзеңдә күпме?

Тимер Котлый. Миндә дә ике меңнән артык. Тик салым ягы гына бераз хәерти. Син үз салымыңны Сәмаркандка озатырга өлгермәдеңме әле, агам? Бөтенесен бергәләп юллар идек.

Идегәй *(җитди)*. Өлгермәдем. Өлгерергә дә җыенмыйм, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый. Ничек?!

Идегәй. Шаһ Тимер миннән җайдакларны да, салымны да, үз колакларын үзе күрә алмаган кебек, беркайчан күрмәячәк. Үз янчыгын үзе тутырсын!

Тимер Котлый *(шаккатып)*. Син акылыңдамы, Идегәй агам? Күк Урдабызның баш хакиме Куnык хан килергә чыккан! Аңа ни дип җавап бирергә уйлыйсың?! Шаһ Тимергә шундук хәбәр итәчәк бит ул!

Идегәй. Килсен, җавабын табарбыз! Ничек килсә, шулай кире кайтып та китәр. Кайтыр юлын кисмәбез. Илчегә үлем юк.

Тимер Котлый. Якага яка килергә телисең, ахры, Идегәй агам: Куnык хан безгә илче булып килми, Шаһ Тимер аны Татар иленә баш хаким итеп билгеләгән.

Идегәй *(тыныч)*. Ә ни пычагыма кирәк безгә Шаһ Тимернең килмешәге? Үзебездә баш юкмыни, Тимер Котлый хан?

Тимер Котлый. Авызыңнан җил алсын! Шаһ Тимергә каршы баш күтәрү ич бу!

Акылына кил, агам! Ул безне, ике дә уйламыйча, ат койрыгына тактырачак! *(Тынычлана алмыйча, зал буйлап йөри.)* Шаһ Тимер кияве бит әле син, житмәсә!

Идегәй *(елмаеп, аны күзәтеп тора)*. Ялгыш тәхеткә орынма, Тимер Котлый хан. Тузанлы ул.

Тимер Котлый. Газраил белән кетикети уйнарга чамалыйсың син, агам!

Идегәй. Тәхетнең тузанын кагарга вакыт дим, Тимер Котлый хан. *(Тирән мәгънә белән.)* Көя төшмәсен!

**Тимер Котлый аның янына килеп утыра.**

Идегәй агаңның башына тай типмәгән, йөрәгең ярылмасын. Куньяк хан килер. Әмма — бу Хансарайга кермәс! Монда — син яшәргә тиешсең, Тимер Котлый хан! *(Тимер Котлый тагын сикереп тора; ләкин Идегәй кул ишарәсе белән аңа утырырга куша.)* Дөрес әйтәсең: индеге көндә Шаһ Тимер белән дошманлану — арба күчәренә, дегет сылыйсы урынга, ком сипкән кебек булыр иде... Ә без — араны бозмыйбыз. Күк Урдага сине хан итеп күтәрәбез дә... Шаһ Тимергә илче җибәрәбез. Туктамыш ханның башын алдына салырга...

Тимер Котлый *(гаҗәпләнеп бүлдерә)*. Туктамышның башын?! Алай дип әйткәнем булмады бит?!

Идегәй. Бусы хак, Тимер Котлый хан! Тик... син әтиеңнең башын кем ора чапканын оныткансың, ахры? *(Тәхеткә ымлый, тирән мәгънә белән.)* Аннан соң... Туктамышның тәхете моңардан биегрәк. Ул да шушы тәхеттән башлады бит...

**15. Күнче солтан чатыры. Кич.**

**Офыкка кадәр бер генә агач заты да күренмәгән тигез далада берничә чатыр корылган, аларның нәкъ уртасында — зиннәтле зур чатыр. Чатыр өстендә яшел әләм җилферди. Чыбылдык ишек катында кораллы сакчылар. Бу — Урал буе олысы тарханы Күнче солтанның җәйләве. Чатыр эченә керәбез: Күнче солтан кәеф-сафа корып ята. Ике кәнизәге аңа күңел ачарга ярдәм итә: берсе кош каурые белән аның шәрә табан астын кытыклый, икенчесе аның башын тезе өстенә куйган да, йөзем җимешләре каптыра. Шунда ук келәмдә думбра ята: Күнче, иренеп кенә, бер кулы белән аның кылларын чирткәли.**

Күнче *(йөзем каптырганда шаярып кәнизәкнең бармагын тешли)*. Ап!

Кәнизәк *(кычкырып куя)*. Алла! *(Чынлап үпкәләп, Күнченең борынына чиртә.)*

Күнче *(сикереп тора һәм аңа бар көченә сугып җибәрә)*. Нәрсә, эт токымы?! *(Чатыр баганасына элеп куйган кылычына үрелә.)*

**Кәнизәкләр чырылдый-чырылдый тышка ташланалар.**

*(Сакчыларга.)* Берсен дә чыгармаска!

**Сакчылар куркып калган кәнизәкләрне тукталалар. Шулвакыт чатыр янына чабып килгән ат тоягы тавышы ишетелә. Сакчылар сорау белән тарханга карыйлар. Күнче солтан да, кәнизәкләрне онытып, җайдакның кергәнен көтә. Шуннан файдаланып, кәнизәкләр тиз генә тышка шылалар. Җайдак, атыннан сикереп төшеп, чатырга керә һәм, кулын күкрәгенә куеп, Күнчегә баш ия.**

Күнче *(сакчыларына)*. Беркемне дә кертмәскә! *(Җайдакка.)* Йә! Ни эшләр кыйраттың?

Җайдак *(ишек чыбылдыгын утугә келәмгә тезләнә)*. Боерыгың тиешенчә үтәлмәде, бөек тархан.

Күнче *(сакчылары ишетмәсен өчен аңа түргәрәк үтәргә ымлый)*. Сөйлә!

Җайдак *(тезләрендә шуышып, алгарак үтә)*. Сарайчыкта Идегәйне күрдем, ләкин аның янына якын килергә чара тапмадым.

Күнче *(ачулы)*. Мин сине нигә җибәрдем анда, эт танау?! *(Кулындагы кылычы белән уйный.)*

Җайдак. Башымны чабарга өлгерерсең, бөек тархан, сөйләп бетерергә рөхсәт ит. Һич акланууым түгел, Идегәй янына, чынлап та, якын килерлек түгел иде. Аның каравы, күңелгә бер шәп уй килде. Килешмәсәң, менә башым, менә муеным! Кылычың кулыңда!

Күнче. Кыскарак! *(Эчтән уртын чәйни.)*

Җайдак. Җаен табып белештем: Идегәй янына кылыч сузымы кадәр якын килергә була: әмер бирсәң, берничә көннән аның башы синең алда ятыр, бөек тархан! Әмма мин ашыкмаска кирәк, дип уйладым.

Күнче. Аңлат!

Җайдак. Кичә бертуган абыеңны Күк Урда ханы итеп күтәрделәр!

Күнче *(сикереп тора)*. Тимер Котлый — Күк Урда ханы?!

Җайдак. Әйе!

Күнче. Ә Шаһ Тимер?!

Җайдак. Ул берни дә белмидер минемчә. Иң кызыгы шунда: Идегәй Тимер Котлый ханны Сәмәркандка сәлам да түләмәскә, җайдакларын да җибәрмәскә күндергән, имеш. Сине дә шуңа котыртырга телиләр. Бүген-иртәгә илче җибәрәчәкләр. Тагын бер яңалык бар. Сарайчык гөж килә: Идегәй Туктамышка каршы гаскәр туплый башлый икән! Әмереңне син кушканча үтәмәвемнең сәбәбе шушы. Инде хәзер... башымны чапсаң да була, бөек тархан.

Күнче *(җайдагын аякосте торгызa һәм үзенең затлы җиләнен аның җилкәсенә сала)*. Хуплыйм! *(Чатыр буйлап кызу-кызу йөри.)*

Җайдак *(сизелер-сизелмәс астыртын елмаеп)*. Идегәйнең башын кыярга кайчан...

Күнче *(аның каршына килеп шып туктый)*. Әйбәтләп тыңла!.. Бүген яхшылап ял ит. Иртәгә... Юк! Бүген үк төн уртасында Сәмәркандка китәсең! Үзең белән ике шәп егет ал. Шаһ Тимергә миннән хат илтеп тапшырасың. Идегәйнең постырмасына әлләкәргә, иптәшләреңне ташла, әмма үзең барып җит! Форсатны ычкындырырга ярамый: Идегәйнең күрәләтә Шаһ Тимергә хыянәте бу! *(Кулын кулга суга.)* Шәп булды, шайтан алгыры!..

**Ишектә сакчыларның берсе күренә.**

Нәрсә кирәк?!

Сакчы. Чакырган кебек...

Күнче. Урыныңда бул! *(Әрле-бирле йөри.)* Тимер Котлый гомергә үз башы белән эш итә белмәде!.. Ахмак!.. Идегәйнең тагын бер оста хәйләсе генә бу!.. Болганчык күлдән кеше кулы белән чуртан балыгы тота!.. Ярый! Ашыккан утка төшкән! *(Җайдагы каршына туктый.)* Әгәр дә, мин кушканны җиренә җиткереп, яхшы хәбәр белән кайтсаң, йөзбашы дип сана үзеңне! Мин әйттем.

Җайдак *(түбәнчелек белән баш ия)*. Боерыгың төгәл үтәлер, бөек солтан! *(Арты белән чигенеп, чыгып китә.)*

**Тышта ниндидер тавышлар ишетелә, ат тояклары тупылдау ишетелә.**

Күнче. Нинди тавыш бар анда?!

Сакчы *(чыбылдыкны ачып)*. Нөгәрләр ике шымчының юлын кисканнәр, бөек тархан.

Күнче. Монда кертергә!

**Сакчы чыга һәм бер-ике минуттан куллары артка каерып бәйләнгән Сәлим белән Бәдрине кертә. Аларны җиргә тезләндерә. Сәлимнең битендә кипкән кан эзләре. Бәдри дә шактый кыйналганга охшый.**

Сакчы. Бик тә тәвәккәл егетләр диләр, бөек тархан: эһелдекләрен чыгарып, кулларын бәйләргә туры килгән. Ак Бүре ыруыннан, имеш. Идегәйне сорашканнар. Туктамышның шымчылары, ахры, болар.

Күнче *(тоткыннарга игътибар белән карап тора)*. Кулларын чиш... *(Сакчысына чыгып китәргә ишарә ясый.)* Йә, эчегезне бушатыгыз. *(Сәлимгә.)* Син башла! Нәрсәгә кирәк булды сезгә минем Идегәй агам?

**Сәлим белән Бәдри бер-берсенә карашалар.**

**16. Алтын Таш хансарае. Иртән.**

**Тәхет залы. Туктамыш хан тәхетендә утыра. Аның сулъягында — хатыны Йәникә. Баш вәзир Киң Җанбай да шунда ук якында урнашкан. Ханның уңъягында — төмәнбашлары, эчке казаклар командирлары һәм күренекле түрәләр. Тәхет залы элеккегә караганда баерак бизәлгән: илнең рәте китә барган саен, хакимнәр күзгә ныграк төтен җибәрергә тырышалар бит. Сюрпризлар моның белән генә бетми. Иң гаҗәпләндергәне — тәхет каршындагы идән. Күз алдына китерик. Залның ике ягында да тәбәнәк өстәлләр тезелеп киткән — анда ханның якыннары, сәедләре, вәзирләре, карачылары һәм күренекле түрәләр тезелешеп утыра. Ә уртада, тәхет белән ишек арасында — махсус көзгедән эшләнгән... күл: аның тирәли камышлар үсеп утыра, суда балыклар йөзеп йөри! Әмма бу — гап-гади имитация. Ул шулкадәр оста эшләнгән ки, залга беренче мәртәбә килеп кергән кеше аны чын күлдән берничек тә аера алмый. Сарай этикеты буенча, һәркем хан алдында, тәхеткә җитәргә өч адым ара калдырып, йөгенергә тиеш, димәк, ясалма күлне чыга алган кеше йә аяк савытларын салып, йә тәвәккәлләп, туптуры итекле килеш үтәргә мәҗбүр. Хатынкызларны да шул ук сынау көтә. Соңгы сугышта каһарманлык күрсәтә алмаган Туктамыш бүтәнчә дан казанырга карар кылганга охшый.**

Туктамыш *(Җанбайга)*. Сүзмә, баш вәзир.

Җанбай *(торып йөгенә)*. Бөек ханиям! Элекке колың Идегәйнең мөкерле хыянәте аркасында, Сәмәрканд патшасы Аксак Тимер вакытлыча уңышка иреште... *(Туктамышның теше сызлагандай йөзен чытуын күреп, сүзен ашыгып дәвам итә.)* Әмма Идегәйнең җинаяте бу гына түгел: Күк Урда тәхетенә ул кан дошманыбыз Тимер Мәликнең углы Тимер Котлыйны хан итеп күтәргән!

**Тәхет залында гөжләү башлана.**

Кемдер. Эт котырса — төнгә табан!

**Туктамыш аларны каш астыннан сөзеп чыга; тыналар.**

Җанбай. Тик үз башына кылана ул: Сәмәрканд әмире Шаһ Тимер аның башбаштаклыгын белми. Шаһ Тимер, Күк Урданы үзенә санап, Идегәйгә, Тимер Котлыйга һәм аның энесе Күнчегә, тарханлык ярлыгы өләшкән. Ярлыкларында хан күтәрү хакында ләм-мим! Димәк, Идегәй үз белдеге белән итәк астыннан ут йөртә. Син дә бөек ханиям Идегәйгә андый вәкаләт бирмәдең.

Туктамыш. Тимер Котлый Идегәйнең итәкләренә кереп баткан, күрәсең; колагыннан тартып чыгарып, артын каезларга туры килер! Тәкъдимең? *(Көлешәләр.)*

Җанбай. Шаһ Тимернең индегә көндә куллары бәйле. Ул гөрҗәләр белән әрмәннәрне бастырып йөри, әмма гайрәтле төрек солтаны Елдырым Баязиттан шикләнә булса кирәк, әлләни эш майтара алмый әлегә. Шушы форсаттан файдаланып, без, Елдырым Баязит белән үзара килешү төзик. Моның белән Урдабызның Каф тавы чикләрен ныгыта алабыз. Икенчедән, бу безгә Идегәйнең, көче буынга сикереп ныгыганчы, ояларын туздырырга юл ача. *(Сүзен бетереп, йөгенә.)*

Туктамыш. Идегәйнең гаскәре канча?

Җанбай. Дүрт төмән. Өстәп әйтим: Күк Урданың берничә олыс бие аны өнәп бетерми.

Туктамыш *(кырыс)*. Күк Урдага хан итеп күтәргән малайның хәтта атасын мина тотып биргән иде ул. Уртак тел тапканнар! Кемдә нинди киңәш бар?

Исабәк. Рөхсәт ит, бөек хан?

Туктамыш. Тыңлыйбыз сине, Җантимер углы Исабәк би.

Исабәк *(торып йөгенә)*. Бөек Ханиям! Сүзем кыска булыр: мин — синең яугирең генә. Үзең яхшы беләсең, сөт туганым Идегәй энемдә кайтарылмаган үчем бар: аңа ияреп китеп, дүрт энекәшем башын салды. Без аның белән соңгы орышта очраштык, әмма, кызганыч, алышырга туры килмәде. Тәнемдә җаным бар чакта мин һәрвакыт аның белән йөзгә йөз очрашуны эзлә-

ячәкмен! Бөек ханиям, үтенәм: Сарайчыкка яубашы итеп җибәр минс. *(Утыра.)*

**Залда тагын үзара чыш-пыш башлана.**

Туктамыш. Битекче! Ярлык әзерлә. Исабәк би... биш төмәнгә яубашы итеп билгеләнә.

**Битекче тамгалыгы өстенә иелә.**

Җанбай *(тагын торып баса)*. Бөек ханиям! Мәскәүдән килгән Василий кенәз кабул итүенне үтенә.

Туктамыш. Кем ул? Без аны беләбезме?

Җанбай. Беләсеңдер, бөек ханиям. Ул — Мамайны тар-мар иткән Мәскәү кенәзе Дмитрийның бездә үскән углы, моннан берничә җәй элек ул, унҗиде яшьлек чагында, Сарайдан качып киткән иде.

**Залдан берәү: «Үз аягы белән кабат безнең капканга керергә булган икән шыр тиле!» Көлешү.**

Җанбай *(кычкырыбрак)*. Аңа Молдоу илчеләре качарга ярдәм иткәннәр, имеш.

**Шул ук тавыш: «Менә хәзер аның үзеннән сорыйбыз!»**

**Туктамышның йөзе кырыслана.**

Шуннан ул Литваның бөек кенәзе Витовт кулына барып эләккән һәм биш ел чамасы аңа хезмәт итәргә мәҗбүр булган. Василий яшь, тәвәккәл, ә бөек кенәзнең бирнә кызы бар. Витовка Мәскәү белән араны ныгытырга бик әйбәт форсат табылган: Василийны, үзенең кызы Софьяга өйләндереп, Мәскәүгә кайтарып җибәргән. Дмитрий Донской күптән түгел вафат. Мәскәү тәхеткә аның улын күтәрүне сорый. Идегәй Тимер Котлый исеменнән Василийга, Мәскәү тәхетенә утырырга ярлык бирергә вәгъдә итеп, хат юллаган инде, имеш...

**Шау-шу башлана: «Ояты юк икән!» «Бездән узып, ярлык бирми генә торсын әле!» Монда без бар! Бик шәбәеп китә башлаган!»**

Җанбай. Сүзем бетмәде.

**Тынычланалар.**

Белүебезчә, Василий кенәз Нижгарны да үзенә сорый. Димәк Городец, Мешера, Торус, Муром калаларын да Мәскәүгә тапшырырга туры килә. Тик бер киртә бар: Муром белән Торус беркайчан да Мономах варислары кулында булмаган, Чернигов кенәзләре биләмәләре алар. Хәтеренә төшерим, бөек ханиям, син Ярослау кенәз углы Бориска Нижгарны бирдең инде.

**Тынлык урнаша.**

Туктамыш. Киңәшең?

Җанбай *(елмая)*. Василий кенәз сиңа, Мәскәү тәхетенә утыргач, әтисе кебек ук, биш мең алтын ясак түләп торырга риза, ә Бористан кәҗә тиресе дә алып булмый, чөнки ул үзе хәерче. Икенчедән, капкабыз төбендә Шаһ Тимернең котырган эте Идегәй йөргәндә, Мәскәүдән йөз чөерү хаталык булыр иде. Өченчедән, Сәмәрканд белән бәхәсебез бетмәде ич әле? Кирәк чакта Василий безгә гаскәре белән хезмәт итәр. Ярлык шарты шушы булса, шәт иншалла... Ә Нижгарга килгәндә... Ярлыкны Василий кенәзгә дә бирик: кайсы өлгеррәк — кала шуныкы булыр!

**Көлеш.**

Туктамыш *(уйланып)*. Василийны зур кадер-хөрмәт белән кабул итәргә! Керсен.

**Залда җанлану башлана: «Сынау көзгесен» ничек үтәр?**

Сарай бие *(ишек ягына карап кычкыра)*. Урыс кенәзе хан хозурына чакырыла!

**Кунакларны кертәләр: иң алдан — булачак бөек кенәз Василий белән аның хатыны Софья атлый. Алар артында бик күп бүләкләр күтәргән урыслар күренә. Василий, тәхет залының искиткеч зиннәтле бизәлүен күреп, туктый.**

Туктамыш *(ачык йөз белән)*. Рәхим ит, каһарман Дмитрий углы Василий кенәз.

**Василий күкрәгенә кул куеп баш ия. Ике яктан ике кеше Василий белән Софьяны «күл» ярына китерә һәм алгарак үтәргә этәрә. Кунаклар аптырашып калалар һәм сиздерми генә тирә-якка каранalар. Залда утыручыларның йөзе бик җитди. Берни сизелми. Василий, тәвәккәлләп, «су эче»нә атлый һәм... каты идәнгә басканлыгын тоеп, тагын да ныграк гаҗәпкә кала. Әмма, сер бирмәскә тырышып, алга атлый. Ә Софья, тиз генә аяк киемнәрен салып ташлый һәм горур кыяфәт белән ирен»нә иярә: ул да нинди әкәмәт бу, дигәндәй, ирексездән идәнгә күз ташлый. Шундук үзен кулга алып, алга атлый. Залдагылар көзгедә аның ап-ачык чагылган ботларыннан күзләрен алмыйлар. Тәхеткә җитәргә өч адым калгач, Василий белән Софья, сул тезләренә төшеп, йөгенәләр... Шулчак ишек артында ниндидер шау-шу куба. Сарай бие шундук ишеккә ташлана.**

Туктамыш *(ягымлы тавыш белән)*. Гозерецне әйт, Василий кенәз.

**Сарай бие тәхет залына ашыгып килеп керә һәм хан колагына ниндер пышылдый.**

Туктамыш *(йөзе үзгәрә)*. Нәрсә, нәрсә?!

**Сарай бие урысларга ымлый: алар тынлап тора, янәсе.**

Туктамыш *(тыныч)*. Дусларыбыздан серебез юк безнең. Әйт!

Сарай бие. Бөек ханиям! Калабызны Идегәй белән Тимер Котлый камап алган!

**Барысы да сикерешеп торалар.**

Туктамыш *(ул тәхетеннән тормаган: үзен елмаерга мәҗбүр итеп)*. Василий кенәз! Сөйләшүебезне бер-ике көнгә кичектерәбез. Кичер. *(Тәхет артындагы ишеккә юнәлә.)*

**Бүтәннәр дә тарала: тәхет залында сарай бие белән урыслар гына кала.**

**17. Алтын Таш хан сарае. Көн.**

**Хансарайның бер кечкенә пулаты. Салкын көз житкән, шуңа күрә Туктамыш хан, баш вәзир Җанбай һәм Исабәк би өсләренә җылы тун кигәннәр. Туктамыш хан утлы күмерле чүлмәк өстендә кулларын җылыта. Аның йөзе бик кырыс. Исабәк бинең башы канлы, ак чүпрәк белән бәйләнгән. Читтәрәк битекче утыра.**

Туктамыш. Йә, инде ни дип акланырсыз, арка таянычлары?! *(Исабәккә.)* Идегәйнең шөпшә оясын биш төмән яугир белән туздырып кайтмакчы идең! Кулыңда егерме төмән гаскәр! Дүрт төмәнгә тулмаган дала карсакларын куып җибәрә алмыйсың! Өч ай капкадан чыкканыбыз юк! *(Җанбайга.)* Канча көнлек ашарыбызга бар?

Җанбай. Кала бие атна-ун көнлек, ди.

Туктамыш. Атна-ун көнлек! Аннан — авызыбызны чөйгә эләбезме?

Җанбай. Гаскәребез гадәттәгечә атларын суеп ашарга керешәчәк. Корал да бетеп бара.

Туктамыш *(Исабәккә)*. Ишеттеңме?

Исабәк *(авыр сулап)*. Беренче көнне үк гаскәребезнең бер өлешен кырга чыгарыйк, дип тәкъдим иттем мин...

Туктамыш. Ызгыттың инде!

Җанбай. Бөек ханиям! Теге вакытта Исабәк би хаклы булгандыр, бәлки... Әмма хәзер моны искә төшерүдән файда юк. Тизрәк бер чара табарга кирәк.

Туктамыш. Табыгыз соң!

Җанбай. Иң куркынычы — көчсезлегебезне күреп, моңа кадәр үзебезгә тугрылыклы булган әмирләр Идегәй ягына шыерылмагайлары... Мәскәү кенәзе Василий өч ай ярлык көтеп ята. Дөрес, көне-төне бәйрәм иттерәбез. Ләкин аның маңгаенда күзе бар: куәтсезлегебезне күреп, бездән йөз чөерә башламагае! Аксак Тимер явыннан соң, болай да...

Туктамыш *(кискен бүлдерә)*. Читкә китмичә генә!

Җанбай. Идегәй солых төзергә риза, бөек хан.

Туктамыш. Авызыңны да ачма! *(Уйланып йөри.)* Ярты дәүләтебезне җую бу! Мин исән чакта, бүлештем юк!

Җанбай. Бүген югалтсак, иртәгә Ходай язса — кире кайтарып та алырбыз, бөек ханиям. Бу бәладән котылыйк. Ерак олыслар белән хәбәрләшә дә алмыйбыз. Ә анда егерме төмәнләп җайдак эшсезлектән трай тибеп ята. Чөнки безнең аяныч хәлне белми!

Исабәк. Беләләр. Кем кемне алдыра — шуны көтәләр.

Туктамыш. Телгә килде! Синең тел — кулыңдагы кылыч! Ә синең сөяксез телең кылычыңнан елгыррак!

Йәника *(яшенә буылып керә)*. Балаларыбыз харап, хан!..

Туктамыш. Саташасыңмы әллә?.. Алар Кырымда иде!

Йәника. Синеңчә — Кырымда, ә мин — явыз Идегәй кулында тотсак икәнлекләрен белдем!

Туктамыш *(каушап)*. Кем әйтә аны?!

Җанбай. Юрамал хәбәр генәдер ул, ханбикә...

Йәника. Мә — укы, Кин Җанбай! *(Йомарланган кәгазен аның йөзенә бәрә.)* Кадыйрбирденең кулын таныйсыңмы?!

Җанбай *(кәгазьне куллары белән тигезләп)*. Чынлап та, ханзадә кулына охшаган...

Йәника. Охшаган! *(Җанбайдан кәгазен тартып ала.)* Идегәй качкан диген, кемнеңдер имеш хәбәренә ышанып, кайтып төшкәннәр. Озата килгән сакчылары дүрт йөзләп кенә, ди. Шакал тозагына эләккәннәрен сизми дә калганнар! *(Елый.)* Бөтен шартларына күн, әмма газизкәйләребезне харап иттермә, атасы!

**Туктамыш, йодрыкларын төйнәп теш шыкырдата.**

Йәника *(яшь аралаш)*. Нәрсә көтәсең инде?! Җаның бармы синең?

Туктамыш. Калдыр безне, ханбикә! Үз тирмәңә чык.

Йәника. Шулаймы?!. Урданың бер чите балаларыңнан да кадерлерәк икән сиңа! Идегәйгә үзем барам, алайса! *(Ишеккә юнәлә.)*

Туктамыш *(Җанбайга)*. Шыгавылга әйтеп куй: ханбикәне каладан чыгармаска.

**Хан әрле-бирле йөри. Җанбай, ханбикә артыннан чыгып, шыгавылга хан боерыгын әйтеп керә.**

Туктамыш. Битекче! Ярлык әзерлә: без Тимер Котлый ханның Сарайчык тәхетендә утыруын таныйга булдык. Ярлыкны үзең тапшырасың! Балаларыбызны бүген үк безгә тапшыра. Һәм гаскәре белән Күк Урдага кайтып китә! Ходай шаһит: ыңгырашып кына риза без моңа!

Җанбай. Күнмәсәләр? Үзләре безгә солых тәкъдим иткәндә ханзадәләр алар кулында түгел иде бит, бөек хан.

Туктамыш *(караңгы чырай белән)*. Күнәрләр!.. Күнмәсәләр... Айтулының башы дивар өстендәге казыкта тырпаеп торыр! Мин әйттем! *(Ашыгып чыгып китә.)*

**18. Идегәй урдасы. Кич.**

**Сарай каласының биек диварларын Идегәйнең гаскәрләре уратып алган: кайда да учаклар яна, атлар пошкыра, кылычлар кайраган тавышлар ишетелә. Кырау төшкән, әмма гаскәрнең кәефе күтәренке — Туктамышның балалары әсир төшкән, орыш озакка сузылмаячак, димәк! Учаклар тирәсендәге гәпләр күбрәк шул турыда бара.**

— Аңгыра сарык бәрәннәре кебек килеп каптылар Туктамышның көчекләре!

— Ике кызы бар икән. Күз явын алырлык чибәрләр, чукынчыклар!

— Хан кызлары булсын да, чибәр дә булмасын!

— Их, җегетләр! Шушы кызу учак янындагы бер төнне Туктамыш кызларының кайнар куеныңдагы бер генә мизгелгә алмаштырыр идем мин! Аннан соң — төне буе шәрә килеш салкын җирдә аунарга да риза!

**Көлешү.**

— Акылың алтын икән! Борыныңны тимер белән кыршаула башта: Идегәй баһадирның углы Нурадын баһадир йодрыгына тап булмагаең!

— Ышкы артыннан балта! Җегетнең җырын боздың!

— Ничек?! Нурадын да минем шикелле шушы учактан ләззәтлерәк җылы ярата микәнни?

**Көлешү.**

— Анысы да монсы, җегетләр: орыш бетүгә сөенегез! Хәзер исәпкә төшкән Туктамыш безнекеләрнең бар авыр шартларына берсүзсез күнәчәк!

— Сүзең фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килсен...

**Идегәйнең чатырында, Нурадын углы белән икесеннән башка, берничә гаскәр башлыгы үзара киңәш тота. Тимер Котлый хан да шунда. Җарияләр түрәләргә ашамлыклар ташыйлар.**

Идегәй *(ашый-ашый)*. Туктамыш хан җавапны озаклатты! Ың-шың ишетелми. Ханзадәләре өчен бик эче пошмый, ахрысы.

Арадан берәү. Яшь хатыннары хәттин ашкан: Ходай тәгалә балаларны тагын да бирер әле, дип боларына кул селтәгәндер!

**Көлешәләр.**

Идегәй. Көлкесен көлке... Бу юлы да килешүне кире какса, нишләрбез? Тимер Котлый хан! Соңгы сүз синдә.

Тимер Котлый *(уйланып)*. Камауны алырга туры килер.

Нурадын *(кызып)*. Өч ай кан түккәчме?!

Идегәй *(елмая)*. Углымның сабырсызлыгын кичер, хан... Әмма... Белүемчә, калада, имеш, бер атналык кына азык калган. Халык эт чалып ашый. Гаскәре дә ачыктан-ачык ханны сүгә. Тагын атна-ун көн түзәргә рөхсәт ит!

**Гаскәр башлыклары үзара чыш-пыш килә.**

Тимер Котлый *(ироничне сизми)*. Яхшы, Идегәй баһадир. Тик... соңгысы бу. Үз гаскәребезнең хәлен дә ташка үлчим.

Идегәй *(елмаюын яшерә)*. Килештек, хан!

**Тышта: «Туктамыш ханнан илче!» — дигән сорон яңгырый. Чатырдагылар арасында җанлану башлана: «Ниһаять! Энә өстендә озак бии алмады Туктамышның!» кебек сүзләр ишетелә. Чатырга шыгавыл керә.**

Идегәй. Йә?

Шыгавыл. Туктамыш ханның баш вәзире Җанбай би Тимер Котлый ханнан кабул итүне үтенә!

**Тимер Котлый Идегәйгә карап куя: Идегәй аңа кабул ит, дип кашы белән генә ымлый.**

Тимер Котлый. Кертергә.

**Шыгавыл чыга һәм чатырга Кин Җанбай килеп керә: куеныңда кәгазь төргәге. Чатырга кергәч, тиз генә барысына карап чыга, Идегәйнең күзләре белән очраша һәм бер мизгелгә эт күргән мәче кебек каушап кала. Ниһаять, биек мендәрдә утырган Тимер Котлыйны таныи, җиңелчә иелә.**

Җанбай. Ходай озын гомер бирсен сиңа, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый. Рәхмәт, Туктамыш хан илчесе. Без тыңлыйбыз сине.

Җанбай *(тураеп баса)*. Бөек ханиябез сорый: ханзадәләрнең кулыңа төшүе хак хәбәрме?

Тимер Котлый. Хак.

Җанбай. Бөек Алтын Урда ханы ханзадәләрне кичектермичә Сарайга кайтаруны боера.

Тимер Котлый. Безгә боера?! Ник безнең хозурга үзе килмәде.

Җанбай. Ханиябезнең вакыты тар. Шуңа күрә үзенең баш вәзирен — мине җибәрде.

Тимер Котлый. Ул чагында... ханың вакыты иркенәйгәч килер.

**Чатырдагылар хан сүзен хуплап, пышылдашып алалар. Вазифаң тәмаммы, илче?**

Җанбай *(ул әз генә дә каушамаган)*. Юк, бетмәде. *(Куеныннан ярлык чыгара һәм, маңгаена тидереп алганнан соң, Тимер Котлыйга суза.)* Алтын Урданың бөек ханы Туктамыш солтан сиңа ярлыкнамә юллый, Тимер Котлый хан! *(Баш ия.)*

**Туктамыш ярлыгын Тимер Котлыйга тапшыралар.**

**Тимер Котлый ашыкмый гына ярлыкны сүтә, укып чыга һәм Идегәйгә бирә. Идегәй кәгазьгә күз төшерә һәм шундук аңа, сизелер-сизелмәс ымлап, ризалыгын бирә.**

Тимер Котлый. Инде хәзер безгә житкерәсе сүзләрең беттеме, Туктамыш хан илчесе?

Җанбай. Җавап ишетмәдем, Тимер Котлый хан. Калганы — синең җавабыңнан тора.

Тимер Котлый. Без... Туктамыш ханның үтенечен кабул итәргә булдык, илче.

Җанбай *(аптырап)*. Үтенеч? Ярлыкта «үтенеч» дилмәгән, Тимер Котлый хан! Бөек каганыбыз Күк Урдада синең хан булуыңны таный, ә син...

Тимер Котлый. Укый беләбез без, илче!

Җанбай. Бусы — телдән әйтелергә тиешле шартнамә: ханзадәләр бүген үк кайтарылырга тиешләр.

Норадын. Мочсы булмас, шырантай Җанбай!

Җанбай *(аның сүзләрен искә дә алмый)*. Туктамыш ханның колагы телдән әйтелгән шартнамәгә җавап көтә, хан.

Тимер Котлый. Әгәр үтенече кире кагылса?

Җанбай. Каганның таләбе кире кагылса, сәргаскәреннең хатыны Айтулының башы кала диварының өстендә казыкта эленеп торачак!

**Чатырда куе тынлык урнаша.**

**Тимер Котлый ирексездән Идегәйгә карый: аның бары тик яңак мускуллары төйнәлгән.**

Тимер Котлый. Ханың хатын-кызлардан үч алуны үзенә түбәнлек дип санамый, димәк!.. Яхшы. Без ханзадәләрне гаскәр башлыгыбызның бикәсенә алмашырга риза.

**19. Шунда ук. Кич.**

**Чатырда Идегәй улы белән генә калган. Җарияләр савыт-сабаларны җыештыралар. Идегәй, мендәргә кырын таянып, уйланып ята. Норадын җарияләрнең чыгып китүен сабырсызланып көтә. Ниһаять, түзми, җарияләргә китәргә ишарә ясый.**

Норадын. Бер соравым бар, әти.

Идегәй. Сора, улым.

Норадын. Ник ханзадәләрне беркарусыз Туктамышка кайтарырга булдың?

Идегәй *(гаҗәпләнеп)*. Газиз анаңны ачы үлемнән йолу-кару түгелмени синеңчә?!

Норадын. Әнигә тияргә батырчылык итмәячәк иде ул! Һич югында, бер-икесен калдырып торыйк.

Идегәй *(елмая)*. Кызларынмы?

Норадын *(кызарына)*. Миңа... барыбер! Бер-икесе безнең кулда калса, киләчәктә бүтән төрлерәк сөйләшер идек без аның белән!

Идегәй *(бераз дәшми торганнан соң)*. Шулай итми хәлебез юк. Хәтерлисеңме икән, Норадын улым, кечкенә чагында бүре балалары алып кайткан идем мин сиңа?

Норадын. Томан аша гына.

Идегәй. Ана бүре шул ук төнне бер колны бугазлап ташлады. Чөнки ул кол бүре балаларын, капчыкка салып, күтәреп кайткан иде!

Норадын. Монысын яхшы хәтерлим.

Идегәй. Баласың җуйган ерткычтан да куркыныч нәрсә юк дөньяда, улым! *(Күтәрелә төшә.)* Әгәр дә без ханзадәләрне үзебездә тотсак итсәк, Туктамыш иртәгә үк егерме биш төмән гаскәре белән әнә шул ана бүре кебек безнең өскә ташланачак иде. Һәм — кем белә...

Норадын. Димәк... Туктамышның үченнән шүрләден, Идегәй баһадир?

Идегәй *(йомшак)*. Хәтереңә тирән салып куй, Норадын улым: курыкмау — ахмакларча эш итү диген сүз түгел! Ханзадәләре качмас... Кызларының берәрсенә күзең төшкән икән, сүзем юк — морадыңа бер ирешерсен. Тик акылыңы җуйма! Алтын Урданың ярты җире безнең кулда хәзер. Сабырлык кирәк. Калганы да бездә булыр! Килер бер көн, Туктамышны Сарайдан шыерып кына чыгарырбыз. Көч туплап бетерик башта.

Норадын *(уйланып)*. Болары аңлашылды, әти... Тик миңа бер нәрсә караңгы: кем мин синең гаскәреңдә?

Идегәй. Ничек — кем? Син — минем улым! Чын яугир булып җит, аннан күз күрер, шәт иншалла...

Норадын. Улыңның яугирлек сынавын күптән узганын сизми калгансың бугай син, Идегәй баһадир! *(Чыга.)*

**Идегәй аның артыннан аптырап карап кала.**

**20. Күнче солтан чатыры. Кич.**

**Тимер Котлый ханның энесе Күнче мунча керә: җылы су тутырылган киң авызлы имән тәпәндә ләззәтләнеп утырган солтанны ярым шәрә кәнизәкләр юындыралар. Икесе аның кулларын мунчала белән уа, берсе башын «сабынлый». Сабын урынына кычыткан ефәге һәм селтеле су кулланалар. Күнче солтан әледән-әле, шаярган булып, кәнизәкләрнең тырпаеп торган күкрәкләрен чеметә: тегеләре кинәт-кинәт чыелдап җибәрәләр, ә ул кычкырып көлә генә — аның кәефе чагы. Чатырга аның бер нөгәре керә һәм йөгенә.**

Күнче. Сүзме, эшме?

Нөгәр. Сүз дә, эш тә, солтан.

Күнче *(нөгәрен каплап торган кәнизәкне, имиеннән тотып, читкәрәк күчерә)*. Башла.

Нөгәр *(елмая)*. Тотсакларыбыз шымчылар булып чыкмады, солтаным! Бая тегеләр утырган чокыр янына...

Күнче *(бүлдерә)*. Барып шып-шыпырт тыңлап тордың, аңлашылды... Кыскарак?

Нөгәр. Чокыр янында беркем дә юк, дип уйлап, тегеләр шаптыр-шыптыр килеп серләшергә тотындылар. Ак Бүре ыруыннан качып киткән егетләр булып чыкты.

Күнче. Максатлары?

Нөгәр. Идегәйне үтерү!

Күнче *(сикереп тора: ул шәп-шәрә)*. Чокыр янында тыңлап ятканыңны белеп, юри сөйләшкән булсалар?!

Нөгәр. Юри түгел, бөек солтан! Башымны чаптырырга әзер.

Күнче. Идегәйдә ни үчләре бар, ди?

Нөгәр. Аксак Тимерне яу китертеп, илне бөлдергәне өчен! Бер сүз дә дәшмәгәне — Сәлим атлы, икенчесе — Бәдри. Бәдрие, куркаграк икән, кире кайтып китик, дип ялвара. Сәлиме тегене чактан гына үтереп ташламады! Кай җире кычый тегенең! *(Елмая.)* Җибәрикме әллә үзләрен? Ниятләре шәп ич!

Күнче *(тәпәннән чыга: кәнизәкләр аның өстенә зур сөлге ябалар)*. Алай... *(Ыңгыр-шыңгыр йөри: кәнизәкләр аның юеш тәнен сөрткәлиләр, солтан аларны чебен куган кебек кизәнеп куа.)* Юк, үзләре генә этем дә кыра алмаслар. Шулпасы үз казаннарында кайнаса да, итен монда пешерәчәкбез! Чокыр тирәсенә кораллы-иярле ике ат бәйлә. Егетләрең арасында берәр шыр сыйрак бардыр — бүтәннәргә сиздерми генә качарга булышсын. Соңыннан башын чап. Ике арада гына калырга тиеш! Идегәйнең үтерелүен

минем исем белән бәйләрлек булмасын, аң бул! Юри генә бастырып куа чык. Шикләнерлек итмәс өчен берсен җиңелчә яраласаң да зыян булмас. Тәвәккәл эшкә гаярь җегет кирәк — кыюына тимәскә. Мин әйттем!

Нөгәр. Үтәлер, бөек солтан! *(Йөгенә һәм арты белән чигенеп чыга.)*

**Күнче солтан өстенә япкан сөлгесе-ние белән сулы тәпәнгә керел утыра.**

**21. Сарайчык артында такыр басу. Көн.**

**Тигез болынлыкта яшьләрне сугышка өйрәтү күнекмәләре бара. Бер читтә куллары богаулы тасколлар язмышларының хәл ителүен көтәләр. Шулар арасында Сәлим белән Бәдри дә бар. Менә аларга да чират җитә: икесен дә, богауларын салдырып, яшьләр каршысына бастыралар. Кырыс йөзле Норадын күнекмәләрнең ничек үтәлүен күзәтеп тора.**

Унбашы *(ул күнегүләр үткәрә)*. Яугирләр! Хәзер — атта кызу чапкан шәпкә дошман башын кылыч белән ора чабу күнекмәсе башлана. *(Сәлимнәр янында торган нөгәргә ишарә ясый.)*

**Нөгәр Бәдригә болынга йөгерергә куша: Бәдри Сәлимнән яклау эзләгәндәй карап тора һәм йөгереп китә. Иң читтә торган яшь яугир бераздан болгыйлый-болгыйлый йөгергән Бәдринең артыннан ташлана. Шактый озак эзәрлекләгәннән соң гына Бәдринең башын ора чабып төшерә.**

Норадын *(яшь егетнең булдыксызлыгына кәефе кырылып)*. Тигәнәк башы кыярга гына ярый бу мокытың! Ничек эшләргә күрсәтмәдеңмени, унбашы? Үзеңнең осталыгың да шулкадәр генәме әллә? Икенче таскол — синеке. Күрсәт һөнәреңне!

Унбашы *(мыскыллаудан гарьләнә, әмма сиздерми)*. Баш өсте, Норадын би. *(Кулын күкрәгенә куеп баш ия һәм Сәлим янына килә.)* Йөгер!

**Сәлим, кулларын күкрәгенә кушырып, аңа горур карап тора. Ачуы чыккан унбашы атын аның өстенә ташлый: Сәлим, җитез хәрәкәт белән читкә тайпыла һәм киң җилкәсе белән аның атына төртеп җибәрә — унбашы аты-ние белән егыла яза. Яшьләр көлешеп куялар. Унбашы аларга каш астыннан усал итеп карап ала һәм кылычы белән Сәлимгә селтәнә: ул иелеп кала һәм, кинәт ыргылып, унбашын иярennән сөйрәп төшерә. Үзе, атка сикереп менеп, качып китә алуын күрсәтә һәм кабат җиргә сикерә, кулларын күкрәгенә кушырып баса.**

Норадын *(кычкырып көлә)*. Шәп! Чын яугир икәнсең, унбашы! Йә, йә, дәвам ит! Әллә шуның белән аллаһ әкбәрме бар осталыгың?!

**Унбашы, беркемгә дә карамыйча, атына сикереп менә һәм Сәлимнең өстенә ташлана: Сәлим бу юлы да җиңел генә читкә тайпыла, көтмәгәндә арткы яктан атка сикереп менеп, унбашын җиргә мәтәлдерә һәм аның кылычын кулына алып өлгерә.**

Яшьләр *(хуплап шәрран яралар)*. Кха!

**Сәлим, җирдән күтәрелеп маташкан унбашының муенын чабарга теләгәндәй, кулын күтәрә һәм... кылычны аның аяк астына ташлый. Шәлперәеп төшкән унбашы кылычка үрелә. Әмма Сәлим, иярдә килеш үрелеп, кылычны тиз генә аның борыны астыннан кулына эләктереп өлгерә. Яшьләр тагын Сәлимне хуплап: «Кха!» дип кычкырып җибәрәләр. Сәлим кылычны кабат каушап калган унбашының аяк астына ташлый. Бу юлы унбашы шундук кылычка ташлана, әмма Сәлим ирек бирми: атын кинәт өстенә ыргылдыра һәм җилкәсенә тибә. Унбашы, ике-өч адым артка таба чигенеп, җиргә тәгәри. Яшьләр тагын: «Кха!» дип кычкыралар. Тычкан белән уйнаган мәче кебек кыланган Сәлим кылычны үрелеп ала һәм унбашы алдына ыргыта. Чыгымчы аттай кыланган унбашы, кылычны тиз генә алып, Сәлимгә ташлана: Сәлим, атының икенче ягына янтаеп, аның кулына тибә — яугирнең коралы кулыннан ычкынып, еракка төшеп кадала.**

Норадын. Кха! Унбашы! Вазифаңнан азат! Яшьләр янына бас!

**Унбашы гарьлегеннән кылычына ташлана һәм, башкалар ул-бу сүз әйтеп өлгергәнче, үз-үзен бугазлый. Моңа беркем дә гаҗәпләнми. Ә Норадын ул якка карап та тормый, Сәлимне бармагы белән ишарәләп үзе янына чакыра.**

Норадын. Атың кем? Кайдан син?
Сәлим. Сәлим. Бүре ыруыннан.
Норадын. Ничек килеп каптың монда?
Сәлим. Бу — минем сер.
Норадын *(аны сынап карап тора)*. Гаебең?
Сәлим. Тотсак ителгәндә ике яугирегезне дөмектердем.
Норадын. Миңа хыянәт итмәссеңме?
Сәлим. Сиңа — итмәячәкмен, Норадын батыр.
Норадын. Ә бүтәннәргә?
Сәлим. Монсы да — сер.
Норадын. Ярлыкау кылсам, качып китмәссеңме?
Сәлим. Мин үзем сезне эзләп килдем. Качар булсам, әллә кайчан эзем суынган булыр иде.
Норадын *(уйланып)*. Син миңа ошадың, Сәлим атлы бүре. Яшьләрне осталыкка өйрәтерсең. Күнекмәләрне дәвам иттер.
Сәлим. Сиңа бер соравым бар, Идегәй углы, Норадын батыр.
Норадын. Сора.
Сәлим *(читтә торган тасколларга ымлый)*. Кемнәр болар? Кайсы йорт кешеләре? Кан-кардәшләр булса, аларга кулым күтәрелмәячәк.
Норадын. Тынычлан, якташларың юк алар арасында.
Сәлим. Шулай да?
Норадын. Болгар йортын талап йөргән урыс ушкуйчыклары алар.
Сәлим. Бүтән соравым юк, Норадын батыр. *(Баш ия.)*

Норадын. Кичен минем янга сугыл: сүзем бар сиңа. *(Атын чаптырып китә.)*

Сәлим *(уйланып, аның артыннан карап тора).* Кылыч! *(Яшьләрнең берсе аңа үз кылычын бирә.)* Дүрт таскол! *(Ул үзе һаман Норадынга текәлгән.)* Икешәрләп ике якка йөгерсеннәр!

**Тасколларны, кулларын чишеп, болынга җибәрәләр. Яшьләр ни булыр икән, дип Сәлимгә карап торалар. Тасколлар төрлесе якка йөгерә. Инде шактый ерак китеп өлгерәләр, ә Сәлимнең күзе һаман Норадында.**

Яшьләрдән берәү *(узалдына).* Куаклыкка барып җитсәләр, көндез чыраг яндырып та табып булмый аларны!

Сәлим *(качкыннар ягына борыла һәм тагын бераз көтеп тора).* Ике күзегезне дүрт итеп карап торыгыз! *(Тасколларны бастырып куа китә.)*

**Иң башта ул үзенә якынрак булган тасколның башын уң кулындагы кылычы белән кыеп төшерә һәм сул яктагын бастырып кылычын сул кулына күчереп ора чаба. Барган шәпкә өченчесен кабат уң кулы белән чабып, җиргә тәгәрәтә. Яшьләр һәр чапканы саен: «Кха!» дип куәтләп торалар. Ә ул арада дүртенче таскол куе әрәмәлеккә йөгереп барып житә: яшьләр тынып калалар. Таскол качып котылса, бөтенесе бергә Сәлимгә ташланачаклар! Сәлим, шуны сизгәндәй, тасколны куып җитәргә ун адымнар чамасы ара калгач, кылычын томыра: үткен корал бичараның арык гәүдәсен үтәли тишеп чыга һәм ул ачы кычкырып куаклык арасына ава. Сәлим, атын әкренәйтеп, аның янына килә һәм иелеп кылычын суырып ала, буялган канын кисмәнә сөртә. Сәлимнең осталыгына шаккаткан яшьләр тып-тын гына көтәләр: үзе качып китмәсме, янәсе! Әле генә тотсак иде бит. Һәм бердәм җиңел сулап җибәрәләр; яңа билгеләнгән унбашы кайтыр якка борыла.**

**22. Алтын Таш хансарай. Иртә.**

**Тәхет залы. Чыраена сукыр лампа кабызып куйгандай караңгы йөзле Туктамыш хан яраннарын киңәшкә җыйган: түмәнбәкләр, һәм бүтән кечерәк гаскәр башлыклары арасында Идегәйнең сөт абыйсы Исабәк тә бар. Ханның сул ягында хатыны Йәникә, уллары утыра, ә уң ягында баш вәзире Киң Җанбай урнашкан.**

Туктамыш. Шаһ Тимернең хатын укы, баш вәзир.

Җанбай *(торып укый).* «Бөек Туран патшасы Әмир Бырлас Шаһ Тимер сүзем...

Туктамыш *(бүлдерә).* Төп өлешенә күч.

Җанбай *(ханга җиңелчә йөгенә һәм дәвам итә.)* «...Кодрәтле Хак Тәгаләбез хакына сорыйм синнән, Туктамыш: син, кыпчак җаны, нишләп миңа каршы шайтан котырткыгы белән тагын корал күтәрдең? Соңгы явымда бар булган көчеңне, байлыгыңны-мөлкәтеңне, хакимлегеңне көл итеп күккә очырганымны оныттыңмыни, акылыңа кайт, игелексез! Миңа никадәр зур бурычлы икәнлегеңне исеңә төшер. Әлегә соң түгел: үзара дошманлыкны туктатырга мөмкин. Ил телисеңме, яумы? Сайла. Мин икесенә дә барам. Тик шуны кисәтәм: бу юлы инде сиңа миннән рәхим-шәфкать булмаячак!» *(Хатны төрә.)*

**Залда утыручылар арасында гөжләү башлана.**

Туктамыш *(болай да караңгы чырае тагын да ныграк сүнә).* Ни әйтерсез, гаскәр сәрләре? Күбегез моннан дүрт кыш элек булган орышта катнашкан яугирләр. Шаһ Тимернең кылычы нинди үткен икәнлеген онытмагансыздыр шәт. Ул сезнең кебек үз коралын бер көнгә дә тутыктырмый! Кулы чытырман!

**Тынлык урнаша.**

Җәләлетдин *(гаскәр башлыклары дәшмәгәч).* Чын яугирләр утыра монда, бөек хан!

**Йәникә улын хуплап елмая.**

Туктамыш. Олуглардан узып сүз алма, Җәләлетдин, улым!

Кыпчак би *(торып баса).* Тәхет варисы Җәләлетдин ханзадә хак әйтте, бөек хан! Шаһ Тимернең кылычын сынаганыбыз бар — аның коралы да кителә. Мондый мәсхәрәле хатка бер генә төрле җавап булырга тиеш: ул яу алыр! Чүпрә җибәрүчеләр юк безнең арада! *(Утыра.)*

Исабәк *(тора).* Рөхсәт итче, бөек хан?

Туктамыш. Тынлыйбыз сине, Исабәк би.

Исабәк. Мин Кыпчак бинең сүзенә кушылам, бөек хан. Әмма яу чабарга әлегә иртәрәк, минемчә. Урамда — кыш уртасы. Атларыбыз йончыган чак. Шуңа күрә мин, бер-ике ай ныклап әзерләнеп, көч туплап, ул чүл бүресенең биләмәләренә Каф тавы аша бәреп керергә тәкъдим итәм. Безгә дустанә Төрек мәмләкәте солтаны Елдырым Баязит белән Мисыр хакиме Баркук та күршедәләр генә анда. Кирәк чакта алар да безгә кушылачаклар.

**Бер гаскәр башлыгы ялгызы мыскыллы көлеп җибәрә.**

Туктамыш *(ачулы).* Шайтан кендеген күрсәтеп торамы әллә?

**Көлүче шым була.**

Җанбай *(урыннан).* Кар астында калган әкият бу! Төрек солтаны белән Мисыр хакиме безгә кушылырга үткән ел килешкәннәр иде! Быел алар бездән йөз чөергәнен онытма, Исабәк би! Каф тавын — шайтан бала чыгарган җир диләр бездә!

Исабәк. Кушылмасалар, чәчрәп киткәннәр — үз көчебез дә җитәрлек. Без дә шалкан бакчасында үсмәгән.

Җанбай. Бик дөрес әйтәсең: Идегәй энекәшең калабызны камаганда куәтеңне бик шәп күрсәттең, Исабәк би!

**Көлешәләр.**

Туктамыш *(кулын күтәрә: шундук тыналар)*. Хәрбиләр киңәшкәндә син дә тынып тор, баш вәзир! Тагын кемдә нинди фикер бар?

Кадыйрбирде *(тора)*. Төпчек улыңа сүз бирче, бөек хан?

**Туктамыш кашын гына җыера.**

Йәникә *(пышылдый)*. Әйтсен. Дәүләт башлыгы буласы тәхет варисларын ич!

Туктамыш *(теләр-теләмәс)*. Тыңлап карыйк сине дә, Кадыйрбирде улым.

Кадыйрбирде *(соенеп)*. Монда мөхтәрәм ил агалары утыра. Минем сүзем аларга сабый лыкылдавы булып тоелыр, бәлки. Мин Алтын Урда дәүләте көрешләренең мыскыллавын беркайчан да җавапсыз калдырырга тиеш түгел, дип саныйм! Аксак Тимер үткән ел безнең белән йөзгә-йөз орышудан куркып, Кавказны бөтенләй ташлап качты. Хәзер, без кайтып киткәч, Кавказны кабат яулап йөрергә мәҗбүр. Әзәриләрне әлегә кадәр тез чүктерә алмый! Аның алҗыган чагы. Әгәр дә ул чынлап та орыш теләсә, безгә солых сорап хат юлламас иде! Масаеп язганына шыр җибәрмик — безне өркетер өчен генә шапырына ул. Кичекмәстән яу ягында мин! *(Утыра.)*

**Гаскәр башлыклары арасында: «Ханзадә хаклы! Дөрес сүз! Яу чабабыз!» кебек хуплаулар ишетелә. Йәникә улының кыюлыгына сокланып утыра. Ханның бүтән уллары да канәгать күренә.**

Туктамыш *(уйланып)*. Димәк, барыгыз да яу тели... *(Башын күтәрә.)* Әгәр дә Идегәй дигән мәртәт без яу чыгуга кабат Сарайга ташланса?

**Тынлык урнаша.**

Җанбай. Ышанычлы хәбәрләргә караганда, Идегәйнең Сараебызда кайгысы юк: ул үз кулы астында үзара талашкан олыс биләрен бастырып йөри. Үз хәле хәл. Өстәвенә, Тимер Котлый ханның энесе Күнче солтан Сарайчыкны камарга әзерләнә, имеш. Идегәйнең углы Нурадын да ни өчендер аерылып, үз гаскәрен туплап ята икән. Дөрес, әлегә араларыннан кара мәче узмаган, әмма... кара мәче табарга кыен түгел ич? *(Елмая.)* Аннан соң... Шаh Тимернең Идегәйгә үчле икәнен дә истән чыгармыйк. Димәк, Идегәй үз ындырын Шаh Тимердән сакларга мәҗбүр хәзер!

Туктамыш. Яхшы. Сезнеңчә булсын. Яу көне билгеләнер. Мин әйттем! *(Тәхетеннән тора.)*

**23. Күк Урда пайтәхете Сарайчык. 1395 елның апреле. Көн.**

**Хан сарае. Тәхет залында Тимер Котлый хан, Идегәй, аның улы Нурадын һәм гаскәр башлыклары. Арада йөзбашы Сәлим дә бар.**

Идегәй. Тимер Котлый хан! Киңәшмә җыюның сәбәбе бер генә: энекәшебез Күнче солтан безгә каршы яу чыккан. Беләм, гаскәре зур түгел, әмма чабавыл чабуларда сыналган баһадирлар бар. Моңарчы бездән асыл йөзләрен яшереп, чабу астыннан ут йөрткән берничә әмир дә аңа кушылган. Күнче солтан — синең бертуган энең. Минем үземә дә кан кардәш. Нишлибез?

**Гаскәр башлыклары арасында гаҗәпләнү башлана: «Ничек?! Үз абыйсына каршы! Чала татар икән!» h. б. Барысы да ханның җавабын көтәләр. Хан аптырап калган. Тынлык.**

Тимер Котлый *(ниһаять)*. Ялгыш хәбәр түгелме, Идегәй әмир?

Идегәй. Түгел, хан. Сарайчыкка бер көнлек юлда чатыр корган.

Тимер Котлый *(узалдына)*. Теге вакытта башын чаптырасы булган икән, юньсез баланың...

**Аны ишеткәннәр сәерсенеп куялар.**

*(Усаллык белән.)* Гаскәребезгә боерык бир, сәргаскәр Идегәй әмир! Туган абыйсына кылыч күтәргән ахмакның башын алдыбызга китереп салсыннар! Мин әйттем. *(Йөзен куллары белән каплый һәм тынып кала.)*

Идегәй *(бераздан)*. Чебенгә чукмар күтәрү булмасмы? Үгетләп игә китереп карасак, хан? Илчеләр җибәрик!

Тимер Котлый *(башын күтәрә)*. Юк! Ул чирлә кигәвене игә килергә охшамаган! *(Тынычрак тавыш белән.)* Җае чыкса, исәнимин килеш хозурыбызга китерергә.

Идегәй. Менә бу — хан сүзе! Нурадын би!

**Нурадын шатланып сикереп тора.**

Хан әмерен үтәү сиңа тапшырыла.

Нурадын. Рәхмәт, сәргаскәр! Хан әмере тиешенчә үтәлер!

**Идегәйнең гаскәр башлыгы итеп үз улын сайлавы бүтән командирлар арасында ризасызлык тудыра: үзара пышылдашу башлана. Идегәй аларга игътибар белән карый. Тыналар.**

Нурадын. Китәргә рөхсәт ит, хан?

Тимер Котлый. Мин сиңа ышанам, Нурадын би. Рөхсәт. Ә хәзер — ялгызымны калдырыгыз.

**Идегәй, улына үзе белән чыгарга ымлап, ишеккә юнәлә. Нурадын Сәлимгә үзе артыннан иярергә ишарә ясый.**

Идегәй *(әкрен генә)*. Ханның әмерен дөрес аңладыңмы, улым?

Нурадын. Дөрес дип уйлыйм, әти.

Идегәй *(Сәлимгә ымлап)*. Ә бу егетең кем була?

Нурадын. Теге вакыт сиңа сөйләгән илем ич? Бүре ыруы егете Сәлим бу. Таскол иде. Хәзер йөзбашы ул минем төмәндә.

**Сәлим Идегәйгә баш ия.**

Идегәй *(улына)*. Шулмыни але бу? *(Сәлимгә сынап карап тора. Сәлим аның күз*

*карашыннан качмый.)* Миңа күчәсең киләме, егет?

Норадын *(ризасызлык белән).* Сәлим минем үземә дә бик кирәк, Идегәй батыр!

Идегәй *(елмая).* Ата белән бала арасында баһадирлар бүлешү язык эш, углым. *(Сәлимгә.)* Ни әйтерсең, батыр егет?

Сәлим. Белмәгән кичүгә сукырларча керергә күнекмәгән мин. Вазифам нидән гыйбарәт булачак?

Идегәй *(егетнең җавабы аңа ошый).* Җан сакчым һәм юлдашым булырсың.

Сәлим *(куанычын яшерергә тырышып).* Миңа ышаныч белдерүең өчен рәхмәт, сәргаскәр. Норадын би каршы төшмәсә, мин риза.

Норадын *(ярымшаярып).* Үлемнән йолып калып, үстер менә кешене! Чишмәне иделгә түккән кебек була да... Нишлисең — көчленеке замана, Сәлим дус! Ә Идегәй батыр көчле сәргаскәр генә түгел, минем әти дә бит әле. Әйдә, ярый, хыянәт ит миңа. Ачуланмыйм. *(Әтисенә.)* Киләчәктә уяу якны өстен тотарга туры килер: дусларымны мактамаячакмын хәзер!

Идегәй. Килештек. Норадын белән яудан урап кайтуга минем янга кил. Икегезгә дә хәерле сәфәр телим.

Сәлим *(баш ия).* Рәхмәт, сәргаскәр.

Норадын *(шаярып егетнең җилкәсенә суга).* Киттек, вәгъдәсез җегет!

**Китәргә кузгалалар. Шул вакыт алар каршына Күнче солтанның илчесе ашыгып килеп керә.**

Шыгавыл. Күнче солтаннан — илче!

Идегәй *(гаҗәпләнеп).* Күнче солтаннан?! Илме, даумы, илче?

Илче *(ул — Сәлимгә качарга «ярдәм» иткән егет. Сәлимне таный, әмма белмәмешкә салыша. Сәлим дә аны таный).* Хәбәрем Тимер Котлый хан колагы өчен, Идегәй батыр!

Идегәй. Яхшы. Монда көт. *(Улына.)* Углым, китәргә ашыкмый тор. *(Хан янына керә.)*

**Сәлим сагаеп калган: илче аны сатмасмы? Шуны сизенеп ахры, илче Норадынга сиздерми генә Сәлимгә күз кыса: тынычлан, янәсе! Сәлим читкә борыла.**

Идегәй *(ишекне ачып, илчегә).* Хан көтә сине. *(Үзе дә керә.)*

Тимер Котлый. Тыңлыйбыз сине, илче.

Илче *(аның алдында иогенә).* Күнче солтанның катгый әмере авызымны ачарга рөхсәт итми, Тимер Котлый хан: монда ике колак артык.

Тимер Котлый. Борчылма, илче: дүрт колакны ике сана.

Илче. Әмереңә буйсынам, Тимер Котлый хан. Күнче солтан сиңа хәбәр итә: Туктамыш хан Кавказда Терек елгасы буенда, Шаһ Тимердән җиңелеп, гаскәрен ташлап качкан. Хәзерге көндә кайда икәнлеге билгесез. Качкан яуга хатын ир. Күнче солтан сине бергәләп Сарай каласын алырга чакыра.

**Хан белән Идегәй гаҗәпләнүләрен яшермичә бер-беренә карап куялар.**

Тимер Котлый *(дулкынлануын көчкә тыеп).* Хәбәрең өчен рәхмәт, илче. Бер сорауга җавап бир: Күнче солтан нинди ният белән, безгә хәбәр итмичә, Сарайчык янына килеп чатыр корды?

Илче. Монысы миңа караңгы, Тимер Котлый хан.

Тимер Котлый. Китәргә мөмкин. Җавапны иртәгә ишетерсең.

**Илче, аның алдында иогенеп, чыгып китә. Ул чыгуга Идегәй сикереп тора һәм зал буйлап йөри башлый. Хан сүзсез генә аңа карап тора. Ниһаять, Идегәй, бер карарга килеп, тәхет каршына туктый.**

Идегәй. Нинди карарга килдең, хан?

Тимер Котлый. Энемә ышанып бетмим мин. Чираттагы мәкере генә булмагае.

Идегәй. Ә мин ышанам, хан.

Тимер Котлый. Максаты?

Идегәй. Шушы тәхеткә утыру. Үе бик гади солтанның: ул сиңа Туктамышның тәхетен яулап алырга булыша, син аңа — шушы тәхетне бирәсең.

Тимер Котлый *(сынап).* Син моңа каршымы?

Идегәй. Каршы түгел.

Тимер Котлый. Димәк... Ходайга тапшырып, Сарайга яу?

Идегәй *(йөрепә).* Юк. Хәзерге вакытта бу — башсызлык булыр иде!

Тимер Котлый. Ник? Иң кулай чак ич?

Идегәй. Киресенчә, хан... Шаһ Тимерне бик яхшы беләм мин: ул эзәрлекли башлаган җанварның җанын кыймыйча туктамый торган ауч ы! Орыш кырыннан качкан Туктамыш иң элек кая юнәләчәк? Үз Сараена! Аңа бүтән чара юк. Яңа гаскәрне ул бары тик шунда гына туплый ала. Бөтен казнасы шунда. Без синең белән әйбәт беләбез: Шаһ Тимер җүләр түгел! Туктамышны эзәрлекләп Сарайга киләчәк. Әгәр дә без барлы-юклы көчебез белән Сарайга барып чыксак, ташкын астында калачакбыз. Арыслан авызына керергә ашыкмыйк. Үз өенә кайтып китсен. Шуннан соң — Сарайга яу чапсак та була. *(Елмая.)* Туктамышның бер акыллы сүзен хәтерлим: арыслан белән юлбарыс үзара талашса, үгез түшкәсе маймылга кала ди, имеш. Мамайның җирләрен ул әнә шулай үзенә каптырды. Акыллы дошманыңнан үрнәк алу бер дә язык түгел!

Тимер Котлый. Хуш. Шаһ Тимер бер уңайдан безнең арт сабакларыбызны да укытырга теләсә, нишләрбез? Юлы өстендә бит без. Вәгъдәбезне боздык!

Идегәй. Аңа моннан ни файда? Байлыгыбыз — ташка үлчим! Иксенчедән безнең аша кайтырга гаскәрләре күнмәячәк: Сәмәрканд юлының нинди каһәрле икәнен бик яхшы беләләр алар. *(Елмая.)* Бер дә булмаса, соңгы чиктә Тимерказык йолдыз безгә юлдаш булыр, Тимер Котлый хан!

Тимер Котлый. Бусы хәл ителде кебек... Энебезгә нинди җавап бирәбез?

Идегәй. Нәкъ шушылай, хан.

**24. Сарайчыкта Идегәй йорты. Кич.**

**Идегәйнең йортында мәҗлес: унбишләп таза сугышчы ашап-эчеп утыра. Түрдә — Идегәй үзе һәм өлкән хатыны Айтулы. Айтулы шактый олыгайган, чәчләренә чал кергән. Кунаклар арасында Норадын белән Сәлим дә бар. Җариядәр, хезмәтчеләр тавышсыз йөри. Кайдандыр талгын моң ява.**

Идегәй *(кунакларына игътибар белән карап чыга)*. Ярар. Барыгыз да хушландымы, яугирләр?

Яугирләр. Рәхмәт! Хушландык! Озын гомер сиңа, бөек сәргаскәр! Йортыгызга хәерле бәрәкәт!

Идегәй. Хушлансагыз, җәгез, амин тоттык! *(Ике кулын күтәреп, дога кыла: башкалар да аңа кушылалар.)* Амин! *(Хатынына.)* Айтулы сөеклем, егетләремә бер-ике сүзем бар иде.

**Айтулы сүзсез генә тора һәм ишеккә юнәлә.**

*(Хезмәтчеләренә китәргә ишарәли.)* Соңыннан. Оланнар! Сез — минем иң ышанычлы батырларым. Барыгыз да тәвәккәл, кыю егетләр.

Берсе *(шаярып)*. Барыбыз да шәп анысы. Уңганлыгыбыз ялкаулыгыбыз аркасында гына күренми. *(Үзе башлап кычкырып көлә.)*

Идегәй *(елмая)*. Сезгә бер бик җитди вазифа йөкләргә булдым. Хезмәт йомышы. Алдан ук кисәтеп куям: җиңел эш түгел. Кемгәдер, бәлки, башын да салырга туры килер. Кем үзеннән шикләнә — хәзер үк баш тартсын. Берегезне дә гаепләмәм моның өчен.

Яугирләр *(бердәм)*. Боер, сәргаскәр! Без синең өчен башыбызны салырга да әзер!

Идегәй. Рәхмәт, оланнар! Бүтән төрле җавапны көтмәгән идем мин. Ил хаҗәте чакырды сезне. Ишеткәнсездер шәт, Туктамыш хан, индеге көндә Шаһ Тимердән качып йөри. Баскан бер җирен ут ала. Шаһ Тимер, Иделебез буена кабат басып керде. Урдабызның иминлеге тагын кыл өстендә. Безгә икесенең дә һәр адымын төгәл белеп тору шарт. Менә ни өчен җыйдым мин сезне. Сез — минем үткен күзләрем, сизгер колакларым булырга тиешсез. Арагыздан берәвегез баш булыр, ә калганнарыгыз берәмберәм нәүбәтләп миңа хәбәр кайтарыр. Беренче хәбәрне мин Сарай каласыннан көтәм. Аңлашылдымы?

Яугирләр. Хезмәтең башыбыз өстендә, сәргаскәр! Боер!

Идегәй. Норадын би барыгызга да көтүлектән иң шәп атлар, хәзинәбездән юл хәстәрлекләре бирер. Кем дә кем, бәхетсезлегенә каршы, Шаһ Тимер яки Туктамыш кешеләре кулына эләгә икән — авызыгыз йозакта булырга тиеш! Ассыннар, киссеннәр — теленне чәйнәп йот! Исән-имин урап кайтканнарга — унар ат. Ә инде авыр сәфәрдә ятып калучылар булса, гаиләләренә егермешәр ат.

**Яугирләр шатланып, үзара гөжләп ала.**

Берсе. Башлык билгелә сәргаскәр!

Идегәй. Сүзем бетмәде әле, оланнар. Башлыкка беренче көннән алып, азакка кадәр хәтәр астында булырга туры киләчәге аңлашыладыр?

Яугирләр. Беләбез, сәргаскәр. Дөньяга бүген килмәгән.

Идегәй. Шулай булгач, ялның иң зуры да аңа тиеш булуы да бәхәс кузгатмастыр?

Яугирләр. Әлбәттә, шулай! Бәхәс күтәрүче булса, уч төбенә йон чыксын!

Идегәй. Яхшы. Башлыкка, исән-имин вазифасын үтәп кайта алса, утыз ат.

**Яугирләр шаккаталар. Кайсыдыр тел шартлата.**

Әгәр дә инде ул... башын салса, якыннарына илле ат!

**Тынлык урнаша.**

Йә, кайсыгыз үзе теләп башлык вазифасын үз җилкәсенә ала?

**Яугирләр бер-берсенә карашалар.**

Җаваплылык куркытамы?

Берсе *(тора: иптәшләре аңа гаҗәпләнеп карыйлар)*. Башлык вазифасын үтәү авыр булачагын һәркем бик яхшы чамалый, сәргаскәр... Күпләребезнең моңа куәте дә җитәдер. Ләкин... башлык булырга телим дип үзең әйтү ничектер... зур бүләккә кызыккан кебек килеп чыгар иде! Башлыкны арабыздан үзең куй инде, Идегәй әмир. Шулай гадел булыр бит, җегетләр?

Яугирләр *(аның өчен җиңел сулап)*. Шулай, шулай! Зинһар, беребезне дә авыр хәлгә куйма, сәргаскәр.

Идегәй *(көлемсери)*. Белеп сайлап алганмын икән мин сезне, оланнар. Болай булгач, ботка пешереп була сезнең белән!

**Егетләр елмаешалар.**

Сезнеңчә булсын, алайса... Сәлим! Килеп бас әле менә монда.

**Сәлим аптырап кала. Әмма үзен бик тиз кулга ала һәм Идегәй янына чыгып баса.**

Бу егетне барыгыз да беләсезме, оланнар?

Яугирләр *(гаҗәпләнеп)*. Белмәскә... Үзебез тотсак иттек аны. Безнең ике дустыбызның җанын кыйган кеше!

Норадын *(кискен)*. Онытмагыз: ул миннән ярлыкау алды! Хаклы алды!

Идегәй *(улына тынычланырга ымлый)*. Менә нәрсә, оланнар: сез миңа башлыкны үзең сайла, дидегез. Һәм мин аны сайладым. Кем моңа канәгать түгел — хәзер үк эштән азат ителә! Йә, кайсыгыз мин сайлаганга каршы?

Берсе *(теләр-теләмәс)*. Каршылыкка каршы түгел лә без.. Оста яугир икәнлеген дә күрдек... Тик... баш була... Холкына киләме икән?

Идегәй *(катгый)*. Ишетелми?

Яугирләр *(бердәм)*. Без риза, сәргаскәр!

И д е г ә й. Мәнә хәзер яхшы ишетелде. Юкса, кемдер авыз эчендә ботка пешергән кебек тоелды. Барыгыз да колакларыгызга киртләп куегыз: шушы вакыттан алып Сәлимнең һәр сүзе — минем сүз! Аңа буйсынмау — миңа хыянәт! Барып життеме?

Б е р с е. Аңлашылды, сәргаскәр.

И д е г ә й. Димәк, килештек.

С ә л и м. Кичер, мин үзем килешә алмыйм, сәргаскәр. Мине үз яныңда калдыруыңны үтенәм.

**Тынлык урнаша.**

Б е р с е. Мәнә сиңа атаң башы!

И к е н ч е с е. Әллә шүрләп калдынмы?

**Сәлим аңа борылып та карамый.**

И д е г ә й *(тыныч, ләкин каршы килмәслек итеп)*. Бу — минем катгый әмерем, таскол. Норадын, углым, егетләрне юлга әзерлә. Ә син, Сәлим, монда кал.

**Егетләр чыгып киткәч, Идегәй торып баса.**

Хикмәт шунда, егет: мине нигә эзләп килгәнеңне яхшы беләм мин.

С ә л и м *(агарына)*. Күнче солтанның илчесе саттымы мине?!

И д е г ә й *(кулын аның җилкәсенә куя)*. Юк. Уртага салып сөйләшик. Очраклы хәбәрләр көтеп ятсам, Идегәй дә булмас идем инде. Курыкма, ачу тотмыйм сиңа. Ниятеңнең сәбәбен яхшы аңлыйм. Орыш корбансыз булмый, егет. Алтын Урда Туктамыш хан табаны астында булганда юкка чыгачагыбыз көн кебек ачык. Тармаңгайлыгы аркасында Идел-Йортыбызга кабат кара афәт килде! Ә теге вакытта Шаһ Тимерсез берни кырып булмый иде! Ни чарадан бичара. Синең миңа күктән таш яуса да үҗәтләнеп үз максатыңа ирешергә тырышуың ошый. Шуңар сайладым мин сине. Килер бер көн, кырымнар да, хажитарханнар да, нугайлар да, болгарлар да, синең якыннарың — бүре ыруы халкы да бердәм яши башлар. Мәнә нәрсә өчен көрәшәм мин!

С ә л и м *(башын күтәрә)*. Ул көннәр килгәнче таш алтынга, кар ялкынга әйләнер, сәргаскәр. Яхшы, боерыгың төгәл үтәлер!

И д е г ә й. Шикләнмим, кардәшем!

**25. Җаек елгасы яры. Язгы көн.**

**Яр башында берничә яугире белән Идегәй басып тора. Атлары яңа күтәрелеп килгән чирәмдә утлап йөри. Идегәйнең зур чатыры да шунда. Арырак берничә гади чатыр корылган.**

**Идегәй ярларына кайтып бетмәгән язгы ташкынга текәлгән: елга уртасында зур сал көчле агым белән көрәшә. Анда — аның икенче хатыны, Шаһ Тимернең кызы Акбеләк. Идегәй яшь хатынын каршыларга килгән. Акбеләк иренә, таныш, яулык болгый. Идегәй кул изәп җавап бирә.**

Я у г и р *(Идегәйнең нөгәрләре бер читтәрәк үзара әкрен генә сөйләшәләр)*. Бу Акбеләк атасы Аксак Тимер сыңары, ахрысы! Бик тәвәккәл нәмәрсә күренә... Котырган ташудан да өркеп калмаган!

И к е н ч е с е. Әкренрәк, Идегәй үзе ишетеп тормасын... Атасы сыман тәвәккәл холыклы булмаса, Идегәй кебек батыр аңа әйләнеп тә карар идеме! Уклау бикә булып чыкмасын иде дип теләгез сез.

**Ерактан җайлак чабып килгән тавыш ишетелә: яр башындагылар шул якка таба борылып карыйлар. Җайдак алар янына килеп туктый: Идегәйнең шымчылыкка җибәргән егетләренең беренчесе ул. Чапкын атын калдыра һәм Идегәйгә бер тезенә төшеп йөгенә. Идегәйнең яраннары, тыйнаклык күрсәтеп, читкәрәк китәләр.**

И д е г ә й. Сарайданмы?

Ч а п к ы н *(күтәрелә)*. Әйе: мин — беренче чапкын. Хәбәрем шатлыклы түгел, сәргаскәр: Туктамыш хан, Сарайда озак туктап тормыйча, Болгар иленә сызган.

И д е г ә й. Шаһ Тимер кайда?

Ч а п к ы н. Шаһ Тимер башта Хажитарханны, талап-яндырып, җир белән тигезләп, аннан соң — Сарай каласын астын-өскә китергән. Без барып житкәндә хәрабәләр генә кара корымланып ята иде. *(Башын ия.)* Хан бистәсе Алтын Таш кына исән.

И д е г ә й *(чырае караңгылана)*. Шулай буласы билгеле иде.

Ч а п к ы н. Соңгысы: Шаһ Тимер Түбән Иделгә калгай хан итеп үзе белән алып килгән Коерчак атлы берәүне куйган, имеш. Монсын — башлыгыбыз Сәлим үзе калага кереп белеште.

И д е г ә й. Рәхмәт. Китәргә мөмкин. Вәгъдә ителгән бүләкне Норадын бидән алырсың. *(Хатынына кул изи.)*

Ч а п к ы н *(башын ия)*. Кичер, сәргаскәр: мондый яман хәбәрем өчен андый зур бүләкне ала алмыйм мин.

И д е г ә й *(капыл егеткә борылып карый)*. Киләчәк яуларда кирәк булачак алар сиңа, унбашы!

Ч а п к ы н *(гаҗәпләнеп)*. Мин — гади яугир, ялгышасың, сәргаскәр.

И д е г ә й. Бүгеннән үзеңне унбашы дип исәплә. Борыныңны төшермә, яугир, башыңны югары тот! Иделебездән Туктамыш ханны да, Аксак Тимер шакалларын өшт иттербез, Аллаһы боерса. Озын-озак бәйрәм итә алмаслар! *(Ярга якынлашып килгән Акбеләккә кул болгап елмая.)* Хуш киләсең, гүзәлем Акбеләк! Исән-имин килеп життеңме?

**26. Сарайчыкта Идегәйнең зур йорты. Кич.**

**Идегәй өлкән хатыны Айтулының иркен пулатына килеп керә.**

И д е г ә й *(ачык йөз белән)*. Мине күрергә теләгәнсең икән, кадерлем Айтулы? Бәй, ник ай кебек нурлы йөзең караңгыланган? Кәефең начармы дисәм... Авырый күрмә, карлыгачым: хәзер син — минем иң яраткан өлкән бичәм итеп билгеләнден. Яшь-җилкенчәкләргә акыл бирү — синең өстә. *(Хатынын җилкәсеннән сөя.)*

А й т у л ы *(читкәрәк тайпылып, сагышлы тавыш белән)*. Андый олуг хөрмәтеңнән азат ит мине, сөеклем. Өлкән хатының итеп

Шаһ Тимер кызын куй. Бик чая. Акыллы. Житез. Итагатьле.

Идегәй *(шаяртып)*. Ничек?! Хәзер үк җәннәткә кертерлек икән, алайса!

Айтулы. Яхшы кеше: койрыгы гына юк! Кичер: никтер кәефсез чагым. Шатлыгынны уртаклаша алмыйм. Табигатем шундыйдыр инде: Сарайга китәргә рөхсәт итче миңа.

Идегәй *(шаккатып)*. Сарай әлегә дошман кулында ич?! Ничек, кайда яшәрсең? Хәрабәләр генә тырпаеп тора, ди, анда!

Айтулы *(горур)*. Син Сәмәркандта чакта яшәдем бит әле. Илдә чыпчык үлми. Норадын углыбызны минем белән җибәр, дип сорамыйм. Хәер, ул үзе дә синнән китмәс иде — басылып яшн ала торган бала түгел ул. Үзеңә охшаган. *(Тора.)* Әгәр дә китәргә ризалыгыңны бирмәсәң, мине дөнья белән бәхилләшкән, дип сана. Ә синең үзеңә ул чакта мәңге бәхил булмаячакмын мин, Идегәй! Салкын гәүдәмне генә алырсың.

Идегәй *(югалып калган)*. Туктале, Айтулы сөеклем... Хатын өстенә хатын алып, түшәк яңарту — ата-бабаларыбыз йоласы ич? Теләсәң, аларның өчесен дә бүгеннән куып җибәрәм мин!

Айтулы. Кума, Идегәй. Теләмим. Син — ир кеше. Гайрәтле чагың. Ә мин — картайдым. Шикләнмә: сиңа үпкәләп китмим мин...

**Идегәй җавап бирергә өлгерми, ишектә Шыгавыл күренә.**

Идегәй *(ачу белән)*. Нәрсә бар?!

Шыгавыл *(куркуыннан тотлыгып)*. Болгар иленнән чапкын. Син аңа, нинди генә вакыт булса да, тоткарлыксыз янына керергә кушкансың икән.

Идегәй *(Айтулыга карап тора һәм бер ишарә кыла)*. Керсен! *(Айтулының китәргә кузгалуын күрә.)* Китми тор. Синнән серем юк минем. Сүзебез дә тәгалләнмәде!

**Чапкын керә һәм алар алдында йөгенә.**

Йә, нинди хәбәрләр алып кайттың, яугир? Тик кыска тот.

Чапкын. Яхшысы юк. Ә кыска тотканда — болай, сәргаскәр: Хаҗитархан, Сарай калаларының җимерек...

Идегәй. Беләм. Сарайны калдырып киткәннән соң булган хәлләр турында гына сөйлә!

Чапкын *(гаҗәпләнеп)*. Сарай каласыннан соң, Идел буендагы эреле-ваклы егермеләп каланың яндырылуын кайтып әйтмәделәрме, сәргаскәр? Миңа чаклы утаман Сәлим дүрт чапкын җибәрде сиңа.

Идегәй. Ничек — дүрт чапкын җибәрде?! Бер чапкын гына күрдем мин, яугир!

Чапкын. Кайтыр юлда бер-бер хәлгә тап булганнар инде алар, димәк... Мин үзем — Болгар йортыннан урап кайттым, сәргаскәр. Шаһ Тимер, Туктамышны куакуа, Идел буйларындагы барлык кала-кирмәнчелекне нигезенә кадәр талап-җимереп менде. Данлыклы Болгар каласы да җир йөзендә юк хәзер. Җүкәтау, Биләр, Казан кирмәннәре дә — хәрабә. Халыкның күбесе кылычтан үткәрелде, сирәк-мирәк исән калганнары урманнарда качып йөри. «Андый бәхет» тимәгәннәрне Шаһ Тимер яугирләренә кол итте. Сәлимнең туган кирмәнен дә яндырганнар, ярый кешеләрнең күбесе урманга качып өлгергән... Туктамышның кыйбласы күренмәде: соңгы мәртәбә чатыр корган җирендә шыелдап җилләр исә. Түмән елгасы ягына шылган дигән хәбәрләр генә бар. Шаһ Тимер әлегә Болгар илендә бәйрәм итә. Урыс якларына борылмакчы дигән имеш-мимешләр йөри. Идел-йортыбыз мәңге кабат тернәкләнә алмаячак хәзер, сәргаскәр! Исәннәребезгә урыслар көн бирмәс инде хәзер. Болай да угры ушкуйчылардан жык булган идек!

Идегәй. Шыңшыма, яугир! Ир икәнлегеңне онытма!

Айтулы. Гаиләң монда торамы, яугир?.. Алайса тынычлан. Шаһ Тимер киявенең каласына тимәячәк! Сәргаскәреннең упыкый-чупыкый чаклары.

**Чапкын шаккатып Идегәйгә текәлә.**

Идегәй *(ачу белән)*. Син! Тыңлап кына тор! *(Чапкынга.)* Ә син боламык булма, унбашы!

**Чапкынның күзләре маңгаена менә.**

Ялгыш ишетмәдең, яугир: унар ат бүләк итәргә вәгъдә бирүем — һәммәгезне унбашы итеп билгеләвем иде ул. Урыс-улакны синең белән мин кумасак, кем куар! Җимерелгән калаларны без күтәрмәсәк, кем кабат торгызыр?! Өметсез шайтанмы? Үзеңә тиешле атларны көтүдән сайлап ал. Китәргә мөмкин.

Чапкын *(баш ия)*. Кичер, сәргаскәр. *(Чыгып китә.)*

Идегәй. Өзелеп калган сүзебезне бетерик...

Айтулы *(ишеккә юнәлә)*. Ачуланма, Идегәй: юлга әзерләнәсем бар.

**Идегәй хатынының бүлмәсендә ялгызы кала. Кулы кылычның сабында бии.**

**27. Сарайчык каласы янында болын. Көзге көн.**

**Такыр басуда яшь яугирләр сугыш күнегүләре ясый. Идегәй белән Норадын, атларын әкрен генә атлатып, яшүсмерләрнең өйрәнүләрен ук атып җир арттарак калкулыктан күзәтәләр. Идегәйнең йөзе кырыс. Ул әледән әле офыкларга күз ташлый.**

**Норадын әтисенең халәтен яхшы сизә булса кирәк, сүзсез генә янәшә йөри.**

Норадын *(ниһаять, түзми)*. Сәлимнән хәбәр көтәсең, ахры, син һаман? *(Әтисе дәшми.)* Безне әллә кайчан оныткандыр инде ул! Хуҗасын җиңел алыштыручыларга ышанмыйм мин, Идегәй батыр. Ни пычагыма кирә әйләнеп килсен ул монда? Унбиш яугир алып китеп, икесе кире әйләнеп кайтты. Бүтәннәре өчен җавап тотудан курка, димәк.

Идегәй. Күп нәрсәләрне белмисең әле син, углым. Башы сау булса, кайтырга тиеш.

Норадын. Нәрсәгә таянып, шулай дисең?

Идегәй *(бик гади генә)*. Сарайчыкка ул синең атаңны үтерергә килгән иде.

Норадын *(телсез кала)*. Сине үтерергә?!. Җан сакчың итеп алганда үзең шуны белә идеңме?!

Идегәй. Белә идем.

Норадын. Акылыңны җуйгансың син, әти!..

Идегәй. Минем белгәнне үзе дә белеп китте ул. Дошманнарын дуска әйләндерә алучы кеше генә Урда хакиме була ала, углым... Тукта... *(Кулын кашына куя.)* Офыкта ниндидер кара күренә. Күзләрең минекеннән яшьрәк, яхшылабрак карале, углым, әнә теге ялгыз каен тирәсен!.. Сәлим түгелме?

Норадын *(көлә)*. Төлке чаклы гына нәмәрсә бит ул!

Идегәй. Аты — аныкы! *(Елмая.)* Сәлим кебек егетләр беркайчан да морадына ирешмичә качмый, углым. Ул җегетнең һәр төкерсе алтынга охшый.

Норадын. Каршысына киттек әйдә!

Идегәй. Чәбәләнмә. Дәрәҗәңне сакла!

**Чынлап та, тиздән кемнеңдер атын кызу чаптырып якынлашканы күренә. Болында күнегү ясаучылар да моны күреп тынып калалар. Хәтта йөгереп киткән тасколны да оныталар. Менә атлы кеше таскол турына килеп җитә һәм... көтмәгәндә бер кулы белән аны, күтәреп, ияренә аркылы сала. Идегәй ялгышмаган икән: Сәлим бу. Ул тасколны яшьләр алдына ташлый һәм Идегәйләр янына күтәрелә. Килеп җитүгә, атыннан сикереп төшеп, Идегәй алдына бер тезенә чүгеп йөгенә һәм шундук тураеп баса. Идегәй дәшми.**

Сәлим. Ата белән угылның киңәшләре берексен!

Идегәй *(җитди)*. Уртасында бул!

Сәлим. Соңгы исәп-хисап ясарга рөхсәт ит, сәргаскәр: Шаһ Тимер, урыс җирләренә сугылып тормыйча, Кавказга юл алды. Туктамыш хан сан ярым калдык-постык гаскәре белән пайтәхет Сарайга кайтып төште. *(Чайкалып куя, әмма бик тиз турая.)* Гаҗәпләнмә, сәргаскәр: тоташтан өч тәүлек ат өстендә. *(Елмая.)*

Идегәй *(ияреннән төшеп, атының тезгенен Сәлимгә тоттыра)*. Атың янган, меңбашы: мә — вәгъдә иткән илле башка өстәмә бүләгем бу! *(Сәлимне кочаклый.)* Гомеремдә беренче тапкыр шушындый яхшы хәбәр алуым! Рәхмәт, кардәшем! Бар, калага кайтып, туйганчы ял ит!

**Норадын әтисенә шаккатып карап тора.**

Сәлим *(Идегәйнең алтын ичрле атына җиңел генә сикереп менә)*. Рәхмәт, Идегәй батыр! Минем — мондый урта бармактай зифа тулпарга менгәнем юк иде! *(Хәйләкәр елмаеп.)* Бөтен аруларым онытылды! Бер тәүлектән артык йоклап булмас, ахры: никтер күңелем шулай ди! *(Кала ягына чаптырып китә.)*

Норадын *(елмая)*. «Меңбашы» дигәнenә исе дә китмәде, бугай, моның! Мә, әти, минекенә атлан, булмаса: Идегәй батырга җәяүгә калу килешеп бетмәс. *(Атының тезгенен әтисенә тоттыра.)* Үзем Сәлимнең алҗыган аты белән ничек тә терек-терек кайтып җитәрмен әле.

Идегәй *(улының атына менә)*. Белмим, углым: бер-ике айдан аягына торып басса гына инде. *(Елмаеп, кала ягына чабып китә.)*

**Норадын Сәлимнең атына борылып карый: ул җиргә ауган.**

**28. Сарайчыкта хан сарае. Көн.**

**Кечкенә залда алтын читлекләрдәге тутый кошларга җим сибеп маташкан Тимер Котлый хан янына җилләп Идегәй килеп керә.**

Идегәй. Тутый кошларыңа җимне җарияләрең сибәр, Тимер Котлый хан: Сарайга яу чабабыз! Сәгате сукты, ниһаять!

**Тимер Котлыйның кулындагы алтын савыт идәнгә тәгәри.**

**29. Сарай каласы. Көзге иртә.**

**Урам икәнлеге дә юньләп беленмәгән хәрабәләр арасыннан атлы гаскәр ташкыны ургыла. Уртада — Тимер Котлый хан, сәргаскәр Идегәй һәм бүтән эре гаскәр башлыклары. Норадын белән Сәлим гаскәрнең иң алгы сафларында бара.**

**30. Алтын Таш хан сарае. Шул ук иртә.**

**Атлы гаскәр ташкыны ярым ачык капкадан хан сарае утарына бәреп керә: андасанда күренгән утар казаклары, коралларын ташлап, төрле якларга сибеләләр. Аларга игътибар итүче дә юк.**

**31. Тәхет залы. Шул ук иртә.**

**Идегәй, Тимер Котлый хан, Норадын, Сәлим һәм бүтән гаскәр башлыклары тәхет залына килеп керәләр: зал буш.**

Идегәй *(тәхеткә күрсәтә)*. Тимер Котлый хан! Хак Тәгаләбез догабызны ишетте — тәхетеңне кабул итеп ал! Бүгеннән — синеке ул! *(Үзе шундук ишеккә юнәлә.)*

**Гаскәр башлыклары Идегәй артыннан чыга: Тимер Котлый янында берничә яралы гына кала.**

**32. Озынча зур зал. Шул ук иртә.**

**Идегәй, эре-эре адымнар белән тәхет залыннан чыгып, рәттән төрле ишекләрне аягы белән тибеп ачып бара. Кайда да бушлык, кайда да онытылган кием-салым, алтын-көмеш әйберләр аунап ята, кубарып өлгермәгән затлы келәмнәр диварлардан салынып төшкән, кыйммәтле сарай җиһазлары, кыйммәтле әсбаплар аркылы-торкылы килгән. Ниһаять, алар Шыгавыл сакта торган тар ишеккә тап булалар.**

Идегәй. Утала чапмаган бер кеше калган икән әле хансарайда!

Шыгавыл *(айбалтасын ишеккә аркылы куя)*. Монда керергә ярамый, Идегәй әмир.

Идегәй. Кем анда?

Шыгавыл. Ханәкә белән Көнәкә. Туктамыш ханның кызлары.

Идегәй. Турысын әйтегез миңа: Туктамыш үзе кайда?

Шыгавыл *(әйтимме-юкмы дигәндәй, бераз икеләнеп)*. Туктамыш хан Кырымга качты.

Идегәй. Гаскәре күпме?

Шыгавыл. Ачыгын белмим, Идегәй батыр...

Идегәй. Шулай да? Курыкма, Шыгавыл: Туктамышның исе дә булмаячак хәзер монда.

Шыгавыл *(йөзе ачылып китә)*. Сан ярым чамасы җайдагын иярткән иде, кайтып кергәндә. Аксак Тимер киткәннән соң кабат калага җыелган җайдакларны да кушсак, өч төмәнгә якын булыр. *(Уйланып.)* Алай ук та юктыр, минемчә.

Идегәй. Ялганласаң, кара аны!

Шыгавыл. Ипикәйдер менә, тамчы да ялган түгел, Идегәй батыр! Син килгәнче качып...

Идегәй *(бүлдерә)*. Ә кызларын ник ташлап киткән?

Шыгавыл. Ташламады ул аларны. Ханәкә белән Көнәкә Идел буенда иделәр, эзләп-эзләп тә таба алмаганнар...

Идегәй. Яхшы. Хан кызларын күз карап кебек сакла. Бөртек чәчләре дә төшмәсен! Минем алда башың белән җавап тотачаксың!

Шыгавыл. Шикләнмә, Идегәй батыр: минем төп шөгылем шушы. Сатар-сатылыр җаным юк. Төп башында йортым, казык башында казаным. Норадын углың минем күз алдымда Ханәкәгә күз атып...

Идегәй *(бүлдерә)*! Хан кая? *(Кырт борылып, тәхет залына юнәлә, бүтәннәр дә аннан калмыйлар.)*

Шыгавыл *(үз-үзенә)*. Артыгын ычкындырдым, ахры. Андый серне ят кешеләр алдында ачып салалармыни, ахмак! Ә икенче яктан караганда... Норадынның хан кызларына элек-электән күз атып йөргәнлеге беркемгә дә сер түгел иде ич? Барыбер — сүзең төпсез чыкты!

**Иягенә йодрыгы белән төртә.**

**33. Сарай каласында Идегәйнең элекке йорты тирәсе. Кичке як.**

**Ат менгән Идегәй белән Норадын, Сәлимне ияртеп, Сарай каласының хәрабәләре арасыннан бердәнбер исән калган йортка якынлашалар. Бу — Идегәйнең элекке йорты: Шаһ Тимер аны кияве хакына имин калдырган. Идегәй дә, Норадын белән Сәлим дә бик кәефсез күренәләр: зур дәүләт талашган, ипләрылган, җимерелгән, исән калган халкы кол ителәгән. Урамда аларга бер җан иясе дә очрамый...**

Норадын *(тирә-якка ымлап)*. Ин явыз дошман да болай рәхимсез кыланмый... Аксак Тимер — синең үз биатаң, житмәсә, Идегәй батыр! Халкы булмагач, ни пычагыма кирәк безгә бу җимерек кала? Биатана рәхмәт инде — үз кияве булгач, синең йортка кагылмаган, баш өстебездә түшәм булачак. Өебезгә керергә әнкәй рөхсәт итсә, әлбәттә! *(Ачыргаланып көлә.)* Аның каравы, хәзер бер йортка — бер хансарай туры килә! Юк, ялгышам икән: тагын бер корылма бар бит әле — Аксак Тимернең биш мең кеше башы сөягеннән ясаткан манарасын санарга онытканмын...

**Улының сүзләрен Идегәй караңгы чырай белән тыңлап бара.**

Идегәй. Төчкергәндә төшкән бала кебек шамакайланма, улым!

**Якында гына думбра чиртү ишетелә. Юлчылар, ирексездән, шул якка таба борылып карыйлар: Идегәйләр йорты каршындагы хәрабә кирпечләре өеме өстендә сәләмә киемле бер сәер адәм утыра.**

Идегәй *(гаҗәпләнеп)*. Үргәнеч диванасы Баба-Сәнгү ич бу!

Дивана *(әллә аларны күреп, әллә очраклы туры китереп, җыр башлый)*. Һай-ай!
Бар иде ул Алтын Урда, бар иде алтын чагы;
Тузды алтын базарлары, сүнде ялкынучагы.
Сарае да, Болгары да, Казаны да болганды —
Алары да, болары да, калганы да талганды!
Әмма аның каруы
Азамат ир Идегәй, һа-ай,
Бөтен йортка яр салды:
— Дәвер кемнең дәвере? —
Идегәйнең дәвере!
— Заман кемнең заманы? —
Идегәйнең заманы!

**Идегәйләр аның каршысында туктыйлар; дивана, аларны күргәч, җырын өзә.**

Идегәй. Син мине танныйсыңмы, Баба-Сәнгү?

Дивана *(аңа текәлеп карап тора)*. Ходай үзенә төс биргәчтен ничек танымаска, тиле күрҗә?! Үргәнечтә адашып йөргән томана ич син, сантый.

Идегәй. Ә бер ялгызың нишләп утырасың монда?

Дивана. И аңгыра! Чукрак бугай син? Ишетмисеңмени, җырлап утырам! *(Көлә.)* Ялгыз булмас идем дә, Сарай Бәркәдә минем җыруны тыңларга акыллы кеше калмады. Аксак патша бөтенесен, ясмык үстерергә тирес кирәк, дип Сәмәркандка алып китте. Башта, җиргә яткырып, аларның өсләреннән атлы чирүен үткәрә, аннан соң, шул дымлы урынны сукалатып, ясмык чәчә. Ә миңа тимәде, чөнки мин — аның иң якын дусты хәзер. Менә тыңла: томана булсаң да, түбәнне карабодай курасы белән яптырганга охшыйсың — бераз аңларсың, бәлки! *(Җырлый.)*
Шаһ Тимерне сорасаң —
Аксак патша, олы хан,
Алтын агач тутый кош
Ал тәхетне алдырып,

Ак филенә мендереп,
Эченә үзең кундырып,
Бар казнаны салдырып,
Алды тулы мал белән,
Арты тулы чаң белән,
Тотсактай коллар белән,
Толымлы кызлар белән
Сәмәркандка юл алды...

Төшендеңме инде, түгәрәкли биш кырык сантый?

Идегәй. Төшендем. Хәзер кайда яшисең, изге кеше?

Дивана *(көлә)*. Минем эшләр шәп хәзер! Идегәйнең чибәр хатыны Айтулы мине үзенә йортка кертте! Чөнки якын дустым Аксак патша аның йортын, минем сүзне тыңлап, жимертмәде, белдеңме, алты биш? Ә Идегәй үзе хәзер кыргый киек сыман далада адашып йөри. Кайтса да кертмим мин аны өенә. Айтулы белән үзем туй ясыйм... Шуннан соң түшәк бүлешә башлыйбыз! Ашыйсың киләме? Айтулы шундый тәмле нәрсәләр пешерә! Валлаһи! Тик бармакларыңны ялгыш чәйнәп йотма, йәме, узгынчы? Хуҗабикәнең бер генә начар ягы бар: кич булдымы — миннән төшлек салдыра. Минем маһирлыкны кемнәндер белеп алган да! Идегәен төн саен төшендә күрмәкче, җүләр хатын...

**Идегәй йортына борылып карый: болдырда Айтулы басып тора.**

Айтулы *(тыныч кына)*. Баба-Сәнгү! Нишләп йорт хуҗасын чит кеше кебек урамда тотасың?

Дивана *(аптырап кала: акылдан язган булса да, ул нәрсәдер төшенә)*. Идегәй үземени инде бу сантый?! Китчәле, булмас, Айтулы! Идегәй булса, аңгыра сарык сыман, үз өен танымый тормас иде ул! Башымны катырмачы! *(Думбрасын сөйрәп, җырлыйҗырлый хәрабәләр арасына кереп югала.)*

Дәвер кемнең дәвере?—
Идегәйнең дәвере!..

## 2 бүлек

**34. Идегәйнең йорты. Иртән.**

**Идегәй, биленә кадәр чишенеп, ухылдыйухылдый юына, хатыны Айтулы аңа су салып тора.**

Идегәй. Шулай итеп, бер жариян дә калмадымыни инде хәзер?.. Рәхәттер, ә! Үзең хуҗабикә, үзең — жария...

Айтулы. Кайбер вак-төяк эшләрне Үргәнеч диванасы маташтыра иде... Син кайткач, ул да каядыр сызды.

Идегәй. Төкер танавына... Күбрәк кой суыңны, кызганма... Туктамыш дигән этне дөмектерик башта... Жарияләребез дә житәрлек булыр, калаларыбыз да кабат торгызылыр... Төн койрыксыз түгел, бер таңы бар. Иң элек Туктамышның исән калган колларын җыеп, ирекка чыгарам... Бала-чагаларны, үсмерләрне коллыкка сатуны бетерәм...

Айтулы. Тегеләй итәм, болай итәм, дисең дә... Тимер Котлыйны хан итеп күтәргәч, тешең үтми башласа нишләрсең?

Идегәй. Минем сүздән чыгып, кая бара ала ул... *(Хатыны биргән сөлге белән сөртенә.)*

Норадын *(ашкынып кайтып керә)*. Туктамыш хан кызлары Алтын Ташта икәнлеген ник моңарчы әйтмәдең, әти?!

**Айтулы кинәт иренә сынап карап куя һәм йортка кереп китә.**

Идегәй *(гади генә)*. Һәр кылганымны сиңа әйтергә тиешлегемне баштан чыгарганмын, углым, кичер. *(Елмая.)*

Норадын *(әтисенең шаяртуын үзен мыскыллау дип кабул итә)*. Сәмәркандта сөйләшкәннәрне оныткансың, димәк?

Идегәй. Юк. Анысын онытмадым. *(Улы янына килеп, кулларын аның җилкәсенә куя.)* Тел төбенне яхшы беләм, углым. Ләкин... Тыгызгарак туры килә. Аталары белән араны өзик башта. Хажитарханга Шаһ Тимер Коерчакны калдырган, аның белән дә катгый сүзебез бар. Алтын Урдада хуҗа бер генә булырга тиеш! Аннан соң — рәхим ит, углым, хан кызларының теләсә кайсы белән туй яса. Туең туйга ялганса, тагын да ыграк шат булырмын!

Норадын *(йөзе ачылып китә)*. Идегәй сүземе? Әни белә: минем күңел Ханәкәдә!

Идегәй *(елмая)*. Идегәй сүзе. Бар, Сәлимне уят: чын яугир артын кояшта кыздырып ятмый!

Норадын. Һу! Кем кыздырып яткандыр әле! Сәлим әллә кайчан аяк өстендә инде — һаман якташларын эзли.

**35. Алтын Таш бистәсе капкасы алды. Иртән.**

**Хан бистәсе капкасы алдына шактый күп кеше җыелган: калада күпме халык бар — утырганы, торганы, артына шуганы, дигәндәй — барысы шунда. Халык шау-гөр килә: Идегәйнең Алтын Таштан чыкканын көтәләр.**

— Тагын — сугыш, тагын — яу! Ниткән бетмәгән орыш булды бу?! Кайчан тынычлап яши башларбыз?! Идегәй күренсен генә: якасыннан алабыз!

— Тәләкә кыздырма, картлач! Идегәй безне коллыктан азат итте — шуңа шатлан! Ә Туктамыш хан үзе кол сатып баеп ята иде! Тәвәне төге белән йотар. Соңгы яу булачак монысы. Идегәй үзе шулай дип әйткән. Яу чыкмас иде — Туктамыш исән чакта аңа тынычлык, безнең иеше караларга якты көн булмаячак. Тәгәрә дә үл!

— Хак әйттең!

— Ахмаклар сез! Як-ягыгызга карагыз! Нәрсә күрәсез?

— Нәрсә күрик? Син ни күрсәң, без дә шуны күрәбез.

— Әйе! Сукырлар юк монда. Хәрабә нәрсә ул? Җыйнаулашып тотынсак, элеккедән дә матуррак итеп ясап ташлаячакбыз каланы!

— Тәртә арасы ни әйтер бит әле. Алдан кычкырма!

— Алла бирсә, дигез!

— Алла үзең тырышсаң гына бирә ул. Сез менә Идегәйнең бу яудан исән-имин

кайтуын ялварыгыз. Идегәй теләсә, Алла бирер, теләмәсә — син шунда тәгәрәп үл, хәрабә булып калачак. Бөтен Урдабыз хакында әйткән дә юк!

— Ансын без син әйтмәсәң дә чамалыйбыз. Тәшвиш салма.

— Чү! Ханкапка ачылды!

**Халык тынып кала.**

**Тимердән эшләнгән авыр капка каерылып ике якка ачыла һәм киң утарда баштанаяк коралланган атлы гаскәр күренә. Яугирләр ук-җәя, кылыч, сөңге, гөрзи, балта кебек гадәти коралларданн башка корык, бау сыман яңа төрләләрен дә алганнар. Хан туын күтәргән байракчылар иң алга тезелгән. Арттарак кечерәк әләмнәр җилферди. Байракчылар артыннан Идегәй белән Норадын һәм Тимер Котлый хан килә. Шулар рәтеннән соң ук Сәлим белән бүтән гаскәр башлыклары чыга. Байракчылар капкадан чыгуга, халык төркеме шаулашып Идегәйнең каршысына ташлана, ләкин ике яктан тезелеп килгән эчке казаклар аларны якын да китерми. Халык, шулай да кычкырып, Идегәйне алкышлый.**

— Исән-имин әйләнеп кайт, Идегәй батыр!

— Явың уң булсын! Туктамышның җанын кысып, казнасына баеп кайт!

— Коллар базарын яптырасың икән, хак сүзме бу, Идегәй?

— Ага базарны кабат ачарга кирәк, Ага базарны!

**Әмма Идегәй берсенә дә җавап бирми: ул халыкны кул изәп кенә сәламли. Атлы гаскәр, туктап тормыйча халык төркемен икегә бүлеп, җимерек урамга үтә. Халык төркеме әкренләп артка кала һәм алдан барган байракчылар белән хакимият башлыклары арасы бушап тора. Шулвакыт исәнләмәгәндә әллә кайдан гына Үргәнеч диванасы Баба-Сәнгү килеп чыга һәм Идегәйнең аты алдына нидер ташлый. Казакларның берсе тиз генә диванаыны аты белән читкә кысрыклый, ләкин аны танып өлгергән Идегәй казакны туктата.**

И д е г ә й. Кагылмаска! *(Атын туктата: гаскәр дә туктап кала.)*

Т и м е р К о т л ы й. Туктамыш өстенә яу чапканда Шаһ Тимернең юлын бүлгән дивана түгелме соң бу? Кызык. Шул ук хәл кабатлана!

И д е г ә й. Шул. *(Сакчы казакка).* Нәрсә ыргыткан ул?

**Казак нәреннән үрелеп, дивана ташлаган әйберне ала һәм Идегәйгә күрсәтә: гап-гади куян тәпие икән. Идегәй бармагы белән диванага үзе янына килергә ишарәли.**

Моның белән ни әйтмәкче буласың, безгә, Ходай бәндәсе Баба-Сәнгү?

Д и в а н а *(көлә).* Ыхы-ыхы-ыхы! Үзең бел, Идегәй! Мин сине нишлидер сантый, дип йөри идем, ә син — Идегәй икәнсең! Шулай булгач, үзең бел!

И д е г ә й. Ярый. Дөрес әйтмәсәм, төзәтерсең, йәме? Куян кебек җитез булуыбызны телисең син, шулаймы?

Д и в а н а *(көлә).* Шулай! Ыхы-ыхы-ыхы!

И д е г ә й. Җитезлек безгә Туктамышны ятьрәк куып тотар өчен кирәк булачак, шулаймы?

Д и в а н а *(кулын чәбәкли-чәбәкли көлә).* Белмәдең, белмәдең! Һаман да сантый икәнсең! Ыхы-ыхы-ыхы!

И д е г ә й. Үзең аңлат алайса? Башыбыз җитмәде.

Д и в а н а *(кинәт җитдиләнә).* Тукмак яллы Туратыңнан сора, Идегәй!

И д е г ә й *(җитди).* Тукмак яллы Туратым бик акыллы да, безнечә сөйләшергә өйрәнеп кенә килә шул, Баба-Сәнгү.

Д и в а н а. Ярый, үзем әйтеп бирәм инде, алайсам. Кыр куяны кебек җитез булсаң да, Туктамышны җиңгәннән соң, сиңа барыбер куян бәхете генә тиячәк, белдеңме? Әһә, бүз кебек ап-ак булдыңмы? *(Кулларын чәбәкләп көлә.)* Тагын бер хикмәте бар әле аның! Син үзең дә калган гомереңне Туктамыш хан кебек урын үгиләп йөриячәксең, Идегәй! Шәп әйттемме? *(Кукрәгенә суга.)* Аксак патшаның ахирие Баба-Сәнгү мин! Ыхы-ыхы-ыхы!

Н о р а д ы н *(чыбыркысын күтәрә).* Исән чакта ычкын моннан, ахмак!

И д е г ә й *(ул үзен кулга алып өлгергән).* Бу кешегә кагылмаска!

Д и в а н а *(үзенчә аңлап).* Читләргә үлем янама, Идегәй! Туктамышны да, үзеңне дә иң якын кешеләрең үтерәчәк! *(Кулларын чәбәкләп көлә.)* Ыхы-ыхы-ыхы... Кайгырма: нәселеңдә иң озын гомерле булачаксың син! Моны сиңа Үргәнеч патшасы Баба-Сәнгү әйтә, Идегәй! *(Күкрәген кага.)*

И д е г ә й. Яхшы сүзең өчен рәхмәт, Баба-Сәнгү... Сәфәребез уң булсын дип теләп, догада бул, йәме? Айтулы хуҗабикәң тең ялгыз калды, күз-колак бул. *(Кузгала.)*

Д и в а н а *(шатланып).* Туйны син урап кайткач бергә ясарбыз, алайса, йәме Идегәй батыр! Туктамыш ханның кызлары сиңа була, ә миңа — Айтулыны бирерсең!

**Норадын кинәт әтисенә карап куя.**

*(Кулларын чәбәкли.)* Ыхы-ыхы-ыхы! *(Бии.)*

**Атлы гаскәр Идегәй артыннан кузгала. Дивана, үз уйдырмасына ышанып, бии дә бии.**

**36. Сарай каласы. Көн.**

**Ханнар бистәсенә якынрак тирәләрдә анда-санда кабат торгызылган йортлар күренә. Урамнар кирпеч ватыкларыннан бераз чистартылган. Кайда да кызу төзелеш бара. Халык әкренләп мәмләкәтнең башкаласына кабат кайта башлаган, димәк. Кала бие, хакимлек нәсе кеше буларак, куштаннарын ияртеп зур урамны иңләп бара. Шомалар урамы бу, төзегрәк. Менә ул яңа кирпеч белән сипләнеп яткан бер зур йорт янында туктый: берәү — хуҗа кеше, ахры, озын таягы белән кемнедер кыйнап ята. Кала бие шуны күреп ала.**

К а л а б и е *(кырыс).* Ни эшең бу, Эргәбай би?! Ник кыйныйсың аны?

Эргәбай *(кыйнавыннан туктамый)*. Нишләтсәм дә — үз колым. Юлыңда бул, Алмыш би!

Кала бие *(ысңаура якын пышылдап)*. Мин — кала түрәсе хәзер! Тимер Котлый ханның соңгы әмерен белмисеңмени син?!

Эргәбай *(исе китмичә)*. Белсәм ни?! Колга кагылырга ярамый, имеш! Үз хатынын бер диванага калдырып киткән ахмак Идегәйнең юләр сүзе белән чыгарылган ярлык ич ул! Төкерәм мин аның ише нәрсәләргә!

Кала бие. Тотсакларны ирекә чыгарырга кушылганны да беләсеңме?

Эргәбай. Белсәм?! Тотсаклар — минем шәхси мөлкәтем! Яуда табанлап тапкан мин аларны! *(Башын иеп торган колга сугарга кизәнә.)* Кирпечләрне әрәм-шәрәм итмә, дип ничә кисәттем мин сине, ә?! Кисәттемме?!

Кала бие *(казакларына)*. Бәйләгез үзен! Алтын Таш зинданына ябарга. Иң тирән базга!

Эргәбай *(таңгын күтәргән килеш катып кала)*. Нәрсә дидең?!

**Кораллы ике казак Эргәбай бине, каты тарткалашуына карамастан, кулларыннан тотып, хан бистәсе ягына таба сөйриләр. Төнлектән чыккандай кара кучкыл йөзе тагын да ныграк каралып чыга. Ул, башын артка ташлап, кала биенә кычкыра-кычкыра атлый.**

Мине зинданга яптырасыңмы?! Борынгы нәселдән чыккан иң олуг бине?! Яхшы чакта җибәр мине!.. Онытма, Алмыш би: бүген син кала бие булсаң, иртәгә — коч бездә булыр! Тезләнер көннәрегез алда әле! Ләхет тактам так иткәндә дә онытмыйм мин моны!

**Эргәбай бине, ай-ваена карамастан, Алтын Ташка алып китәләр. Кыйналган кол, шуны гына көткәндәй, урам буйлап йөгерә: кала биенең нярченнәре аның артыннан көлешә-көлешә сызгырып калалар.**

Кала бие *(караңгы чырай белән)*. Нәрсәсе көлке?! Иртәгә җыларга туры килмәгәе! *(Урам буйлап ары китә.)*

**Шулвакыт ерактан, хәрабәләр артыннан сөрән килә: «Халык! Шатлан! Кырымга качкан Туктамышны Идегәй батыр тар-мар итте! Халык! Тагын бер кат шатлан! Идегәй Хаҗитарханда Аксак Тимернең калгае Коерчакны Иделгә ташлады! Индеге көннән Алтын Урда Тимер Котлый олысы дип атала! Ошбу ике олуг шатлык хөрмәтенә уң көн бәйрәм була!» Сөрәнче, хәрабәләр артыннан чабып килеп чыга, кала бие аны кулы белән ишарәләп туктата. Аларны әкренләп халык уратып ала.**

Кала бие *(хәбәрне ничек кабул итәргә дә белми)*. Ниме?.. Хәбәрең хакмы, сөрәнче?

Сөрәнче *(ул һаман да сөрән салгандай бар тамагын киереп кычкыра)*. Хак, кала бие! Бәйрәмгә әзерлән, халык! Тимер Котлый хан белән сәргаскәр Идегәй әмир иртәгә Сарай Бәркәгә кайта!

Кала бие. Нигә тамагыңны киереп бакырасың? Чукраклар юк монда!

**Сөрәнче каушап кала.**

Ниме, дим?.. Туктамыш хан ничек? Ул да үтерелгәнме?

Сөрәнче *(карлыккан тавыш белән)*. Монсыннан мин бихәбәр, Алмыш би. Мин кушылганны гына халыкка җиткерәм.

Кала бие *(ачу белән)*. Ярым-йорты хәбәрең ни пычагыма безгә?! *(Арттырып җибәргәнен тоеп, тавышын йомшарта.)* Ярар, шатлыклы хәбәрең өчен рәхмәт. Сөенечкә — Кала казнасыннан бер алтын алырсың. Юлыңда бул!

Сөрәнче *(йөзе ачылып)*. Тагын йөз җыл яшә, Алмыш би! Рәхмәт! *(Сөрән сала-сала ары чабып китә.)*

Кала бие *(узалдына)*. Дөнья шулай ул, Эргәбай би... Бер алдын, бер артын күрсәтә. Ә син — иртәгә коч бездә булачак, дисең... *(Хан бистәсенә таба кырт борыла.)*

**Халык, икегә аерылып, аңа юл бирә.**

**37. Алтын Таш зинданы. Төн.**

**Авыр тимер ишекне ачы чыелдатып ачып, кулына факел тоткан төрмә каравылчысы идән астындагы зинданга керә. Аңа Кала бие Алмыш би ияргән. Сак кына атлап таш баскычтан тирән зинданга төшәләр. Тимер рәшәткәле авыр ишекләр. Караңгы, юеш.**

Төрмәче. Бу баскычы җимерек, игъләп, Алмыш би...

**Астагы ишек тә авыр шыгырдап ачыла. Тар, караңгы коридор. Юеш дивардар факел яктысында җем-җем килә. Тома тимер ишек янында туктыйлар. Төрмәче зур ачкыч белән тутыккан йозакны ача. Ишек бик кыенлык белән генә ачыла. Эчтә караңгы.**

Кала бие *(кулын суза)*. Ут, үзем генә керәм. Шакырмыйн. Монда икәнлегемне беркем дә белмәсен. *(Эчкә үтә.)*

**Төрмәче ишекне яба һәм аркылы тимер сала. Колак куеп тыңлый. Таш баскычтан югары күтәрелә.**

**38. Зиндан камерасы. Шул ук вакыт.**

**Алмыш би караңгы бүлмәгә керә һәм факелны югары күтәрә: Эргәбай би почмакта идәндә бөгәрләнеп йоклап ята. Затлы бишмәтен астына салган. Ут яктысына кинәт уяна.**

Эргәбай *(шомланып)*. К-кем бар монда?!

Кала бие *(бераз көттереп)*. Курыкма, Эргәбай би. Мин бу, Алмыш би! *(Үз йөзен факел белән яктырта.)*

Эргәбай *(торып баса)*. Ни кирәк сиңа, тамак колы?! Идегәйгә тәлинкә тотарга яңа сәбәп эзләп кердеңме?! Бар, йокы качырып йөрмә монда! *(Алмыш бигә таба төкерә һәм йокларга әзерләнә.)* Ашыкма... Эргәбай би кадерс зинданда череп ятмас! Синең кебек Алладан җәяү качкан этләрне күп күрде абзагыз!

Кала бие. Ниме?.. Күселәр борчымыймы, Эргәбай би?

**Эргәбай дәшми. Алмыш би аңа якынрак килә.**

*(Ишек ягына борылып карый һәм тиз-тиз пышылдый.)* Кичерә күр мине, Эргәбай би... Шулай кирәк булды. Идегәйне бүген халык Алла урынына күрә. Ә бәкләрне аннан биздерергә кирәк! Без әкрен кыймылдарга өйрәнгән халык. Борыныбыз белән эт тизәгенә төртмичә, акылга килмибез. Сине монда япканны белгәч, акчуралар кырмыска оясына таяк тыккан кебек тузынды! Бары да Идегәйне эт итеп сүгә! Менә нәрсә өчен тыктым мин сине бу таш капчыкка, Эргәбай би! *(Әкрен генә көлә.)*

Эргәбай. Ни мыгырдыйсың, ашаган табагына аай иткән мөртәт! Табынымда жигән ризыкларыңны костырам әле мин синнән!

Кала бие *(аның янына чүгәли)*. Мин юри генә — Идегәйнең колы булдым бит. Ә халык моны белми: калада ни генә кылынса да, аның ихтыяры белән эшләнгән булып санала. Борчылма, Эргәбай би: аксөякләрнең Идегәйгә каршы ташы кызып җитсен, шундук йолып алабыз без сине моннан. Бүгенге өчен үпкәләмә, тамак ягы такыр монда, иртәгә иртүк үз табынымнан китертәм мин сиңа тәмле ризыклар.

**Эргәбай би аңа ышаныр-ышанмас торып утыра.**

Күнче солтан абыйсына каршы көч туплый икән. Күчмән әмирләр дә аның белән бер авызда: Тәңре янына киткән олугларны корган өеп җирләүне Идегәйнең тыюы беркемгә дә көтеп арган шатлык түгел! Мөэмин мөселманча чардуган кую бик җиткән, имеш. Күпмегә чыдый ул?! Ун-егерме елдан кемнең каберен кем беләчәк?! Кара халык белән бертигез ясау ич бу! Шуңа күрә әмирләрнең күбесе күтәрелергә җай гына көтеп тора. Безгә дә форсатка әзер булырга кирәк. Әлегә бераз иртәрәк — Идегәйнең бүресе улаган чак. Туктамыш булып, Туктамышны җиңеп кайтып ята...

Эргәбай. Туктамышны үтергәнме?!

Кала бие. Әлегә ачыгы билгесез... Мин үзем болай уйлыйм, Эргәбай: ни ул, исән калган! Сөрән салырлар иде. Ярый, мин киттем, сизенүләре бар... *(Тора.)* Ә! Нитәбез. Син миңа ташлангандай ит, ә мин төрмәчегә ярдәм сорап кычкырган булып кыланам...

Эргәбай. Ни пычагыма?

Кала бие. Картаясың икән, Эргәбай би! Яшерен сөйләштеләр, димәсеннәр. Йә, ябеш якага. *(Елмая.)* Кара аны, артыграк кыланып ялгыш буып ташлама! Тиз кылан, болай да озакланды...

**Эргәбай би сикереп торып, чын-чынлап кала биенең бугазына ябыша: Алмыш биенең тавышы табигый гырылдап чыга.**

Ярдәм итег... гез! Тотсак миң... не үтерә! *(Каушап, көч-хәл белән ишеккә таба чигенә.)* Син нәрсә?! Ни бит... Син... нәр...сә?! Үтерә... ләр! *(Ишеккә арты белән бәрә.)*

**Аркылы тимернең шалтырап таш идәнгә төшкәне ишетелә.**

**Һәм төрмәче атылып килеп керә. Тарткалашучыларны араларга тотына, барып чыкмагач, Алмыш биенең кулыннан төшеп киткән факелны идәннән алып, Эргәбайның битенә селтәнә: Эргәбай би шунда гына кулларын Алмыш биенең муеныннан ычкындыра.**

Эргәбай. Тавис кауырыйлары такчы козгын!

Төрмәче. Әй, син! Олуг би дип тормам! Тагын берәр сүз дәшсәң, атна буе суга тилмертәчәкмен! *(Алмыш бигә.)* Янына якын бара күрмә, дип кисәткән идем ич мин сине, Алмыш би! Тоткын кешегә нәрсә ана! Аның югалтасы юк. Барыбер башы киселәчәк. Йә — сөяге шушында черячәк. Шулай саксыз кылану ярыймы инде?

Эргәбай *(көлә)*. Ничек? Кеше ышанырлык чыктымы? Әҗере генә әле бу, Алмыш би!

Кала бие *(ниһаять, телгә килә)*. Кабәхәт!.. Күрсәтермен әле мин сиңа... *(Бармагы белән диварда асылынып торган чылбырга күрсәтә.)* Чылбырга утыртырга! *(Кырт борылып, ишеккә юнәлә.)*

**Эргәбай би кычкырып көлеп кала.**

**39. Алтын Таш хансарайда диванханә. Кичке як.**

**Диванханә бәйрәм мәҗлесе өчен көйләнгән: ярым түгәрәк рәвештә диварларга якын итеп тезелгән тәбәнәк өстәлләрдә күз күрмәгән, колак ишетмәгән затлы ашамлыклар, һәр өстәл янында чапчак-чапчак эчемлекләр. Түр өстәлләренең икесе биегрәк урында: алары — Тимер Котлый хан белән сәргаскәр Идегәй өчен куелган. Идегәй ханның уң кулында. Аның сул ягында — хатыннары Айтулы, Акбеләк һәм тагын безгә таныш булмаган ике яшь хатыны. Шулар рәтендә үк Нораддын урнашкан. Тимер Котлый ханның хатыннары уң якта. Мәҗлескә, болардан тыш, гаскәр башлыклары, илнең олуглары, әмирләр, сәедләр, бәкләр һәм шуларише күренекле кунаклар җыелган. Барысы да идәнгә җәелгән озын келәмдә аякларын бөкләп утыралар. Тимер Котлый хан гына тәхет сыман итеп эшләнгән тәбәнәк утыргычка аякларын бөкләп менеп кунаклаган. Һәр кунакның артында гаянгыч меңдәрчекләр.**

**Сылу гәүдәле җарияләр һәм кәнизәкләр бертуктаусыз төрле-төрле ашамлыклар ташып торалар: уртага искиткеч матур зур келәмнәр җәелгән, шуңа күрә аларның тыз-быз йөрүе сизелми дә. Өстәлләр янына куелган бал-буза чапчаклары кырына шундый ук чибәрләр тезләнгән: алар өрөзлексез алтын җамаякларга эчемлек коялар. Кайдандыр талгын моң агыла, ярымшәрә кызлар, сөяксез сөлектәй сыгылмалы гәүдәләрен салмак хәрәкәтләндереп, әкрен генә биләр.**

**Тимер Котлый ханга эчемлекне махсус билгеләнгән аякчы салып бирен тора: ул — бүре ыруы егете Сәлим. Сәлим, йола буенча, эчемлекне башта учына агызып йотып куя** *(агуланмаган, янәсе)*, **аннан соң ханга бирә.**

Тимер Котлый *(энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән алтын касәдән эчемлекне бик аз гена эчә)*. Меңбашы Сәлим бабыр! Син орыш кырында күп тапкырлар чын яугир икәнлегеңне раследың. Шуңа күрә без сине бүген үзебезгә аякчы итеп куйдык. Инде

хәзер зирәклегеңне дә беләсебез килә. Саркытымны иң беренче нәүбәттә без кемгә бирергә телибез, әйтеп бирә алырсыңмы шуны?

Сәлим *(ханга йөгенә һәм аның кулыннан касәне ала).* Беренче саркыт — сәргаскәр Идегәй батыргадыр дип уйлыйм, бөек хан!

Тимер Котлый *(елмая).* Хуп мәйле, Сәлим батыр! Беренче уебызны укый алдың. *(Идегәйгә.)* Рәхим ит, сәргаскәр: беренче саркытым, чынлап та, сиңа ниятләнгән иде. Тау сиңа!

Идегәй. Тәхетең астында тузсын, Тимер Котлый хан. *(Касәне алып эчә.)*

Мәҗлес *(барысы бергә).* Тау сиңа, Идегәй батыр! Тагын йөз җыл яшә!

**Хан Сәлимгә касәне тагын тутырырга ымлый. Сәлим эчемлек коя һәм, агуламадым, дип ритуалны кабатлый.**

Тимер Котлый *(касәне алып, йотып куя).* Ә икенче саркытыбыз кемгә ниятләнде икән, аякчы?

Сәлим *(касәне ала һәм аз гына уйланып тора).* Орыш батыры Норадын бәккә, минемчә!

Тимер Котлый *(көлеп җибәрә).* Бераз ялгыштың бу юлы, аякчым! Орыш кырында — син бик күпләргә тиңсез батыр, әмма ханыңның уен тиз чамалар өчен тәҗрибәң җитенкерәми икән...

**Залда тынлык урнаша: ханның әйтеп бетергәнен көтәләр.**

**Һәркем үз исемен әйтер дип уйлый. Норадын, тиресеннән атылып чыгардай бүртенеп, башын аска ия.**

Син хаклы: Норадын батыр, һичшиксез, икенче саркытабызга бик лаек. Әмма бүген монда аңа тиң тагын бер батырыбыз бар. Шулай булгач, Норадын батыр безгә үпкәләмәс. Ул кеше... син үзең, аякчым! Тау сиңа!

**Зал шым була: хәтта музыка да туктый, биючеләр шул мизгелдә алган позаларында катып калалар.**

Сәлим *(югалып).* Кичер, бөек хан... Мин моңа лаек түгел! *(Тирән итеп йөгенә.)*

Тимер Котлый *(кырыс).* Хан сүзе беркайчан да егылмый, аякчы.

Норадын *(авыр тынлыкны өзеп, чын күңелдән кычкырып җибәрә).* Тау сиңа, меңбашы Сәлим батыр!

Мәҗлес *(дәррәү аңа кушыла).* Тау сиңа, Сәлим батыр!

Сәлим *(дулкынлануын яшерә алмый).* Рәхмәт, бөек хан... Ходай сиңа озын гомер бирсен! Барыгызга да исәнлек-саулык! *(Хан саркытын эчеп бетерә.)*

Тимер Котлый. Касәне үзеңә калдыр — миннән сиңа бүләк ул. Аякчыга махсус өстәл!

**Сарай хезмәтчеләре шундук каяндыр ризык-нигъмәтләр куелган өстәл чыгарып, хан каршысына бастыралар.**

Тимер Котлый. Аша-эч, Сәлим батыр. Аяк ялы булсын!

**Каушап төшкән Сәлим, ханга йөгенеп, аңа таба карап утыра. Кунаклар ашау-эчүне дәвам итәләр.**

Тимер Котлый. Мәҗлесебезне матур дәвам итәр өчен, хәзер без үзебезгә икенче аякчы билгеләргә булдык. Ул... Норадын батыр!

**Барысы да Норадын утырган өстәл ягына борылып карыйлар: аның өстәле буш. Тынып калалар. Кемнәрдер чыш-пыш сөйләшә...**

Тимер Котлый. Җавабыңны ишетмибез, Норадын батыр? *(Ул шунда гына борылып карый һәм Норадынның югалганлыгын күрә.)* Моны ничек аңларга, Норадынның этисе Идегәй әмир?

Идегәй *(елмая).* Мәҗлесебез шактый озакка сузылды бит, Тимер Котлый хан: ханнар да җәяү йөри торган җиргә чыккандыр?

Тимер Котлый. Була торган хәл! *(Көлә.)*

**Көлешәләр.**

Акбеләк *(үз алдына сөйләнгәндәй, әмма бөтен мәҗлес ишетерлек итеп).* Норадын урынында булсам, мин дә чыгып китәр идем.

**Бу — дөньяда булмаган әдәпсезлек: бөтен мәҗлес башта тынып кала, аннан соң көчле гөҗләү башлана. Идегәйнең кече хатыннары өйдәшләре Акбеләккә шаккатып карыйлар. Хан Идегәйгә текәлә.**

Тимер Котлый *(ул, каушап, хуҗа булуын да онытa, ахры).* Э... Тавыклар әтәч булып кычкыра башлады түгелме?!

**Көлешәләр.**

Идегәй. Нишлисең бит, Тимер Котлый хан: быел — тавык җылы ич!

**Сирәк-сирәк көлешү.**

*(Елмая.)* Тавык йомырка салса, әтәчнең арты каный: безгә бик азга гына мәҗлесне калдырып торырга рөхсәт итче?

Тимер Котлый *(сәргаскәрнең уңайсыз хәлгә калуына сөенгәндәй, көлә).* Әлбәттә рөхсәт, Идегәй агам!.. Туган-тумачалар арасында ич син!

**Идегәйнең оятка калуына сөенүчеләр чыш-пыш киләләр. Идегәй торып Акбеләк янына килә һәм аның колагына нидер пышылдый. Хатыны ризасызлык белән авызын ача, ләкин, иренең усал карашын күреп, сикереп тора һәм ишеккә юнәлә.**

**40. Анфилада рәвешендә төзелгән бүлмәләрнең берсе. Шул ук вакыт.**

**Хатынының һәм улының кыланышыннан чыгырыннан чыгарга җитешкән Идегәй кызу-кызу алдан атлый. Акбеләк, нидер әйтергә теләп, иренең җиңеннән тота.**

**Идегәй** *(борылып та тормыйча)*. Атлавыңны бел, ояңны пычраткан тавык!

**Акбеләк** *(горур)*. Мин — дөньяның яртысын буйсындырган Шаh Тимернең кызы! Ә син — аның ярдәме белән аруга чыгып...

**Идегәй** *(хәнҗәрен кынынннан суырып алып, хатынына таба җәһәт борыла)*. Тагын берәр сүз дәшсәң! Чонтык аяклы атаң яу теләсә — мин әзер! Иртәгә үк йортыңа кайтып китәсең! Сүземне атаңа җиткер! *(Кырт борылып, алга үтә.)*

**Каршыларына Норадын очрый: аның кулында канга баткан кылыч. Кынына да тыгып тормаган. Норадын куркуга төшкән Туктамыш хан кызларын нәрткән. Идегәй гаҗәпләнеп туктый.**

**Идегәй.** Ни эшең бу, улым?! Кем җанын кыйдың?!

**Норадын** *(елмая)*. Тимер Котлый ханга ярамасам, Туктамыш хан кызлары йөз чөермәс, бәлки! Борчылма, Идегәй батыр: Ханәкә белән Төнәкәне бүлмәләреннән чыгармый тоткан шыгавылның каны гына ул. *(Кылычын кедәмгә сөртеп, кынына тыга.)* Аталарын җиңү хөрмәтенә җыелган мәҗлестә кызларына урын табылырга тиештер, минемчә!

**Идегәй** *(кызларга кискен)*. Үз бүлмәгезгә барыгыз! *(Норадын хан кызларын үзе белән әйди)*. Ишеттегезме?

**Кызлар шатланышып кире йөгерәләр.**

**Норадын.** Идегәй батыр дигән абруйлы атыңа таянасыңмы, әти?

**Идегәй.** Шаh Тимергә илче булып китәргә әзерлән. Иртәгә юлга чыгасың. *(Акбеләккә ымлый.)* Аны да үзең белән аласың. Башкасын иртән вәзенләп сөйләшербез!

**Норадын** *(аптырап кала, әмма бик тиз ушына килә)*. Улыңа үлем эзлисең, димәк, Идегәй батыр?

**Идегәй.** Юкны чәйнәмә! Илчегә үлем юк!

**Норадын.** Сөйлә, сөйлә! Туктамыш хан минем күз алдымда бик аз илченең башына җитте бит. Син, Сәмәрканд патшасының фәрманын санга сукмыйча, куеп киткән калгаен мәче баласы шикелле суга батырдың. Үз углыңны шуннан соң аның кулына тапшырасың! Кызын тотсак ит hич булмаса!

**Акбеләк.** Мин монда бер көн дә тормыйм! *(Китеп бара.)*

**Идегәй** *(хатыны артыннан бераз карап торгач, аптырагандай маңгаен уа)*. Син хаклы, углым... Иртә кичтән хәерлерәк. Уйлашырбыз. Ә мәҗлескә кабат кереп йөрмә. *(Улын калдырып, мәҗлес залына китә.)*

**41. Аш залы. Иртән.**

**Залда Тимер Котлый хан белән Идегәй әмир генә. Алар ашап туйганнар инде, чәмчеиеп кенә утыралар.**

**Идегәй** *(торып йөри)*. Хан! Күнче энекәшебез белән нишлибез?

**Тимер Котлый.** Нишләргә дә белгән юк инде аның белән! Күк Урда тәхетен сорады — бирдек... Нәрсә житми аңа?! Тегевакытны безнең өстән Аксак Тимергә пычрак әләк җибәргән иде, ярый шымчының юлын кисеп өлгердек. Инде тагын... әмирләр арасында коткы оештыра, имеш...

**Идегәй.** Имеш түгел — хак хәбәр, хан. Итәк астыннан ут йөртеп, Шаh Тимер белән яшертен әшнәлек итеп ятуы да раст. Туктамышның Кырымнан качкан бер көчеге дә Сәмәркандта. Үзебездән илче җибәрергә кирәк дигән фикердә мин. Норадын углымны күндерергә исәп. Ни өчен дигәндә, тәвәккәл таш яра. Раст, бердәнбер углыбызны аңа ышанып җибәрәбез — гайрәтебез бар дигән сүз. Икенчедән, Шаh Тимер тиздән Һиндстанга яу чапмакчы икән, кайгысы бездә түгелдер. Кылны кырыкка ярыр чагы. Урдабызның канаты астыннан чыгуын, күтә түгел, таныргә мәҗбүр булыр! Акбеләк тә илчебез белән бергә әтисенә кунакка китмәкче иде дә... Әлегә монда калуы хәерлерәк.

**Тимер Котлый.** Бусы белән килешәм, агам. Туктамышның углына килгәндә... Әтисе дә качак, үзе дә качак, дигәндәй... Арбадан төшеп калган кемсәләр хәзер! *(Елмая.)*

**Идегәй** *(уйланып)*. Җан биреп ятканда да арысланда ун сарыкны бугазларлык гайрәт кала, хан.

**Ишектә шыгавыл күренә.**

**Шыгавыл.** Кала бәге Алмыш би!

**Идегәй кашларын җыера: ханның соралы карашын күргәч, кул гына селти.**

**Тимер Котлый.** Керсен.

**Алмыш** *(кереп йогена)*. Иртүк бимазаларга базганым өчен кичер, бөек хан.

**Тимер Котлый.** Тыңлыйбыз сине, кала бие.

**Алмыш.** Бөек хан! Олуг бәйрәм көннәре. Зинданда тоткыннар шактый күп. Гореф буенча, ханнар олуг бәйрәм хакына аларны ярлыкалыйлар иде. Фәрман булырмы?

**Тимер Котлый** *(Идегәйгә карап)*. Ә...

**Идегәй.** Без әле генә хан белән шул хакта кинәш тотып тора идек, Алмыш би, ярлыкау игълан ит барысына да.

**Алмыш** *(икеләнеп)*. Кичерегез... Ни бит, Идегәй әмир... Тоткыннар арасында үтә хәтәр җинаятьчеләр дә бар... Берсе бигрәк тә...

**Тимер Котлый.** Кем ул? Без беләбезме аны?

**Алмыш.** Эргәбай атлы би. Синең гадел ярлыгыңа төкереп, колларын иреккә чыгармаган. Халыкны ачыктан-ачык икегезгә каршы күтәрергә маташа. Тотып алгач та, сезне мәсхәраләп, әллә ниләр кычкырды. Барыбер сезнең көннәр санаулы, янәсе!

**Тимер Котлый.** Моның өчен нинди җәза каралган?

**Алмыш.** Халык алдында башы чабылып, мал-мөлкәте хан казнасына алынырга тиеш, бөек хан.

**Тимер Котлый** *(Идегәйгә карый)*. Гаебе бик җитди икән дә...

**Идегәй.** Әйе, хан. Гаебе бик җитди. Шулай да, гадел хөкемнә кушылам: Эргәбай бине ярлыкау зирәк хакимлек итүнең билгесе. Халык хуплаячак моны.

Тимер Котлый. Мин дә шулай уйлыйм. Тагын нәрсә, кала бие?

Алмыш *(аңа китәргә генә кала)*. Фәрманың үтәлер, бөек хан. *(Хан белән Идегәйгә йөгенеп, артка чигенеп чыга.)*

Тимер Котлый. Мин синең тәҗрибәгә таянам, агам ... Ләкин... Хаталык кылмадыкмы?

Идегәй. Кылмадык, хан. Без монда — яңа кешеләр. Халык безнең турыда фикерне беренче адымыбызга карап йөртәчәк. Эргәбай би — олуглар арасында абруйлы. Эргәбай бинең башы безгә бик кыйммәткә төшәр иде!

Тимер Котлый. Үзең кара инде, агам. Димәк, килештек: углың Норадын Сәмәркандка илче булып китә. *(Өстәл артыннан кузгала.)*

Идегәй. Хәл итәсе нәрсәләр бетмәде, хан. Мәскәү кенәзе Дмитрий углы Василий белән ачык аңлашыр чак җитте. Шаһ Тимернең явыннан файдаланып, урыс йортбасарлары Болгарны бер кат талап киткәннәр иде — берничек тә җавап бирмәде! Василийны хозурыбызга чакыртып, илче юллау дөрес булыр. Кичектермик. Калган эшкә кар ява! Ишетүемчә, урыс ушкуйчылары кабат Чулман тирәләренә килеп чыкканнар. Үләксә көткән козгыннар кеби, олысларыбызның көчсезләнгәнен сагалап кына яталар. Василий бу юлы да сүзебезгә колак салмаса — Мәскәүгә яу чабачакбыз! Йомшак агачны корт баса.

Тимер Котлый. Дмитрий углы Василий тәхет ярлыгын Туктамыш ханнан алды. Аны үзебезгә каратып булырмы, агам?

Идегәй. Алтын Урда индеге көндә — Тимер Котлый олысы атала. Шулай булгач, ул кем каршына басарга тиеш?

Тимер Котлый *(уйланып)*. Димәк — Мәскәүгә яу.

Идегәй *(елмая)*. Василийның тәртәгә тибү-типмәве хәл итәчәк моны, хан... Безгә дә ял кирәк бит!

**42. Вильно. Бөек Витовт кенәз резиденциясе. Көн.**

**Литва-Урыс кенәзлегенең бөек кенәзе Витовт үз пулатында Туктамыш ханны бергәбер кабул итә. Витовт олы гәүдәле, тәкәббер карашлы, кыю һәм үзенә артык нык ышанган тәвәккәл кеше. Ул Туктамыш белән тигез дәрәҗәдә сөйләшсә дә, вакыты-вакыты белән аның язмышы үз кулында икәнлеген сиздереп куя.**

Витовт *(бер урында утырып тора алмый)*. Яхшы, кадерле кунагым Туктамыш патша, мин сиңа Алтын Урда тәхетен кайтарып бирәм. Сараеңны да, Болгарыңны да. Аждаркан белән Азак та үзеңә булыр. Җаек арты да. Ә син үзең миңа ни вәгъдә итәсең, Туктамыш патша? Гаскәрең кырык мең чамасы бит әле синең?

Туктамыш *(ул утырып тора, шуңа күрә үзен биек гәүдәле Витовт алдында бераз уңайсыз тота)*. Әйе, әлегә чирүем дүрт сан гына, бөек кенәз Витовт... Әмма мин — өч меңле гаскәрем белән урыслардан бүтән беркемгә җиңелмәгән Мамай әмирне тиз чүктергән хан. Идегәй атлы бер кемсәнең кара мәкерлеге аркасында...

Витовт *(тынычлык бирми мазалаган чебенне куалагандай)*. Бик яхшы беләм, кунагым! Ләкин... үткән-беткән! Элекке каһарманлыкларыбыз белән шапырынып чакмы? Мин дә — кайчандыр Тевтон Орденының муенын сындырган идем, ә ул бу көндә кабат терелеп, миңа кабат күсәк яный! Кичер, хан, бу сүзләрем белән сине кимсетергә теләмим мин. Син кайчандыр сөйгән кызым Софья белән киявем — Мәскәү кенәзе Василий Дмитриевичны өч ай кадерләп сый иткән патша. Кызым әлегә кадәр шул чакларын матур итеп искә төшерә... *(Көлә.)* Бигрәк тә көзгеле идәнеңне мактый. Бөтен нәрсә ялт итеп күренеп торамы, хан!

Туктамыш *(җитди)*. Кунак ашы — кара каршы, бөек кенәз. Тузан астын актармыйк, булмаса. Сыеныр урын эзләгән кенәмдә син мине үз җиреңә керттең, тукланырга Лида каласын бирдең... Әгәр дә Тәңрем миңа багышлаган тәхетемне кайтарып бирсәң, мин сиңа... Бөек Новгород белән Псковны багышлармын, Аллаһы боерса. Немецларны да...

Витовт. Юк, хан! Немецларны мин үзем акылга утыртачакмын! Мәскәү кенәзе ит син мине!

Туктамыш. Анда — синең киявең утыра ич?!

Витовт. Шул — киртәме? Тәхете сумалалы түгелдер ич? *(Көлә.)* Юкса... Алтын Урдада хәзер кем төп хан икәнлеге дә билгесез, дип зарлана. *(Кинәт җитдиләнә.)* Мәскәүнең Бөек кенәзе ит син мине! Псков белән Бөек Новгородны бир. Тверь, Рязань — болай да минекеләр. Киев, Смоленск, Рыльск, Волынь кенәзлекләре — күптән минем вассалларым. Бөек Литва-Урыс дәүләте тәэзергә телим мин! Синең белән якын дус булырга! Тик моны, патша, син бел дә мин бел!

**Туктамыш хан уйга кала.**

**43. Алтын Таш утары. Көн.**

**Хансарайдан чыгып килгән Идегәй каршына төрмә бие йөгереп килә.**

Төрмәче. Идегәй әмир! Сәргаскәр! Эшләр харап!

Идегәй *(салкын)*. Кабаланмыйча гына сөйлә, төрмә бие.

Төрмәче *(авыр сулап)*. Бүген иртән, хан фәрманын үтәп, зиндандагы тоткыннарны иреккә чыгардык. Соңгы булып Эргәбай би калган иде... Ишеген ачып керсәк — агулап үтерелгән! Нишләргә дә аптыраш!

Идегәй. Үтерелгәнен каян беләсең?

Төрмәче. И Идегәй әмир! Төрмә бие булуыма беренче көн түгел ич!

Идегәй. Кем эше?

Төрмәче *(пышылдап)*. Иртәнчәк Алмыш би аңа үз өеннән ризык китерткән иде...

Идегәй. Кем рөхсәте белән?

Төрмәче *(каушап)*. Соң бит... Элек-электән кала биләре...

Идегәй. Алмыш би үзе кайда?!

Төрмәче. Белмибез, Идегәй әмир... Кичәдән бирле аны күрүче булмаган... Өенә кеше җибәргән идем — тапмыйча кайтты. Кала гөж килә! Эргәбай — зур ыру башы

иде бит. Нәсел-нәсәп агачы, дигәндәй... Кайбер әмирләр каланы ташлап киткәннәр, имеш...

**Идегәй, аны тыңлап бетермичә, Хансарайга кереп китә.**

**44. Тимер Котлый хан мунчасы. Шул ук вакыт.**

**Тимер Котлый калын келәм җәелгән сәкедә кальян тартып утыра. Кәнизәкләре аңа мунча әзерлиләр: кайсы кайнар су ташый, кайсы хуш исле үләннәр кертә һ. б.**

Идегәй *(атылып килеп керә).* Көш! *(Кулы белән ишарә ясауга, кәнизәкләр юк булалар.)*

Тимер Котлый. Мунча керергә дә ирек бирмәскә булгансың, ахры, син ханыңа, агам!

Идегәй. Үпкәләшер чак түгел, хан: Эргәбай бине зинданда үтергәннәр.

Тимер Котлый *(кул селти).* Ә! Бер би артык, бер би ким... *(Кальянын суыра.)* Кем иде әле ул? Исеме таныш кебек...

Идегәй *(кулыннан кальян марҗугын тартып ала).* Бүген — сират күперен үтәсе көнебез, хан! Эргәбай — Урдабызның иң атаклы бие иде! Артында уңлаган әмир тора! Аның үлемен синең белән миңа аударачаклар. Чарасын тапмасак — атыңны иярләтергә генә кала!

Тимер Котлый *(сәкедән төшә).* Баштук шулай аңлаталар аны, агам! Киңәшең?

**Ишектә шыгавыл күренә.**

Шыгавыл. Вильнудан атчабар, бөек хан!

Тимер Котлый. Юк бул!

Идегәй. Тукта, хан: керсен!

Атчабар *(керен йөгенә).* Бөек хан! Туктамыш хан, Литва кенәзе Витаускас белән берләшеп, Урдабызга бәреп керде. Гаскәрләре — кырык төмән!

Идегәй. Кай төштән?

Атчабар. Мин кайтыр юлга чыкканда Ворскла елгасы ярында чатыр корып калдылар.

Идегәй. Китәргә мөмкин.

**Атчабар, икесенә берьюлы йөгенеп, чыга.**

Тимер Котлый. Кырык сан гаскәр! Йа, Хода! Менә хәзер, чыннан да, моннан үкчәбезне күтәрергә вакыт!

Идегәй *(күңеле күтәрелгән).* Утала күрергә ашыкма, хан! Шымчының хәбәре бик вакытлы килеп җитте. Вак мәшәкатьне зуры каплый! Яуга әзерләнергә фәрман бир! Нурадын урынына Шаһ Тимергә илче итеп бүтән кеше җибәр — улым яуда кирәк. Энекәшебез Күнче солтан да соңгы тапкыр шунда сыналыр!

**45. Ворскла елгасы буенда Витовт чатыры. Көн.**

**Витаускас чатырында мәҗлес. Туктамыш хан, Идегәйнең сот тугany Исабәк би һәм Туктамыш ханның баш вәзире Кин Җанбай да шундалар. Литва кенәзенең кәефе шәп, Туктамыш ханның күңеле төшенке күренә.**

Витовт. Туктамыш патша! Зур орышны үзең теләдең. Ник кәефең начар? Нәрсә борчый сине? Орыш аягы шикләндерсә, уфтанма! Аша-эч! Болай бер дә ошамыйсың син миңа! *(Көлә.)*

Туктамыш. Орыш нәтиҗәсе борчымый мине, бөек кенәз. Көчебезгә ышанам! Тик... ни көтәбез без бу сазлыкта? Нишләп туп-туры Сарайга яу чапмыйбыз?

Җанбай. Кичер, ханиям. Син дә, зинһар, кичерә күр, Витаускас кенәз... Урда сәргаскәре Идегәй белән йөзгә-йөз очрашуга алай бик үк җиңел карамас идем мин.

Витовт *(мыскыллы караш ташлый).* Кем син? Ике патша сөйләшүен бүлдерергә кем рөхсәт итте?!

Туктамыш. Ачуланма, бөек кенәз: минем баш вәзирем Җанбай би ул. Идегәй, чыннан да, каты чикләвек. Монда аның сөт туганы Исабәк би утыра. Сүземне ул да раслар.

**Исабәк бөек кенәзгә баш ия.**

Витовт. Кем соң ул — Идегәй? Ничә яшьтә? Европа нишләп аны белми?

Туктамыш. Яше шактый инде аның. Иллене узган кеше. Мине куып килә.

Витовт. Иллене узган кеше?! *(Көлә.)* Илле яшькә җиткән кешене бездә хәтта көрәш уены мәйданына да кертмиләр! Яшьрәк батырлар бил алышканны карап кына утыр, дип куып кына җибәрәләр!

**Сөрәнче тавышы: «Алтын Урда каганы Тимер Котлыгтан илче!» Чатырда җанлану башлана. Туктамыш хан урынында кымырҗып куя. Иярченнәре бер-берсенә карашалар.**

Витовт. Әһә! Яшь тәхет карагының тәртәсе сынды! Менә нәрсәне көттем мин, Туктамыш патша. Аның гайрәтен сындырсым килде! *(Ишек ягына карамыйча гына кычкыра.)* Хан илчесен кертергә!

**Чатырга Сәлим керә һәм, дәрәҗәсен тотарга тырышып, барысына берьюлы баш ия.**

Сәлим. Бөек кенәз! Алтын Урда ханы Тимер Котлый сиңа озын гомер, исәнлек-саулык һәм уңышлар тели.

Витовт. Уңышлар тели? Үзенә каршы орыштамы? *(Кычкырып көлә.)*

Сәлим *(кенәзнең дорфалыгына исе китми).* Шуңа өстәп әйтергә боерган сүзләре мондый: «Бөек Литва кенәзе Витаускас! Миңа качак Туктамышны тотып бир — ул минем дошманым. Аның синдә сыенып яшәвен ишетеп, түзеп тора алмыйм!»

**Туктамыш хан нидер әйтмәкче булып талпынып куя.**

Витовт *(кулы белән аңа сабыр булырга куша, ачу белән).* Минем кадерле кунагымны мәсхәрәләгән сүзләрең өчен мин сине ник туганыңа үкенерлек җәзаларга тиеш, илче! Бәхетең... Тәхет карагы Тимер Котлыйга минем җавабымны тапшырасың бар. Мин Туктамыш патшаны бирмим, ә Тимер

Котлый патшаны үземнең күрәсем килә! Сүземне сүзгә-сүз тапшыр мәнсез хуҗана.

Сәлим. Тапшырылыр, кенәз. *(Җиңелчә баш иеп, чатырдан чыга.)*

Туктамыш. Катгый җавабың өчен рәхмәт, Витовт кенәз... Ләкин... илченең авызыннан чыккан сүзләр Идегәйнеке түгел, минемчә. Ул кемсә — турыдан-туры орышка көчәр иде. Гаскәр белән килеп җитмәгән ул, димәк. Шушы әйбәт форсаттан файдаланыйк!

Витовт. Тимер Котлыйның җавабын ишетик!

**46. Ворскла елгасы. Иртән.**

**Тар елганың бер ярында — Тимер Котлый хан, каршы якта — Литва кенәзе Витовт. Икесенең дә нярченнәре бераз читтәрәк.**

Витовт. Тимер Котлый патша! Илченнең дорфа сүзләрен ишеттек, син дә минем җавапны алгансыңдыр. Инде хәзер тагын ни әйтәсең бар мина?

Тимер Котлый. Бөек кенәз Витаускас! Мин синең җирләреңә басып кермәдем, ник син минем биләмәләремне чирүең белән таптыйсың?

Витовт. Алла миңа ай астындагы бөтен җирләрне буйсындырды. Син дә миңа буйсын һәм тугры углым бул! Ә мин сиңа — яхшы ата булырмын. Миңа ел саен ясак һәм салым түләп тор. Әгәр дә сүземне тыңламасаң, миңа кол булырсың. Ә Урдаңны кылычтан үткәрермен!

Тимер Котлый *(бераз каушап)*. Таләпләрең үтә җитди, сүзләрең күктәге Нәйзә агай сөңгеседәй кадаулы, бөек кенәз! Уйланырга бер көн бир миңа.

Витовт. Бер көн бик күп, хан! Соңгы җавабыңны бүген кич шушында көтәчәкмен. Аннан соң — үзеңә үпкәлә! Син төлке булсаң, мин — аның койрыгы! *(Атын кисәк борып, чабып китә.)*

**47. Тимер Котлый чатыры. Көн.**

**Хан чатырында көчле бәхәс купкан: Алтын Урданың гаскәр башлыклары шактый зур паникага бирелгәннәр. Идегәй белән Норадын анда юк. Шулай да, кайберләре Витовтка орыш белән җавап бирергә тәкъдим итәләр. Тимер Котлый хан дәшми.**

Күнче *(ул бигрәк тә нык кыза)*. Витовт, безне куркытып, орышсыз-нисез Урдага хуҗа булмакчы була! Аның гаскәре бездән бер дә артык түгел. Тимер Котлый хан! Әгәр дә үзенә шикләнсәң, гаскәрне вакытлыча миңа тапшыр. Килеп җитмәгән Идегәйне көтеп булмый. Яугирләребезнең рухы нык чагын кулдан ычкындырмыйк! Икеләнүебезне алар куркуга санаячаклар.

Сәлим. Мин — моңа катгый каршы! Идегәйне көтәбез. Төп көч — аның белән килә. Баштанаяк тимергә төренгән атлы гаскәр. Идегәйдән башка орышка ташлану — башсызлык! Ә Витовтның таләпләрен кабул итү — килешәм, чынлап та куркаклык!

Күнче. Һе! Ул — килешә! Сыерлар бәкедән су эчкәндә, бозаулар боз ялый иде бездә.

Сәлим *(ачуын тыеп)*. Яугир орышта сынала, Күнче солтан.

Тимер Котлый. Бәхәсне бетердек. Витовтның таләпләре Алтын Урданы кимсетү, әлбәттә... *(Сүзен бүлә.)*

**Тышта быргылар кычкырткан, барабаннар каккан тавышлар ишетелә.**

Нинди тавыш анда? Витовт җавабыбызны көтеп алырга түземлеге бетеп, һөҗүмгә күчкәнме әллә?!

**Кемдер тышка ташлана. Аның әйләнеп кергәнен көтәләр.**

Идегәй *(Норадын белән бергә ашыгып килеп керә)*. Чынмы ул?! *(Беркем дә дәшмәгәч.)* Витовтка орышсыз бирелергә әзерләнүең хак хәбәрме, дип сорыйм мин синнән, хан!

Тимер Котлый *(куркып кала)*. Э... Киңәшү генә ич әле бу, сәргаскәр...

Идегәй. Ниткән киңәш?! Орыш булмас борын — бирелү хакында киңәшәсезме?! Ярый син, хан, яшь әлегә, тәҗрибәң житеп бетми. Син орышта бер ай булсаң, без яуларда сакал агарттык. *(Өлкәнрәк яшьтәге гаскәр башлыкларына.)* Ә сез ни карыйсыз, орыш батырлары?! Яуларда чәч агарткан әмирләр?!

Күнче. Арыслан белән сарыкны бутама, Идегәй! Килеп өлгермәсәң, мәсәләң, гаскәрне үзем орышка күтәрәчәк идем!

Идегәй *(аңа сынау белән карап тора һәм сүзен тынычрак дәвам итә)*. Кем сарык та, кем арыслан — орыш күрсәтер, Күнче солтан. Гаскәребезне орыш өчен уңай урнаштыргансың, Тимер Котлый хан. Инде хәзер... һәркем үз һөнәре белән шөгыльләнсен. Сәргаскәр итеп куйгансың икән — төп эшемә керешим. Витовт соңгы җавабыңны кайчан көтә? Үзем сөйләшәм мин аның белән! Орыш бирәбез: буйсынудан — үлем артык!

**48. Ворскла елгасы. Кичке як.**

**Ярларның берсендә — Идегәй, икенчесендә — Витовт. Икесенең дә нярченнәре читтәрәк.**

Идегәй. Витовт кенәз! Син Тимер Котлый ханга углың булырга кушкансың икән. Һәм Урда тәңкәләренә моннан соң Литва мөһере сугылсын дигәнсең. Безнең ханны углым диюең белән син хаклы. Ул чыннан да яше белән синең углың кебек кенә әле. Әмма үзең уйлап кара: мин ни кадәр синнән өлкән булсам, син шул кадәр үк миннән яшьрәк. Димәк, мин синең атаң булырга, ә син минем углым булырга тиеш. Ясагың да, салымнарың да, җәй саен бөтен кенәзлегеннән җыеп, миңа түләрсең. Синең акчаларыңда — минем мөһер торыр!

**Идегәйнең сүзләрен тыңлаган саен ярсый барган Витовт, бернн җавап бирмичә, атын чаптырып китә.**

Витовт *(чапкан шәпкә иярченнәренә кычкыра)*. Иртәгә иртүк Ворсклапы кичәбез! Орыш!

**49. Идегәй чатыры. Кич.**

**Сәргаскәр Идегәй үз чатырына орыш алдыннан соңгы киңәшмә җыйган. Тимер Котлый хан да шунда.**

Идегәй. Шулай итеп, хәлиткеч орыш — иртәгә иртән. Витовт белән Туктамышны шушында каршылыйбыз.

Күнче. Мин, караңгылыктан файдаланып, таң атканчы Ворскла елгасының теге ягына чыгарга кирәк саныйм. Дошман моны көтми, димәк, каушап калачак.

Норадын. Мин дә Күнче солтанның тәкъдименә кушылам, сәргаскәр.

Сәлим. Уйлашыйк әле. Елганың аргы ягына чыгып, ялгышмабызмы? Бигрәк тә — караңгыда. Орыш алдыннан буталчык килеп чыкса? Суга кергәч, көймәсенең тишек икәнен күргән ди берәү.

**Көлешәләр.**

Аргы якны без яхшы белмибез бит. Ә Витовт ул җирне биш бармагы кебек өйрәнгән! Без килеп җиткәнче ул анда кыртлаган тавыкларын ояга утыртып, чебеш чыгартып, хәзер шуларның ите белән Туктамышны сыйлый. Үз күзләрем белән күреп кайттым мин.

Идегәй. Орыш урынын хәл иттек. Инде хәзер — кем кайда булачак... Күнче солтан! Сиңа — уң канат.

Күнче. Ризалыгымны алганчы, калганнарын да әйтеп чык, сәргаскәр?

Идегәй. Ярый. Сул канатны Норадын би җитәкли. Күнче солтан белән икегезгә икe постырма. Маңгайда — Сәлим би. Дошман чирүе белән башлап ул очраша. Үзәктә — Тимер Котлый хан белән мин.

Бер әмир. Ә без — төмәнбашлары?!

Идегәй *(елмая)*. Юк, сезне дә онытмадык, әмирләр. Сезгә, гадәттәгечә, орышның иң авыр чагында утка керергә туры килә: артта чагдавыл гаскәр — сезнеке. Чагдавылга утаман итеп Тимәр әмирне куябыз. Берегез дә каршы түгелме, олуг әмирләр?

Әмирләр. Килешәбез моның белән. Шулай дөрес булыр!

Идегәй. Килешсәгез... киңәшмә шуның белән тәмам. Калганы — Ходай кулында.

Норадын. Хак Тәгалә безгә ярдәм кулын сузармы, юкмы — ул үзе генә белә. КылычЪ*ларыбыз авыр булмасын диик!

**Көлешәләр.**

Күнче. Таралышмый торыгыз. Мин үз урыным белән килешмим, сәргаскәр.

Идегәй. Ә-ә, син нидер әйтмәкче идең... Тыңлыйбыз сине, Күнче солтан?

Күнче. Мин, беренчедән — маңгайбашын Сәлим бигә бирүгә каршы. Аның берниндu тәҗрибәсе юк. Маңгайга — мине билгелә. Тик — үз төмәнем белән. Бүтәннәр кан койганда кайдадыр постырмада күккә төкереп ятасым килми! Анда Сәлим кебек каурыйлары катып өлгермәгән яшьрәкләр дә качып ята ала!

**Сәлим сикереп тора.**

Идегәй *(Сәлимгә)*. Постырмада бик җиңел булыр дип уйлап хаталанасың, Күнче солтан... Ярар, теләгеңә каршы килмим. Чөнки орыш алдыннан хәтереңне калдырасым килми. Син ризамы, Сәлим би?

Сәлим *(чын күңелдән)*. Боерыгың, Идегәй әмир!

50. Орыш кыры. 1399 елның 12 августы. Иртә.

**Сыек томан астында киң елга тугаенда Идегәйнең гаскәре төзелгән: иң алда, киңәшмәдә килешкәнчә, Күнче солтанның җиңел коралды төмәне. Сугышчыларда садак белән ук-җәя, кылыч, кечкенә калкан гына. Киемнәре дә җиңел: күн очлым, күн чалбаркүлмәк. Терсәк-тез япмалары да күннән.**

**Алар артында — сөңгечеләр: боларның кораллары да, киемнәре дә ныклырак. Алдагы рәттәгеләрнең сөңгеләре кыскарак, икенчеләрнеке — бераз озынрак саплы, өченчеләрнеке — тагын да озынрак. Үзәк гаскәр әнә шулай өчәр-өчәр рәт булып тезелгән. Барысы да тимер очлымлы, тимер көбәле һәм зур тимер калканлы. Атлары гына — күн япмалы.**

**Идегәй үзе, Тимер Котлый хан белән бергә, чатырыннан ерак түгел калкулыкта утыра: аннан бөтен орыш кыры аларга уч төбендә кебек ап-ачык күренә. Идегәй янында, хан иярчennәре, байракчылар һәм сакчы казаклардан башка, уннарча атчабар адъютант бар: алар Идегәйнең һәр боерыгын гаскәр башлыкларына тапшырып торырга тиешләр.**

**Менә зур чалмалы сәед, намазлыгын җиргә җәеп, дога кыла һәм учына туфрак алып, дошман ягына таба өч мәртәбә сибә: «Ул як качты! Ул як качты! Ул як качты!» Торып баса һәм Идегәйгә сорау белән карый. Идегәй, янына килеп, кулларь белән сәеднең аяк очларын сыпыра.**

Идегәй. Теләгең фәрештәләрнең «Амин!» дигәненә туры килсен, сәед!

Сәед. Аллаһы Тәгаләбез ярдәмсез калдырмасын! *(Кушырылган кулларын маңгаена куеп башын игән килеш чигенә-чигенә читкә китә.)* Изге йола үтәлде: Идегәй орышка әзер.

Күзәтче. Дошман елганы кичә башлады!

**Шул ук мизгелдә сугышка әзерләнергә кушып, быргылар кычкырту, дум-думбак барабаннар кагу башлана. Әкренләп таралган сыек томан артында Витовтның атлы гаскәре елга кичә. Быргы-барабан тавышлары тына. Дәһшәтле орыш башланыр алдыннан була торган шомлы тынлык. Иге-чиге күренмәгән дошман ташкыны, болын тутырып Идегәй гаскәренә якыная.**

Күзәтче *(Идегәйнең артында)*. Туктамыш ханның маңлай башы — Исабәк би!

**Барысы да Идегәйгә борылып карыйлар: ул тыныч. Ике гаскәр арасы бер чакрымлап калгач, Идегәй кулларын кушырып алга таба ишарә ясый: бер адъютанты ат менеп, маңгай гаскәр янына барып килә. Күнче солтанның атлы гаскәре шундук дошманның «маңгае»на каршы ташлана: Иң алда аның күк байрагы җилферди. Ике ташкын арасы күзгә күренеп тарая. Идегәй тирәсендәгеләр кинәт «Аһ!» дип кычкырып җибәрәләр: Витовт гаскәренең атлы авангарды чапкан җиңкә икегә аерыла һәм аралыкта йөзләгән утчагыр тип ачыла — Витовт Идегәйгә сюрприз әзерләгән икән! Ә Идегәйнең гаскәрендә андый корал юк. Утчагырлар, барысы берьюлы күк күкрәгән тавыш чыгарып, Күнче**

**гаскәре өстенә ут бөркеп атып җибәрәләр. Дистәләгән сугышчы атлары-ние белән бергә җиргә тәгәри, атлар өркеп чыгымлый, сугышчылар үзләре дә, котлары алынып, югалып кала, әмма Күнче солтан, нидер кычкырып, паниканы туктата: алар кабат тигез саф ясап алга ыргылалар. Тиздән ук атым ара гына кала: Күнче солтанның төмәне, дошман өстенә меңләгән ук яудыра-яудыра, ике яктан дуга ясап кирегә борыла. Дошман утчагырлары кабат атмый: яңадан кору бик озак икән. Күнче солтан гаскәре укларыннан шактый сирәкләнеп калган дошман «маңгае»ның ике чаты бергә кушылып, утчагырларны яшерә.**

**Идегәй тагын кушырылган кулларын алга таба селти: шул ук адьютант, ат менеп, тагын Күнче янына ташлана. Күнче солтан икегә бүленгән гаскәренә дошманга каршы борылырга боера: «маңгай»га «маңгай» кабат бәрелешә. Бу юлы да дошман «маңгае» баштагы маневрын кабатлый: утчагырлар тагын күк күкрәтеп ут бөрки. Бу юлы Күнче солтанның гаскәрендә каушау зур булмый, әмма көчләр тигез түгел, дошман ташкыны артканнан-арта бара. Идегәй, ике кулын ике якка күтәреп, алга таба селти: икенче адьютанты үзәк гаскәр янына ташлана. Сөңгечеләр һөҗүмгә күчәләр. Витовтның да үзәк гаскәре алга чыга һәм арбалетлардан тимер уклар яудыра башлый: Идегәй гаскәрендә җиргә тәгәрәүчеләр күзгә күренеп арта бара. Арбалетчылар бер үк вакытта «маңгай» маневрын кабатлыйлар: утчагарлар тигез ритм белән туп яудыралар. Көчле кыргын кызганнан-кыза. Сөңгегә сөңге бәрелешеп сына, калканнар тишелеп оча, сөңгегә күтәрелгәннәр җиргә тәгәри, атлар җан ачысы белән кешни. Идегәй колачын киң итеп җәя һәм кинәт кулларын куша: беренче адьютант Күнче янына чаба. Идегәйнең фәрманын алуга, Күнче солтанның атлы гаскәре ике яклап Витовтның гаскәренә ташлана, әмма алар дошманнан күпкә аз. Дошман гаскәре аларны язгы ташу йомычкаларны ике ярга эшереп аткандай гына кызган шәпкә таратып үтә. Идегәйнең үзәк гаскәре дә әкренләп артка чигенә башлый. Өстәвенә, ул арада аларны ике яктан Витовтның моңарчы орышка кермәгән атлы гаскәрләре кысрыкларга тотына. Әмма Идегәй орышны тыныч кына күзәтүен дәвам итә. Менә берзаман, аның үзәк гаскәрен икегә кисеп, Витовтның атлы гаскәре уртага бәреп керә. Үзәк агайлар ике якка янтая.**

К ү з ә т ч е. Дошман орышка барлык алайларын кертте. ·

**Идегәй Ворскланың аргы ягына карый: анда, чынлап та, бүтән гаскәр күренми. Әмма Идегәй боерык бирергә ашыкмый: бу — Витовтның хәйләсе булуы мөмкин.**

К ү з ә т ч е *(ышандырырга теләгәндәй шатланып)*. Витовтның байрыгы — орыш кырында! Туктамыш ханныкы да!

**Идегәй күзәтче күрсәткән якка карый һәм җиңел сулап куя: менә хәзер дошманның яшерен гаскәре юклыгына ышанырга да була! Ә бу вакытта Идегәйнең гаскәре, чигенә-чигенә, аның калкулыгына якынлашып килә инде. Идегәй, сул кулын җилкәсе аша артка таба күтәреп, алга селти. Тагын бер адьютанты ат менеп каядыр чаба. Чагдавылга чират икән: калкулык астыннан Үз Тимер сугышчылары килеп чыга, әмма көчле дошман ташкынын алар белән генә туктатырлык түгел. Идегәйнең арткы гаскәре дә әкренләп чигенә. Витовтның гаскәре, вакыт-вакыт икегә аерылып, утчагырларына атарга аралык калдыра-калдыра алга омтыла. Дошман, тантана якынлашуын сизеп, тагын да ныграк гайрәтләнеп сугышырга тотына.**

К ү з ә т ч е *(калкулыктагыларга шом сала)*. Күнче солтан ак әләм күтәргән! Исабәк би белән кушылды! Бергәләп безгә каршы ташландылар!

И д е г ә й *(үз алдына)*. Менә кайчан асыл йөзеңне күрсәттең син, шакал!..

Т и м е р  К о т л ы й. Мин көткән идем моны! Ниндидер әшәкелек әзерли бу юньсез малай, дип уйлаган идем! Постырмаларны кертергә вакыт, Идегәй агам!

И д е г ә й *(тыныч)*. Сабыр ит, хан...

**Ә Витовт Идегәйне менә-менә качарга мәҗбүр итәчәк! Тимер Котлый ханның нярченнәре һәм җан сакчылары борчыла башлыйлар. Хан үзе дә хафага төшкән. Бары тик Идегәй генә һаман нидер көтә. Менә ул, ниһаять, кулларын ике якка җәеп, кинәт алга таба һаваны ярып төшерә. Ике адьютант, атларына сикереп менеп, ике якка ташлана. Бер минут, ике минут үтә... Гаскәрләр күренми! Биш минут, алты... Идегәй гаскәре соңгы чиккә җиткән!**

К ү з ә т ч е *(шатлыктан кычкырып җибәрә)*. Кха! Тимер гаскәрләр! *(Онытылып китүен чамалап.)* Постырмада торган канатлар дошманны ике яктан урый.

**Витовт гаскәренең флангларында баштанаяк тимергә төренгән авыр атлы гаскәрләр җир астыннан калыккандай пәйда була. Хәтта атлары да тимер ябынчыклы. Дошман гаскәре аларның каян килеп чыкканлыгын аңышмый да кала. Моны бер могҗиза кебек кабул итә сыман: сугышчыларның күбесе, каршы торуны башларына китермичә, орышны ташлап качмакчы була, әмма соң инде! Витовт белән Туктамыш гаскәрен ике яктан көчле тимер ташкыны уратып алган! Артка да, алга да юл юк: артта үзләренекеләр, алда — дошман. Ә Идегәйнең тимер гаскәрләре корал кулланып та тормый: рәттән бөтенесен таптап изә бара. Дошман арасында көчле паника күтәрелә: барысы да качып котылу ягын гына карыйлар.**

К ү з ә т ч е. Витовт белән Туктамыш гаскәрләрен ташлап качтылар.

**Аның шатлыклы тавышын ишеткәндәй, киң болында көчле «Ура!» яңгырый. Дошман тәртипсез рәвештә кача: орыш кырында утчагыр-туплар гына, беркемгә дә кирәкмәгәндәй, тырпаеп калалар.**

И д е г ә й. Ат!

К ү з ә т ч е. Бөек сәргаскәргә — ат!

**Идегәйгә шундук алтын иярле ап-ак тулпар китерәләр: ул, яшь егеттәй җиңел генә**

**сикереп, няргә куна. Ул арада Тимер Котлый хан, нярчеләре, байракчылар һәм сакчы казаклар үз атларына менеп өлгерәләр.**

Идегәй. Минем арттан! Туктамыш белән Витовтка качарга бирмәскә! *(Калкулыктан аска, аңынчы тарих күрмәгән мәхшәр тәмамланып килгән болынга томырыла.)*

**Калкулыкта Идегәйнең сугыш чатыры гына кала.**

**51. Сугыш кыры. Икенче көн иртән.**

**Сыек томан. Бары тик Идегәй чатыры торган калкулыкта һәм киң болынның кайбер төшләрендә генә томан ерткаланган. Идегәй белән Тимер Котлый хан урынында... ач бүреләре өере.**

**Бүреләр калкулыктан ат үләксәләре, кеше мәетләре өелеп яткан болынга төшәргә кыймый торалар. Нидер куркыта, ахры, аларны. Орыштан соң ганимәт, мәетләр һәм яралыларны җыючы командалар килгәннәрдер, дисәң — бер төн генә үткән әле.**

**Талгын җил чыга: сыек томан теләр-теләмәс кенә әкренләп орыш кырыннан читкә шуыша башлый. Һәм бүре өерен нәрсә куркытканлыгы ачыклана: киң болынны мәетләр арасыннан үзләренең ирләрен, якын туганнарын эзләүче хатын-кызлар, бала-чагалар басып алган икән. Үз кешеләрен табу аларга җиңел түгел: мәетләр күп урыннарда тыгыз йомгак булып аралашып беткән. Менә бер урында яшь кенә кызчык белән аннан да кечерәк малай кисәге үз әтиләренең мәетен тапканнар: кызчык әтисенең башын сөякчел тезләренә куйган да, бала тирбәткәндәй, селкетеп утыра.**

— Папочка!.. Пап!.. Роднуля ты наш! Открой свои глазеньки! Это я — твоя старшенькая Танечка! И Коленька здесь... Открой, пожалуйста, синие оченьки-и! *(Елый.)*

**Ә орчык буе энекәше ирләргә генә хас җитдилек белән әтисенең күкрәгендә тырпаеп торган укны каурыйлы сабыннан тартып чыгармакчы була...**

— Коленька! Не дергай! Ему же больно! Как ты не понимаешь?!

**Бу ике сабый әтиләре күзләрен мәңгегә йомганын беләдер дә кебек, әмма аның авыртуны сизмәвен аңларлык яшьтә түгел әле...**

**Икенче урында чәчләре тузгыган бер марҗа ярты гәүдәсе ат үләксәсе астында калган иренең күккә төбәлгән пыяла күзләрен йомдырырга тырыша һәм көйли-көйли үкси:**

— Чем же теперь прикрыть твои очи, мой родненький? Когда тебя земля укроет, неужели ты так и будешь лежать с открытыми глазами?! Великий грех же это!.. И на кого ты нас, своих сирот, оставил, кормилец ты наш? И кто же теперь будет кормить-одевать твоих бедных сиротинушек? Как же подыму я без тебя, родненький мой, наших несчастных сиротинушек?! Ведь ты знаешь: их трое у нас с тобой!

**Шулвакыт янында гына авыр итеп ыңгырашу ишетелә: хатын сискәнеп китә һәм үксүеннән туктый. Куркуыннан күзләре шар була: татар ыңгыраша икән! Киемнәре бөтенләй үз иренекенә охшамаган. Марҗа җен ачуы белән сикереп тора һәм, иренең гәүдәсе янында яткан канлы кылычны алып, татар яугиренә ташлана.**

— Проклятый татарин! Это ты убил моего мужа! Это ты сделал нас несчастными сиротами! Убью, гадина ты басурманская! *(Татарга кадарга теләп, кылычын югары күтәрә, ләкин тораташ кебек катып кала: яралы яугир күзләрен ачып аңа карап тора.)*

Яугир *(коргаксыган телен көчкә әйләндереп)*. Су...

Хатын *(сугышчының күз карашы белән очрашкач, кылычын ирексездән түбән төшерә)*. Теперь у меня воды просишь, проклятый... Откуда мин сина су найду?!. Син минем мужа зарезал, а мин сина су табарга должна, да?!

Яугир *(күзләрен йома)*. Синең иреңне... мин үтермәдем, марҗа... Ул мине... суйды...

Хатын *(яугир күзләрен йомгач, ул кылычны кабат күтәрә)*. Алдыйсың, басурман, будь ты трижды проклят!

Яугир *(күзләрен көчкә ача)*. Су бирмәсәң... Үтер мине... *(Күзләрен йома.)*

Хатын *(бертын уйланып катып тора һәм кылычын читкә ташлый)*. Не могу убить, проклятый!.. Я же — не убийца, как ты!.. *(Яугир янына чүгәли: үлдеме әллә дигәндәй, бармагы белән ипләп кенә төртеп карый — яугир ыңгыраша.)* Атын кем, татарин?.. Эй! *(Аны катырак селкетә.)*

Яугир *(ыңгырашып, күзләрен ача)*. Үз ireңне эзлә... *(Күзләрен йома.)*

Хатын. Говорю же я тебе: ты убил моего мужа! Ты нас без кормильца калдырдын! Вот син и безга кормилец будешь, понял, басурманин?! Как сине зовут? Атын кем, говорю?

Яугир *(күзләре йомык килеш)*. Рахман... *(Аңын югалта.)*

Хатын *(колагын аның күкрәгенә куеп тыңлый)*. Не смей умирать, вражина! Ульма! Я не дам тебе умереть! Ты, как проклятый, всю жизнь будешь нас кормить-одевать! Хм, Рахман его зовут... По нашему, вроде «спасибо»... Ну и пусть, что он басурманин! Кто-то должен же о нас заботиться! Откуда найду я теперь себе другого мужа?! Я не дам тебе так легко отделаться от меня... Как миленький будешь нас кормить... *(Елый-елый, татар яугирен каядыр сөйрәп алып китә.)*

**Сугыш кыры мәш килә: хатын-кызлар — якыннарының үле гәүдәләрен тапканнары — улап елый, балалар үкси-үкси үкерешә, акылдан шашканнар җан өшетеп кычкырып көлә... Ә бүреләр, шушы манзарага шаккаткандай, калкулыкта тезелешеп карап торалар. Күктә козгыннар коркылдавы ишетелә.**

**52. Сарай каласы. Көн.**

**Алтын Урданың башкаласы, өлешчә кабат төзекләнгән булса да, әле һаман хәрабә килеш ята. Шулай да, кайбер урамнары чамалап була инде.**

**Шундый төзегрәк урам буйлап атлы сөрәнче чабып уза.**

Сөрәнче. Сарай халкы! Бөек җиңү! Сәргаскәр Идегәй Литва кенәзе Витаускас бе-

лән качкын Туктамыш ханның сансыз чирүен башма баш тар-мар кылган! Киевкә кереп бикләнгән Витаускас өч мең алтын Литва акчасы түләп кенә котылган! Ә Туктамышны Норадын углан Болгар урманнарына кадәр эзәрлекләп киткән! Ишетегез һәм шатланыгыз! *(Ары чабып китә.)*

**Урам әкренләп халык белән тула. Быргы кычкырткан, сорнай уйнаткан, барабаннар каккан тавышлар астында яудан кайтучы атлы гаскәр күренә: иң алда — алтын иярле ап-ак атта яу батыры Идегәй. Сәлим аның белән янәшә бара. Горур кыяфәтле байракчылар да шунда. Алар артыннан атлы тимер гаскәр килә. Алардан соң җиңел кораллы алайлар уза. Кала халкы җиңүчеләрне алкышлый: «Идегәй батырга дан!» Идегәй халыкны кул белән сәламли. Гаскәр артыннан ганимәт утчагырлар үтә башлый: һәр тупның лафетына дошман әләмнәре җәеп салынган. Андый нәрсәне гомерендә күрмәгән халык шаккатып карап тора. Шулай да, халык арасында гаҗәпләнү көчәя: ә Тимер Котлый хан кая?! Үзара чыш-пыш китә: «Хан кая, хан?»**

**Арадан берәү: «Юлда авырып үлгән дигәнгә ышанмагыз: Идегәй, үзе тәхеткә утырыр өчен, Тимер Котлый ханны да, тәхет варисы Күнче солтанны да үтерткән!» — дип пышылдый. Кем әйткәнен дә белми калалар. Шулчак траур арбалары килеп житә: иң алдан алтын-көмеш, ефәк белән бизәлгән тәхет арбасы якынлаша. Кемдер: «Тимер Котлый ханның мәете!» — дип пышылдый. Халык ханга хөрмәт йөзеннән җиргә тезләнеп баш ия. Икенче, өченче арбалар якынлаша. Шул ук кеше тагын пышылдый: «Ханыбызның энесе Күнче солтанның гәүдәсе! Ә өченче арбада — Идегәйнең сөт туганы Исабәк би!» Халык аларга да баш ия. Болардан соң яралылар һәм мәетләр төягән иксез-чиксез озын олау үтә башлый. Халык, яралылар төягән арбаларны ике яктан сырып алып ияреп бара: һәркем үзенең якын кешесен эзли. Берәүләр үкереп елый, икенчеләре якыннарының исән кайтуына шатлана...**

**53. Алтын Таш хан сарае. Кичке як.**

Идегәй *(ул тәхет залында)*. Сарай бие! Без яуда чакта йортта нинди хәлләр булды?

Сарай бие *(Идегәйгә ярарга тырышып)*. Син югында, Идегәй әмир, бар да тыныч торды. Каланы төзекләндереп киләбез...

Идегәй. Ансын күрдем. Йортыбызның иминлеге, халыкның хәле хакында сорыйм мин синнән.

Сарай бие. Халык канәгать болай. Калабызның элекке бие Алмыш бәк кенә моннан бер ай чамасы алдарак халык арасында сиңа каршы коткы таратып маташкан иде дә, койрыгына тиз бастык. Хәзер кайдадыр качып йөри... Иминлеккә килгәндә... Берике яман хәбәр алдык. Синең яуда булуыннан файдаланып, урыслар Болгар җирен тагын бик каты талап киткәннәр. Юрий Дмитриевич атлы кенәз баскынлык иткән. Туктамышның Аксак Тимергә сыенган углы Бүләкбирде Кырым тирәсендә исәнәеп йөри, имеш. Кырым аңа әтисеннән калган мирас булырга тиеш, янәсе!

**Идегәйнең йөзе караңгылана.**

Идегәй *(берәздән)*. Сәмәркандтан хәбәр юкмы?

Сарай бие *(шатланып)*. Килде, Идегәй әмир! Шаһ Тимер Урдабызга дуслык вәгъдә иткән. Акбеләк бикә дә исән-аман атасы белән күрешкән, ди. Тәхетебез генә ятим калды. Кемне күтәрербез икән? Үзең утырсаң яхшырак булмасмы, Идегәй әмир?

Идегәй *(кискен)*. Тәхет Шадибәк солтанныкы! Ярлык әзерлә: Бүләкбирдене Кырымга кертмәскә яу чыгабыз. Икенче ярлык: бусы — Мәскәү кенәзе Василийга. Ул безнең кан дошманыбыз Туктамышның угыллары Җәләлетдин белән Кәримбирдене үзенә сыгындырды. Берничә ел инде, безгә түлисе салымны, кенәзлекләреннән тиешен җыеп барса да, үзендә калдырып, Мәскәвен ныгытып ята. Ничә ярлык юлладык, телебезне алмады! Без аның кенәзлеген Аурупа йортбасарларыннан саклыйбыз. Үзен акыллы башка санап, берьюлы ике атка атланмакчы, ахры. Башбаштаклык итәргә теләсә — бездән яу алыр! Ярлык минем исемнән булсын. *(Тәхет залыннан авыр атлап чыгып китә.)*

**54. Кырым. Аю-Даг тирәсе. Көз көн.**

**Диңгез ярыннан ерак булмаган бер урында сәргаскәр Идегәй әмирнең яу чатыры корылып ята.**

**Идегәй Сәлим белән бергә биек тау үзәне буйлап корылып бетмәгән чатыры янына кайтып килә. Ул бик алҗыган, әмма канәгать.**

Сәлим. Бүләкбирденең алайлары күп булмас, үземне генә жибәр, дигән идем, тыңламадың, сәргаскәр... Ә мин хаклы булганмын: ике меңлек ертавылыбызны күргәч койрыгын бот арасына кыстырып качты! *(Көлә.)*

Идегәй *(җитди)*. Качты... Әмма — исән! Эт этлеген итми каламы?

**Чатырның аргы ягыннан атчабар Идегәйләргә каршы атылып килеп чыга һәм еракган ук авызын ера.**

Атчабар *(атыннан сикереп төшеп, йөгерә)*. Юлыңны бүлдерәм — кичер, Идегәй әмир: хәбәрем гади түгел!

Идегәй. Әйт!

Чапкын *(шат йөз белән)*. Аксак Тимер Кытайга яу чапканда буза эчеп үлгән! Өтөрар дигән калада, ди!

Идегәй. Эт орыр?! Андый каланы белмим мин. Утрарны беләм.

Сәлим. Утрарда җан бирсә дә, эт органы шәп булган! *(Көлә. Җитдиләнеп.)* Никтер шатландырмады сине бу хәбәр, сәргаскәр. Атчабарга сөенче дә вәгъдә итмисең!

Идегәй *(атчабарга)*. Сөенчегә сиңа — бәйге тоткан бер йөгерек ат. Китәргә мөмкин.

Атчабар. Рәхмәт бөек сәргаскәр! *(Шатланып, читкәрәк китеп, Идегәйгә баш иеп кала.)*

Идегәй. Нәрсәгә сөенмим?.. Иң хәтәр дошманның да үлеменә шатланырга яра-

мый: синең асылынны яхшы белүче берләнбер кешеләр ул, бәлки! Бөтен Урта диңгезне дер селкеткән Төрек йортының солтаны Елдырым Баязит, Шаһ Тимер кулына төшеп, адәм мәсхәрәсе булып дөнья куйды. Индеге көндә Шаһ Тимер үзе дә, ярты галәмне тез чүктергән зат, вафат киткән икән. Кайчандыр гайрәтен кая куярга белмәгән Туктамыш хан — ялгыз калган каз бәбкәсе кебек далада каңгырып йөри...

Сәлим. Белүемчә, соңгысының каңгыруына син үзең сәбәпче ич, сәргаскәр! *(Елмая.)*

Идегәй *(тәрттерүен колагыннан читтә уздыра)*. Литва кенәзе Витаускас... Хәер, ул яшь. Күк күкрәтер көннәре, бәлкем, алдадыр! *(Атын кирегә бора.)* Минем кемлекне шушы затлар гына белә!

Сәлим *(гаҗәпләнеп)*. Син кая, сәргаскәр?

Идегәй. Атчабар хәбәрен ишеттен ич. Шаһ Тимер Туктамыш кулыннан Үргәнеч белән Хәрәзем олысларын тартып алган иде, Урдабызга кире кайтарырга җай вакыт!

Сәлим *(җилкәсен җыера)*. Ничек армый икән бу кеше?! *(Идегәй артыннан китә.)*

**55. Бохара тирәсе. Иртән.**

**Шанлы кала капкындагы калкулык өстендә Идегәй гаскәре тора. Алар алдындагы кала ап-ачык күренә. Искиткеч матур биналар, алтынланган гөмбәзле зур мәчетләр һәм күзнең явын алырдай гүзәл гөлбакчалар. Ләкин болар барысы да — биек таш койма эчендә. Шәһәр капкалары бикле.**

Сәлим *(сокланып)*. Бохара! Безнең якта шушы кала турында бер матур җыр бар.

*(Җырлый.)* Шам шәрифкәй дигән, ай, калада
Кич ахшамсыз капка ябылмас;
Үткәндә генә гомер, калган хәтер —
Сатып алыйм дисәң табылмас.
Тик моның капкасы иртән дә бикле икән!

Идегәй. Дәмашык ул — Шам шәриф.

Сәлим. Белмәгән нәрсәң юк синең, Идегәй батыр! Сиңа ияреп, күпме гаҗәеп йортлар гиздем — мондый да гүзәл каланы күргәнем булмады. Артыбызда калган Үргәнеч, Хәрәземнәр бу могҗиза янында тулпар ат каршында торган корчаңгы ишәк кебек кенә икән! Шаһ Тимер мәмләкәтен киңәйтүне ошбу каланың ачкычын үз кесәсенә салудан юкка гына башламаган, күрәсең! Инде хәзер ул алтын ачкыч синең кесәгә күчәргә тиештер, Идегәй агай!

Идегәй. Дөрес булса, Шаһ Тимергә кала ачкычын Бохара халкы үзе китереп биргән... Миңа ачкыч китерергә ашыгучы күренми нишләптер. *(Елмая.)* Мәчетләренең манараларын иеп, алтын чалмаларының тузанны каккаларга туры килер, ахрысы!

Сәлим. Бераз көтик... Игә килмәсләрме...

**Гаскәр артыннан: «Сарайдан чапкын!» — дип кычкырган тавыш ишетелә. Идегәй белән Сәлим аптырашып бер-берсенә карап куялар.**

Идегәй *(караңгы чырай белән)*. Менә — алдыбызда торган тәмле калҗаны турый башламадык, табыныбызга кара таракан төште. *(Ак күбеккә баткан атта килеп туктаган чапкынга.)* Хәбәрең яманмы?

Чапкын *(авыр сулап)*. Әйе, сәргаскәр... Шалибәк хан, олугларны котыртып, сиңа каршы сугыш ачты!

Идегәй. Ашаган табагына кәкәй иткән нәрсә икән!

Чапкын. Тагын бер хәбәр, Идегәй әмир... Туктамыш ханның улы Җәләлетдин, Болгарга басып кереп, үзен хан дип игълан итте... Мин киткәндә... Шалибәк ханнан Сарай тәхетен даулап калды! Менә хәзер яңалыкларым бетте, сәргаскәр. *(Аты җиргә ава.)*

Идегәй *(Бохара каласына карап уйланып тора)*. Язган ризык тешеңне сындырып булса да авызыңа керә, диләр... Язмаган йорт булган, күрәсең! Тезгәннәрне Болгарга таба тартабыз.

Сәлим. Нишләп Болгарга?! Моннан Сарайга якынрак бит?

Идегәй. Шалибәкне үзем куйдым, үзем бәреп тә төшерермен. Җәләлетдин, әтисе белән кушылып, урысларны безнең өскә яуга котыртмагае! Ул — Мәскәү куштаны!

**56. Сарай каласы янында болын. Иртә.**

**Киң болында атлар утлап йөри: беренче карашка, хайваннар һәрберсе үз иркенә җибәрелгән кебек тоела. Әмма күзәтә белгән кеше атлар арасында да үзенчә каттый тәртип барлыгын күрер иде. Әнә, мисал өчен, читтәрәк бер зур гына өер аерым утлап йөри: олы гәүдәле өер айгыры аларны бүтәннәр белән аралаштырмый. Димәк, бу атлар — өер айгырының «хәрәме». Аның үзенә бер генә мизгелгә дә җан тынычлыгы юк: әле бер яктан, әле икенче яктан чит айгырлар, дәртле кешнәп, аның җилбәзәгрәк яшь биясләрен үзләренә ияртеп алып китмәкче булалар, ләкин өер айгыры бик сизгер һәм кырыс холыклы: көндәшләре якын килә башлауга, ажгырып өсләренә ташлана һәм киң күкрәге белән бәреп кенә очыра. Тик шунысы бар: үз «хатыннары»на да гел күз-колак булырга туры килә — аларның кайберләре аның «каты хакимлеге» астыннан чыгып таярга гына торалар. Өер айгыры булу бер дә оҗмах түгел икән!**

Идегәй *(ул Сәлим белән болынга сәйрәнгә чыккан)*. Нәрсә карап тора икән дисәм, син дә өер айгырын күзәтәсең икән! *(Көлә.)* Минем хәлне аңлый башладыңмы инде, энекәш?

Сәлим *(җитди)*. Урдабызның «бияләре»нә читләрнең күзе кызуга шаккатмыйм мин. Гомергә шулай булган, ахырзаманга чаклы шулай булыр да... Кайбер олысларыбыз «әрсез айгырлар»га ияреп читкә таю ягын каералар — шунысы аяныч. Ярый ла, синең, сәргаскәр, гайрәтле чагың, йортыңны учыңда йомарлап, нык тотасың. Ләкин бит берәү дә бу фани дөньяга мәңгегә килмәгән!

Идегәй. Көннән-көн гаҗәпләндерә барасың әле син мине, Сәлим дус...

Сәлим *(үзенчә аңлап)*. Ни чәчсәң, шуны урырсың, сәргаскәр! *(Көлә. Җитдигә күчә.)* Кызганычка каршы, син Туктамыш ханның эзеннән барырга мәҗбүр...

Идегәй. Нишлисең бит, дошманның койрыгын кисмичә туктарга ярамый!

Сәлим. Аны әйтмим мин, сәргаскәр... Туктамыш башта Мамайның хакимлеген бетерергә тырышып, әмирләрен аерылырга котыртып яткан, ә тәхет үзенә күчкәч, Урданың вакланган кисәкләрен кабат җилем белән ябештергән. Син дә, сәргаскәр, шуны ук кабатлыйсың. Туктамышның тәхетен син ничек какшатсаң, аның малайлары хәзер синекен какшатырга тырыша! Чик күрмим.

Идегәй *(кырыс)*. Туктамыш белән эшне бетерик — шуннан күрерсең! *(Йомшара төшә.)* Ошыйсың син миңа, энекәш... Норадын углым янында да синең кебегрәк ике-өч гаярь җегет булса иде! Миңа алмаш бар ул... *(Атын кала юлына бора.)*

Сәлим *(сынагандай)*. Норадын улыңмы?

Идегәй *(атын юырта башлый)*. Ашыгыйк, энекәш, тәхет суына башлаганчы яңа хан күтәрергә камка әзерләтергә кирәк.

Сәлим. Сер булмаса, тәхетне бу юлы кемгә багышларга булдың, сәргаскәр?

Идегәй. Булат солтанга.

Сәлим *(шаккатып, атын туктата)*. Үзеңә хыянәт иткән Шадибәк хан углынамы?!

Идегәй *(аңа таба борылып)*. Син үзең дә миңа тугры хезмәт итәргә килгән җегет түгел ич? Ә хәзер — мин сине иң якын дусларымның берсе дип саныйм! *(Атын чаптырып китә.)*

**57. Сарай каласының шомалар урамы. Көн.**

**Идегәй белән Сәлим би, атларын әкрен генә атлатып, үзәк урам буйлап Алтын Таш хан сараена якынлаша. Аларның каршысына Сарай бие очрый.**

Сарай бие *(шатланып)*. Кайтып керүең бик әйбәт булды әле, Идегәй әмир! Юкса, мин үзем сине эзләргә китеп бара идем!

Идегәй. Нәрсә булды?

Сарай бие. Ничек дип әйтергә дә белмим инде, Идегәй әмир... Мин көнетөне чәбәләнәм... Калабызны торгызырга тырышам! Аңламассың безнең кайбер әмирләрне!

Идегәй. Кыскарак тот.

Сарай бие. Бөтен олугларга, угланнарга, бәкләргә туп-туры әйтелде: һәркем үз йортын үзе торгыза. Кемнең үз көче җитми, казна ярдәм итәчәк, диелде! Кыл да кыймылдатучы юк! Бүген иртүк Бознак би, Үз Тимер әмир, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр, каланы ташлап, далага күчеп киттеләр...

Идегәй. Үз Тимер әмир дә?!

Сарай бие. Әйе!

Идегәй. Сәбәп?

Сарай бие. Сәбәбе билгеле инде — бер генә: хан алышынган саен җимерелә торган каланы төзекләндерәбез дип, барлы-юклы мал-мөлкәтебезне әрәм-шәрәм итеп бетергәнче, далада иркенләп күченеп йөрүебез мең артык, диләр. Әнә генә: Болгар, Азак, Кырым аяклары бер-ике җәй эчендә калаларын ал да гөл итеп кабат күтәрделәр, ә пайтәхетебез — һаман да көл-күмер астында ята!

Идегәй *(үз алдына)*. Кемнән-кемнән, Үз Тимер әмирдән көтмәгән идем моны... Бер-ике көннән тәхеткә хан күтәрәчәгебезне беләләрдер бит?

Сарай бие. Соң инде, белмәскә! Бөтенесе дә хәбәрдар!

Идегәй *(караңгы чырай белән)*. Малларын ат койрыгына таксыннар инде, алайса...

Сарай бие. Танай би әйтә: яңа хан күтәрә-күтәрә, камка ертып та Урдабыз бөлеп бара инде, ди...

Идегәй *(ризасызлык белән)*. Хан күтәрергә әзерлекне төгәлләгез.

Сарай бие *(кулын күкрәгенә куеп, иегенә)*. Үтәлер, Идегәй әмир! *(Хансарайга юнәлә.)*

Сәлим *(Сарай бие еракларак киткәч)*. Олугларның күчмәгә китүе биналарын күтәрергә теләмәүдән түгел, минемчә, сәргаскәр.

Идегәй. Беләм. Мин керткән мөселманча тәртипләр ошамый аларга. Элеккечә, кол җилкәсендә кырын ятып, һавага төкереп яшәүләрен сагыналар. Дөнья куйгач, өсләренә тау-тау корганнар әйдерәселәре килә! Ә нинди гамәлләре өчен андый зур хөрмәт?!

Сәлим. Алай гынамы икән, сәргаскәр? Минемчә, иң зур сәбәп: гап-гади кешеләрне — менә минем кебекләрне үз яныңа якынайтуыңда! Һәм — ханнардан да гайрәтлерәк сәргаскәр булуың кемнәргәдер йокы бирми!

Идегәй. Анысы да бардыр... Күрербез!

**Аларга атта чабып килүче сөрәнче якынлаша.**

Сөрәнче. Ишетмәгәннәр — ишетсен! Күңелсезләр — сөенсен! Норадын батыр, Җаек таулары артында бастырып тотып, Урда дошманы Туктамыш ханның башын ора чапкан! Норадын батыр йортыбызга тагын бер зур шатлык алып кайтып килә!

Идегәй *(йөзе ачыла, әмма кырыс)*. Менә, Сәлим дус, игътибар ит: әгәр дә Туктамыш хан, язмышны елмаеп, мине җиңгән булса, ошбу сөрәнче шушындый ук шат йөз белән бу хакта хәбәр иткән булыр иде. Чөнки халыкка Идегәй җиңде ни дә, Туктамыш ни — икесе дә барыбер, халык икесенә дә биек каланчадан төкереп кенә карый!

Сәлим *(елмая)*. Ниндидер усал кигәвен тешләгән, ахры, сине бүген, Идегәй агай! Барыбер булса — мин Туктамыш ягына чыгар идем. Димәк, һәркемгә дә барыбер түгел!

**Халык уртасында калган сөрәнчегә таба китәләр.**

Идегәй *(киная белән)*. Синең — үтәлмәгән максатың бар. Шул ниятең йөртә сине минем янда! *(Атын кызулатып китә.)*

**Сәлим гаҗәпсенеп туктап кала.**

Сәлим *(Идегәй артыннан кычкыра)*. Алайса... Нишләп соң син мине үз тирәңдә тотасың, сәргаскәр?!

Идегәй *(аңа таба башын борып)*. Онытылып китеп, хата җибәрмәс өчен! Кайчак-

та хәтта гап-гади чебен дә кешегә ваемсыз йокларга ирек бирми! *(Кола.)*

**58. Алтын Таш хан сарае. Тәхет залы. Кич.**

**Тәхет залына Идегәй, аның улы Норадын, Сәлим би һәм Җанбай би керәләр.**

Норадын *(тәхет янына килә, кулында — канҗага).* Туктамышны, әткәй, атының койрыгын чираклап төйнәп, шул сүтелгәнче бастырып ку дигән идең,— өч мәртәбә чиракларга туры килде. Менә хәзер — канҗагадагы «бүләк»не сиңа да күрсәтергә була! *(Канҗаганы төбеннән тотып селки: тәхет каршына Туктамыш ханның канлы башы тәгәрәп төшә.)* Тәхеткә менеп утырып, Идегәй батыр, аякларыңны шушы баш өстенә куй! Гомерең буе хыялланган көнең килде, ниһаять: дошманың кояшы баеды, иртәгә таңнан — күккә синең кояш калкачак!

Идегәй *(тыныч булырга тырышып).* Гөнаһлы булма, улым Норадын, син мөселман баласы ич. Туктамыш хан, безнең өчен кем генә булмасын, гайрәтле яугир иде, иртәгә хөрмәтләп җирләрбез, канҗагана салып куй. Вәгъдәңдә тордың, улым, атаның кан дошманыннан үч кайтарып кайттың, рәхмәт. Инде хәзер, улым, вәгъдәмне үтәргә минем нәүбәт: Ханәкә — синеке, туйга әзерлән!

Норадын. Монсы белән шатландырдың мине, әти! Ә тәхет?!

Идегәй. Тәхеткә ни булсын? Тәхет булганда хуҗасы табыла аның, улым. Берсекөнгә Шадибәкнең улы Булат солтанны тәхеткә күтәрәчәкбез.

Норадын. Мин риза түгел моңа, әти! Тәхет — синеке! Инде дә үзең анда утырырга теләмәсәң...

Идегәй *(катгый бүлдерә).* Бу хакта сүзне бетердек, улым! Озын сүз нигә кирәк?

Норадын *(кызып).* Юк! Бетермибез, әти!

Идегәй *(Сәлим белән Җанбайга).* Улым белән икебезне генә калдырыгыз.

**Сәлим белән Җанбай баш иеп чыгып китәләр.**

Норадын. Мин һаман аңламыйм сине, Идегәй батыр!

Идегәй *(борчулы).* Аңлар идең дә... Аңларга теләмисең, ахры! Җанбайны ник үзең белән алып кайттың? Ник орыш кырында башын дөмектермәдең?! Туктамыш хан белән арабызга гомер буе кара мәче җибәреп ятучы шул эт иде бит инде!

Норадын. Туктамыш хан мине синең янына Сәмәркәндкә куганда шул Җанбай би әзерләтте миңа юл хәстәрен! Икенчедән, картлыгын кызгандым. Аннан соң — ялгызы ни кыра ала ул хәзер? Туктамышның үләр алдыннан әйткән сүзләре хак булган икән: ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас, диде ул! Идегәй Чыңгыздан килгән чал башымны чаптырса да, хакимлекне үз кулында барыбер озак тота алмаячак ул, дип көлде! Ә син үз кулына килеп кергән тәхеткә менеп утырырга да куркасың! Гомерлеккә аны үз нәселеңә багышлау турында уйламавыңны әйткән юк!.

Идегәй. Бер үк сүзне атаңнан кабат-кабат кабатлатма, улым! Урданың каты кануны бар: аның буенча тәхет — безнең нәселгә язык. Беркем дә кичермәячәк безне. Хәтта бүгенгесе көндә дус иткән әмирләр дә безгә каршы күтәреләчәк. Шуны телисеңме син?! Нәрсә җитми сиңа, улым?! Ханнар башында коры таҗ гына бит — хакимлек тулысынча безнең ихтыярда! Пешереп сөйләш!

Норадын. Мин — куркак ханнарның колы булырга теләмим! Кем кан коя-коя Урданы ныгытты?! Синең белән без икәү! Ә унга тугыз тулмаган бер килмешәк рәхәтләнеп җәелеп тәхет кыздырып утырсынмы?! Мәңге килешмим мин мондый гаделсезлек белән! *(Ишекне тибеп ачып, чыгып китә.)*

**Туктамышның башы тәхет алдында тузанда аунап кала. Идегәй, авыр сулап, утыргычка барып утыра: улы белән сүзгә сүз килүне алдан сизенгән ул, әмма болай бик тиз орыш-талашка күчүне көтмәгәнгә охшый.**

**59. Алтын Ташта хан кызлары пулаты. Шул ук кич.**

**Туктамыш ханның кызлары Ханәкә белән Кәнәкә кәнизәкләре арасында үкси-үкси елап утыралар.**

Ханәкә. Нишлим, зинһар, өйрәтегез мине, кызлар?.. Башта ачы язмыш Кәнәкә белән икебезне бөтен якын туганнарыбыздан, газиз әткәбез белән әнкәбездән аерып, кара дошманыбыз Идегәй кулына тапшырды! Инде килеп, хәзер аның кабәхәт улы Норадын сөекле әткәбезнең асыл башын ора чапкан! Әнкәбезнең язмышын да белгесез... Абыйларыбызның һәм энекәшләребезнең хәлен шулай ук белмибез! Ә бүген ишетәм: Идегәй мине, бөек Туктамыш каганның кызын, үзенең кара күчегенә — атамның изге канын койган кабәхәт улына тотып бирмәкче икән! Әй, Кәнәкә игезәккәем! Каһәрле язмыш татыр өчен генә килгәнбез икән без синең белән бу фани дөньяга! Хан кызлары булып туганчы, бер мескен кол кызы булып туган булсак, мондый ачы көннәрне күрергә язмас иде, бәлки!

**Җанбай би килеп керә: хан кызлары шатланып аңа ташланалар.**

Кәнәкә. Газиз әтиебез урынына күргән Җанбай агабыз! Син исәнсең икән! Ә безнең мескен әтиебезне... *(Буылып елый.)*

Җанбай *(аларның чәчләреннән сыйпап юата).* Еглмагыз, ятимкәйләрем... Әтигезнең урыны оҗмахта булыр... Олуг җанлы, зирәк акыллы хаким иде ул... Нишлисең бит, тәкъдиредер... Гомерем күпме калгандыр, барысы да Ходай кулында, әмма мин шуны яхшы беләм: Туктамыш каганның якты сурәтен мин мәңге йөрәк түремдә саклаячакмын! Атсыз идем, ул мине атлы итте, котсыз идем, ул мине котлы итте! Дансыз идем — дан бирде! Еглама, Ханәкә! Бу көннәрдә сиңа бигрәк тә башыңны югалтырга ярамый! Нык бул! Киңәшемне тыңласаң, кызым... Кызым дип дәшкәнгә кичер мине.

син миңа үз кызым кебек кадерле бала! *(Бүтәннәргә чыгып китәргә ишарәли. Ханәкә белән икәү генә калалар.)*

Ханәкә. Кинәшеңне әйт, Җанбай агай! Хансарайда хәзер бердәнбер таяныр кешем — син!

Җанбай. Канәчкеч Норадын әтиеңнең башын тәхет аягы астына ташлаганда мин дә бар идем. Шушы «батырлыгы» өчен Идегәй углына хатынлыкка сине вәгъдә итте. Норадын, бәлки, шушы кичтә үк сине күрәсе килеп керер: тар карныңны киңәйтеп, биленә киез урап куй! Көмәнле дип уйласын! Кем эше бу, дип сораса — үз атаңнан белеш дип җавап бир. Аталы-угыллы канга батып орышсыннар әйдә! Бер-берсен җәһәннәмгә олактырсалар тагы да әйбәтрәк! Эшлисеңшуны, кызым?

Ханәкә *(тәвәккәллек белән)*. Эшлим, мең кат кирәксә, мең кат эшлим, Җанбай агам!

**60. Алтын Таш хансарай. Шул ук кич.**

**Караңгылы-яктылы анфилада бүлмәләренең берсендә Норадын белән Ханәкә очраша.**

Норадын *(йөзе ачылып)*. Хәлләр ничек, тулган аем Ханәкә солтан! *(Кызның «көмән»ен күреп, авызын ачып ката. Көчкә исенә килеп.)* Бу нинди бүләк?! Тәнаңны кем бүресеннән ялаттың, Ханәкә солтан?! *(Кызны җилкәләреннән тотып җилтерәтә.)* Кем эше?! Дөресен әйт!

Ханәкә *(башын аска ия)*. Атаңнан сора... Мәгънәсен ул белә! *(Норадыннан ычкынып, үз юлы белән китә.)*

Норадын. Үтерәм мин аны! *(Тәхет залына ташлана.)*

**Ханәкә үз пулатына йөгерә.**

**61. Тәхет залы. Шул ук вакыт.**

**Ачуыннан нишләргә белмәгән Норадын тәхет залына атылып килеп керә: Идегәй һаман да баягыча борчулы уйлар эчендә утыра. Углы кергәч, шатланып башын күтәрә, ләкин шундук чырае кара күмергә әйләнә.**

Норадын *(әтисен киеменең якасыннан тотып җилтерәтеп торгыза)*. Син мине ничә еллар, Сарай каласыннан алыс булсын дип, качкын Туктамышны эзләп чабарга мәҗбүр иттең! Ялыңны-койрыгыңны кисәм хәзер!

Идегәй. Чү, углым, чү, нишлисең?! Язмаганны сөйләмә! *(Якага яка килләр.)*

Норадын. Астыртын ниятеңне беләм хәзер! Син, үз сүзеңнән танып, углыңа багышланган киленеңне үзеңә янга калдырырга чамалагансың икән, карт төлке! Ә мин яр башына ятып, сусыз икмәк кимереп йөрим! Моннан соң атам түгел син миңа — кара дошман! *(Әтисен бар көченә этеп җибәрә. Идегәй йөзе белән тәхет култыксасына янтаеп барып төшә һәм, «Ай күзем!» — дип идәнгә тәгәри, башы белән Туктамыш хан башына бәрелә.)*

Идегәй. Ай, консыз имгәк икәнсең, күземне чыгардың! *(Уң күзен кулы белән каплый: бармаклары арасыннан кан чәчрәп чыга.)* Үз атаңа кул күтәрәсең?! Мин сине дөньяга тудырдым, картаймыш көнемдә үз башыма гына булган икән! Хан баласы сыман тәрбияләдем, чык тидерми үстердем! Ә син су эчә торган коеңа төкергән ят бавыр булып үскәнсең! Атаңнан да аерылгач, кемгә барып сыгынырсың син бу дөньяда, яхшыдан яман туган нәмәрсә?! Бердәнбер таянычың — мин ич! Әйтеп адәм ышанмас!

Норадын. Яссы телең ни әйтмәс! Кылыгым кемгә яраса, шуңа сыгынырмын! *(Пыр тузып чыгып китә.)*

**Тәхет залына Сарай бие ашыгып килеп керә.**

Сарай бие *(Идегәйнең кан эчендә утыруына аптырап, ишек төбендә туктый, уңайсызланып)*. Кичер, Идегәй әмир, вакытсыз кердем бугай...

Идегәй *(авырлык белән торып баса һәм елмайгандай итә)*. Туктамыш хан үлгәч тә миннән үч ала, ахры: ялгыш канына басып таеп егылдым... Йомышыңны әйт, Сарай бие!

Сарай бие. Хәбәрләрем шәптән түгел, Идегәй әмир: Туктамыш ханның өлкән углы Җәләлетдин солтан, Литва кенәзе Витаускаска сыенып, Кырымны яулап алган! Ә кече энесе Кадыйрбирде солтан Күк Урда пайтәхете Сарайчыкны камаган. Кебәк белән Кабуллары — Сыгнакта, имеш... Күрәм: аталарының эше беткән, уллары бәлигъ булды — хәзер алар каныгачак сиңа!

Идегәй *(кискен)*. Хан күтәрергә бар нәрсә дә әзерме?

Сарай бие. Син боерганча, Идегәй әмир.

Идегәй. Ярен иртүк хан күтәрәбез. Кырымга яуны Булат хан белән үзем житәклим! Сарайчыкка... бер төмән белән Сәлим би китер. *(Идәндәге башка ымлый.)* Моны — җыештыр!

**62. Кырым. Сиваш бугазы. Кич.**

**Идегәйнең гаскәре, кыенлык белән тозлы диңгез суын ерып, Кырым ягыннан Сиваш бугазын кичә: атлар көч-хәл белән атлыйлар, сугышчылар да бик нык алҗыган.**

**Идегәй янына каршы яктан чапкын килә. Сәргаскәрнең уң күзе кысык.**

Чапкын. Сәргаскәр! Җәләлетдин солтанны Булат хан, Кырымнан далага чыккач, бастырып куып җитте. Орыш бик каты булды: ике яктан да чиру-чиру баш салды! Ә Булат хан үзе авыр яраланды. Җәләлетдин солтанның алтын аткыюч угы тигән. Төмәнбашы Шәйбан әмир сорый: Булат солтанның хәле бик начар, нишлибез, ди.

Идегәй. Булат хан орышта үзен ничек тотты?

Чапкын *(икеләнеп)*. Әйтеп мактарлык түгел, салып таптарлык түгел, дигәндәй... Яшь чагы бит әле.

Идегәй. Ә Җәләлетдин?

Чапкын. Ул тагын качып котылды. Калдык гаскәре белән бергә! Шәйбан әмир аны Киевкә тиклем эзәрлекләргә тели. Гаскәре аз!

Идегәй *(уйланып)*. Сарайга кайтып, тәхеткә Тимер Котлый ханның улы Тимербәкне күтәрсен. Мин үзем, Сәлим би артыннан, Кадыйрбердене бастыра китәм. Яна ай туута мине Сарайда көтсеннәр!

**63. Сарай каласы капкасы. Төн.**

**Якты аяз төн: күктә яңа ай калыккан. Сарай каласы капкасы янына Идегәйнең аз санлы атлы гаскәре якынлаша. Капка бикле. Атлы гаскәр капка алдына килеп туктый. Идегәйнең бер нөгәре капка шакый.**

Тоткавыл *(капка өстендә күренә)*. Төн уртасында кем йөри анда кала мазасызлап?!

Сәлим. Ач күзеңне, тоткавыл! Сәргаскәр Идегәй әмир синең алда!

Тоткавыл. Сарайчыкны кырып салган кара афәттән дөмекмәдемени әле ул?! Кайдан кайтса — шунда тайсын! Идегәй дигән сәргаскәрне белмибез без индеге көндә. Үзен «ирекле ир» дип атарга ярата иде — хәзер чыннан да ирекле, дүрт ягы кыйбла!

Сәлим. Ни мыгырдыйсың, ахмак?! Эт талый дип, бет талый!

Тоткавыл. Син үзең ахмак, Сәлим би! Сарайга хәзер Тимер-бәк хан хуҗа! Ул Идегәй дигән шакалны калага кертмәскә кушты!

**Дивар тирәсендәге караңгылыктан бер хатын килеп чыга.**

Идегәй *(шаккатып)*. Айтулы?! Нишләп йөрисең син монда төн карасында?! *(Атыннан төшеп, хатынын коча.)*

Айтулы. Синең кайтканыңны көттем, Идегәй... Тимер-бәк хан мине тәхетендә яңа шопкә каладан куып чыгарырга боерды! Далада купкан ваба йотсын ирең белән бергә, ди.

Тоткавыл *(көлә)*. Менә — хатыны да табылды, сыңар күз Идегәй! Бергәләп кырда улашырсыз! Икегезгә өч күз: Тимер-бәк ханнан качарга төнге юлны җиңел табар... Гык! *(Авызына ук кадалып, капка астына әйләнеп төшә: Сәлим аткан икән.)*

**Капка артында эчке якта көчле шау-шу башлана: бик күп ат тояклары тавышы якыная.**

Тавыш *(эчке яктан)*. Капканы ачарга!

Айтулы. Тимер-бәк хан тавышы! Идегәй! Сөеклем, кач тизрәк: аның гаскәре бик күп! Явыз җанбаз булып чыкты ул. Хан итеп күтәргәнгә сиңа рәхмәт укыйсы урынга...

Идегәй. Айтулы бикәгә ат!

**Шундук иярле ат китерәләр. Идегәй хатынына ияргә менәргә ярдәм итә һәм үзе дә атына сикереп менә.**

Идегәй. Минем арттан! *(Төн караңгылыгына чума.)*

**Идегәйнең аз санлы гаскәре аның артыннан ташлана. Шул мизгелдә кала капкасы дәрвәзә ачыла һәм эчтән атлы гаскәр ташкыны ургылып чыга. Иң алда яшь хан Тимер-бәк солтан килә. Алар төн караңгылыгында югалган Идегәйне эзләрлекләп китәләр.**

**64. Ку күле буе. Иртә.**

**Камышлы күл яры буйлап бер сыбай бара: аута чыккан Киң Җанбай ул. Җилкәсеннән җәясен сала һәм садагыннан ук ала: күл читендә ук бернечә кыр үрдәге чемченеп йөри икән. Киң Җанбай атын иләп кенә атлатып, камышлыкка керә. Шулчак камыш арасында посып яткан яугирләр аның муенына бугалак салалар һәм ияреннән җиргә сөйрәп төшерәләр. Ә дигәнче кулларын артка каерып бәйләп, ияренә аркылы ташлыйлар. Постырмада торган атларына менеп, Киң Җанбайны каядыр алып китәләр.**

**65. Кадыйрбирде ханзаданең яу чатыры. Иртә.**

**Киң Җанбайны, атыннан төшереп, чатырга кертәләр һәм Кадыйрбирде алдына тезләндерәләр.**

Кадыйрбирде *(үрдәк ите кимереп утыра)*. Нәрсә, Туктамыш атамның элекке баш вәзире Җанбай би, үрдәк ите ашыйсың килдеме? Ауга чыктыңмыни? *(Көлә.)* Мә, аша! *(Бераз ите калган үрдәк тәпие белән Җанбайның авызына бәрә.)* Элек атамның колы идең, хәзер кемгә тәлинкә тотасың? Бүген кемгә кол булдың? Миңа мирас алтын тәхеткә кемне мендерәсең, юмакай тел?!

Җанбай. Мин Идегәй түгел, Туктамыш хан улы Кадыйрбирде ханзада. Аның кебек ханнар башы белән уйный алмыйм.

Кадыйрбирде *(кискен)*. Ашыкма, Идегәегез дә ханнар башы белән күп уйный алмас! Ваба афәтеннән котылса, минем кылычтан үтәр! Сарай юлына Җәләлетдин агам тузан төшермәде, инде миңа чират! Йә, әйт, эт Җанбай: атама хыянәт итеп, аны дошманы алдында ялгызын калдырып сызганың өчен нишләтим сине?! Оят белмәгән чал башыңны ора чабыйммы, ат койрыгына тагыйммы? Әллә — янәдән икейөзлеләнеп бер яктан икенче якка күчеп йөри алмас өчен табан астыңны телгәләп, ат кылы сибимме? Сайла!

Җанбай. Чал башымны нахакка мәсхәрәләмә, Кадыйрбирде ханзадә. Мин гомер бакый атаңа тугры булдым. Атагыздан сез тугыз бала — тугыз солтан ятим калдыгыз. Миңа тугызыгыз да үз балаларым кебек кадерле.

Кадыйрбирде *(үз алдына)*. Аның каруы — без үзебез бер-беребезгә дошман! Бугазларыбызны чәйнәшергә әзер торабыз.

Җанбай. Бер кашык каным бар: агызмасаң, мин аның һәр тамчысын сиңа багышлаячакмын.

Кадыйрбирде *(шаркылдап көлә)*. Куллыннан ни килә соң синең, эшем хәсрәте?!

Җанбай. Эшем түгелгә тыгылганым юк. Идегәйнең улы Нурадынны тотып бирә алам дисәм, ни әйтерсең, ә, Кадыйрбирде ханзадә?

Кадыйрбирде *(янтавына энә кадалгандай дерт итә)*. Нурадынны?! Кайчан?!

Җанбай *(эченә җылы керә)*. Ау өчен җайлы урын карап кайтырга җибәрде ул

мине: Ку күле камышлыгына постырма куй: кичке якта Норадын каршында басып торыр.

Кадыйрбирде *(көлә)*. Үзеңне кәҗә бәтие урынына бәйләп ташлаган жирдәме? *(Кырыс.)* Кара аны: йә уңам, йә туңам, дип мине карама көленә утыртырга маташсаң — кулым озын минем!

**66. Ку күле тирәсе. Кичке як.**

**Камышлы күл янына атка атланган Норадын белән Киң Җанбай килә. Кояш батарга күп калмаган — офыктан агач биеклеге генә югарырак. Үрдәкләр кычкырышкан гавыш.**

Җанбай. Ишетәсеңме, Норадын би? Ә син ышанмаган идең!

**Кыр үрдәкләре кычкырышкан турга якынлашып, камышлыкка керәләр. Җанбай арткарак кучә һәм кинәт юкка чыга: Норадын моны сизми дә кала. Атын камышлык эченә бер-ике атлатуга, Норадынның муенына бугалак бау салалар һәм, ияреннән сөйрәп төшереп, кул-аякларын бәйлиләр. Норадын эһ диярга дә өлгерми. Аны, атына аркылы салып, Кадыйрбирде чатырына алып китәләр.**

**67. Кадыйрбирде чатыры. Кич.**

**Кадыйрбирде ханзадә әмирләре белән ашап-эчеп киңәш тота. Киң Җанбай да шунда.**

Кадыйрбирде. Ярар, олуг әмирләрем, кан дошманыбызның улы Норадын безнең кулда — улын нишләтәбез дә, атасын ничек тотабыз?

**Әмирләр фикерләрен ачып салырга ашыкмыйлар.**

Җанбай. Һәр эшнең бисмилласы була дигәндәй, әмирләрең ачуланмаса, бер киңәш әйтеп карар идем, Кадыйрбирде ханзадә.

Кадыйрбирде. Тыңлыйбыз сине, Җанбай би.

Җанбай. Ишетүемчә, Идегәй индеге көндә Җаекның аръягында күчмә йөри, имеш. Илчеләр җибәреп: улыңны кун түләп йолып алмасаң, башын юк итәбез, дип әйттерик. Мин аны яхшы беләм: ул улы өчен утка-суга керергә әзер. Хәйлә белән тозакка төшерә алырбыз шәт?

Кадыйрбирде. Киңәшең ярыйсы. Кемне илче итеп җибәрәбез, әмирләр?

Җанбай. Кичер, хан: тагын бер сүзем калды. Ни җитте кешене җибәрү бездән хаталык булыр. Монда җыелган әмирләрнең улыллары Норадын белән бергә аунап үстеләр. Аларны юлласак, ышанычлырак булмасмы?

Әмирләр *(үзара пышылдап)*. Эшләп түгел, кешнәп ярый белә бу! Теле чарлы!

Кадыйрбирде. Күрәм: зиһенең тупыйкланмаган икән әле, Җанбай би! Шулай иттек!

**68. Җаек елгасы ярында Идегәй чатыры. Көн.**

**Елга уртасында аргы яктан Идегәй чатыры янына чыгып килүче зур сал күренә.**

Шыгавыл *(чатыр авызына башын тыга)*. Сәргаскәр! Теге яктан ниндидер сал килә! Норадын би түгелме икән? Берсе аңа бик тә охшаган.

**Чатырдан шундук Идегәй белән Айтулы атылып чыга: кулларын кашларына куеп, салны күзәтәләр.**

Айтулы *(көрсенеп)*. Ялгышасың, шыгавыл... Улыбыз юк анда. *(Күңелсезләнеп чатырга кереп китә.)*

**Идегәй сүзсез генә салның килеп җиткәнен көтә. Аның янына нөгәрләре җыела. Илчеләр ярга чыгалар һәм Идегәйгә баш иеп йөгенәләр.**

Идегәй. Юлыгыз булсын, атыгыз кем? Ни-нәрсә хәбәр китердегез: аумы, илме?

Берсе. Без — Кадыйрбирде ханның илчеләре. Ил дә түгел, яу да түгел, Идегәй әмир! Улың Норадын ханыбыз кулында тотсак! Без барыбыз да Норадын белән бергә орыш-яу уеннары уйнап үскән уланнар, шуна күрә үзебез килергә булдык. Кадыйрбирде хан сиңа дошманлык сакламый, улыңны, кунын түләп, йолып алырга үзенә чакыра. Тик Кадыйрбирде ханның Сарай тәхетенә калгай икәнен танырга тиешсең. Шушы шартнамәгә күнмәсәң, Норадын үтереләчәк! *(Идегәйгә ярлык-хат суза.)*

**Чатырдан Айтулы атылып чыга.**

Айтулы. Ризалыгыңны бир, атасы! Йолып ал газиз улыбызны!

Идегәй *(шартнамәне алмый)*. Җанбай би сездәме?

Илче. Әйе! Ул хәзер — Кадыйрбирде солтанның баш киңәшчесе.

Идегәй. Киң Җанбай булган җирдә бер-бер этлек әзерләнми калмас! *(Нөгәрләренә.)* Җилесен бәйләгез! Телчәне белән!

**Илчеләрне, күз ачып йомган арада коралсызландырып, бәйлиләр.**

Ә икәвегез Кадыйрбирдегә кайтып житкезегез: Норадынны нитсә дә — аның үз эше. Ләкин белеп торсын: мин монда калганнарыгызның барысын да юк итәчәкмен!

Айтулы *(иренең кулына ябешә)*. Зинһар хаталык кылма, атасы!.. Улыңны җиде кушта бәрабәренә харап иттерәсең бит! Ул аларның һәрберсен сыңар кулы белән генә чәя иде.

Идегәй *(китәргә кыймый торган ике илчегә)*. Сүземне ишеттегез!

**Айтулы ушын югалтып егыла.**

*(Нөгәрләренә.)* Бикәгезне чатырга кертегез.

**69. Кадыйрбирденең чатыры. Кич.**

**Кадыйрбирде солтан кәнизәкләре белән кәеф-сафа корып, мәхәббәт уены уйнап ята.**

**Чатырга сакчы белән шаулаша-шаулаша әмирләр килеп керәләр.**

Кадыйрбирде *(ачу белән).* Ни кирәк? Күзегез чыкмагандыр! Иртәнчәк!

Әмирләр *(бер-берсен бүлдерә-бүлдерә).* Угылларыбызны Идегәй тотсак итеп алып калган! Тугыз угланның җидесен! Без җидебез дә синең кебек үк Чыңгыз нәселеннән! Угылларыбызны коткаргыл, Кадыйрбирде солтан!

Кадыйрбирде *(шәрә кәнизәкләренә югалырга ишарә ясый, үзе ефәк ятмага төренә).* Берәмләп кенә сөйләгез! Мангышлак олысы бие Барын, син!

Барын. Зинһар, сүзебезне екма, Кадыйрбирде солтан! Норадын углымны теләсә нишләтсеннәр, тик истә тотсыннар — кулыма эләккән җиде угланның җидесенең дә башын юк итәчәкмен, диган Идегәй! Угылларыбызны, шул мәртәтнең көчегенә алмашып, йолып калыйк! Атабыз бул!

Кадыйрбирде *(уйланып).* Яхшы-яхшы!.. Җанбай бине минем янга!

**Тышта бер-бер артлы «Җанбай би — солтан янына!» дип кычкырган тавышлар ишетелә. Озакламый чатырга күтәренке кәефле Кин Җанбай килеп керә.**

Җанбай *(баш иеп).* Кичер, хан: еракта-рак идем, бераз көттердем.

Кадыйрбирде *(кырыс).* Син! Юка баш, сыек ми! Синең киңәш белән олугларыбызның угылларын Идегәйгә җибәрдек: ул аларны тотсак иткән — башларын чаптырырга ниятли. Югары очырып, түбән кундырдың! Хатаңны җуймасаң, миннән ярлыкау көтмә! Бу юлы чал башың да киртә булмас!

Җанбай *(сөмсере коелып, эченә шыр җибәрә).* Иртәнгә чаклы вакыт бир, Кадыйрбирде хан?

Кадыйрбирде. Орыш бие Шырын! Чатырына сак куй — үзе сораганча уйласын!

**70. Зиндан. Иртән.**

**Агачтан өелгән жыелмалы күчмә зинданга Кадыйрбирде солтан, әмирләр һәм Кин Җанбай жыелганнар. Алар каршына уртага үткен пычак очлары тырпаеп торган урындык куелган. Ишектән кергәч, урындык янына үтәсе идән такталарына да очлы тимер чөйләр кагылган.**

Кадыйрбирде. Тотсакны кертергә!

**Ишек тирәсендә ыгы-зыгы килү ишетелә һәм ярым яланга ч Норадын килеп керә: аның куллары артка каерып бәйләнгән.**

Кадыйрбирде. Түргә үт, тотсак, утыр. *(Урындыкка ымлый.)*

**Норадын үзен нәрсә көткәнен шундук аңлый, әмма горур кыяфәт белән, яланаяк очлы чөйләргә баса-баса, пычак суккан махсус урындыкка барып утыра. Каршысында утыручы дошманнары аны күзәтәләр, ләкин ул сер бирми, хәтта йөзе дә чытылмый. Очлы пычаклар тиз арада Норадынның тәненә үтеп керә һәм идәнгә кызыл кан янгыры ява башлый. Әмма ул утыргычтан тайчанмый.**

Кадыйрбирде *(егетнең чыдамлыгына гаҗәпләнә).* Буталыштан форсат табып, син күчмә нугайлар белән пайтәхет Сарайга бәреп кердең: атамнан мирас калган казнаны кая иттең? Ничә буын ата-бабамнар түкми-чәчми туплаган малны!

Норадын *(сызгырып куя).* Юк, без яшь чакта сызгыру юк иде дип әйтте ди бер бабай! Атаң белән бабаңнар һәм бертуган абыйларың халыкны талый-талый, ач-ялангач калдырган иде — калдык-постыгын кырып-себереп сәдакә итеп өләштем.

Кадыйрбирде. Чапса, жир бавырын кыдырган туры атым бар иде — аны нишләттең?

Норадын. Туры атыңа менеп, үзеңә каршы яу чаптым. Орышта синең уктан ауды!

Кадыйрбирде. Сарай каласында биек-биек бай йортларыбыз бар иде — алар кая?!

Норадын. Төннәр айсыз караңгы чак иде — янар учак иттем.

Кадыйрбирде. Кара кештән тегелгән миң куйлык, утыз кызлык алтын-көмеш бизәкле көбә туным бар иде — ул кая?

Норадын. Ул туныңны җилкәмә салып, сиңа каршы сугыштым, шунда кылычтан теткәләнде. Бөктәр тышлатып, бер колыма бүләк иттем!

**Кадыйрбирде ачуына буылып тынып кала.**

Җанбай. Ыржыенны ыржайтма! Тугыз солтанның атасы Туктамыш каганны нишләттең, Норадын? Гүзәл Ханәкә белән сылу Көнәкә солтаннарны нишләттең, Норадын?! Алтын Таш хансарай тулы саф алтын, энҗе-якут, гәүһәр ташлар иде — аларны кая куйдың, Норадын?!

Норадын. Кәмал углы эт Җанбай! Ат коега төшсә, гөберле бака айгырлык кылыр! Батырның аяк-кулы бәйле булса, эт Җанбай тылмач булыр! Ял авызыңны, юрга янында юрга, мулла янында мулла! Кем аш бирсә — син шуңа ул, кем мал бирсә — син шуңа кол. Җиде балаң да кол булып, җиде корысын! Хәер, сигезенче углың янында утыра, бугай: Йәникә бикә тирәсендә артык еш чуалуыңны һәркем белә иде! *(Көлә.)* Ярар, анда минем эшем юк — үзегез ачыкларсыз. Ханәкә белән Көнәкәгә ни өчен «кызым» дип дәшүеңне дә!

**Кадыйрбирде ялт итеп Кин Җанбайга карый: аның ачуыннан ярылырга житкән.**

*(Кадыйрбирдегә карап сөйли.)* Син, Кадыйрбирде солтан, шушы мәкерле эт ярдәмендә алдалап, мине кулыңа төшердең! Мин синең атаңның башын, сакалын кара канына батырып, тулгамалы үз айбалтасы белән ора чаптым һәм Идегәй атамның аягы астына салдым. Ханәкә белән Көнәкә туташнарны миңа Тәңре үзе бирде — мин ул яткан тауларны кәнизәкләрем иттем! Хәзер миңа рәхмәт укыйлар. Атаңнан артып калган казна малын кая иткәнемне ишеттең.

Аяк-кулым бәйле, ҝулымда ук-садагым, булат кылычым юк, ирекле булсам, мин синең үзеңне дә атаң артыннан олактырыр идем, Кадыйрбирде! Исән калдырсам — миннән эзең дә өркер иде! Эт дагалап көн күргәннең хәйләсе белән кулга төшереп, үткен пычакта утыртасың: йөрәгемә пычак тыксаң да ыжламам! Богаулы алдында ядәч киерү — йоклаганны үтерү белән бер: ир кеше эше түгел ул, хатын-кыз эше! Әйдә — корал тотып, йөзгә-йөз чык минем каршыга! Шунда булырсың чын яугир!

**Кадыйрбирде** *(әмирләре белән караша, әйтерсең, Җанбайны күрми дә)*. Кыю әйттең, Норадын би... Атаң янына миннән сагъ кит! Кулларын чишәргә! Идегәй әмир углына — ат!

**71. Кадыйрбирде чатырының алды. Иртән.**

**Норадын өчен алтын иярле ат китерәләр. Кадыйрбирденең яугирләре аны Җаекка кадәр озатырга әзерләнә. Норадынны бер төркем сугышчы, качмасын дигәндәй, уратып алган.**

**Җанбай** *(Кадыйрбирденең колагына пышылдый)*. Кадыйрбирде хан! Атны иярсез бирсеннәр: мин әйткән төп хәйлә дә шул ич инде! Норадынның арты яралы чак...

**Кадыйрбирде** *(йөзен чыта)*. Исемдә! *(Янында торган бер нөгәренә нидер пышылдый.)*

**Норадынны алтын иярле атка атландыралар, ләкин киемен бирмиләр.**

**72. Җаек елгасы. Кич.**

**Елганың аргы ягында — Идегәйнең чатыры. Идегәй үзе, берничә нөгәре белән бергә, яр башында тора. Хатыны Айтулы анда күренми.**

**Җаекның бирге ярына Кадыйрбирденең яугирләре чабып килеп туктый. Җайдак аттан Норадынны җиргә төшерәләр: димәк, юлда килгәндә иярен салдырганнар. Ул сизелерлек хәлсезләнгән, әмма әлегә аякларында нык тора.**

**Идегәй** *(түзми, ашкынып кычкыра)*. Норадын углымны җибәрегез! Мин җиде тотсакны сезгә кайтарам!

**Норадынны, салга бастырып, елгага кертеп җибәрәләр.**

**Аргы яктан аның каршысына әмирләренең балалары килә.**

**Норадын зур ишкәк белән үзе ишә: ягырчир башланса да гайрәте шактый калган әле.**

**Ике сал елга уртасында очраша.**

**Идегәй.** Җиде Идел кичкән, Туктамыштай алыпның башын ора чапкан батыр углым! Каршыңа җиде дошманыбызның җиде углы килә — берсен дә исән калдырма! Берәм-берәм суга томыр барысын да!

**Әмирләренең угыллары, Норадын белән очрашмас өчен, читкәрәк ишәргә тырышалар, әмма Норадын бар гайрәтенә ишеп, салны салга бәрә һәм дошманнары өстенә арысландай ташлана. Бер-ике минуттан ике сал өстендә ул берүзе кала. Салны салга бәйләп, атасы янына ашыга. Аның артында су өстенә һава куыклары гына калкып чыга.**

**73. Җаекның аргы ягы. Шул ук вакыт.**

**Бер-берсенә бәйләнгән ике сал ярга бәрелеп туктый: Норадын әтисе янына менә. Ул хәлсезлектән шактый чайкала. Идегәй моңа башта игътибар итми: ул — чиксез шат.**

**Идегәй.** Исән-имин кайттыңмы, батыр углым! *(Сөенеченнән улы тирәсендә ике-өч тапкыр бөтерелеп әйләнеп чыга.)*

**Норадын** *(ике тезенә дә төшеп, әтисенең кулларын үбә)*. Бөтенесе өчен кичер мине, әткәм!.. Акылсыз углың сиңа күпме кайгы-хәсрәт китерде! Анамның күпме чәчен вакытсыз агартты! Анам кайда? Анамнан да энҗе дип балык күзе саткан юньсезләргә алданып йөргән юләр углын кичерүен үтенәм!

**Идегәй** *(углының башын сыйпый, авыр сулап)*. Соңга калдың, углым... Анаң сине көтеп ала алмады... Ул вафат инде...

**Норадын.** Ничек — вафат?!

**Идегәй.** Моны бер Ходай гына белә, углым... Тор, син явыз дошман авызыннан исән-имин котылып кайттың, бу минем — сөенечем! Безне алда зур эшләр көтә: Урдабызны Туктамыш көчекләреннән арындырасыбыз бар! *(Улын күтәреп торгызмакчы була.)*

**Норадын** *(аякларына басарга тели, ләкин булдыра алмый)*. Кичер, әткәм: аякларыма мин хуҗа түгел хәзер...

**Идегәй** *(ул шунда гына улының канлы яраларына игътибар итә)*. Махсус яралап, тирләгән атка атландырып җибәргәннәр?! Тәнеңә кара ат тире үткәргәннәр ич?! *(Телсез кала.)*

**Яугир** *(икенче ярдан карап торганнар икән)*. Идегәй! Сөекле Норадыңны каршы алдыңмы?! Урыс әйтмешли, яхшы яман, клади карман! *(Кычкырып көлеп, чабып китәләр.)*

**Аларның көлүе бу як ярда бик озак яңгырап тора.**

**Идегәй сыкранып кулын күкрәгенә куя.**

**Норадын.** Бу — хак, әткәм... Гомерем киселде! Оныкларыңны синең кулыңа тапшырам!

**Идегәй улына аварга бирмичә, башын күкрәгенә кыса.**

**Күзләрендә яшь ялтырый.**

**74. Дала. Көн.**

**Бүз юшан кебек әремнән бүтән берни үсмәгән япа-ялан дала. Күз күреме якын тирәдә анда-санда җирдән тырпаеп борын төрткән гади һәм чынаяк кирпеч кисәкләре генә бу кырда кайчандыр зур кала булганлыгын сөйли. Бу җирләр безгә таныш: Алтын Урданың пайтәхете балкып торган урын ул. Киң дала буп-буш, моңсу: бары тик болытсыз күктә бер тилгән генә бөтерелә һәм әрем дә үсмәгән пеләшрәк урында дивана Баба-**

**Сәнгү думбра чиртеп, жыру сузып утыра. Әмма аны да бик танып бетереп булмый: әллә ул чамадан артык нык картайган, әллә — бу бөтенләй без белмәгән икенче бер сәер кеше? Кем чоры икәнлеге дә ачык аңлашылмый. Дала киң, әмма ничектер тирән сагыш тынны кыса.**

Д и в а н а *(җырлый)*.

Бар иде ул Алтын Урда, бар иде алтын чагы, һа-ай!

Туздьі алтын базарлары, сүнде ялкынучагы:

Сарае да, Болгары да, Аждарканы болганды —

Алары да, болары да, вә Казаны тулганды.

Ил болгаучы батырларның сөягеннән ком кала,

Ком өстендә кол кала да, кол телендә җыр кала.

Кала икән, гасырларга бара икән моңлы зар:

Һәр халыкның да коллыктан котылырга хакы бар.

Ни горур хан Туктамыш та баш бирде Идегәйгә,

Абынды Аксак Тимер дә, егылды Идегәй дә...

Әй, Шаһ Тимер! Кая булды тиңдәшсез җиңүләрең,

Кай җитте торымтайдай елдырым чирүләрең?!

Әй, Туктамыш, синең дәвер, синең бөек дан кая,

Биләдең ярты дөньяны, шул ярты дөньяң кая?

...Әй, Казан, Кырым, Әчтерхан!

алда сезгә ни язган? —

Әүвәлге урыс колыгыз индеге көн бугазда.

Бугаз баскан батырларның сөягеннән ком кала,

Ком өстендә кол кала да, кол телендә җыр кала!

Бар иде ул Алтын Урда, бар иде алтын чагы,

Туздьі алтын базарлары, сүнде ялкынучагы...

**Тарихчы (моны дивана җырына фон итеп язма рәвештә бирергә мөмкин) «1410 елдан соң Алтын Урданы кабат туплаган Идегәйнең якты көннәре үтә инде: дөрес, ул әле Киевкә, Мәскәүгә яу чаба, Сарайга кайтып, һаман да хан артыннан хан алмаштыра тора. Кайсын ул үзе тәхеттән алып ташлый, кайсын ханнарның якын туганнары үтерәләр. Идегәй моңа буыннар алмашынуы дип кенә карый, әмма Алтын Урданың алтын чоры узган: Идегәй үзе — бөек дәүләтнең соңгы каһарманы, аның соңгы җырын җырлаучысы гына... Ул үлгәч, Чыңгыз токымнары берләштергән Көнчыгыш Аурупа халыклары, ниһаять, азатлыкка ирешәләр».**

АВТОРЛАР: «Бөек каһарман Идегәй 1419—1420 елларда Кадыйрбирде хан белән бергә соңгы бәрелештә һәлак булган, диләр. Ләкин бүтән төрле юрамалар да бар: Идегәй, Кадыйрбирдене үтергәч, шул орышта каты яраланып, Сарайчык каласы тирәсендә күлгә баткан, имеш. Анык кына билгеле түгел. Ә бәлки ул бүре ыруыннан аны үтерергә ант итеп чыккан Сәлим кулыннан үткәндер? Һәрхәлдә, әмирләрнең, биләрнең һәм ханнарның туктаусыз үзара сугышып, илгә һәлакәт китерүенә һәм канга батыруына гади халык битараф булмаган...»

Тәмам

*1993—1994.*

# ШИГЪРИЯТ



## Факил Әмәк

### ВАКЫТЫНДА ӘЙТЕЛГӘН СҮЗ

* * *

Өлкәннәр кечелекле булганда
Яшьләр дә кешелекле.
Мөнәсәбәтләр ап-ачык,
Гамәлләр эчтәлекле.

* * *

Дусларым күп дисең...
Минем берәү дә юк.
Миңа җиңелрәк.

* * *

Ачышларны акыллылар ясый.

Акылсызлар кулына эләккәч
Мәгънәсезлеккә әйләнә
Һәр ачыш.

* * *

Суалчан бик файдалы икән —
Туфрак эшкәртә ди.
Урыс телен өйрәттеләр —
Башны эшләтә дип.

Орыш телен өйрәндек,
Кизәндек туган телгә.
Суалчан кадәрле дә
Файда итмәдек илгә.

* * *

Даһилар җүләр була, дип,
Үз-үзен юаткан җан.
Акыл сатып йөри торгач
Үз-үзен югалткан җан.

Һәй, даһилык мөнбәре!
Күзләр нурсыз, муен төз.
...Почмактагы пәрәвездә
Чебен дулый «без дә без»...

Мүккә поскан үрмәкүч:
«Тынуыңны көтәбе-з-з!»

* * *

Бәхете — бәхетсезлеге.
Кимчелеге — шул бәхеткә ия булуында.

* * *

Сокланыр өчен дә,
Сакланыр өчен дә
Таулар кирәк.
Үзәннәрдә үтәли җил йөри...

## Микән?..

Күк йөзенә йолдыз таратканда
Киек каз юлыннан арбалар үткән.

## Кала...

Учактан — төтен,
Көрәшчедән — өн...

## Бер уй

Кешеләр начарлык эшләүдән туктап,
Гел яхшылык эшләүгә генә күчсәләр,
Бер-берсен яхшылык эшләп җәфаларлар иде.

* * *

Ятимнәр үксез була.
Игелек сүзсез була.
Мәрхәмәтлек кылганнарга
Ил-гавәм күзсез була.

* * *

Иясез мал — бәрәкәтсез.
Урам эте булмый җәрәхәтсез.

* * *

Үлән арасыннан яшен кебек
Кәлтә үтте йөгереп.
Яшәешнең бөек сере
Таш астына качты кереп.

* * *

Өйдәш булып ятлар тулса —
Өстәл-сәкең булыр тупса.

* * *

Кай ара җиткән көзләр —
Аккошлар киткән күлдән.
Яр читендә ак мамык:
Җилкәне төшкән көймә...

* * *

Шөһрәт әләме теткәләнер,
Әмма ямаулы булмас.

## Вактүрә

Исәнлек тә алмый үтте.
Вәкарь бу, ну эре!
Түрәсе алдында калтырап төште —
Ни үле, ни тере.

* * *

Яшьлегемдә йолдызларга үрелдем.
Хәзер җирдән утлы күмер чүплим.

## Тәшвиш

Көтмәгәндә иренемнән
Чупылдатып үпте...

Чәлпәрәмә — Тынычлыгым,
Харап булды, бетте.

* * *

Вакытында әйтелгән сүз генә асыл.
Алда әйтелсә — көлке.
Соңга калса — төссез.

* * *

Күнелдәге бозны
Мең кояш эретә алмый.
Яхшы сүзләр соңга кала —
Иясенә житә алмый.

* * *

Эт елында — янадан туыйк! —
Ак бүре булыйк.

## Мәҗлестә

Эчеп кем дә исерә! —
Син эчмичә исереп кара:
Аһ, каршымда сылу кыз бала!..

* * *

Торган жирең иркен булсын,
Булсын кысан:
Җүләр урны булыр түрдән,
Акыллыга — тупса.

* * *

Аһ, карашың! — Гомер буе
Яндырырга житәрлек.
Жанга — хөрлек,
Жанда — коллык,
Һәм баш бирмәс исәрлек!

# Шигърият

Бу санда укучыларыбызга кызыклы, яңа бер шигъри сәхифә тәкъдим итәргә булдык: анда — бүген төрле җирләрдә, төрле илләрдә яшәп, әмма әнкә тел — Шигърияткә чын гашыйклар, төрле профессия кешеләренең язганнары туплап бирелә. Авторларның күбесе — көндәлек матбугатта басылган шигырьләре аша укучыга инде билгеле исемнәр. Мәсәлән, филология фәннәре докторы, «Татар исемнәре сүзлеге», «Ни өчен шулай аталган?» (Татарстан топонимнары) кебек мәгълүм китаплар авторы Гомәр Саттар-Мулилле — укучыга яхшы таныш. Күпләребезнең тел буенча укытучысы, университет профессоры...

Ялтада яшәп, Татарстан хәлләре, телебез, халык язмышы турында да мәкаләләр бастырып торган публицист, тынгысыз якташыбыз, педагогия фәннәре кандидаты Фоат Мортазин, Казан дәүләт ветеринария медицина академиясе профессоры, фәннәр докторы Рифат Җамал (Корбанов), укытучы-тәрбияче Флера Гатина да — шундыйлардан. Казаннан табиб Ринат Мәннан, Әгерҗедән — мәгълүм иҗатчы Чыңгыз Мусин, Ижаудан — Ибраһим Биектаулы исемнәре дә битараф калдырмый: туган телебезгә чиксез мәхәббәт, тумыштан Моң баласы булу берләштерә аларны, мәдәниятебез киләчәге өчен чын горурлык хисләре уята; «...әдип ул, шагыйрь ул...» дип, халкыбызның көч-хис, сүз һәм матурлык дәрьясы мәңге саекмас булуына ышаныч арта. Әйе, шигърият дигән олы диңгезгә төрле-төрле чишмәләр, инешләр, елгалар коя...

Бу күренеш — мәңгелекнең үзе кебек табигый, шатлыклы, дәвамлы юл. Укучы да моны аңлап, сәхифәне яратып кабул итәр дип ышанасы килә...

## Гомәр Саттар-Мулилле

### Була алсам...

Булалсам исем-атамалар атаманы,
Юк, кирәкмәстер миңа дөньяның башка даны.

* * *

Туула үлем бар,— ни өчен?
Яшәүдә хикмәт бар,— ни өчен?
Үлем бер тирән сер,— ни өчен?
...Киләбез, китәбез — җыр өчен,
Тудырган, туйдырган җыр өчен.

## Кабер һәм бәгырь

Чит илләрдә каберләре Исхакыйның,
Туган илдә бәгырьләре — һәр хаккыйның.

## И дөнья!

И, барсына ия булган дөнья-тормыш, җиһан-хәят,
Кайчан, әйтче, сафланырсың, пакьләнерсең син, ниһаять?!
Ник бәндәңә һаман борчу, кайгы-сагыш китерәсең,
Сагыш белән җилеген сурып, җанын курып киптерәсең?

## ИСЕМНӘР ЧӘЧӘКЛЕГЕ

### Гөлчәчәк

Исемең гөлдән һәм чәчәктән гыйбарәттер,
Тыйнаклыгың бик күпләргә чын гыйбрәттер.
Чибәрлегең яңа чәчәк аткан сөмбел,
Тирә-юньгә хуш ис чәчкән саф асыл гөл.

Ике битең алсуланып пешкән алма,
Урталары батып торган чокыр-алка;
Бөдрә чәчең, ак шәл бәйләп, яшерсәң дә,
Таң җиленнән, дулкын булып, өскә калка.

Тыйнаклык һәм чибәрлекне туплаган гөл,
Сафлык белән пакьлек бөреләнгән чәчәк,
Күзем йомсам, күз алдыма син киләсең,—
Юктыр чарам, нишләсәм дә, син — киләчәк...

### Чәчәк

Исемең Чәчәк, җисемең чәчәк, иренең чәк-чәк,
Күргәч сине һәр күңелгә яз киләчәк.

### Мөслимә

Шундый күркәм, шундый сылу Мөслимәсең,
«Сөбханалла»,— дип әйтәмен, күз тимәсен.

### Гөлйөзем

Гөл йөзле Гөлйөземдә —
Балкыш ике күзеңдә,
Итагатьлек сүзеңдә,
Иман нуры йөзеңдә.

### Җиләк

Җиләк кебек пешеп тәмам өлгергәнсен,
Назлар көтеп тилмергәнсең, тилергәнсең,
Язлар көтеп, назлар өчен яши кеше.
Назлар көтеп, язлар өчен яши кеше.
Табигать бит яз җимеше, наз җимеше,
Назсыз калса, язсыз калса, яман эше.

### Галимәгә

...Илле яшьтә бер мизгелдә елмаерга
Күпме бирә адәми зат көчен менә,
Алтыннарга бәрабәрен бу мизгелнең
Яшьлек үткән, илле җиткән үзе белә.

*Казан*

## Фоат Мортазин

### Бөек хакыйкатьне эзләп

Гомер буе биек тау башына
Менгәннән соң, белдем ахырда:
Тау түбәсе һаман ерагайды,
Җиталмәдем барыбер асылга.

Ә бит түбә кул сузымда гына —
Бик якында иде югыйсә.
Авыр булды миңа: бик тә тайдым,
Упкыннарга төштем мин ничә!

Валун, кыя, үткен сөңгеләрдә
Асылынып тордым мин-фәкыйрь.
Җәнлек тоягыннан сулар эчтем,
Кыл өстендә булдым күп тапкыр.

Янап торды барлык кыйтгалардан
Җәнлек-киек, шакал өере.
Әмма һаман югарыга дәште
Чишелмәгән серләр төене.

Кеше кайдан килгән? Кая китә?
Мәңгелекме — безне ни көтә?
Янәшәдә йөргән ачы үлем
Ник шул чаклы җанны өркетә?

Бу биек тау чын хакыйкать иде,
Тау менүем шуның хакына —
Җан канатып, күгәрекләр алып
Мөритләрчә түзеп барсына...

Әмма барыбер бик аз белә алдым:
Надан китәм Алла каршына.
Бөек хакыйкатьтән — валчык кына,
Бөртек кенә газиз башымда.

## Ватаныма мәдхия

Ватаным, син татлы хыял сыман,
Ак җилкән күк зәңгәр диңгездә.
Туган Ил дә, назлы гөлбишек тә,
Газиз Ана да бит син безгә.

Ватаным, син сихри якты кебек,
Шул яктыга һәрчак омтылам.
Бер карасаң, гап-гади кыр ягы,
Әмма аңа тиң җир юк сыман.

Ватаным, син иң яхшы җыр кебек,
Җырларыңның сихри моңнарын
Миллион көй арасыннан таный —
Антеннадай сизгер колагым.

Ватаным, син сөйгән ярым кебек:
Йөрәгемдә һәрбер мизгелдә.
Яшәү диңгезенең тугыз баллы
Давылларын кичтек без бергә.

Ватаным, син — шүрәлеләр иле!
Сөйләвенчә кошман бабамның,
Вальс бии төнлә түрәлеләр
Яңгыратып урман аланын.

Толымнарын чайкап чаба — суда,
Елак таллар чатыры эченнән
Балачагым дусты — су анасы
Чабып чыгар төсле кич белән.

Ватаным, син бөек Болгар иле!
Гаяз Исхакыйлы, Тукайлы.
Мәчетләрең калка һәр төбәктә —
Манаралы, биек ак айлы.

Туган телем дә син, күзем дә син,
Иң саф, иң пакь гореф-гадәт тә.
Иманым да, кыйблам, кәгъбәм дә син,
Инсанлык та, инсаф-әдәп тә.

*Ялта шәһәре*

# Рифат Җамал (Корбанов)

* * *

*«...Көнләшүдән күгәргәнче,*
*сагынудан саргаям».*

*Равил Фәйзуллин*

Синең белән бергә чакта
Гел көнләдем ятлардан.
Сине көнләп кайта идем
Йөгереп ераклардан.

Сине көнли-көнли инде
«Күгәрдем» дә, агардым.
Син генә армагансыңдыр,
Мин үзем инде ардым.

Аерылдык — каерылдык...
Беләм, син ятлар белән.
Көнләмим дә... Әллә көнлим?
Моны тик Алла белә.

Тик, нигәдер, хәзергәчә
Сине сагына күңел.
Көнләп яшәү — кыен иде...
Ә синсез — яшәү түгел!

## Дүртьюллыклар

* * *

Шатланам, елмаям янында,
Моңланам, сызланам — бер үзем:
Белмәсен, күрмәсен беркайчан...
Йә, Ходa, миңа да бир түзем!

* * *

Сине күрсәм — башым күккә тия.
Кырык яшьтән узган мин — малай!
Сине күрми торсам — мин бөгеләм,
Туксан яшьлек карттай, урталай...

* * *

«Вакыт — яхшы табиб!» — диләр иде,
Нигә дәваламый ул мине?!

Ул — сихерче: үзе белән бергә
Күз алдымда тота гел синә!

* * *

Нинди сүз бу?! Кемнәр уйлап тапкан,
Кемнәр әйткән аны — «Сөяркә!..»
Сөяркәләр булсын — патшаларга...
Сердәшемне язсын — сөяргә!

* * *

Матурлыгың сурәтләрлек
Сүзләрне табалмадым.
Шуңа күрә шигыремне
Башламый тәмамладым.

* * *

Кирәк түгел, Ходай, хур кызларың.
Салсаң, сал, син, мәңгелек утка.
Тик бүләк ит миңа җир кызының
Татлы назын тик бер минутка.

* * *

Мин телимен синең сөйгәнеңне,
Үзең яккан утта көйгәнеңне.
Ә син тик көләсең, тыңлаганда
Йөрәгемнән чыккан көйләремне.

* * *

Кырык яшем — инде акыл кергән,
Хисләрем дә әле бетмәгән.
Әллә язым, әллә инде көзем —
Һаман гүя нидер җитмәгән.

* * *

Алда-артта яманлыйлар —
Кайчак үләсем килә:
Үлгәннәр бездә яхшылар —
Яхшы буласым килә.

* * *

Җитте заман. Кайберәүләр
Күкрәк суга: «Я — татарин!»

Кайчан өйрәнер әйтергә:
«Татар мин,— дип,— татар мин!»

*Казан*

## Ибраһим Биектаулы

### Соңгы Оран

Оран сала күктән киек казлар:
«Уяныгыз, гафил рәван җаннар,
Рух өрегез озак йоклаганга,
Сулкылдасын тамырларда каннар!»

Оран сала күктән киек казлар:
«Тарихларың булган — тузга язган,
Туздырылган тузлар, утта янган,
Исәннәре — җир астында калган!»

Оран сала күктән киек казлар:
«Болгар углы! Йә, әйт, ничек хәлең,
Суың бармы — кипмәдеме Күлең,
Хәтерлиме болгарлыгын Илең?»

Йөрәгеңне уят әле, туган,
Ишетелер шулчак Соңгы Оран:
«Бабайларның баш очында курган —
Өсләренә бөркет оя корган!»

### Татар булсаң...

Чал тарихның янган битләрендә
Калган синең хәтәр язмышың.
Иманыңа тугры калу өчен
Корбан бирдең, Татар, азмы син?!

Дошманнарга артык мәрхәмәтле,
Юмарт булды, Татар, йөрәгең:
Җан таратып бөтен дөньяларга,
Оныта яздың Ватан кирәген.

Татар булсаң, күз карасы итеп
Сакла Илең, Туган Телеңне,
Ата-бабаларның изге Рухы
Нурландырсын туар көнеңне!!

*Иҗау шәһәре*

# Флера Гатина

* * *

Актарыла дәрьяларның суы,
Дулкыннары ярсып чайпала.
Шул илергән, шашкан дулкыннарда
Йомычка күк кораб чайкала.

Күккә ашкан дәрья дулкыннары
Ул корабка ярсып ташлана.
Әйтерсең лә йолдызларны йоткан
Мәхшәр төне шулай башлана...

Ялкын сарган ул галәм корабын
Йә, ходаем, үзең ташлама.

## Сүнмәс нур

Туган җирнең матурлыгын җырлап барам,
Туган телдән җырларыма нурлар алам.

Туган телдә җырлыйм назлы бишек җырын,
Җырларыма илһам биргән былбыл моңын.

Гашыйкларның бәхет тулы саф җырларын,
Чишмәләрнең көмеш күк саф ак чыңнарын.

Туган җирем, изге туфрак гел чакыра,
Каеннарың сөеп җырлыйм һәр чак шуңа.

* * *

Сахраларга сине эзләп чыктым,
Канатланып биеклеккә очтым.

Дулкын булып сиңа йөзеп бардым,
Ярларыңа җитә алмый ардым.

Калды сиңа җырланмаган җырым,
Сагыш тулы йөрәктәге кылым.

Синсез үтте ул сагышлы төннәр...
Күкләрдә дә җаным сине эзләр.

## Рәхмәтем

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам,
Көмеш каләм кулымда.

Рәхмәтемне сиңа җырлыйм
Көмеш чыңлы җырымда.

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам,
Ак йолдызлар юлымда.
Сафлык иңгән ак нурларың
Чыңлый йөрәк кылымда.

Бәллүр Җиһан, бирдең илһам,
Рәхмәт юллыйм җырымда.
Хак тәгаләм, бирдең иман
Илаһи моң нурында.

Көмеш каләм — кулымда...

## Юксыну-өметләр

Бу дөньяда нидер югалттым мин,
Нидер җитми шашкын күңелгә.

Эзләсәм дә — табалмамын кебек,
Хыялларым — упкын төбендә...

Югалтулар — өмет баскычлары,
Өмет җыры чыңлый күңелемдә.

*Казан*

# Чыңгыз Мусин

## Сагыну

Карт сөяген сөйрәп, көчкә-көчкә
Болын буйлап атлый бер бәндә.
Туган телен бераз бутап сөйли,
Чит илләрдә озак йөргәнгә.

Заманында күпме җәфа күргән,
Ул басмаган җирләр калмаган.
Мәңге кайтмам, диеп сүз бирсә дә,
Сагынуга түзә алмаган.

Кайтып килә менә тәүге тапкыр
Тәпи баскан газиз аяга.

Туган-үскән җирдән кадерлерәк
Ни бар икән тагын дөньяда?!

Маңгаена буй-буй юллар сызган
Читтә йөргән еллар арасы.
Туган ягым, зинһар, кабул ит, дип,
Ялварулы сыман карашы.

## Гүзәллек дәрьясы

Таң туа, җир өстенә рәшә төшә,
Агыла моң чәчәкләргә күчә-күчә.
Күңелемне тибрәндерә шушы ягым,
Илаһи гүзәл минем туган ягым.

Офыклар балкый гаҗәеп төс белән,
Һәр бөҗәк үзенчә мәшгуль эш белән.
Ерактан урман-кырлар, таулар кичеп,
Иртәнге назлы җилләр килде исеп.

Бу чәчәкләрдә күпме буяу төсе,
Бөркелә тирә-якка хушбуй исе.
Тургайлары менгән зәңгәр күгенә,
Җир өстенә сихри моңнар түгелә.

Таңнарда хәтфә болыннарга чыгып,
Ялгызым йөрим шулай уйга чумып.
Иртәләрдә серлемен дә, моңлымын,
Бозармын дип ошбу дөнья тынлыгын.

Йөримен, саф хисләрем ташып-ташып,
Идәнгә йомшак-йомшак кына басып.
Күңелләргә мәңгелек илһам ява,
Туң йөрәкләрне эретерлек дәва.

Бу хакыйкать — яшәешнең асылы,
Саф гүзәллек дәрьясының ташуы.

## Тамырлар

Бу җирләрдә урыс белән
Аралашып гомер иттек.
Нигез кордык, йортлар салдык,
Бергә-бергә иген иктек.

Түбәбездә һәммәбезгә
Бер үк кояш, бер күк иде.
Без урыска чыпчык булсак,
Урыс безгә бөркет иде.

Башны иеп сәламләдек
Юлыбызда очраганын.

Бакчабызны ертсалар да,
Кыйнамадык чучкаларын.

Кимсенүдән, татар телен
Өйрәнмәде балалары:
Безнең телләр алар белән
Аңлашырга ярамады.

Үтте айлар, үтте еллар,
Кырыс җилләр исеп китте.
Урыс халкы дәррәү кубып,
Калаларга күчеп китте.

Күчеп китте. Тормыш сөргән
Нигезләре ерак калды.
Бакчаларда тулып пешкән
Миләшләре елап калды.

Язгы бозлар кузгалгандай,
Кузгалдылар авыллары.
...Бу милләтнең, ахры, монда
Булмагандыр тамырлары...

*Әгерҗе*

## Ринат Мәннан

### Каләмле күз

Алтын күз сары каләмен,
Әнә, очлап куйгач та,
Җылы җәйләр агып китте,
Болытлардай, еракка...

Күз илендә тик мин калдым
Һәм сары каенкайлар.
(Алар хәзер никтер моңсу,
Нигәдер боекканнар.)

...Сары яфракларга карыйм;
Әйтә алар: каласыз...
Озакламый — вакыт җитәр! —
Күз дә калыр... каләмсез.

*Казан*



**Барлас Камал**

# ЯШЬЛЕККӘ ХЫЯНӘТ

хикәя

Бәдрия ханым мәктәптән тәмам миңгерәүгә сабып, оят-хурлыгыннан җир тишегенә керердәй булып кайтты. Мең дә бер нерв җепселенең һәммәсе соң чиккә җитеп ярсынган иде. Бәгыреннән — эчке кисемнәренә, алардан костюм-күлмәге аша пальтосына ут кабар төсле тойды ул үзен.

Онытылып китеп (гарьлек, ачу акылны ала!), өч бүлмәле фатирлары бусагасына җиткәч, ишек кыңгыравына басты. Җавапка зарланып миявулаган мәче тавышы гына килде. Шуңа хәтле чыдаган иде Бәдрия, инде түземе төкәнде, җылап җибәрде. «Беләм ләбаса өйдә кеше югын! Акылдан язаммы соң инде әллә, ходаем?» Ул үзенә-үзе бик кызганыч булып тоелды.

Кушкатлы итеп ясаткан ишекне өч ачкыч белән алты җирдән ачып керәсе бар иде. Калтыранган бармаклары ачкычларны йозак уентыларына тиз генә туры китерә алмый җәфаланды ул.

Өй бусагасыннан атлап кергәч, Бәдриянең аякларына түтен түсендәрәк йонлач песи килеп сарылды да ялагайланырга керешге. Бүтән чакта кулына алып назлый, күзләреннән, кирза итегедәй кара салкын борыныннан үбеп ала торган хуҗабикә бу юлы аны дорфа гына читкә тибәрде.

— Хәсрәтем син түгел сәнә, Йонлач, син түгел!..

Мәче рәнҗеп читкә китеп барды.

Мескенләнмә дә, сукранма да, Йонлач! Үз хәлләрем хәл... Адәм хурлыгына каласы көннәрем бар икән...

Бәдрия зар түгә-түгә чишенде. Чәшке тиресеннән тегелгән затлы бүреген элгечләр өелегенә куйды, яз-көз кия торган сыек яшел төстәге пальтосын, сафъян читекләрен салды да ишек катындагы зур көзгә каршына килде һәм янә җылардай булды. Күз яшьләре аның сөрмәсен юып төшергән, иннек-кершәнле битенә суалчан эзләре калдырган иде. Күзләре исә, гаҗәп, яңгырдан соң аязып калган җәйге күк йөзе кебек юылып, матурланып киткәннәр иде.

— Тагын косметика сеансына утырырга инде, тагын! — дип чәчәләнде Бәдрия, бүтән бер генә ашыгыч эше, тәҗел мәшәкате булмаса да.

Югары хәрби училищеда укытучы ирен-подполковник Рәхим Назировны һәр тумыш көндә артисткаларча бизәнеп каршы алу аның көндәлек гадәтенә әверелгән иде.

Бизәнү-төзәнү кеенече аның өчен олы кайгысын бер генә минутка булса да онытып торудан гыйбарәт иде. Бәдрия яңадан кара кайгыга батты. Шул ук вакытта ул үзен әле бүген генә мәктәпкә чакыртып аулакта гына сөйләшкән класс җитәкчесенә теш кайраудан да туктамады.

«— Әгәр дәме, әгәр дә,— дип сөйләнде ул үзалдына,— Фирая Мохтаровна күрәзәлек иткәннәр расланмаса, балам өстенә пычрак яла яккаsuccessful өчен башын төрмәдә черетәм бит мин аның! Төрмәдә!.. Уйлап кына кара, ничек ди бит? Без инде, хатын-кызлар, урау юллар эзләнми генә аңлашыйк: кызыгыз Зәйтүнә йөкле түгелме, дип мин бик сагаям. Буйсынына карап торам-торам да шундый шиккә төшәм, ди! Ничек инде, дим, сигезенче класстамы, дим? Аның, явыз мадамның, үз кырыгы — кырык. Бәдрия Сәфәровна, ди, озын-озакка сузмыйча врачка барыгыз, ди. Әгәр дә Зәйтүнә чыннан да йөкле икән, аны язгы каникулдан соң кичке мәктәпкә күчерергә кирәк, сигезенче классны шунда булса да тәмамласын иде, ди. Җитмәсә бит әле явыз мадам ни дип тә өстәде? Мин бит сезнең кызыгызга яхшылык кына телим, ди... Үзе чукынсын ла! Әйткәннәре чыннан да хак булса? Ни дигән галәмәт була инде бу? Моны әтисенә ничек әйтим, ди, мин?! Суя бит ул Зиночканы, суя! Мине дә аның белән бергә пычакка ала. Билләһи шулай итә. Ул бит авыл малае, Зөя буе мужигы... Аңарда татар каны, чеп-чи татар гадәтләре, татар психологиясе... Гыйффәтлек дип, кыз сафлыгы дип, тугрылык дип саташкан крестьян камырыннан әвәләнгән бәндә бит ул... Офицер юлыннан китмәгән булса, бүгеннәрдә, дин яңадан терелеп азапланганда, авылында мулла булып, мәчет манарасы күтәреп йөрер иде ул!..»

Менә шулчак Бәдрия ханымның күз яшьләре янә ихтыярсыз чишмә төсле актылар да киттеләр...

Бу көнне Бәдрия ханым Рәхименә әлеге гөнаһ шомлыгы хакында ләм-мим ычкындырмады, үзенең кәефсезлеген тамчы да сиздермәскә тырышып, гадәттәгедән ачыграк, уенчаграк булырга тырышты. Иң әүвәле җайлап-юньләп кенә кызы белән күзгә-күз сөйләшеп аңлашуны кирәк санады. Тик... әтисе күптән кайтты, ашап-эчте, ял итеп алды, иртәгесе көнгә лекцияләренә хәзерләнде һәм йокларга ятарга җыенды, ә кыз юк та юк иде. Бәдрия ханым ут йота иде, тирән суласа, карынынннан сөрем бөркелер төсле, алай да хафасын тышка чыгармады. Беләː элеп алып китәргә сыңар сүз генә булсын, Рәхим өермәләнә башлый. Кызын, аңардан битәр, Бәдриянең үзен каһәрләргә керешә. Әле атна булса да, ун көн юктыр, шундый җанҗал чыкты бит.

Ниндидер җыелышлары булып, подполковник соң гына кайтып килә икән, Зәйтүнә үзенең Колясы белән моңа каршы очраган. Җилтерәтеп алып керде әти кеше кызын. Укуының рәте-чуты юк, төн карасында егет сәләмәсенә ияргәнсең, дип тетмәсен тетте. Бәдриягә дә сөбханалла диярлек эләкте. Синең тәрбия җимеше, син бит: «Нигә ул тикле аңа химия дә физика! Бәхетле кыз, бәхетле хатын, бәхетле ана булырга язсын!» — дип йөрисең. Җил куып бәхеткә тиенгәннәрне очратканым юк әле минем, дип тезепме тезде.

Ирендә мәрхәмәт, аяу кузгатырга теләп, Бәдрия җил уңаена салпы салам кыстырып та баккан иде дә, җавабы бәгырь көйдергеч булды.

«Әй Рәхимҗаным, рәхимле җаным! Барысы да ходай кулында. Мин менә үземне дөньяның бәхетлеләреннән саныйм. Өлешемә тигән көмешем син булдың. Аллаһе Тәгалә сиңа озын гомер, саулык бирсен дә зиһенеңне ишәйтә торсын... Кызларыбызга да синдәй ирләр насыйп булсын... Хәер, Зәйтүнәбез ирдән уңды дисәм, язмыш күпсенмәс лә инде... Хатын-кызның чын бәхете — таяныр ирендә аның, Рәхимҗаным!» — дигән иде Бәдрия.

Байтактан уйлап, үлчәп, тәфсилләп йөргән фикерләре булгандыр дип фараз кылырга кирәк. Рәхим Гариф улы Назиров лекцияләрендә исбатланган, формуланы калыплап әйткән сыман җавап кайтарган иде: «Ит күрмәгәнгә үпкә тансык, диләрме әле? Турыдан-туры гаебең булмаса да, синең чын бәхетне татып караганың юк бит әле, Бәдриякәем! Татырга өлгерә алмый калдың. Миңа кияүгә чыктың да ил гизәргә иярдең. Дөнья гизәргә дисәң дә ҳата юк... Югары белемле әдәбиятчы-телче идең дә соң, офицер хатыннарының уртак язмышы сине дә читләтеп үтмәде. Хезмәт китергән бәхетне белмисең син... Тулыр-тулмас бер ел укыту дәверендә син әле яраткан эш дигән күлгә чумарга өлгермәдең, читендә аяк чылатып кына калдың. Дөрес, болай һәммә нәрсәң җитеш. Германиядән кайткан мебель, чүпрәк, савыт-саба тагын бер кеше гомеренә җитәрлек... Дәүләт биргән квартираң менә дигән... Тик менә өй тавыгы булып яши торгач, кызыныңның кыек басуын тоймый калма. Бәхетеңнең чәлпәрәмә килгәненә үкенерләр бетә алмассың!»

Үзен бәхетлеләрдән чутлыйм дисә дә, сүзләр ире күңелен күрүгә генә исәпләнгән. Асылда Бәдрия белә: бәхете китек аның. Тик соң инде, терсәк ерак...

Рәхим Назиров беренче танышкандагы мөлаем лейтенант түгел хәзер. Погоннарында йолдызлар ишәя барган саен холкында кырыслык, килешмәүчәнлек, үҗәтлек һәм әмер бирүчәнлек арта бара. Солдатларга куелган таләп — «Белмәсәң өйрәтербез. Теләмәсәң мәҗбүр итәрбез!» — хатынына, гаиләсенә булган мөнәсәбәтләргә дә күчә. «Мин әйттем!» — холкы шул сүзләргә сыеп бетә. Хатыны — нибары ашчы, идән юучы, кер уучы, бала үстерүче һәм иренең теләкләрен канәгатьләндерүче.

Шул рәвешле, офицер погонында яңа йолдыз кабынуга, бигрәк тә зурлары ялтырый башлауга, хәләленең күңел гөмбәзендә ике-өч йолдыз сүнә тора. Ирләре аларны катгыйның арьягында кисәтә, Бәдрия уйлый бүген: менә шундый кисәтүләрдән соң мәрхәмәт көтеп кара син аңардан!..

Сәгать унбер туларак ишек кыңгыравы өзек-өзек итеп ике тапкыр чыңлап алды.

— Кайтты! — Бәдрия ханым ишек ачарга юыртты. Шунда уйлап алды: «Үзендә булмаса, кыз баланы алты түгел, алтмыш йозак белән дә бикләп куеп саклый алмыйсың икән аны!»

Инде байтактан уртын чәйнәп йөргән Рәхим тимер суыгы суккан көр тавыш белән үкереп куйды:

— Кайда йөрдең шушы вакытка кадәр?

Зәйтүнә, әнисенә охшаган чибәр кыз, дер калтырап киткәндәй булды. Аның юка гәүдәсен тетрәү алды шикелле. Йөзе агарынып китте. Әтисенең өйдә туган телдә сөйләш дип тукуыннан гаҗиз булганга, ватасындыра җавап бирергә ашыкты.

— Дуста кызда булдым. Аныкын телевизор карадым.

— Өйдә телевизор юкмыни безнең? — Ата карашы белән кызын үтәли тишәрдәй итеп бораулады. — Әгәр моннан соң тагын бер тапкыр кичегеп кайтсаң, принцесса, «Әпипә»гә биетәм мин сине! Шуны бел! Апаң да үсте, хафа белмәдек, син агартасың чәчләремне!..

Ачуыннан кара коелган подполковник йокы бүмәсенә узды. Тегеләр аналы-кызлы чышын-пышын сөйләшә калдылар. Кая ул Фирая Мохтаровна хәбәрләрен әйтү! Бәдрия багалмасын тизрәк юындырып яткыру ягын карады. Иренә сер чишү тиклесен әйткән дә юк инде. Бу килеш тә баланың җанын алырга тора лабаса! Мәгәр бүген әйтмәсәң дә, бер чишәргә туры киләчәк сер Бәдриянең йокысын гына түгел, җан тынычлыгын да тәмам качырган иде. Ире йоклап киткәч тә аның керфекләре ябыла алмады. Уйларының әллә ниндиләре ябырылып килде башына. Бер төшмәсен икән ул шомлы уй. Чиге дә, чамасы да булмый икән аның. Күзгә шыксыз кондәге болытлар сыман аслы-өсле юрган булып агылдылар да агылдылар. Йокы алмагач, торып, түр якка чыкты Бәдрия.

Көндез мәктәпкә барганда ук почта әрҗәсеннән алган хат исенә төште. Чаллыдан, өлкән кызлары Фәйтүнәдән иде бит ул. Пальто кесәсеннән шул хатны алып килде. Люстраны кабызмыйча, өстәл лампасын гына алып утырды. Хат укый башлады.

«Мамуля, папочка, Зайтунчик!» Болары — урысча язылган иде. Анары татарча башлана. Бер сүздә ике хата булса була, әмма үз телебездә. Зәйтүнә беләә, аңардан хат русча килсә, әтисенең җен ачулары чыгачак. Әнисенә чираттагы шелтәнең каһәрлесе эләгәчәк. «Үзең татар теле-әдәбияты укытучысы дипломын учлап яшисең, ике бөртек кызыңны туган телдә сөйләшергә, укырга-язарга өйрәтә алмадың! Син дә булдың педагог!» — диячәк.

«Без бер көе әйбәт кенә яшәп ятабыз. Хәниф яхшы гына эшли. Үзенең элекке урынында, слесарь-инструментальщик. Яшәвебез дә һаман шунда, малосемейкада. Бер бүлмәле квартираны, өчәү булгач, бирерләр дип торабыз инде.

Мин тагын ике атнадан декретка чыгам. Эштән китәргә туры килә, бик кызганыч. Больницада коллектив шундый яхшы, мин аңа бик ияләшкән идем. Һич китәсе килми. Коллегаларым — медсестралар да, врачлар да бик әйбәтләр. Эшемне дә бик яратам. Медучилище гына бетердем, дип үкенергә уйламый да идем. Ну вот китәргә туры килә. Мин ялга чыккач, Хәниф тә отпуск алырга уйлый. Хотя бы бер атнага Казанга кайтып килергә дип планлаштырабыз. Аһ, ничек сагындым Казанны! Сезне барыгызны да сагындым!

Үткән шимбәдә Хәнифләр авылына кайтып килдек. Бакчасарайга. Чаллыдан егерме биш километр. Кайнанам да, кайнатам да бик яхшы каршыладылар. Кунак булдык. Бик җылы озаттылар.

Кыскасы, бүгенгә минем хәлләрем бик әйбәт. Киләчәктә дә шулай була күрсен иде инде.

Үзегездә ни хәлләр бар? Ничек яшисез? Әти укытамы? Үзең авырмыйсыңмы? Зәйтүнәнең эшләре кай тирәдә?..»

Укып өлгерә алган кадәресеннән соңгы җөмлә Бәдриянең йөрәгенә пәке белән сызып җибәргәндәй итте. Зәйтүнәнең хәлләре...

Бәдрия өстәлгә куйган беләкләре өстенә сыгылып төште.

«Кызның үзеннән ничек сораштырыйм? Укытучысының шикләнүе хакка чыкса? Ужас бит, ужас! Көмәненнән ничек арынырга? Үзе дә бала гына бит әле. Корсак төшерүгә чыдармы? Аннан соң беренче йөклелекне юк итүнең зур дәһшәте бар бит. Еллар үтү белән, чын-чынлап ана булырга ниятләсә дә, балага узмавы бик ихтимал лабаса! Моннан да куркынычрак нәрсә бармы? Йә, ярый, анысы киләчәк эше, бүген ниләр генә кылырга?»

Язгы таңны йокысыз каршылады Бәдрия ханым. Ятып тормады, ирен — хезмәткә, кызын мәктәпкә озатырга дип аш-су әзерләргә ябышты. Ирен — хезмәткә... Әйе, анысы шулай. Кызын мәктәпкәме соң? Юк инде, ул бүген мәктәпкә бармастыр, бүген Зәйтүнәне врач янына алып барырга кирәк булачак...

Иртәгесен Рәхим хезмәтенә гадәттәгедән дә алдарак кузгалды. Хатыны да, кызы да аякланып кына киләләр иде әле.

Бәдрия кызының ятагы янына барып басты.

— Торасыңмы инде, кызым? — дип сорады ул үтә йомшак, җан җылылы итеп. — Әйбәт йокладыңмы?

Кыз иренеп кенә торып утырды, күзләрен ачар-ачмас кына җавап бирде.

— Рәхмәт, мамочка, яхшы йокладым. Но все же йокым туймады. У — ух... — Ул шундый итеп киерелде, аның җаны ни теләгәнен анык кына белер хәл юк иде...

— Яз көне шулайрак була ул, кызым. Йокы туеп җитмәүчән була. Врачлар аны язга таба организмның ялыгуы белән аңлаталар шикелле. Кеше организмында көздән тупланган витаминнар кимеп кала, диләр

бугай... Хәер, бүгенге тормышта адәм баласы витаминга ул тикле ярлылана микән?

Бәдрия витаминнар турында сөйләгән булып, врач сүзен дә кыстырып куясы итте. Зәйтүнәгә моның тәэсире ничегрәк булыр, янәсе. Үзе сөйләнде, үзе теләр-теләмәс кенә караваты янәшәсенә җәелгән кечкенә паласка төшеп баскан кызының буй-сынын күзәтте. Ефәк эчке күлмәк бүлтәя төшкән кебек күренде аңа. Күзенә шулай чалындымы, әллә шайтан күзлек кидердеме, күкрәкләре дә тулыша төшкәнгә охшыймы соң? Лифчигын төртеберәк торалар төсле. Йа, ходай, класс җитәкчесе, теге явыз мадам әйткәннәр рас килерме икәнни соң?»

— Бар юын, таран... Иртәнге аш әзер...— Әнисе кызын ванна бүлмәсенә озатып калды. Үзенең миен бер генә сорау бораулый иде: «Ничекләр итеп кенә сүз башлыйм да ничегрәк итеп дөресен белешим?» Аннары ул сабый чагында әбисеннән өйрәнгән өтек-төтек догаларын укып алды — кай очракка яраклы икәннәрен, үтер, белми иде! Һәм аллага ялварырга кереште. «И ходаем, шул чырайсыз Фирая Мохтаровна юраганнарны юш китермәсәнә! Әгәр дә балакаем саф булып, көмәнле дигәне юк сүзгә чыкса, быел кайнатама корбан чал дип акча бирер идем, җәлләмәс идем... Бер үк, Ходаем, мәрхәмәтеңнән мәхрүм итмә, кызыма җан сафлыгы, тән пакьлыгы насыйп иткән була күр...»

Чәйгә утырдылар. Кызының — йокысы туймаганга, әнисенең ут йотканга ашыйсы-эчәселәре килми иде. Рәтенә килсен дип кенә берәр чынаяк чәй эчеп куйган булдылар. Икесе бер юлы диярлек чынаякларын өстәл эчкәресенә этәрделәр. Урыннарыннан күтәреләбез дигәндә, аларның күзләре очрашты. Карашлары бер-беренә магнит белән тарттыргандай тоташып алды. Бер мизгел, кем кыюрак дигән кебек, бәхәстә тордылар төсле. Аннары Зәйтүнә чыдамады, күзләрен читкә алды. Сүз башлар минут шушы дигән карарга килде Бәдрия.

— Синең белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсем бар, кызым,— диде ул.— Кил, утыр әле...

Бәдрия түрдәге софага барып утырды һәм учы белән кагып кызына урын күрсәтте.

Зәйтүнә әнисе янына елышты. Үзе өчен үтә газиз затны кочаклыйсы, иркәлисе, назланасы килгәндер бәлки. Әмма алай итә алмады. Ике арага күзгә күренми, кул белән тотып булмый торган, иссез дә, төссез дә бер яры эленгән иде кебек. Нәрсә иде ул? Кызның үз карынында да икенче тормыш яралып килүдән туган хис идеме?

— Мин кичә мәктәптә булдым, кызым. Класс җитәкчең чакырткан иде. Фирая Мохтаровна...

— У-ул? — Зәйтүнә гаҗәпсенә калды.

— Әйе, класс җитәкчегез. Эш менә нәрсәдә, кызым. Бик читен булса да, әйтми хәл юк, сине йөкле түгел микән, ди ул.

— Ә нәстә ул «йөкле»?

Бәдрия чыраен сытты. Хикмәт бу сүзнең урысчасы ничек булуындамыни соң? Урысча әйткәнне көтеп утыра бит бәлабаш!

— Беременная! — Бәдрия кычкырып салды, ләкин шундук үзен тыйды.— Әйе, кызым, укытучыгызның шундый шиге бар. Мин ышанырга теләмәдем дә соң... Дөресен белергә кирәк. Бу бит яшереп кала торган нәрсә түгел.

Кызы өчен бу сүз шул тикле көтелмәгән шикелле булды, ул, бичара, урыныннан сикереп торды. Аннары утырды тагын.

Шуннан берничә мизгел тынлык. Тораташ хәле. Шартлау! Зәйтүнә үкереп җылап җибәрде һәм башын әнисенең итәгенә салып яшь түгә башлады.

— Да, мам... Миндә что-то неприятное... Нәстә, нигә, белмәгән...

— Кем белән булдың соң? — И-их, шушы сорауны бирмәс өчен генә дә ул хәзер әллә нинди җәзаларга күнәр иде!

— Ничек? — Зәйтүнә башын күтәреп, күзләрен зур ачты.

— Ничек дип? Ир-ат халкыннан кем белән якынлык кылдың? Коля беләнме?

Зәйтүнә тагын әнисенең итәгенә капланып үкседе. Сүзләре идән астыннан ишетелгәндәй тонык иде.

— Да, Коля белән...

Бәдрия кызының башын итәгеннән каерып алырга теләгән иде дә булдыра алмады, ике кулы белән җайлап кына күтәрде, урыныннан торып, кызына төбәлде.

— Нишләдең булып чыга инде, балакаем? Ниләр генә кыландың? Аракы эчеп төштеңмени соң шул хәлләргә?

— Нет, не арака... Вино попробовать иткән идем...

— Әтиең күзенә ничек күренәсең инде? Мин ничек күренәм аның күзенә, йә? Гайбәте дөньяга таралачак бит бу эшеңнең...

— Коля тоже кайгыра...

Зәйтүнәнең әлеге сүзләре болай да күкертләнеп китәргә торган Бәдрияне чыгырыннан чыгарды.

— Дәшмә ичмасам! Телеңне тешлә! — Бу кискен тавышка кыз сискәнеп китте, өнсез калды. — Коля да кайгыра, имеш! Ишкән икән ишәк чумарын! Коляга нәрсә аңа! Күтәрәсе бармы, тудырасымы? Агуын салган да киткән. Ә синә менә, бәлабаш, күсәкнең чукмары. Буй җитеп, туйлап кияүгә чыгасы җан иден бит син дә. Апаң Фәйтүнә кебек... Кая барып кадалырыңны фәһемеңә дә китермичә кабалангансың...

Зәйтүнә җылый да алмас тәкъдирдә бер ноктага текәлеп утыра башлады. Аның шушы халәте әнисенең котын алды. Кызым җүләрләнә күрмәсен, дип өтәләнә башлады ул. Янә мөлаем булырга тырышып сүз катты.

— Кызым, ямьсезнең аръягындагы хәлгә тардык, инде чарасын күрү кирәк. Шушы яшеңнән бала тапмассыңдыр бит инде?

— Юк, конечно.

«Эһе, акылында икән! Сораганга җавабы бик туры...» Бәдрия сүзен җайлап кына дәвам итте.

— Врачка барыйк. Карасын, тикшерсен. Аборт турында киңәшик. Нәрсә дияр? Ясарга ризалашса, язгы каникул көннәрендә чистарынып чыгарга кирәк сиңа.

— Бик страшно буламы?

— Куркыныч дип, җиңел булмас инде. Түзәрсең. Врачы ясамаска итәр әле аның. Организмың бит бала-чаганыкы... Бар, юынып чык. Кешелеккә дигән киемнәреңне киярсең. Бүгеннән калмый барабыз. Соңгарганны яратмый ул эш...

Гинекологка Бәдрия әүвәле үзе генә керде.

Регистратурада белешкән иде, ишектәге язудан укып, врачның исемен, әтисенең исемен, фамилиясен хәтеренә теркәп керде.

— Исәнмесез, Вера Зиновьевна! — Бәдрия әйләнү-тулгануларсыз сөйләп китәргә булды. — Мин сезнең яныгызга зур йомыш белән килгән идем. Махсус сезнең сменаны көттем.

Соңгы җөмләсе — җил ягына салам кыстырып булмасмы дигән өмет белән алдашу иде.

— Утырыгыз, — диде табибә, бик гадәти генә итеп. — Тыңлыйм. Сезне кем дип белергә кушасыз?

Бәдрия урыс колагына тиз генә барып ирешмәстәй исемнәрне — Бәдрия Сәфәргали кызы дигәннәрне җәһәт кенә үзгәртеп әйтте (һәрчак шулай итә).

— Мине Рия Сафроновна дип йөртәләр, Вера Зиновьевна. Үзем сау-сәламәт, йомышым кызым турында. Кызым Зәйтүнә, Зина, балага узган шикелле.

Табибә иңнәрен сизелер-сизелмәс кенә сикертеп куйды һәм Бәдриягә керфек какмый карап торды.

— Кызыгыз узган, сез килгәнсез. Аңлап бетермим,— диде аннары.
— Ул да биредә. Урамда калып торды. Бик яшь әле ул. Унбишен тутырды гына.
— Укучымыни?
— Әйе.
— Никахсыз гына булып чыга инде алайса?
— Шул-шул, Вера Зиновьевна, шу-ул!— Бәдрия тулышты, күзләрен яшь пәрдәсе сарды.— Шуның көмәнен юк итәргә булышыгыз инде. Алла хакы өчен. Буш итмәс идем...
— Туктагыз әле, сабыр итегез. Күз яше белән генә берни майтарып булмый мондый хәлдә. Чакырыгыз үзен.— Вера Зиновьевна шактый кырыс сөйләште. Зәйтүнә кергәч, Бәдриянең чыгып торуын сорады.
Мәсьәлә ачык иде. Класс җитәкчесе Фирая Мохтаровнаның күрәзәлеге хакка чыкты. Шулай да табибә Зәйтүнәгә өзеп кенә бер нәрсә дә әйтмәде.
— Чыгып тор, әниең керсен. Аның белән сөйләшергә кирәк,— диде.
Кабинетка кабат әйләнеп кергәндә Бәдрия коелып иңгән иде. Вера Зиновьевнаның күзләренә күтәрелеп карарга да кыймады. Гинеколог ханым әйтәчәк сүзләр аның өчен югары хөкемнең соңгы һәм дәһшәтле карары булып яңгырыйсын көткән хәлдә, ул куырылып калды. Вера Зиновьевна исә бик тыныч, үтә гади сөйләп китте.
— Рия Сафроновна,— диде ул, урындыгына җайлабрак утыргач.— Беренче баланы төшерүнең нинди күңелсезлекләргә китерү ихтималын беләсездер дип уйлыйм.
Бәдриянең сабыры сынды. Ул кечкенә сумкасыннан кульяулыгы алып күзләренә каплады.
— Беләм инде, доктор, беләм.
— Мин кызыгызның бала тапмый торган хатын булып калу ихтималы турында әйтәм. Кысырлыкка дучар булу хакында. Мондый факторның киләчәктә аның гаилә тормышына ни дәрәҗәдә тискәре тәэсир итәчәген күз алдына китерәсездер?
— Китерәм, Вера Зиновьевна.
— Абортка ятарыннан алда һәръяклап уйларга кирәк. Җитди итеп. Җиде кат үлчә, бер кат кис, диләрме?
Мәлҗерәп торыр минутлар түгеллеге Бәдриянең аңына ап-ачык булып барып җитте бугай. Ул балавыз сыгып утыруыннан туктады, гәүдәсен турайтты, теленә дә тәвәккәллек чыкты.
— Хөрмәтле доктор, безнең хәлләр шундый: бер уйлап, бер кисә торган. Мине аңларсыз дип өметләнәм. Зиночкага бала табарга һичничек ярамый. Һич-ни-чек! Кеше арасында рисвай булачакбыз, бусы — бер, икенчесе, әйтер идем, иң каһәрлесе, әтисенең абруена пык сугачак бу нәрсә. Ә ул безнең, ни генә димик, подполковник кеше, югары хәрби училищеның танылган укытучысы. Холкы — корыч, алмаз, тагын әллә нәрсә. Үз халкыбызга тел тидерү булса да, әйтим инде, чын татар. Атасыз бала табу дигәнне күтәрә алмаячак. Җитмәсә шушы яшендә...
— Сез кызыгызның балага узуын да, аборт ясатуын да иретездән сер итмәкче буласызмыни, Рия Сафроновна?— Гинеколог ханымның соравын төрлечә аңларга мөмкин иде шикелле. Теләктәшлек күрсәтеп сызлана дип тә, әһә, мондый эшкә барасыз икән, син инде, күгәрченкәсем Рия Сафроновна, минем белән бүтән нотада сөйләш дип тә...
Табибә соравына нинди генә төсмер салынган булмасын, Бәдрия үзенең шушы ханымның тотыгы, әсире икәнен аңлый иде инде. Шунсыз кая барасың?! Шунсыз Назировлар гаиләсе һәлакәткә хөкем ителгән. Шунсыз подполковник Рәхим Назиров кызын да, хатынын да һичнигә карамастан куып чыгарачак...
— Әтисенә тамчы да белгертергә ярамый, Вера Зиновьевна. Бу — мәхшәр булачак. Сез ярдәм итсәгез һәм Зиночканың абортын сер итеп

сакласагыз, безнең гаилә өчен фәрештәлек кылу булыр иде. Мин моны ихластан әйтәм, ярдәмегездән ташламагыз.

— Шифаханәдә ясаган абортны ничек сер итәргә боерасыз?— Табибә Бәдриянең күзләренә томырылып карады.— Ни рәвешле? Минем миссиям юллама кәгазь язу белән тәмамлана бит, Рия Сафроновна.

Бәдриягә югалып калырга һич ярамый иде инде, ул оятын җуярга мәҗбүр адәмнәрчә әрсезләнә бирде.

— Ә, ниме, хөрмәтле Вера Зиновьевна, сез бу эшне өй шартларында гына майтарып чыга алмас идегезме?

— Кем өендә?

— Соң безнең квартирада түгел дә түгел инде, Вера Зиновьевна. Иремнең холкын-фигылен, дөньяга нindirәк күзлектән каравын аңлаттым ич инде, доктор.

— Әйе, аңлаттыгыз. Мин дә аңладым. Алайга китсә, сезнең халыкта йөклелекне өзүгә гомумән кеше тормышын кыю дип карыйлар түгелме соң? Кеше үтерү дип?— Врач Бәдрия ханымның күңел түренә шомны булдыра алган кадәр күбрәк салырга тырыша иде кебек.— Мөселманнарда әүвәле бу шулай бәяләнгән дип беләм. Аннары чегәннәрдә... Табор кануннары буенча, чегән хатынының аборт ясарга хакы юк. Алар үз нәсел-ыругларын саклап калырга тырышудан шулай итәләр...

Бәдрия врач ханымның үзен аңларга теләмәвенә аптырый башлаган иде инде. Гаҗиз булып:

— Борынгыдан кайсы халыкта ни булмагандыр инде, хөрмәтле Вера Зиновьевна. Заманалар үзгәрә, кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары да үзгәрми калмый, күрәсең. Бүгенге яшьләр үз язмышларына да тамаша карагандай мөнәсәбәттә. Минем хәлем, кызымның бүгенге хәле гамәлебезнең һәр мыскалын үлчәүгә салып торырлык түгел бит. Сез — хатын кеше, мине нечкәләп аңларга тиешсез. Врач кешенең аерата мәрхәмәтле булуына ышанасым килә минем...— Ул Вера Зиновьевнаның күзләренә мөлдерәп карады. Бөялгән күз яше аша врачның гәүдәсе аңа җәелә барган, калтыраган сыман күренде.— Өметебезне өзмәгез бер ук. Ялварам, Вера Зиновьевна, булышыгыз. Тик бу безнең өчебез арасында мәңгелек сер булып кала күрсен иде.

Доктор кыяташтай кала бирде. Аның зур зәңгәр күзләрендә котып салкынлыгын чамалау читен түгел иде. Юка иреннәрен кысып беравык торгач, ул әйтте:

— Сез, Рия Сафроновна, чабуыгызга ут капкандай шулай үрсәләнәсез, беләм. Фактта мине җинаятькә этәрмәкчесез. Минем тыныч-имин яшисем килә. Быел көзгә улымны армиядән көтәм. Ул егетнең дә ялгызак-ятим калуын теләмим.

Бәдрия өнсез калды. Бүтән ялвару сүзләрен дә әйтә алмас булды. Теле аңкавына ябышкан иде диярсең. Тыны киселде шикелле. Аннары аның бәгырь эчкәресеннән шул тикле кайнар тын бәреп чыкты, врач ханым имәнеп киткән төсле булды. Йөз пешерерлек сулышка моңынназакәтен җуйган авазлар ияргән иде.

— Сабыр канатларымны сындырмагыз, Вера Зиновьевна! Алла хакына дип әйтүем. Сорагыз тиярен, үз квартирагызда башкарып чыгыгыз. Сезгә карата нинди кара уем була алсын, йә? Нигә рәнҗетәсез? Безне кара язмыштан йолып калыгыз...

Сүзнең болай да озынга киткәнен бик белеп торган врач кистереп сөйләшер минут җиткәнен чамалады.

— Ярый, бик гозерлисез икән, Сез сораганча булыр, Рия Сафроновна. Әмма...— Ул кечкенә тыныш ясады.— ...минем дә җитди шартым бар. Бриллиант кашлы йөзегегез белән түләрсез. Артык та түгел, ким дә түгел...

Бәдрия дертләп китте, татлы йокысыннан төрткәләп уяттылармыни! Хәер, нәрсә ул йокы бүлдерү?! Йөрәгенең бер читен кисеп алдылар диярсең, йөрәгенең!

Әмма икенче мизгелдә үк ясалма-риялы булса да елмаерга азаплана иде инде.

— Мин риза, бик риза...

Бәдрия уң кул бармагыннан йөзеген сала башлады.

Юлда кайтканда Бәдрия ханым кызына ничек итәргә туры киләчәген бәйнә-бәйнә төшендерде. Язгы каникулга чыгу белән Вера Зиновьевнаның үз квартирасында... Әтиеңә ангина аркасында больницага керде диярмен...

Кызы ниләр тойгандыр, ниләр кичергәндер, Бәдрия үзе өерелеп-өерелеп яуган карны да сизми, аяк астының лычма су, ләпек икәнен дә тоймый иде.

Туксанынчы елның язы ашыга идеме, әллә кабаланган булып кылана гына идеме, белмәссең. Бәдрия йөрәгендә бәргәләнгән тойгылар исә җилле, янгырлы, аяк асты бозлы көнгә тәңгәл иделәр.

Өйгә кайтып кергәч, Бәдрия ханым дөрләп янган уттан алып бәкегә чумырган бәндә хәлендә калды. Шомлануы хәттин ашты. Мәкерле мәче йонлач кенәриләрнең берсен буып ташлаган иде.

— Читлеганнән үз башына чыккан икән бичара кошчык! — дип сукранды ул. — Хәер, хәер... адәм балалары да читлекләреннән үз башларына чыгалар ич. Күрәчәкләрен эзләп... Кем генә җитәкләп алып чыккан иде бу баланы бәласына таба?! Буып ташлаган кенәри түгелме соң бүген мин үзем? Тамырларында бабаларының кыргый каны уйнаган йонлачтан киммени яшькелт-зәңгәр күзле Вера Зиновьевна? Аякларыңа басып, муеныңны тартып өзәргә тора лабаса... Тик... тик ул безне эзләп килмәде бит, без аңа йөз суы түгеп бардык.

Шул чак Бәдрия миендә яшен сызылып узды. Чартлатып сугасын көтеп, ханым куырылып килде, бөрешеп калды. Баш өстендә үк булмады, ахрысы, дәррәү китереп ормады, бервакыттан гына гөлдерәгәндәй итте. Яшеннең тармакланып яшьнәве дигәнебез — Бәдрия аңына класс җитәкчесе Фирая Мохтаровна хакындагы уйның барып җитүе иде.

Ярый, врач ханым авызына су капты, ди. Кирәген алды бит инде. Аннары ул үзенең ришвәт алуын кычкырып йөрмәячәк, яшереп аборт ясап яткан өчен баштан сыйпамауларын бик әйбәт белә. Ә менә Фирая Мохтаровна дигәннәренең авызын ни белән томалый алырсың? Ул бит алтын йөзек түгел, бәйрәм бүләге итеп чәчәк тә кабул итми, укучыларына: «Минем өчен сездән иң зур бүләк — яхшы укуыгыз, әдәпле булуыгыз», — дип кенә җибәрә. Шулай да ул явыз хатын белән нишләргә булыр соң әле? Бармадың, күрмәдең, ди. Ә үзе чакыртса һәм: «Йә, ни хәлләрегез бар? Бик дулап чыгып киткән идегез, минем сүзем хак булдымы? Нахак әйткәнмен икән, яла яккан өчен хөкемгә тарттырыгыз! Ә-ә, тарттыра алмыйсызмыни? Менә бит ничек! Йөзең кара — телең кыска, дигәннәре шул була ул! Әле Рәхим Гарипович белмидер бу хәлләрегезне,..» — дисә? Бәлки, Ходай кушып, ул бер сүз дә әйтмәс. Чакыртмас та, җәрәхәткә тоз да сипмәс. Педагог ич ул. Педагогларны такт саклауга, әдәп кысаларыннан чыкмау мәсьәләсендә врачлар белән чагыштырып булмыйдыр... Үзем гаепле. Тирәкнең төбенә тоз коймый торып җикеренә башладым. Барып гафу сораргамы? Монысы бит инде кызның хәлен турыдан-туры сөйләп бирү белән бер. Чыннан да, ни хәл итәргә? Юк бит, юк, әтисе белән уртага салып киңәшә торган эш тә түгел. И-и ходаем, тагын ниләр генә күрәселәрем бар икән?

Кызы, өйгә нинди эшләр бирделәр икән, белешеп кайтыйм да хәзерләнеп барырмын, дип, классташ кызларына китте. Чирек азагы, укытучылар бер дәрестә ничә кешедән сабак тыңлаталар, чөнки чирек билге чыгарасылары бар...

Ялгызы калгач, Бәдрия ирә кайтуына аш әзерли башлады. Куллары тик тормады, ләкин алар күнегелгән гадәт буенча гына кыймылдадылар, ә уйлары һич күнегелмәгән, моңарчы агарга туры килмәгән үзәннән актылар. Чуала-чуала, бутала-бутала, бер өермәләнеп, бер тыйлыгып...

Үзенең бүгенге Зәйтүнә шае чагын хәтерләде Бәдрия. Кая ул мондый йөгәнсезлекләр күрсәтү! Аркылы Тукай (хәзерге Фатих Кәрим) урамындагы алтынчы йортта туып үскән Казан кызы ундүрт-унбиш яшьләрендә үсмер егет белән янәшә атларга да ояла иде. Бер ул гына түгел, һәммә кордашлары шулай иде.

Рәхим Назиров белән мехчылар клубында узган концертта танышып китүләрен искә төшерде. Ул чакта Рәхим — лейтенант погоннары тагып кайткан яшь офицер, Бәдрия — институтның дүртенче курс студенткасы. Лейтенант училище тәмамлаганнан соң бирелә торган ялына кайтканда Казандагы кардәшләренә кереп чыгарга карар иткән икән. Сәфәре — Зөя буендагы туган авылына, әти-әнисе янына. Кунакка, күреп китәргә. Аннары хәрби хезмәт юлы аны Ерак Көнчыгышка алып китәчәк...

Танышудан соң ике елга якын гомер үтүгә кавышу, өйләнешү. Ул сәгать сукканчы ике арада хатлар өзелмәве. Аларга теркәлгән кайнар хисләрдән кәгазь-конвертка ничек ут капмады икән диярлек.

Бәдрия үз-үзеннән көлебрәк хәтергә төшерә: хисләр канатлануы сәбәп булгандыр, ул Рәхимгә челтәр бәйләүгә кагылышлы тезмә юллар да язып җибәргән иде. Никахлашкач, Бәдрия үткән юллар да нәкъ иренекечә булды. Энә кая — җебе шунда: Ерак Көнчыгыш, Мәскәү яны, Германия, Калининград өлкәсе, Мәскәү шәһәре... Ниһаять, Казан.

Фәйтүнә туган ел, мең тугыз йөз алтмыш сигез... Икенче бала булсынмы, юкмы дип фикер бизмәненә салулар, сагаюлар, икеләнүләр (хәрбиләр гаиләсенә аерата хас уйлар). Җиде елдан соң гына Зәйтүнәнең дөньяга килүе. Тагын әллә ниләр, әллә ниләр...

Ире кайтып кергәнче аш-су ягында маташты ул.

Рәхимнең кәефе әйбәт иде бугай, ашын да бик ошатты, чәйне дә үтә тәмләп эчте, ачылып китеп сөйләште, хәтта шаярды да. Зәйтүнә кайтып кергәч тә бик җан җылылы булды. Кичке мәлне телевизорны кабызгач кына бервакыт тыңлап утырды да сөмсере коелды. Шактый озынга сузылган телетапшыруда «интернациональ бурыч» дигән сүзләрне бик еш тәкрарладылар. Шуннан подполковник әйтә куйды:

— Шулкадәр гомерләрне өзү, астрономик масштабта матди чыгымнарга төшү, халыкның рухын сындыру, берничә буынга күңел җәрәхәте калдыру кирәк идеме соң?..

Алда телгә алган Коля — татар малае. Аның чын исеме — Носрәтулла. Гарәпчәдән тәрҗемә кылсаң, Аллаһе Тәгаләнең ярдәмле колы булып чыга.

Савинка әһелләре синең исемеңне тулы килеш әйтеп торалармы, мәктәпкә барганчы ук «улла»сын балта белән чабып өзгәндәй иттеләр. «Носрәт» калды. Урыс катыш татар «Ә» авазын әйтеп азапланамы? «Носрат» дип кенә җибәрә. Шуннан китә инде! «Т»ны гына азрак йомшарталар да...

Кыскасы, татар исемнәре башына төшкән гадәти бер язмыш: Носрәтулла Николайга әверелә һәм, яшүсмер буларак, Коля...

Носрәтулла-Николай-Коля тугызынчы класста укып йөри. Йөрми булдыра алмаганга йөри. Чибәр генә, таза, нык егет. Аның кебекләр байтак.

Носрәтулла соңгы көннәргә кадәр үзенең яшьтәшләреннән берни белән дә диярлек аерылмый иде. Ни уңайга, ни тискәрегә. Ә менә моннан берничә көн элек кенә якын таныш-белешләрен генә түгел, күпне күргән чекистларны, җинаятьчеләрне эзләүдә тиз хәрәкәт итүчеләрне дә, шаккаттырды...

Җиденче заводта эшләүче Мәрфуганы поселокта бик тә тыйнак хатын дип беләләр. Ире вафатыннан соң да сырхау әнисе карчыкны һәм мәктәптә укып йөрүче улы Носрәтулланы тәрбия итүдә җанын аямый. Бер нәрсәдә дә зурдан купмый, аякларын юрганына карап кына суза. Көнтөн эшли, кай арада йоклый, кайчанрак хәл җыя — өзеп кенә әйтә дә алмассың.

Менә шул хатын, очын-очка чак-чак ялгап көн күрүче Мәрфуга, соңгы араларда дусларыннан, танышларыннан бурычка күпләп акча-ала башлады. Завод профсоюз оешмасына да акчалата ярдәм итүне гозерләп май аенда бер-бер артлы ике гариза язды. Кыйммәтле әйбер сатып алырга ният итә дияр идең, кайгысы анда түгеллеге көн кебек ачык. Әнисе ничәнче ел инде урын өстендә, малаен да аякка бастырасы бар. Күзенә ак-кара күренерлекмени?

Әҗәткә акча биреп торучыларның бер ишесе тагын бер нәрсәгә дикъкать итми калмадылар: Мәрфуга фани дөньядан үткән төсле йөри, чыраенда — курку, дәһшәт галәмәтләре...

Май аеның ямьле бер көнендә Носрәтулла өйләренә каңгырып кайтып керде. Ана йөрәге сизмиме газиз баласының рухи халәтен? Мәрфуга, мәгълүм инде, өтәләнеп хәл-әхвәл сораштырырга керешә. Улы да, әнисенең сорауларын гына көтеп торган диярсең, коточкыч хәл турында сөйләде.

Автозаправка тукталышында өч адәм Носрәтулланың юлын кискәннәр. Берсе чегәнгә охшаган, икенчесенең кул аркалары кытай карасы белән чәнчеп ясаган рәсемле, өченчесе җирәнрәк, күн тужуркадан икән. Машиналары японныкы, һушыңны алырлык... Менә шулар Носрәтулладан бер атна эчендә биш мең сум акча табып бир дип даулаганнар. Тапмыйсың икән, үзеңне дә, әниеңне дә, яраткан кызыңны да теге дөньяга олактырабыз дип янаганнар.

Әлеге йөрәк яргыч хәбәрне әйткәч, Носрәтулла зар жылап үтенде, әнкәй бәгырем, бер үк милициягә әйтә күрмә, мине көне-сәгате белән юк итәчәкләр, дип ялынды. Алар кулыннан җан биргәнче мин үз-үземне үтерәм, дип өзгәләнде.

Шулай да, ни булса да булыр, аллага тапшырдым дип, улының ялынычын бер читкә тибәреп, Мәрфуга хәлне милициягә ирештерү әмәлен тапты. Үзе бармады, ахирәт хатыныннан булышлык сорады.

Шимбә көн кич белән, майның егермесендә, кесәсендә тегеләр янап даулаган акчасы бар хәлендә, Носрәтулла очрашуга юнәлгәндә, тиешенчә коралланган өлгерләр күзгә-башка күренми генә егетне озатып-күзләп бардылар. Алар һәртөрле көтелмәгән хәлләргә әзер кешеләр иде инде. Мәгәр күңелләрендә шик очкыны да бар иде. Носрәтулла тасвирлаган кыяфәтле кешеләр һәм аларның «Тойота» машинасы хакында бернинди мәгълүмат кыйпылчыгы да юк.

Әле анда сугылып, әле монда кагылып Носрәтулла Казанның төрле почмакларында ике сәгатьтән артык йөреде. Аннары өйләренә кайтып, әнисенә теге явызлар сораган акчаларны тапшырдым диде. Шуннан соң егет подполковник Назиров гаиләсе яши торган тугыз катлы йортка юл тотты, Зәйтүнәгә мең ярым акча калдырды, шуннан соң танышларына китте. Белешләре белән үзенә «Ява» мотоциклы сатып алу мәсьәләсендә гәп куертты.

Эчке эшләр идарәсенә алып килгәч, Носрәтулла бик тә сәерсенеп калды.

— Минем ни гаебем бар? — диде ул күзләрен шарайтып. — Аңламыйм. Берәүне дә талаганым юк. Акчаны миңа әнкәй бирде. «Ява» алырга җыенам. Дус кызыма акча бирдем. Киенсен. Бай яшисем килә минем...

Хокук саклау кешеләре аның ни кылганын күпме генә аңлатмасыннар, Носрәтулла үз фикерендә калды: «Берәүне дә талаганым юк...»

Мәрфуга ни кылсын, елады, сыкрады, ә берәнберен кичерде, гафу итте. Ярлыкау — аналар эше, күрәсең...

Июнь керде. Бу айны, җәй башын, табигать туплар атып каршылады булып чыкты. Майның соңгы төне таңга авышканда яшенле, күк күкрәүле яңгыр явып узды.

Җиһанда яшеллек патшалыгы. Чәчәкләрнең бихисап төсләре, һаваның сафлыгы, көннәрнең матурлыгы хәйран итә. Бакчаларга, паркларга

керсәң, хыял канатлана. Агачларга да: «Саумы, каен кызы!», «Исәнме, имән егете!», «Хәерле иртә, миләш зифасы!», «Ни хәлләрең бар, юкә сылуы?!» — дип эндәшәсе килә.

Күпме таңсынып карасаң да, бар матурлыкны бәяләп бетереп булмастыр. Өстәвенә сандугач сайравы, кәккүк моңнары!..

Иртүк Идел аръягындагы Суксу авылы янындагы бакчаларыннан кайтып килгәндә шундый тойгылар әсирлегендә иде. Ире белән кызы да әйтеп аңлатуы мөмкин булмаган бер халәт кичерәләр иде шикелле. Сүзсез генә янәшә атлаулары шуннан булгандыр.

Рәшит Мусин урамына кайтып җиткәч, үз йортларына борылабыз дигәндә, Бәдрия ханым өчен кояшны болыт каплагандай булды, табигать хозурлыгы аның өчен, селтәң аткандай, юкка чыкты. Аларның каршысына әллә елмаеп, әллә чырай сытып Вера Зиновьевна якынлашып килә иде. Өйләренә үк барган булганмы әллә? Кайтуларын көтеп, сагалап торганмы?

Бәдриянең йөрәге күкрәк читлегеннән каядыр аска шуышкан төсле булды. Самолетта очканда кайчак шундыйрак имәнү булып алучан.

Врач ханым Назировларның һәммәсенә берьюлы сәлам ташлады:

— Исәннәрмесез, әйбәт кешеләр!

Рәхим белән Зәйтүнә исәнләштеләр дә узып киттеләр. Бәдриянең туктамый хәле юк иде.

— Рия Сафроновна, кадерлем! Сезгә йомышым төшеп тора бит әле.— Вера Зиновьевна чәчелә-түгелә башлаган иде, Бәдрия тыныч, сабыр булырга чамасыз тырышып, аны бүлдерде.

— Хөрмәтле Вера Зиновьевна, зинһар, гафу итегез. Бакчадан кайтышыбыз гына. Хәзергә туктап тора алмыйм. Иремне ашатып-эчертеп эшкә озатыйм, аннары үзем сезнең яныгызга килермен.

Табибә килеште.

— Мин бүген үзе сәгать икедән соң гына кабул итәм. Әмма сезне шунда көтәрмен. Күпмедән?

— Сәгать ярымнан, Вера Зиновьевна.

— Килештек.

Табибә яныннан киткәндә Бәдрия тез буыннарының йомшавын сизде, аякларының тыңламаска әйләнүенә аптырый калды. Ике чигәсендә ике чүкеч сандалга салып кызган тимер таптыйлар иде: «Менә сиңа! Менә сиңа!»

Бәдрия «Ник килгән бу тагын?» дигән сорауга җавап эзләп изаланды. Вера Зиновьевнаның үзләрен махсус көтеп алганлыгына шиге юк иде инде.

— Кем булды ул сине туктаткан кеше? — Рәхим өс-баш алыштырып, кырынып-юынып йөргән мәлдә генә сорап куйды.

— Безнең поликлиника врачы. Сидоренко ханым. Вера Зиновьевна.

— Йомышы бармыни?

— Юк... — Бәдрияне бизгәк тота башлагандай итте.— Таныш булгач, сәлам бирүедер инде.

— Кайдан белә ул сине?

Ире тагын бер сорау бирә калса, подполковникның хәләл җефете аягында торып кала алмас иде, мөгаен. Ходайдан күркәм сабырлыклар сорап, кухнядагы урындыкларның берсенә барып утыргач, Бәдрия телен көч-хәл әйләндереп җавап бирде.

— Гинеколог ул. Ничек инде белмәсен. Әйтерсен лә, мин аңа күренми торам.

— Ә-ә...

Рәхимнең кызыксынуы шунда тәмам булды. «Гинеколог нишли ул?» дип тә төпченмәс бит инде.

Иртәнге чәй янында бик гадәти утырдылар. Һәрвакыттагы сүзләр, киңәш-уңаш, бүгенгә планнар... Бәдрия ут йотып утырганын ничекләр итеп булса да сиздермәскә тырышты. Ә Зәйтүнәгә Сидоренко апасының

очравы берничек тә тәэсир итмәгән идеме соң әллә? Ай-һай ла, әтисе алдында гына тыныч күренергә дип көчәнмәдеме икән? Вера Зиновьевна квартирасында үрле-кырлы килгәннәре еллар үткәч тә йокысыннан сискәндереп уятыр әле аны.

Рәхим училищега китте. Иренең лифт арбасына керүен кушкатлы ишек аша ишетеп торган Бәдрия көзгә каршына утырып бизәнергә кереште. Аннары иң яраткан күлмәген алып киде, шуңа иш ташлы колак алкаларын такты, биек үкчәле туфлиләренең күлмәге төсендәгесен киде, кул сумкасының бөтен киеменә тач туры килгәнен сайлап алды. Тыштан гөлчәчәк иде, кыскасы. Йөрәгендә исә чәчкәнең чәнечкеләре тырпаешкан. Күңеле эчкәресендәге үтә нечкә кылларның тибрәнүеннән сизә Бәдрия: хәерлегә түгел врач хатынның әйләнеп тулганулары!..

Вера Зиновьевна Бәдрияне поликлиниканың төп ишеге буенда көтеп алды. Табибәнең юкка матур иреннәренә елмаю кунган, җете зәңгәр күзләре илтифатлы карый. Ясалма озынайтылган керфекләрен бермәтекләп санарга мөмкин иде.

Шулай да бизәнү дигәндә врач ханым чама җуймый. Шуңа ул җанлы кеше булып кала бирә. Бәдрия дә иннек-кершән, сөрмә белән эш итә белми түгел, тик төзәнеп бетергән минутында таш курчакка әйләнә дә куя.

— Килдегезме, Рия Сафроновна?

— Күргәнегезчә, Вера Зиновьевна.

Ике хатын мизгел дәвамында гына бер-берсенә сынаулы текәлеп тордылар. «Йә, кайсыбыз чибәррәк? Кайсыбызның буй-сыны шәбрәк? Кайсыбыз заманчарак киенгән?» ди иде аларның бар булдыклары.

Аннары врач ханым Бәдрияне сак кына култыклап алды, башы белән генә Черноморская урамы ягына атлыйк дигәнне аңлатты. Тегесе карышмады. Вак-вак атлап китеп бардылар. Дәрт-дәрманнары ташып ук тормаса да, кемнәрнеңдер йөрәкләренә баскандай атлыйлар иде.

— Сезне борчыдым, гафу сорыйм,— диде нәзакәтле итеп Вера Зиновьевна.— Кичерә күрегез. Ничек диләр әле, нужа печән ашата, диләрме? Хәлем печән ашарлык ук булмаса да, сезгә мөрәҗәгать итми чарам юк.

Сагайды Бәдрия, колакларын шомрайтты. Шулай да чыраенда көләчлек сакларга итеп:

— Тыңлыйм, Вера Зиновьевна,— диде.

Табибә үгезне мөгезеннән эләктерергә булды.

— Кырыкны уздым, Рия Сафроновна, ничәнче ел инде табиблек итәм, адәм рәтле киенә алганым юк. Ирдән аерылып малай үстердем... Менә өченче көн генә бик матур тун тәкъдим иттеләр. Натуральный мехтан. Үземә үлчәп теккәннәр диярсең.— Вера Сидоренко култыклашып барган мәлдән башын борып Бәдрияне йөзенә карады. Тел төбемне төшенәме, янәсе. Төшенсә, нинди рәк уйга киләчәк?— Шуны алырга акчам җитеп бетми. Сездән әҗәткә сорап тормакчы идем.

Нәкъ Бәдрия фараз кылганча килеп чыкты, нәкъ! Тагын бәгырь итен умырмакчы гуҗ бәндә!

Подполковник хатынының шул секундта алга-артка карамыйча бу комсыздан качасы, оятсыз син, дип бөтен кеше ишетерлек итеп кычкырасы килде, ләкин ул ничарадан бичара булып, култыклашкан килеш атлый бирде. Авызына су кабып барыр чак түгел иде. Сорады.

— Күпме дисез инде, Вера Зиновьевна?

— Мең сум.— Табибә моны шулкадәр тыныч әйтте, сүз, гүя, чәчәк бәйләме алырлык акча хакында гына иде. Бәдриягә килгәндә, ул башына таяк белән органдай хәлдә калды. Шып туктады. Кулын тартып алды.

— Ме-ең сум?— Аның тавышы яшелле-күкле булып чыкты.— Акылыгыздамы сез? Каян килгән, ди, миңа андый акча?! Без бит бер кеше хезмәт хакына яшибез. Мин эшләмим. Шаяртмагыз, зинһар. Бала-чага түгелбез...

Бәдрия артка чигенде. Табибә дә аңа таба бер адым атлады.

— Шаяртмыйм, хөрмәтле Рия Сафроновна, ша-ярт-мыйм...—Вера Зиновьевнаның юка иреннәре кысылды, күзләрендә яман очкыннар ялтырады, йөзеннән матурлык качты.— Кирәк тирәкне ега. Шуңа гозерләвем. Расписка язармын, шикләнердәй булсагыз. Бер юлы гына түли алмам, шулай да озаклатмаска тырышырмын. Сезгә кирәк чакта мин бит ярдәмемнән ташламадым. Хәтерсез булмагыз инде алай ук, Рия Сафроновна!

Белә иде Бәдрия врачның шулай диясен, көтеп торды ул бу сүзләрне. Шул өермә баштан узмаган булса, аның алдында калтырап торыр идемени? Алай да мәңгелек кабалага эләгергә димәгәндер ләбаса инде! Әйтми торсаң, еллар буе күләгәң төсле йөрер бу.

— Ярдәмегезне буш итмәдем, Вера Зиновьевна. Хакын мөлдерәмә итеп тутырук алдыгыз.— Кыюлыгын җыеп Бәдрия шулай кырт кисте.— Инде артыгын өметләнмәгез. Кешенең бәхетсезлегеннән файдалану килешкән эш түгел. Бриллиант кашлы йөзегем бармагыгызда бит.

Вера Сидоренко башын югары күтәрде һәм моңарчы күрсәтмәгән кирелек белән өздереп сорады:

— Акча биреп торырга теләмисез алайса? Бу — соңгы җавабыгызмы?

— Юк миндә андый акча.

— Яхшы! Ирегез табып бирерлек итәрмен. Менә... — Ул, биеп торган чегән хатыны сыман, асыл ташлы йөзек кигән кулын Бәдриянең борын төбендә дерелдәтеп-уйнатып алды.— ...Сезнең подполковниктан сер иткән астыртын эшегезнең телсез шаһиты. Ирегез бик тиз танып алыр аны.

Бәдрия чайкалып китте, куллары белән нәрсәгәдер тотынырга теләгән хәрәкәт ясады, бәхеткә, аяк өсли калды.

— Шулай эшләр идегезме? — Ул сабыйларча сорап куйды.

— Ике дә уйламыйм, күземне дә йоммыйм! — Сидоренко ханым әллә тешләрен дә шыкырдатып куйды шунда.— Мине берәү дә кызганмый, нигә әле мин генә аяулы булып маташыйм? Заманасы шундый, мәрхәмәтсезләр хакимлеге...

Бәдриянең мие түнгән иде. Табибә, аны мәрткә киткән җиреннән уятырга теләгәндәй, тавышын күтәрә төште.

— Инде ни диярсез, Рия Сафроновна?

— Шантажистка сез... — Бәдрия моны пышылдап кына әйтте, бүтәнчәсенә көче калмаган иде.— Уйлап карармын, эзләрмен, табарга тырышырмын...

Вера Зиновьевна канатланды.

— Иртәгә өйләгә кадәр, хөрмәтлем Рия Сафроновна. Минем кабул итү сәгатем көндез ике тулырга унбиш минутта бетә. Поликлиникага китерерсез. Хушыгыз!

Ул баш иеп саубуллашты. Читтән карап торучы булса, бу нинди тәкәллефле ханымнар дияр иде.

Бәдрия өйләренә көч-хәл белән кайтты. Юл аркылы чыкканда әздән генә трамвайга тапталмый калды. Вагонны ярты адымда туктаттылар. Салонда шул хәтле ыгы-зыгы купкандыр, күрәсең, исләренә килгән берничә юлаучы сикереп чыгып, Бәдрияне эт итеп сүгәргә кереште:

— Исеректер юньсез!

— Юк, эчкәнгә охшамый. Уенда мужикның кәттәсе!

— Әҗәл эзләсәң, поезд астына ташлан!..

Ишекне Зәйтүнә ачты. Бәдрия, бусагадан атлап керүгә, лап итеп идәнгә утырды һәм тилемсә кеше төсле ыңгылдап елый башлады.

Кызның коты калмады. Ул:

— Мам... мамочка... Нәрсә? Кем? — дип өтәләнде.

Мең газап белән чишенеп, Бәдрия урынга барып ауды.

— Скорая чакырыйммы? Нуль три бит?

Әнисе кирәкми дип баш чайкады һәм мендәргә капланып елый бирде. Инде уламый да, шыңшымый да, иңнәре генә тыелгысыз дерелдәшә иде.

Бервакыттан хуҗабикә тынычланды. Әллә йөзтүбән йоклап китте, әллә очсыз-кырыйсыз уйларына чумып ята иде. Зәйтүнә аны берничә кат еракган гына карап килде: сулый, исән...

Чыннан да, арып-өшәнеп, җаны да, тәне дә таланып-алҗып йоклап киткән булган, ахры, сәгатьтән артык вакыт узгач Бәдрия торды. Салкын су белән озаклап юынды, валидолмы-ниме капты һәм шул даруның организмга тәэсирен көтеп тын гына утырды. Шуннан соң кызын үз янына чакырып алды. Софага янәшә утырдылар.

— Кызым! — диде ана, бу дөньядагы һәммә нәрсәгә битараф бер кодрәтсез тавыш белән. — Сине битәрләвем түгел. Буласы булган, буявы уңган. Ахырын гына ходаем хәерле кылсын... Теге врач хатын, Вера Зиновьевнаны әйтәм, тәмам тигәнәк булды бит. Синең хәлләреңне әтиеңә ирештерү белән яный, әтиеңә... Тун алырга дип мең сум акча сорый. Мең сум! Саклык банкында анлык кына акчабыз бар барын. Көннәрнең берендә әтиең таптыра башласа? Ни хәл итәргә дә белмим, акылым ирешми... Мин бит инде аңа үземнең бриллиант кашлы йөзегемне салып биргән идем...

— Ка-ак? — Зәйтүнәнең уймактай гына авызы ачылды да калды, ябылмый торды. Аннары гына телгә килде ул. — Ә нигә?

Бәдрия хәйран булып кызына карап торды.

— Ни өчен икәнен белмисеңмени соң? Сине бит ул үз квартирасында берәүгә дә белдерми генә чистартты. Под-поль-но! Андый эшне рәхмәткә башкармыйлар. Ярар, сүз ул хакта түгел, йөзегем дә, балдагым да тагын бар. Менә акча дигәндә нинди генә әмәлләр табасы? Әгәр дә чын эшләр әтиеңә ишетелә калса, кыямәт бит, мәхшәр! Икебезне дә куып чыгарачак яисә атып үтерәчәк...

Бәдрия ике учы белән башын кысып, идәнгә карап утыра башлады. Шулчак Зәйтүнә миенә бер тамчы нур тамды бугай. Ул әнисенең беләгенә сак кына кагылып сорады.

— Мам, ә ул күпме просит?

— Ай аллакаем, әйттем ләбаса, мең сум! Тысяча рублей, татар баласы!

Зәйтүнә сикереп торып үз бүлмәсенә кереп китте һәм миңгерәп утырган әнисенә акча китереп тоттырды.

Бәдриянең күзләре маңгаена менде. Утыз тугыз яшенә җитеп аның бу дәрәҗәдә аптыраганы да, шашынганы да булмагандыр. Бу тиклс җүләрләнгән караш газиз баласын бәреп үтергән патшаларда гына була.

— Кайдан алдың бу акчаларны? Кем бирде? — Мондый кыргый тавыш та әҗәл белән алышканда гына чыга торгандыр. — Синнән сорыйм, каян сиңа бу хәтле акча?

Зәйтүнә, әнисенә капма-каршы буларак, артыгында тыныч җавап кайтарды.

— Коля бирде.

— Коля? Нәсрәтулламы? Аңа кайдан килгән мондый акча?

— Әнисе биргән.

Бәдрия, өнемме соң бу, саташулы төшемме, дип икеләнә калып, башын чайкап карады. Дәһшәтле-зәхмәтле хәлләрдән арынасы килә иде аның. Нормаль кешеләрчә фикерләп багасы килә иде.

— Соң, Зәйтүнә, уйлап кара, Коля әнисенең кешегә бирерлек нинди байлыгы булсын? Тол хатын бит ул. Анасы карчык күпмедән бирле урын өстендә, диләр... Өйләрен рәтләрләр иде алар, акчалары булса. Капка баганалары икесе ике якка янтайган... Син, маташтырма, кызый, әйт хәзер үк дөресен: бу акчаны ничек таптыгыз? Урлаштыгызмы? Кеше таладыгызмы? Квартира бастыгызмы? Әйт! Әтиең кайткач барыбер әйттерер. Хәзер аңардан бер нәрсәне дә яшереп калдырып булмаячак! Аһ аллам! Әлмәккә кертәсең бит мине! Асылынып үләргә генә калды миңа!..

Шул чиккә җитеп хәлсезләндеме, һушыннан ук яздымы, Бәдрия софага ауды. Кызы аны җайлап яткырды.

— Ма, мамочка... Юкка не беспокойся, ярый? Бернинди дә воровство юк, грабеж юк. Акча Коляныкы. Ул миңа подарил... Честное слово!

Бәдрия әллә ишетми, әллә бөтенләй тыңларга теләми иде, ак та димәде, кара дип тә җавап бирмәде.

— Мин отнесу үзем... Син успокойся, мам... Мин хәзер!..

Ул әнисе кулыннан төшеп идәнгә таралган унлыкларны җыйды, ашыгып киенде дә Вера Зиновьевнаның өенә китте. Белә бит кайда яшәгәнен, таныш квартира...

Язмышы белән килешүдән гайре чарасы калмады Бәдриянең. Һич югы бүгенгә. Бая башын җуяр тәкъдиргә җитеп, һәммәсен түкми-чәчми Рәхимгә сөйләргә карар иткән иде ул. Куса кусын, үтерсә үтерсен иде инде. Бәла ялгыз йөрми диләр, шулай да язмыш ник кенә бер кеше иңенә шул тикле таш өя икән соң?

Азрак суынгач, бүтәнчәрәк фикерләп карарга булды. Чыннан да, аның баласы карак яки талаучы була алмый бит инде. Зәйтүнәнең яман ялгышы да кеше малына күз кыздыру белән бәйле түгел, яшьлек хатасы, тәкатьсезлек бәласы... Әгәр, чыннан да, Норсатулла биргән акчалар икән, анысына да, хак әгәре, әнисе биргән икән, илтсен теге ач күзгә. Носрәтуллага аз-азлап түләп бетерермен дип исәпләде ул. Рәхимгә серне чишүдән дә, аннан соң күрәчәкләрдән дә авыррак булмас аз-азлап әҗәт кайтаруы...

Бәдрия шундый нәтиҗәгә килеп, вакытлыча гына булса да үз-үзен юатып маташкач, Зәйтүнә врачка акчаларны биреп кайтканнан соң, подполковникны көндәгечә диярлек каршыладылар. Бәдрия ханым кәефе юклыктан зарланды зарлануын, чөнки рухи халәтен яшерерлек түгел иде. Әлегә вазгыятьнең янә бер ягы телгәли иде аның йөрәген: кызын турысын танудан, дөресен сөйләүдән үзе үк читкә алып китә түгелме соң?

Бер күзәтте Коля-Носрәтулла Вера Сидоренконың бакчасына килгән чагын, ике күзәтте. Ничә барса, ничә кайтса да ялгызы гына. Кыргый сыман. Кешеләр белән аралашырга яратмый булса кирәк.

Поликлиникадан иртән кабул итсә, атнаның теләсә кайсы көнендә өйләдән соң юнәлә ул бакчага. Җир корты диярсең, баш күтәрми казына...

Июнь азагы иде. Эш көне. Бакчада анда-санда пенсионерлар гына кыймылдаша.

Икәү каршыладылар Вера Зиновьевнаны. Коры елгадагы бакчасында иң кырый участокта. Берсе читтә торып торды. Коля куктән төшкән төсле, врач ханымның каршысына килеп басты.

— Стоп! Син — Вера Зиновьевна Сидоренко. Шулаймы?

— Ә-әйе.

— Тынлык! Кабер тынлыгы! Сыңар сүз әйтүең — йөрәгеңә пычак!— Егет хәнҗәр ялтыратты.— Хәзер үк бриллиант кашлы йөзекне саласың и ... гуд бай! Сиңа төс түгел ул. Йә! Бер... ике...

— Мә, мә, ал да китә бир! — Вера Зиновьевна йөзекне салып бирде. Чырае киңдер төсенә кергән иде, иреннәре дерелдәште, куллары калтыранды.

— Алам да китәм. Безелдәсәң бел: хөкем карары көнендә чыгарылачак. Җәза — үлем. Улың Юрий армиядән кайтасы. Синең безелдәвең — аңа да үлем... Хуш иттек!

Бик тиз китеп бардылар. Койма аръягында тырылдап мотоцикл кабынды. Вера Зиновьевна бу тавышны ишетмәде. Ул һушсыз иде...

*1991.*



## Миргазиян Юныс

# ГАСАБИЛЫ УЙЛАР

Француз психологы һәм философы Люсьен Леви-Брюльнең фәнни ачышы белән танышкач, аңладым. Армия хезмәтен, хәрбилекне, чин-дәрәҗәне, үтереш (сугыш) эшендә геройлык күрсәтүне без шул Леви-Брюль ачкан «күмәк күзаллау», «мифологик караш», «параллель мантыйк», ниһаять, ике җәпле әхлак кануннарына таянып бәялибез. Хәер, «бәялибез» түгел, рәсми пропаганда ничек әйтсә, без шуны попугай шикелле кабатлыйбыз.

Корея. Вьетнам. Әфган сугышы. Куба. Никарагуа. Ангола. Карабах. Днестр буендагы һәм Абхазиядәге бәрелешләр. Тбилисидә, Бакуда, Вильнюста коелган каннар. Ниһаять, тарихтагы иң кыргый, иң вәхши һәм канлы геноцид — Ичкерияне тар-мар итү. Кан кою гына түгел, туктаусыз героизм эшләнеп торды бу сугышларның барысында да. Бу геройлыкларны Ватан сугышы геройлары белән чагыштырып буламы? Нигә булмый? Нәкъ Рейхстаг кебек үк Грозныйны хәрабәгә әйләндергәч, диварына Рәсәйнең «изге» флагын кадап куйдылар. Горурландыкмы без бу эшкә? Нигә горурланмадык? Сугышның нишләп әле мәгънәсе үзгәрде? Соң бит ватан сугышында солдат аналары малайларын коткарырга фронтка китмәделәр. Нишләп соң Ватан сугышында үлгән ирләре өчен тол солдаткалар хөкүмәт, хакимият тарафына канлы күз яшьләренә сугарылган ләгънәтләрен җибәрмиләр?

Сугыш. Геройлык. Җиңү. Җиңелү. Ватан өчен! Ельцин өчен! Әгәр мин күрше республикага барып, аның кешеләрен үтереп, йортларын җимереп йөрсәм, суд ясап, мине атарлар, иде, мөгаен. Әгәр нәкъ шул эшне генерал Павел Грачев приказына таянып эшләсәм, минем түшемә орден тагалар, сугыш ветераны ясап, гомер буе өстенлекләр белән файдалану мөмкинлеге бирәләр. Менә шушы парадоксларны аңлау өчен, кабат әйтим әле, Леви-Брюль ачкан фәнни законнарны мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнергә кирәк. Мәктәпләрдә өйрәнелә башлаганчы, беренче чиратта, без язучылар бу тәгълиматне «бисмилла» дәрәҗәсендә үзләштерергә тиешбез.

Сайлау вакытында үзен президентлыкка кандидат итеп күрсәткәч, Бил Клинтонның Вьетнам сугышына катнашудан баш тартуын фаш иттеләр. АКШ сайлаучылары сугыштан баш тартуны җинаятькә санамадылар. Бил Клинтон президентлыкка сайланды. Рәсәй чынбарлыгы сугышка катнашудан баш тартучыны

нишләтер иде икән? Аңлашыла. Ә менә мөстәкыйль дәүләтебез Татарстан? Без бит егетләребезне чеченнәрне үтерергә җибәрүдән коткара алмадык. Ә президент сайлаганда сугышка катнашудан баш тарткан кандидат очраса, без нишләр идек икән? Сорау өстенә сорау. Алар иксез-чиксез. Заманасы шундый...

Икенче бөтендөнья сугышы турында йөз меңләгән китап язылган. Көнбатыш әдәбиятында сугышка катнашучыларны Une Generahuon Perdue — «юкка чыгарылган буын» дип атап йөртәләр. Бу сүзнең килеп чыгуын Эрнест Хемингуэй болай аңлата:

«Хужа аңа әйтә: Сез барыгыз да generation perdue!

— Менә кемнәр сез. Барыгыз да шундый! — диде мисс Стайн. — Сугышта булган бөтен яшьләр дә шундый. Сез — юкка чыгарылган буын...» (Э. Хемингуэй. «Бәйрәм һәрчак синең белән»).

Көнбатыш язучыларының әсәрләрендә сугышка катнашу — кеше язмышының иң мәҗбүри, иң фаҗигале, кешелек вазифасына санап бетергесез зыяннар китерүче гамәл итеп күрсәтелә. Инде күптәннән, унсигезенче гасырдан ук диярлек көнбатыш әдәбияты сугышны кешелек дөньясында сакланып калган кыргыйлык атавизмы итеп күрсәтә. Дөрес, бүгенге көндә шул ук Көнбатышта әзерләнгән кеше үтерүгә мәдхия җырлаучы боевиклар безнең телеэкраннарны каплап китте. Мәкаләдә сүз чын әдәбият, классика турында бара.

Эрнест Хемингуэй, Эрих Мария Ремарк, Джон Херси, бигрәк тә алман язучылары, шулар арасында Генрих Бёлль, Вольфганг Кеппен, Герман Гессе — шушы язучыларның әсәрләрен укыган кеше белә, искиткеч көчле нәфрәт ята аларның эчтәлегендә. Сугышны оештыручыларга (оештыру һәр очракта хакимият, сәясәтчеләр кулында) җан тетрәткеч ләгънәт яңгырый. Хәтерли торгансыздыр, Генрих Бёлльнең «Унынчы яртыдагы бильярд» дигән әсәрендә сугыш Алмания җиренә кергәч, нимес капитаны чигенгәндә элеккеге сугышларда җиңүчеләргә багышлап куелган үз иленең һәйкәлләрен шартлатып, җимереп бара. Сугышта җиңү — иң зур җинаять... яңа сугыш иске җиңүдән башланып китә, дип аңлата капитан.

Рәсәй империясе корал көче, кан кою, яулап алу юлы аша барлыкка килде. Шуңа күрә ул коралга, кан коюга, сугышка таянып кына яши ала. Чөнки бу империянең идарә итү ысулы, хәтта яшәү ысулы хәрбилеккә, милитар көчкә таянып эш итүгә көйләнгән. Рәсәй шартларында демократиянең, базар икътисадының урнаша алмавы да шуңа бәйле. Хәрбилек, көчкә, кан коюга, куркытуга таянып эш итү идарә системасына гына түгел, бу империядәге яшәешкә, анда яшәүче кешеләрнең психологияләренә, хәтта канына үтеп кергән. Менә шушы шартларда, билгеле, урыс совет әдәбияты һәм Рәсәйдә яшәүче «вак халыклар» (урысча — «инородецлар») әдәбияты Ватан сугышындагы тоташ героизмны күкләргә чөеп мактауга багышланган иде. Сугышка мәдхия җырлаган китаплар күп миллионлы тиражлар белән чыгып китапханә киштәләрен тутырдылар.

Дөрес, сугыш турында тоташ мәдхиядән тыш К. Воробьев, В. Астафьев шикелле язучыларның әсәрләре дә бар иде. Киң катлам укучы аларның барлыгын белә алмады. Ә инде үзгәртеп кору якынлашкан елларда В. Кондратьев һәм А. Гыйннәтуллин шикелле сугыш турында дөреслекне язган әдипләрне «окоп хакыйкатен» куертучылар дип тәнкыйтьләделәр.

Татар әдәбиятына сугыш Г. Әпсәләмов әсәрләре аша килеп керде. Ә инде Ш. Рәкыйпов һәм С. Шакир әсәрләрендәге сугыш асылда фронтовиклар арасыннан татар геройларын эзләп табуга, «җиңүгә без, татарлар да зур өлеш керттек»не раслауга багышланган иде. Рәсми пропаганда җиңүне «победа русского оружия» дип аңлатканга күрә, үзәктә андый әсәрләргә әһәмият биреп торучы булмады диярлек. Гомумән, җиңүгә багышланган Кремль мәҗлесендә «бөек генералиссимус»: «Пьем за русский народ, первый среди равных» дип тост күтәргәннән соң, бәхәс кайсы халыкның икенче, кайсыларның өченче, егерменче, кырыгынчы урында булулары турында барды.

Әле менә узган елда Г. Владимовның Ватан сугышына багышланган «Генерал һәм аның армиясе» дигән әсәре дөнья күрде. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң башланган эзләнүләрдән, икенче бөтендөнья сугышыннан соң кешелек дөньясындагы һәм адәми затлар психологиясендәге кара көчләрнең каян килеп чыгуын аңлаткан философия — экзистенциализм барлыкка килде. Владимовның әсәрендә гаҗәп кыйммәтле, сугышның нәрсә икәнлеген аңларга ярдәм итәрлек тирән фикерләр бар. Моңа кадәр сугышны шул дәрәҗәдә тирәннән анализлаган әсәр барлыгын хәтерләмим мин.

Ватан сугышы турында язганда без сугышны 1945 елның 9 маенда тәмамланды дип исбатлыйбыз. Чынбарлыкта исә, СССР 9 майдан җиң сызганып яңа сугышка әзерләнә башлады. Әзерлек эше белән генә канәгатьләнмичә, сугыш утын җир шарының төрле төбәкләренә таратырга тотынды. Корея һәм Вьетнам сугышы, Куба һәм Никарагуа, Хәбәшстан һәм Сомали, Мисыр һәм Израил, Конго һәм Ангола, Әфганстан һәм Гыйрак, Иран һәм Курдстан, Босния һәм Герцоговина — аларның барысын да санап бетерерлекмени! Һәм шул сугышларның барысында да СССР да (хәзер инде Рәсәйдә) ясаган корал, шушы илнең империячел сәясәтенең һәм хәрби инструкторларының турыдан туры катнашуы шартларында алып барылды.

Ниһаять, сугыш бумеранг рәвешендә әйләнеп, СССР ның үзенә кайтты. Чечнядан соң сугышның кайсы төбәктә кабынуы безгә билгеле түгел...

* * *

Ялгышмасам, Ключевский язган Рәсәй тарихының дүртенче томында бу турыда шактый тулы мәгълүматләр бирелгән. Сугышка катнашучыларга ганимәт өлеше чыгару, каланы алганнан соң өч көнгә аны солдатлар кулына биреп тору (талау, хатын-кызны көчләү өчен), исән калып сугыштан кайтучыларга бик күп өстенлекләр бирү, тол калган солдаткаларны салымнан коткару, дәүләт тарафыннан аларга ярдәм күрсәтү Явыз Иванның бабасы Иван-III чорында ук җайга салына. Сугыш аны оештыручыларга гына түгел, аңа катнашучыларга да файдалы булырга тиеш. Матди файдадан тыш сугышка катнашучыга әхлаки яктан да өстенлекләр оештырырга кирәк. Күршеләренең җирләрен яулап алу бәрәбаренә әкренләп байлык керә башлый. Шуңа өстәп, сугыш кирәк-ярагына дип Рәсәй үз халкын да төрле салымнар белән аяусыз талап тора. Көч туплауны, корал әзерләүне, соңгы чиктә, җиңүне шушы юл белән оештыра баралар.

Революциядән соң дәреслекләрдә «Рәсәй — халыклар төрмәсе» дип язган чакларда, Шамилны азатлык өчен көрәшкән халык герое итеп, Суворовны Пугачев явын бастырган өчен Әби патшаның сатрапы, патша хөкүмәтенең яулап алуларын колониаль сәясәт дип аңлаткан чорда бер мәлне шовинистик пропаганда туктала торды. Кайсы санда икәнлеген хәтерләмим, 1939 елны «Правда» газетасында «Мы не иваны не помнящие родства» дип башланган баш мәкалә басылып чыкты. Мәкаләдә Илья Муромец, Добрыня Никитич һәм Алеша Поповичны мыскыллап, шуларга каршы сатирик поэма язган Демьян Бедныйны пыр туздырып тәнкыйть белән тукмадылар. Үзәк комитет газетасының баш мәкаләсендә совет чорында беренче тапкыр патша чорындагы җиңүләрне күккә чөеп мактау, патша яугирләренең батырлыкларын, аларның җиңүләрен яшь буынны тәрбияләүдә үрнәк итеп куярга кирәк дигән рәсми фикер әйтелде. Моңа кадәр бары тик гражданнар сугышы геройлары гына тәрбия эшендә үрнәк итеп кулланыла иде.

Ватан сугышы җиңү белән тәмамлангач, сугышта күрсәтелгән геройлыкларны күкләргә чөеп зурлау, батырларча сугышуны иң изге, иң бөек сыйфат итеп күрсәтү пропаганда эшенең үзәк конвейрына куелып, әдәбият, көндәлек матбугат, кино, радио, телевидение аша мул сулы дәрья булып җәмгыять өстенә ага башлады. Сугыш ветеранын да онытмадылар. Син ватанны фашизмнан саклап калдың, кан койдың, авырлыклар кичердең, без сине беркайчан да онытмабыз, һәрдаим ихтирам итәбез, пенсияне сиңа башкалардан күбрәк түлибез, салымнарны кичерәйтеп салабыз һ. б., һ. б. өстенлекләр белән тәэмин итеп торабыз, дип туктаусыз тукып тордылар.

Чын сугыш ветераннары арасында комсызлар сирәк очрый. Алар, чыннан да, әздән дә канәгать. Аларның күбесе өстенлекләр бирүнең төп сәбәбен аңлап та бетермиләр. Чынбарлыкта исә, ветераннарга биргән привилегиянең төп максаты — яшь буынны сугышка ихтирам белән карарга өйрәтеп тәрбияләү өчен. Әнә, сугышка катнашучылар нинди почетта, әгәр киләчәктә сугышка барсагыз, сезгә дә шундый почет һәм өстенлекләр биреләчәк. Хакимиятнең төп максаты менә шуннан гыйбарәт.

Девальвация башлангач, халык кибеттәге товарларны кырып-себереп алырга тотынды. Бигрәк тә азык-төлекне. Көнбагыш маен алу өчен чиратта торабыз. Сатучы кисәтте:

— Юкка көтмәгез, мичкәдә ике кешегә җитәрлек кенә май калды.

Ике өлешнең берсен пенсионер карт алып өлгерде. Соңгы порция инде күптән алтмыштан узган карчыкка тиешле иде. Шул мәлдә бер таза гына ир бидонын кран астына тыгып өлгерде:

— Минем чиратсыз алырга хакым бар. Мин — сугыш ветераны,— диде ул тавыш куптаручыларга. Өлешеннән колак каккан карчык еларга тотынды:

— Зинһар өчен... Мин үзем ветеран түгел, ләкин... иремне сугышта үтерделәр... Зинһар өчен!

— Минем чиратсыз алырга хакым бар. Давай, тизрәк агыз! — диде ветеран сатучыны ашыктырып. Шул чакта карчыкның артында чиратта торучы бер яшь хатын капыл гына кизәнде дә бидоны белән ветеранның маңгаена тондырды.

Милиционер килеп аралаганчы яшь хатын да, ветеран да, аларны аерырга тырышучылар да канга батып өлгергәннәр иде инде. «Җинаятьчеләр»не милиционер алып киткәч тә ызгыш, кычкырыш шактый озак дәвам итте. Бәрелешне башлап җибәргән шул ике бәндәнең кайсы гаепле икәнлеген ачыклауны укучыга тапшырып, икенче манзарага күчәм.

Чәчтарашханәдә чират көтеп утырабыз. Янымда сугыш ветераны. Кулында бушлай чәч алдырыр өчен муниципалитет биргән талон. Картлач шундый канәгать:

— Кер юдырткан, кием чистарткан өчен түләргә дә талоннар бирделәр,— дип безгә күрсәтеп куанып утыра. Ниһаять, ветеранның чираты җитте. Аны ашык-пошык кына «эшкәртеп» алдылар. Мескеннең чәчен әйтерсең эт талаган. Без парикмахер кызны тирги башладык.

— Талон өләшенгәннән соң чәч алдыру хакы ике тапкыр күтәрелеп өлгерде,— дип аклана чибәр кыз.— Миңа әле сез рәхмәт әйтергә тиеш. Башкалар талон тотып килгәннәрне креслога утыртмыйлар да.

Ә ветеран чыннан да бәхетле иде. Прическасы бозылуы аның кәефен һич тә төшерә алмады. Шул чакта мин Италиянең Савона портында очраткан Америка ветеранын исемә төшердем. Ул «Юлий Цезарь» исемле океан лайнерына утырып үзенең сугышып йөргән җирләрен карарга килгән иде. Лайнерга бушлай утырудан файдаланып, янки катафалк зурлыгындагы «понтиак»ка карчыгын, ике кызын да утыртып алып килгән. Бушлай өләшеп йөрер өчен ветеран машинасының багажнигына АКШ флагы рәсеме төшерелгән водолазкалар һәм башка вак-төяк сувенирлар төягән. Ветеран исә, АКШ хөкүмәтен, президент Рейганны эт итеп сүгә:

— Сукины дети,— ди янки.— Оныгымның Италияне күрәсе килә иде. Оныгың синең гаиләң әгъзасы түгел, түләүсез утырта алмыйбыз диләр, сукины дети!

АКШ ветераны шундый бәхетсез, хакимияткә шундый ачулы, өстенлеккә канәгать түгел иде...

* * *

Сугыш беткәнгә майда илле ел тулды. Ватан сугышына катнашучылар көннән-көн азая, ә ветераннар саны бер дә азаймаган шикелле. Чечен сугышында кан коючыларга да «ветеран» кенәгәсе бирерләр. Чечен сугышында «Рәсәй герое» дәрәҗәсенә ирешүчеләр саны инде берничә дистәгә җитте шикелле. 1993 елның 4 октябрендә Ак йортны штурмлаган өчен элеккеге Эчке эшләр министры генерал Ерингә «Рәсәй герое» дигән исем биреп, түшенә алтын йолдыз тактылар.

Бюрократик системаның мәңгелектән килгән һәм киләчәктә дә мәңге хөкем итәчәк бер корыч кануны бар: әгәр синең кулыңда мөһер суккан кәгазең булмаса, Александр Матросов каһарманлыгын кырык тапкыр кабатлап, күкрәгең белән амбразура капла, син ветеран да түгел, участник та түгел. Разбой сал, маңгаеңны ташка бәр, ачлык игълан ит — барыбер синең сугышка катнашуыңа ышанмыйлар, әгәр кулыңда мөһер сугылган кәгазең булмаса. Шул кәгазьне алу законлы булсын өчен югарыдан төшерелгән карар, яисә нинди дә булса әмер булу шарт.

Мәсәлән, мин утыз елга якын чит илләргә корал ташыдым. Канлы сугыш барган «кайнар нокталарга». Портка кача-поса гына төнлә кереп туктыйсың, коралларны төяп бетергәч, шулай ук, кача-поса чыгып китәсең дә, суга салган шикелле югаласың. Сугыш барган җирдә корабтан корал бушатканда өстеңә бомба да ява, «кайнар нокта»га якынлашканда каршы якның хәрби кораблары сиңа орудие көпшәләрен төбәп озатып баралар. Көпшәнең куркыныч кара тишегеннән снарядның кайчан очып чыгасын, кайчан синең палубаңны айкап ташлаячагын берничек тә алдан белә алмыйсың. Тәнең чымырдап, йөрәгең ләп-леп итеп

типкәнен тыңлап, көтәсең, көтәсең, көтәсең... Ничәмә еллар мин шул газапларны кичердем, ә сугыш барган җиргә корал ташучыларны «катнашучыга» санарга дигән приказ булмаганлыктан, без шушы көнгә кадәр «катнашмаучылар» булып саналып йөрибез. Аның каравы, Ватан сугышы елларында мин сугышчан заданиега очмасам да «катнашучы» саналам. Кораллы көчләр министрының приказы минем ветеранга санарга куша.

Рәсәйдәге «закон как дышло» шартларында ветеранлык кәгазен эләктерүне максат итеп куйган кешегә шактый гына мөмкинлекләр бар. Мәсәлән, минем дустымның әнисе сугыш вакытында Дәүләт оборона комитетында машинистка булып эшләгән. Фронт Мәскәүгә якынлашканда аны Куйбышевка күчергәннәр. Фронт ерагайгач, тагын Мәскәүгә кайткан. Карчык — сугыш ветераны. Документлары — полный ажур.

Николай Иванович — артист. Пенсиягә чыккач сценарийлар яза башлаган. Без аның белән иҗат йортында таныштык. Заманында уналты яшьлек Николаша театр студиясендә артистлыкка укып йөргән. Фронт Мәскәүгә якынлашкач, студия шәкертләре күмәк рәвештә военкоматка барып, ополчениегә язылып кайтканнар. Берничә көннән театрны эвакуациягә озатканнар. Баш режиссер берничә шәкертне, шул исәптән, Николайны да тылга алып киткән. Венкомат исемлегендә Николайның фамилиясе калган һәм шул исемлек нигезендә Николай Ивановичка ветеран билеты язып биргәннәр.

Сугыш шартларында да бит әле «катнашу»ның төрлесе бар. Мәсәлән, фашистлар зур тизлек белән Мәскәүгә якынлашып килгәч, безнең гаскәрләр чигенгән чакта НКВД солдатларыннан төзелгән заградотрядлар эшкә керештеләр. Бу турыда шактый күп мәгълүмат тупланган. Әйтик, батальон «Н» биеклегеннән дошманны куып җибәреп, шунда позиция тотарга приказ алды. Батальон атакага ташланды. Каршы яктан фашистлар аталар, арттан атакага баручыларга автоматларын төзәп заградотряд сугышчылары килә. Заградотрядта хезмәт итүчеләргә дә ветеран дигән изге исемне бирделәр. Бу эшкә укучы ничек карый икән?

Минем беркайчан да сугыш татымаган илләрне, сугыш күрмәгән халыкларны күзәтеп йөргәнем бар. Көнбатыш әдәбияты сугышта катнашучыларны «юкка чыгарылган» буын дип дөрес бәяли. Сугыш ул ветеранның тәнендә черки тешләгән кадәр генә эз калдырмаса да, аның йөрәгендә, психологиясендә каты җәрәхәт үлгәнче яши. Үлем белән күзгә-күз очрашу беркайчан да кешедә уңай тәэсир калдырмый. Сугыш булган илдә аңа катнашмаучылар да йә әтисен, йә абыйсын, яисә башка бер туганын югалткан. Шуңа өстәп, сугыш алып килгән кайгы-хәсрәтле, канга буялган атмосфера адәм баласының табигатен агулаган. Менә шул агу буыннан-буынга тапшырылып, яшәешне гарипләндереп тора. Сугыш иле — кайгы-хәсрәт иле, җәбер, гаделсезлек иле...

* * *

Ярты гасыр үтте бит. Инде ул сугыш онытыла башлаган иде. Инде без сугышның чиркандыргыч хатирәләрен тарих тулысынча йотып бетерер дигән өмет белән яши башлаган идек. Кинәт, сугышны телевизор экраныннан күрдек. Танкта янып күмергә әйләнгән танкистларны, җирдә аунап яткан аяк-кулларны, череп, сасып яткан мәетләрне һәм җир белән тигезләнгән Грозный шәһәрен. 1995 елның 19 гыйнварында Кремльдән президент Ельцин безне кисәтте: «Пусть трагедия, пережитая Россией и чеченским народом, послужит уроком для народов и политиков». Тукта-тукта! Бу сүзләрнең мәгънәсен дикъкать белән анализлап карыйк әле. Бу бит турыдан-туры янау, куркыту. Әгәр безнең диктатка буйсынырга теләмичә, мөстәкыйльлеккә, иреккә омтылырга телисез икән, сезне дә Чечня фаҗигасы көтә дигән сүз бит бу сәясәт теленнән кеше теленә тәрҗемә иткәндә. Кемгә карата, кайсы халыкларга, нинди сәясәтчеләргә юнәлгән бу янау? Ә бит бу сүзләрне әле күптән түгел генә «Мөстәкыйльлекне күпме тотасыгыз шулкадәр алыгыз!» — дип вәгъдә биргән президент әйтә. Димәк, Рәсәй шартларында беркемгә дә, шул исәптән президентның үзенә дә, ышанырга ярамый. Димәк, Рәсәй чынбарлыгында бер генә бәхәсне дә кан коймыйча, бомбага тотмыйча, танкларга таптатмыйча хәл итеп булмый? Хәтта илнең язмышын хәл итәргә халык тарафыннан сайланган парламентны да Ак йортка бикләп туп атып кына президент үз җаена бора алды.

Ватан сугышына бәйле бер генә вакыйганы да Чечнядәге кан коюдан аерып булмый башлады. Чеченнәр дә бит Ватан сугышында СССРны (шулай атасак та асылда ул барыбер шул ук патша заманындагы Рәсәй империясе иде инде)

коткару өчен кан койдылар. Кавказлыга хас батырлык һәм кыюлык белән сугыштылар алар. Дудаевны атом бомбалары йөртә торган стратегик бомбардировщиклар дивизиясенең командиры, армиядәге иң җаваплы, иң зур тәгәллек, кыюлык һәм акыл таләп иткән, турыдан-туры баш командующийга гына буйсына торган урынга билгеләү очраклы хәл түгел иде. Чечен — нинди генә очракта да әйткән сүзен тота, биргән вәгъдәсен үти. Икейөзле була белмәү аларның каннарында, күзәнәкләрендә. Тугрылыгы белән фронтта кан коеп йөргән чечен фронтовикларның аналарын, балаларын, хатыннарын 1944 елны тимер юл станциясенә куып китереп хайван ташый торган вагоннарга бикләделәр дә туган туфракларыннан сөрделәр.

Авыруларны, гарипләрне сарайларга бикләп керосин сибеп яндырдылар. Азатлык сөюче тау халкы — чеченнәрнең алтмыш проценты сөргендә үлде. 50 нче елларда басылып чыккан тарих китапларында, сүзлекләрдә «чечен», «балкар», «кырым татары» дигән сүз бөтенләй юк иде. Димәк, геноцидның максаты аларны тулысынча юкка чыгару булган. Бу хәшәрәтлек, бу ерткычлык чеченнәр тарафыннан җавапсыз калырга тиеш түгел иде. Ярты гасыр аларның каннарында нәфрәт, үч акты. Чечен сугышы 1994 елның 11 декабрендә башланды дип уйлаган кеше бик ялгыша. Чечен сугышы аларны ватаннарыннан куган көнне 1944 елның 23 февралендә башланды. Һәм аны чеченнәр түгел, геноцидны оештыручы Берия палачлары башлады. Ул чакта карт-корының, хатын-кызның, бала-чаганың кулында коралы юк иде. Палачларның кораллы сугышына каршы чеченнәр бары тик нәфрәт кенә туплый алдылар. Нәфрәт һәм өмет.

Ниһаять, геноцидтан да әшәке, икейөзле, ымсындыргыч ялган: президент Ельцин татарларга «мөстәкыйльлекне теләгән кадәр алыгыз!» — дип вәгъдә бирә. Билгеле, бу вәгъдә бары тик татарларга гына бирелмәгән иде. Бу вәгъдәгә бирген вәгъдәләрен бозарга өйрәнмәгән чечен халкы ихлас күңелдән ышанды һәм шундук мөстәкыйльлекне хәл итәргә кереште.

Казан татарларына геноцид оештырылмады дип бары тик дөм томана кеше генә әйтә ала. Сугыш беткәч уналты-унсигез яшьлек кызларны, буыннары да катып бетмәгән яшь егетләрне кая озаттылар? Нәкъ шул яшьтәге үсмерләрне Украинадан һәм башка оккупациягә эләккән төбәкләрдән сугыш вакытында Алманиягә озату турында дистәләгән томлы китаплар язылган. Ә бит миллионлаган тонна кара алтын бәреп чыгып торган җирдә ач, хәерчелектә яшәгән татар үсмерләре ерак шахталарда, урман кисүдә, торф чыгаруда, бәлки тамагыбыз туяр, өстебезгә кием рәтли алырбыз дип, татарга хас самими беркатлылык белән өметләнеп киттеләр. Татарстан җиренә килгән эшелоннарга Валентин Распутин «архаровцы» дип атаган әтрәк-әләм тәялгән иде. Революция чорына багышланган берничә том тарих китабы язган кәҗә-сакал Солженицын телевизор экраныннан: «Татарстанда татарлар бары тик 42 генә процент, аларның бернинди республика төзергә хаклары юк, кичекмәстән губерния төзи башларга вакыт», дип демагогия чәчә.

Бу бүлекне мин юкка гына «патриотлык хисе» дип атамадым. Безгә, яслегә йөри башлаганнан бирле, тукып торылган «совет патриотлыгы һәм пролетар интернационаллыгы» югарыда сурәтләнгән вакыйгаларга катнашып кереп урнаша торды безнең карашыбызга. Һәм, чыннан да, мәкаләнең башында искә алынган Леви-Брюльнең фәнни ачышын кулланмыйча берничек тә очына чыгып булмый. Төньяк Кавказ халыкларын, кырым татарларын кырып бетерү. Иң тырыш, иң эшчән социаль катламны «кулак» атлы мәсхәрәле мөһер сугып кырып ташлау. Белемле, алдынгы карашлы, мөстәкыйль фикер йөртә белгән интеллигенцияне атып юкка чыгару. Боларның барысы да Сталин эше. Ә гади халык «бөек юлбашчыны» сабыйларча сагына. Сагына гына түгел, «әгәр ул исән булса,— ди гомер буе бюрократларга канын эчертеп, аларның тамакларын туйдырып торган мескен халык,— без әле бүгенге көндә дә бәхетле яшәр идек». Сталинны сагынучылар җыелган җирдә демократияне яклап: «Борынгы греклар заманында, Ренессанс чорында, бүгенге Япониядә, Сингапурда, Швейцариядә рәхәт, мул көнкүреш, кешенең хокукларын яклау бары тик демократия шартларында гына мөмкинлек тапты»,— дип каршы әйтә күрмәгез тагын. Рәсәй чынбарлыгында «демократия» битлеген кичәге партократлар, ришвәтчеләр, мафиозилар киделәр, «Чит илләрнең күбесендә халык бай, тыныч һәм иректә яши»не гади халык кичәге пропагандадан аерып ала алмый. Аның ышанмаска хакы бар. Халык дөрес эшли. Беркемгә ышанмау — бүгенге ялганнардан саклану чарасы.

«Күмәк күзаллау», «мифологик караш», «параллель мантыйк» безнең һәммәбездә тулып ята. «Менә мин аңлыйм, ә алар — томаналар, аңламыйлар»,— дип әйтергә беребезнең дә батырлыгыбыз җитми.

* * *

Инде ничәмә гасыр Рәсәйнең төп кәсебе — миллионлаган гаскәр асрау. Кораллы гаскәрнең төп вазифасы — сугышу. Сугышмыйча торган армия әкренләп үзенең гайрәтен, батырлыгын югалта. Белмим, күршеләрнең җирләрен басып алып, җирен зурайтуны туктаусыз кайгыртып тормаса, Рәсәй империясе яши алыр идеме икән?

Империя шартларында ирләр затының күпчелеге казармада тәрбия алып тора. Буыннан-буынга, бабадан атага, атадан балага казарма гадәтләре, бүгенге көндә «дедовщина» дип аталган көчне законнан һәм әхлакъ кануннарыннан өстен кую гадәте җәмгыятьтә чиктән тыш киң таралган, бу гадәт рәсәйлеләрнең психологиясенә сеңеп беткән. Бәлки һәр чорга хас үзенең «дедовщинасы» булгандыр? Бу проблеманы тарихи социологларга махсус өйрәнергә кирәк иде.

Сугыш чорында «дедовщина» менә нидирәк иде.

1944 елның көзе. Татарстанның барлык районнарыннан җыйган призывникларны Бөгелмәдә бер мәктәпнең спорт залына китереп тутырдылар. Әллә нинди төшенкелек. Күп малайлар өчен бу беренче тапкыр еракта, өй җылысыннан, әнкә кайгыртуыннан читтә, тома билгесезлектә калу иде. Китәсе көнне барысы да, шул исәптән, гомерендә авызына бер тамчы аракы алмаган малайлар да бик әшәке эчкәннәр. Үтереп баш авырта. Күңел болгана. Биштәрле капчыкларыбызны баш астына салып, юылмаган, себерелмәгән пычрак идәнгә яттык. Күзгә йокы керми. Кемдер ут яндырды. Бер төркем хулиганнар өерелеп ишектән залга ургылдылар:

— Татарва! Потрусите сидора! Шмонь устраивать будем! Самогон и водяру выставьте сразу — все равно найдем!

Бу сүзләрне ул чорда бик тә модный саналган тезгә җитеп торган пальто «московка» кигән җәнлекнекенә охшашлы сирәк, нечкә тешле бәндә кычкырды. Безнең капчыкларны чишеп самогон эзләргә тотындылар. Каклаган иттән, газиз баласына пешереп балга катырган баурсактан да баш тартмыйлар иде бандитлар. Кайбер капчыкларны тибеп очыралар. Идәнгә сохари коелды. Армиягә китәр алдыннан махсус бәйләнгән өч бармаклы бияләйләр идәндә аунап ята.

Без, иллегә якын, әле унҗидене тутырып та бетермәгән таза егетләр бандитлар чыгып киткәч шыңшый башладык: «Военкоматка белгертергә кирәк...». «Жалоба язарга...». «Аларның безне таларга хаклары юк иде». Шыңшу, зарлану, мескенләнү китте. Миңа әле дә оят. Татар язмышы бу. Татар куркаклыгы. Нәкъ безнеңчә — оеша, берләшә белмәү. Безнең каннарга кереп оялаган коллык бу.

Икенче төнне безне эшелонга төйи башладылар. Ни күзебез белән күрик, теге бандитлар безнең белән Кызыл Армия сафына баралар. Паханның фамилиясен дә ачыкладык: Славка Афанасьев, Бөгелмә горсоветы рәисенең сөекле малае...

Белмим, шундый инструкция булгандыр инде. Сугыш елларында гаскәрләрне төнлә озаталар, караңгыда китереп бушаталар иде. Бәлки бары тик безгә генә шулай туры килгәндер? Пенза өлкәсендәге Кузнецк станциясенә дә төн урталарында китереп бушаттылар. Сафка тезеп шәһәр эченә алып кердfestivalләр дә кызыл кирпечтән салган мунчага китереп тутырдылар. Мунчага керер алдыннан безне спекулянтлар чорнап алды: «Сатыгыз, барыбер кире кайтарып бирмиләр...». Шунысы кызык, бер генә авыл малае да киемен сатмады. Шәһәрдән алынганнар мунча эченә шәрә калып диярлек керделәр.

Киемнәрне салып ташлау белән чәчне кырып ыргыталар, култык асларын, гаурәт тирәсен... Шуннан соң гына кулга «шайка» (тас) тоттыралар һәм туңып үләрлек суык юыну бүлмәсенә куып кертәләр. Шайкадагы су да боздай салкын. Юынып чыгуга — хәрби кием.

Шинель минем тезәмә дә җитми иде. Гимнастерка Халхин-Гол сугышы чорында тегелгән — кайтарма якалы. Мине шунысы тетрәндерде, әле шактый яңа гимнастерканың уң як күкрәк турында бер ямаулык, икенчесе — сул як җилкә турында. Алгы яктагы ямау кечкенә генә, арка ягындагысы уч хәтле. Гимнастерканың беренче (бәлки икенче, өченче) хуҗасы пуляларны, һичшиксез, атакага барганда алган.

Сафка тезә башлагач күреп алдым — бер бәләкәй малайның шиненең итәге патша хатыннарының унсигезенче гасырда киеп йөргән парадный күлмәкләре шикелле, җирдә сөйрәлеп бара. Командирлар күреп алганчы без тиз генә алмаштык. Мукшы малае иде, фамилиясе әле дә хәтеремдә — Трункин. Ул миңа хезмәт итә башлагач каяндыр «Дон Кихот»ны табып бирде. Мин аңа шушы көнгә кадәр рәхмәт укыйм.

Сафка тезеп, шәһәрдән алып чыгып киттеләр. Суык. Шыксызлык. Кием тәнгә ят. Аякны кирза итек кыса. Минем гомеремдә ыштыр ураганым юк иде. Хәтта

ат жигеп сабан сөргәндә дә оекбаш киеп йөрдем, сабан артыннан буразнага батып барганда ыштыр оекбаштан күп мәртәбә кулайрак булса да.

Кар баскан калкулыклар арасындагы бер мәйданга китереп туктаттылар да роталарга бүләргә тотындылар. Калкып торган кар өемнәре землянкалар булып чыкты. Һәр ротага бер землянка. Эчкә алып кереп урнаштыра башладылар. «Нары» аталган ике катлы тоташ землянканың буеннан-буена эшләнгән сәкеләр. Безне шунда урнаштырдылар. Одеялларга бирка тегеп, шинельләребезнең якалары астына шәмәхә каләм белән фамилияләребезне яздырткач, отбой уйнадылар.

Фронттан яраланып кайтучылар миңа хәрби киемгә күчкәндә ничек кенә булса да оекбашны саклап калырга киңәш биргәннәр иде. Өйдән алып килгән әйберләрне хуҗасында калдырмас өчен бик каты тоттылар. Оекбашның берсе эченә икенчесен тыгып мин мунчала ясадым. Һәм дөрес эшләгән булып чыктым. Одеял астына кереп яту белән арка өши, аяклар туңа башлады. Мин чалбар кесәсенә яшергән йон оекбашларны киеп, аякларымны майга тыккандай итеп җылыттым.

Иртә шатланганмын икән. Бер карсак буйлы, ефрейтор одеялларны ачып новобранецларның яту тәртипләрен тикшереп йөри иде. Оекбашны күрү белән торгызып юеш, салкын идәнгә бастырды. Тагын шундый өч-дүрт «җинаятьче» фаш ителде, арада — миңа үзенең кавалеристлар өчен махсус тегелгән озын шинелен бүләк иткән Трункин да бар иде.

Ефрейтор безне сафка тезде. Ул үзенең фамилиясен дә әйтте — Мудрецов. Законы шундый — начальникның фамилиясе күк күкрәгән шикелле яңгырап, эченә боз салкыны өреп торырга тиеш. Мудрецов миңа (арадагы иң озын салагага) швабра тоттырды, Трункинга — чүпрәк, бер егеткә (ул Азат исемле Шөгер малае иде, фамилиясе онытылган) — чиләк. Идән юарга керештек. Юып бетергәч, Трункин ефрейторга барып әйтте. Мудрецов килде, кесәсеннән кульяулыгы чыгарып, идәнне ышкыды.

— Повторить!

Мин новобранецларны йокыдан уятканчы барыбер өлгереп булмас, дип аңлатырга теләп сөйли башлаган идем, ефрейтор минем урысча белмәвемне әләктереп алды.

— Йолдаш! Ясненько. Вдобавок — разгильдяй. Мы тебя заставим.

Сугыш елларында «йолдаш» («юлдаш»тан бозып үзгәртелгән) мәсхәрәле кушаматны урысча белмәгән, никадәр тырышсаң да солдатлыкка өйрәтеп булмаслык, гел кара эшкә, абруйны төшерә торган вазифага билгеләнә торган төрки халыклар вәкиленә тагалар иде. Чыннан да, иртәнге барлау вакытында икенче взводның беренче отделениесына һәртөрле өйрәнүләргә каршы килә, «философия» куерта (совет чорында армиядә генә түгел, бар җирдә диярлек «философия» сүзе мәсхәрәле яңгырый иде) торган разгильдяй «йолдаш» әләккән. Отделение минем кем икәнлегемне белеп, уяу булырга, минем кимчелекләремне бетерер өчен отделение командирына ярдәм итәргә тиеш.

Икенче төнне дә миннән идән юдырттылар, өченче төнне бәдрәф казырга кырык градуслы суыкка чыгарып подъемга кадәр тоттылар. Дүртенче төнне дә Мудрецов, кулыма көрәк тоттырып, бәдрәф чокыры казырга алып чыкты. Минем инде таш булып каткан туң җирне казу түгел, аягымны сөйрәп йөрер хәлем дә калмаган иде. Көндез без иртәдән кичкә кадәр стройда йөрергә өйрәнәбез, пластунча шуышабыз, атакага ташланып, штык белән салам карачкының эчәгеләрен айкыйбыз.

Мудрецов мине чокыр янына китереп бастырды.

— Прыгай!

Караңгы. Чокырның төбе күренми. Бармак кыймылдатырга да хәл юк. Өстәвенә, бәгырьләрне ачыттырып, тау булып кинәт өстемә өелгән гаделсезлек миңа карата Мудрецовның ерткычлык алымнары куллануы йөрәгемне тырный.

— Кому приказывают! Прыгай, йолдаш! — Мудрецов минем аркама китереп тондырды.

Башындагы бүреге очып карга төшкәч кенә мин нәрсә эшләгәнемне аңлап алдым. Үзеннән-үзе, аңсыз рәвештә килеп чыкты бу хәрәкәт. Мин, бар көчемне җыеп, ефрейторның бугазына көрәк йөзе белән селтәп тондырганмын икән. Отделение командирының башын иярга өлгерүе аның гомерен, минем штрафбатка эләгүемнән коткарып калды.

Көрәкне чокырга ыргыттым да землянкага киттем. Чишенүемне дә, башымны мендәргә төртүемне дә хәтерләмим. Подъем тавышын ишетеп сафка барып баскач, беренче сүз мине штрафбатка җибәрү турында булыр дип көтә баш-

ладым. Белмим, ефрейтор курыкты булса кирәк? Кансыз, аяусыз ерткыч кеше һәр очракта куркак була бит ул.

Белмим, бәлки армиядә «тәрбия» бирү тәртибе хәзер үзгәргәндер?

Оборона министры итеп Грачевны билгеләү шул Явыз Иван чорыннан бирле яшәп килгән «дедовщина» әле һаман да исәндер дигән фикергә китерә. Мин «курс молодого бойца» дип аталган академияне үткәндә өйрәтү, тәрбияләү методикасы шундый иде: бер-ике разгильдяй — «йолдаш»ны фаш итеп, башкаларны куркытыр өчен аларны туктаусыз җәберләп торырга, берничә «отличник»ны туктаусыз мактап, башкаларга үрнәк итеп тотарга.

«Яшь сугышчы» курсын үтеп, укырга керешкәч, «йолдаш»лыгымнан тыш остазлар Аллаһе Тәгалә тарафыннан мина шактый әйбәт хәтер бирелүен ачыкладылар. Белмим, ефрейтор Мудрецов әллә укчы-радистлыкка өйрәнеп фронтка эләгүдән курыкты, әллә инде аның миендәге сырлар бик аз булып чыкты — аны, курсантлыктан азат итеп, аэродром саклау ротасына күчерделәр.

Һәм, шуны әйтергә кирәк, «яшь сугышчы курсын» үткәндә ачка интегүләр (тикшерү вакытында интендатларның безгә дигән азык-төлекне «сул якка» озатып, үзләренә байлык туплаулары мәгълүм булды), Мудрецовның золымы инде күптән онытылды. Сугыш еллары искә төшкәндә минем күзалдыма дуслар килеп баса. Белмим, бәлки шундый авыр елларда, казармадагы рухи шыксызлык, андагы хайвани инстинкт өстенлек иткән чакларда гына барлыкка килә торгандыр тирән һәм мәңге онытылмаслык көчле дуслык хиседер ул.

Беренче тапкыр строй каршына чыгарып миңа благодарность белгерткән Бөгелмә малае помкомвзвод Толя Тигелевкә мин шушы көнгә кадәр рәхмәт укыйм. Ул ротада хезмәт итүчеләргә минем «йолдаш» түгел икәнлегемне һәм, киресенчә, киләчәктә хәрби белем үзләштерүдә зур уңышлыкларга ирешү мөмкинлегем барлыгын белгертте һәм мине Мудрецовтан йолып калды. Үземнең якташым Баулы егете Рифкәт Мөхәммәдиев искә төшә. Пенза егете Иван Плешаков, Казакъстаннан алынган Рәшит Агишев, Свияга егете Александр Касыймов — шулар искә төшкән чакта күңелгә дулкын булып җылы хис йөгерә дә дөньялар яктыра, күкрәк эчендә эчке бер рәхәтлек туа.

Мин еш кына «Урыс белән дус булсаң, балтаң билеңдә булсын» дигән тетрәндергеч татар әйтеменең каян килеп чыгуын, нинди шартларда тууын аңларга тырышам. Бу турыда минем ике версиям бар: беренчесе, Казан ханлыгының яуланган еллары һәм чукындырулар чоры; бу чорларда мәкальнең эчтәлеген кан коюда, талауда катнашкан һәр урыска карата кулланганнар булырга тиеш. Икенче версия, хакимияттә утыручы урысларга карата. Бусы әле бүгенге көндә дә актуаль яңгырый. Ельцин тирәсендәге сәясәтчеләр, Иван Рыбкиннар, Шумейколар безгә җай чыккан саен, әгәр без у.... ярхамкалла дип тормасагыз, сезне Чечня язмышы көтә дип кисәтеп, яисә киная ясап торалар.

* * *

Вакыт узган ватан сугышын тарих төпкеленә һаман тирәнрәк этәрә. Ул чор кешеләре отыры сирәгәя бара. Озакламый сугышка катнашучыларны күргәннәр дә фани дөньядагы эшләрен бетереп, мәңгелеккә кереп эреп бетәчәкләр.

Ватан сугышын, гомумән сугышның нәрсә икәнлеген аңлар өчен без көчебез житкән кадәр зирәклегебезне, акылны, ниһаять, кырып-себереп булса да инде бездә бетеп барган әхлакны бергә туплап Чечнядә нинди сугыш барганын, аны кемнәр башлаганын, шушы кан коюны кемгә файда, кемгә иксез-чиксез канлы һәлакәт алып килүен аңларга тиешбез. Чечен сугышында Рәсәйнең инде менә биш гасыр гамәлгә ашырып килгән милитаристик сәясәте пыяла линза аша үткән кояш нурларыдай куерып бер ноктага тупланган. Сугышсыз яши алмау. Катлаулы проблемаларны корал көче белән хәл итү.

Көнбатышта «юкка чыгарылган буын» дип сугышка катнашучыларны атыйлар. Мәсәлән, без, татарлар, туксан тугыз процентка «юкка чыгарылган», имгәтелгән халык. Ярый әле бу хакыйкатьне аңлап житкермибез, яисә бөтенләй аңларга теләмибез. Бу хәл нәрсәгәдер ышанырга, ниндидер өметләр багларга, кыскасы, алданып, үзебезгә үзебез күз буяп яшәргә ярдәм итә.

Быел мин кышны Баулыда үткәрдем. Беренче карауга рәхәт анда. Тыныч. Ашамлык Мәскәүдәгедән арзан. Кибетләрдә әйбер тулып ята. Ай саен ярминкә. Район культура сараена җыеп ай саен диярлек алдынгыларны бүләкләп торалар. Халык телендә «кулацкий поселок» дип аталган коттеджлар мәхәлләсе үсә.

Урамда карчыклар ватып-җимереп булса да оныклары белән урысча сөйләшеп йөриләр. Культура үсү билгесе. Дөрес, дин дә шактый зур кыюлык белән тормыш-көнкүрешкә үтеп керә, җәелә шикелле. Мин бит махсус динне өйрәнгән һәм утыз елга якын ислам илләрендә дин тотуны күзәтеп, дикъкать белән карап йөргән кеше. Минем чагыштыру мөмкинлегем бар. Дөрес, һәркем динне әхлакый җегәре, мөмкинлеге җиткән кадәр генә үзләштерә ала. Диннең мөмкинлекләре иксез-чиксез. Бүгенге көндә уяна башлаган дин нишләптер күбрәк ашка җыелып Коръән укытуга, сәдака өләшүгә, исламның ритуалларын башкаруга тупланган. Өмет багларга хакыбыз бар: Алла боерса, әкренләп дин безнең җаннарыбызга, күңел тирәнлегенә дә үтеп керә алыр һәм шәригать кануннары безнең инстинктларыбызны әкренләп тәрбияли башлар...

Күршегә телевизор карарга кергән идем. Илләләр тирәсендәге бер интеллигент ханым килеп керде. Сөйләшә, танышa башладык. Ханым тарих укытучысы икән. Әтисе зур урыннарда эшләгән, хәтта бабасы да укымышлы кеше булган. Ханым культура ягыннан артта калганлыкка зарлана. «Безгә әле,— ди ул,— урысларны куып җитү өчен ким дигәндә тагын ярты гасыр вакыт кирәк». Билгеле, өлкән абыйлар теләндә сөйләшәбез. Чечен мәсьәләсенә күчтек:

— Шул бандитларның күптән кәлләрен күккә очырырга кирәк иде,— ди тарих укытучысы.— СССРны җимерделәр, халыкны распустили. Чечнядан соң башка төбәкләрдә дә тәртип урнаштыра башларлар дип өметләнәм мин.

Мин тизрәк бүрегемә үрелдем. Бераз яшәгәч аңлый башладым: тарих укытучысы ялгыз түгел иде. «Чечнядә конституцион тәртип урнаштырырга» ашкынып яшәүчеләр бер ул гына түгел. Бу хакта мин күпләр белән сөйләштем. Күпләрнең «тәртип» шартларында яшиселәре килә. Тәртипсезлек кешеләрне рәнҗетә, ялыктыра... Тәртипне алар цивилизациягә, чын демократиягә ирешкән илләрдәгечә, әхлакый мохиттә яшәгән законнарны катгый рәвештә үтәп тору дип аңламыйлар. Тәртип саклауны әхлак кануннарын һәм юридик законнарны бозмау, үзара итагатьле булу, шәхси тормыш шартларын тынычлыкны бозмаска җайлап кору икәнлеген дә берничек тә аңлатып булмый. Безне балалар бакчасыннан башлап йодрык тәртибенә, ОМОН солдатлары, танклар белән урнаштыра торган «хакыйкать» кенә чын, ышанычлы тәртип дип өйрәттеләр. Өйрәттеләр генә түгел, нәкъ урыс менталитетына хас Новочеркасск, Алма-Ата, Баку, Тбилиси, хәзер инде Грозный (бу шәһәрне Явыз Иван исеме белән кем атады икән?) шәһәрендә урнаштырылган «тәртип»не аңлаешлы булсын өчен җиренә җиткереп, гамәлгә дә ашырып килделәр. Шуңа каршы чыгарга хәзерлек юк безнең. Куркабыз да инде. Курку безнең мәңгелек юлдаш.

Ватан сугышының без бары тик бер ягын — сугышта күрсәтелгән геройлыкларны гына өйрәндек. Менә бер гаҗәп үзенчәлекле статистика: Сталин чорында сугыш корбаннары саны 7 миллион санала иде. Тәхеткә Хрущев утыргач 20 миллионга үсте. Горбачев чорында корбаннар саны 28 миллион иде инде. Бүгенге көндә, архивларны җентекләп тикшерә, сугыш тарихын җитди рәвештә өйрәнә башлагач сугышта «туп ите»нә әйләнүчеләр саны рәсми рәвештә 35 миллионга җитте. Бу сан әле тагын да артачак. Яңа җинаятьләр, яңа ялганнар ачылачак, чөнки Рәсәй шартларында сугышта иң көчле, иң хәлиткеч корал итеп ялганны кулланалар. Ялган һәм күз буяу.

Грозный шәһәрен Сарай Бату хәрабәләренә әйләндерү, күп меңләгән хатын-кызларны, бала-чаганы, картларны, шул исәптән, урыс милләтеннән булучыларны да кырып ташлау турында бүген Рәсәй тәхетендә утыручылар елмаеп, хәтта шундый табигый мөлаемлык белән сөйлиләр. Безнең авызыбыздан соңгы сыныгыбызны тартып алып җыйган Рәсәйне хәерчелектән коткарырга кирәк дип, бездән талап алган күпме триллионнарны чеченнәрне канга батыру өчен, аларның торакларын, шифаханәләрен, мәктәпләрен җимерер өчен тотып бетерделәр. Бу турыда «Известия», «Московские новости», «Московский комсомолец» язып чыкты. Сугышчан заданиега, Грозныйга бомба ташларга очканда, бомба «йөген» шәһәр өстенә бушатып кайткан очучының кулына бишәр миллион акчаны тоттырып торганнар. Чечен сугышындагы «батырлык»ны шушы юл белән гамәлгә ашырганнар. Хәзер инде хакимият Грозный шәһәрен, Чечен республикасындагы башка шәһәрләрне, мәктәпләрне, балалар бакчаларын торгызу турында сөйли башлады. Киләчәк ун-унбиш елда бездән тартып алган салым акчалары шул «торгызу»га китеп торачак. Юкка гына без Сталинны сагынмыйбыз. Бөек юлбашчыдан да остарак булып чыктылар «тәртип урнаштыру» эшендә Рәсәй тәхетендә утыручылар. Бу илдә «тәртип урнаштыру»ның ысулы шундый. «Тәртип урнаштыру» белән генә чикләнмичә, Рәсәй хөкүмәте Чечнядә «яхшы чеченнәр»дән җирле администрация» оештыра башлады.

Нәкъ Чечнядагечә, фашистлар башта Ауропада, аннан соң СССРның оккупациягә эләккән төбәкләрендә «урындагы администрация» төзеп азапландылар. Алар да бу эшкә «яхшы украиналыларны», «яхшы белорусларны» куеп карадылар. Фашистлар да, нәкъ Грачев шикелле, каршылык күрсәткән авылларны яндырдылар, каршы чыгучыларны үтереп бетерделәр. Буйсынудан баш тартучыларны газ мичләренә тутырып яндырдылар. Никадәр тырышсалар да фашистлар теләкләрен тормышка ашыра алмадылар. Киресенчә, сугыш Азатлык ягына борылгач, теге «яхшы украиналылар» «яхшы белоруслар» фашистларга сатылган полицайлар булып чыкты. Аларның язмышлары турында сөйләп торасы юк. Ә менә бүгенге көндә нәкъ шул вазифаны өсләренә алырга азапланган чечен чиновниклары турында уйламыйча булмый. Соң бит шәһәр-авылларны җимереп, кешеләрне сытып йөргән дошман танклары артына яшеренеп яшәп тә, идарә итеп тә булмый.

Кешелек дөньясы тарихында булган сугышларның барысы да кеше үтерү максаты белән оештырылган. Күбрәк үтерә, күбрәк җимерә алган як җиңеп чыга, сугышка катнашучыларын күләмлерәк югалткан, җирен, мөлкәтен саклый алмаган як җиңелә. Әмма чечен кебек соклангыч, горур халыкның җиңелүенә ышанасы килми, урыс армадасы тарафыннан ике тапкыр кырылуга дучар ителгән халык өченче тапкырында да үз-үзен яклый алачак. Ходай Тәгалә иманлы халык ягында.
Кызганыч, сугыш афәтләреннән кешелек сабак ала белми шул...

# Рашат Низамиев

## ҖӨМЛӘЛӘР

(ФИКЕР ҺӘМ ТӘҖРИБӘ ҖИМЕШЛӘРЕ)

- Адәм баласы өч нәрсәгә мәңге бурычлы: әнкәсенә, балачакка һәм мәхәббәткә.
- Белем-тәҗрибәсе сай, ихтыяры сыек булганнар камырны хәтерләтә: андыйлардан теләсә ни әвәләргә мөмкин.
- Күңеле яралы кешеләр, гадәттә, бер-берсен тизрәк аңлаучан булалар.
- Мәхәббәттә бирәү — көн, бирәү — төн. Көн һәм төн тәүлекне барлыкка китергән шикелле, менә шушы ике капма-каршылыкның берлеге, бөтенлеге гаҗәеп гармония тудыра да инде.
- Мәхәббәт формуласын болайрак күзалларга мөмкин: тормыш — сәхнә, катнашалар — икәү, финал — бәхет яки бәхетсезлек.
- Мәхәббәт — дөньяны һәм үз-үзеңне танып белүнең иң көчле бер төре.
- Сагыш ул — рух байлыгы, серлелек, күңел тирәнлеге дигән сүз.
- Сөю ике генә нәрсәне — хыянәтне һәм пыскып янганны кичерә алмый.
- Бик кыен чакларда мәҗбүри елмая белергә өйрән — шундук эчтән яктырып, үзгәреп киткәндәй буласың.
- Мәхәббәт йөрәктә туа, әмма ул кайберәүләр өчен кухня һәм тормыш-көнкүреш мәшәкатьләре диңгезендә батып үләргә дә мөмкин.



Миркасыйм Госманов

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ: «ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ» ҺӘМ ПАТША ЦЕНЗУРАСЫ

(ИҖАТЫНЫҢ ЯҢА СӘХИФӘЛӘРЕ АЧЫЛУ)

Бөек әдипнең иҗатында, язмышында, хәтта аның аерым әсәрләренең язылу, басылып чыгу тарихында да халкыбызның авыр тәкъдире көзгедәге сыман чагылып тора. Моңа язучының дөнья күргән беренче зур әсәре — «Ике йөз елдан соң инкыйраз» китабы да дәлил. Аның дөньяга ничек чыгуыннан алып, аннары нинди эзәрлекләүләргә, тыюларга дучар ителүенә кадәр. Татарның үзенчәлекле бай, бер үк вакытта гаять катлаулы һәм фаҗигале язмышы, шул язмышның тарихы шикелле «Инкыйраз» әсәре дә моңарчы цензор пычагы белән тураклаңган, таланган хәлдә басылып чыккан һәм дистәләгән еллар буе йозак астында яткан. 1904 елда дөнья күргән беренче нәшере дә, шуның нигезендә 1990 елда «Казан утлары» битләрендә (№ 1—2) кабатланган яңа басмасы да. Моның шулай икәнлегенә цензор кулы белән әсәр тукымасыннан кисеп, йолкып алынган шактый сәхифәләр шаһитлек итә. Әллә нинди хикмәтләр белән генә сакланып калган, цензор пычагының канлы эзе төсле кызыл кара белән аркылы-торкылы сызылган сәхифәләр...

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» ул безнең өчен сүзнең чын мәгънәсендәге бөек әсәр. XX гасыр башы татар әдәбиятының иҗтимагый эчтәлегенә төп юнәлешләрне, рухына иман эзлеклеген биргән һәм бөтен пафосы белән уяну чоры сүз сәнгатебезнең лейтмотивын — төп аһәңен төшкил иткән уникаль әсәр ул. Аның дөньяга чыкканнан соң 70 ел үткәч кенә табылган һәм 85—90 ел узгач укылу, өйрәнелү мөмкинлегенә ирешә алган сәхифәләре дә гыйбрәтле. Безнең узганыбызны үзенчә гәүдәләндерә торган гомум милли аңыбыз, йолкышланган тарихи белемебез, халык сыйфатында танылу дәрәҗәбез кебек үк, алар да имгәтелгән хәлдә өлешләп кенә сакланып калган икән.

Ниһаять, укучы күрер, моңарчы без Гаяз Исхакый иҗатының кайбер үзенчәлекләрен һаман аңлап, дөрес бәяләп бетермәгән икәнбез. Хәтта бу иҗатка карата элек хөкем сөреп килгән рәсми тискәре караш җимерелгәч тә...

## I. Көтелмәгән очрашу

«Ике йөз елдан соң инкыйраз», мәгълүм булганча, 1902 елның 27 ноябрендә Оренбургта язылып беткән, 1903 елда «Хатимә» *(соңгы сүз)* өстәлеп, 1904 елда Казанда, Харитонов матбагасында басылып чыккан. Вак-вак хәрефләр белән тыгыз итеп җыелган 96 битле китап рәвешендә.

Шул басманы кулына тотып караган һәм әсәрне «Казан утлары» битләреннән укып чыккан кешеләр игътибар иткәндер, аның текстында вакыт-вакыт фикер өзелүдән мәгънә аңлашылып бетми торган урыннар очраштыргалый. Китапның үзендә, шулай ук «Казан утлары»нда да андый кыскартылган җирләргә ишарәләп тора торган «бушлык» галәмәтләре куела барган. Гадәти өч нокталарга охшамаган эрерәк һәм сирәгрәк куелган күпнокталар рәвешендә.

Әсәрне җентекләп уку нәтиҗәсендә андый махсус билгеләр куелмаган тагын ике урын булуы ачыкланды. Җыеп әйткәндә, цензор тарафыннан кыскартылган урыннар 1904 елгы басмада тәртип буенча түбәндәге битләрдә очрый: 12, 20, 21, 23, 28, 30, 38, 42, 43, 51, 55, 56, 57 (ике урында), 64, 65, 66, 67, 71, 79, 80, 81, 82, 83, 85, 94, 95 битләр. Барлыгы — 27 урында.

Болардан икесе, ягъни 30 һәм 38 битләрдәгеләре, әле генә әйтелгәнчә, махсус галәмәтләр белән билгеләнмәгән. Ләкин кыскартуларның булганлыгы бернинди шик тудырмый — алар документаль дәлилләр белән раслана.

Дөрес, әле генә күрсәтелгән битләрдән кайберләрендәге кыскартуларның реальлеге бик үк ачык булмаганнары да бар. Мәсәлән, 21, 64, 71 һәм 83 биттәгеләре. Болар хакында алга таба махсус сүз булыр.

Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, бүген шул цензор тарафыннан башкарылган кискәләү, тураклауларның бер өлешен бетерү, ягъни табылган хәтлесен игълан итү мөмкинлеге барлыкка килде.

* * *

**1974** елның көзендә, хан ярлыклары буенча материаллар туплап йөргән чакта, миндә Ленинград—Петербург архивларында актарыну, җөмләдән элекке чор рус ориенталистларының шәхси архивларында да эзләнү ихтыяҗы туган иде. Кайчандыр Кырым ярлыклары буенча берничә мәкалә бастырган мәгълүм ориенталист, тагын да мәгълүмрәк патша цензоры В. Д. Смирновның кәгазьләре белән танышып йөргән чакта, минем кулга әле «өйрәнелеп җитмәгән бер «эш» килеп керде. Архив хезмәткәре аны, минем үҗәтләнеп «көне-төне» эзләнүемне ихтирам иткән төсле, «для предварительного знакомства», дип, кыска вакытка гына биреп торган иде. Чөнки ул вакытларда эчтәлеге «тикшерелмәгән» кәгазьләрне укучыларга бирмәү гадәте — советча гадәт хөкем сөрә иде.

Төрле рәвеш һәм төрле характердагы, нигездә татарча язылган текстлардан торган кәгазьләрдән — Смирнов тарафыннан цензурага килгән кульязмалардан «кыркып алынган» сәхифәләр, йәисә шундый кульязмаларның үзләреннән үк гыйбарәт иде болар.

Минем игътибарны битнең ике ягы да вак-вак хәрефләр белән тутырылган кәгазьләр җәлеп итте. «Амбар кенәгәсе» форматындагы дәфтәр битләре. Текстка игътибар белән күз салуга ук аларның Гаяз Исхакый язган «Ике йөз елдан соң инкыйраз»дан йолкып алынган сәхифәләр булуын аңладым...

Әлбәттә, җитмешенче елларда, Г. Исхакыйның исемен сүгенмичә, йәисә «тәнкыйтьләмичә» телгә алу мөмкин булмаган чорда, әлеге кәгазьләрне күчереп тору мөмкинлеге ихтималдан ерак иде. Ул елларда гарәпчә язулы материаллардан фотокүчермәләр сорый башласаң, мәсьәләне хәл итүче вә-



1. Гаяз Исхакый. 1908 елда басылып чыккан «Мөгаллим» (драма) китабында беренче мәртәбә нәшер ителгән рәсем.

калэтле кеше, әгәр үзе ул язуларны укый алмаса: «Боларда халыклар дуслыгына зыян китерерлек нәрсәләр юкмы?» — дип сорарга онытмый иде. Ә ул көнне, миңа әлеге «эшне» биреп торган кеше, күренекле иранист Е. Бертельсның улы Дмитрий Бертельс (сталинчылар чорында «кунакларда» булып кайткан зыялы), бирәр сәгатьтән соң, гафу үтенгән төсле уңайсыз гына елмаеп, әлеге папканы борын төбеннән алып киткән иде... (60 нчы елларның ахырында шул ук архивта Риза Фәхретдиннең моңарчы билгесез хәлдә яткан архивы белән беренчеләрдән булып танышып, шуның хакта институттагы төрки-монгол бүлегендә белдерү ясавымның кайберәүләргә ошамаганлыгы да миңа мәгълүм иде инде.) Шуна күрә мин: «Хәер, кучереп алсаң да, алар белән нишләрсең?» — дип юаткан булдым ул көнне үз-үземне.

Архивларга ишекләр киңрәк ачылу, элек хөкем сөргән мәгънәсез чикләүләр бетә бару, белгәнебезчә, 80 нче елларның ахырларында гына башлана башлады. Шуңа күрә 1990 елның яз аенда, «Инкыйраз»ның тексты «Казан утлары»нда яңадан басылгач, беренче мөмкинлектән файдаланып, юлга чыктым. Күптән сагындырган архивка керүгә үк 50 нче фондның беренче тасвирламасы буенча саклана торган 150 номерлы «эшне» соратып алдым. Өч-дүрт көн буе «эшнең» 8—14 нче кәгазьләрендәге текстны күчереп утырдым.

Иңен 22, буен 35,5 сантиметр тәшкил иткән зур форматлы җиде кәгазьнең ике ягын да вак-вак хәрефләр белән «шыплап тутырган» текст. Аны җентекләп укып чыгуы, күчерә баруы ялыктыргыч та, ләззәтле дә эш иде. Вак хәрефләр күзне талдырса, еш кына очрый торган имля төгәлсезлекләре аптыратып куя, төгәлсезлекләрнең сәбәпләрен ачу, төшеп калган хәрефләрне ачыклау рухландырып җибәрә. Шулай автографның мәгънәсенә керә-керә, Г. Исхакыйның уй-хыялларына тирәнрәк үтәсең, «Инкыйраз»ның әһәмиятен төгәлрәк аңлый барасың...

Махсус әдәбиятта әдәпле рәвештә чамалап кына күрсәтелгәнчә, Гаяз Исхакый ашыгып, хәтта кабаланып, шашынып дигәндәй иҗат иткән. Язган, сызган, бер язганын акка күчереп тормыйча, шунда ук ары таба дәвам кылган. Әдипнең текст өстендә ничек ашыгып, ургылып торган фикерләрдән буыла-буыла эшләве кульязмадан — автографтан бик ачык күренә.

Язучы иҗатына хас мондый күренеш — ашыгу, кабалану күренеше — фикеремчә, киләчәктә махсус өйрәнелергә тиеш. Аның үзенә күрә иҗтимагый (хәтта социаль-сәяси) сәбәпләрен ачыклау ул бөтен гомерен иҗтимагый гаделлеккә, милли-азатлык көрәшенә багышлаган әдипнең эшләү стилен дә, беренче нәүбәттә, әдәби иҗатның кайсы ягына өстенлек бирүен дә анукларга ярдәм итәчәк. Моны билгеләү, минемчә, язучы телендә очраштыргалый торган гадилекнең дә, стилистик төгәлсезлекләрнең дә табигатен аңлауга китерәчәк. Бу исә гамәли әһәмияткә ия: киләчәктә аның әсәрләрен бастырып чыгарганда андый үзенчәлекле урыннар белән кайчан нишләргә, аларны ничегрәк шәрехләргә кирәклегенә күрсәтәчәк.

Цензор кайчысы белән туракланган кульязмаларны җентекләп өйрәнүнең икенче яктан да әһәмияте зур. Болардан Смирновның сәяси позициясен, кешечә әхлакый йөзен тагын да ачыграк күрергә мөмкин. Гәрчә аның кара йөрәклеге, ихлас вөҗдансызлыгы моңарчы да шактый киң мәгълүм булган хәлдә дә. Яңа материаллардан муенчаклы патша цензорының бу конкрет әсәрдәге нәрсәләргә каныгып бәйләнүен, нәрсәләрне теш-тырнагы белән «пущать итмәвен» — сызып, кисеп ташлавын, шул рәвешчә «халыклар дуслыгына» рәсәйчә хезмәт кылуын йәнә дә ачыграк күрергә мөмкин.

Алардан шулай ук Смирновның «Инкыйраз» кульязмасын бәйләнә-бәйләнә ике мәртәбә укып чыккан булуын да беләбез. Беренче тапкыр ул, текстны зәңгәр йәисә гади карандаш белән әсәр текстындагы аерым сүзләрне, җөмләләрне, кечерәк абзацларны гына сызып, шулардан «криминал» табып укыган. Икенче юлны аркылы-торкылыга сызып, шул рәвешчә әдәби әсәрнең текстын бутарлап, имгәтеп барган. Кайвакытларын юкка да диярлек бәйләнеп маташкан.

Смирновның әсәр тукымасы белән ни дәрәҗәдә шапшак, тупас, әхлаксыз кылануын күргәч, китап чыккач гарьләнгән авторның, Петербургка барып, цензорны үтерү хакында хыялануының («Казан утлары», 1990, № 1, 87 б.) сәбәпләрен аңлагандай буласың.

Казанга кайтып, күчермәләрне 1904 елгы басма текст белән чагыштыра торгач, әлеге җиде кәгазьдәге өзекләрнең һәммәсенең дә урыннары табылды. Шуны-сы да тагын ачыкланды: Смирнов кулы белән, өлешчә яки тулаем сызылган

битләр — текстның сызылмаган өлешләренең китапта сакланылган булуына караганда — «цензор галиҗәнапларына» китап дөньяга чыккачҗибәрелгән икән. Әмер-фәрманның үтәлүен күрсәтер өчен.

Әмма, текстларны чагыштырып өйрәнү нәтиҗәсендә, мөһим табыштан күтәрелгән, илһамланган күңелнең бер чите кителеп тә төште диярлек. Чөнки «Инкыйраз»дан цензор сызып ташлаган сәхифәләрнең һәммәсе дә миңа мәгълүм архив эшендә сакланмаган иде. Мәсәлән, югарыда мин 1904 елгы басмада әсәрнең 27 урынынннан текстлар төшерелүгә күрсәтә торган галәмәтләр — «бушлыклар» бар дип әйткән идем. 1974 елны беренче тапкыр күргән, шунда кыскача теркәп алган, 1990 елны гына кулдан күчереп кайткан өзекләр әле күрсәтелгән егерме җиде «бушлыкның» нибары унберен генә тутыралар иде. Мәсәлән, 28, 30, 38, 42, 43, 57 (ике өзек), 65, 66, 94, 95 битләрдәгеләрен. Калган уналты урында һаман «ертыклар» кала бирә...

Хәзергә табылмаган, Смирновның миңа таныш кәгазьләре арасында сакланмаган, әмма әсәрдән алынганлыгы бәхәссез булган өзекләрнең күләмнәре, язмышлары хакында бүгенгә бернәрсә дә әйтеп булмый. Аларның нашир һәм басмаханәче тарафыннан цензорга җибәрелү, җибәрелмәү мәсьәләсе дә ачык килеш кала. Бик кечкенә кыскартулар булып, җибәрелмичә калганлыклары ихтималга каршы килмәгән шикелле, аларның цензорга ирешкәч тә югалган булулары мөмкин...




2. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» китабының (1904) титул бите. 1970 елда археографик экспедиция вакытында табылган нөсхәдән.

Ихтимал, ачык калган сорауларга киләчәк архив табышлары җавап бирер. Шул юнәлештәге минем үз ниятләрем исә хәзергә тормышка аша алмады. 1992 елда Г. Исхакый иҗатына багышланган бер конференциядә табышлар хакында хәбәр иткәннән соңгы кайбер эзләнүләрем дә нәтиҗә бирмәде. (Минем белүемә караганда, дәһшәтле цензорның шәхси архивы таркалган, аның кайбер өлешләре төрле архивларда саклана шикелле.) Өстәвенә соңгы елларда иркенләп ил-шәһәрләр гизү, озаклап архивларда казынып яту, юмартланып фотокүчермәләр ясату мөмкинлекләре дә юкка чыкты. Шуңа күрә хәзергә табылган өлешләр, ягъни кулда булган кадәресе белән канәгать хасил кылып, ул өзекләрне игълан итә тору дөресрәктер дигән нәтиҗәгә килдем. Чөнки әдип әсәрләренең күп томлыгы чыга башлаганда «Инкыйраз» әсәренең тексты да яңа табышлар исәбенә мөмкин кадәр тулырак, сыйфатлырак һәм дөресрәк булып басылырга тиештер дип ышанам. Ягъни цензор архивыннан алынган өзекләр беренче чиратта Гаяз Исхакый әсәрләренең нәшрият планындагы шул күптомлыгын күздә тотып басмага әзерләнде.

Шул ук вакытта мәсьәләнең икенче мөһим ягы да бар әле. Югарыда әйтелгәнчә, әсәрнең икенче мәртәбә басылуын — 60—70 ел дәвамында эзәрлекләнеп, тыелып яткан китапның хәзерге укучыларга кайтуын 1990 елда «Казан утлары» тормышка ашырган иде. Анда да әсәрнең цензор пычагыннан узган төшләре 1904 елгы басмадагыча өлешчә күрсәтелгән. Шуңа күрә «Инкыйраз»ның цензор төрмәсеннән коткарылган өзекләрен әсәргә икенче гомер биргән, дөресрәге аны большевизм зинданыннан чыгаруга өлеш керткән журнал битләрендә бастыру хокук җәһәтеннән дә, әхлак ягыннан да дөресрәк булыр.

Әсәрнең журналда чыккан редакциясе әле авыррак шартларда дөнья күргән иде. Сталин күсәкчеләре һаман ажгырып, һаман өскә ыргылып маташкан, ягъни өлкә секретарьларе элеккечә үк диярлек кодрәтле, аларның имансыз куштаннары исә өстерүне генә көтеп торган елларда. (Рафаэль Мостафинның бер мәкаләсеннән соң оештырылган махсус кампаниене — муенчаклы профессорларның

«бәйдән җибәрелүләрен» искә төшерик.) Шундый шартларда ашыгыч рәвештә, «артык шауламыйчарак» дигәндәй, басмага әзерләнгән текстта кайбер текстологик, орфографик житешсезлекләрнең очраштыргалавы әллә ни гаҗәп түгел. Шуларны исәпкә алып, басыла башлаячак күптомлыкның һәрьяктан да югары сыйфатка ирешүен теләп каласы килә.

«Инкыйраз»ның әдәби һәм гыйльми хәрәкәткә кайтарыла торган, моңарчы цензор Смирнов «читлегендә» бикләнеп яткан өзекләре журналда түбәндәге тәртип һәм искәрмәләр белән тәкъдим ителә. (Әсәрләрнең күптомлыгында исә алар, әлбәттә, китаптагы үз урыннарында — тезүчеләр тарафыннан кабул ителгән кагыйдәләр буенча басылыр.)

1. Әсәрнең 1904 елда чыккан беренче басмасында — **«ББ...»**, 1990 елда чыккан икенче басмасына исә **«КУ, № ...»** дигән шартлы билгеләр куелып, тиешле битләре күрсәтелер.

2. Өзек алдыннан, ББ һәм КУ буенча урыннары күрсәтелгәннән соң, китапта шул өзектән элек килә торган җөмләләр, яки аларның өлеше, куштырнаклар эченә алынган рәвештә, петит белән басылыр. Өзекләр күчерелеп беткәч, аларның архивтагы һәм төп нөсхәдәге (**«ТН»** — Г. Исхакый кульъязмасындагы) урыннары күрсәтелеп, «моннан соң» дигән гыйбарә белән басмага кергән текстның өлеше китерелер.

3. Сүзләрнең язылышында автор имлясы мөмкин кадәр төгәл чагылдырылган хәлдә, тыныш билгеләре, мәгънә сөрешеннән чыгып, хәзерге кагыйдәләргә буйсындырылды. Кайбер грамматик һәм стилистик төгәлсезлекләр, әгәр алар мәгънәгә артык хилаф итмәсәләр, оригиналдагыча калдырылды. Өстәмә сүзләр, иҗек һәм хәрефләр куелу ихтыяҗы туганда, алар почмаклы җәяләр [...] эченә алынды.

4. Архаик сүзләргә бирелгән кыскача сүзлекчәләр һәр өзектән соң урнаштырылды.

5. Махсус атамаларга, күренеш һәм тарихи фактларга яки кинаяле сүзләргә бирелгән аңлатмалар, публикация буенча үтәли (баштан ахыргача бер уңайдан) куелган тәртип саннары ярдәмендә махсус искәрмәләрдә булыр.

6. Цензор тарафыннан текстның ике мәртәбә укылган, беренче юлны Смирновның нәрсәләргә игътибар иткән булуын күрсәтер өчен өзек эчендәге андый өзекчәләр «*...**» галәмәте арасына алынып, *курсив* ярдәмендә басылган текст белән бирелде.

«Инкыйраз»ның табылган хәтле өзекләрен шулай игълан итү белән бергә, әсәр тукымасында һаман сакланып кала бирә торган цензор яраларын — «ертык» урыннарны да төгәлрәк билгеләү файдалы булыр. Киләсе басмаларда шундый таланган урыннар искәрмәләр белән махсус күрсәтелсә, әсәрне аңлавы да, аңлап укыган кешенең уйлануы да арта төшәр иде. Аннары, әдипнең үз сүзен кулланып әйткәндә, китешебез киләчәге («китеш» Г. Исхакыйда «развитие» мәгънәсендә йөри) никадәрле томанлы, шөбһәле булса да, яхшыдан өмет итик: шартлар азрак тәзекләнә төшеп, максатчан эзләнүләр дәвам итсә, калган өзекләрнең дә табылуы ихтимал бит. (Югарыда бер әйткәнемчә, Смирновның шәхси архивы әлегә төгәл барланмаган.)

Мәсьәләнең шушы ягын истә тотып, «Инкыйраз»дан кайчандыр цензор кисеп алган, әмма хәзергә кадәр үзләре табылмаган өзекләрнең дә урыннарын төгәлрәк күрсәтү, беркадәре дәлилләү зарур. Чөнки аларның гадәти генә күпнокталар, ягъни авторның үз ихтыяры белән куелган махсус тыныш билгеләре генә булмавын исбатлау сорала. Бер үк вакытта әсәр текстындагы фикернең ничек өзелүен, күп очракта шул рәвешчә мәгънә ничек бозылуын ачыграк күрсәтү дә зарур. Шушы максаттан чыгып, формаль ишарәләр белән генә канәгатьләнмичә, төшерелгән урыннарга кадәрге һәм алардан соңгы текстлардан ике-өч җөмләдән торган өзекләр китерелер. Суелган төшләргә исә шул ике өзек арасындагы почмаклы җәяләр эченә алынган, әмма яңа юл уртасына урнаштырылган күпнокталар [.......] күрсәтелер. Аерым урыннарда гына, бик ихтыяҗы туса гына, кыскача искәрмәләр бирелер.

## II. Цензор пычагы эзләре

### 1. Табылган өзекләр

**1**

*ББ, 28 б. (өстән 14 нче юл); КУ, № 1, 130 б. (өстән 18 нче юл):*

«Үзләренең гәзитәләре бар, театрлары бар, хатыннарының йортлары бар иде. Шушысы бик яман: мәктәпләр, мәдрәсәләр дә бер дә юк иде»:

Бу гәзитәләр Кырымда дәвам итә торган «Тәрҗеман» гәзитәсе[1] берлән бер мәсләкдә халыкка файдалы мәсьәләләрне мөляхәзә кылып, ватанымыз вә милләтемез тугърысында хәмийәте ватанийә уята торган озын мәкаләтләр, фәнни мәгълуматлар бер[лән — ?] халыкның рухын күтәрәләр иде. Вакыты берлән ул гәзитә битләрендә чыккан тел мәсьәләсе берлән дә бөтен дөньяны тутырганлар иде. Төрле кеше төрле фикердә булып, бәгъзесе «әдәби лисанымыз халис татарча булсын», бәгъзесе «кырымчарак булсын» мәсьәләләренең мөзакәрәләре[2] гәзитәләремездин рус гәзитәләренә ва андин Йаурупа, Америка гәзитәләренә кадәр китә иде. Бу мәсьәләдә кырык мәсләк, сиксән кадәр фикер киткән иде.

Архив востоковедов, 50 нче фонд, 1 тасвир., 150 нче эш, 13б б (ТН: 30 б.); моннан соң:

«Әдәби лисан мәсьәләсе бетә башлагач, лисанның рәсме хатты хакында озын мәсьәлә башланган иде» (ББ, 28 б.).

---

М ө л я х а з ә  к ы л у — уйлау, фикер йөртү; Х ә м и й ә т е  в а т а н и й ә — ватан химаясе *(саклау)*; Л и с а н — тел; Х а л и с — саф; чын; М ө з а к ә р ә — фикер алышу; Р ә с м е  х а т т — язу, почерк төре *(каллиграфиясе)*.

## 2

*ББ, 30 б. (астан 8 юл); КУ, № 1, 132 б. (өстән 4 юл):*
*«... кеше арасында аны мәкруһ күрелгәнгә, аны әхлаксыз кешеләр кулына төшергән иде»:*

Шуның өче ул әхлаксызлар кулында әхлак бозар өчен бер аләт булган иде. Әүвәлдә * *бәгъзе руслар йәһүдиләргә*** исерткеч, фәхешне үз музыкабыз берлән безнең үземезнеке итәр өчен буяп күрсәтә башлаганлар иде. Һәм вакыйган бик файда иткәнләр иде...

(Архивта 13а б. (ТН: 31 б.); моннан соң:

«Һәммә йирдә музыка[ны] фәхеш, исерткечнең гайебен капларга истигъмаль кылу халык арасында тарала башлаган иде» (ББ, 30 б.)

---

М ә к р у һ — начар, тыелган; А л ә т — корал, чара; В а к ы й г а н — чыннан да; И с т и г ъ м а л ь  к ы л у — куллану, файдалану.

## 3

*ББ, 38 б. (астан 9 юл), КУ, № 1, 138 б. (өстән 17 юл):*
*«Гәзитәләремез бетте, мөхәррирләремез бетте; бетмәсә дә, егерменче гасырның башларындагы кеби каблийәт, дәрд берлән язганлары калмадылар»:*

Гәзитәләремез бетте. Иң әүвәл, 50 сәнә дәвам иткәндән соң, «Тәрҗеман» гәзитәсе беткән иде[3]. Мөхәррирнең вафатыннан соң вак-төяк кешенең кулына төшкәнгә, аларда гәзитә нәшер кылырлык, бердән, гайрәт юклыгындан, икенче[дән], хәмийәт юклыгындан идарә ябылган иде. Гәзитә туктаган иде. Бу эш әрбабе милләткә бик авыр тоелган иде. Чөнки шул кадәр зур хезмәт иткән бер мөхәррирнең, йоклаган бер милләтне уяткан бер затның үзе берлән бергә гәзитәсенең үлүе, мәсләге *югалуы без болгарлар тарихында истикъляльемезне югалтудан ким түгел иде**. Һәм, вакыйган да, моның бетүе бик зур тәэсир кылган иде. Халык тагын йоклый башлаганлар иде. Вә уянуларыннан файда һич булмады. Гәзитәнең иткән хезмәте, мөхәррирнең бөтен галәмнең тәкъдирендән гаҗиз калырлык гайрәте бетте дә китте. Казан гәзитәләре матәм тоттылар. Һәммә йирләрдә яшьләремездә матәм булды. Ләкин көн үтте, ай үтте, ел үтте, тагын тормыш үз халенчә бара башлады. *«Тәрҗеман» хакында вә аның мөхәррире Исмәгыйль бәк хакында китаплар, рәсемләр, тәрҗемәи хальләр болгарлар арасында** кулдан кулга гына йөрсә дә[4], бара-тора ул да сүнә башлады. Шундан күп үтмәде, ун-унбиш елдан, Казандагы «Кабан» гәзите, аның артыннан Әстерхандагы «Хәзәр»[5] гәзитәсе, мөхәррирләре бетүе берлән һәм дә алучылары азлыгы берлән, ябылганлар иде. Бу мәсьәлә тагын бик тавышлы булды. Яшьләр акча җыярга тотындылар. Җыйдылар. Янгыздан[6] «Кабан»ны нәшер итә башладылар, тагын озак үтмәде — ардылар. Акчалары бетте. Гәзитә ябылды; берәм-берәм журнал, рисаләи дукуталар[7] бетә башлады; иң соңга «Игенче» гәзитәсе калган иде. **Ул да дәвам итә алмады.*

*Егерменче гасырның ахырында бер газитә дә калмады диргә ярый иде***. «Болгар» исемендә руслар тарафыннан нәшер ителә торган тарихи журнал берлән «Сату» исемендәге газитәгә башка берсе дә калмаган иде. Бу газитә дә ахырга таба игъланлар берлән генә киченә башлаган иде. 21 нче гасыр керде. Руслар, Йаурупа халыклары бик зур бәйрәм иттеләр. Газитәләр, журналларда, махсус китапларда 20 нче гасырның хисабы чыкты.

Архивта 8а б. (ТН: 31 б.); моннан соң:

«Башка халыкларда, һәр йирдә алга бару күренә иде, һәммә халык шуның өчен гъэйд ясыйлар иде» (ББ, 38 б.).

---

Каблийәт — сәләт, талант; Хәмийәт — химая, саклау; Әрбабе милләт — милләт әһелләре; Истикъляль — мөстәкыйльлек; Вакыйган да — чыннан да, дөрестән дә; Тәкъдирендән гаҗиз калу — мактап бетерә алмау; Гъэйд — бәйрәм.

4

*ББ, 42 б. (өст. 8 юл); КУ, № 1, 141 б. (өст. 6 юл):*
«... олугларына һәйкәл кую да мөляхәзә кылына башлаган иде. Бу тавыш тагы бик зур итеп иганәләр җыюга кадәр йитеккән иде»:

Һәйкәл[нең] берсе «Тәрҗеман» мөхәррире Исмәгыйль бәккә, икенчесе болгар әдәбиятына бик зур хезмәт иткән бер затка, өченчесе болгар музыкасын ислях кылган болгарга иде. Болардан соң мөәррихләргә, фәнгә хезмәт итүчеләргә, сәнаигы нәфисәгә хезмәт итүчеләргә кую да уйланган иде. Исмәгыйль бәккә [һәйкәлне] Кырымда куярга кирәк булса да, ул вакытта Кырымда калынучылар да[8] бәгъзесе төреккә күчеп, бәгъзесе теге ауру берлән үлеп беткәнгә, Казанга ачылу уйланган иде. Шуның өчен Казан мәйдан [ларын]да, һәйкәлләргә урынлар да хәзерләнгән иде. Исмәгыйль бәк бер бик караңгы халык берлән тулган өйгә бик якты электрик лампасы яккан идеп куелачак иде[9]. Әдип кулына тоткан бер китапта тезмәләгән[10] каләм берлән дөм сукыр кешеләрнең күзләрен ачкан итеп куелачак иде...

Бүтәннәренә дә, хезмәтләренә күрә, эшләрен белдерерлек төс-кыяфәт уйланган иде.

Архивта: 14б б. (ТН: 34 б.); моннан соң:

«Ләкин бу калган халык та көндән-көн кими барганга, көндән-көн ярлылана барганга...» (ББ, 42 б.).

---

Мөәррих — тарихчы; Йитеккән — житкән, житешкән; Сәнаигы нәфисә — нәфис сәнгать.

5

*ББ, 43 б. (өст. 11 юл); КУ, № 1, 141 б. (аст. 3 юл):*
«Егерме беренче гасырның 97 нче елында булган гомуми тәхрире нөфүстә Җәгъфәр Русиядә 3,800 болгар барлыгын белде»:

Болар аңарга шул кадәр авыр булды — һич әйтеп бетерерлек түгел. Мондан ике йөз ел элек, унтукызынчы гасырда үзләрен язды[р]мас өчен сугышкан, тәхрире нөфүстә 15 милиун болгар халкы[11] ике йөз елда 3800 гә калган иде. Бу сиферләр арасының күплеге Җәгъфәрне болгар халкының тәмам бетү[енә] ышандырган иде. Шуның өчен 15 милиун вакытта үзен-үзе саклый алмаган, үз кирәген эшли алмаган, фараз берлән гомерен үткәргән бер халык 3800 аксак, чулак, сукыр, күзсез, гъәриб берлән алга китүнең имкяны юк иде. Моннан соң Җәгъфәр дә рәтләнеп язмый да башлады. Чөнки, язуның файдасы юклыгын белгәнгә, тәмам гайрәте кайткан иде. Алай булса да, исмасам, монкарыйз булсалар да, тарихтан исемләре югалмасын дип, болгарларның фәнгә, әдәбиятка, музыкага иткән хезмәтләрен җыя башлады. Һәм болгарларның ачык тарихына бик күп әсәрләрен[12] җыеп, мәгыйшәтләре тугърысында, гадәтләре хакында бик күп нәрсәләр язды. Җәгъфәрнең әсәрләре һәр кеше өчен бик кыйммәт булганга, **руслар*

_өчен дә үзләренең ничә гасырлар бергә торган_** ватандашларының, хәтта бәгъзе җәһәтләрендән үзләренең мөгаллимләренең мәгыйшәтләрен белү, тарихлары, музыкалары берлән ашна булу, әлбәттә, матлаб булачак иде. Шуның өчен Җәгъфәрнең һәр әсәре *_русчага тәрҗемә кылынып, меңләрчә нөсхәләр тарала, рус_** галәменең һәр сыйныфы тарафыннан укыла, мөхакәмә кылына, хәтта болгарларны кызганалар иде. Болгар әдипләренең әсәрләре, тәрҗемәи хальләре, болгар белик (кәлим)[13], хаким (фәйләсуф)ларының *_фикерләре русчага тәрҗемә кылына иде_**. Болгар музыкасы русларның иң зур шәһәрләрендән иң вак шәһәрчекләренә кадәр таралган иде. Русларның иң бөек сыйнфы да, иң түбән сыйнфы да болгар музыкасы берлән тәэсирләнәләр иде. Болгар әдәбиятында әллә нинди *_русларның үзләрендә күрелмәгән бер җиддилек, къәльбдән чыкканлык_**, нинди таш йөрәкләргә дә тәэсир кылырлык бер арт[ык]лык табалар иде. Болгар музыкасында кайгылыктан башка бер руханийе хаканийәт[14], инсанның бөтен фикерен, уен [җәлеп] итә торган бер хасият табалар иде. Шул кадәрле гали музыканың моңганча үзләренең аталары, бабалары тарафыннан илтифатка алынмадыгы мөляхәзә кылына иде. Моңганча үзләренең ата-бабалары[ның] шундай ләззәттән мәхрумлыклары өчен аларны кызганалар иде. Аларның бәгъзе ноксанлыкларын да, хәтта шул музыка берлән тәэсирләнә алмагандан дип уйлыйлар иде. Театр, музыкальный вечер игъланнарының башына «болгар музыкасы» дигән сүзне бөтен халыкны җәлеп кыла торган бер сихер кебек карыйлар иде. Музыка магазиннары, музыка журналлары, музыка мәктәпләре шул мәсьәлә берлән мәшгуль иде. *_Рус театрларында болгар драмалары иң беренче урында иде. Болгар әдәбияты, болгар әдипләре һәр рус тарафыннан мөкаддәс затлар сайылына иде_**. Хәтта ни кадәр кешеләр үзләренең нәселләре болгарлык булуын дәгъва берлән, болгарилыклары берлән икътимад да итәләр иде. Хаслы русларның[15] түбән сыйнфында бер болгар бизгәге бар иде. Бу сүзләр, белмим, хәкыйкать иде, белмим, «үлгән сыгыр сөтле була»ның хәкыйкатьлеген исбат өчен тагын бер дәлиләт кенә иде. Ни булса да әдәбият һәм халык шуның берлә мәшгуль, һәммә кешегә болгар дигән сүз әллә нинди бер хисен уяндыра иде. Бер болгарга, кая күрсәләр дә, аның берлән танышалар иде. Аның берлән дустланышалар, аңардан үзләренең мәгыйшәтләрен сөйләндерәләр иде. Язу таныган һәр рус болгар *_мөхәррирләренең исемләрен бер мөкаддәс_** итеп йөриләр, аларның тәрҗемәи хальләрендәге вакыйгалары салонларда сөйләнә, аларның көлкеләре һәммә кешене көлдерә иде. Хаслы[16] руслар шул дәрәҗәгә килгәннәр иде. Әгәр шул вакытта яңгы болгар милләте уяначак булса, үзләренең ярты тормышларын бирәләр иде.

Шул ук вакытта русларда икенче бер мәсьәлә дә бар иде. Ул да егерме икенче гасырны көтү иде. Рус халкы бу гъәйдне бик шатлык берлән көтәләр иде. Һәм руслар бу гасырда бик күп эшләр эшләгәнгә үзләренең эшләрен карау хәкыйкатән дә гъәйд булачак иде. Чөнки мәшәккать, хезмәт, гайрәт сарыф кылган бер эше эш булгач, карауның эшләүчегә биргән ләззәтене дөньядагы һичбер ләззәт берлән чагыштыру мөмкин түгелдер. Руслар моны беләләр иде. Бу көннең киләсен, бу сәгадәтнең тизрәк йитүен җаннары, тәннәре берлән көтәләр иде. Һәммә йирдә бәйрәмгә хәзерләнү, һәммә кешегә киләчәктәге шатлыктан ләззәтләнү йөзләренә чыккан иде. Рус гәзитәләрендә, журналларында русларның инсанийәткә, үз милләтләренә нә хезмәт итүләре хакында озын мәкаләләр бизәкли иде.

*_Бу мәкаләләр болгарларның инкыйраз мәкаләсе берлән алды-артлы укылгач, русларның хезмәтләрен тагын ачык күрсәтә, русларда бер мөнкарыйз милләт булу ихтималымыз да бар иде бит_**, [әмма үлеп бетүче] без түгел бит, дип тагы шатланалар иде[17]. Бу тавышлар зурая бара иде. Чөнки бу көн якыная бара иде. Ниһайәт, бер ел була, бер айдан була, бер атнадан була, дип сөйләнә башлады. Ахырда «иртәгә була» көне дә йитте. Һәммә кешедә хәзерләнү, һәммә кешедә бер шатлык, һәммә җәмгыйәттә шул көнгә хәзерләнү, һәммә гәзитәләрдә мәкаләләр хәзерләү, журналларда рәсемләр хәзерләү иде. Җәмгыйәтләр арасында тарих җәмгыйәте Петербургка үзенең әллә ни кадәр әгъзасын җыеп, Болгар хакында булган мәгълүмат нәшер кылыначак, болгарларның музэсе халык[ка] күрсәтеләчәк иде. Болгар әдәбияты[18], болгар музыкасы, халыкка болгар тормышы хакында мәгълүматлар биреләчәк иде. Һәм дә болгарлардан бер кеше дә булсын өчен актыккы болгар Җәгъфәрне чакырганнар иде. Җәгъфәр җәмгыйәткә хальне сөй[лә]мәгән иде. Бикә берлән килергә вәгъдә итте.

Архивта: 9а,б бб., (ТН: 36—37 бб.); моннан соң:

«Руслар шул эшләрне эшләгән вакытта безнең Җәгъфәр абзый да һәрвакыт үз эшендә иде» (ББ, 43 б.).

Тәхрире нөфүс — җан исәбен алу; Имкян — мөмкинлек; Исмасам — ичмасам.

Монкарыйз булу — үлеп бетү; Ашна булу — таныш булу, дус булу; Матлаб булу — таләп ителү; Мөхакәмә кылыну — тикшерелү, хөкем чыгару; Къәльб — йөрәк, күңел; Монганчыга — моңарчыга (моңа кадәр); Ноксанлары — кимчелекләре, җитешсезлекләре; Сайылыну — саналу, исәпләнү; Икътимад (игътимад) — ышану; Хаслы — чын, саф; Янгы — яңы, яңа; Музэ — музей.

## 6

*ББ, 57 б. (өст. 2 юл); КУ, № 2, 118 б. (өст. 25 юл):*
«... игълан кылына торган көн тиз булганга, болгар тарихына хезмәт итә торган нәрсәләрне, болгар әсәрләрен[еңъ] һәммәсен төзәтәләр, карыйлар иде»:

Шуның өчен бу манараны да русларның зур бәйрәмләренә буйыйлар иде, флаклар асарга урынлар хәзерлиләр иде.

Архивта: 10б б. (ТН: 51 б.); моннан соң: «Мәсҗедкә «Болгар көтебханәсе» дип язылган иде» (ББ, 57 б.).

## 7

*ББ, 57 б. (аст. 4 юл); КУ, № 2, 119 б. (өст. 3 юл):*
«Ни бар?! Әллә унтукызынчы гасырның ахырында, егерменче гасырның башында шул кадәр шаулаган Труйскида[н]19 тагын бер тәрәкъкый хәбәреме?! Тәрәккый хәбәре!!...»

19 нчы, 20 [нче] гасырда Болгар йортының һәммә тарафыннан, һәммә сыйнфыннан кешеләр суырган ханәкъә[20] җимерелгән, ике кешене баскан!! Шуның артындин ук монда **бер болгар да булмаганга болгарларның мәсҗедләре, мәдрәсәләре [нең] бәгъзеләре музэга, бәгъзеләре гаҗизханәләр[21], бәгъзеләре газ заводына әверелгәне*** язылган иде. Һәм дә 22 нче гасыр бәйрәме өчен «Болгар альбомы» исемендә бер болгар рәсемләре берлән мөзәййән бер альбом нәшер кылынуы язылган иде. Җәгъфәрнең башына труйскиларның[22] шул кадәр тантаналы хәлләре һәм дә ни кадәр хезмәтләр итүләре, ләкин табигый булган төпсезлекләре хакында эшләре нигә әве[рел]үләре хакында бик озак уйлады. Шул фикерләр берлән торганда бер рус 22 нче гасыр календаре кирәкмиме диде. Тышы мәсҗед берлән, болгар сурәтләре берлән зиннәтләнгән иде. Алды, карарга тотынды. Һәммә йирдә болгар сурәте бар иде. Болгар мөхәррирләре, болгар фәйләсуфлары, музыканлары берлән һәр бите зиннәтләнгән иде. Әгәр болай булмаса иде, бу рәсемләр, бу сурәтләр мине бу көн болай еглатмаенча, һәммә болгарны көлдерер иде. Әгәр болгарлар бу кешеләрнең юлы берлән китсәләр, бу киләчәк 22 нче гасырда безнең бөтен дөньяга бетүемез игълан кылынмас иде. **Бөтен дөньяга безнең бер милләт икәнлегемез, безнең бер бәни бәшәргә нинди файдалар китерүемез мөляхәзә кылыныр иде***. Бу рәсемләр, бу рәсем ийәләренең гали сүзләре һәммә кеше тарафыннан үлә торган милләтне коткарып калдырган дару кебек мөкаддәс бер нәрсә хисап кылыныр иде. Ничә милиун болгарлар боларның рухларына догалар кылырлар иде. Бөтен Болгар галәме бер тантана, шатлык, рәхәттә калыр иде диде. Һәм шул хәзер дә ни өчен ул рәсемле календарларны тотуыны уйлады да: «Болай булуымызга кем сәбәп булды?! Ләгънәт аларга! Ләгънәт!!» — диде.

Архивта: 10а б. (ТН: 52 б.); моннан соң:

«Вакзалдагы халыклар да тиз-тиз йөри башладылар...» (ББ, 57 б.).

---

Кешеләр суырган — кешеләрне (үзенә) җыйган; Мөзәййән — зиннәтләнгән; Бәни бәшәр — кешелек (дөньясы); Мөляхәзә кылу — уйлану, фикер йөртү.

## 8

*ББ, 65 б. (аст. 6 юл); КУ, № 2, 124 б. (аст. 1 юл):*
«Лаләнең тавышының яхшылыгындан (...) һич еглаламаенча торырлык түгел иде»:

Икенче яктан **рус кызларының, рус кенәзләренең үзенең хан[лык]ны*** шул кадәр тәгъзим берлән торулары, ирекле-ирексез Җәгъфәр әфәндегә татар хан-

ларының солтанатларын, бөтен дөньяны дер селкетеп, Йаурупаи Шәркыйдә үзләре генә торуларын, ул мәмләкәте, ул зурлык...

Архивта: 11б б. (ТН: 61 б.); моннан соң:

«Җәгъфәр әфәнде бара-тора бетә-бетә бу көнгә калуын уйлап изелеп киткән иде» (ББ, 65 б.).

---

**Тәгъзим** — олылау, хөрмәтләү; **Йаурупаи Шәркый** — Көнчыгыш Европа.

### 9

*ББ, 66 б. (өст. 14 юл); КУ, № 2, 125 б. (өст. 27 юл):*
«Бу юлы да Җәгъфәр әфәнде шулай бер болгарланып алмакчы булган иде. Һич ашыйсы килмәсә дә, кандитрдан болгар «как-төше» китергән иде. (Бу как-төш егерме беренче гасырларда руслар арасында бик таралган була — М. Г.)»:

**Үзенең өстендә болгар киеме булганга моның булмасе хәзер 20 нче, 19 нчы гасыр болгарының Петербургка «дин» өчен дип, динсезлек өчен падишаһка прашение бирергә килеп, бер швейцарга акчалар биреп киткән дипутат[23] булмәсе төсле булган иде. Җәгъфәр әфәнде үзе дә моны сизә иде**, мөмкин кадәр шул рәвешчә ясарга тырыша иде.*

Архивта: 11 а б. (ТН: 62 б.); моннан соң:

«Килгән русларга болгар тормышын күрсәтләр өчен һәм дә табигате дә шуны теләгән өчен...» (ББ, 66 б.)

### 10

*ББ, 94 б. (аст. 5 юл); КУ, № 2, 146 б. (аст. 3 юл):*
«... Ислам итә дисәңез, Исламга бик зур ифтира, һәм дә кыйамәт көнендә сезне бик зур мәсьүлийәткә и[л]тә торган ифтирадыр»:

Унбиш милиун халыкка нә укырга бер мәдрәсәмез бар, нә бер һөнәр мәктәбемез бар, нә бер гәзитәмез бар. Ике-өч милиун финләрнең ике йөз гәзитә-журналлары бар. Авылларына кадәр мөкәммәл мәктәпләре бар, шәһәрләрдә әгъдади гали мәктәпләре, һөнәр мәктәпләренең исәбе юк[24].

Архивта: 12а б. (ТН: 86 б.); моннан соң:

«Йаурупаның һәр зур мәктәпләрендә әлләникадәр шәкертләр укыйлар» (ББ, 94 б.).

---

**Ифтира** — яла; **Әгъдади** — күп санлы.

### 11

*ББ, 95 б. (аст. 13 юл); КУ, № 2, 147 б. (аст. 21 юл):*
«Качанга кадәр үземезнең шул наданлыгымызны күрмәенчә сукыр төсле мәсләксез хәрәкәт итүемезне саклармыз?»:

Оят безгә, оят! Бөтен дөнья җәһаләт астында сакланган вакытта Болгар кебек мөкәммәл шәһәрләр, шул кадәр монтазыйм идарәләр, шул кадәр бөтен дөнья гизә торган гайрәтле болгарларның угылы түгелме без? Без шулай үк үлдекмени? **Без үземезнең кем икәнлегемезне дә белми йөреп беткәнмез...***

Архивта: 12б б. (ТН: 87 б.), моннан соң:

«Әгәр бездә аз гына гайрәт, аз гына хәмийәт булса, безнең һәр эшемездән ике өлеш файда чыгуында һич шөбһә юктыр» (ББ, 95 б.)

---

**Җәһаләт** — наданлык, томаналык; **Монтазыйм** — тәртипле, законлы.

12

*ББ, 12 б. (өст. 8 юл); КУ, № 1, 118 б. (өст. 1 юл):*

«... Һәммә кешегә русча уку лязим булачак, имеш, мәдрәсәләр ябылачак, мәсҗедләр ябылачак! Балаларны көчләп алып, русча укытачаклар!!! Фәлән шәһәрдә бер кешенең угылы русча укыган икән!..

[..........]*

Фәлән муллага килгән рус та, сезнең дин ни, безнең дин ни, барыбер бит, дигән ди, әман, йарабб, бу ни куркыныч хәбәрләр?!! Менә әле күрше хатыны да кунакка барган йирендән балаларны тәяп киткәнне ишетеп кайткан!!...»

*Күпнокталар китап юлының яртысын кадәр алып тора.

13

*ББ, 20 б. (өст. 3 юл); КУ, № 1, 123 б. (аст. 15 юл):*

«Халкымызның уку ягы бу дәрәҗәдә булса да, ягъни филҗөмлә алга китүдә булса да, тиҗарәт җәһәте бик каты тәнәззел иткән (түбән төшкән — М. Г.) иде. Бик күп фирмалар банкрот булган...

[..........]

Элгәрге сәүдәгәрлек табигате бетмәсә дә, бик кечкенә эш берлән генә кәсеп итә башлаганлар иде. Кызыл мал берлән сату итү, вак-төяк галантерийный әйберләр берлән сәүдә бетмәгән булса да, күбесе лимон, әфлисун, алма, карбыз, иске-москы берлән сату итүдән уза алмыйлар иде...»*

*Вакլануның сәбәбен автор максатчанлык бетүдә, сәүдәгәрләрнең эчкечелеккә, фәхешкә бирелүендә күрә. Цензор тарафыннан төшерелгән юлларның, югарыдагы мисаллардан күренгәнчә, татар сәүдәгәрләренең элек русларга үрнәк булуларына, йәисә патша хөкүмәте тарафыннан аларның эчке базардан кысырыкланып чыгарылуына караган булуы ихтимал.

14

*ББ, 21 б. (аст. 4 юл); КУ, № 1, 125 б. (өст. 4 юл):*

«Әмма голямага килсәк, бу гасырда алардан да бер нәрсә дә чыкмады. Яңа тарикать, яңа ишанлыклар, дөньяга яңа ялган карашлар, гавамны алдарга Иблис үзе белмәгән хәйләләр чыкса да, болардан милләткә килгән файда түгел, гомум милләткә — ишан хәзрәтнең корсагы берлән мәхдүм[25] әфәндене

[..........]

-дән* артмый иде. Дөрес, файда иткән галимнәр, файда иткән мирзалар бар иде. Ләкин алар йөзгә бер түгел, меңгә бер иде...»

*Журналда күпнокталардан соң килгән кушымча -нән дип бирелгән. Ләкин ул иске имлябызда нигездә *-д, н* рәвешендә язылa торган кушымча, нинди сүз һәм аваздан соң килүенә карап, алты вариантта яңгырарга мөмкин: -дан -дән, -тан -тән, -нан -нән. Шуңа күрә язучы аны кешенең арт ягын белдерә торган мәгълүм сүзнең кушымчасы сыйфатында кулланган, дип уйларга, бер рәвештә генә укырга ашыкмыйк. Чөнки китапта ул сүз кыскартып-нитеп тормыйча да тулы килеш язылa (ББ, 4, 83 бб.). Автор аны бер урында гына шулай кыскартып тормагандыр, шәт.

15

*ББ, 23 б. (өст. 12 юл); КУ, № 1, 126 б. (өст. 16 юл):*

«Хатын-кызны укыту, хатыннардан мөгаллимәләр җитештерү 19 нчы гасырда ук башланган булса да[26], бу гасырда чынлап сөйләнә башлады. Билгеле, бу мәсьәлә дә әүвәл муллалар тарафыннан бик каты уклар берлән атылды. Ләкин озакламады, уклары файда итмәгәнне, пурыхлары начар икәнлекне аңладылар. Гомум халыкта боларның кычкырган

сүзләре буш, юк сүз, аткан уклары, туплары халыкны куркытыр өчен генә икәнлеген һәм шарт иткәндән башка әсәре калмавын белделәр. Кызлар өчен мәктәпләр ясый башладылар. Яшьтән тол калып, ничә еллар...

[.........]

эштә гомерен кичергәндән соң эш таба алмаенча, сабак кызлары укытырга тотынган карчыкларга кадәр бетә башлады. Кызларны мөгаллимләрдән укыттыруны да бик чит күрми башладылар».

## 16

*ББ, 51 б. (ост. 12 юл); КУ, № 2, 114 б. (өст. 18 юл):*

«Мөхәррирнең сүзенә караганда, асыл болгарларның инкыйразына сәбәп шул иде, чөнки шул кадәр гайрәтле, эшлекле, тырышчан болгарларны бернигә ярамаслык ялкау сыер төсле, хайванлык дәрәҗәсенә төшерергә ишанлар гына сәбәп булган иде, вә алардагы ут кебек гайрәтләрне сүндерергә дә шул зикерләр[27] башчы булган иде. Шулкадәр тырышчылык вә эшлекчелекне бетерергә дә алар тарафыннан дөнья кую хакында булган сүзләр юлчы булган иде...

[.........]

Әмма бу болгар ишанлары, болгар голямалары[нда], боларның динләрендә «руханийәт» дигән нәрсә булмаенча да торып, халыкның шул кадәр боларның курайларына биюләрен һич тәүҗия кылырга мөмкин түгел. (...) Ни булса да болгарларга болар кадәр зарар иткән сыйныф булмаган !!!»* — сүзләре берлән мәкаләсен бетергән иде...»[28]

---

*Бу куштырнакларга караганда, цензор тарафыннан төшерелгән өзектә шул «цитатаның» башы да булганга охшый.

## 17

*ББ, 55 б. (ост. 3 юл); КУ, № 2, 117 б. (өст. 2 юл):*

(Җәгъфәр, бер ялгыз калган чирле картны күрер өчен, поездда Оренбургка бара.) «Кузләрдән тәгәрәгән энҗе бөртеге кебек яшьләре ашыга-ашыга [аккан] Сакмар суы кебек тиз-тиз йөзендән агалар иде. Һәм тагы ябылган «болгар» мәсьәләсенең ябуын (җөйләрен — М. Г.) үзләренең тозлары берлән эреткән кебек, төрле яктан ача гына баралар иде. Ул ачылган саен аянычлана иде, аянычланган саен аның өчен күз яшьләре күбәя иде.

Озак үтмәде, Җәгъфәр әфәнденең күз алдында Оренбург килеп чыкты. Җәгъфәр әфәнде*...

[.........]

... Җәгъфәр әфәнде ат алып, теге бабай ята торган больницага илтергә кушты. Барып йиткәч тә, бик тиз ашыгып керә башласа да, моны туктаттылар. «Ни кирәк?» — дигән сүзенә бу шул кешенең исемен әйтсә дә, «Кичә үлде һәм күмелде», — диделәр».

---

*Журналда басылган текстта бу «Җәгъфәр әфәнде» гыйбарәсе бөтенләй төшерелгән. Чынлыкта исә юлчының шәһәргә якынлашучы поезддагы халәте белән аның шәһәрдә кылган беренче гамәлләре (ихтимал, кунакханәгә урнашуы) һәм аннары хастаханәгә юнәлүе арасында «тирән бушлык» барлыкка килгән. Түбәндәге өзектән аның хастаханәдән чыгуга ук «номерга» кайтуына игътибар итегез.

## 18

*ББ, 56 б. (ост. 6 юл); КУ, № 2, 117 б. (аст. 8 юл):*

(Хастаханәдән кайтышлый Җәгъфәрнең күзе бер бинага төшә) «һәм бик озак бу бинага карап торганнан соң: «Бу бина, бу мәдрәсә, бу вакыфлар[29] йәһүдиләр, әрмәннәрдә булса иде, моннан нинди файда иткән булырлар иде? Моннан нинди кешеләр чыгарырлар иде, милләтләренә ни хезмәтләр итәрләр иде?» — дип, аларның кылачак эшләрен бик озак уйлагач, номерга (! — М. Г.) китте һәм, анда барып ашап эчкәч тә, юлда тузанланып беткәнгә, мунчага барырга уйлады...

[.........]

Ул шул кешеләрнең, төпсез эштән мәгънә чыкмый, дип, аларга сөйләгәндә, «Аллага тапшырган!» — дигән сүзләрнең хәзер мәгънәсен уйлый иде.

һәм дә хәзер ул кешеләргә ул сүзнең дөресме, түгелме икәнлеген күрсәтәсе килә иде. Шул уй белән мунчадан чыкты»*.

---

*Соңгы өзектән Җәгъфәрнең мунчада кемнәрдер белән ниндидер мәсьәлә буенча фикер алышканлыгын, яисә кайчандыр булып узган бер бәхәсне исенә төшергәнлеген фараз итәргә мөмкин.

## 19

*ББ. 64 б. (өст. 8 юл). КУ. № 2. 123 б. (аст. 12 юл):*
«Бу хисне аңлатырга сүз юк. һәммәгез дә, әлбәттә, үзегез татыгансыз! Болгар музыкасы бу хасыяте берлән һичбер вакытта үз исемен юга[л]тмаячак һәм дә йөрәкләрендән чыккан болгарларның да исемләрен үзе берлән бергә кыяматкә кадәр алып барачактыр!..

[..........]

Бу сүзләргә тагы «браво» тавышлары берлән бөтен дөнья тулды. Мөгаллимне әллә ничә мәртәбә торып рәхмәт укырга мәҗбүр иттеләр»*.

---

*Бер яктан караганда, монда фикер өзелүе, мәгънәгә зарар килүе артык сизелми сыман. Әмма мөгаллимнең туры сөйләме тәмамланмыйча калган. Күпнокталарның китап юлыннан өчтән берен диярлек алып торуы да уйланырга мәҗбүр итә.

## 20

*ББ. 67 б. (өст. 14 юл); КУ. № 2. 126 б. (өст. 26 юл):*
(Җәгъфәргә музейда элекке чор болгарлы мәдәният әһелләренең сурәтләрен күрсәтәләр). Аннары «йөзек салыш уйный торган кызлар, егетләрнең җыены, 19 нчы, 20 нче гасырда «Сабак абыстайның кулына чыбык тотып сабак бирүе», «Болгар кызларының ярыктан, берсе өстенә берсе менеп, егетләрне караулары», «Болгар балаларының әйләнбәйлән уйнавы...»

[..........]*

вә боларга башка да әлләни кадәр рәсемләр бар иде. Җәгъфәр әфәнде бик озак карап йөрде. Бу рәсемләр арасында Җәгъфәр әфәнденең бер дә күрмәгән рәсемләре дә бик күп иде».

---

*Монда да кыскартуга ишарә иткән күпнокталар китап юлының дүрттән бер өлешен тәшкил итәләр. Әмма сүз сөрешенә, мәгънәгә зыян килүе артык сизелми. Шуңа күрә берничә рәсем исеменең төшерелгән булуы ихтималга якынрак.

## 21

*ББ. 71 б. (аст. 4 юл); КУ. № 2. 129 б. (аст. 10 юл):*
(Элек тәртипләр бик каты булып, соңра кинәт артык йомшарып китүдән) «чылбырдан котылган эт кебек болгар хатыннары килеп чыкмышлардыр. һәм дә әбиләренең файдалана алмаган хөрриятләрендән бер юлы файдаланмакчы булып, әхлаксызлыкка салынмышлардыр. 19 нчы, 20 нче, 21 нче гасыр[лар]да боларның хатыннары фәхеш галәмләрендән бик зур роль уйнамышлардыр...

[..........]*

һәм икенче яктан мәгариф тәрәкъкый иткән саен галим кешегә тору ни кадәр җиңел булса, надан кешегә шул кадәр авыр буладыр».

---

*Текст төшерелгән җиргә биш кенә нокта куелган булса да, ике өзек арасындагы «чокырның» шактый тирән булуы шик тудырмаса кирәк.

## 22

*ББ. 79 б. (аст. 14 юл); КУ. № 2. 135 б. (аст. 9 юл):*
«Рәсем кияүгә яңа бирелгән кызның кияүне көтүе иде. Рәсем яхшы эшләнгән иде. Ләкин иске фикер белән кызның йөзен качырган иттереп эшләнгән иде. Җәгъфәр әфәнде моны сын әйтте, өйдә болгар хатыннарының һичбер качмауларын...

[..........]

һәм хөр икәнлекләрен сөйләде. Болардан соң тагы әлләнинди музыкантлар килделәр».

## 23

*ББ, 80 б. (аст. 8 юл); КУ, № 2, 136 б. (аст. 13 юл):*

(Болгар әдәбияты һәм язучыларың мирасы һәм әһәмиятләре тәфсилләп тасвирлангач, докладчы дәвам итә:) «Болгар әдипләре дә, әдәбиятлары кеби, житди кешеләр генә булгангамы, болар арасындан да бәгъзе француз романлары кебек мәгънәсез, кәгазь әрәм иткеч хикәяләр бер дә булмадыгы кеби, болар үзләренең карендәшләре госманлы төрекләре кебек, тормышларын тасвир урнына әллә нинди...

[..........]

ят халык тормышын тасвирлар күренмидер. Хәтта болар әдәбиятында тәрҗемә дә бик аздыр. Болгар әдипләре, тәрҗемәләр милли әдәбиятларга зарар итәчәген белеп, милли рухны саклар өчен, мөмкин кадәр тәрҗемәдән сакланганлардыр».

## 24

*ББ, 81 б. (аст. 6 юл); КУ, № 2, 137 б. (аст. 21 юл):*

(Докладчы сүз ахырында:) «җәмгыять тарафыннан аңарга (Җәгъфәргә — М. Г.) тәкъдим итәр өчен хәзерләнгән «әдәбият профессоры» исеме берлән тәбрик кылам», — диде дә, дөньяны кузгата торган тавышлар арасында урныннан төште.

Җәгъфәр әфәнде...

[..........]

болгар әдәбиятына болгарларның үзләренең иң кирәкмәс эш, эш[с]езләр генә эшли торган нәрсә, дип карауларын уйлап гаҗәпкә калды».

## 25

*ББ, 82 б. (аст. 7 юл); КУ № 2, 138 б. (өст. 19 юл):*

«Җәгъфәр әфәндегә шул җәмгыятьнең «Болгар әдәбият[ы] музее» исемендә болгарларда матбагачылык башлангандан бу көнгә кадәр килгән болгар китаплары илә тулы музейгә керергә рөхсәт бирделәр...

[..........]

Җәгъфәр әфәндегә күрсәтеп йөрергә бик күп кеше үзенең хезмәткә хәзер икәнлеген бәян кылсалар да, Җәгъфәр әфәнде ялгыз гына барачак булды».

## 26

*ББ, 83 б. (өст. беренче юл); КУ, № 2, 138 б. (аст. 24 юл):*

«... Җәгъфәр әфәнде анысына карамаенча, бер китапны алып ачты. Күзенә нифас, хатыннарның рәхемләрендин килә торган кан...

[..........]

дигән сүзне күргәч тә, нинди китап икәнлеген белде»*.

---

*Г. Исхакый әсәренең төп мәгънәсен аңларга теләмәгән Смирнов авторның фикъһ китабына карата булган ирониясен кабул итмәгән булырга охшый...

## 27

*ББ, 85 б. (аст. 13 юл); КУ, № 2, 140 б. (аст. 18 юл):*

«Иң беренче гәзитә мөхәррире, иң беренче милләтпәрвәр, иң беренче хәмийәи миллия уяткан, иң беренче мәңгелек йокыдан уянып, иптәшләрен уяткан, бөтен болгар галәменә мәгариф, гыйлем зыясын (яктылыгын — М. Г.) сачкан Исмәгыйль бәк берлән сөйләшкән кебек булды. Аның берлән болгар мәсьәләләрен мөхакәмә кылган кебек булды. Моның күңеленә Исмәгыйль бәнең...

[..........]

... туңган, каткан башлар «Тәрҗеман»ның электрик йылысы берлән эрүләре, үлгән-беткән җаннарның терелүләре, хәрәкәткә килүләре хаслы (чын, асыл — М. Г.) болгарлар арасында бүген сөйләнгән, бүген макталган һәм макталынырга

сәләхиятле нәрсәнең һәммәсенең дә мөәссисе (нигезләүчесе — М. Г.), сәбәпчесе «Тәрҗеман» мөхәррире икәнлеген уйлап: «Болгарлардан да шул кадәр гали кешеләр чыккан, ник бу беткән соң?» — дип хәйрәткә калды».

## ИСКӘРМӘЛӘР

[1] «Тәрҗеман» — 1883—1918 елларда Кырымда, Бакчасарайда, Исмәгыйль бәк Гаспралы (1851—1914) тарафыннан чыгарылган Русиядәге беренче төрки-татарча газит. Башта ул ике телдә — татарча һәм русча чыккан. Газитнең исеме шуңа да ишарә итә. Болай ике телдә чыгарудан нашир һәм мөхәррир бер яктан төрки-татар укучыларын рус һәм көнбатыш дөньясы белән, икенче тарафтан, русларны мөселманнар тормышы белән таныштыруны максат итеп куйган.

[2] Язучының 1902 елда ерак киләчәк өчен дип, фараз рәвешендә әйтелгән бу фикере 1906—1914 еллар арасында татар вакытлы матбугатында реаль чынбарлыкка әверелгән иде; «Шура» журналы битләрендә оештырылган мәгълүм «тел ярышы» да шул хәрәкәтнең бер чагылышы иде.

[3] Чынлыкта «Тәрҗеман» газите 1918 елда, совет хөкүмәтенең мәгълүм декреты буенча чыгудан туктый.

[4] 1908—1914 еллар арасында «Гасыр» һәм «Васыйтә» нәшриятлары тарафыннан күренекле татар әдипләре, мәдәният әһелләре һәм җәмәгать эшлеклеләренең (мәсәлән, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, һ. Атласый, һ. Максуди һ. б.) фоторәсемнәре «ачык хат» *(открытка)* рәвешендә киң тарала. И. Гаспралының фоторәсемнәре исә, газит-журналлардагы күпсанлы репродукцияләрдән тыш, икe-өч мәртәбә шулай аерым басыла.

[5] «Кабан» һәм «Хәзәр» — автор хыялы белән чыгачак имеш дигән газитләргә бирелгән исем. Кабан Казан шәһәренә ишарә итсә, Хәзәр — Каспий диңгезенең төркичә борынгы исеме иде. (Хәзер азәрбәйҗан телендә сакланган.)

[6] Бу сүзне яңыдан (яңадан) дип укырга да мөмкин.

[7] Сүз шартлы рәвештә укыла.

[8] Моннан соң «аз булып» кебегрәк бер-ике сүз язылмый калганга охшый.

[9] Искә ирексездән «Ильич лампасы» дигән гыйбарә төшә.

[10] Ике сүз шартлырак рәвештә укылды.

[11] Узган гасырда Русиядә гомум җан санын алган чакта, кайбер төбәкләрдәге татарларның, моны чукындыру максаты белән башкарылган бер чара, дип исәпләп, теземгә алынудан баш тартуларына («без татар түгел, без — мөселман», йәисә «без — болгар»дип расалуларына) ишарә.

[12] Моннан соң «нәрсәләр язды» дигән ике сүз артык язылган (дөресрәге сызылмыйча калган) — җөмләнең ахырына карагыз.

[13] Белик — белем (иясе); кәлим — сөйләүче, әңгәмәдәш; ике сүздән автор хәким йәисә оратор дигән мәгънә чыгарырга теләгән төсле.

[14] Руханийе хаканийәт — падишаларча (ягъни бик югары, затлы) рухилык; русча царственная духовность гыйбарәсенә туры килә.

[15] Моннан соң язылган «бу» сүзе (б. у) автор тарафыннан сызылган («түбән» дип язасы сүзнең беренче иҗегенә нокта ялгыш куелудан).

[16] Автографта «часлы» рәвешендә ялгыш язылган.

[17] Сүз «иб» (әлиф + йай + ба) рәвешендә ялгышрак язылган.

[18] Кулъязмада: әдәбиятын.

[19] Труйск — Көньяк Уралдагы (хәзерге Чиләбе өлкәсе) Троицкий шәһәре. Узган гасырның икенче яртысында анда зур-зур татар мәдрәсәләре, күпсанлы руханилары булган, XIX йөз ахыры, XX гасыр башы татар мәдәни үзәкләренең берсе.

[20] Ханәкъә — дәрвишләр, суфыйлар яшәр өчен, гадәттә хәйрия юлы белән тәрбияләнә торган, махсус йорт. Монда галим-голяма җыела торган бина мәгънәсен дә белдерә.

[21] Гаҗизханә — картлар, мәҗрүхлар (инвалидлар) яшәр өчен хәйрия исәбенә тәрбияләнә торган йорт.

[22] Труйскиларның — Троицкийда яшәүчеләрнең.

[23] Кайберәүләрнең милләт һәм дин мәнфәгате өчен дип, башкалага вәкил буларак барып, белем җитмәү һәм җүнләп тел белмәү аркасында зур түрәләр янына үтеп керә алмыйча, вак-төяк чиновникларга ришвәт өләшеп йөрүләренә ишарә.

[24] Язучының финнар һәм Финляндия мисалына мөрәҗәгать итүе очраклы түгел: 1917 елга кадәр Финляндия дә, Русия империясенең составында яшәгән финнар, үзләре аз санлы булсалар да мәгърифәткә ирешкән, дип кинаяли автор.

[25] Мәхдүм — мулла улы. Мәчет-мәдрәсә тотучы руханилар, гадәттә, аң-белемнәренең, әхлак-мораль йөзләренең нинди булуларына карамастан, үз урыннарына мәхдүмнәрне калдырырга тырышканнар. Нәтиҗәдә халыкка, мәхәлләгә рухан һәм дини хезмәт итү эше «хосусый милеккә» әверелә язган.

[26] Яңа дәвер фәнни әдәбиятында хатын-кызлардан мөгаллимәләр әзерләүне бары XX гасыр башына бәйләп карау гадәткә сеңә язган.

[27] Сүз журналда «зәкәр» рәвешендә укылып, ирләрнең җенес огъзасы дип тәрҗемә ителгән. Болай укылган чакта «ата хайваннар» (самец) дип тәрҗемәләү дөресрәк булыр иде. Әмма, ул сүзне «зикер» дип укып, ишаннарның зикер әйтүләре — Алланы искә төшерә-

төшерә экстазга бирелүчәнлеге сыйфатында да аңларга мөмкин. Минемчә, Г. Исхакый бер төрле язылып, ике төрле аңлашыла торган сүзне очраклы гына кулланмаган шикелле.

[28] Фикерләр бер русча журналда басылган «Ишанизм и его последствие» дигән мәкалә авторының сүзләре сыйфатында тәкъдим ителә.

[29] Сүз мәшһүр Хөсәеневләрнең мәктәп-мәдрәсәләре, вакыф биналары хакында.

## III. Эзәрлекләнгән фикерләр

Шулай итеп, югарыда китерелгән материаллардан күренгәнчә, «Ике йөз елдан соң инкыйраз»китабының шактый өлешен цензор В. Д. Смирнов йолкып, тунап алган икән. Икенчерәк итеп әйткәндә, без моңарчы әсәрнең барлык нечкәлекләрен, авторның һәрбер мәсьәлә буенча нәрсәләр әйтергә теләгәнен төгәл белмибез икән. Хәзер дә, китап тукымасыннан йолкып алынган унбер өзек табылгач та, безнең өчен эчтәлекләре билгесез хәлдә кала бирә торган югалтуларның саны кимендә унбишне тәшкил итә. Болар, әлбәттә, мәсьәләнең сан ягын гына күрсәтәләр. Ә аның, кем әйтмешли, сыйфат ягы да бар.

«Сыйфат» дигәч тә, укучы бу сүзнең монда, ягъни әдәби әсәрнең аерым өзекләренә карата шартлы рәвештә кулланылуын аңлагандыр, дип уйлыйм. Төгәлерәк әйткәндә, сүз монда цензорның **ничә урынга** пычак чәнчүе хакында гына түгел, бәлки аның **нинди фикер** һәм **мәгънәләргә** каныгуын ачыклау хакында бара. Моны Смирновның иң элек нәрсәләргә игътибар итүеннән күрергә мөмкин.

Югарыда күрсәтелгәнчә, «Инкыйраз» кульязмасын цензор ике мәртәбә укып чыккан. Беренче кат укыганда ул, күрәсең, «дәүләт» өчен «хәтәр» булып тоелган җирләрне зәңгәр һәм гади карандаш белән тамгалап барган. Аннары, әйтелгәнчә, канлы пычак айкалуын хәтерләткән кызыл каләм эзләре барлыкка килгән. Ягъни, беренче кат укуда ук тамакка сөяк булып кадалган төшләрне бөтен әйләнә-тирәләре белән аркылы-торкылы сызып-кисеп чыккан. Моның шулай икәнлеген югарыда китерелгән өзекләр эчендәге аерым урыннардан, ике ягына да йолдызчыклар куелып, курсив хәрефләр белән җыелган сүзләрдән, җөмләләрдән күрергә мөмкин.



3. «Инкыйраз» китабының 28 нче сәхифәсе; бит уртасындагы күпнокталар цензор кыскартуларын аңлата.

Табылган унбер өзекнең уналты төшендә шундый алдан куелган тамгалар бар. Эчтәлекләре ягыннан, Смирновның иң элек нинди темага игътибар итүенә килгәндә, шундый тамгалы урыннарны ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесен «болгар» (татар) халкының бөтенләй инкыйраз булып, аларның күренекле әһелләре, матди һәм рухи культура истәлекләре тәмам бетү хакындагы хөкемнәр тәшкил итә. Андыйларның саны биш-алтыдан артмый. Икенче төркем исә, әлеге «монкарыйз болгарлар» белән русларның үзара мөнәсәбәтләренә (бербersенә уңай һәм кире тәэсирләре, ярдәмнәре, яхшы мөнәсәбәтләре һ. б.)

багышланган фикерләрдән, дөресрәге әдәби фаразлардан гыйбарәт булып, алары тугыз-ун урында очрый. Ягъни күпчелекне тәшкил итә.

Цензор тарафыннан әсәрне әүвәлге мәртәбә укыган чакта тамгаланган фикерләрнең **беренче төркеме** ни өчен игътибар җәлеп итүен ачыклау артык кыенлык тудырмый. Аларга игътибар итүе белән Смирнов китап авторының үз халкына ясаган иң кырыс кисәтүләрен йомшартырга, көчсезләндерергә теләгән. Г. Исхакый үз укучысының «кабыргага каты төртелүдән» сискәнеп китеп «йокыдан уянуын», инкыйразның ихтималы хакында җитдирәк уйлануын, шуннан чыгып иҗтиһад юлына басуын теләгән. В. Д. Смирнов һәм ул вәкәләтлек иткән иң консерватив рус шовинистлары өчен болгар-татарларның һаман йокыда кала бирүләре күпкә кулайрак һәм мәгъкульрәк иде. Шуңа күрә патша Русиясенең һәм идеологы, һәм ялчысы булган цензорга татарларның үз узганнарын онытуы, Исмәгыйль Гаспралы кебек милләтне уятучы олы шәхесләрне мөмкин кадәр аз белүе, хәтта бөтенләй белмәве мөһим иде. Моның шулай икәнлеген раслый торган характерлы мисалны унберенче өзектән күрергә мөмкин.

Смирновның татар дөньясында «чыккан» (дөресрәге чыгачак дип өмет ителгән) гәзитләр хакындагы әдәби фаразларны да өтекләп кырка баруы халыкта үзанны уятмауга омтылуның гәүдәләнеше иде. Йөз ел дәвамында татарларның үз ана телләрендә гәзит-журнал чыгару омтылышларын тыеп килгән патша хөкүмәтенең реаль сәясәтен цензор җәнаблары, шулай итеп, әдәби әсәрдәге фаразга — фантазиягә карата да күчерә.

Мәчет-мәдрәсәләрнең ябылулары, харап булулары ихтималы хакында да, цензорның, уйлавынча, халыкка әйтергә, аны уйландырырга ярамаган. (Цензор Смирновка, аның бәхетсезлегенә каршы, совет чорында күпчелек мәчет-мәдрәсәләрнең, «музей һәм гаҗизханәләргә» генә түгел, бәлки клуб дип исемләнә торган абзарларга, тимер-томыр, солярка-мазут амбарларына әверелүен күрергә насыйп булмаган.)

Икенче төркемгә караган тамгалар аерата әһәмияткә ия. Алар, югарыда бер әйтелгәнчә, болгар-рус «мөнәсәбәтләренә» карый. Һәм, укучы игътибар иткәндер, икенче өзектәге бер генә очракны исәпкә алмаганда, аларда русларга караган бер начар сүз, бернинди тискәре мөнәсәбәт юк. Киресенчә, киләчәк гасырларның руслары үлеп бетүче мескен болгарларга ярдәм кулын сузарга әзер «гуманлы затлар», башка халыкларны «ихтирам итүче», аларның тарихларын, сәнгатьләрен белергә, аңларга омтылучы кешеләр итеп сурәтләнә. Моның шулай икәнлеген күрер өчен бишенче өзеккә, анда тамгаланган җиде урынга тагын бер кат дикъкать белән күз салып чыгыйк.

Укучы игътибар иткәндер, шәт: Смирновка иң элек болгарларның руслар белән «бергә» торганлыгы, аларның «ватандаш» булганлыклары хакындагы сүзләр ошамаган. Кайда ул кайчандыр русларга «мөгаллим» булган болгарлар-татарларның әсәрләре «русчага тәрҗемә ителү», рус сәхнәләрендә «драмалары уйналу»!.. Ә менә «язу таныган һәр рус болгар мөхәррирләренең исемнәрен бер мөкаддәс итеп йөриләр», дигән сүзләрне укыган чакта профессор-цензорның чыгырдан чыгып гарьләнүендә шигем юк. «Инкыйраз» кульязмасындагы тәгәл бер кәгазьнең һәр ике бите дә тулаемы белән диярлек аркылы-торкылы сызылуы үзе күп нәрсә хакында сөйли...

Дөрес, Смирновның бу гамәлләренә икенчерәк аңлатма бирергә дә мөмкиндер. Йәнәсе цензор-миссионер русларның бүген генә (XX гасыр башында) түгел, хәтта киләчәктә дә татарларны ярата алмаячагын чагылдырган. Ихтимал. Ләкин бер сорау туа: китап авторының русларны шулай яхшы яктан тасвирлауда, әсәр укучыларында аларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләүгә омтылуында нинди начарлык та, кемгә нинди «хәтәр» бар?

Бу сорауга төрлечә җавап бирергә мөмкиндер. Әмма әдәби фараз рәвешендә генә әйтелгән, хыял ителгән әлеге фикергә Смирновның болай аркылы төшүе, андый юлларны, хәтта сәхифәләрне сызып-сызып ташлавы, минемчә, әлләни гаҗәп түгел. Чөнки православие чиркәвенең иң клерикаль бу вәкиле Русиядәге гайре рус, бигрәк тә христиан булмаган халыкларның эреп бетүләренә, юкка чыгуларына бер дә каршы түгел иде. Әмма андый «эреп бетүне» ул китаптагыча мөселман килеш инкыйраз рәвешендә түгел, бәлки христианлашып, руслашып бетү аркылы күз алдына китерә, шулай өмет итә иде. Һәм бу очраклы йәисә шәхси фикер күренеше генә түгел, бәлки патша Русиясенең колониаль сәясәтендәге төп идеологиянең чагылышы. Чөнки иске Рус империясендә беренче планда гайре христиан халыкларны җисмән юк итү — физик геноцид идеясе түгел, ә рухи һәм милли йоту, ягъни мәдәни геноцид омтылышы тора иде. (Мирас булып калган рухи геноцид идеясенә физик геноцид практикасын да өстәү ул большевистик империядә гамәлгә кереп, постбольшевистик хакимият чорында дәвам итә...)

Җыеп әйткәндә, киләчәктә булуы ихтимал кебегрәк тасвирланган болгар-рус мөнәсәбәтләрен яшь Г. Исхакыйның шулай уңай һәм күркәм итеп сурәтләвен Смирновның кискен рәвештә кире кагуы очраклы күренеш түгел икән. Ул православие миссионерларының омтылышы һәм программаларының төгәл чагылышы иде. «Инкыйраз» цензурасы мисалында Смирнов гамәлләренең табигате, шул рәвешчә, әлләни сер булмыйча, шактый җиңел чишелә икән.

Әмма соңгы 60—70 ел эчендә Г. Исхакыйның эшчәнлеге, мирасы һәм гомумән шәхесе тирәсендә барган сәяси, идеологик ыгы-зыгылар белән азмы-күпме дәрәҗәдә таныш укучы өчен аңлашылып җитми торган мәсьәләләр дә булырга мөмкин. Җөмләдән, цензор тарафыннан сызылган сүзләрнең, фикерләрнең асыл мәгънәләре, язылу сәбәпләре. Гел «ак эмигрант», «татар милләтчелегенең баш идеологы», «пролетар интернационализмның, совет властеның явыз дошманы», димәк, Русия һәм руслар белән көрәшкә бөтен гомерен багышлаган кеше сыйфатында дөньяга танытылган берәүнең руслар хакында гел шулай әйбәт сөйләве мөмкин идеме соң? (Безнең чынбарлыкта, бигрәк тә соңгы 40—50 ел эчендә, интернационализм белән руслык арасына тигезлек билгесе куелу хәзер артык сер булмаса кирәк.) Әллә болай кылану язучының цензурадан узар өчен генә рыялануы, ялган сатуы булды микән?!

Сорауларның беренчесенә «әйе!», икенчесенә исә кискен рәвештә «юк!» дип җавап бирер идем.

«Ни өчен?» дигән өченче ихтимал сораугa җавап биргәнче (һәм җавапны нигезлерәк, дәлиллерәк итеп бирер өчен), әсәр текстыннан йолкып алынган өзекләрдән өстенрәк күтәрелеп, «Инкыйраз» китабының үзенә мөрәҗәгать итик. Чөнки анда цензор иләге аша да үтә алган, 1902—1903 еллардагы Г. Исхакыйның уй-хыялларын, иман һәм омтылышларын чагылдыра торган фикерләр, дәлилләр шактый.

Ләкин, китап текстында сакланып калган безнең өчен мөһим андый фактларга күчкәнче, цензор кыскартуларына караган тагын бер мәсьәләгә махсус тукталу зарур.


60—70 нче елларда ук Г. Исхакый мирасының Октябрьгә кадәрге өлешен өйрәнү кирәк дигән фикерне әкренләп, чамалап кына күтәрә башлаган кешеләрнең берсе профессор Ибраһим Нуруллин булды. Шуңа күрә аңа өлкә комитеты җитәкчеләреннән, кыеклап кына булса да, «эләккәләп алгалаган» иде (хәер, андый түрәләрнең кайберләре соңрак актив «исхакыйчылар» сафына да бастылар!..). Ләкин шул иманыннан кайтмаган Ибраһим ага да, үзенчә ихлас коммунист буларак (моны галимнең язучы Фәнзаман Баттал белән булып алган мәгълүм бәхәсеннән дә күрергә мөмкин иде), әдип мирасының революциядән соң тудырылган өлешенә карата сак булып калды. Заманалар кискен үзгәреп, узганга бөтенләй башкача бәя бирүләр башлангач та, ул язучының «эмиграциядәге тормышы һәм эшчәнлеге турында без хәзергә аз беләбез», дип, аның совет чынбарлыгында «милли мәсьәләнең практик рәвештә хәл ителеше белән килешмәвен» икърар кылды. Фикерен ачыклый төшеп, галим «Г. Исхакыйны һәр җәһәттән акларга, турайтырга, шомартырга җыенмыйбыз», дип раслады (КУ, 1990, № 1, 86—87 бб.). Димәк, бу сүзләрнең авторы бездә бәхәссез хакыйкать рәвешендә киң таралган бер караш — Исхакый ул интернационализм, халыклар дуслыгы идеясенең (СССР шартларында руслашу тенденциясенең) дошманы, «ата милләтче» дигән хөкем белән килешә яза иде. Әлбәттә, беренче чиратта иҗат һәм эшчәнлекнең 1917 елдан соңгы өлешенә карата.

Шул ук вакытта профессор И. Нуруллин Г. Исхакый иҗатындагы әлеге сыйфатның элек-электән, «Инкыйраз» язылган чордан ук килүен дә таный төшә сыман. Мәсәлән, әлеге китапның ничек чыгуына, аңа цензор кулы керүенә, нәрсәләрнең сызылу ихтималына карата ул болай яза: «ике йөз елдан соң татар милләтенең юкка чыгуын яки чыгачагын автор шактый күп сәбәпләр белән аңлата. Әмма сәер хәл: шулар арасында *милли-колониаль изү, шуның бер күренеше булган христианлаштыру, ассимиляцияләү кебек сәбәпләр юк.* Ямашев һәм Коләхмәтов белән берлектә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмалап, революциондемократик позициягә баскан Г. Исхакыйның *бу мәсьәләне белмәве һәм «Инкыйраз»да күтәрмәве мөмкин түгел.* Менә ни өчен без кыскартылган урыннар, һәрхәлдә, аларның күпчелеге, һичшиксез, самодержавиенең милли-колониаль политикасы белән тәгеләйме-болаймы бәйле дип әйтә алабыз» (КУ, 1990, № 1, 88 б. Курсив безнеке — М. Г.). Автор үз фикерен икенче урында тагы да куәтли төшә: «безне бер нәрсә сәерсендерә: арада (милләт артта калуының Исхакыйда саналган сәбәпләре арасында — М. Г.) милли-колониаль изү, шуның бер күренеше — көчләп христианлаштыру, ассимиляцияләнү кебек сәбәпләр юк... Текстта

еш очрый торган күп ноктalar бу сорауга җавап була ала...» (Гаяз Исхакый. Зиндан. Казан, 1991, 7 б.).

Шулай итеп, тәнкыйтьче И. Нуруллин язучы Гаяз Исхакыйның колониализмга, конкрет алганда, рус империализмына каршы омтылышларынынф0021Ь гасыр башыннан — «Инкыйраз» чорыннан үк килүенә шикләнми икән.

Әмма, әсәрнең текстыннан Смирнов йолкып алган һәм шактый өлеше хәзер игълан ителә торган өзекләрдән күренгәнчә, галимнең катгый нәтиҗәсе бик үк акланып җитми. Чөнки, югарыда кат-кат күрсәтелгәнчә, 1902—1903 еллардагы Г. Исхакыйда колониализмга, рус империализмына каршы юнәлгән фикерләр юк иде әле. (Кыскартуларның әле табылмаган өлешләрендә дә андый фикерләрнең булуына артык ышанмыйм. Чөнки андый өзекләр төшерелгән урыннарның тематик үзенчәлеге иркен фаразларга киңлек калдырмый.) Киресенчә, бу чорда язучының рус мәдәниятен, рус әдәбиятын, рус характерын бик югары бәяләве, хәтта беркадәре идеаллаштыра төшүе үзен нык сиздерә. Мондый нәтиҗәнең тарихи дөреслеккә якынрак икәнлеген әсәрнең дөньяга чыккан вариантындагы күпләгән фикерләр дә раслый.


۱۱

آنڭ مقدمه‌سنده «انقراض علامتلری» کبی اوڭونان عوامل شونلردر :

۱ — جاهل، متعصب، مردود مسائل اجتماعیه وبالخاصه مسائل دینیه‌ده کندی جوروش فکرلرینی ملته زورله قبول ایتدیرمه‌ن ، ملتك کافه مقدراتنی اداره ایتمك ایسته‌ین وبو حرکتلریله ملی انقراض اوجوروملرینه طوغری سوروکله‌ین «صنف علما» ؛

۲ — دارالعرفان اولان مکتب ومدرسه‌لرك فقدانی ، موجودلرنده تحصیل اولونان معلوماتك هیچ برایشه یارامه‌مسی ومکتب ومدرسه‌لرك اصلاحنه اهمیت ویرلمه‌مسی ؛

۳ — ملته خدمت ایده‌جك ذوات ، آشاغی طبقه‌دن یتشدیکلرندن تامین معیشت قورقوسیله فکرلرنده ثبات واستقلالك یوقلغی ؛

۴ — تاتارلرك ، جهالتلرنی اعتراف ایتمه‌یوب ، آوروپا معارفندن حصه‌مند اولمه‌یه چالیشمامه‌لری ؛

۵ — تاتارلرك ، هر ایشلرنده ، [illegible] کوسترمه‌لری .

«انقراض»ك تصویرینه کوره ، تاتارلرك زنکینلری ، اون طوقوزنجی عصرده دوکونلر وسائر [illegible] پاره‌لرنی [illegible] تلف ایتدیلردی ؛ «صنف علما» [illegible]

4. «Н. Г.» тарафыннан язылып, 1910 елда Истанбулда нәшер ителгән «Шимали төрек әдипләреннән Гаяз Исхакый» исемле китапның 11 нче бите.

Профессор И. Нуруллин кат-кат дөрес күрсәткәнчә, әсәрнең төп пафосы ул милләтнең тәрәккыятен тоткарлый торган, ахыр чиктә аның бетүен тәэмин итә торган биш «манигы тәрәккый»не — биш киртәне, сәбәпне фаш итүеннән гыйбарәт. («Беренчесе — иске фикерле руханилар, бигрәк тә ишанлык; икенчесе — шулар кулындагы мәктәп-мәдрәсәләр; өченчесе — милләткә хезмәт итүчеләрнең фәкыйрьлеге; дүртенчесе — рус мәктәпләрендә укырга теләмәү, рус культурасыннан тайчану; бишенчесе — эшләгән эшләренең нәтиҗәсезлеге, башлау-ташлау»... — Г. Исхакый. Зиндан, 7 б.) Шулардан дүртенче сәбәпкә — русча һәм европача тәгълим-тәрбия һәм тормыш гамәлләренә карата «Инкыйраз»да уздырылган фикерләр аерата игътибарга лаек. Сүзне озакка җибәрмәс өчен, түбәндәге өч мисалны гына күчерү һәм башкаларының урыннарын күрсәтү белән канәгатьләнәм.

1. «...халкымыз арасында иң аңлаган дигәнләремез дә бу көнгә кадәр хөкүмәт мәктәпләрендә (руслар кулындагы һәм нигездә русча укыта торган уку йортларында — М. Г.) укудан качалар һәм качыралар [...] Безнең Русия идарәсенә табигъ булганымызга өч йөз илле ел булса да, шул озын гомердә руслардан һич *файдадан башка нәрсә күрмәсәк тә*, бу көнгә кадәр безнең [...] руслардан әллә нинди куркып, аларның һәммә эшләренә шикләнеп караучыларның да исәбе-хисабы юктыр. Бу безнең *милләтемезнең китеше өчен һәм ватанымызның файдасы өчен* бик зарарлы эштер» (ББ, 4 б.; КУ, № 1, 112 б. Курсив безнеке — М. Г.).

2. «Русларның яңа низам (тәртип — М. Г.) берлән ачылган мәктәпләре балаларны икенче төрле фикер берлән тәрбия кыла башладылар. Һәм озак үтмәде, русларда һәр сыйныфның үзенә күрә мәктәпләре тәэсис ителде (нигезләнде — М. Г.). Рус милләтенә икенче рух бирелде. Рус диган гонван (исем — М. Г.) мөкаддәс сайыла (санала — М. Г.) башлады. Озакламады: һәр эштә яңа фикерле, яңа мәгълүматлы руслар мәйданга чыкты [...] Русларның бу эшләрен күреп, алар артыннан бара башламадык. Бәлки, бабаларымыз гадәтләрен югалтмыйк, дип, кирәкмәс гадәтләремезгә чормалып яттык...» (ББ, 11 б.; КУ, № 1, 117 б.).

3. «Бәгъзе аңлаган кешеләр: безгә хәзер ничек булса [да] укырга кирәк, укытырга кирәк, ни булса да укысын! Ни булса да белсен, рус мәктәпләрендә укырга кирәк! Үз мәктәпләремез юк! Алардан качмаска кирәк! Барыбер качып

котыла алмыйбыз! *Милләтемезне инкыйраздан (!) коткарасымыз килсә,* мотлакан рус мәктәпләрендә уку тиеш!..» (ББ, 17 б.; КУ, № 1, 121 б.. Курсив безнеке — М. Г.)

Әдипнең рус мәгарифенә һәм русча укуга караган фикерләре китапта тагын әллә ничә урында очрый (карагыз: КУ, № 1, 118, 119, 122, 124, 129, 133, 136 бб. һ. б.). Боларның берсендә дә без күрергә теләгән антиколониаль мотивлар юк. Бары бер мәртәбә генә «дөньяның китешен аңламаган» авызлыксыз, агрессив миссионерларның мөселманнарга күрсәткән җәбер-золымнары, тупаслыклары аркасында татарларның үз эчләрендә йомылулары әйтелеп, бу күренеш инкыйразының «ярты сәбәбе» рәвешендә бәяләнгән (ББ, 75 б.; КУ, № 2, 132 б.). Смирнов исә моны сызмаган. Ни өчен? Фикеремчә, мәкере нечкәртелгән, миссионерлыкның «цивилизацияле», ягъни хәйләле төренә өстенлек биргән Н. Ильминскийның шәкерте һәм фикердәше булган Смирновка да Лука Конашевич ишеләрнең эш стильләре ошап бетмәгән, күрәсең.

«Инкыйраз» авторының Русиягә, рус хакимиятенә мөнәсәбәтен күрсәтә һәм аңлата торган фактларның тагын берсе бар. Ул язучының Төркиягә һиҗрәт мәсьәләсенә карашы. Китапта дини изүдән качарга теләгән татарларның күпләп Төркиягә күченүләре тасвирлана. Халыкны бөлгенлеккә салган бу хәрәкәткә — «бу фетнәгә» авторның карашы тулысынча тискәре. Чөнки чит-ят җирләрдә сине сагынып көтеп тормыйлар. Чөнки халык үзе яралган, кавем буларак үзе оешкан җирдә — асыл ватанында яшәргә, шунда тормышын рәтләргә тиеш. Ә татарның төп ватаны ул Идел-Урал. Димәк, Русиядә (ББ, 13—15 бб.; КУ, № 1, 118—119 бб.). Алга таба күрербез, киләчәктә М. Галәү романына азык булырлык бу мотив китапка очраклы гына килеп кермәгән иде.

Җыеп әйткәндә, басылган «Инкыйраз»да колониализмга, рус хакимиятенә турыдан-туры каршы мотивларның булмавы цензор ихтыярына гына бәйле түгел икән. Минемчә, мондый күренешнең сәбәбен, дөресрәге сәбәпләрен, Г. Исхакыйның гомум иҗатыннан, бигрәк тә соңгы чор иҗтимагый-сәяси эшчәнлегеннән эзләргә ярамый. Бәлки аларны әле формалашып бетмәгән яшь әдипнең дөньяга карашыннан табарга кирәк.

## IV. Бәхәссез чыганаклар

Гаяз Исхакый «Инкыйраз»да үзе өчен абруйлы, алларында үзе баш иярлек шәхесләрне әлләни күп атамый. Бары Исмәгыйль бәк Гаспралыны дүртбиш мәртәбә лаеклы рәвештә олылап, Каюм Насыйрины гына бер-ике мәртәбә телгә ала. Совет чорында әллә нинди уйдырма гөнаһларда гаепләнгән И. Гаспралы, асылда, күпкә катлаулы вә тирән шәхес иде. Ул, бөек гуманист һәм ялкынлы мәгърифәтче дә, эзлекле милли патриот һәм гаҗәеп кырыс, зирәк реалист та буларак, Русиядәге төркиләр өчен руслар белән тигез хокуклы халыклар хәлендә аралашып, аң-белем уртаклашып яшәүдән башка юлны күрми иде. Иң киме якын гасырлар өчен шундый юлны мөмкин һәм мәгъкуль саный иде. (Бу хакта карагыз: Исмаил бей Гаспринский. Россия и Восток. Казань, 1993). Шуңа күрә дә аны консерватив руслар күрә алмаган булсалар, хәзерге яңа иман эзләүче рус «евразиячеләре» үзләренең фикердәшләре итеп күрергә тырышалар (карагыз: Мир Льва Гумилева. «Арабески» истории. М., 1994, 369—414 бб.). Чөнки гасырыбызның 20 нче елларында рус интеллектуальләренең бер төркеме арасында туган «евразиячелек» теориясенең кайбер идеяләре XIX йөзнең 80 нче елларында ук Исмәгыйль бәк Гаспралы тарафыннан уртага куелган иде...


Г. Исхакыйның К. Насыйрины искә төшерүенә килсәк, монысы да махсус игътибарга лаек факт. Бу мәгърифәтче, мәгълүм булганча, шактый киң таралган бер карашны: Русиядәге белем безнең өчен житә, шуна күрә гыйлем эзләп чит илләргә барып йөрисе юк, кебек колачы чикләнгән, дөреслеге дә шөбһәле, әмма бик җайлы фикерне алга сөргән шәхес иде. 1902—1903 еллардагы Гаяз Исхакыйның аңын да, минемчә, шундыйрак бер фәлсәфә биләгәнгә охшый.

Мондый хөкемнең гадәти генә фараз булмавын язучының үз сүзләре дә раслый. Әсәрнең хатимәсендәге соңгы абзацтан нәкъ шундый сүзләрне укыйбыз: «Безнең һәрвакыт төзәп куйган фикеремез «Русия мөселманлары» булудыр. Русиядәге ***шул кадәр безгә бирелгән иркенлек, безнең хактагы гъадаләт*** (гаделлекләр — М. Г.) һичбер мәмләкәттә һичбер милләте мәхкүмәгә (ирексез милләткә — М. Г.) бирелмәгәндер. Шулардан файдаланырга гайрәтемез калмаганмыни?.. (КУ, № 2, 148 б. Курсив безнеке — М. Г.).

Бу сүзләрдә К. Насыйриның чикләнгән ышанычы белән И. Гаспралының утопик хыялы бергә кушылган, бергә үрелгәнлеген күрүе артык кыен булмаса кирәк. Соңгы фикер иясенең хезмәтләрендә («Русское мусульманство» һәм «Русско-восточное соглашение») империядәге төрки халыкларга карата «русские мусульмане», «мусульмане России» дигән, бер төшенчәне аңлаткан гыйбарәләр актив хәрәкәткә кертелгән, аталган хезмәтләрдә исә Русия мөселманнарының шул чордагы авыр хәлләре, реаль ихтыяҗлары һәм өметләре яктыртылган иде.

Шулай итеп, «Инкыйраз»ның ахырында әйтелгән концептуаль фикер очраклы гына ычкынган сүз түгел, бәлки чирек гасырдан артык акыл ияләребезнең «башын катырган» актуаль мәсьәләләрнең үзенчәлекле чагылышы икән.

Әмма, ничек кенә булмасын, Русиядә гасырлар буена ажгырып торган милли, дини изү фактларын читләтеп узу, дөресрәге аларны әлегә күрә белмәү, барлык бәла-казаларның чыганагын гел халыкның үз сыйфатларыннан табарга тырышу — гәрчә болар тарихи хакыйкатькә әлләни каршы килмәсәләр дә — барыбер чынбарлыкны берьяклырак аңлау нәтиҗәсе иде. Ләкин бөтен бәла-казаларга кирәкле дәваны да бары тик рус мәгарифчелегенә сыенудан, русча укудан гына эзләү дә — гәрчә монда да дөреслек бар һәм шактый булган хәлдә — мәсьәләне шулай ук тарайтып куя иде. Йомыклыкны, рус тәэсиреннән качуны күрә белү белән бергә мондый гамәлләргә халыкны нәрсәләр, нинди сәбәпләр этәргән булуын да аңлау, ягъни Русиядәге реаль милли изүнең нәтиҗәләрен дә исәпкә алу зарур иде.


برهان شرفکه یازوچیسندن
بولاک عیاض ۲۸ مای
1918
محمد عیاض الاسحاقی نڭ مجموعه آثاری.
زلیخه
محمد عیاض الاسحاقی

5. «Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмүгаи асаре» сериясендә басылган «Зөләйха» драмасының титул бите (Мәскәү, «Шәрекъ басмаханәсе», 1918). Битнең өске ягында — әдипнең автографы: *«Борһан Шәрәфкә язучысыннан бүләк. Гаяз. 28 май, 1918».*

Әсәр исеменнән соң түбәндәге сүзләрне укырга мөмкин: *«Драма 5 пәрдәдә, 6 манзарада.*

*Вакыйга алтмышынчы елларда.*

*Беренче мәртәбә язылa башланды 1907 нче елда Чистай төрмәсендә. 2 нче мәртәбә Истанбулда Кандилледә, 1911 нче елда. Язылып бетте Петроградта 1912 нче елда гыйнвар башында.*

*Нашире: Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый».*

Кыскасы, XX гасыр башы мәдәни һәм иҗтимагый фикеребезнең алтын маясын тәшкил иткән татар әдәби хәрәкәтнең елга башында торучы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре язылган чакта аның авторы 1907—1917 еллардагы көчле публицист Гаяз Исхакый да, Октябрьдән соңгы кайнар сәясәтче Исхакый-Иделле дә түгел иде әле. 24 яшьлек егет чакта ук язган бер әсәре белән 1905 елдан соң килгән шагыйрь-язучыларыбызның һәммәсе өчен диярлек дәрт-ялкын, тема-материал биргән булса да.

Әсәрнең бу хосусыятенә игътибар иткән профессор И. Нуруллин «Инкыйраз»ны хаклы рәвештә Гогольнең «Шинель»енә охшата. Әһәмиятләре белән шулайрак булса да, бу ике әсәрнең язмышлары белән иҗтимагый юнәлешләрендә сизелерлек аерма да бар иде. Икенчерәк итеп әйткәндә, әдәбиятыбызның «алтын гасыры» өчен елга башы — илһам чыганагы булган «Инкыйраз» Гаяз Исхакыйның киләчәктә канат җәячәк үз иҗаты өчен дә, аның катлаулы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге һәм гел көрәштән торган фаҗигале язмышы өчен дә үзенчәлекле «кереш сүз», йәисә дәртле бер «увертюра» иде.

Мәсьәләгә шулай төрле яклап тукталу, аның чикләнгән якларын күрсәтү белән мин Г. Исхакый иҗатының башлангыч чорын әһәмият ягыннан кечерәйтергә дә, йәисә күккә чөеп күтәрергә дә җыенмыйм. Теләгем бер генә: аның иҗатын бербөтен һәм уникаль күренеш сыйфатында кабул иткән хәлдә дә, шул бай

эшчәнлекнең һәр дәверенә карата һәм тарихи дөрес, һәм кешечә гадел мөнәсәбәт урнаштыру. Без, кызганычка каршы, күп очракта бер әсәрне бөтен иҗаттан аера алмыйча, йәисә конкрет иҗаттагы бер дәвернең күренешләрен, сыйфатларын шул иҗатның барлык чорларына күчереп карарга яратабыз. (Әйтик, Г. Тукай бөек шагыйрь икән, аның һәр әйткән сүзе, һәр хөкеме соңгы хакыйкать булырга тиеш; әйтик, 1911—1922 елләрдагы Галимҗан Ибраһимов һичшиксез мөстәкыйль фикерле зур әдип икән, аның соңгы чор яраклашулары да «иҗат казанышы» кебек бәяләнсен; әйтик, Һади Такташның муллалар турындагы бер-ике шигырендә гаделсезлек бар икән, аның шагыйрьлеге дә тулаем шик астына алына; әйтик, «Моабит дәфтәре» чыннан да уникаль җәүһәр булса, Муса Җәлилнең сугышка кадәрге көйле агиткалары да классикага керергә тиеш һ. б.)

Гаяз Исхакый мирасына карата да бездә шундыйрак мөнәсәбәт хөкем сөреп килде. Хәзер дә андый сөремнән азат түгелбез, дип әйтер идем.

Югарыда бер урында 60—70 нче елларда әдипнең мирасын, ичмасам, аның революциягә кадәрге өлешен әдәби һәм гыйльми хәрәкәткә кайтару хакында талпынышлар булуы әйтелгән иде. Хрущев «җепшеклегеннән» соң Иван Бунин һ. б. берничә рус әдипләренең элекке чор мираслары кайтарылган кебек. Әмма бу чикләнгән омтылышка да юл куелмаган иде. Өстәлләргә шап-шап итеп сугып, а ың «ата милләтче», димәк, руслыкның дошманы, хәтта берьюлы өч-дүрт илнең шпионы булуы хакындагы уйдырмалар кабатланып, авызлар томаланган иде.

«Шпионлык» мәсьәләсен чын шымчы һәм җасусларның үз намусларына калдырам. Мин монда Г. Исхакыйның барлык чор эшчәнлегенә бер тамга — гел милләтчелек тамгасы сугылу фактына кыскача тукталыр идем.

Дөрес, Беренче рус инкыйлабыннан соң Исхакыйның милли мәсьәләләр буенча карашларының радикальләшүе, кискенләшүе шик тудырмый. (Мондый борылышка конкрет нәрсәләрнең сәбәп булуын алга таба күрербез.) 1917—1918 еллар арасындагы милли-азатлык хәрәкәте чорында аның карашлары кичергән үзгәрешләр беркадәре мәгълүм. 1919 елдан соңгы Исхакый-Иделле исә тагы да үзгәрәк. Әмма шушы сыйфатларның һәммәсендә диярлек 1905 елга кадәрге Исхакыйга күчерә алабызмы, моңа нигез җитәме?

Минемчә, юк. «Инкыйраз»ның цензор кыскартулары табылу күп нәрсәгә ачыклык кертте. Ул әсәрдән берәүләрнең антиколониаль мотивлар, икенчеләренең исә гел «русларга каршылык» эзләүләренең дөрес булмавын күрдек. Бер сүз белән әйткәндә, 1905 (ихтимал, 1904) елга кадәрге Гаяз Исхакый әле Русиягә дә, рус мәдәни дөньясына да ихлас өмет белән караган, киләчәктәге нормаль хезмәттәшлеккә бар күңелдән ышанган чын мәгърифәтче рухындагы язучы, фикер иясе иде.

Әдипнең ул вакыттагы рухында мәгърифәтчелек идеяләре хакимлек итүне, ә мәгърифәтчелекнең исә объектив сәбәпләр аркасында һәм чикләнгән садә, һәм шул садәлеге, беркатлылыгы нәтиҗәсендә ихлас, кайнар булуын күрүе кыен түгел. Моның өчен югарыда күчерелгән язучы фикерләренең түбәндәге өлешләренә игътибар итәргә мөмкин. Мәсәлән, керештәге «өч йөз илле ел» дәвамында **«файдадан башка нәрсә күрмәү»** һәм хатимдәге **«безгә бирелгән иркенлек, безнең хактагы гаделлекләр»** хакындагы сүзләр үзләре ни тора!

Әйе, «Инкыйраз»ны язган чактагы Гаяз соңрак иҗтимагый көрәш мәйданында каләмен — кылычка, уй-фикерен — янартауга, әсәрләрен исә ут-ялкынга әверелдергән, сайлап алган юнәлешенә соңгы сулышына кадәр фидаиларча тугърылыклы булып калган Гаяз Исхакый-Иделледән бик нык, бик тә нык аерыла иде.

Шулай да «Инкыйраз» белән бергә аның киләчәктәге күпкырлы әдәби, мәдәни, иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлеге башланып китүе дә игълан ителгән иде. Бөтен татар дөньясын сискәндергән, уйландырган, тетрәндергән, аңлы һәм сәләтле, булдыклы ир-егетләрне төрле юнәлештәге иҗади вә интеллектуаль эшчәнлеккә этәргән серле, шул ук вакытта шомлы тавыш белән яңгыраган игълан иде ул...

Шушы Тавыш белән Тукайдан алып, бөтен гасыр башы татар әдәбиятында клерикализмга, мөтәгассиблеккә каршы юргылган бер тәгәл агым барлыкка килгән иде. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр...», «Ишан» шигырьләреннән алып, Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт»енә кадәр. Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ыннан, «Бүләк өчен»еннән алып, «Безнең шәһәр серләре»нә, тагын бераздан Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»енә хәтле. «Китмибез»дән башлап, Мәхмүт Галәү-Мәрҗанинең «Мөһаҗирләр»енә кадәр. «Таң вакыты» кайнар көрсенүе белән «Кораб» соравында да — 1904 елда яңгыраган шул ук Тавышның үзенчәлекле кайтавазы...

«Әл-Гасрелҗәдит», «Әл-Ислах» гәзитләре белән «Мәктәп», «Шура», «Ан», «Сөембикә» журналларында да «Инкыйраз»да беренче тапкыр кабыргасы белән куелган сорауларга җавап эзләнде. Нигә без артта калган, нигә без ярлы, томана мәсьәләләре. Җөмләдән, «милләтнең яртысы» булган хатын-кызларны тәрбияләү мәсьәләсе дә. Ижбуби мәдрәсәсе белән «Галия»дә башкарылган мәктәпне яңарту омтылышына, бәхәссез казанышларына кадәр...

Солтан Габәши, аталы-уллы Заһид һәм Фәрит Яруллиннарның, ниһаять, Салих Сәйдәш белән Рөтсәм Яхиннарның кабатланмас олы моңнарында да «Инкыйраз»дагы Җәгъфәр әфәндenең (укы — Гаяз хәлфәнең...) «болгар музыкасы»на булган гашыйклыгы белән сагышларына җавап яңгырый сыман. Болгар тематикасына караган рәсемнәр хакындагы сәхифәләрне укыган чакта Бакый Урманче әсәрләре дә ирексездән күз алдыннан уза. Узалар.

Дөрес, тормышта тәэсирнең турыдан-турысы белән янәшәдә кыеклап суккannары да була. Бу хакыйкатьне икърар итсәк, «Инкыйраз» белән Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыяте» арасында да уртаклыкны күрү кыен түгел. Әгәр беренчесендә «ихтималга» публицистик рухта кисәтү ясалган булса, икенчесендә «нәтиҗәгә» сәнгатьчә «йомгак» ясала...

Болай санап чыгу белән күпләгән мәшһүр әсәрләребез һәм тарихи күренешләребезнең «дөньяга килүләрен», эчтәлек-рухларын бер «Инкыйраз»га гына кайтарырга, шуның белән тукталып калырга җыенмыйм, әлбәттә. Гәрчә шулай эшләргә дә дәлилләр шактый булса да. Андый санау алымы белән мин гасыр башы мәдәни-иҗтимагый хәятебезне бер зур симфоник оркестр сыйфатында күз алдына китерергә тырышам. Һәм шул оркестр башкарып, бер яңгыратып алган, башка кабатланмас симфониябезнең «кереш» өлешендә, иң элек, сискәндергеч труба авазы булып яңгыраган әлеге Тавышны — «Инкыйраз» тавышын ишеткәндәй булам. «Васыятьнең» моңы исә шул симфониянең йомгагындагы ялгыз флейтаның үксүе сыман...

Әйе, 96 битле генә бер кечкенә Китап күтәргән Тавыш. Әле садә мәгърифәтчелек ихласлыгыннан арынмаган, мәгәр мәгърифәтчелек дигән олы күренешнең барлык нигезләргә нигез булу идеясен иҗтимагый аң, сәяси көрәш югарылыгына күтәргән көчле Тавыш...

## V. Сәер сәбәпләр



Гаяз Исхакый.

Мәгърифәтче Гаяз хәлфәнең зур җәмәгать эшлеклесе, әдип һәм публицист Гаяз Исхакый дәрәҗәсенә кайчан үсеп җитүен махсус аныкларга кирәк. «Русия мөселманларының» берсе, ләкин тулы хокуклысы булып яшәргә хыял иткән Гаяз әфәнде Исхакыйның милли-азатлык идеясенә баш-аягы белән чумуын, мәгърифәтчелек иллюзиясеннән арынып, радикаль милләтпәрвәр кырыслыгына кайчан, ничек күтәрелүен, үзгәрүен аныклау да мөһим мәсьәлә.

Күпләгән кардәш һәм күрше халыклар белән у р т а к  в а т а н д а яшәү хокукыннан мәхрүм булган *русияле* Исхакыйның, үз илен вә үз халкын үлеп яратканы хәлдә, «бөтендөнья гражданины» Исхакый-Иделлегә — гомерлек сөргенгә әверелүе дә үзенә аерым проблема. Нинди сәбәпләр нәтиҗәсендә, кемнәрнең гаебе һәм тәэсире белән кайчан һәм ничек үзгәргән ул? Ниһаять, «кем»гә үзгәргән?!.

Моның өше үзгәрүләрне безнең тарихыбызда бер Гаяз Исхакый гына кичермәгән. Андый язмышка Йосыф Акчура белән Садрый Максудый да, Габделбари Баттал белән Фуад Туктар да, ниһаять, Зәки Вәлиди дә дучар ителгәннәр

иде. Болардан эшчәнлекләренең гомум әһәмияте һәм колачы ягыннан Г. Исхакый белән бер Й. Акчура гына ярыша ала. С. Максудый исә якын килә яза. Г. Баттал белән Ф. Туктар андый чагыштыруга үзләре дә дәгъвә итмәгәннәр. Гел ярышучы көндәш сыйфатында бары З. Вәлиди генә йөргән. (Кулга-кул тотышып, уртак дошман булган империализмга каршы көрәшәсе урынга, сепаратизм юлын сайлаган Вәлидине Исхакый гомере буена кичерә алмаган...)

Барысының да чит илгә — Төркиягә барып егылуларына бер күренеш — Россия чынбарлыгының «сәер» үзенчәлеге, анда большевистик режим урнашып, канлы диктатура килүе сәбәп иде.

Шулай да боларның язмышлары, гамәл һәм төп иманнары, дөресрәге, аларның реальләшүләре арасында аерма да бар. Бигрәк тә Акчура һәм Исхакый арасында.

Йосыф Акчура да (1876—1935) халкын үзенчә яраткан, аның якты киләчәге, хөрлеге өчен көрәшкә бил баглаган зат иде. 1905 елгы революциядән соң ул канатланып, актив иҗтимагый эшкә тотына. Казандагы беренче татар газитләреннән «Казан мөхбире»н чыгаруда катнаша. Рус кадетлары (конституцион демократлары) белән хезмәттәшлеккә кереп, лигитим юлдан бара-бара татар һәм башка төрки халыкларның руслар белән тигез хокукка — нормаль хокукка ирешүен өмет итә. Башта ул кадетларның милли мәсьәлә өлкәсендәге ялган вәгъдәләренә ышана, ичмасам, 1905 елгы ачы тәҗрибәдән соң Русиядә дә, ниһаять, аңлы көчләр хәрәкәткә килгәндер дип уйлый. Әмма, мондый омтылышның империячел Русия өчен тормышка ашмас хыял гына икәнлеген аңлагач (ни гаҗәптер, бик тиз аңлап алгач!), барысына да кул селтәп, Төркиягә һиҗрәт итә. 1908 елда ук. Анда исә — «яшь төрекләр» хәрәкәте. Нигездән черегән мөтәгассиб Госманлы солтанлыгының җимерелүе. Прогрессив рухлы реалист яшь офицерларның хакимияткә килүе. Мостафа Кәмал Ататөрек белән хезмәттәшлек. Парламент әгъзасы. Госманлы империясе харабаларында Яңа Төркияне — дөньяви рухлы Төркия җөмһүриятен төзүгә катнашу... Бер сүз белән әйткәндә, төрек дөньясында тәмам үз булып, тәмам төрекләшеп бетү...

С. Максудый белән З. Вәлиди дә, ватаннарыннан чагыштырмача соңрак китүләренә карамастан, шундый ук диярлек үзгәрү кичерәләр: яңа шартларга яраклашалар — төрекләшәләр. Депутат та булалар, профессорлык дәрәҗәсеннән дә ахыргача файдаланалар. Гәрчә элекке иманнары, кылган реаль гамәлләре, рухлары ягыннан башка-башка булсалар да.

Ә менә Мөхәммәт Гаяз Исхакый исә бөтенләй икенче юнәлеш белән китә. Төп юлыннан тайпылмый, төп иманына тамчы да хыянәт итми. Гомумтөркилек идеясен нигездә кире какмаган хәлдә, ул а х ы р г а ч а  т а т а р  б у л ы п  к а л а бирә. Тиз генә Төркиягә барып сыенасы, җайлырак кәсеп эзлисе урынга ул Русия читенә якын өлкәләрдәге качак милләттәшләре арасында көрәш эшен дәвам итә. Финляндия, Польша, Манжурия, Корея, Япония, тагын Польша, Германиядә...

Кайда барып чыкса да ул таркау милләттәшләрен оештыру, аларга җәмгыятьләр төзү, мәктәпләр ачу, газит-журналлар чыгару фикере белән янып яши. Бары, Совет хөкүмәтенең соравы буенча Гитлер тарафыннан сөрелгәч кенә, Төркиягә барып егыла. (Г. Исхакыйны элегрәк фашистлар белән хезмәттәшлек иткән дип раслауларның оятсыз яла булуы хәзер тулысынча исбатланды.)

Тик монда да, Төркиядә дә ул үзе булып, татар булып кала. Татар дигән халыкның барлыгы рәсми танылмаган, «дөньяда бер генә төрек милләте бар», аның «эчендә» генә «шималь төрекләре», йәисә «казанлылар» булуы ихтимал ише тоталитар аң хөкем сөргән шартларда. Башкалар кебек бераз үзгәреп, җирле таләпләргә чак кына яраклашып, шуның нәтиҗәсендә тормыш хәлләрен үзгәртү мөмкинлекләре булган хәлдә дә — үзгәрмичә кала. Үз ана телендә әдәби әсәрләр язуны дәвам итә. Матди ихтыяҗ, ярлылык кочагында калып, рухи ялгызлык чорнап алган килеш тә, Идел-Урал якларының азатлыгын үзенчә күз алдына китерә...

Шул хыял белән, шул сыйфатларын саклаган килеш, дөньядан үтә...

Ниһаять, шуңа да игътибар итик: 1917 елдан соң эмиграциягә киткән татар милләтпәрвәрләре элек гадәти автономчылар — бер ил, «бер бөтен Рәсәй» эчендә үз халкына бәләкәй генә мөстәкыйльлек сораган эшлекләр иде. Аларны сепаратизм, ягъни тотал мөстәкыйльлек юлына — Идел-Урал дәүләте идеясенә шул чикләнгән автономияне дә бирмәү этәрде.

Татар сепаратистларын, шулай итеп, рус дәүләт әһелләре үз куллары белән ясаган иде.

Беренче нәүбәттә һәм ахыр чиктә милли-мәдәни автономия идеясен кискен рәвештә кире каккан большевиклар сәбәпче иде мондый үзгәрешкә.

... Без моңарчы Гаяз Исхакый хакында сүз чыкса, аны Русия һәм русларга карата дошманлык хисен һич үзгәртмәгән милли радикал — тар милләтче сыйфатында күз алдына китерергә күнектек. Шулай уйларга күнектерделәр. Иҗат һәм эшчәнлегенең соңгы чорлары өчен мондый бәя беркадәре туры килә яза кебек. Әгәр үз халкыңны ихлас ярату, аның ихтыяҗларын белү, кимчелекләрен бетерү теләге, аның мәнфәгатьләре өчен гомереңне багышлау шулай «милләтчелек» булса, ул, һичшиксез, милләтче иде. Г. Исхакый — Бөтен Русия чынбарлыгыннан, рус шовинизмыннан тәмам йөз чөергән, большевистик режимның икейөзлелеген, реакционлыгын аңлап алган, беренче планга иң элек үз халкының мәнфәгатьләрен куйган чын милләтпәрвәр. Һичнинди бәхәссез. Тик «яхшымы» бу, әллә «начармы» — анысы бөтенләй ... өченче мәсьәлә. Кемнең проблемага ничек карап, нинди мәнфәгатьләрдән чыгып бәяләвенә, әлеге төшенчәгә нинди мәгънә салуына бәйле мәсьәлә. Берәүләр андый сыйфатны «милләтче» дип, начар мәгънә салып тамгаласалар, икенчеләре «милли патриотлык» дип олылыйлар. Нинди реаль көчкә, нинди «дус-ишкә» ия булуларына карап...

Әмма, югарыда китерелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, чынбарлыкта дөньяга башкачарак карап, туган халкының «китешен» икенчерәк күз алдына китергән, **уртак ватан** булган Русиядәге **ватандашлары**, җөмләдән руслар белән дә аралашып, ярдәмләшеп яшәү мөмкин дип уйлаган, шуңа ихлас ышанган элекке Гаяз Исхакый да булган икән. «Инкыйраз» язылган чордагы Исхакый. Үз халкының бәхетсезлегендә, ярлылыгында, наданлыгында башкаларны, шул исәптән русларны да гаепләмәгән, гаепләргә омтылмаган Исхакый. (Бу фактлар Г. Исхакыйны гомумән русларның дошманы итеп сыйфатлауның йә исә шыр наданлык, йәки явыз мәкерлелек күренеше икәнлеген раслый. Бездә моның икесе дә урын алды бугай...)

Шулай, моңарчы «һич үзгәрмәгән» дип расланган Исхакыебез, чынлыкта, кискен үзгәреш тә кичергән иде. Ләкин чит илләргә киткәч, яңа шартларга яраклашу максатыннан чыгып түгел, бәлки үзенең туган җирендә — үзенең ватаны дип исәпләгән Русиядә кичергән иде ул андый кискен үзгәрешне. Яраклашу өчен түгел, бәлки үзенең туган халкының мәнфәгатьләренә, ихтыяҗларына булмыш шартларны яраклаштыру — үзгәртү өчен барлыкка килгән үзгәреш бу.

Шул ук вакытта мондый үзгәрешләрне барлыкка китергән, дөресрәге аларның тууларын котылгысыз итә торган объектив шартларның, сәбәпләрнең дә булуы ап-ачык. Русиядә алар колбиләүчелек системасыннан, ягъни крепостнойлыктан, утыз-кырык ел элек кенә чыккан (бәлки әле чыгып бетмәгән) системаның катып калган консервативлыгыннан, тискәрелегеннән, хокук дигән нәрсәнең халыклар өчен дә, аерым шәхесләргә карата да бөтенләй булмавыннан гыйбарәт иде.

Ниһаять, рус хөкүмәтенең, рус җәмгыятенең хаким катлауларындагы бер гаҗәеп сәләтнең, искитәрлек талантның да булуы бәхәссез — үз тарафдарларының башын ашау, табигый һәм ихтимал дуслардан дошман ясау таланты. Көчсезләрдән гел коллык таләп итү сәләте; көчлерәкләр алдында үзе колчылык күрсәтү табигате. Михаил Лермонтов әйтмешли, «юылмаган... коллар иле, хуҗалар иле»нең чак кына калкыган башларга сугып, аларны кырка бару гадәте...

Бу сүзләрнең коры дәгъва, нигезсез яла булмавын күрсәтер өчен илнең, дәүләтнең тарихына мөрәҗәгать итик. Тик әлләни ерак үткәнгә — XVI гасырдагы канлы бәрелешләргә, Казан халкын кыруларга, XVII—XVIII йөзләрдәге рухи геноцид фактларына кадәр кайтып тормыйк. Монда 1902—1903 еллардан соң, ягъни «файдадан башка нәрсә күрмәү» һәм «безгә бирелгән иркенлек, гаделлекләр» язылгач барлыкка килгән кайбер күренешләргә мөрәҗәгать итү дә җитә. Әмма, сүзне артык күпкә җибәрмәс өчен, фактларны санап чыгу юлыннан файдаланыйк. Мәсәлән:

— дәүләт башыннан рәхим-шәфкать, ярдәм сорап килгән, поп Гапонга ияреияре «падишаһ хәзрәтләренең гаделлегенә» ихлас ышанган Петербург халкын 1905 елдагы ату факты;

— мәгълүм манифест биргән чикләнгән ирекләкне дә ел ярымнан соң кире тартып ала башлау;

— реакция елларында халыкны, бигрәк тә рус булмаган халыкларны эзлекле рәвештә кысырыклау, җөмләдән 1910—1912 елларда «панисламизм хәрәкәте» дигән уйдырма яла ярдәмендә алдынгы мәктәп-мәдрәсәләрне туздыру, татар зыялыларының һәммәсен диярлек кара исемлеккә кертеп, аларда тентүләр ясау, кулга алулар;

— эсэрлар, ягъни «социал-революционерлар» исемендәге крестьяннарның, ягъни күпчелек халыкның интересын яклаучы партия сафына якынрак торганы өчен күпләгән зыялылар белән бергә Г. Исхакыйның үзен дә туктаусыз эзәрлек-

ләү: кулга алу, төрмәгә ябу, сөргенгә куу, тагын төрмә, тагын гәзитне ябу, тагын сөрелү;

— аннары, демократик революция нәтиҗәсендә патшаны бәреп төшереп, халыкчан җәмгыять төзүгә өмет чаткылары кабына башлаганда гына, икенче бәла-каза — Думаларны куута күнеккән шартларда халык сайлаган законлы Учредительное собраниене дә тарату, шул рәвешчә хакимияткә большевиклар килү; нәтиҗәдә ватандашлар, ягъни гражданнар сугышы өчен җирлек тудырылу һ. б. һ. б.

Мондый кыргый гамәлләр — җәмгыятьне дистәләгән елларга, бәлкем, гасырлар буена нормаль үсештән тоткарлый торган сәер сәбәпләр яңа заман дөньясында иң элек Русиядә тормышка ашты...

## VI. Күңелсез нәтиҗәләр

Узганны, андагы сәер хәлләрне аңлар өчен бүгенге көнгә күз салу да файдалы. Чөнки бүгенге күренешләр узганның сыйфатларын, аларның асыл табигатен калкурак итеп күрсәтә алалар.

Русия хөкүмәтенең, рус җәмгыяте житәкчеләренең дустан дошман ясау сәләте мисалларын совет чорындагы фактлардан да теләгәнчә табарга мөмкин. 1917 елда хакимияткә законсыз юл белән килгән, аннары ныгып алган большевиклар да, гәрчә үзләрен чын гуманистлар, тар миллилектән өстен демократлар дип игълан итсәләр дә, ахыр чиктә Русия империалистларының тугрылыклы варислары булып чыктылар. Дөресрәге, шуңа әверелеп калдылар. Хәтта алардан уздырып та җибәрделәр. Дәлил кирәксә, рәхим итегез:

— үз фикерләре булганы өчен алдынгы җәмәгать һәм фән эшлеклеләрен йөзәрләп-йөзәрләп илдән сөрү, дистәләп-дистәләп руханиларны ату;

— эшлекле даирәләрне кысрыклап, тураклап, халыкның һәммә катламнарын да пролетариатка тигезлибез дип, кешеләрне милексез люмпеннарга әверелдерү;

— халыкларны союздаш, автоном республикалар, автоном өлкәләр дигән, ләкин һичнинди автономсыз төрләргә, ягъни хокуксыз сортларга аеру («тигезләр арасындагы беренче», икенче, өченче, дүртенче сортлы һәм гомумән «сортсыз», ягъни бернинди милли «автономиясез» халыкларга бүлгәләү сәясәте); шул рәвешчә халыкларда бер-берсенә карата көнчелек хисен тәрбияли торган, асылда «бүлгәләү һәм хакимлек итү» максатына хезмәт итә торган империячел сәясәт уздырылу;

— мондый гаделсез һәм шовинистик тәртипләр белән чак кына килешмәүчеләрне милләтчелектә, шпионлыкта һ. б. гөнаһларда гаепләп эзәрлекләү, җәзалау;

— милли шовинизм өстенә сыйнфый шовинизм сәясәтен дә уздырып, большевикларның халыкка җир бирү хакындагы сүзләренә ышанган крестьяннарның иң эшчән катламнарын меңәрләп кыру, ахыр чиктә гади халыкны колхоз крепостнойларына әверелдерү;

— 20 нче елларда Идел буенда, аннары Казагыстанда, аннары Украинада махсус оештырылган ачлык казалары ярдәмендә халыкны буйсындырып тоту (камчыдан соң перәннек...);

— 30 нчы еллардагы канлы репрессияләр — һәр халыкның, һәр милләтнең миллионлаган иң аңлы, иң эшчән, иң фикерле вәкилләрен кырып-себереп юк итү;

— 40 нчы елларда Кырым татарларыннан башлап, чичәннәргә, калмыкларга кадәр әллә ничә халыкны төп ватаннарыннан сөрү, яртылаш кырып бетерү (хәзергә кадәр «акладык» дип алдап йөртү);

— 60—80 нче елларда илгә бераз гына тәртип, халык өчен аз гына иркенлек, ил башындагы түрәләрдән бераз намуслылык, узгандагы явызлыкларга карата гадел хөкем — тәүбә сораучыларны диссидент, дип тамгалап, илдән-ватаннан сөрүләр яки җүләрләр йортына ябып, махсус дарулар белән акылдаң яздырулар һ. б. һ. б.

Нәтиҗәдә нәрсә булды?

Гел куркып яшәгән кешеләрдә — битарафлык; шул битарафлык аша хакимиятвласть башында торучыларга карата дошманлык, нәфрәт хисе тәрбияләнде.

Мондый нәтиҗәләр белән килешмәүчеләр булса, аларга түбәндәге сорауларны бирик:

— Әллә мондый өзлексез җәбер-золым астында яшәгән халыкта, халыкларда, «партия һәм халык бердәм!» дигән шигарь-лозунг адым саен эленеп, көн саен яңгырап торуга карамыйча, шул партиягә карата мәхәббәт тәрбияләндеме?

— Әгәр тәрбияләнде, дип әйтергә теләсәк, ул чакта ГКЧП дигән әкәмәт фетнә кисәгеннән соң элекке өлкә секретаренең сыңар кулы белән бер селтәнүеннән бөтен КПССның ишелеп төшүен, пыр тузып таралуын ничек аңларга?

— Халыкның, җөмләдән 18 миллион коммунистның да шул указга карата битараф калуын ничек бәяләргә?!

Коммунистлар хакында сүз чыккан икән, шуны да өздереп әйтергә кирәк. Монда сүз утопик коммунизм идеясенә ихлас күңелдән ышанган, үз намусларына хәл кадәри тап төшермәгән, аңлы рәвештә вөҗданын вакламаган аерым кешеләр хакында бармый. Унсигез миллион арасында андыйларның йөз меңләгән, хәтта аннан да күбрәк булуы бик ихтимал. Җитәкче большевиклар арасында да аерым якты шәхесләрнең булуы шик тудырмый. Шунысы да характерлы: андыйлар белән аерым-аерым эш итсәң, нормаль фикер йөртүче, дөньяга аек күз белән караучы әйбәт кешеләрне дә күрерсең. Әмма алар бергә җыелып, берәр мәсьәләне «коллектив белән» тикшереп, карар кабул итә башласалар... Гафу итегез, рыядан, ялганнан, күз буяудан, колчылык психологиясе белән дөреслеккә, гаделлеккә, димәк, Кеше һәм Шәхескә төкереп караудан башка бернәрсә дә күрмәссез...

Шулай итеп, монда сүз коммунизм идеяләренә ихлас ышанган аерым кешеләр турында бармый. Сүз монда «күпчелек исеменнән» дигән булып, бер уч җитәкчеләрнең барлык кешеләрне тигезләгән, шулай тигезләү аркылы һәммәсен буйсындырган, теләгәнчә изгән Система хакында бара. Битлеге, шигарь-лозунглары яңа булса да, асылы һәм тарихи традициясе крепостнойлык чорыннан килә торган тоталитар Система турында...

ГКЧП фетнәсе көннәрендә күпчелек, хәтта барлык коммунист-большевикларның, әле генә әйтелгәнчә, пыр тузып юкка чыгулары, күпчелегенең «яу качкач» батырланып, билетларын ыргытып ташлаулары, яндырып йөрү күренешләре дә шул крепостнойлык агымыннан килә иде. Чөнки унсигез миллион коммунистның иң кимендә унбиш миллионы «күпчелекнең фикеренә» буйсынып яшәүләре белән азчылык җитәкчеләр (номенклатура!) кул астындагы крепостнойлар иде. Хәтта елга бер килә торган «Юрьев көне» дә булмаган бөтенләй хокуксыз крепостнойлар. Ә крепостнойларны, тарихтан белгәнебезчә, мужикларның «гадел падишасы» Пугачев та ахыргача берләштерә алмаган...

Система галиҗәнабларының кешеләр аңына ясаган тискәре тәэсиренә тагын бер мисал. 1993 елның декабрендәге сайлауларны искә төшерик. Аерым партияләрдән иң күп тавышны җыючы ул тагын яулап алуларны башларга, тагын камчы һәм төрмә тәртипләрен кертергә, йөнә милләтләр, халыклар хокукын чикләргә вәгъдәләр иткән Жириновский партиясе булды.

Нәрсә бу? Очраклылыкмы?

Юк, әлбәттә. Бу — люмпенлашкан халыкның качып таралган большевиклардан өмет өзеп, әмма Сталин чорындагы артка тибә-тибә эшләтүче, ачтан үлмәслек дәрәҗәдә генә ашатучы, арзан аракы да чыгаргалап торучы каты куллы хуҗаны сагынуы иде.

Сайлау нәтиҗәләре билгеле булгач, хәтерлисездер, бер сакаллы демократ агай телевизордан кычкырып җибәрде: «Россия, ты одурела!» Йәнәсе, акылыңны җуйдың...

Хәзер уйлап карасаң, мәгълүм публицистның мөрәҗәгатендә дөреслектән бигрәк хата күбрәк икән. Булмаган нәрсәне югалтып буламы соң? Җөмләдән, халыкның коммунизм идеясенә «тугрылыгын» да?!.

Бары ел ярым-ике ел чамасы узгач кына бер уч таланган, рәнҗетелгән, кыерсытылган пенсионерларның башын кушып, өч-дүрт идеалист яки авантюрист кисәге биш-алты коммунистлар партиясен «тергезеп», һәрберсе, үзара ызгышкан килеш, элекке КПССның варислыгына дәгъва итә икән, монда, гафу итегез, бернинди җитдиятлек юк. Алар элеккеге бердәм һәм чыннан да кодрәтле, тоталитар партиянең күләгәләре генә. Хәтта боларның кайберләре вакытлы рәвештә властька кайта алсалар да...

Әйе, Русия империясенең тулаем гаделсез, тоталитар (самодержавие!), шовинистлык һәм гуманлыкка каршы сәясәтен дәвам иткән, хәтта үстереп җибәргән большевиклар партиясе дә үз тарафдарларыннан дошман ясауга гаҗәеп сәләтле бер көч иде.

Советлар Союзының, аның нигезе һәм арка сөяге булган, аңа үзенең традициясен биргән Русиянең дә дустан дошман ясый торган бу сыйфатын халыкара

масштабта (Корея, Чехословакия, Венгрия, кайбер Африка дәүләтләре, Әфганстан ... һ. б. мисалында) тасвирлап тормыйм.

Шулай да бер фактны — үз халкы сайлаган, үз дәүләтенең байрагын күтәргән парламентка ату вакыйгасын читләтеп узып булмас. Моңа да гаҗәпләнмик; биредә хакимият башында торучылар (Үзәк комитет, генераль секретарь, президент...) һәрвакыт дөрес һәм хаклы дигән үзаң ярылып ята. Алар каршында кешеләр генә түгел, халыкка вәкаләтлек иткән депутатлар төркеме дә чүп кенә!

Тагын искә төшерик: дәүләт Думаларының бер-бер артлы куылуы, Учредительное собраниенең таркатылуы, СССР халык депутатларының язмышы, Россия парламентының Ак йортта атылуы — дәвамлы традиция...

Битлек, сүз һәм декорацияләр үзгәргән булса да, тарихи традиция, үзаң һәм Система галиҗәнаблары элеккечә кала бирүнең нәтиҗәсе иде бу.

Тарихи тамырлы Системаның аерым шәхесләрдән дә ничек итеп үзенә дошманнар тудыру сәләтенә, шуңа искитмәле «осталыгына» берничә мисал.

Әллә туган иленең мәнфәгате өчен кирәк, дип ихлас ышанып, аны водород бомбасы белән коралландырган, мәгәр соңрак Кеше хокукын яклап чыккан Андрей Сахаров элек-электән үк СССРның һәм Русиянең дошманы идеме?

Илдән сөрелгән мәшһүр музыкант Ростроповичның дәүләт җимерелгән көннәрдә дәртләнә-дәртләнә мәйданнарда дирижерлык итүен ничек аңларга? Әллә ул да элек-электән үк сәясәтче идеме?

Ә Солженицын? Сөргеннәрдән соң дус булып кайттымы ул элекке СССР белән хәзерге Русия хакимият ияләренә?..

Совет армиясе сафларында тәрбияләнгән, белеме һәм сәләте белән СССР, димәк, Русиянең дә хәрби көчләрендә генерал дәрәҗәсенә ирешкән, еракка оча торган бомбардировщиклар дивизиясенә җитәкчелек иткән Җәүһәр Дудаев та элек Русиянең кан дошманы түгел иде. Әгәр рус кызына өйләнгән совет офицеры Дудаевта Рус дәүләтенә, русларга карата аз гына да дошманлык хисе булган булса, ГРУ — хәрби КГБ «егетләре» аны атом бомбалары белән коралланган зур очкычлар дивизиясенә түгел, бәлки гади пулеметлы истребительләр янына да якын җибәрмәсләр иде. Ә совет тәртипләре һәм русияле чынбарлык аннан дәүләтнең, империянең кан дошманы ясады. Хәтта аны халык герое итте. Үз кулы белән.

Ике-өч гасыр дәвам иткән геноцид нәтиҗәсендә болай да бер уч калган чичән халкын киләчәктә бөтенләй кырылып бетү чигенә китереп куюга өлеш кертүче Дудаевта да кеше кыйммәтенә төкереп карый торган совет һәм русияле җитәкчеләргә хас мөнәсәбәтне чалымлау артык кыен булмаса кирәк. Гәрчә, Русия хөкүмәтенең чикләнмәгән кирелеге, кансызлыгы, кыргыйлыгы фонында президент Дудаев милли азатлык өчен көрәш каһарманына әверелгән хәлдә дә...

Русиядә элек-электән хөкем сөргән Кешегә, аның шәхси дәрәҗәсенә, шуның аша халыкларга, аерым милләтләргә дә карата ящәп килгән шушы сыйфат — «дәүләт интересы», «бердәм һәм бүленмәс мәмләкәт мәнфәгате» дип Кешене санга сукмау, кешеләрне изү, халыкларга төкереп карау сыйфаты аның дошманнарын тудыра килде, булдыра килде.

Арттыра барачак.

Тарихны тирән белмәгән кайбер укучыда бу сүзләрдән шундый сорауның туувы ихтимал: болай дустан дошман ясауның фәлсәфи, идеологик нигезе нәрсәдән гыйбарәт соң?

Бер сүз белән әйткәндә, ул һәр *и к е  и м п е р и я д ә* дә халыкларның, бигрәк тә вак милләтләрнең аңлы, хөр, ягъни нормаль шартларда яшәргә омтылуларына чик куярга теләүдән гыйбарәт. Мондый омтылышның иске Русия шартлары өчен реальлеген Казан епископы Алексийның 1909 елда әйткән сүзләре раслый. Империя өчен, ди ул, гадәти ислам динен пропагандалау гына куркыныч түгел. Бәлки: «страшно... нечто другое. Это следующее: с 1905 го в среде татар стало развиваться религиозное оживление, выразившееся в устройстве мечетей, в открытии школ, в издании и раздаче листков, газет и прочее... Всюду у татар видно религиозное оживление, *и н т е р е с  к  п р о с в е щ е н и ю  и  в о о б щ е  с т р е м л е н и е  к  с о з н а т е л ь н о й  р а з у м н о й  ж и з н и*» (бу документны Петербургтагы архивтан доцент М. Мәхмүтова тапкан: ЦГИА РФ, 821 фонд, 8 нче тасвир, эш № 800, 43 б. Курсив безнеке — М. Г.).

Епископ Алексийның рухи агасы булган В. Д. Смирновны да Гаяз Исхакый «Инкыйраз»ындагы аңлы, хөр тормышка омтылыш идеяләре куркыткан. Аерма шунда гына: Казан епископы хөрлеккә, аңлылыкка омтылуның «куркынычлыгын» 1905 елдан соңгы күренеш дип бәяләсә, цензор Смирнов рус империясе өчен андый «хәвеф-хәтәрнең» барлыгын Бишенче елга кадәр үк «тойган», шуңа каршы конкрет чаралар да күрә башлаган икән.

Игътибарлы укучы сизгәндер: цензор Смирнов һәм епископ Алексий фикерләре совет хакимияте чорында сүздән гамәлгә әверелгән иде. Милли язулар бетерелү, милли мәктәпләр ябылу, төрле халыкларның ана телләрендә матбугат кыскартылу шуның нәтиҗәсе.

Шулай итеп, бүгенге көнебездә ерак һәм якын узганыбызның, ә узган тормыш фактларында бүгенге көн сыйфатларыбыз чагыла икән.

Димәк, узган белән хәзерге аерылгысыз күренеш — бербөтен процесс икән.

Аларның икесеннән исә Киләчәк үсеп чыга...

Дәүләт Кеше һәм Халык өчен түгел, бәлки Кеше һәм Халыклар дәүләт өчен булганда һәрвакыт шулай дәвам итәчәк. Һәрвакыт кеше — колга, йәисә дошманга әвереләчәк.

Гаяз Исхакый да, иҗатын үз халкының, үз иленең улы, «Русия мөселманнарының» бер вәкиле буларак башлаган; шулай калырга теләгән Гаяз Исхакыйны да Русия чынбарлыгы үз кулы белән дошман ясаган иде. Кол булып калырга теләмәгәне, намус сатарга җыенмаганы өчен — колониаль Русиянең, тоталитар СССРның дошманына әверелдерелгән иде ул.

Әгәр бу күңелсез нәтиҗәләр белән килешмәсәң, кадерле укучым, әдипнең бөтен тормыш юлын күзәтеп чык. Юл уңаенда йөз елдан артык татарча гәзит-журнал чыгару тирәсендә барган өзлексез көрәшне дә искә төшер. 1905 елдан соң җанлана башлаган милли-мәдәни агарту эшләренең — беркемгә бернинди дошманлык тотмаган хәрәкәтнең — эзәрлекләнүенә, алдынгы мәдрәсәләрнең туздырылуына да күз сал. Төрмә, сөрген, тагын сөрген һәм төрмә фактларын да онытма. 1910—1912 елларда барган «панисламизм хәрәкәтенә (?)» каршы көрәш дип, бармактан суырып чыгарган яла нәтиҗәсендәге репрессияләр хакында да уйланып ал...

Уйла.

* * *

Шулай итеп, күптәннән бирле төрле яклап бәяләнгән, дөресрәге төрлечә гаепләр белән тамгаланган Гаяз Исхакый иҗатының, ул калдырган мирасның әле җентекләп өйрәнеләсе, ныклап тикшереләсе мәсьәләләре шактый икән. Без исә бу юнәлештә бер әсәр язмышы мисалында гына ул иҗатның аерым чорына игътибар белән карарга тырыштык. Бер тамчыдан бөтен күл суының сыйфаты беленгән шикелле, бер әсәрнең үзенчәлегеннән дә катлаулы олы язмышның казанышларын да, фаҗигасен дә күзалларга мөмкин икән.

Әгәр башка әсәрләренең язылу, дөньяга чыгу тарихларын җентекләбрәк өйрәнсәк, һәр мәсьәләгә әтрафлабрак карасак, Гаяз Исхакый иҗатының тагын яңа кырлары ялтырап, моңарчы исәпкә алынмаган тагын яңа сыйфатлары ачылыр иде. Андый сыйфатларның күбрәк ачылуы, үз нәүбәтендә, узган тарихыбызны төгәлрәк аңлап, хәзерге хәлебез белән киләчәк язмышыбыз хакында да җитдирәк уйланырга өстәмә нигез бирер иде.

Гаяз Исхакый иҗаты ул, катлаулы язмышыбызның көзгесе буларак, мондый махсус игътибарга, һичшиксез, лаек.

## Йомгактан соңгы тәкъдим

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» язылып бетеп дөньяга чыккач узган 80—90 ел эчендә бөек әсәрдә тасвирланган, булуы ихтимал хәвеф-хәтәрнең кайбер өлешләре тормышка аша башлаган шикелле. Моның шулай икәнлеге шул әсәрнең телен (1902—1904 еллар өчен гаять гади, халыкчан телне!) бүгенге татар яшьләренең зур өлеше генә түгел, хәтта Татарстандагы урта буын кешеләренең дә шактые укый алмавы, авыррак аңлавы белән раслана. «Милли газета» дип рус телендә гәзитләр чыгарырга мәҗбүр диаспоралар хакында әйтәсе дә юк...

Бу уңай белән төрлечә фаразлар корып, төрлечә фикер йөртергә, якага-яка килеп бәхәсләшергә дә мөмкин. Әмма мин, башка җәелеп тормыйча, бер тәкъдим белән чикләнергә телим. Ул түбәндәгедән гыйбарәт.

**Әгәр без халкыбызның «йокыга киткән» өлешенең, кечерәк булса да, бер төркеме уянуын, «Инкыйраз» кисәткән бәла-казалар хакында уйлануын, азмыкүпме чаралар күрүен теләсәк, ул әсәрне халыкка якынрак итәргә тиешбез. Моның бер юлы, минемчә, әсәр телен адаптацияләп, ягъни урта дәрәҗәле укучыларыбыз**

**да җиңелрәк аңларлык рәвештә эшкәртеп, күп тиражда бастырып чыгару, махсус аңлатмалар белән киңрәк даирәләрдә тарату.**

**Мондый изге эшне халкын ихлас яраткан хәзерге эшмәкәрләребез канат астына алсыннар иде.**

**Әсәрнең телен, аның мәгънәсенә зарар китермичә, эшкәртүдән, текстны абзацларга бүлүдән курыкмыйк. Алдынгы Европа илләрендә элекке чор әсәрләренә карата мондый алым күптән кулланыла (мәсәлән, Англиядә Шекспир әсәрләренең шулай адаптацияләнгән вариантлары еш басыла).**

**Классик язучының теленә тимибез, дип, классик әсәрне халыктан читтәрәк тотмасак иде. Сүз Гаяз Исхакый әсәрләренең күптомлыгы, аерым фәнни басмалары хакында түгел, ә киң катлам укучыларга якынрак махсус басмасы хакында бара.**

**Халкын ихлас яраткан, аның мәнфәгатенә бөтен гомерен багышлап, шул юлда, шул көрәшкә үзен корбан иткән бөек әдипнең мондый якынлыкка — безнең тарафтан чак кына җитди мөнәсәбәткә бөтен хакы бар.**

*Казан, 1995*
*25 январь — 2 март*

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

# Заһидә Бурнашеваның тууына 100 ел

Аның әдәби псевдонимы — «Гыйффәт туташ». Шул имза белән басыла беренче шигырьләре, әдәби җәмәгатьчелектә һәм халык хәтерендә шулай кала. Үз вакытында көндәлек матбугатта, замандашларының язмаларында шактый чагылып кала бу исем. Әйтик, Ш. Бабичның «Китабеннас»ында. Татар шигърендә ул — беренче Гыйффәт туташ. Икенчесе — Сания Гыйффәт, Октябрьдән соң эмиграциядә яшәгән шагыйрә, мөгълүм галим З. Кадыйри хатыны... Шулай, гыйффәтлелек (пакь, таза, ару булу) — татар хатын-кызларының күркәм сыйфаты.

Гыйффәт туташ — Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева 1895 елның 19 октябрендә Рязань өлкәсенең Әҗе авылында туа. Бай сәүдәгәр кызы. Яшьтән белемгә омтыла, әдәбиятка тартыла. Нәтиҗәдә, 1913—1915 елларда Мәскәүдә олуг әдип Г. Исхакый мөхәррирлегендә чыгучы «Ил», «Сүз» газеталарында әлеге псевдоним белән шигырьләре басыла.

Әти-әниләренә бу ошамый һәм яшь кыз өен ташлап чыгып китә. Бу турыда матбугатта үз вакытында шактый шаулыйлар... 1915—1917 елларда бер-бер артлы «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле өч китабы дөнья күреп, шагыйрә шактый ук популярлык казана... Шигырьләрдә ул — Тукай мәктәбе укучысы, аны дәвам итүче. Татар хатын-кызлары язмышын җырлаучы. Лирик шагыйрә...

1917 елдан соң ул — Урта Азиядә. Башта Сәмәрканд шәһәрендә, аннан Төркмәнстан, Кыргызстан илләрендә. Партия һәм мәгариф, матбугат эше, кардәш халыкларда мәдәни эшчеләр, укытучылар тәрбияләү... «Почет билгесе» ордены, медальләр, грамоталар белән бүләкләнү...

Менә болар инде — шагыйрәнең иҗтимагый тормышы, совет заманы «иҗат җимешләре». Дөрестән дә, бу чорда ул аз яза. 1919—1921 елларда Казанда татар һәм урыс телләрендә хикәяләр китабын гына бастыра. Шигырьләре күренми...

1952 елда, пенсиягә чыккач, ул Казанга күчеп кайта. 1971 елда аның «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» исемле китабы дөнья күрде.

Заһидә Бурнашева — Гыйффәт туташ 1977 елның 5 ноябрендә Казанда вафат. Шигырьләре «Татар поэзия антологиясе»нең ике басмасында да бар.

**Рәдиф ГАТАШ.**



## МӘГЪСҮМ НАСЫЙБУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

# АК ТЕЛӘКНЕ ҖИЛКӘН ИТЕП

Язучыга бай биография кирәк, диләр. Бу, чыннан да, шулайдыр. Гыйбрәтле, катлаулы үткәнең булу әсәрләрендә мәүзуг төрлелеген, тормышны киң һәм тирән чагылдыруны тәэмин итә. Янә дә моның әһәмияте шунда: андый шәхес кешеләрне нечкәләбрәк аңлый. Бу хәл исә аңа аларның холыкфигыльләрен, үз-үзләрен тотышын, фикер сөрешләрен яшәешнең үзендәгечә бай һәм каршылыклы итеп гәүдәләндерергә мөмкинлек бирә.

Мәгъсүм Насыйбуллинга килгәндә, ул — үзе бер роман каһарманы булырлык шәхес.

Татар дөньясының һәр тарафы башкаларыннан кайсы да булса ягы белән аерылып торган шикелле, М. Насыйбуллин туган Кукмара төбәгенең дә үзенә хас асыл сыйфатлары бар. Кукмара. Бу сүзнең мәгънәсе «күк төсле зәңгәр тау чәчәге» дигәнгә туры килә. Исеменә лаек булырдай бик матур табигатьле як ул! Ләкин аның төп горурлыгы — кешеләре. Бу төбәктә дөньяның иң гүзәл, иң булдыклы, иң талантлы, иң сәләтле кешеләре генә яшидер кебек тоела миңа. Элек-электән үк мәдәниятле тараф булып саналган ул. Мәчкәрә мәдрәсәсе үзе генә дә ни тора. Хәер, мәктәп-мәдрәсә, мәчет һәр авылда булган. Хәзер дә күпчелек авылларда мәчет манаралары күтәрелде. Әйе, Кукмара ягы — иманлы як. Ә туган авылы Байлангар исә әдип күңеленә аеруча якын.

Булачак язучы дөньяга килгән 1925 елның 15 октябре гадәти генә көн булган кебек... Әмма 15 октябрь... (иске стиль белән 2 октябрь). Шулай дип яздым да, ирексездән тукталып калдым. Чү, бу татар халкы тарихында бик хәсрәтле көн түгелме соң? Әйе, нәкъ шул көнне 443 ел элек, Явыз Иван татар халкын канга батырган. Шуннан соң, Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «күпме михнәт күргән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән». Мәгъсүм Нәҗип улы да, әбибабайлардан ишетеп, безнең мескен хәлебез өчен кечкенәдән үк әрнеп үсә.

Аның күңеленә тагын бер аянычлы хатирә уелган. Белә-белгәннән бирле ул өлкәннәрнең матур итеп, бизәкләп язылган китапларга хөрмәт белән карауларын күңеленә сеңдереп үсә. Кайчан шуларны кулга алып укый башлармын дип хыяллана. Әмма аңа дүрт-биш яшь чагында бу изге язулы китаплар, ни сәбәптәндер, шүрлектән югалалар, аларны кеше күзе төшмәслек аулак урыннарга яшерәләр. Кирәк чагында, тәрәзә пәрдәләрен тартып, яшертен генә укый башлыйлар. Моны ул соңыннан гына аңлый: илдә дингә каршы каты көрәш оештырылган икән. Озак та үтми; каяндыр читтән китертелгән исерекбашлар мәчет манарасын кыеп ташлыйлар.

...Җидееллык мәктәптә Яңалиф белән укыган малай, 1942 елда үзе Сазтамак мәктәбенең башлангыч сыйныфында укытучы булып эшли башлагач, ни өчен әле мин балаларга урыс хәрефе өйрәтергә тиеш, дип баш ваткан. Бу вакытта кешеләрнең башында икенче зур хәсрәт — 1941 елның июненнән бирле ил гаять авыр сугыш алып бара. Мәгъсүмнәр буыны фронтка киткәннәрне алмаштыра. Ул да, көнне төнгә ялгап, колхозда эшли. Шуның өстенә, мәктәптә дә укыта. Чират, ниһаять, аңа да җитә. 1943 елның сентябрендә аны да армиягә алалар. Кече командирлар курсын үтә. Аннан соң Белоруссия фронты, Литва, Көнчыгыш Пруссия җирләре... М. Насыйбуллин шушы мәхшәрләрдә исән калганлыгына хәзер дә аптырап куя. Егерме ике яшендә армиядән кайтканда, ул инде дөньяга үз карашлы, күп нәрсәне тирәнтен аңлый торган егет була. Аны иң газаплаганы илдә хөкем сөргән гаделсезлекләрнең артык күплеге иде.

Тормышта нинди юл сайларга? Укытучылык юлыннан китәргәме? Балалар белән эшләү аңа рәхәт иде. Алар күңеленә игелекле фикерләр сеңдерү — изге эш. Ләкин, игелекле булсын өчен, синең сүзләрең дөрес булырга тиеш. Ул азмы-күпме укыту тәҗрибәсеннән шуны аңлады: укытучыларга хакыйкатьне сөйләргә рөхсәт булмаячак. Юк, Мәгъсүм балалар алдында икейөзле була алмый. Сугыш аңа моңа кадәр аңламаган күп нәрсәләрне төшендерде. Аның башына шундый уй килә: бу гаделсезлекләргә каршы көрәшеп булмыймы? Гаепсез кешеләрне төрмәгә ябуларга чик куярга мөмкин түгелме? Тик ничек итеп? Нигә үзеңә югары белемле хокукчы булмаска? Шул ният белән ул икееллык хокук мәктәбенә укырга килә. Аннан соң Свердловск каласында хокук институтын тәмамлый. Свердловск, Көкшетау өлкәсендә прокуратура органнарында эшли. Көндәлек хезмәтендә аңа бик күп кешеләр белән очрашырга туры килә, шуңа күрә аларның күңелен аңлау өчен теоретик нигезне тагын да камилләштерә төшәргә кирәклеген аңлый һәм шул ук Свердловскидагы педагогия институтының филология бүлеген дә тәмамлый. Әкренләп иҗат эшенә керешүенең нәкъ шушы елларга туры килүе бер дә гаҗәп түгел.

Кайда гына яшәмәсен һәм эшләмәсен, М. Насыйбуллин үзенең туган теленә, халкыбызның рухына, яшәү рәвешенә турылыклы булып кала. Казаннан газит-журналлар, китаплар алдыра. Милләттәшләр белән аралашу, туган җыр-моңнарны тыңлау аңа җан рәхәте, рухи ләззәт бирә. Байлангар мәктәбендә татарча белем алу аңа, байтак еллар урыс чолганышында яшәргә туры килсә дә, гомер буена милләтенең бер вәкиле булып калырга ярдәм итә. Алтмышынчы еллар башында, татар телен мәктәпләрдән кысрыклап чыгаруга йөз тотып, татар балаларын урысча укытуга күчерә башлагач, Мәгъсүм Нәҗип улының йөрәге нык әрни. Ана телендә укыту булмагач, тел онытыла, башка тел — ул чит рух дигән сүз. Балаларга урыс исемнәре кушу гадәткә керә бара. Дин бетә. Менә ничек астыртын алып барыла икән ул аерым милләтләрне юк итү! Үзгәртеп җибәрәсе иде бит мондый хәлне. Ләкин милли мәсьәлә турында авыз да ачарга ирек бирмиләр. Ихтимал, Татарстан янсә Башкортстан кебек милли җөмһүриятләрнең берсендә яшәсә, әлеге мәсьәләләргә якынрак торыр иде. Башкортстанга эшкә билгеләнү турындагы тәкъдимне алгач, ул шатланып бетә алмый. Уфа, ни дисәң дә, элек-электән татар мәдәни үзәкләренең берсе, әйтергә кирәк, шактый алга киткәне иде.

Уфага күчеп килү, чыннан да, М. Насыйбуллинга нык тәэсир итә, ул эштә дә, урамда да, концерт-театрларда да татар теле, туган моңнар белән ешрак очраша башлый. Биредә чыгып килә торган «Кызыл таң» газитен йотлыгып укый. Нәкъ менә шушында яшәгән елларда каләменең йөгерекләнеп китүе дә табигый хәл. Ул көндәлек эшендә үзе очрап торган хәлләр турында хәбәрләр, очерклар яза башлый. Тора-бара хикәяләр иҗат итүгә килә. Тема шул ук: җинаятьчелек, аның сәбәпләре, мондый тискәре күренешләрне булдырмау юллары хакында уйлану. Әлбәттә, башта урыс телендә язарга туры килә. «Конец опасной тропы» дигән беренче китабы да 1968 елда Уфада урыс телендә басыла. Әлеге китап үзенең авторын берничә тәүлек эчендә танылган шәхескә әверелдерә. Җөмһүрият газитләре аның хакында мәкаләләр бастырып чыгаралар. М. Насыйбуллин бер нәрсәне ачык аңлый: язучы сүзе гаять җаваплы сүз икән.

Яшь язучы үзенең икенче китабын башкорт телендә әзерләргә мәҗбүр булды (ул вакытларда Уфада татар телендә китап бастырырга мөмкин түгел иде). «Енәйәт эззәреннән» («Җинаять эзләреннән») дип исемләнгән әлеге җыентык (1970) шулай ук зур кызыксыну белән укылды. Әмма язучы канәгать түгел. Яхшы фикерләрне үз милләттәшләренә туган телдә җиткерәсе иде бит. Ана теле белән кергән күңелгә ныграк оялый. Тырыша торгач, татар теле — аның төп теле булып китә. Бу эштә аңа Башкортстанда яшәп иҗат итүче язучылар Гайнан Әмири,

Хәким Гыйләҗев, Гали Ибраһимов, Расих Ханнанов, Суфиян Поварисов, Равил Шаммас һәм башкалар ярдәм итәләр. М. Насыйбуллин шул елларда СССР Журналистлар берлегенә әгъза итеп алына, Язучылар берлеге эшенә тартыла башлый.

Әмма М. Насыйбуллин бөтен күңеле белән үзе өчен тагын да газизрәк җир — татарларның чын мәркәзе Казанга тартыла. Ниһаять, житмешенче еллар башында форсат та туа: «Юстициянең өлкән киңәшчесе» дигән дәрәҗәле исем йөрткән мөхтәбәребезгә Татарстан прокуроры ярдәмчесе булып Казанга күчәргә тәкъдим итәләр. М. Насыйбуллин, куанып, туган җөмһүриятенә әйләнеп кайта. Татар мохите, туган телдәге радио һәм телевидение тапшырулары, көндәлек матбугат, кибетләрдәге һәм китапханәләрдәге татарча китаплар гаҗәеп сагындырган икән! Идел буеның шифалы җилләре сыман, алар аның җанына рәхәтлек өстиләр. Дөрес, җөмһүрият прокуратурасындагы эш бөтен вакытны ала. Иртәнге сәгатьләрдән алып кичкә кадәр иҗат турында уйларга вакыт та булмый. Житмәсә, еш кына районнарга, төрле шәһәрләргә командировкаларга йөрергә туры килә. Тәҗрибәле хокукчы буларак, башка җөмһүриятләргә һәм өлкәләргә дә ярдәмгә чакыралар. Вакытны күп алсалар да, мондый сәяхәтләрнең файдасы да бар, күңел яңа тәэсирләр белән тулылана, алар турында язасы да язасы килә.

Әдәби әсәрләр язуга ихтыяҗ тууның чыганаклары, каләмне эшкә җигүче көч кайда? Уйлап карасаң, бер дә әллә кайда түгел, шул ук үзе өчен барыннан да кыйммәтрәк булган намуслы кешеләрне яратуда, җир йөзендә иң кирәкле дип саналган хезмәтенә мәхәббәт белән карауда. Кешеләр белән рәсми бүлмәләрдә, җинаять урыннарында, хөкем йортларында сөйләшү бер нәрсә, ә менә аларны матбугат, китаплар ярдәмендә тәрбияләү, шулар нәтиҗәсендә гражданнарның хокук сагында торучылар белән җинаятьче буларак сирәгрәк очрашуларына омтылуда әдәби әсәрләр язуны тагын да үтемлерәк юл дип саный ул. Димәк, иҗатта да шул ук эшчәнлек дәвам итә. Хокукчы һәм язучы бер-береннән аерып ала алмаслык бербөтен булып әверелә.

Казанда яшәү чоры — М. Насыйбуллинның язучы буларак шактый тизлек белән чарлану еллары. Әйтергә кирәк, бу үсешле үзгәреш тиз бара, камилләшүгә илтә. Моңа, әлбәттә, татар мохитенең тәэсире зур була. Шул ук вакытта каләмдәшләренең хәерхаһлы мөнәсәбәтен дә истән чыгарырга ярамый. Бервакыт Мирсәй Әмиргә ул үзенең берничә хикәясен бирә. Күп тә үтми, алар Язучылар берлегенең китапханәсендә очрашалар, шактый озак сөйләшеп утыралар. Әдәбиятыбызның аксакалы яшь каләмдәшенең хикәяләрен хуплавын белдерә, аларда тормыш күренешләренең рәссам күзләре белән бәяләнүен сиземләргә мөмкинлеген әйтә. Әлеге әсәрләрне бер-бер артлы тоташтан уку ниндидер зур күләмле әсәр белән танышуны хәтерләтүен искәртә. «Сиңа,— ди ул,— зуррак күләмле әсәр, мәсәлән, повесть язарга вакыт житмәдеме икән?»

Әйе, тормышта да, иҗатта да бернәрсә дә үзеннән-үзе генә барлыкка килми. Сан сыйфат барлыкка китерә, дигән гомуми фәлсәфи канун бу очракта да үз көчендә кала. Моннан берничә ел элек аңа беркем дә повесть язарга киңәш итмәс, ул үзе дә моңа тотынмас иде. М. Әмирнең мондый тәкъдиме инде хәзер урынлы тоела.

Язучы өчен тагын бер мөһим сыйфат әһәмиятле. Ул тел остасы булырга тиеш. Татар язучылары арасында телнең академиклары булырдайлары бар. Г. Бәширов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Х. Сарьян, М. Мәһдиев, Ә. Баян... Ул әлеге әдипләрнең әсәрләрен укый, аларның эслүбен җентекли. Әдәби мәҗлесләрдә чыгышларын тыңлый. Х. Сарьян — классик шагыйрь Дәрдемәнднең «уеңны уйдырып сал» дигән шигъри юлын үзенә төп шигарь итеп алган әдип — каләмдәше М. Насыйбуллинны аеруча үз итә. Танылган прозаиклар А. Расих, Ә. Баян һәм Л. Ихсановалар тарафыннан аңа Язучылар берлеге әгъзалыгына керү өчен тәкъдимнамә бирелә. Моны каләменә ышаныч күрсәтү дип тә, олы иҗат юлына фатиха бирү дип тә кабул итә ул. «Аның мөмкинлекләре күп. Өметләнүемчә, ул әле укучысын файдалы, мавыктыргыч әсәрләр белән күп тапкырлар шатландырыр», дип яза А. Расих. Аның каләменең үзенчәлекләрен Л. Ихсанова да шактый дөрес билгели: «Ул вакыйгаларны ышандырырлык, мантыйклы, ихлас җәелдерә. Моның белән укучыларның да әсәрдә сурәтләнгән кешеләр кичергәннәрне хис итүләренә ирешә». «Язучы,— ди Ә. Баянов,— үзен мавыктыргыч сюжет төзү остасы итеп күрсәтте. Аның әдәби әсәрләре, китапларының каһарманнары уйлап чыгарылмаганнар, әсәрләренә тормышның үзеннән килеп кергәннәр. М. Насыйбуллинның әдәбиятыбызда үз мәүзугы, иҗади юнәлеше бар, ул тормыштагы төрле каршылыкларны оста тотып ала». Ә. Баянов, безнеңчә, дөрес әйткән.



1985 елда Бөек Ватан сугышында җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм иткән көннәр. Язучы Мәгъсүм Насыйбуллин *(ул уртада)* сугыш ветераннары белән бергә мәңгелек ут янында басып тора.

Шуны ышанып әйтергә мөмкин, каләмдәшләренең өметен аклады ул. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Югары Советы Президиумының 1986 ел, 2 гыйнвар Указы белән язучы Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллинга Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

М. Насыйбуллин иҗаты Мәскәү әдәбият белгечләренең игътибарыннан да читтә калмады. Менә шуларның берсе, «Современник» нәшриятының бүлек мөдире Н. Фомичев 1982 елда болай дип язды: «Безнең алдыбызда чын детектив, аерым алганда, социаль детектив. Чөнки автор бары интригалар һәм аларда хәрәкәт итүчеләрнең холык-фигыльләрен сурәтләп кенә калмый, шуның белән бергә, ул безнең җәмгыятьтә урын алган җинаятьчелекнең килеп чыгу сәбәпләрен сәнгатьчә тәфтишләп бирә. Төп кызыксындыру көче сюжет-вакыйгалар интригасында түгел, бәлки җинаятьне тикшерүне оештыру, алып баручың үзен җентекле һәм каршылыклары белән сурәтләүдә». М. Насыйбуллин иҗатының әлеге хасиятләре аның очеркларында һәм хикәяләрендә үк ачыла башлаган иде. Аларда бары тик җинаять кенә сурәтләнсә, бәлки, укучы өчен артык кызык та булмас иде. Ул бер әсәрне укыр, икенчесен... ә өченчесендә ялыга ук башлар. Бу исә әдәбият өнәми торган бертөрлелеккә китерер иде. Вакыйгаларга ябышып ятудан да иҗади уңыш көтеп булмый. Димәк, каладыр бер юл — ул да булса сәнгатьлелек ысулларын һәм чараларын баету, чарлау, кешене һәм аның рухи дөньясын сурәтләүнең яңадан-яңа юлларын һәм мөмкинлекләрен табу.

Гадәттә, детектив әсәрләрдә җинаятьтә шикләнелгән кешенең психик авыру икәнлеге билгеләнү аның кылганнары өчен җаваплылыгын йомшартучы нәрсә итеп сурәтлиләр. М. Насыйбуллин әсәрләрендә шул күзгә ташлана: ул, киресенчә, сорауны «акылы камил кеше мондый кара эшләргә сәләтлеме?» дип куя. Менә ни өчен ул сурәтләнүче кешеләрнең тормыш йомгагын сүтүгә, аларның холык-фигыльләре калыплану үзенчәлекләрен тәфтишләүгә аеруча игътибар итә. «Мондый нәрсәне психик авыру гына эшли ала, ул сәламәт, димәк, җинаятьне ул эшләмәгән», ди аның бер герое прокурор Садыйков. Мәсьәләне болай куюның әһәмияте шунда — һәр шикләнелгән кешедә җинаятьче күрергә теләгән кайбер тикшерүчеләрне кисәтү бу. Кеше язмышын хәл итүгә гаять тә җаваплы килергә кирәк, бары шулай эшләгәндә генә үзеңне хокук сагында торучы дип санарга мөмкин.

Һәр талантлы әсәр үзенә күрә тормышның яңа катламын ачып салу дип исәпләнә ала. Шулай да М. Насыйбуллинны укучыларга аеруча таныткан повесте «Телсез шаһитлар» дип аталганыдыр. Юк, эш биредә тасвирланган хәлнең вәхшилеге белән аерылып торуында түгел. Әлбәттә, бу кадәресе дә җәлеп итә. Әмма язучы өчен иң әһәмиятлесе — теге яки бу хәл-әхвәлгә мөнәсәбәтле рәвештә кешеләрнең төрлелеген ачу, кабатланмас холык-фигыльле образлар тудыру. Шунысы кызык, М. Насыйбуллин, җинаятьчеләрнең бер төрле генә булмавын җентекләп тәфтишләгәне кебек, тикшерүчеләрнең дә төрле-төрле икәнлеген ассызыклап күрсәтә. Яшь, әмма «борыны исне тиз сизүче» Гайнан Ибраһимов, Акбүләк район прокуроры Әсхәт Мөхәммәтшин, Чулпан район прокуроры Рәүф Саттаровлар — бөтенләй төрле кешеләр. Саттаров өчен эшнең канун хәрефенә ябышып яту хасияте булса, шул нигездә кеше язмышын хәл итүгә җиңел караса һәм иң аяныч — бөтен нәрсәдә үз шәхесе язмышын кайгырту алгы планга чыкса, Ибраһимов белән Мөхәммәтшин өчен барыннан да бигрәк дөреслеккә, гаделлеккә ирешү кыйммәт. Язучы боларны укучыга әзер нәтиҗә итеп бирми, бәлки шулай икәнлеген бик катлаулы мөнәсәбәтләрдә ача, әсәр белән танышучыларның акылына исәп тота.

М. Насыйбуллинга кадәр бездә тикшерүчеләр, милиция хезмәткәрләре бары тик уңай кешеләр, акыллы, төпле, гадел белгечләр итеп кенә сурәтләнделәр. М. Насыйбуллин исә алар арасында да үз эшен үтәргә сәләтсез, яки канунның хәрефенә ябышып ятып, кеше язмышын икенче пландагы нәрсә итеп караучыларның булуын да ачып салды. Нәкъ менә шушы язучыбыз тикшерүчеләр дөньясын шактый тулылыгы белән күрсәтеп бирә алды. Җинаять эшләгән кешенең иң әүвәлге омтылышы — үзне чәбәләндерү, аны каядыр икенче якка борып җибәрү. Тикшерүче исә бердәнбер дөрес юлга чыгаручы зәгыйфь кенә җепне булса да эләктереп алырга тели. Менә шушы тартышны, җинаятьче чәбәләндереп бетергән җепне сүтеп, бер йомгакка чорнаучы җанлы итеп гәүдәләндерү — детектив әсәрләр язучының төп бурычы.

Күрәбез, бер уйлаганда, детектив әсәр авторының иҗат өчен мөмкинлекләре чикле, әсәр схемасы алдан ук билгеләнгән. Биредә, теләсәң дә, теләмәсәң дә, ниндидер бер калып колы булу ерак йөрми. Тик М. Насыйбуллин әсәрләрендә бу чикләнгәнлек сизелми. Дөрес, вакыйгаларның төенләнеше һәм чишелеше кебек мондый әсәрләр өчен хас булган бертөрлелек аңарга шулай ук әллә ни киңәеп китәргә мөмкинлек бирми. Ләкин һәр кеше үзенә бердөнья булган кебек, теләсә кайсы җинаять тә бүтәннәреннән кайсы ягы беләндер аерыла. Шуның өстенә, язучы аларның моңа кадәр кабатланмаган яңа бер очрагын күрсәтүне максат итеп ала. Вакыт-вакыт аның әсәрләре драма жанрын хәтерләтә башлый. Аларны укыганда бүлектән-бүлеккә нервлар киеренкеләнә бара. Җыйнак, җегәрле диалоглар да бу охшашлыкны арттыралар. Ул повестьларны экранлаштыру яки сәхнәдә уйнау әлләни кыенлык тудырмас иде, мөгаен.

М. Насыйбуллин әсәрләренең яратып укылуы — хакыйкать. 1980 һәм 1982 елларда Татарстанда хокук саклау мәсьәләләренә багышланган әсәрләрнең укылу дәрәҗәсен билгеләү буенча конкурс уздырылган иде. М. Насыйбуллинның «Алтын алка» әсәре — беренче, ә «Ярканат» повесте икенче урынга чыктылар. 1988—1993 елларда җөмһүриятебезнең Милли китапханәсе шулай ук хәзерге татар язучыларының иң күп укыла торган әсәрләрен ачыклау буенча тикшеренү үткәрде. Шулар арасында М. Насыйбуллинның «Син тикшерүче бит» исемле китабы икенче урынны алды. Укучыларга таратылган сорауларга җавап алуның нәтиҗәсе тагын да күзгә ташланып тора. «Иң яраткан язучың кем?» дигән сорауга мең сигез йөз алтмыш өч кешенең дүрт йөз алтмыш өче М. Насыйбуллинны атый. Моның шулай икәнлеген укучы хатлары да раслый. Башкортстанның Яңаул районыннан Хәмит Халиков болай яза: «Мәгъсүм абый! Сез күзне ачтыгыз. Рәхмәт! Бер иптәшемнең тәкъдиме белән өч китабыгызны укып чыктым. «Их, шул кешеләр кебек булырга иде», — дигән уй туды миндә. Минем гаделсезлеккә каршы көрәшәсем килә. Юрист булган кешегә бу өлкәдә бик күп мөмкинлекләр бар икән». Шул ук җөмһүриятнең Октябрьск шәһәреннән Рамилә Әхмәтвәлиева дә шуңа охшаш фикерләр әйтә: «Мин сезнең «Юрист язмалары», «Без капчыкта ятмый», «Телсез шаһитлар» дигән китапларыгызны укып чыктым. Бу искиткеч әйбәт әсәрләрне укыганнан соң миндә тикшерүче булу теләге туды. Мин әле үз гомеремдә бер профессияне дә шулкадәр яратканым юк иде. Нинди изге икән ул тикшерүче һөнәре». Бу инде язучының иҗатына бирелгән югары бәя. Укучы хатларыннан күренгәнчә, М. Насыйбуллин әсәрләре белән байтак кешеләрдә хокукчы һөнәренә карата кызыксыну, хәтта мәхәббәт уята алган.

Кырымның Судак шәһәрендә яшәүче медицина фәннәре докторы Әнәс Хәсән уйлары да әлеге язучыбызның тормышына һәм иҗатына олы бәя булып яң-

гырый: «Мәгъсүм абый — Язучылар берлегенең танылган әгъзасы — китаплары, мәкаләләре белән хокукый, бәйсез мәмләкәтебез өчен хәленнән килгәнчә өлешен кертә. Җинаять — җәзадан аерылгысыз, укучыга шул фикер сеңдерелә. Элек «безнең Совет илендә җинаятьчелекнең социаль тамырлары юк!» — дияргә ярата идек. Баксаң, бар икән шул. Аның тамырлары бик тирән икән. Күрмәмешкә салышуның нәтиҗәләре яхшыга китермәде». Моның тамырлары, әлбәттә, рәсми хакимиятнең җинаятьчел сәясәтенә барып тоташа иде. Җәберзолымны ялган белән тоташтырды, халыкларның борын-борыннан камилләштерелгән әхлак системасын юк итте. Һәрбер әхлакның нигезен, әлбәттә, мәгълүм булганча, «үтермә!» дигән кагыйдә билгели. Кеше гомере мәңгедән иң кадерле нәрсә булып саналган. «Сталинчылар бу мәңгелек кагыйдәне сызып аттылар, әхлак нигезен дә таркаттылар», — дип нәтиҗә ясый М. Насыйбуллин үзе. Әйе, мондый абруйлы хокукчыларга илебезнең үткәндәгеләренә, белгеч буларак фәнни бәяләмә бирүне дә тарих үзе йөкләде. Күргәнебезчә, М. Насыйбуллин үзенең бу вазифасын да дәлилле, димәк, ышандырырлык итеп башкарып килә.

М. Насыйбуллин иҗаты каләмдәшләренең һәм әдәби тәнкыйтьчеләрнең дә игътибарын җәлеп итеп килә. Чөнки татар әдәбиятында детектив жанрына яңа сулыш өргән бу каләмдәшебезнең әсәрләре үзләре үк өйрәнүне сорап тора. Аның каләменең хасиятләрен тәфтишләүгә дистәләрчә-дистәләрчә мәкаләләр багышланган. Аларның авторлары арасында Татарстаннан З. Мәҗитов, Б. Камалов, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, Ә. Гаффар, С. Хәйретдинов, А. Расих, Х. Вәлиәхмәтов, Ш. Мостафин, Х. Сарьян, Ә. Сәхәпов, И. Фәйзуллин, И. Киндер, Ф. Шәфигуллин, Л. Хәмидуллиннарны; Башкортстаннан — С. Хафизов, С. Поварисов, М. Мөлековларны; Үзбәкстаннан — Н. Баракаев, Т. Хәмитләрне; Кыргызстаннан — Э. Калдаровны һәм башкаларны күрәбез. М. Насыйбуллин әсәрләре алда әйтелгән урыс, башкорт, татар телләреннән тыш, үзбәк, казакъ, каракалпак, чуваш, якут, удмурт, кыргыз телләрендә дә басылды. Иң отышлы әсәрләре, кытай һәм төрек телләренә дә тәрҗемә ителеп, чит илләрдә дә дөнья күрде. Ул төрле җөмһүриятләрнең әдәбиятчылары белән аралашуга, ул телләрдә чыккан әсәрләрне өйрәнүгә дә вакытын кызганмый. Еш кына әдәби бәйләнешләр хакында мәкаләләр язып бастыра. Аның татар һәм казакъ әдәбиятлары мөнәсәбәтләре хакындагы мәкаләсе Төркиянең Эрзерум шәһәрендә чыга торган «Кардәш әдәбиятлар» журналының 1992 елгы 21 санында да басылып чыкты. Дөресрәге, татар әдәбиятын үз иле укучыларына җиткерү буенча шактый эзлекле эшләүче Мостафа Өнәр аны «Казан утлары» журналының 1989 елгы 12 нче саныннан үзе тәрҗемә итеп бастырган иде.

Язучының төп иҗат йөзе, һичшиксез, аның әдәби әсәрләрендә ачыла. Ләкин ихлас каләм әһеле көндәлек хәлләргә дә мөнәсәбәтен белдерми булдыра алмый. Хикәя, повесть яки роман язганчы күп вакыт үтеп китә, ул укучыга барып ирешкәнче вакыйгалар кайнарлыгы суынып та өлгерә, сүзең вакытында теләгән кадәр файдасын китерергә өлгерә алмый. М. Насыйбуллин вакытлы матбугатка дөнья күргән чәчмә әсәрләрендә, мәкаләләрендә дә укучыларны, аеруча яшьләрне, әхлаклы, игелекле итеп тәрбияләүгә күп игътибар бирә. Әлбәттә, хокук тәрбиясе беренче урында тора. Гәзит-журнал битләрендә аның бу турыдагы язмаларына еш юлыгырга мөмкин. 1989 елда «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналы ел буе аның шушы мәсьәләләргә багышланган мәкаләләрен, хокук тәрбиясенең фәнни нигезләре турындагы карашлары яктыртылган язмаларын бастырып килде. Аларның исемнәрен генә искә төшерү дә авторның бу мәсьәләләр хакында колачлы фикер йөртүен күрсәтә. Алар: «Педагогика һәм хокук», «Хокукый дәүләт», «Җинаять сәбәпсез булмый», «Ничек тәрбиялибез?», «Теле барның иле бар», «Тапкансың икән — үзең бак» һ. б.

Үткен каләмле публицист буларак, ул татар халкының үткәндәге язмышын, бүгенгесен өйрәнеп, бигрәк тә киләчәген кайгыртып язган мәкаләләре белән җәмәгатьчелектә милли аң тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Шул хезмәтләр, бигрәк тә «Ватаныңның азаматы бул» дигән мәкаләсе, милләтебезнең киләчәген ирекле һәм бәхетле күрү юлында бөтенлекле караш буларак кабул ителә.

Гомумән, тынгысыз җанлы, ихлас милләтпәрвәр М. Насыйбуллин халыкка, аның алга барышына ярдәм итәрлек бер генә мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмый, аларны мөмкин кадәр файдалырак итеп эшкә җигәргә тырыша. Аның тарихка, әдәбият-сәнгатькә, фәннең төрле тармакларына караган хезмәтләрне өйрәнеп баруы — көндәлек шөгыле. Шундый вакытларда ул кызыклы гына табышларга да юлыга. Әйтик, аның кулына элек бездә әсәрләрен уку тыелган М. Булгаковның заманында Мәскәүдә чыккан «Дьяволиада» исемле хикәяләр

жыентыгы кёрэ. Андагы әсәрләр, аерым алганда «Чичиков мажаралары» («Чичиков совет шартларында») дип аталганы белән танышкач, М. Насыйбуллинның исе китә. Кара син ә?! Рәсәй империясенең егерменче гасыр азагында нинди хәлләр кичерәсен никадәр алдан күреп язу! Түзми, бу әсәрне татарчага тәрҗемә итә һәм аны башта «Кызыл таң», аннары «Татарстан хәбәрләре» газитләрендә (1991—1992) бастырып чыгара.

...Боларның һәммәсе аңардан һәрдаим армый-талмый хезмәт итүне, һәрвакыт иҗади халәттә булуны таләп итә. Язучы дигән олы исемне алгансың икән, димәк, халыкка хезмәт итүнең чиге була алмый. Чөнки ул синнән һәрчак төпле сүз, акыллы киңәш, туры юл күрсәтүне көтә.

Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллин жиде дистәне тутырып килгән бу көннәрдә, үткәннәренә борылып карап, зур канәгатьлек хисе кичерә ала. Гомернең яшәлгән кадәресе мәгънәле үтелгән, гаделлек, җәмгыятьнең сафлыгы, халык бәхете өчен көрәш белән дистә арты дистә еллар узган. Инде хәзер ял итәргә дә мөмкиндер. Әмма язучы йөрәге гамьсез була аламыни? Шуңа да язучы йөрәге бит ул!

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — 1996 ЕЛДА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

«Казан утлары» журналы 1996 елда сезнең игътибарга байтак кына кызыклы әсәрләр һәм язмалар тәкъдим итәргә җыена. Менә шулардан кайберләре:

**Тәлгат Галиуллин.** «Тәүбә». *Бүгенге көннәр романы.*
**Габдулла Шәрәфи.** «Тормыш арбасы». *Повесть.*
**Зәки Зәйнуллин.** «Ат караклары». *Повесть.*
**Фәүзия Бәйрәмова.** «Атылган йолдыз». *Пьеса.*
**Фәрит Яхин.** Мөхәммәт пәйгамбәр турында кыйсса. II китап.
**Рабит Батулла.** Мин Американы ачтым. *Сәяхәтнамә.*
**Әнәс Галиев.** «Хыял диңгезе». *Роман.*
**Ләлә Гыймадиева.** Әтием истәлекләре.
**Гурий Тавлин.** «Һәлакәт». *Роман.*
**Сәйфи Кудаш.** Дәрдемәнд турында истәлекләр.
**Шамил Маннап.** Тормыш хикмәтләре. *Зыялылар тормышыннан мәзәкләр.*
**Булат Солтанбәков.** Татар зыялыларыннан Ф. Кәрими, А. Шәехгали, Алкиннар, Сталинның сәркатибе булып эшләгән М. Бурундуков турында тарихи-документаль язмалар.

Шулай ук танылган галимнәребез һәм публицистлардан **Әбрар Кәримуллин, Индус Таһиров, Миркасыйм Госманов, Рафаэль Мостафин, Миргазиян Юныс, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди** һ. б. үзләренең яңа язмаларын тәкъдим итәчәкләр.

Тукай, Фатих Әмирхан һәм Мәхмүт Галәүнең тууына 110 ел, Муса Җәлилнең тууына 90 еллык уңаеннан да кызыклы язмалар белән танышырсыз.

Кыскасы, журнал битләрендә сезне кызыклы сәхифәләр көтә.
Язылыгыз! Укыгыз! Гел бергә булыйк!

## С. ДӘМИРӘЛНЕҢ М. ШӘЙМИЕВ БЕЛӘН ОЧРАШУЫ

14 сентябрьдә Анталиядә Төркия Президенты С. Дәмирәлнең Татарстан Президенты М. Шәймиев белән очрашуы булды. Очрашуда икеяклы хезмәттәшлек мәсьәләләре тикшерелде. Президентларның 1992 ел көзендәге беренче очрашуыннан бирле мәдәнният, икътисад һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлекнең яхшы үсешенә ирешелде, дип билгеләп үтелде.

Президент С. Дәмирәл Татарстанның Россия Федерациясе белән татулыкка Шартнамә нигезендәирешү сәясәтенә югары бәя бирде һәм Татарстанда алып барыла торган сәяси, икътисади курсны яклавын белдерде.

## ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ

10—14 сентябрь көннәрендә Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин житәкчелегендәге делегация Германиядә визит белән булды. Аның барышында «Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм Түбән Саксония Җире хөкүмәте арасында хезмәттәшлек турында килешү» төзелде. Анда Түбән Саксония Җире башкаласы Ганноверда һәм Казан шәһәрләрендә бергәләшеп икътисади вәкиллекләр ачу һәм Казан белән Ганновер шәһәрләре арасында турыдан-туры һава юлы элемтәсе булдыру да каралган.

Татарстан делегациясе составында Германиягә Җөмһүриятебезнең Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Татарстан халык депутаты Р. Мөхәммәдиев та барды.

## БМОның 50 ЕЛЛЫГЫ ХӨРМӘТЕНӘ

Мәркәзебездә Берләшкән Милләтләр Оешмасының 50 еллык юбилеена багышланган тантаналы жыелыш булып узды. Аны кереш сүз белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев ачты. Тантанада Россия Тышкы эшләр министрлыгының халыкара оешмалар департаменты директоры урынбасары А. Орлов, БМОга бүлышу ассоциациясе рәисе урынбасары Л. Минһаҗев, республикабызның милли һәм мәдәният җәмгыятьләре ассоциациясе вице-президенты Р. Сальянов, сугыш һәм хезмәт ветераны — рәссам, жырчы һәм композитор С. Вәлиева һ. б. чыгыш ясады.

Олуг юбилей хөрмәтенә «Берләшкән Милләтләр Оешмасы: аның бүгенгесе һәм киләчәге» дигән темага фәнни конференция үткәрелде, М. Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркының каеннар аллеясына «Дуслык агачы» утыртылды.

## ТАТАРСТАН XXI ГАСЫРГА АТЛЫЙ

Моннан ике ел элек Татарстан хөкүмәте белән Американың «Хьюз Нетворк Системз» компаниясе арасында республикабыз башкаласында һәм шәһәр-районнарында санлы, катнаш һәм күзәнәкле элемтә системасын гамәлгә ашыру турындагы контрактка кул куелган иде. Бер үк вакытта Германиянең «Алкатель-Сел» компаниясе дә бу гаять мөһим эшкә алынды. Инде уртак тырышлыкның беренче нәтиҗәләре дә күренә. Күптән түгел генә Татарстан Элемтә министрлыгы Казанда һәм Чаллыда санлы шәһәрара телефон станцияләре, Казанда ике яңа телефон станциясе ачылуны һәм күзәнәкле элемтә челтәрен гамәлгә кертүне тәгъдир итү-презентацияләү үткәрде. Башкалабызның «Азино-2» бистәсендә АКШ фирмасы җиһазлаган әлеге күзәнәкле элемтә станциясе — Татарстанда гына түгел, Россиядә дә бердәнбер. Дөнья стандартлары буенча ул иң алдынгы, иң ышанычлы, иң уңайлы элемтә системасы буларак дан тота. Шулай итеп, Татарстан хәзер элемтә буенча XXI гасырга аяк басты.

Шушы истәлекле вакыйга уңаеннан, Казанда, Россия, Татарстан һәм чит илләр журналистлары өчен, матбугат конференциясе оештырылды. Анда Татарстан Президенты М. Шәймиев, Россия Федерациясе Элемтә министры В. Булгак, Җөмһүриятебез Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, ТР Элемтә министры Р. Җәләлов, «Хьюз Нетворк Системз» фирмасы Президенты Дж. Шоу, «Алкатель-Сел» фирмасы вице-президенты Э. Танненберг һ. б. катнашты.

## ЧАЛЛЫ МЭРЫ АМЕРИКАГА ЖЫЕНА

Чаллы шәһәренең мэры Р. Алтынбаев «Бирменгем факелы» дигән абруйлы халыкара премиягә лаек булды. Әлеге бүләк аңа базар мөнәсәбәтләре нәтиҗәсендә килеп чыккан икътисади кыенлыклар алдында югалып калмаганы, социаль-икътисади процессларны нормальләштерүгә үзеннән лаеклы өлеш кертkәне өчен бирелде.

Лауреатны бүләкләү тантанасы шушы елның октябре азагында Бирменгем (АКШ) шәһәрендә булачак.

## ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАРНЫ ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Төркиянең Ататөрек исемендәге Культура, тел, тарих институты һәм Культура мәркәзе идарәсе 2000 елга кадәр төрек телендә һәрберсе 600 биттән торган 30 томлык «Төрки дөнья әдәбияты»н әзерләп бастыруны планлаштыра. Аның 13 томын

әдәбият тарихы, 8 җилдән антология, ягъни фольклор һәм язма әдәбият үрнәкләре тупламы, 5 томын «Төрки дөнья әдәбиятлары энциклопедиясе» һәм 4 җилдән «Әдәбият белеме сүзлеге» тәшкил итәчәк. Ерак Якутиядән һәм Алтайдан алып Балканга кадәр яшәгән төрки кавемнәренең фольклор һәм язма әдәбиятын үз эченә алган бинаһая бу зур хезмәт Төркия галимнәре һәм башка төрки мәмләкәт әдәбиятчылары тарафыннан язылачак.

12—15 сентябрьдә Анкарада «Төрки дөнья әдәбияты»н язуның проектын тикшерүгә багышланган халыкара симпозиум булды. Ана Төркия, Әзербайҗан, Үзбәгестан, Татарстан, Кыргызстан, Уйгырстан әдәбиятчылары чакырылган иде. Бу мәртәбәле киңәшмәдә доклад белән һәм фикер алышуда Казан университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты. Ул «Төрки дөнья әдәбияты» хезмәтен язуның рәис урынбасары итеп тә сайланды.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

28 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тууына 110 ел тулу юбилеена әзерлек мәсьәләләре, Т. Гыйззәт, Г. Ахунов, Т. Миңнуллин, М. Маликова юбилейларын уздыру һәм Азнакайда татар әдәбияты көннәрен үткәрү турында эшлекле сөйләшү булды.

Шул ук көнне Якуб Зәнкиев, Роза Мулланурова, Заһид Мәхмүди, Ләлә Сабирова, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Мөхәммәт Мирза, Мәрди Рафиков Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

## ҖӘЛИЛ ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

Билгеле булганча, киләсе елның 15 февралендә Муса Җәлилнең тууына 90 ел тулачак. Шул уңайдан, әлеге юбилейга әзерлек эшләре башланды инде.

Үзенең үлемсез «Моабит дәфтәрләре» белән дөньякүләм танылган шагыйрьнең туган төбәгендә исә мәһабәт һәйкәл куелачак. Танылган сынчы — үзебезнең Саба районы егете, хәзер исә Мәскәүдә яшәүче милләттәшебез Кадим Җәмитов эскизлары буенча Казанда коелучы ул һәйкәл Оренбург шәһәренең иң матур мәйданнарының берсенә урнаштырылачак. Бу эштә Татарстан хөкүмәте дә үзеннән зур булышлык күрсәтә.

## КОНКУРС ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ АТЫЙ

Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан үткәрелгән «Бөек Җиңүгә — 50 ел» иҗади конкурсына йомгак ясалды. Конкурста республика, шәһәр, район газеталарында, күптиражлы газеталарда, төрле журнал редакцияләрендә эшләүче журналистлар, язучылар катнашты.

Жюри «Казан утлары» журналының бүлек мөдире — язучы Шаһинур Мостафинның республика журналларында һәм газеталарында басылган очеркларын һәм документаль язмаларын беренче бүләккә лаек дип тапты.

Язучы Рашат Низамиев һәм «Известия Татарстана» газетасы хәбәрчесе Вадим Рәхимов исә икенче бүләкне яуладылар.

Өч өченче премия язучы-фронтовик Мөхәммәт Садригә, «Ватаным Татарстан» газетасының җаваплы сәркатибе Нургали Булатовка һәм «Гасырлар авазы» журналы хезмәткәре Хәмзә Зариповка бирелде.

Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасының штаттан тыш хәбәрчесе Михаил Михайлов, ветеран журналист һәм язучы Мәрди Рафиков, Мамадыш районының «Нократ» газетасы мөхәррире Зиннур Хәсәнов язмаларына кызыксындыру премияләре бирелде.

## МУСА МАЛИКОВКА — ГРАН-ПРИ

16—23 сентябрь көннәрендә Мәскәүнең яшьләр сараенда «Иртәнге йолдыз» («Утренняя звезда») телеконкурсының чираттагы тапшырулары булып узды. Анда республикабыз данын Казан консерваториясе каршындагы махсус урта мәктәп укучысы — 12 яшьлек җырчы һәм композитор Муса Маликов яклады. Милләттәшләребезгә яхшы билгеле сәнгатькәрләр — ирле-хатынлы Рөстәм һәм Гүзәл Маликовларның улы бу юлы да сынатмады — конкурсның җиде турында да уңышлы чыгыш ясап, Гран-Прига лаек булды. Абруйлы жюри әгъзалары — О. Газманов, В. Леонтьев, С. Моргунов һәм башкалар Мусаның башкару осталыгына югары бәя бирделәр.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Сәнгать өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының опера җырчылары Венера Әхмәт кызы Ганиевага һәм Зилә Даян кызы Сөнгатуллинага, Россия Федерациясе Президентының 1995 ел, 5 август Указы нигезендә, «Россия Федерациясенең халык артисткасы» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Әдәбият вә сәнгать өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен, шагыйрь Роберт Вәли улы Әхмәтҗанов (Роберт Әхмәтҗан), «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе», әдәбият галиме Фоат Галимулла улы Галимуллин исә «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәргә лаек булдылар.

# ЙӨРӘК КҮЗЕ

**«Аңларга теләп, бик күп диннәр хакында уйланып карадым мин: күп ботаклы агачка ничегрәк килешеп торалар икән соң болар, дидем. Адәм баласын икенче бер дингә көчләп кертмә икән, ул кәүсәгә ят ботак була. Төп кәүсәгә берексен ул. Менә шул чакта гына ул әһәмиятле зат булыр».**

*Хөсәен ибн Мансур әл-Хәлләҗ.*

Сәнгать тарихы хакында уйлана башласаң, күпләгән буыннарны әсир иткән татар шәмаилләре күз алдына килә. Күпме буыннарның сәнгати тәҗрибәсе бит бу! Урыслар гына түгел, татар халкы да юньләп белеп бетермәгән гүзәл сәнгать хакында сүз бара. Ихлас шигърият хакында!

Горурларның каршылыкларын аңлатып бетерә торган түгел. Бу соклангыч, гаҗәеп паннолар һәр татар йортының ишек өстендә эленеп торды. Аларны кадерләп сакладылар, буыннан буынга изге хатирә иттереп тапшыра тордылар... Совет хакимияте елларында йортта шәмаил тоту җинаять дип саналды.

Бәхет җиңде, бүтән чорлар килде. Шушы бөек сәнгатьне яңадан кайтару өчен дә шартлар туды.

Фәнни мәкаләләр күренә тора, сәнгать белгечләре шәмаилнең үзенчәлекләрен өйрәнәләр, журналларда шәмаил осталарының әсәрләре күренә башлады.

Борынгы сәнгатебезне яңартучылар арасында Чаллы рәссамы Фирдәүс Гыйльметдин улы Гыйрфанов та бар.

Азрак тарихка төшеп меник инде... Шәмаил сәнгате татарның тирән тарихларына кереп чума. Шәмаилләрнең гүзәл үрнәкләре Бөтен Болгар корылмаларына, кабер ташларына чукып язылган булган.

Шәмаил — сынлы сәнгать һәм графика әсәре. Аны Христоска багышлап иҗат ителгән иконалар белән генә чагыштырырга мөмкин. Христианнарның дини сәнгате белән чагыштырганда, мөселманнар изгеләрнең кыяфәтен сурәтләмәгәннәр, Изге китап сюжетларын да кешегә күрсәтмәгәннәр — Аллаһе Тәгалә сүзен — Коръән сүрәсен генә язып элгәннәр. Шуңа күрә дә татар шәмаилне «дога», «аятел-көрси» дип атый. Хәер, шәмаилләр арасында фәлсәфи әйтемнәр дә, үткен сүзләр дә, шигъри юллар да очрый. Мөселманнар өчен изге урыннарны сурәтләгән рәсемнәргә, бизәкләргә дә юлыгырга мөмкин.

Сез шәмаилләрдә тере җан ияләренең — кешеләрнең, хайван-җанварларның сурәтләрен күрмәссез. Ислам кешене сурәткә төшерүне тыя. Коръән моны кистереп тыймаса да, Пәйгамбәр хәдисләрендә әйтелгәнчә, «тере җан иясен сурәтләгән кешене каһәр суксын!» Коръән бары тик агачларны, чәчәкләрне, гомумән, җан иясе булмаган затларны гына сурәтләргә куша. Чөнки, Ислам әйткәнчә, кеше — Алла, Алла — кеше була алмый.

Шулай да, фәнни әдәбият белгечләренең әйтүенә караганда, сынлы сәнгатьләрнең барлыкка килүе Аллаһе Тәгаләгә һәм аның рәсүле Мөхәммәдкә бәйле икән. «Нәкышчеләр» сүрәсендә болай дип әйтелә: «Сынлы сәнгатьне кем башлаган, дип сорасалар, җавабың шушы булсын: Аллаһе Тәгаләнең рәсүле Мөхәммәдтән башланды ул!» Ә буяучыларның килеп чыгуы Коръәндә болай аңлатыла: «Җәбраил фәрештә утыз ике буяу алып килде, Мөхәммәдкә бирде һәм аны рәсем ясарга өйрәтте».

Тарихның төрле чорларында адәм баласын сурәтләүгә карата мөнәсәбәт төрлечә була торган. Исламның тере җан ияләрен сурәтләүне тыюы моның белән аңлатыла: Аллаһе Тәгаләдән башка беркемнең дә җан иясен бар итәргә хакы юк, Аллаһе яраткан җанны чынга охшатып сурәтләргә дә хакы юк аның. Андый эш кылганнар Аллаһе Тәгаләнең каһәренә дучар булыр. Ул үзе генә язмышларыбызны хәл кыла ала!

Ягъни, җан ияләрен сурәтләү Аллаһе Тәгалә эшенә тыкшыну булып саналган.

Татар шәмаилләрендә иң мөһиме — сүз. Гарәпчә әйтелгән сүз. Каллиграфия — матур язу сәнгате. Татар шәмаилләрендә бу сәнгать аерата көчле күренә. Гарәб язуы фикер алу өчен генә түгел, карап соклану өчен дә! Гарәп язуы фикерне бизи. Чөнки, Аллабызның Рәсүле Мөхәммәд болай дигән: «Аллаһе Тәгаләбез үзе күркәм, шуңа күрә дә ул матурлыкны ярата». Мөселманнарның зәвыгы әнә шуңа корылган. «Укый-яза белү — гыйлемлекнең яртысы!» — дигән Пәйгамбәребез. — Ә белем — өстенлек, Ходай Тәгаләбезнең бүләге!»

Фирдәүс Гыйрфановның эшләрен карагыз. Бу аның тормышка карашы бит! Ислам хакында, яшәеш һәм бу дөнья турында уйлануларының нәтиҗәсе.

«Кәгъбәтулла» дигән шәмаилен ул 1990 нчы елда Мәккәгә барып кайтканнан соң иҗат итте. Мәккәдәге изге йортны тәгәл сурәтләгән әсәр түгел бу. Ә бәлки Исламның изге урынын сурәтләгән символ! Таш өстендә алтын-көмеш нур балкып тора. Изге, серле таш шулай яктыра... «Борынгы йорт»тагы таш...

Таш тирәсендә — җиде бөҗра-кәгъбә ташын җиде тапкыр урап чыгу тамгасы. Биш багана — динебез кушкан биш васыять. Төсләр камиллеге ягыннан соклангыч ясалган шәмаил бу. Төсләр кискенлеге, балкышы шәмаилгә тантаналы, бәек төсмер биргән.

Ә барысы да балачактан башланган бит! 1952 нче елда уникe яшьлек Фирдәүснең әтисе базардан шәмаил алып кайтып, өйгә элеп куйган. Әлбәттә, ишек өстенә... Фирдәүс бу көнне әле дә онытa алмый. Ул шаккатып карап торган... Четерекле графикага сокланган ул. Иң гаҗәбе — шундый ук панно ясыйсы килгән малайның. Аның иң беренче «шәмаил»енә күршеләре дә шаккатып тел шартлатканнар. Аларга да ясап бирергә туры килгән.

Ул чагында алар Казан бистәсендә, үз йортларында яшәгәннәр. Электр уты юк. Кичләрен әтисе белән әнисе, җиделе лампа кабызып, гарәп хәрефләре белән язылган китапларны кычкырып укыйлар. Балалар тыңлый... Шул чакта ук Фирдәүс гарәп язуына мөкиббән киткән. Хәрефләрдән ясалган нәфис сурәтләргә исе киткән аның.

Ташкенттагы театр-сынлы сәнгать институтында укыган чагында сәнгатьнең бу төре егетнең күңелен тәмам биләп алган. Шәмаил сәнгатенең никадәр нечкә, катлаулы эш икәнен бик яхшы аңлаган ул. Моңа аерата зур осталык, белем, шигъри сизем кирәк. Менә шуңа күрә Фирдәүс шәрыкъ миниатюраларын, Бохарада, Сәмәркандтә, Казанда, үзебезнең борынгы Болгарда сакланып калган борынгы, сокландыргыч мөселман әсәрләрен җентекләп өйрәнергә тотынган.

...Аның күп төс белән ясалган шәмаилләрендәге күренешләр күңелне алгысытып куя. «Шәһри Казан», «Шәһри Болгар»... Төгәл сызыклардан чиксезлекнең үзен тоясың. Майлы буяу белән рәсемнәр ясаучы буларак та, ыстан композициясе остасы буларак та, оста үзенең һәр эшендә төс ярдәмендә ерракка юнәлүне күрсәтә белә. Аның бу сыйфаты безне аерата кызыксындыра. Борынгы шәмаилләргә сурәтне бер үк яссылыкка төшерү хас. Архитектурада гына түгел, гади әйберләрне сурәтләүдә дә күләмне күрсәтүгә омтылыш булмаган.

«Шәһри Казан» шәмаиле ифрат та нәфис, назлы төсләр якын тора, төсләр камиллеге нәкъ кирәгенчә. Сурәт сәнгатенә хас аһәң бар монда. Күләмлелек мәсьәләсен рәссам үзенчә, шартлы рәвештә хәл иткән. Бу манзарага үзенне кошлар очып узган биеклектән караган шикелле хис итәсең. Шуңа күрә бәләкәй генә бер яналыкта да катлаулы композицияләр күренә. Шул сурәткә берьюлы шәһәр манзарасы да, тулаем шәһәр үзе дә, экстерьерга хас бина бизәкләре дә күз алдына килеп баса.

Монда — Казанның уналты гасырлык гомере...

Шәмаилгә сеңгән барлык чалымнар халкыбызның канына сеңгән Сөембикә манарасы тарафына алып китә. Манара үзе илаһи сурәт белән чорнап алынган. Карагыз! Менә ул безнең Казанның борынгы кыяфәте! Сул кулда — Хан пулаты, уңда — сигез манаралы Җәмигъ мәчете! Күрегез: күпме юл ята безнең алдыбызда! Туры юлдан барсаң, Сөембикәнең үзенә барып ирешерсең. Җаныңда изге ниятле кешеләргә юл — шунда. Бер юл исә сезне хан пулатына алып килер. Икенчесе — мәңгелек чишмәләргә. Тагын берсе — кабер ташлары тезелеп торган зиратка.

«Шәһри Казан» шәмаиле рәссамның гыйлеменә генә таянганмы? Ә «Шәһри Болгар» шәмаиле? Рәссам хыялының күк гөмбәзе бу. Икенче «Шәмаил Мәккә»не күрү тәэсирләре!

Рәсемнең уртасында алтын капкалы Җәмигъ Мәчете балкып тора. Аның диварларын меңләгән бизәкләр яктырта...

Мәчет алдында — фонтан! Тормыш хаклыгының, мәңгелекнең галәмәте. Бер якта — Кара Пулат, икенче якта — ханнар зыярәте — Төрбә. Йорт бизәлешенең төрле өлешләре кабатлана тора, әмма алар үзенә күрә бер моңга әверелә: манаралар, бабайлар яшәгән йортлар, өсләре күккә укталган шәһәр капкалары...

Рәссам үзенең шәмаилләрендә шәрыкъ сәнгатеннән килгән борынгы йолаларны һәм Аурупа сәнгате ирешкәннәрне бергә куша белгән. Бу әсәрләрдә Аурупа төс һәм һавага бәйле күләм тойгысы булса, шәрыкъка гына хас төс төгәллеге, сызыкка сеңгән шигъри мәгънә, нәни генә мәйданда да бизәкнең гүзәллеген күрсәтә белү, үсемлекләрнең җанын тою, аларны сокландыргыч итеп сурәтләү хас.

Шәрыкъка хас булганга бар яссылыкка төшерелгән төсләр — борынгыдан килгән йолага хас. Халык иҗатының нәтиҗәләре бу.

**Рауза СОЛТАНОВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** Шәмаил. Авторы Фирдәүс Гыйрфанов.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы М. Насыйбуллин.

Д. Бунтуков фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




МИҢНУЛЛИН РОБЕРТ. **«Талбишек»:** *шигырьләр.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1995—478 бит. Тиражы — 5000 данә.

«Талбишек» — танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның М. Җәлил бүләге лауреаты, Андерсен исемендәге халыкара диплом иясе Роберт Миңнуллинның моңа кадәр чыккан китаплары арасында иң тулысы һәм иң күләмлесе. Китапка, нигездә, олылар өчен язылган шигырьләр, җырлар тупланган, һәм алар, элегрәк чыккан басмаларның сөземтәләре рәвешендә якынча хронологик тәртиптә урнаштырылганнар. Китап полиграфик яктан яхшы сыйфатлы итеп эшләнгән. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган 60 лап фотоиллюстрация теркәлгән. Китапка кереш сүзне шагыйрь һәм тәнкыйтьче Галимҗан Гыйльманов язган.

СӘЙФУЛЛИНА ГҮЗӘЛ. **Сәхнә бәхете.** Мөнирә Булатова.

Актрисаның шәхесе, тормышы һәм иҗат юлы турында очерк-монография. Нәшире — «Аккорд» акционерлык җәмгыяте. Казан: 1995, 152 бит. Тиражы — 5000 данә.




Мөнирә Булатова — татар халкының мәшһүр җырчысы, ярты гасыр диярлек М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында төп рольләрне оста башкарган сәхнә йолдызы. Ул, шулай ук, кабатланмас затлы тавышы белән Европаның зур театрларында да тамашачыларны әсир иткән җырчы. Монографиядә Җырчының иҗат юлы һәм иҗтимагый эшчәнлеге (М. Булатова — озак еллар буе татар әһелләре бүлегенең рәисе булып торды) үтемле тел, документаль дәлилләр белән бәян ителә. Китап заманча полиграфик ысул белән яхшы кәгазьдә басылган, күп кенә фотоиллюстрацияләр белән бизәлгән.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог